ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2003



# Tatarstan Respublikası Prezidentı

## UKAZI

### 2003 yılda Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət büləkləren birü turında





Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət büləklərе komitetı təqdimnəren qarağannan son, **qarar birəm**:

2003 yılda Tatarstan respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət büləkləren tübəndəgelərgə birergə:

1. Yazuçı **Məsəğit Mədərris ulı Xəbibullinğa** «Qubrat xan» kitabı öçen — Qazan, «Məğərif» nəşriatı, 2001 yıl.
2. Dirijor, başqaruçı **Rəstəm Yunıs ulı Abəzovqa** — S. Səydəşev, N. Cihanov, R. Yaxin, Ğ. Tuqay istəlegenə bağışlanğan konsertları həm «Cırçı — Rəstəm Abəzov», «Yubiley siklı», «La Primavera» premeraları», "Küŋel moŋı" konsert premeraları öçen.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

Qazan, Kreml', 2003 yıl, 25 aprel'

N UP- 293

# Казан утлары
# Qazan utları

*2003*

**6**

**(968)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Төнге юллар. *Роман* .......... 5
Шәүкәт ГАДЕЛША. И, Себер татарым, ни диим? *Шигырьләр* .......... 44
Әсгать САЛАХ. Каеннар юлы. *Повесть* .......... 47
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Дүртенче кыш. *Шигырьләр* .......... 101
Сәйдә ЗЫЯЛЫ. Тылсым. *Шигырьләр* .......... 104
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Алма. *Хикәя* .......... 107
Әнәс ИСХАКОВ. И гомер агышлары. *Шигырьләр* .......... 110

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Айдар ХӘЛИМ. Кырымда күргәннәрем .......... 113

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Милли реализм юлыннан *(язучы Ф. Латыйфига 60 яшь тулу уңаеннан)* .......... 134

**ФӘН**

Булат ГАЛИЕВ. «Төсле тоемлау»—могҗизамы, әллә гадәти бер «күз буумы»? .......... 148
Гүзәл САФИНА. Татар шигъриятендә синестезия күренешенә кайбер мисаллар .......... 150

**СӘНГАТЬ**

Марат ЗАКИР. Җан аһәңе .......... 154
Коръән татар телендә .......... 158

**ХӘТЕР**

Розалина НУРУЛЛИНА. Томаннарга еллар күмелде .......... 160

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Мулла абзый китап яза .......... 170
Рифат СВЕРИГИН. Нурзилә новеллалары .......... 174

**ЮБИЛЯРЛАР**

Рәмил ИСЛАМОВ. Нур аганың нурлы эшләре .......... 177
«Казан утлары» архивыннан .......... 182
Ләбиб ЛЕРОН. Аулак почмак. *Пародияләр* .......... 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


«Проза и поэзия»: Т. ГАЛИУЛЛИН. Роман «Ночные дороги» *(начало)*; повесть А. САЛАХА «Березовый сок»; рассказ Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «Яблоко»; стихи Ш. ГАДЕЛЬШЫ, Р. ИДИЯТУЛЛИНА, С. ЗЫЯТДИНОВОЙ, А. ИСХАКОВА.
«Публицистика»: А. ХАЛИМ. «Воспоминания о Крыме».
«Литературная критика»: статья Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ «По пути национального реализма» посвящена творчеству Ф. Латыфи.
«Наука»: статьи Б. ГАЛИЕВА «Что такое синестезия?» и Г. САФИНОЙ «Образцы синестезии в татарской поэзии»
«Искусство»: статья М. ЗАКИРА посвящена творчеству художника Э. Зарипова.
Коран на татарском языке
«Память»: Р. НУРУЛЛИНА «Ностальгия по прошлому».
«Книжное обозрение»: М. ВАЛЕЕВ рецензирует новую книгу Г. Галиева, Р. СВЕРИГИН—Новеллы Нурзили.
«Юбилей»: статья Р. ИСЛАМОВА к 75-летию литературоведа Н. Гиззатуллина.
Из фотоархива журнала.
«Юмор-сатира»: пародии Л. ЛЕРОНА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Золотая Орда. Работа художников И. Гаянова и Р. Калырова (Уфа); литературовед Рифат Сверигин.


## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*


"Prose and poetry": T. GALIULLIN. Novel «Night roads» *(begining)*, A. SALAH´s narrative «Birch sap», F. ZAMALETDINIVA´S story «Apple»; verses of SH. GADELSHA, R. IDIATULLIN, S. ZYATDINOVA, A. ISKHAKOV.
"Journalism": A. KHALIM «Recollection about Crimea».
"Literary criticism": D. ZAGIDULLINA´S article «By road of national realism» devoted to F. Latyfi´s creative works.
"Science": Articles of B. GALIEV «What is sinesteziya?» and G. SAFINA «Sinesteziyas models in Tatar poetry».
"Art": M. ZAKIR´S article devoted to E. Zaripov creative works.
Koran in Tatar language.
"Memory": R. NURULLINA «Nostalgia by the past».
"Books review": M. VALEEV criticizes new book of G. Galiev, R. SVERIGIN - Nurzilya´s short stories.
"Jubilees": R. ISLAMOV´S article the 75th anniversary of specialist in literature N. Gizzatullin.
From magazine´s fotoarchives.
"Humour-satire": L. LERON´S parodies.
The diary of social and cultural life.
On our covers: Gold Horde. The work of artists I. Gayanov and R. Kadirov (Ufa); specialist in literature Rifat Sverigin.



★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.



Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 19.05.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8031. Заказ Я—302
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2003 ел.



## Тәлгат Галиуллин

# ТӨНГЕ ЮЛЛАР

РОМАН

*Караңгының күзе,*
*Төннең сүзе юк.*
Халык мәкале

1

Нинди сөенеч, Әнисә, ниһаять, Казанга кайта. Казан каласына, йөрәк парәсе—улы Илдары янына. Чит илдә ясалган яшел төсле машина, чибәр хуҗасының ихтыярына буйсынып, барча йортлары калай түбәле олы татар авылы яныннан элдертә.

Әнисәнең үзеннән, дөньясыннан канәгать икәнлеге йөзенә чыккан, ул хәтта аның җитез хәрәкәтләреннән сизелеп тора. Бар җиһанны нурга төргән әбиләр чуагы исә хис-кичерешләрне яңартып, йөрәкләрне уйнатып, уйларны зирәкләндереп җибәрде, янә хаятнең, матурлыкның мәңгелегенә инандырды.

Бу минутларда аңа кемдер бәла-каза адәм баласын һәрчак сагалап кына тора, саграк бул, дисә, Әнисә моңа мәңге ышанмас, хәят арбам, машинам кебек үк, келтер-келтер итеп җайлы гына алга тәгәри, минем фани дөньяда дошманнарым юк дип кенә җавап бирер, радиодан яңгыраган татар моңы белән ләззәтләнеп, юлын дәвам иттерер иде.

Акрын искән мәҗүси җил ярым ачык тәрәзә аша сузылып, Әнисәнең кыска киселгән, зирек бөдрәләре кебек аксыл-коңгырт чәчләре белән уйный, рөхсәт мазар сорап тормыйча, алсу яңакларыннан сыйпый, борынын пәп итеп үтә.

Министрлык аны тиздән Мюнхенга алыш-биреш буенча җаваплы солых төзергә җибәрергә ниятли. Министр урынбасары белән күптән түгел булган сөйләшүне исенә төшереп, Әнисә бөтен гәүдәсе белән талпынып, рәхәтләнеп көлеп куйды. Тарихтан мәгълүматы төпле икәнлекне күрсәтергә

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН *(1938)—прозаик, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы; күпсанлы китаплар («Дәгъва», «Тәүбә», «Элмәк», «Шигърият баскычлары» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

теләп булса кирәк, ул чакта Ренал Ибраһимович шаяртып:

—Сине, Әнисә Мортазовна, анда җибәрергә дә куркам. Көн буе гел шул хакта уйланып йөрим әле,—дигән иде.

—Ни өчен күнелегезне шик корты кимерә дип белик инде?—дип сорады Әнисә.—Ирләре чибәр, дәртле диләрме әллә? Курыкмагыз, немецчам бик чамалы, тирәнгә кереп булмас.

—Хатын-кызның уенда шул гына, бозыклыгына исең-акылың китмәле, бар хәсрәтләре ир-ат.

—Ходай тәгалә безне шулай яраткан. Нишлисең инде,—диде ул, тыныч кына, Ренал Абдулловичның шаяртуын кабул да итмичә, кире дә какмыйча.

—Гитлер кебек сыра путчы оештырып куймагаең диюем иде. Ауропада болай да татарны дала баскынчылары дип кабул итәләр.

—Безне, татар халкын, Көнбатышта шулай яхшы беләләрмени?—диде Әнисә ихластан. Төркиядә, Кипрда, Болгариядә ял иткәләсә дә, рәсми икътисади шөгыль белән чит илгә чыгарга беренче җыенуы иде.

—Юк ла! Ялган тарихчылар тырышлыгы белән безне монголлар белән бутыйлар, явыз канэчкеч, чи ит ашый торган, камыт аяклы халык дип күз алдына китерәләр.

—Килеш-килбәтем белән мин татарга охшамаган ич,—дип Әнисә бераз чытлыкланып алды.

—Мондый озын, төз аяклы, фирүзәдәй зәңгәр күзле ханымны күргәч, Мюнхен бюргерлары безнең турыда фикерләрен кискен рәвештә үзгәртергә мәҗбүр булырлар дип уйлыйм.

Күзлеген кулына күчереп, сабын ирененә терәп, мәгънәле итеп өстәп куйды:

—Сине чит илгә барырга тәкъдим иткәндә, мәсьәләнең тарихи, сәяси ягын да исәпкә алдык.

Әйе, исәп-хисап хезмәткәре Әнисәнең тарихтан мәгълүматлары бугаз киереп сөйләшерлек түгел иде. Үткәндә булып узган вакыйгалар аны артык борчымый, нәрсәнедер белмәвен дә җитешсезлеккә санамый. Ихтыяҗ чыкса, белешмә китабын ал да кара, ни өчен әле бердәнбер башыңны чүп-чар белән дыңгычлап тутырырга, аның мөмкинлекләре болай да чикле. Аның уенча, хатын-кыз бүгенге көн мәшәкатьләре һәм балаларының киләчәге белән яшәргә тиеш. Икенче Бөтендөнья сугышы тудырган сәбәпләр, бу олы фаҗига турында аның укыганы, ишеткәне бар. Бабасының гомере шунда өзелгән. Булган-беткән, башка кабатланмасын, аның газиз Илдарына мондый йөрәк әрнеткеч хәлләрне күрергә, шунда катнашырга язмасын!

Улы исенә төшкәч, нечкә тукымадан тегелгән соры чалбарын төзәткәндәй итте һәм як-ягыннан кызыл, яшел, ак сызыклар уздырылган милиция машинасын күреп, табигый сизгерлек белән аягын газдан алды.

Юкка борчылган икән: юл сакчылары чибәр ханымга, аның Көньяк Кореяда ясалган машинасына бик мөкиббән китмәделәр. Ак «Жигули»ны туктатканнар да, йөртүченең кәгазьләрен тикшерәләр. Юлда була торган гадәти вә шомлы хәл. Узып киткән арада Әнисә кулына кәгазьләр тоткан таза гәүдәле ГАИ офицерын һәм аның янында ни өчендер борчылып, урыннарында тынгысыз биеп торган ике яшь егетне шәйләп алды. Машина йөртүчеләр арасында милиция хезмәткәрләренә мөнәсәбәттә үзара теләктәшлек, бердәмлек көчле булса да, һәркемнең үз кулмәге тәненә якынрак, «иншалла, мина бәйләнмәде» әле дип, аның тәртип сакчылары яныннан тизрәк китәргә ашыгуы табигый, монын өчен беркемне гаепләп булмый.

Юл буендагы машиналарны күнелдән генә сәламлап узганда, Әнисә ханым үз башына төшәчәк кызыклы һәм фаҗигале борчу-хәсрәтләр хакында, офицер янында биешеп торган гасаби затлар белән үзенә якыннан аралашырга туры киләсен, шул гарасат нәтиҗәсендә олы мәхәббәтенә юлыгасын күз алдына китерә алмый иде. Кешегә, кызганычка каршы, сиземләү, хыял даласына кереп китү хас булса да, алдан күрүчәнлек сәләте, киләчәген тәгаенләү бирелмәгән шул. Һәрнәрсәне алдан белеп яшәсәң, җиһанда яшәве күнелсез булыр иде.

## 2

Юл хәрәкәтен тикшерүгә бүген капитан Карам Сәгъдиев үз теләге белән чыкты, өстәл артында кәгазь кыштырдатып утыруны аның җене сөйми. Бөтен барлыгын милиция эшенә, дөресрәге, автомобиль инспекциясенә багышлаган, яшәешен, тормышын башкача күз алдына китерә алмаган, шунда хезмәт итү өчен туган адәми затларның берсе иде Карам. «ГАИ», соңрак «ГИБДД» сүзләрен әйтүгә, машина белән бәйле кешеләрнең күз алдына, тулы гәүдәсенә карамастан, терекөмеш кебек хәрәкәтчән, елгыр, әрсез, татарлар арасында сирәк очрый торган аксыл-җирән чәчле, сыек зәңгәр үткен күзле, машина йөртүчеләрне дер селкетеп торган Сәгъдиев килеп баса. Бу дөньяда шундый оешма яшәмәсә дә аны Карам өчен төзергә, уйлап табарга кирәк булыр иде. Аның явыз, усал эт кебек бәйләнчек дигән даны, дөресрәге, яманаты үзеннән, мәгълүм элемтә чараларыннан тизрәк йөри, халык иҗаты әсәрләре кебек, еллар дәвамында бер машина йөртүчедән икенчесенә тапшырыла килә, Ул хөкүмәт икмәген киң учларын чалбар кесәсенә тыгып, сыбызгысын чинатып йөреп кенә ашамый, йөкләтелгән вазифаларын, үзе аңлаганча, намус белән үти. Җаена, кәефенә туры килмәсә, бигрәк тә газиз башкайлары кышкы суыкка түзмәгән агачтай чатнаган вакытка туры килсә, бәхетсез шофер юк кына тәртип бозу белән кулына килеп эләксә, Карам аның җиде буын бабасының исемен әйттереп, желегенә төшәчәк. Аучылар кебек, агач, өй артына качып, үзләрен качып көткән дәҗҗал инспекция хезмәткәрләреннән гарык булган, бер-берсенә хәерхаһ шоферлар,—бигрәк тә яшь машина йөртүчеләрне кисәтеп куялар: «Дустым, син анда юлыңны күзәтеберәк бар, түгәрәк, итләч битле, таза гәүдәле капитан Сәгъдиев кулына эләгә күрмә, иманыңны укытыр! Аның чәчсез, һәрвакытта диярлек кызмача башы абстракт фәлсәфи фикерләрне кабул итми, шуңа күрә, дөньяныкын белеп булмый, кабинанда гәзиткә төрелгән ике «чуаш малаең», ягъни аракың ятсын. Акча алмый, башка бер аңлатманы кабул итми».

Чырае явыз, тавышы трубадан чыккандай көчле булып, усал кыланса да, Карам гадәттә эшне зурга җибәрми, юлда йөрүчеләрнең таныклыкларын алып калып йөдәтми, ягъни авылдан китеп, әле генә милициягә урнашкан ефрейтор яисә сержант кебек вакланмый. Холкын-фигылен белгән шоферлар, аны шәйләүгә, машиналарын читкәрәк куеп, янына хәл-әхвәл белешергә киләләр:

—Карам абый, нихәлләр бар? Исәнлекләрегез ничек?

—Яхшы, энем. Син кайсы районнан әле? Әтиең кем! Беләм, беләм.

—Карам абый минем ике «чуаш малае» белән бер кыздырылган кучат[1] барие. Кая куйыйм?

Сәгъдиев, йөз сиксән градуска борылып, кулы белән үз машинасының арткы ишегенә күрсәтә.

—Шуны ачып, акрын гына куй, энем. Үзең тиз генә ычкын! Күземә күренмә.

Бу мизгелдә ике яртысы белән кабымлыкларын ГАИ машинасына куюга рөхсәт алган шофердан да бәхетле кеше дөньясында юктыр. Дуслык күпере салынды дигән сүз. Карам авыз аша ашказанына төшә торган нигъмәтләрне ришвәткә санамый. Кулың чиста булсын, кесәдә утырып калмасын, өйгә ияреп кайтмасын...

Ак «Жигули»ны Сәгъдиев гадәти тикшерү өчен туктата. Машинаның урланган булуыннан, анда утырган ике егетне күптән җир бетереп эзләүләреннән хәбәрдар булмый, әлбәттә.

Кулын җәһәт кенә фуражкасына тидереп ала: «Капитан Сагдеев. Проверка документов».

Рульдә утырганы, озын буйлы, кара тут йөзлесе, кыска күн куртка кигәне—шоферлык таныклыгы буенча Ленар Сайганов дигәне—кесәсеннән бер пачка акча чыгарып, капитанга суза.

---

[1] Кучат—этәч. *Мишәрчә.*

—Менә шуны алыгыз да, безне җибәрегез. Бик ашыгабыз.

Сәгъдиевнең җен ачулары чыга.

—Сез нәрсә, мине сатып алырга уйлыйсызмы? Минем үз гомеремдә бер тапкыр взятка алганым юк. Машинагызга документларны күрсәтегез!

—Машина минеке түгел. Чаллыда яшәүче дустымныкы. Кәгазьләре бардачокта... Элек карамаган да идем.

Сүзгә икенчесе, җилкәгә кинрәге, озын чәчен артка, учмага җыеп бәйләп куйганы катнаша.

—Иптәш капитан, җибәрегез инде. Казанга, минем кызның туган көненә ашыгабыз. Акча алмасагыз... теләсә күпме штраф салыгыз. Квитанция кирәкми.

Мондый әрсезлекне көтмәгән капитанның мангаена, күз төпләренә тир бәреп чыга. Алсу кинчә янагы тагын да кызара төшә, күңеле нидер сизенә. Машина урланган-мазар түгелме? Ярдәм чакырасы булыр.

—Мин шоферны, машинаны тикшерәм. Сезнең белән сөйләшмим. Читкәрәк китеп торыгыз.

Күпъеллык тормыш, хезмәт тәҗрибәсе, егетләрнең үзләрен артык киеренке тотулары, акча тәкъдим итүләре капитанны сагайта: «Нәрсәдер бар монда. Чиста түгел. Егетләре дә гадәти күренмиләр. Йә берәр начарлык кылып, качып баруларыдыр. Салонны тикшереп карыйсы булыр».

«Ленар Сайганов» дигән таныклыкны сул кулында тоткан килеш, Карам машинаның арткы ишеген ачып, кабинаның эченә күз сала. Салон чиста, утыргычларга кечкенә паласлар җәелгән. Идәндә буш су шешәсе аунап ята. Утыргычка ташланган спорт чантасының өсте ачык. Үзе дә аңыштырып бетермичә, эчтән килгән тавышкамы, сиземләүгәме буйсынып, йөнтәс, олы уң кулын сумкага тыга, нииндидер чүпрәк-чапрак тартып чыгара. Бакса, хатын-кыз киемнәре, үтә күренмәле эчке күлмәк, кара бизәкле оек... Бу мәсьәләдә бик нәзберек капитан, чыраен сытып, киемнәрне кире ташларга дип кузгала, әмма эчке күлмәктә каткан кан тапларын, шундый ук кан эзләрен башка киемнәрдә дә күреп, элеккеге уеннан кайтып, чүпрәкләрне кулында тоткан килеш турая, сораулы карашын машина йөртүчегә юнәлтә. Киемнәр кемнеке, кан каян килгән дип сорарга нияте. Өлгерми. Ишекне ачып, әйберләрне тартып чыгарган арада, Сәгъдиевның янына ук килеп баскан кин җилкәле егет наган түтәсе белән бар көченә капитанның башына ора. Гәүдәсе чайкалып китә. Гөрселдәп аумый, әүвәл, шаярган кебек, бер тезенә чүгә, аннан, билгесез ханымның канлы эчке киемнәрен кочаклаган килеш, читкә, канауга егыла.

Капитанның һәр машинаны диярлек туктатып, җентекләп тикшерүенә күнеккән кече сержант Петр Глухов руль артында радиоалгычны боргалап утыра бирә. Карам абыйсының ыңгырашып егылганын гына ишетә. Озын чәчле егет, юл чатында яткан капитанның янына килеп, тагын нидер эшли. Шартлау-мазар ишетелми. Күрәсең, тавыш бетерү җайланмасын куйганнардыр. Ул да булмый, егет кискен борылып, Петрның машинасына ата башлый, арткы пыяла коелып төшә. Пистолет көпшәсеннән беренче ялкын күренүгә, саклану инстинкты хәрәкәткә килә. Глухов аска шуышып төшә, янына килүче булмый. ГАИ шоферы башын күтәргәндә, ак «Жигули» шактый юл алган була инде. Петр җәһәт кенә машинасыннан чыгып, үзен тикшерә, яра, кан күрмәгәч, капитан янына йөгереп бара. Авырлык белән Карамны аркасына яткыра. Сәгъдиевнең авызыннан күбекләр килә. Ике пуляның берсе күкрәгенә, икенчесе муенына эләккән. Үтерүче якыннан төзәп, белеп аткан. Ленар Сайганов таныклыгын үзе белән алган, хатын-кыз киемнәре җирдә, туфракта аунап ята, аларын җыюны кирәк тапмаганнар, ашыкканнар.

Бу сәер, фаҗигале манзара яшь егетнең күнелендә озакка калачак. Куелган вазифаңны намус белән үтәгәндә батырларча һәлак булу шулдыр инде ул.

Глухов әле имән төбе кебек нык, гренадердай таза капитанның үлеменә ышанмый, һаман «Карам абый, Карам абый, тор», дип пышылдый. Бераздан гына аңына килеп, мәнге төзәтеп булмаслык хата, явызлык эшләнгәнне

аңлап, машинадагы рациягә йөгерә, ГАИ постына хәбәр итеп, янәдән капитанның үле гәүдәсе янына килеп чүгәли. Ләкин миһербансыз явызлык тормышка, яшәешкә гашыйк, шат күңелле капитанны дусларыннан, гаиләсеннән аерып мәңгелеккә алып киткән була.

Казанга утыз чакрымнар калгач, кечкенә генә күперне чыкканда, күптән түгел ГАИ хезмәткәре туктаткан ак «Жигули» Әнисә машинасын куып уза да, аркылыга диярлек төшеп, туктый. «Берәр йомышлары бардыр» дип, Асылбаева тормозга баса. Озын чәчле егет ак машинадан яшен ташы тизлеге белән чыгып, йөгереп килеп, Әнисәнең чигәсенә пистолет көпшәсен китереп тери, уң кулы белән ишекне ачып, ханымны руль артыннан сөйрәп чыгара. Берни аңламаган ханым, хәтта куркырга да өлгермичә, машинасы янында торараштай катып, югалып кала.

Киң җилкәле егет, алтатарын курткасы эченә яшереп, Әнисәгә якын килеп, колагына усал итеп пышылдый:

—Хәзер без кушканны үтисең! Акыллы бул. Югыйсә, син—мәет.

Шул арада икенче егет—озынрагы ак «Жигули»ны текә яр буена борып, моторын сүндермичә, үзе сикереп төшеп, машинасын яр астына мәтәлдерә. Кызыл спорт сумкасын җилкәсенә асып, Әнисә машинасы янына йөгереп килә. Күз ачып йомарлык арада таза егет хатынны күтәреп диярлек элеккеге урынына утырта. Асылбаева як-ягына карап ала. Басып алучыларның озыны, үз машиналарын яр астына озатучысы, уң якка, алга хуҗаларча кереп оялый, корал тотканы артка чумәшә.

Елгыр ирләрнең кем икәнлегенә төшенә, үзенең шактый мөшкел, бәлки фаҗигале хәлгә дучар булуын аңлый башлаган Әнисә, аңына килеп:

—Машинамны алыгыз. Мине җибәрегез,—ди-ди, мәсьәләне хәл ителгәнгә санап (баш исән булсын, малы табылыр), ике утыргыч арасындагы кечкенә кара сумкасын алып, ишеккә тотына.

Алда утырганы, галәмәт олы танаулысы, күз ачып йомганчы, көчле бармакларын ханымның беләгенә батыра.

—Сумканны урынына куй. Машинаны үзең алып барырсың. Тиз бул, кабыз, киттек,—ди, тавышын кычкыру дәрәҗәсенә күтәреп.

Ак «Жигули»ның сәер хәрәкәтен, су буена төшеп каплануын, ике егетнең чит ил машинасына кереп утыруын, рульдә хатын-кызны күреп калган узып баручы КамАЗ шоферы беренче милиция постына хәбәр итә. Сержант Глуховның шомлы сигналы да килеп ирешә. Яшел төсле җинел машинаны эзләү башлана. Башка, мәгълүм җинаятьләре өстенә, милиция капитанын шул ук җаһилларның атып үтерүе шик тудырмый. Явызларның мәкерле җәтмәсенә бер гаепсезгә, чынбарлыкка, тирәлеккә ышанып яшәве, шуның нәтиҗәсендә кайбер нәрсәләрне уйлап-аңлап җиткермәве, язмышның шулай адәм баласы белән уйнап алырга яратуы нәтиҗәсендә, Асылбаева да коточкыч хәлләрнең бер чылбырына әйләнә.

ГАИ капитанын үтерүләрен күрмәсә дә, үзе сайлап алмаган юлдашларының явыз, мәрхәмәтсез адәмнәр булуын аңлавы кыен түгел иде. Өр-яңа «Жигули»ны аһ та итмичә, чырайларын сытмыйча, ярдан төртеп төшереп, Әнисәне машинасы өчен кулга төшерүләрендә югары профессионализм күренә.

Уйланырлык нәрсәләр бар иде. Асылбаеваның якыннары кисәттеләр: ерак юлга берүзең чыкма, һичьюгында иптәш ал, диделәр. Үз тискәрелеге үзенә җиткән, берәүне дә тыңламады: нәрсә булсын, зур трасса, көпә-көндез, машинасы ышанычлы... Ни пычагыма дип күпердә тукталды, тәрәзәләрне ябып, ишекләрне йозакка утыртып, артка биреп, узып кына китәсе иде. Татарга акыл төштән соң, янсә бәла килгәч керә шул. Үзен кулга алырга, курыкканын, каушаганын җаһилларга сиздермәскә тырышса да, киләчәгенең аянычлыгын аңлавы тәнен боламыктай итте, куллары бизгәк тоткандай калтырады, чарасызлык миен игәүләде, эчке сыкранудан колаклары чыңлады. Табигый чыдамлылыгы да ярдәмгә килмәде. Көтмәгәндә килеп туган бу гарасатның ни белән бетәсен күз алдына китерүе кыен иде. Ханым, үзенә сыгылып-сынып төшмәскә кушып, иреннәрен кысты.

Тормышыннан тулаем мәмнүн булып, киләчәккә фаразлар корып,

үзен унай бәяләп, башкарган эшеннән канәгать калып, улы Илдар янына кайтып барышы иде ләбаса, ике ятып бер төшенә кермәслек, сөйләсәң кеше ышанмаслык: көпә-көндез, тыныч Татарстан юлында мажара килеп чыксын имеш! Бер әшәкесе уң ягында кукраеп утырсын, икенчесе катырак суласаң да бердәнбер гомеренә нокта куярга әзер булып, муен тамырына кабер мисле салкын алтатар көпшәсен терәп барсын әле. Төшемме бу, өнемме дип үзенне чеметеп карарсың. Төш кенә булса түзәр идең әле: уянып, бисмилланны әйтеп, икенче якка борылып ятар идең дә, вәссәлам. Шыпырт кына юл күрсәткеч көзгесенә күз салды. Озын чәчлесе, муенсыз башы гәүдәсенә үк утыртылганы, үлем коралын әзер килеш, утыргыч биеклегендә тота. Бер ялгыш хәрәкәт, күңелләренә хуш килмәгән сүз булсын— кургаш кисәгенә куышыннан очып чыгу өчен җитә калачак. Ул Әнисә Асылбаеваның гыйнвар карыдай ап-ак тәненә кереп кадалачак. Пуля башсыз, мәнсез, аңа кем гәүдәсенә, кайсы әгъзасына керсә дә барыбер. Ул—явыз ниятне башкаручы, кеше гомерен өзүче кол гына.

Шул уйларыннан ханымның иркә, назлы тәне чирканып, электр тогына тигәндәй, калтыранып алды. Куркуы бөтен вөҗүде, йөрәге аша үтеп, аягына төште. Машинаны явызлар кушкан юнәлештә, тизлектә алып бару өчен аяклары, куллары кирәк иде. Юлны рәтләп белмиләр, картага караган булалар, бер-ике тапкыр тукталып, сораштырып та алдылар. Анда да берсе генә чыга—Әнисәне ялгызын калдырмыйлар. «Бирешмәскә, курыкканны сиздермәскә» дигән фикерне тәкърарлап, күңелен тынычландырырга тырыша ханым.

Алда утырганы бардачоктан аптечканы табып алып, тикшереп, кирәк санаган даруларны кесәсенә шудыра. «Димәк, машинада озак калырга уйламыйлар, үзләрен эзләүләрен, иртәме-соңмы табачакларын беләләр. Ә минем язмышны ничек хәл итәрләр? Гомер шәмем шулай билгесезлектә сүнәрме? Газиз әнием белән улым кайда югалганымны да белми калырлар микәнни? Машинам белән бергә ярдан төшереп җибәрерләрме, атып калдырырлармы? «Геройларча үлемем»не кайда табармын?»,—дип, үз-үзен сораулар биреп, юаткан булды. Газраилның салкын кулы маңгаенда торганда бик шаяртасы килми икән шул. Алда утырган колгасы авызын сыер кебек чапылдата-чапылдата нидер чәйнәргә тотынды. Арттагысы туктаусыз тәмәке суыра һәм нидер исни.

Әнисә музыка җибәргән булып, радиоалгычын кушмакчы иде. Җилкәсенә наган көпшәсе төртелде.

—Кирәкмәс! Тавыш яратмыйм.

«Сагыз» башына китте бугай, янында утырганы телгә килде.

—Син курыкма. Без милициядә эшлибез, особый отдел. Бик явыз «Үгез» кушаматлы рецидивистны эзлибез. Ул танымасын өчен, безгә бөтенләй чит машина кирәк булды. Син килеп чыгып, коткардың.

Артта утырганы көлемсерәп куйды:

—Ханымга барыбер. Казанына әйләнгеч юл белән кайтып килә.

Куркудан телсез калган, җаны үпкәсенә төшкән дип уйламасыннар дигән ният белән, явызлар сүзенә җайлашып җавап бирергә булды.

—Маршрутны үзгәртү кыен эш түгел. Җәяү бармыйбыз. Сезнең мина әлегә начарлык эшләгәнегез юк.

«Машинагызны гына әрәм иттегез»,—дип өстәмәкче булган иде, тыелып калды. «Бу үләтләрне котыртырга ярамый. Сак булырга кирәк. Әни әйтмешли, бүре кебек ач, елан кебек ялангач күренәләр». Озак еллар министрлыкта эшләү, төрле ширкәтләр белән аралашу, дәрәҗәле кешеләр арасында еш булу аны кайбер нәрсәгә өйрәткән иде. Иң мөһиме—тышкы тынычлыкны саклау, ваемсыз булып кылану. Мондыйлар шаһит калдырмыйлар, дип ишеткән иде. Үле кеше барча дөньяви серләрне мәңгегә үзе белән алып китә. Кеше юк—проблема юк, дигәнме әле бер тираны...

Әнисәнен яшел машинасын күпердә КамАЗ шоферы күрде, ул хәлләрдән хәбәрдардыр, милициягә дә хәбәр иткәндер, бәлки, тик аны кем эзләр дә, кем ярдәмгә килер икән? Егетләр үзләренен барыр җирләрен чамалап, машинаны олы трассадан чыгарып, каланы авыл юлларыннан—

әйләнеп үтеп, төрле сукмак-чокырлардан алып киттеләр. Җир коры, машина яхшы, юлсыз урыннардан куркып тормый, элдертә генә. Ана—ни, бензинны яндыруын белә.

Баскынчыларның үзара өзек-өтек җөмләләр белән аралашуыннан Әнисә «ГАИ» капитаны белән булган хәлләрне беркадәр күз алдына китерде. Шул хакта сүз чыкканда, үзара ачуланышып кискен-кискен генә әйткәләшеп тә алалар. Артта утырган озын чәчлесе яшьрәк иптәшен битәрләп ташлый:

—Блин, ни пычагыма теге хатынның эчке киемнәрен үзең белән алдың? Шулай яраттыңмыни? Трусигын кулына алып, күз алдыңа бәхетле минутларны китереп, ләззәт таптыңмы? Пычрак чүпрәкләр аркасында яндык. Шулай ук яратсаң, үтермиләр аны, понтың юк.

—Син чәй чүбен чәйнәп ачуны китермә! В натуре. Кем уйлаган офицер кисәге сумкада актарыныр дип. Мин ул хатынның киемнәренә иялаштем. Эчке күлмәкләренә карыйм да, чибәр гәүдәсен күз алдына китерәм.

Артта утырганы: «тсс» дип, пистолет көпшәсен иреннәренә куйды.

Әнисәнең йөрәге «жу» итеп китте. Димәк ки, аның «сөекле» пассажирлары гади үтерүчеләр генә түгел. Хатын-кыз белән пычрак алымнар белән эш итүчеләр. Йа, Ходам, улымны да күрә алмыйча, үлемемне табармын микән? Әнием, ник мине шундый бәхетсез итеп тудырдың бу фани дөньяга? Ярый ла, интектермичә, җәфаламыйча, көчләмичә атып кына үтерсәләр. Синең дә тәнеңне назлаган эчке киемнәреңне менә шул пычрак, сасы сумкада кадерсезләп, аунатып йөртсәләр? Бәлки, зур тизлектә машинаны ярдан аска ташларга, берәр баганага, агачка алар утырган ягы белән китереп бәрергә? Әнисе «кеше курыкмый булмый, куркак булырга гына ярамый», ди торгание. Бу селәгәйләрдән газиз тәнеңне, рухыңны рәнҗеттергәнче, фаҗигале үлемең артык. Тик бу ике аяклы хайваннарны исән калдырырга ярамый. Гөнаһлары, кылган явызлыклары бинибһая күренә. Күзләре нәкъ ач бүренекедәй усал, дөньяны йотардай булып ялтырый.

Усал ниятен тормышка ашырырга уйлагандай, эңгер-меңгердә (утны кабызырга рөхсәт бирмиләр) урман кырындагы чокырны Әнисә шәйләми калды. Сикертү шактый көчле булып, башлары түшәмгә тиде. Кулында корал тотып баручысы ямьсез сүгенеп куйды.

—Син нәрсә, падло. Блин, карап бар, хәзер нечкә муеныңны үтәдән үтә чыгам. Безне үтерергә хыялланасыңмы әллә? Без, абыстай, тиз генә кәнкәя торганнардан түгел. Синең кебекләрнең, яшьрәкләрнең рәхәтен күреп, теге дөньяга шактыен озатырбыз әле.

—Берни күренми. Ут алырга иде,—дип зарланып алды ханым.

Сөйләшү-анлашулар аның файдасына бармый. Күнелендәген сизенделәр бугай. Юлны ак болыт шәүләсе генә яктырта ала. Ае да, оялгандай, бу әшәкеләрнең шаһите булырга теләмәгәндәй, күренеп-күренеп кенә ала да, янәдән, каядыр ашыккан ак сарык көтүедәй болытлар арасына кереп югала.

—Беләсеңме, чибәр апа, син бәхетле, без ашыгабыз, башка вакытта булса без сиңа заманча фокусларны базарсыз күрсәткән булыр идек.

—Егетләр, мин сезнең өчен карт инде. Әнә нинди чибәр яшьләр үсеп килә.—дигән булды Әнисә .

—Хикмәт анда түгел. Ярый, теленне озайтма. Әнә теге тар юлга чык!

Әнисәнең урлаучыларына буйсынып, алар кушканны үтәүдән башка чарасы юк, ул бүген үтерүчеләр кубызына биергә тиеш. Нишләмәк кирәк. Шул арада артта утыручысы яна боерык индерде.

—Машинанны унга бор, урманга кер, бу аланлыкны уз, әнә теге вак куаклык арасына кереп бас. Сүндер, рульдән чык, ачкычларны миңа бир!

Боерыклар бозлы янгыр кебек шапылдап төшеп кенә тора.

Алда утырган озыны Әнисәнең крокодил тиресеннән тегелгән кечкенә сумкасында актарына башлады. Урыс акчаларын чалбар кесәсенә йомарлап тыкты. Шоферлык таныклыгын укып, исем-фамилиясен хәтерләргә тырышып, кире урынына куйды. Кесәдә чит кеше, бигрәк тә хатын-кыз документын йөртүнең мәртәбәле эш түгеллеген белә иде ул.

—Әнә шул юан нарат янына барып бас! Качарга уйлама,—дип, наганын һавага чөеп, тотып алды. Пуля синнән тизрәк оча дип кисәтүе булгандыр кабихның.

Ялгыз утырган юан, озын нарат агачы кырына килеп басып, Әнисә уң кулын наратның кытыршы каерысына куйды. Талгын жылылык, илаһи тынычлык килгәндәй булды. Ялгыз агач белән үз шәхесе арасында мәҗүси якынлык, хисси бердәмлек тойгысы сизде бичара ханым. Күпне күргән агач аны үз итте, рухын ныгытты. Күрәсең, бандитлар аны, буш шешәгә аткандай, кызык табып, үтерергә җыеналардыр. Йөрәккә тидерә алсалар, интекмичә, җәфаланмыйча, наратны кочаклап вәхшилек белән тулы кырыс дөньясын ташлап китәр иде. Язмыштан узмыш юк, күрәсең, тәнемә генә кагылмасыннар. Ходаема соңгы үтенечем калды.

Киллерлар, күзләрен Әнисәдән алмыйча, үзара киңәшеп, сөйләшеп, хәтта бәхәсләшеп алдылар. Билгеле бер карарга килгәч, өлкәнрәге Әнисәне чакырып алды.

—Хәзер машинаңа кереп, руль артына утыр. Ачкычларны үзебез белән алабыз. Сине борчып тормасыннар. Тиздән кайтырбыз. Артур, утыргычка, рульгә ныклап бәйләп куй чибәр түтине, оеп утырсын шунда. Алдан күңелен күреп, үзен соңыннан хәл кылырбыз.

Үзен юлга карап баргандай гына тотса да, Әнисә хатын-кызга хас сиземләү белән, янында утырган озын буйлысының аның ягына комсыз караш ташлап алгалаганын тоеп барды. Әнисә ир-атның күзен кыздырырлык иде шул. Шактый мул күкрәге, аякларының чалбар да яшерә алмаган төзлеге, аккошныкыдай озын муены дисеңме, барысы бергә ханымны бизиләр, табигый матурлыгын ассызыклап торалар. Хатынның кулларын артка каерып, утыргычка бәйләп куйгач, егет үзен хуҗаларча тотып, рәхәтләнеп Әнисәнең күкрәген капшады, татлы иреннәреннән үбәргә маташты. Ханым йөзен читкә алырга тырышып, ризасызлыгын белдерүдән уза алмады. Язмышы кыл өстендә торуын аңлап, йомры сүзләр байлыгын ярдәмгә чакырмаска акылы житте. Фани дөнья белән алыш-бирешне өзү, гомер капусын томалау өчен бер ялгыш адым—кирәкмәгәндә очып чыккан сүз житә иде.

Кораллысы озынның ханым янында озак маташуын хупламады.

—Киттек тизрәк. В натуре, туя белмәдең хатын-кыздан. Кайткач, иркенләп, туйганчы иркәләрсең, изәрсең үзен. Миңа да калыр әле. Жирән безне шул станциядә көтәргә тиеш. Азык-төлек алырбыз. Тамак та кипте. Авызына чүпрәк тыктыңмы? Төртеп чыгарырлык, кычкыра алырлык булмасын! Тончыгып үлсә, тапкан кеше күмәр.

Әнисә ягындагы тәрәзә генә яртылаш ачык калды. Ашыгып, онытгылар бугай.

3

Явызлар Әнисәне утыргычка ныгытып бәйләсәләр дә, бер мәсьәләдә көчсез иделәр: аның зиһененә, уйлану, хыяллану мөмкинлегенә богау сала алмадылар. Хәтер—кешене башка жан ияләреннән аерып торган иң олы бәхете, казанышы, байлыгы һәм тулы мөстәкыйльлеккә ия дәүләте. Вакытны тизрәк үткәрү нияте беләнме, тормыш юлына мәгълүм нәтиҗә ясарга омтылыпмы, ханым хәтер канатында үткәненә—кадерле балалык, яшьлек елларына әйләнеп кайтты, әнисенең, әтисенең язмышын, үзе үткән чирәмле һәм тузанлы юлларны искә төшерде. Шулар белән чәбәләнеп, вакытның узганын сизми дә калды...

Гомеренең байтак өлеше авылда, Казан артында узса да, Әнисә калада, студент гаиләсендә туа. Дөресе, әниләре ике игезәк кызны ифрат жаваплы чорда—дәүләт имтиханнарын биргәндә таба. «Шуна күрә, кызым, укуга бик һәвәс булдың, барча фәннәрне жиңел үзләштерден»,—дип шаяртырга ярата иде әнисе—Шәмсия ханым. Янәсе, аның шул чордагы белеме корсагындагы кызына иңгән.

Әнисе, үзе кат-кат сөйләгәнчә, язмышы кызыгырлык, көнләшерлек

булмый. Яшьли ятим кала. Әтисе, өч баласын чирле хатынына калдырып, 1941 елның июлендә сугышка китә. Сентябрь аенда аның, Ватанны саклап, батырларча һәлак булуы турында кара хәбәр килә. Болай да тамагына берни каба алмаган, баллы чәй белән яшәгән Зәйнәп апа шул кайгыны күтәрә алмыйча, мәңгегә күзләрен йома. Әтиләре ягыннан, үзе дә сугышка алынмаслык дәрәҗәдә өлкән яшьтәге, шулай ук күп балалы абыйлары, соңгы көннәре килеп җитүне сизенгәч, ятимнәрне интернатларга тарата. Бер үк ата-ана балалары, үзара аралашмыйча, туганлык хисләрен татымыйча, төрлесе төрле якта үсәләр.

Балалар йортында, интернатта тәрбияләнгән кеше әрсез, усал, күзенә арыш кылчыгыдай кадалып булса да, үзенә кирәген суырып ала, әмма кешене нахакка рәнҗетми дигән фикер тулаем дөрес булса да, бу катгый фикер Әнисәнең анасы Шәмсиягә кагылмый. Ул явызлыкка, усаллыкка, хәрәмләшүгә өйрәнергә теләми, андый начар гадәтләрне табигате кабул итми, басынкы, күндәм, ярдәмчел, ләкин мөстәкыйль холыклы, хәтта үзсүзле булып үсә. Күрәсең, таза, сәламәт нәселдән чыккан баланы тирәлек, мохит кына сындыра алмый. Ата-бабадан килгән акыллы табигать җил-давылларга, хөсет йогынтыларга бирешмичә, нәсел орлыгын саклый.

Шәмсия, озын буе белән мактана алмаса да, күкрәге, билдән түбән өлешләре, тәне, аяклары йөзенә кызыллык китерерлек булмый. «Инеңбуең бер булып бара, апаем»,—дип үртәүчеләргә артык исе китми, рәнҗеми, сыктанмый.

—Интернатта көненә өч кат маргаринга манчылган макарон, аратирә бәрәңге ашап кара да, тазарма, имеш. Безнең Рәсәй токмачы бит ул ефәк җеп калынлыгындагы итальян спагеттие гына түгел. Буйга килгәндә, алдан—тәбиячеләр күлмәктән чыгасың, өскә тартылма дип, башка төеп торсалар, аннан—кыска тимер караватат үсәргә ирек бирмәде. Ялангач тәпиләрне, минеке төсле җыйнак булсалар да, тышка чыгарып яту кыз кешегә килешми. Хөкүмәт караваты буйлы гына калырга туры килде. Сайрар кошлар зур булмый. Сизеп торам, ирем кое колгасы кадәр озын булыр, утырып йә ятып үбешергә туры килер,—дип, кызык эзләп йөрүчеләрнең авызын шук тәгъбирләре белән яба да куя.

Ятим баланың догасын, теләк-ниятен Хак тәгалә тормышка ашыра, кабул итә, диләр, һәр адәми затның тирәндә, аң төпкелегендә яткан, ахыргача мәгънәсен аңлап, бәяләп житкермәгән хыял дагасы була. Шәмсиянең алар икәү иде: берсе дөнья гизеп, тау түбәләрен буйсындырып, төрле халыклар белән очрашып, Пржевальскийлар кебек, яна тәр атлар чыгару. Шул гоманы аны Казан педагогия институтының география факультетына алып килә. Икенчесе—ире ягыннан әти-әниле, тулы гаиләдә яшәү. Үзеңнеке булмаганда, кешенеке кадерле дигәндәй, ул иренең әнисен—каенанасын, бианасын өзелеп яратыр, сүзеннән чыкмас, буранлы кичләрдә башын аның иненә куеп, мичтә чатыр-чытыр янган агачларга карап утырыр. Адәм баласы гел иркәгә мохтаҗ шул. Ә назның чыны, кан тибешенә үтәрдәе, жанга ятардае сирәк була икән.

Буе кыска булу сәбәпле, Шәмсия егет халкына өстән карап, эреләнеп йөри алмады; тупас кыланмыйча, әмма тирәнгә җибәрмичә, «үз кабыргаларыннан ясаткан» җенес вәкилләре белән очрашып, аралашып яшәде. Иптәш кызы Марина әйтмешли, «үпкән кочкан жилгә очкан, иреннәрне картайтмас өчен үбешеп яшәү лязим». Кинога кеше көлдереп үз акчаңа йөрмәссең ич, бигрәк тә, читтән килерең булмаганда. Борчу-хәсрәтен иненнән ташлар өчен генә очраштырып йөргән уенчак егетләрнең берсе дә Шәмсия күңелендә житди эз калдырмый, жанын тетрәтми, хис-кичерешләрен ярларыннан чыгарып ташламый. Ул үз өлешен, үз көмешен көтә. Яшьлегенең кайнар тояк чаткыларын аның өчен саклый, мәңгелек яры булырлык икенче яртысы табылуга шикләнми.

Өметкә сусаган көннәрнең берсендә, инде дүртенче курсны «аударып» килгәндә, «монастырь» дип йөртелгән тулай торакның беренче катына, танцыга төштеләр. Барысы диярлек таныш йөзләр, бичарадан ничара гына бииләр. Бер мәлне урамнан бер төркем егетләр килеп керә. Беренче булулары

түгел күрәсең , үзләрен кыю тотып, кызларны биюгә чакыра башлыйлар. Араларыннан берсе, кырда үскән ялгыз озын, төз агач кебек, барысынан да аерылып, баш ярымга өскәрәк күтәрелеп тора. Шәмсия егетнең йомры башыннан күзен ала алмый, күзенә чалынырга тырыша, мәгәр озынрак буйлы кызлар аны каплыйлар да куялар, ул янәдән аларны төрткәләп алгарак чыгарга итә. Кыз гомерендә беренче мәртәбә кыска буе өчен гарьләнә. Хатын-кыз вальсы игълан ителгәч, булачак географ, ике уйлап тормыйча, безнең баш кая гына югалмаган дип, «колганы» биергә чакыра. Теге әүвәл озак итеп өстән аска карап тора, кызның чибәрлеген, ике якка аерылып торган күкрәкләренең килешле муллыгын бәяләп һәм хуплап, мәйданга чыга. Кулларын кызның биленә төшереп кую теләге туса да, үзенә төбәлгән күзләрнең житдилеге бу уеннан чигенергә мәжбүр итә. Озын куллар Шәмсиянең иннәренә яткач, «колга» янындагы кыз тагын да бәләкәйләнеп, дөя янындагы пони атыдай торып кала. Егетне биюгә чакыргач, сүзне ул башларга тиештер инде. Бар кыюлыгын теленә күчереп:

—Минем исемем Шәмсия,—ди кыз, балет биючесе кебек, бармак очларына күтәрелергә тырышып.

Егет жавапка кесәгә кереп тормый:

—Ә мин Мортаза абый булам.

—Ни өчен абый?

—Күрмисезмени, мин сездән икегә үк булмаса да, бер ярымга озынрак. Буе белән мактана дип фараз кылган табигать бизәгенең кытыгы килә.

—Озынлык акыллылык билгесе саналмый кебек?

—Каян беләсез? Бәлки.

—Жирафны берәү дә иң акыллы, иң зирәк хайваннар рәтендә йөртми.

—Мина кушамат та тактыгызмы?

—Мин—булачак географ,—дип, Шәмсия егетнең реакциясен белергә теләп, күзләренә карамакчы була, әмма ияк асты белән, оешып бетмәгән ияк чокырчыгыннан башка нәрсә күрми. Халык «бер карыймын йөзләренә, икенче күзләренә», дип, юкка гына әйтми торгандыр. Кызның эчке ымсынуын сизгәндәй егет башын аска ия. Төсләрен билгеләп өлгерә алмаса да, күзләре ягымлы, назлы, нурлы, дигән фикергә килә кызый.

—Сезнең комплиментны, иптәш кем... Шәмсия, ми казанына салып куйдым. Бүртә торсын.

Кыз жавап бирергәме, гафу үтенергәме диебрәк уйланып торган арада, хәерчегә жил каршы дигәндәй, бию көе бетә. Күнеленә хуш килмәгән егет танцыга чакырганда музыка гомергә бетмәс кебек тоела. Ә бу юлы нинди кыска булды. Иптәш кызлары янына Шәмсия вак-вак атлап, озаграк барырга тырыша, бәлки, егет озатып куйган арада яна жыр башланыр. Юк шул, дөнья без теләгәнчә генә бармый, шайтан алгыры.

Музыка бик озак уйнамыйча тора. Килгән егетләр каядыр югалып алалар. Шәмсия бөтенләй сөмсере коелып, бәхетсез яшьлеге турында ялгыз аккоштай кангырап, тәрәзә асты тактасына сөялеп торган мәлдә, кемдер аның жилкәсенә кагыла. Күтәрелеп караса, ап-ак, тешләрен ялтыратып, Мортаза басып тора. Астан күтәрелеп караганда, иләмсез озын күренә, аз гына сузылса, башы матчага тияр дигән тойгы кала. Мортаза, күптәнге танышлар аралашкан кебек, «син»гә күчә.

—Мин сиңа тоже кушамат таптым.

—Нинди?

—Әлегә әйтмим. Ир белән хатын булып яши башлагач, бик ачуны китерсән, шунда әйтеп салырмын.

Шәмсия баскан урынында сикереп куйгандай, кемдер нечкә йөрәк кылларын чиертеп уяткандай була. Шатланырга кирәктер, бәлки, ә аның жен ачулары чыга. Кара син бу жирафны, нинди нахал булып чыкты. Буе кечкенә дигәч тә, үз горурлыгыбыз үзебезгә житкән.

—Сез ни сөйлисез, тузга язмаганны? Исерекме әллә? Сезгә кем рөхсәт иткән үзегезне шулай тотарга?

—Гафу ит. Кыюлык өчен пиво жиффәргән идем. Вәт шул. Мин,

кызым, пороховойда эшлим. Армиядән кайтып шунда урнаштым. Әти белән әни Казаннан ерак түгел бер авылда яшиләр. Икесе генә. Казан кызы апкайт, нәселне яңартырга вакыт, ди әти.

—Туктатыгыз әле шул лыкылдавыгызны. Гомердә беренче кат очрашабыз. Сез әллә кайларга, тирәнгә кереп барасыз. Өйләнү сөйләну генә түгел ич,—ди кыз. Һәм өстәп куя:—Сез миңа ошамыйсыз.

Әлбәттә, Шәмсия күңелендәгенең киресен сөйли. Риясыз, ихласлы егет күренә. Шулай да беренче очраган колгага, озыннарны яратса да, ябышып чыга алмый ич. Нәсел тамырларыннан килгән ачык күңелле Мортаза кызны тыңламый да.

—Соң, бүлмәңә меник. Мин шунда рәсми тәкъдим ясармын. Иптәш кызларың алдында. Миңа, короче, хатын кирәк, авылда, әти-әни белән бергә яшәрлек кеше булсын.

Мондый ук әрсезлекне, кыюлыкны, бөердән сөйләшүне көтмәгән Шәмсия югалып кала. Ә үзенә егет ошый. Шундый озын буйлы, әтиәниле ир турында гомере буена хыяллана түгелме соң ул ? Әйдә, ни булса булыр дип, булачак географ кыз «колганы» бүлмәсенә чакыра.

Сигез кеше яши торган олы бүлмәләре, гөнаһ шомлыгына каршымы, бәхеткәме, буш иде. Мортаза: «Синең караватың кайсысы?»,—дип сорады да, кыз төртеп күрсәтүгә, шунда барып утырды. Торып басты.

—Шәмсия, сезгә миңа тормышка чыгарга тәкъдим итәм. Бер шартым бар: укып бетергәч, минем туган авылыма кайтабыз. Бәлки, гомерлеккә булыр.

Шәмсия, кыска матур бармакларын уа-уа, бүлмә буйлап йөренә. Ни әйтергә белми, барысы кинәт көтмәгәндә килеп чыкты. Бер-берсен бөтенләй белмиләр, шулай бухты-барахты ярыймы соң инде?

—Мортаза, сез шаяртмыйсызмы?

—Билләһи... Ипи бир. Ипи белән ант итәм.

—Мин бит ятим кыз. Әти, әнисез, интернат-мәктәптә үскән бала. Туганнарыгыз ничек карар минем биографиямә. Бигрәк тә әниең,—ди кыз, күңеле нидер сизенгәндәй.

—Мин өйләнәм, алар тегел,—дип, Мортаза ихластан әтәчләнде. Шәмсиянең ана ышанасы килде. Үзе барып чакырды биергә, димәк, язмыш, аларның җаннары, бәлки, узган гасырларда ук таныш булганнардыр. Бер-берсен югалтып, янәдән тапканнардыр.

—Аннан ни бит, Мортаза, минем буем бик кыска. Әнә син нинди.

Егетнең җавабы әзер.

—Мин күптәннән синең кебек кечтеки буйлы, таза, сәламәт гәүдәле кыз турында хыялланып йөрим. Ниһаять, таптым.

—Ә ни өчен нәкъ шундый кыз кирәк сиңа?

Мортаза алдан яхшы ат кебек башын чайкап, бүлмәне яңгыратып көлде, аннан соң, интернат баласына бәйнә-бәйнә аңлатып ук бирде.

—Түшәктә хатыным минем култык астына сыйсын. Авызын шунда куеп ятсын... Күтәреп йөрерлек булсын.

Кыз юри генә «фу» дигән булды.

—Соң аны бит, ирне, алдан мунчага алып барып, ышкып-ышкып юасың, аннан бөтен «фу»ы бетә.

Ул кичне яшьләр үбешкәннәрме, юкмы, соңрак һич кенә исләренә төшерә алмадылар. Икенче көнне загска гариза илтеп бирделәр, яна елны бергә каршыладылар. Дәүләт имтиханнарын тапшырып йөргән көннәрдә Шәмсия ике кыз алып кайта, берсенә Әнисә, икенчесенә заманчарак булсын дип Альбина кушалар. Озын Мортаза ике кулына ике чибәркәен тотып, сөйгәненең имтиханнан чыкканын көтеп йөри. Иң авыр, иң бәхетле көннәре иде яшьләрнең.

Диплом алгач, географик ачышлар ясау, биштәр асып кыяларга үрмәләү, кыргый кабиләләр белән очрашу турындагы хыялларын Казанда калдырып, Шәмсия каенана, каената йортына кайтып төшә. Ятимлегеннән качып, бәхетен эзләп, гөнаһсыз өметләр илә, күңелендәге ялгызлыкны бастыру нияте белән яңа гаилә әгъзасы булып килә Әнисәнең әнисе.

Үзенең сөйләвенә караганда, ул бу гаиләгә саф күңел, иң изге ниятләр

белән керә. Язылышкач, беренче кайтканда ук, Мортазаның әти-әнисенә үзенең аларга, дөньяга мөнәсәбәтен ачык белдерә:

—Мин ятим бала.Әтиемне, әниемне хәтерләмим, аларның җылысын тоеп үсмәдем, башымнан беренче сыйпаучы кеше—ирем Мортаза булды. Мин сезгә әни, әти дип эндәшермен, якын итәрмен. Мине рәнҗетмәссез, дип ышанам.

Кеше ата-анасы, нинди генә изге җанлы булсалар да, үз туганнарыны алыштыра алмыйлар икән. Мортазаның әтисе, киң күңелле, риясыз кеше, киленне яхшы кабул итте: «үзләре яратышкач, торсыннар, миңа оныкларым булыр»,—дип, нәтиҗәсен ясады.

«Әни» кеше шактый катлаулы, үз рухи дөньясына башкаларны кертми торган булып чыкты. Әйе, малае аны тыңлады, Казан кызын, югары белемле укытучы алып кайтты. Анысы өчен рәхмәт. Соң, буе озынрак кыз таба алмаганмы шунда? Адәм мәсхәрәсе. Бүтәкә, кәҗә бәтие ияртеп кайткан, оялмыйча. Кияү эзләп йөрүче кызлар белән Казан шыгырым тулган, ди.

Оныкларының исемнәрен ошатмады. Әнисәсе ярый әле, Альбина исем булдымы инде?

Күпмедер күләмдә ул хаклы иде, әлбәттә.

Һәрнәрсәгә ихластан ышанучан, беркатлы, коткыга тиз бирелүчән, шул сыйфатлары аркасында тарихын оттырган татар халкы балаларына бәйнәлмилəл алып килгән, дөньякүләм таралган исемнәрне кушарга ярата. Янәсе, башка халыклар исемен бозып әйтмәсеннәр, бала күңеле рәнҗемәсен. Менә шундый ифрат «гади» хисләр (сугыштан кайткан ирләр балаларына бик күп саф урыс исемнәре куштылар, янәсе, бик якын дусты булган, сүз куешканнар, әмма урыс балалары арасында Гыйльметдин, Мирвәли, Галиулла кебек исемнәр күренми. Беркатлы татарны янә төп башына утырттылар) саф татар исемнәрен кысырыклап чыгаруга алып килә. Борынгыдан килгәннәре артта калганлык, хәтта наданлык билгесе санала ярым зыялы гаиләләрдә.

Педагогик «карашлары» үзенчәрәк булып чыга хуҗа ханымның. Яшь киленне ул йорт, камыр эшләренә өйрәтергә теләми, янәсе үз белдеге белән барып җитсен, үзе төшенсен. Беренче мәлдә ифрат кыен була интернат баласына. Абзар, өй эшләренең җаен белми, сыер янына барырга курка, тәкә гел аны сөзү җаен карый, җитмәсә чуаш хатыннары итәге кебек чуар кикрикле әтәче дә аның өстенә сикереп, тавыклар алдында абруен күтәрә. Яшь килен, күзләре кызарып чыкканчы качып елый да, яңадан сыер имчәкләрен юа башлый, усал кәҗәнең муен астын кашый. Мортазасы фермада механизатор, иртә таңнан китә, кич эңгер-меңгердә кайта. Хатыны мәктәп белән өй, каенана белән балалары арасында йөгереп көнен уздыра. Төннәрен иренең күңелен күреп, култык астына, җылыга кереп урнашуы була, кызларның берсе нәрсәдер таләп итә, аның тавышына икенчесе уяна.

Сабыр төбе сары алтын дип, Шәмсия барысына да түзәргә риза. Тик аны әнисенең салкын карашы, һәр нәрсәдән гаеп табуы, хатын-кыз шөгыльләренең нечкәлекләренә өйрәтергә, дусларча, туганнарча сөйләшеп, гәпләшеп утырырга теләмәве борчый. Ике арадагы салкын бозны эретү өчен ничек кенә тырышмый Шәмсия. Иртән коймагын пешереп өлгертә, чәен өсталгә бирә, ялт иттереп, мул күкрәгенә куеп, ипиен телемләп кисеп куя. Әмма сөзеп, астан караш, чит-ят итү яшь киленне кайда да эзәрлекли. Ул күзләрне Шәмсия хәтта дәрес алып барган сыйныф балалары арасында да күргәндәй була. Сискәнеп китә. Үз әнисен сагына башлый. Әнисе ана «түзәргә кирәк, балам» дигән киңәшен бирә. Шәмсия исә, «бу аждаһага чәчең белән җир себерсәң дә ярый алмассың», дип өстәп куя. Шулай да усалланасы килми, каенанасының аны үз итәсенә ышана. Бер караганда, кешелекле мөнәсәбәтләр туу өчен нигез бар кебек.

Шәмсиянең каенанасы сөйләмендә «аллам ташламасын, Ходаем, Ходай тәгаләм» кебек сүзләрне мул кулланырга ярата, карап торышка диндар, яшьлек матурлыгының эзләре сакланган гадәти авыл карчыгы. Озынча муены, матур һәм мәгънәле күгелҗем күзләре, артык симерүгә бирешмәгән гәүдәсе ана ихтирам һәм хөрмәт уятырга мөмкин иде. Бары тик якыннары гына аның җаһил, убыр, албасты хатын икәнлеген беләләр, аны читләтеп

узарга тырышалар. Дөрес, аның күзләре начар күрә, шуны яшерергә тырыша. Бавыры да, хуҗабикәсенә тынгы бирми, саруын кайнатып, ачы суын тамакка күтәреп кенә тора. Бер төрле уйлап, икенче төрле сөйләве, кара тавыш чыгаруга маһирлыгы, бәлки, шул авырудан килә торгандыр, дип уйлый якыннары. Өенә килене—чит кеше аяк баскач, ул бар явызлыгын, яшерергә кирәк тапмыйча, яклаучысыз Шәмсиягә күчерә.

—Сине беренче тапкыр күргәч үк, улыма: «бу интернат килмешәге сиңа, яхшы ата-ана баласына, тиң түгел, дип әйттем».

—Нәрсә әйтергә теләгәнегезне аңламадым, ничек инде ул интернат—дәүләт оешмасы килмешәк була алсын,—дип җавап кайтара Шәмсия, башын җүләргә салып, кәмпернең ни әйтергә теләгәне аерымачык булса да.

—Шыр ятимлегең өстенә, нәселсезлегең янына, син ахмак та икәнсең әле. Эшнең рәтен, ирнең кадерен белмисең,—дигәндә чыраен иләмсез җыерчыклар каплый.

Соңгы гаепне Шәмсия аеруча авыр күтәрә. Йөрәген чәнчеп-чәнчеп алган үпкә төер булып тамагына күтәрелә. Нәфрәт дулкынын шунда туктата, үзен кулга ала белә яшьбикә. Каенана тумыштан килгән явызлыгын теленә күчереп, ятимәне рәнҗетүне, җанын кыйнауны дәвам итә.

—Өйгә килен кергәч, фәрештәбез качып, йортыбызга шайтан оялады,—дип тә ычкындыргалый, кызык эзләп, күрше-күлән алдында.

Беренче көннәрдә каенанасының үтәли җилдәй карашыннан ук коелып төшкән, каршы әйтергә базмаган Шәмсия, мондый нахак сүзләрне теш күрсәтеп кенә бастырып буласын төшенә башлый. Явызлыкны усаллык кына җиңә ала.

—Йорт, өй эшләренә өйрәтмисез, күрәсең, үзегезнең белү чамалыдыр. Авылда синең каенанаң иң явыз карчык, дигәннәр иде. Дөрес икән. Иремне... сезгә күрсәтеп кадерләмим. Ул хәтлесе Мортазага мәгълүм,—диде дә кырт борылып чыгып та китте.

Соң, чыннан да, Шәмсия авыл тормышының бөтен ваклыкларын чамалый, рәтен белеп бетерми торгандыр. Аны бит беркем бу шөгыльләргә өйрәтмәгән, тормыш-көнитешкә әзерләмәгән. Ул—сул аяктан атлап йөри ала, пионер, комсомол җырларын яхшы хәтерли, кашыкны, тәлинкәне ялап куя белә. Бәхетне байлык, муллык, югары белем, хыялый дөнья гына алып килми икән шул. Һәркемнең җаны, тәне ял итә торган үз оясы, йорты, фатиры булырга тиеш. Кемдер оясын төзеп, килештереп, җанга ятмаган җирләрен бизәп, матурлап бетмәс борын туздырырга, пыран-заран китерергә маташа. Бусы—язмышның кешене сынавыдыр. Ул каенана рәвешендә килгәндер. Мортазасы исән булсын. Әлегә анасы сүзеннән чыга алмаса да, рәнҗеттермәс. Хатын бәхете ирдән, ир бәхете хатыннан тора, диләр ич. Өстенә өерелеп килгән болытлар таралыр, аяз көннәр килер, килми калмас. Каенана үзе дә мәңгелек түгел. Миендә җыела килгән явызлыклары, кемгәдер, нәрсәгәдер рәнҗүләре бетәр. Шәмсия аңа начарлык теләми. Үзе бәйләнмәсә, тыныч кына, шыпырт кына йөрер. Гаиләләрендә көтмәгәндә килеп туган бер вакыйга аларның бүрәнәләрен бүлә дә куя.

Каенана белән килен арасындагы мөнәсәбәтләрнең ничек, нинди юнәлештә үсеп китүен чамалавы кыен булмаса да, көтелмәгән фаҗига Мортазалар гаиләсе язмышына житди үзгәрешләр кертә. Һич уйламаганда, Мортазаның әтисе, тап-таза авыл карты суга батып үлә. Язмышы чакырып алган дип фараз кылырга гына кала. Миннулла абзый сәгать жиделәрдә «бераз йөреп керим әле, эчем поша» дип, чыгып китә. Өйгә инде аның гәүдәсен икенче көнне генә күтәреп керәләр.

Бик гадәти хәл. Авыл кырыенда исемсез бер инеш бар. Ачлык, сугыш елларында халыкны балык белән туендырып торган бу елгачык, яр буендагы тал-тирәкләр киселеп, корып беткәч, язгы ташу көннәрендә бер дулап ала да тына, эссе җәйләрдә тәмам кибә, әмма ике тирән упкынында су, лайла, юеш измә беркайчан бетми. Берсен «шайтан упкыны», диләр. Заманында бу урында су тегермәне гөрләп он тарткан, халыкны ач үлемнән коткарып калган.

Гомеренең очын эзләп баргандай, Миннулла карт упкын яныннан, кулларын артка куеп, уйланып атлаганда, «Рәшит батты, Рәшит упкынга

чумды, Рәшитне шайтаннар тартып алды» дигән тавышларны, бала-чаганың куркулы чыр-чуын ишетә. Яше мөмкинлек биргәнчә микъдарда Карт, йөгерә-атлый, яр буена төшә. Чыннан да җиде-сигез яшьлек малайның башы, кармак калкавычы кебек, бер бата, бер калка. Миннулла резин кәвешләрен генә салып, суга керә. Чумып диярлек, малайны эзләп таба, ике култыгыннан тотып, күтәреп алып, сай урынга ташлый, кинәт ул басып торган җир аска китә, картны сөйрәп ала, аякларын үзендә калдырып гәүдәсен сазлыктан чыгарырга бирми, ниндидер явыз көч аны үзенә, мәңгелеккә өстери, кемдер «Миннулла, карышма, тиздән сиңа бик рәхәт булыр, җаның тынычланыр», дип пышылдый. Малайлар картның ярдәм сорапмы, фани дөнья белән саубуллашыпмы бер-ике тапкыр кулын чыгарып изәвен күрәләр. Бабайның үле гәүдәсе өскә калыкмый, хәтта багорлар белән таба, тартып чыгара алмыйлар, икенче көнне генә Казаннан килгән водолазлар аны көч-хәл белән сазлык патшалыгыннан йолып алалар. Мәетне тикшергән табиб «йөрәге тоткан булырга тиеш» дигән нәтиҗә чыгара.

Шәмсия бу югалтуны бик авыр кабул итә. Каенатасы Миннулла аңа туган атасы кебек якын иде. Килененә һәр тарафтан ярдәм итеп, үзен артык тынлаучы булмаса да, «минем кызыма авыр сүз әйтмәгез, рәнҗетмәгез», дип кабатларга яраткан карт аларны ташлап китә.

Хуҗаны җирләп кайтып, туганнары таралышып, үзләре генә калгач, Шәмсия каенанасының ачы хәсрәтен, кара кайгысын уртаклашырга, аз булса да юатырга, терәк булырга теләп, караватында уфылдап утырган карчыкның янына килеп утыра, аркасыннан сыйпап, иннәреннән ихластан кочып ала.

Вакыйгаларның алга таба үсешен Шәмсия сизми, аңламый кала. Әле генә балавыз сыгып, ак башъяулыгының чите белән яшьләрен сөртеп утырган карчыкны бер мизгелдә җен алыштырды диярсең. Каенана дигән зат, яшьләр кызыгырлык җитезлек белән Шәмсиянең кулларын үзеннән алып ташлый, сикереп торып, югалып, тагын да кечерәеп калган хатынның каршысына басып, төкерекләрен чәчә-чәчә бүлмәне әшәке, шакшы сүзләр белән тутыра:

—Йөрәгемдәген әйтсәм әйтим инде. Син бәдбәхет бусагамны атлап керүгә, йортка бәхетсезлек артыннан кайгы килә. Кара сарыкны бүре алды, көчегебез син ташлаган сөяккә кадалып үлде, ике алмагачым корыды, тавыклар йомырка китерми башлады. Яхшы баланы ата-анасы, туганнары детдомга илтеп ташламый. Ул йорттан җүнле кеше чыкканы юк әле. Мортазам сиңа, бүтәкәгә, әрәм булды. Синнән туеп, сине күралмыйча ирем үз теләге белән суга батып үлде... Күрәсем дә килми үзеңне, кулың, аягың коргыры нәрсә, бәдбәхет, дәҗҗал...

Мондый ямьсез, ялган, җанны талый, бәгырьне өшетә торган сүзләрне гомергә ишетмәгән Шәмсия имәнеп китә, каршы сүз түгел, аңлатма бирергә, бүлдерергә көче, дәрманы җитмичә, атылып йортка, аннан урамга чыга. Корт чаккандай, янәдән йортка чабып керә. Йортта, комлыкта уйнап утырган сабыйларының башларыннан ансыз рәвештә генә сөя дә, Мортазасын эзли башлый. Болай да хәсрәтле башка тимер таяк булып төшкән кара хаксызлык, яла турында кемгәдер сөйләргә, хәсрәтен бүлешергә, яклаучысын булмаса, аңлаучысын табарга тиеш ул. Каенанасы аны үзеннән кисеп ташлагач, бу ят авылда аның ике кызы белән ире генә кала. Әйе, аның бит никахлы тормыш иптәше бар, ул хатынын нахакка рәнҗетергә юл куймас. Әнисенә кисәтү ясар, туктатыр ул албасты хатынны.

«Жирафын» көч-хәл белән эзләп таба. Ирләр, ни әйтсәң дә, кайгыны таратырга юаныч таба белә. Әнә аның хәләле печәнлектә рәхәтләнеп, гырылдап йоклап ята икән.

—Мортаза, тор, балаларны алабыз да бу йорттан чыгып китәбез. Мин бирерә артык кала алмыйм. Әнием кешелегемне җиргә салып таптады, суалчан урынына изде, гомерлеккә рәнҗетте. Ник эндәшмисең? Йоклаган булып кыланасыңмы?

Соңгы сорауларына җавап ишетмәгәч кенә, ул иренен ләх исерек булуын, аңа ике дөнья бер кәнди[1] икәнлеген аңлады.

[1]Тимер аш савыты—диалекталь сүз.

Мортазаны уята алмагач, мәктәпкә йөгерде, ишек шакырга да онытып, атылып директор бүлмәсенә килеп керде. Мәктәп хуҗасы бик ипле кеше, алтмышның өске ягында булса да, эшен җайлап, майлап, җил уңаена алып бара белә. Утызынчы еллар мәхшәрен, сугыш фаҗигасен башыннан кичергән, сирәкләнеп калган чал чәчле, әлсерәгән йөзле, әмма борын астында гына калдырылган кәттә мыеклы карт коммунист иде аларның директоры.

Яшьләр Вәли абыйның кайбер гадәтләреннән көләләр; коллектив белән очрашканда, фикерен үз сүзләре белән әйтәсе урынга, алдан әзерләнгән язмасына карап сөйләү гадәте өчен «кәгазь сандугачы» дигән кушамат уйлап тапканнар. Өлкәннәр, аның тормыш юлын белгәннәр, кара елларны күргәннәр эндәшми: кәгазьгә мөрәҗәгать итмичә, күнелендәгесен турыдан ярып салганы өчен Вәли, заманында, Сталин зинданында сигез елын заяга калдырып кайткан. Ошбу хәлләрдән соң ил, халык беркадәр сүз азатлыгына ирешсә дә, директор гел дөрес сүз, рәсми китапта язылганнарны гына сөйләргә ант иткән, диләр. Бер авызың пешкәч, салкын суны да өреп кабасың, дип юкка гына әйтмиләр икән шул.

Шәмсияне—яшь белгечне Вәли агай бик җылы кабул итте, теләгән сәгатьләрен бирде, балалары яшь дип, иҗтимагый шөгыльләрне азрак йөкләргә тырышты. Гомумән, укытучылар коллективына Шәмсия бик җиңел керде, тиз арада үз кеше булып китте.

Шәмсиянең бүлмәгә шакымыйча, капыл килеп керүен мәктәп хуҗасы шулай булырга тиеш кебегрәк кабул итте. Шундый зур югалту! Директор Миннулла кордашын күмүдә үзе дә катнашты. Ханымның халәтен аңлый, юату сүзләрен язып куймаган булса да, табар, югалып калмас. Шуңар да ул ишекне каерып ачып, япмый калдыруга, укытучының күлмәк изүләре каптырылып бетмәгәнгә, битендәге кызгылт тимгелләргә дикъкать бирми. Мәгәр күтәрелеп карагач, ханымның сөт өсте кебек ап-ак йөзе, бөтен гәүдәсе белән калтырануы, кулларын кая куярга белмичә бутавы күпне күргән директорны да гаҗәпләндерде, кызгану катыш курку хисләре уятты. Чәчләре җилкәсенә тәртипсез ишелеп төшкән, күзләре тоныкланып, мескенләнеп калган.

—Шәмсия Абраровна, үзегезне кулга алырга тырышыгыз. Сез шулай бетеренеп кенә Миннулланы кире кайтарып булса иде.

—Юк, Вәли Зәетович, минем керүем башка сәбәп белән. Миңа балаларым белән вакытлыча яшәп торырга мәктәптән бер бүлмә биреп торыгызчы?

—Нәрсә булды, сеңелем? Монысы—яңалык. Йортыгыз зур,—дигән булды директор, зиһене, мыегы белән үк ниндидер күңелсезлек сизенеп. Мәет чыккан йортта, бигрәк тә аны хуҗа ташлап китсә, җәнҗал чыкмый яисә берәр хикмәт булмый калмый.

—Мине каенанам бик нык кимсетте, рәнҗетте,—ди-ди, ханым кечкенә, тулы кулы белән күз яшьләрен сөртеп алды.

—Иренен үлемен миннән күрә. Мин, янәсе, детдом баласы, алар йортына бәхетсезлек алып килгән.

Яшьрәк чакта Миннулланың бераз салып алгач, хатынын шактый тискәре чагыштырулар белән әрләп, «түзәр хәлем калмады, хет чыгып асылын», дигән әрнүле сүзләре исенә төште директорның. Карышусыз, тынлаучан табигать баласын өеннән куып чыгаруга барып җиткән кәмпергә унай бәя бирүе кыен.

—Карале син аны, шайтанны, ирен югалту кайгысыннан зиһене чуалып киткәндер. Сина анда яшәве кыен икәнен сизеп торам. Бәлки, бераз түзәрсең. Кайтып төшәр.

—Инде мин кайтып төшә алмам, Вәли Зәетович. Җитәрлек түздем. Мин дә бит кеше. Ятим үссәм дә. Кәбестә арасыннан тапмаганнар. Әти-әнием булган.

—Ул карчыкка кем кирәк инде тагын. Беренче килене белән уртак тел таба алмады. Дөрес, анысы бала тапканчы, өч айдан ук ташлап чыгып китте, бугай.

Бу сүзләрне зиһене аша үткәргәндә, Шәмсиянең болай да зур коңгырт

күзләре мангаена менәрдәй булып ачылды, битендәге кызгылт тимгелләре тимрәү тәсенә керде, дөньяны кара кургаш болыт каплады.

—Мортаза өйләнгән идемени? Мин аның икенче хатыны булып чыгаммыни?

Игезәкләре белән чиләнеп, һәр тәнәфестә мәктәп белән өй арасында чабып, гаиләсеннән башка мохит белән аралашмау сәбәпле, шундый «олы» серне Шәмсия белми калган икән. Мортаза бу хакта ләм-мим бер сүз ычкындырмады. Кемдер, бәлки, кинаяләп, төрттереп сиздергәндер, гайбәтләрдән өстен торган табигать баласы бу сүзләрне кечкенә, үтә күренмәле, алсу колагына кертмәгәндер. Шәмсиянең каенанасын яхшы белгән укытучылар яшь коллегаларын кызганып, үткән-беткәнне кумпайтып тормаганнардыр.

Ирексездән сер чишүче, гайбәтче, әләкче, тагын әллә кем вазифаларын өстенә алган директор кирәкмәгән сүз әйтеп ташлавын аңлап, эченнән сыкранып, сызланып куя, үзен ифрат җайсыз хис итеп, урындыгында боргалана, өстәл өстендә яткан кәгазьләрне бимазалый, урыннарын алыштыра. «Мәхлук ханым берни белми яшәп ята икән. Ошбу хәбәрне ул башка кешедән ишетсен, яисә бөтенләй белми калсын иде. Икенче яктан, урам себеркеләре авызыннан арттырылган, күпертелгән хәбәр килгәнче, аны барыбер бер ишеттерерләр, миннән белүе хәерлерәктер»,—дип фаразлап, Вәли Зәет улы үзен тынычландырырга тырышты.

—Соң, Шәмсия Абраровна, Мортазаң үзе бу хакта әйтмәдеме? Хотя бы өйләнешкәч булса да...

—Хәтерләмим... Хәзер әйләнеп киләм,—диде ханым, бик акрын, каяндыр бавырдан, бәгырьдән чыккан тавыш белән. Күз аллары әлҗемөлҗе килә, йөрәге күкрәгеннән чыгып китәрдәй булып, дөп-дөп итеп тибә. Тизрәк, тизрәк, белешергә, дөньяга ачыклык кертергә. Кыска, тулы балтырлы аяклары велосипед тәгәрмәчләредәй әйләнә. Максат, ачу, гарьләнү, үпкә кебек хисләр йөреткәндә адәм баласына әллә ниткән җен-пәри көчләре керә. Кызлары йортта юк иде, күрәсең, өйгә кереп киткәннәр. Йөгереп килгән унайга, Шәмсия тыгыз гәүдәсен баскычтан лапас башына ташлады, һаман да каерысы алынган юкә агачы кебек сузылып яткан Мортаза өстенә сикерде, атланып утырган килеш ирен кыйный башлады, күкрәген, янтауларын төйде, яңакларын, куллары арып, үзе хәлдән тайганчы, чабаклады. «Юкә агачы», ансыз рәвештә куллары белән үзен якларга тырышты, нәрсәдер мыгырдады, затсыз аракы белән агулануы бик көчле булгандыр, уяна алмады.

Иң көчле беренче ачуын, үпкәсен, рәнҗүен баскан Шәмсия, бушап, һавасы чыгарылган шар кебек калды. Мәлҗеп төште һәм яңадан мәктәп тарафларына салмак кына атлап китте. Йөгерерлек хәле, ашыгырлык урыны калмаган иде. Әти-әнисе исән-сау булса, ике чибәрен ике култык астына кыстырып, кайтып китәр иде, башка сыенyр урыны юк шул. Әле ярый мәктәбе бар, анда үз урынын тапты, кабул иттеләр, яраттылар.

Ханымның хәле мөшкеллеген, үз хатасын аңлаган директор карарын әзерләп куйган, рәхмәт яугыры.

—Мәктәптән бүлмә табып булыр иде, үзенә, кеше күзендә җайсыз булыр. Безнең урамда, тыкрыкта Саимә апаның (чак кына иреннәреннән «ташландык» сүзе очып чыкмады) буш йорты бар. Үзе өченче ел инде Чиләбедә, балаларында яши, кайтып күренгәне дә юк. Авыл советы рәисе белән сөйләшенгән. Ул риза, Саимә апа ачкычларын миндә калдырган иде, китереп бирермен, ди. Мәктәптән караватн, матрац, одеал ише әйберләрне әзерләп куярга куштым. Утыр, бераз тынычлан, хәл тарт, барысы адәм баласы башыннан уза. Авыр хәлгә тарган син беренче түгел, соңгысы да булмассың. Тормыш—каршылыклар көрәшеннән, ялгышларны ясау һәм төзәтүдән тора. Һәркем үз язмышын узарга тиеш.

Вәли абыйларының, күпчелек өлкән яшьтәгеләргә хас булганча, игътибарлы тыңлаучы булганда, вәгазь укырга, кинәш бирергә ярата торган гадәте авыл халкына, мәктәп коллективына мәгълүм. Берәрсенә тәрбияви хикәят сөйләргә җае чыкса, төшке ашын корбан итәргә, ач калырга риза.

—Кызганычка каршы, адәм балалары иң явыз ерткычлардан да яманрак

шул. Хайваннар арасында да ризык яисә башка сәбәп белән сугышлар чыга тора. Ләкин бу орышлар үлем белән тәмамланмый, көчсезе читкә китә, үч сакламый. Ә кеше, акыл иясе, табигатьнең тажы, тынычлана алмый, болай да тарих бизмәнендә бер көнлек гомерен үч алуга багышлап кыскарта.

Вәли абыйсының акыллы хатынны тынычландыру өчен сөйләнгән сүзләре Шәмсиянең кызышкан миенә барып житми. Бер көндә ике фажига. Ай тотыласы көн түгел микән бүген. Директорның күптәннән яраларына кайтып төшкән тыныч инеш кебек салмак, талгын сөйләме, яшь укытучы өчен шулай борчылуы бераз тынычландыра ханымны.

—Мина күченергә ярдәм итәргә берәр кеше бирә алмассызмы?

Директор иренмичә үзе коридорга чыкты, комсомол оешмасы секретаре белән пионервожатыйны алып керде.

—Укытучы апагызга Саимә әбиләрегез йортына балаларын, әйберләрен алып килергә булышыгыз.

Яшьләр бер-берсенә карашып, берни анламый торалар, ханнар сарае кебек яхшы йорттан кем инде алачыкка үз теләге белән күчсен ди. Вәли, Мортазаның өйләнүе турында әйтеп ясаган хатасын төзәтеп, Шәмсияне кирәкмәгән анлатмалардан коткарды.

—Беләсезме, кызлар, бу вакытлыча гына. Географ апагыз үзе дә, кызлары да мәет чыккан йортта калырга куркалар. Иялəшкәнче, башка жирдә яшәп торырга булдылар. Жидесен, кырыгын, бәлки, елын уздыргач, кире кайтырлар.

Бу гөманны Шәмсия үзе дә бик теләп кабул итте, соныннан барлык кызыксынучыларга шулай гына анлатты.

Мортаза, аңына килеп, күз ачкан вакытта инде кояш Муллалар тавы артына төшкән, каранғылык үзенең пәрдәсен жир өстенә ябарга чамалаган энгер-менгер була. Ирнең тәне, бите, кабыргалары сызлый, авырта, ынгыраша-ынгыраша лапас башыннан төшеп, өйгә сөйрәлеп керә. Әнисе, ут алмыйча, бизәкле сандыгы өстендә кара янып утыра. Теләктәш карчыклар күренми.

—Шәмсия, балалар күренми, берәрсе үзләрен чәйгә алып киттеме әллә?—ди «Жираф», күзләрен уа-уа.

—Детдом имгәгең мина авыр сүзләр әйтеп, кызларын ияртеп, безне ташлап китте. Юлына ак жәймә. Килмешәк, өебезгә бәхетсезлек арты бәхетсезлек алып килде...

Айнып, акылына төшеп житә алмаган, гел әнисеннән куркып, кол булып яшәгән Мортаза, кулларын алга сузып, карчык өстенә килә:

—Син куып чыгардыңмы сабыйларымны? Кая киттеләр? Мин сиңа каян хатын житкерим. Берсен куып чыгардың, икенчесен... Үзеңне өйдән каты себерке белән куарга вакыт житмәсен. Әти, беләсең килсә, синнән котылыр өчен генә суга батып үлде...

Гомерендә әнисенә каршы сүз әйтмәгән Мортазаның сабыр канатлары сына, тузына, зилзилә бураннары чыгарып, гаиләсен эзләп китә.

Эзләр Саимә карчык йортына алып бара. Тар, кечкенә ишектән иелеп, бөгелеп, эчкә үтә. Бернидән хәбәрдар булмаган сабыйлары шатланышып, йөгерешеп әтиләре янына киләләр. Шәмсия кыска, жәйге күлмәк итәген күтәреп кыстырып, тулы ак аякларын бөкләп, пычак белән кыра-кыра идән юа.

Әле фашланганын белмәгән Мортазаның йөрәген әрнү, кызгану һәм газаплану, үзенең гаебен тану хисләре тырный. Идәнгә катырак төшерсәң, түшәмгә житә торган туп шикелле тыгыз тәнле, матур йөзле, иркә күзле хатынын ярата иде ул. «Мин аңа хәзер ничек ярдәм итә алам? Бу алачыкта яшәп калыргамы?» Шактый вакыт тораташтай катып, як-ягына каранып торганнан соң, телгә килә:

—Мин, Шәмсия, берни анламыйм? Нәрсә булды? Нинди кәмит?

Әлегәчә кергән кеше ягына юри әйләнеп карамаган Шәмсия аягына баса. Кулындагы юеш чүпрәгеннән су тама... тып... тып... Язмыш тамчысы диярсен. Бавырдан төшә диярсен... Бу мизгелдә хатын бер үк вакытта матур, дәһшәтле һәм усал да иде.

—Бияләйдәй, хатын алыштырып яшәргә күнеккән, ул хакта әйтергә

курыккан кеше өчен кәмиттер инде ул. Ә кем өчендер фаҗигадер. Ярый, мин суындым, ин пычрак сүзләр белән безне өйдән куып чыгарган әниең янына кайт. Минем кебек намусын, сафлыгын саклап, озын буена алданучы тинтәкләр табылыр әле. Бар, тагын Казаннан хатын алып кайт. Әниең белән икәүләп анысын да куып чыгарырсыз, әниең аны мыскыллап, кешелектән чыгарып озатканда син дөм исерек булып кыланырсың. Үз башыгызга котыруыгыз булмаса.

Мортаза ни диярга белмичә, бу юлы инде туры мәгънәсендә матчаны терәп тәк басып тора. Имәндә икән чикләвек. Аның өчен көтелмәгән борылыш. Әни белән уртак тел таба алмаулары бер хәл. Ике арага кемдер кара мәче кертеп җибәргән. Бу хәтле авыр, ахмак хәлдә, адәм мәсхәрәсе көненә калганы юк иде әле механизатор ирнең. Болай да аңгы-миңге хәлдә иде, бөтенләй томаланып калды.

Әлбәттә, беренче хатыны Хәтимә турында, соңыннан булса да әйтеп, мәсьәләне ябып куясы булган. Әүвәл таныргa кыюлыгы җитмәде, аннан «булган-беткән, барысы да онытканнардыр инде, Шәмсия белмичә калса, яхшырак булыр» дип, кул селтәде. Үткәнең, явыз елан кебек җирдән шуышып, гел синең арттан эзәрлекләп килә икән.

Беренче хатыны Хәтимә язылышмыйча-нитмичә үзе ияреп кайтты. Агроном кыз иде. Пороховой заводы эшчесе—Мортаза аның белән авыл хуҗалыгы институтының тулай торагында танышты. Кызның диплом алып йөргән көннәре. Аксыл чәчле, зәңгәр күзле, озын борынлы, төз аяклы Хәтимә Мортаза белән танцыда танышканнан соң бергә йоклаудан баш тартмаса да, язылышу мәсьәләсенә житди карый торган ханым булып чыкты.

—Паспортны пычратканчы авылыңны, йортыңны күрсәт, әти-әниең белән таныштыр. Җәйне уздырырмын, башкасын соңрак хәл итәрбез, сөеклем.

Хәтимә чая, үткен, башбирмәс, мөстәкыйль фикерле мишәр кызы булып чыкты. Берничә көннән соң булачак каенанасы әйтә моңа:

—Хәтимә, бүген мунча ягып җибәр әле.

Тегенең җавап калыпка салынган:

—Мунчагызда юынырга риза булсам да рәхмәт әйтерсез. Бик иске, пычрак.

—Хәтимә, иртәгә көтүне куа алмассыңмы?—кебек үтенечкә авыл хуҗалыгы белгеченең җавабы әзер:

—Мин сезгә прислуга булып килмәдем. Иртәнге йокыны обожаю. Мин төнлә эшләргә күнгән. Әнә, Мортазагыз кусын, белеме юк, ана барыбер көтүче генә буласы.

Хәтимә ике айдан аз гына артыграк яши дә абыйсына хәбәр итә, тегесе машина белән килеп алып та китә сеңлесен. Авыл халкы явыз каенана белән тынышмаган өчен киленнәре аерылып китте дип пышылдаса да, мәсьәлә башкада, тирәндәрәк иде. Бер атна узуга, Хәтимә Мортазага дәгъвасын белдерә:

—Иртә ятасың, гырылдап йоклыйсың, таң белән чыгып таясың. Мина андый уҗым бозавы кирәкми.

Берни аңламаган Мортаза:

—Мин нишләргә тиеш булам соң?—ди.

—Мине иркәләргә.

—Кайчан йоклыйм соң? Мин бит авыр эштә.

—Теге дөньяда туйдырырсың йокыңны. Ахмак. Синең ашказаны начар эшли торган анаң белән үзеңә уважайть иткән бер хатын да тормаячак. Үзенә ызба өлгерт. Аерылып чык. Атаң нормальный карт. Мыр-мыр килеп йөрүен сагынырмын.

Аерылып киткәндә, Хәтимә Мортазаны бер почмакка чакырып алып соңгы сүзен әйтә:

—Егетем, синең ирлек сыйфатларың ташка үлчим. Фантазияң юк. Надан, ирләр заты күрмәгән ару авыл кызын эләктерергә тырыш, синең белән шул тора алса гына. Тамырга тегел, буйга гына киткәнсең шыл. Мин барыбер изменять итәр идем. Аждаһа әниеңә сәлам диген. Мәңгелеккә дигән ярым, елап калыр балам юк. Хуш. Чао.

Акыллы һәм гадел карт—Мортазаның әтисе:

—Әниең аркасында ташлады. Хәерле булсын, төнлә килеп керде килен, төнлә чыгып китте. Төнге юллар йә бик изге кешене, йә бик хәерсезне йөртә шул. Башың сау булса, хатын табылыр,—дигән нәтиҗәсен ясады.

Беренче хатын әйткән ачы сүзләр келт итеп исенә төште. Шәмсия дә ташлап китсә?

—Шәмсиям, кадерлем, мин барысын аңлатам.

—Кирәк түгел аңлатуың да, үзең дә. Сөйгән ярым урынына кулымдагы юеш чүпрәгем генә калды,—дип, Шәмсия бар ачуын, үпкәсен, гарьләнүен юеш, пычрак чүпрәккә ышанып тапшырып, оста уенчы кебек өскә сикереп, аны Мортазаның битенә сылады. Шунда калдырды. Чүпрәк үз белдеге белән һәм Архимед законына буйсынып, шап итеп идәнгә төште. Ханым почмактагы казенный матрацларга барып капланды. Бу аның Мортазаны, балалары хакына, гафу итүе иде, күрәсең. Битеннән, киемнәреннән агып төшкән пычрак су иргә шифалы яңгыр кебек тоелды.

Мортаза сабыр, йомшак холыклы, итагатьле Шәмсияне рәнҗеткәне өчен әнисен гафу итә алмаса да, аны ташламады. Ике ут, ике йорт арасында калды, ике арада йөри-йөри үзенә бикләнде, еш эчә башлады.

Соңрак, берүзе калгач, каенанасы килененә нисбәтән йомшарып, кире кайтырга чакырып караса да, Шәмсия аны кичерә алмады. Күрәсең, ятим үскән балалар, назга сусаган кебек үк, рухи җәрәхәтне, нахакка рәнҗетүләрне үткәрә алмыйлар. Андый шәхесләр салпы якларына арыш саламы гына кыстырып торсаң, бер төндә тауны башка урынга күчереп куюлары мөмкин. Нахакка рәнҗетсән, мәрхәмәт көтмә.

Каенанасы өеннән куып чыгарганда, Шәмсия өченче балага көмәнле була. Шул хәл Мортаза файдасына эшли. Ятим үскән ана өч баласын үз язмышына төшерә алмый.

Кинәт үсеп киткән кызларына әбиләренә барып йөрергә, хәлен белергә, ярдәм итәргә рөхсәт итә. Бу адымын йомшаклык дип санамый. Азрак әбиләреннән явызлыкка өйрәнерләр, дөньялыкта анысы да кирәк, дип аклый бу адымын. Минем кебек, бер янакка китереп сыласалар, икенчесен куеп тормаслар. Толстой бабабыз мондый киңәшен башкаларга гына биргән, үзе алпавыт булып, крепостной кызларының рәхәтен күреп, бөтенләй башка тормышта яшәгән. Сүз һәм гамәл... Икесе ике шүрлектә. Әдәбият һәм тормыш... Икесе ике киштәдә....

Саимә карчык йортында озак яшәмиләр, ул елларда әле укытучы халкына, димәк, халыкның зыялыларына игътибар, ярдәм бар иде. Бигрәк тә югары белемлеләргә. Шәмсияне балалары белән колхоз исәбенә салынган менә дигән йортка күчерәләр.

Каенанасы бер-ике тапкыр «кире кайтсыннар, кешедән яхшы түгел», дип чакырып караса да, географ ханым тирәнгә кереп тормыйча гына:

—Бер киселгән икмәк кире ябышмый,—дип кенә җавап бирә, ә үзен «авыр килгән бәхет татлырак була», дип тынычландыра.

Кызлары тугызынчыны тәмамлаган елны, язын әбиләре вафат була. Үлгән кеше белән булышуны түбәнлек санап, Шәмсия чыгып киткәннән соң беренче тапкыр килен булып төшкән йортына аяк баса, каенанасын җирләшә, мәгәр яшьлек канатын сындырган өйгә күчүдән баш тарта. Соңрак бу нигезгә күп яклары белән әбисенә тартым кызы Альбина хуҗа булып күчәчәк.

Бәла-каза аерым йөрми, диләр. Шул ук җәй бу гаиләгә янә бер бәхетсезлек алып килә. Гаиләсе, инде дүрт баласы, яраткан хатыны белән әнисе арасында йөгереп, аларны килештерү турында сабыйларча хыялланып, барып чыкмагач, кайгы-хәсрәтен, моң-зарын шайтан суына «түгүне» ешайткан Мортазаны паралич суга. Дөрес, урын өстендә озак ятып, якыннарын артык интектерми, табигатьтән килгән тазалыгы, саф һава, тәрбия аны бер елда аякка бастыра, әмма телсез, сүзсез кала. Үзе аңлый, ишетә, мәгәр җавап кайтара алмый. Болай да җөмләсен сыгып чыгара, авызын ачса үпкәсе күренә торган озын Мортаза кешеләргә хас аралашу чарасыннан бөтенләй мәхрүм кала.

Мортазаны гаиләсе, бигрәк тә чая, үткен, әрсез, әче телле кызы Альбина житдигә алмый. Ни гажәп хәл: ул сөйләшә, аңлаша алмаса да, акылы яхшы тегермән кебек эшли, үткәненә, якыннарына, хәл-әхвәлләргә дөрес бәя бирә. Күрәсең, кешенең бер әгъзасы хужасына хезмәт итүдән баш тартса, икенчеләренең куәсе арта, җегәре ныгый. Халык юкка гына «аксак күп йөри, сукыр күп күрә», дип әйтмәгәннәрдер. Ләкин Мортазаның акыл сәләте артуыннан гаиләсенә ни файда. Ыңгыраша, кулларын бутый-бутый нидер аңлатырга азаплана, ләкин Шәмсиядән башка берәүгә дә аның акыллы киңәшенең дә, үзенең дә кирәге юк. Яраткан хатыны исә аны житдигә алып, янына килеп, битләреннән, аркасыннан сыйпап, сөйләнә, киңәштабыш иткән була. Аның «б», «м» ыннан нидер аңлаган булып, «дөрес әйтәсең, Мортазакаем», дип нәтиҗәсен ясаган була, чирлеңең күңелен күтәреп куя. Тегесе сөенеп туя алмый, янәдән кулларын бутый-бутый нидер әйтергә тырыша. Күзләреннән бәхетле яшьләр шарлап ага. Читтән караганда, Мортаза агайның эшләр җиңел. Болдырга чыгып утыра, кәттәләнеп үзе белән уйнаган кояшта—бөкшәйгән аркасын, сөякчел кулларын җылытып, көннәрен мәлҗерәп тик уздыра. Тирә-юнь аны параличтан тиле-миле калды дип санаса да, аның башы элеккегедән яхшырак эшли, күзләре дөнья мәшәкатьләрен, кешеләрнең кыланышларын, сүзләрен үзенә сеңдереп, миенә тапшыра килә.

Бүген аның кәефе аеруча әйбәт. Яраткан кызы Әнисәнең малае бар. Илдар кушканнар дигән хәбәр килде. Чандыр гәүдәле, озын буйлы Мортаза картлыкка бирешмәскә тырыша. Тик менә инде 16 ел «телсез» яшәп, үзендә күпме сер саклый. Шәмсиясенә әйтәсе килгән матур, рәхмәтле сүзләрен иясенә тапшыра алмый. Күзләренең нурлары әле сүнмәгән. Иңгә-буйга берүк булып киткән карчыгын күргәч, күзләрендә тычкан уты кабына. Яшьлек хатасы өчен үкенеп бетә алмый. Теге вакытта мут, тел бистәсе, яман холыклы хатын алып кайтып ялгышты. Әмма аның күкрәкләре тәбәнәк тау итәгедәй, тешләре хәнҗәр кебек ялтырап тора иде шул. Бер урам әйләнсә, пожарка янында дамино суккан авыл ирләре селәгәйләрен агызып, авызларын җыйнарга онытып утырырлар иде. Чибәр гәүдә тиле башка тап булган, нишлисең. Ул өйләнүе турында вакытында Шәмсиягә әйтмичә генә ялгышты. Ташлап китәр, дип курыкты. Хатын-кызның холкын белмәссең, керделе-чыктылы. Беренче хатынын әүлия дип иярттеп кайткан иде. Ташлап киткән булды, әллә кем булып. Казандагы танышлары соңыннан әйттеләр: Мортазага чыкканчы, бала төшерткән булган.

Дөньяда иң сөенечле, иң көенечле нәрсә—гыйшык тотудыр. Сөю-сөелү, дәрткә сыймау, үрле-кырлы сикерү. Дөреслектән качу. Сөйгәненне әллә кем, фәрештә итеп күрү. Шәмсиягә мәхәббәтен гап-гади мавыгу дип уйлаган иде, битенә пычрак юеш чүпрәк белән китереп сылагач, чын сөюнең шул икәненә инанды.

Адәм балаларын Ходай Тәгалә тигез яратмый икән шул. Берсенә матурлыкны, таң калдырырлык чибәрлекне, икенчесенә дөньяны янача, бизәп күрү сәләтен, өченчесенә азгынлыкны, бозыклыкны мул итеп бирә, дүртенчесен горур, эре итеп тудыра... Ләкин ул аларның һәммәсен яратканда башына акыл исемле гәүһәр сала. Аны сыекча дип кимсетәләр, чынында ул асылташтыр әле. Акыл куәсен кеше балачактан ала. Аны эшкәртү, чарлау—тирәлек шөгыле. Хатын-кыз кем кулына эләгә, аның белән бер юнәлештә үсә яисә юкка чыга. Ходай Тәгалә үзен телдән мәхрүм иткәч, башына акыллы фикерләр күбрәк килә башлады. Ләкин алар хужалары белән бергә, файдасыз күмелерләр шул. Җаным—тормышым гөле—гәүдәмне ташлап киткәнче яшим инде. Кая барасың.

Шул арада Мортаза белән Шәмсиянең кызлары үсеп җитә. Бер карында янәшә яшәгән пар канатлар төсләре, холыклары белән бер-берсенә бөтенләй охшамыйлар. Альбина гәүдәсе, килбәте, тән төзелеше ягыннан нәкъ әнисенең күчермәсе. Әмма холык, фигыль, менәз тарафларыннан, бик теләмәсә дә, Шәмсия кызында каенанасы чалымнарын күрә. Буе кечтеки булса да, өстән карап сөйләшергә, өйрәтергә, кушарга ярата, үз шәхесенә тәнкыйтьне теләмичә кабул итә.

Әнисә шыксыз озын үсмәсә дә, гәүдә ягыннан нәкъ әтисе инде,

баздагы бәрәңге тамырыдай гел өскә, кояшка тартыла. Үз-үзен тотышы, тыйнаклыгы, үҗәт тырышлыгы, кирәк чакта сүзендә нык торуы, мөстәкыйль фикер йөртүе ягыннан нәкъ әнисе инде.

Альбина—үткен, үзенә тиешлесен, хәтта артыгын кычкыртып, талап ала. Шәмсия соңрак кызларына бер күзәтүен сөйләргә ярата иде:

—Биш-алты айлар булгандыр сезгә. Бабагыз ясаган сәке-караватта ятасыз. Икегезгә дә бер үк төсле шешәләрдә, бер үк күләмдә сөт бирәм. Альбина сөтен хап-хап эчеп бетерүгә, шешәне кулына алып, идәнгә ташлый. Әнисә, ризыгы бетсә дә, өлкәннәр килеп алганны елмаеп көтеп ята. Сина, Альбина, шешә җиткерә алмыйча интектем, аптырагач, җеп белән бәйләп куярга яисә кизүдә утыртырга мәҗбүр була идем.

—Соң, син, әни, Әнисәне күбрәк яратасың, яклыйсың бит.

—Ни өчен дисен? Мина калса, икегезне тигез күрәм.

—Әтигә охшаган өчен.

—Син төсен, гәүдән буенча мине кабатларга җыенасың.

Сине артыграк яратырга тиеш булам түгелме, Альбинам?

Тугызынчы сыйныф укучысын сыртка салып булмый.

—Хатын-кыз ирләрне үзеннән күбрәк ярата. Син Әнисәнне әткәй төсле колга булганы өчен күбрәк яратасың. Сөяленә бастыммы?—дип тыкылдый Альбина. Үз тугызы тугыз.

Шәмсия «яшьләргә җавап табып бетермәссен» дип, игезәкләрен берәмберәм күкрәгенә кыса да, мәктәпкә йөгерә. Бүген—туган якны өйрәнү түгәрәге утырышы.

Әнисә урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. Укуга бик әһәмият бирмәгән, тиктормас, омтылышлы, романтик, дөресе, бормакай холыклы Альбина мондый дәрәҗәгә ирешә алмый, әмма гаепне башкалардан эзли:

—Озын сыйракны якладылар. Әни аны күбрәк ярата.

Шәмсия кызынын дәгъвасын кабул итми.

—Үпкәләгән кешегә бүтәкә ашаталар. Дәресләренне ашык-пошык кына әзерләп, гел урамга, клубка шылу ягын карадың шул. Бу дөньяда бер нәрсә дә җинел генә бирелми.

Альбина үзсүзләнеп:

—Мин барыбер бәхетле булам,—ди.

—Бирсен Ходай, кызым. Икегез дә, дүртегез дә балда-майда йөзегез. Тик бәхет төшенчәсенен мәгънәләре бик күп шул. Һәркем аны үзенчә анлый.

Әнисә рухы белән әнисенә якын булса да, тышкы кыяфәтен, килешкилбәтен, озын матур аякларын үзенә һәдия иткән әтисен кызгана, анын «би», «бы», «ме», «ы» ларын анларга, юрарга, тынычландырырга тырыша.

—Әти, борчылма, мин быел медицина институтына укырга керәм. Беренче курстан ук сина ябышкан әшәке чирне шәхси дошманым итеп, ана каршы сугыш фронты ачам. Өченче, ну, бишенче курсларда сине дәвалый башлыйм. Кыскасы, алты-җиде ел тиз үтеп китәр, син элеккедән матуррак итеп сөйли башларсын. Әнигә мәхәббәттә анлашырсың... Башка кешегә түгел, кара аны.

Мортаза кызы сөйләгәннәрнен барысын да анлап бетермәсә дә, ифрат та канәгатьлек билгесен чыраеннан юып төшерә алмый. Авызын тутырып елмая. Сүзнен анын файдасына барганын чамалый, каты сөякле куллары белән Әнисәнен аркасыннан сөя, аннан елап җибәрә.

«Әтине дәваларга, телен кайтарырга» дип тәһлилләгән Әнисә коткысына бирелеп, Альбина да документларын медицина институтына бирә. Җәй буе аркага арка куеп әзерләнәләр. Мәгәр ул уку йортына яхшы укыган өчен генә алмыйлар икән, Әнисәгә бәхетен киләсе елга сынап карарга тәкъдим итсәләр, Альбинага исә, «юк белемен белән бу тирәдә баш катырып йөрмә»,—дип, кистереп әйтәләр. Иске чемоданнарын күтәреп, кызлар авылларына кайтып төшәләр.

—Армиягә китәсегез юк. Киләсе елга барырсыз,—дип тынычландыра әниләре һәм шунда ук икесен дә эшкә урнаштыра.

Әнисә мәктәптә китапханәче булып китсә, чая, үткен Альбинаны

клуб мөдире итеп билгелиләр. Бәхетләре бар икән: ике оешманың да хуҗалары туачак балалары белән бәйле ялга чыкканнар.

Озын аяклы, аксыл коңгырт чәчле, аяз күк йөзедәй зәңгәр күзле Әнисә үзгәрми, карындашының мул күкрәгенә, тулы балтырлы кыска аякларына, уймак авызына, табадан әле генә чыжлап төшкән коймактай кызарып торган яңакларына көнләшеп карый да, теоремалар, кагыйдәләр ятларга керешә. Альбина укуга кулын селти. Ана егетләр белән урам әйләнү, клубта иптәш кызлары илә ләчтит сатып утыру кызыграк тоела, миендә исә дөньяда бер тапкыр гына яшәү фәлсәфәсе, укымаганнар ким-хур яшәми дигән ышаныч тирән үренте җибәрә.

Авыл егетләре күңеленә тулы бәдәнле, кыска буйлы, тыгыз тәнле Альбина якынрак, сөйкемлерәк, теләкләрне көчлерәк уята. Шуның өстенә аның колагы белән карый, авызы белән тыңлый торган чая кыз булуын исәптән чыгарып ташларга ярамый. Чибәр кызга энә өстендә озак биергә ирек бирмиләр. Армиядән кайткан Хәмит бер-ике ай кичләрен урам әйләнеп, кызның өлгергән чиядәй иреннәрен тәмләгәч, чәчләрен бәйләргә тәкъдим итә. Егете бик үткен, флотта хезмәт иткән, шунда биергә, тәмәке төтенен борыннан чылбыр төсле бер-бер артлы тезелгән көмеш боҗралар итеп чыгарырга өйрәнеп кайткан. Шәмсия ханым сизенә: кияүгә чыгып калмаса, дәрте ташыган, нәфесе кызган Альбинасын иртә өлгергән җиләк-җимеш язмышы көтә. Һәркемнен аны тансык вакытта тәмләп карыйсы килә. Ә соңрак, күпләп өлгергәч, җиләккә берәүнең дә исе китми.

Әнисә анын кияүгә чыгуына карышып маташа:

—Чыдар хәлең калмадымы әллә, бром эч, укымыйча, надан каласың!

Кызын кызганып йөрәге әрнесә дә, ана ризалыгын бирергә мәҗбүр була. Август аеның беренче көннәрендә гөрләтеп туй ясыйлар.

Сүзеннән кире кайтмас холкы, мәхәббәт-назга иртә өлгергән тәне Альбинаны дөнья мәшәкатьләренә батыра. Анысы әле баласы, мич башында яткан анасы дигәндәй, килennән каенанасы шактый таләпчән, унган, явызлыгы йөзендә чалкан яткан хатын булып чыга. Нәкъ Шәмсия язмышы. «Нишләп кешелек җәмгыяте шулай кабатлана, мөмкинлекләре тар, чикле микән?»—дип уйлый әнисе. Татарның бар булган явыз, динозаврлар заманыннан калган карчыкларын, мәми авыз ирләрен махсус Казан артындагы, Саба аймагындагы бер авылга җыйганнар, диярсең. Альбина әле яшь, күнегер, үзенекен алыр. Анардан да «югары дәрәҗәле» каенана чыгачак бер заман»,—дип уйлый Шәмсия, ярым канәгать елмаеп.

Хәмит клубта, кызлар алдында гына шундый батыр вә булган егет икән. Әнисе янында тавышы түгел, өне дә чыкмый.

Дөрес, каенана, киленне өйгә төшереп, авызына бал белән май каптыруга, улына акыллы киңәшен биргән имеш:

—Миннехәмитем, бәхетенәме, бәхетсезлегенәме, әйтә алмыйм, ну безнең биш йөз йортлы авылыбыз бармактан яларлык мондый чибәр кызны күргәне юк иде әле. Хатының үзеңнеке генә булсын дисәң, итәгең баладан бушатма!

Әнисенең сүзен онытмый Хәмит. Әнисә башлы-күзле булырга җыенган көннәрдә Альбина өч бала анасы иде инде.

Әнисә бер еллык «хезмәт вахтасында» ныгый, тагы да житдиләнә, әтисенең сөйләшү сәләтен кайтару хакындагы беркатлы балалык хыялларыннан арынып, замана таләбен тоеп, финанс-икътисад институтына барып керә. Аны да әнисенең йөзенә кызыллык китермичә, кызыл дипломга тәмамлап, Казанда жайлы гына эшкә дә урнаша, унышсызрак булса да, гаиләсен корып җибәрә. Менә инде ул нәкъ сигез ел бер министрлыкта көнен күрә. Бүгенге вакыйгалар гына аны иярдән сөйрәп төшерде. Ахыры ни белән бетәсен белгән юк.

Әнисенең язмышы, яшьлеге турында уйлану ханымга вакытны уздырырга, кулларының сызлавын онытып торырга ярдәм итә. Хәтерләү, үткәнең булу—зур таяныч икән. Шулвакыт Әнисә кыштырдау, саклык белән атлаган аяк тавышларын ишеткәндәй булды, тирә-юньдәге усак, юкә яфраклары усал итеп шаулашып алдылар. Хатирәләргә бирелү вакытымы бу дип ханым колакларын сагайтты, аяклары белән машина идәненә тибә, ынгыраша башлады.

## 4

Шактый якын дип йөргән әшнәсе, аркадашы, «кит» кушаматлы адәм тарафыннан «атылган» Сәет Сакманов камышлар, вак куаклар, тагын әллә нинди үсемлекләр белән «бизәлгән» суда күпме вакыт ятканын әйтә алмый. Кыска гына арада зиһенен югалтып алды бугай. Өшеп, калтыранып айнып киткәннән соң аның күзләренә караңгылык пәрдәсенә төренә башлаган күк, тирә-юньдәге яндагы вак агачлар, күл буеннан аз гына арырак күтәрелеп киткән урман чалынды. Берни аңламыйча, кымшанырга куркып, үзе белән ни-нәрсә булганны болганчык хәтерендә яңартырга азапланды. Ваһапов, кулындагы үлем уенчыгын ана төбәгәч, үзендә нинди көч табып, суга сикереп, унгарак алырга, тирәнгәрәк төшәргә һәм үлән, агач тамырларына ябышып аста озаграк ятарга азапланганын, һава җитмәгәнен, сулыш аны, киресенчә, өскә төртеп чыгарырга тырышканын хәтерли иде.

Ул исән-имин калды бугай. Тирә-юньдә нинди дәһшәтле тынлык. Мәрхәмәтле тал агачы башын куярдай ботагын биргән. Күзгә су—ана карыны түгел икән, тизрәк яр буена, корыга чыгарга кирәк. Шулчак аның ярым-йорты уйларын якында гына яңгыраган көчле шартлау тавышы бүлде. Озакка сузылган коры көннәрдән соң күк ярсыгандай булып китте. Ут ялкыны тирә-юньдәге агачлардан өскә күтәрелеп, күккә ашты. Күл суы тымызык җылыга таргандай булды. Янгын ничек тиз кабынган булса, шулай ук тиз сүнде. Янәдән дөньясына гамьсез тынлык инде.

Сәет ясалма түшәгеннән торырга азапланды. Гәүдәсен күтәрә алмагач, борылып, сай судан үрмәләп китте. Шунда аның күзе шадра күл өстен бизәгән кызыл тапларга төште. Аның канымы бу? Әллә яралап өлгергәнме шайтан, дигән күңелсез уй миен өшетеп үтте. Янында гына нинди дер кара түмгәк йөзеп йөри. Игътибар беләнрәк караса, аның яраткан эшләпәсе хуҗасын эзли икән. Аны, иелебрәк, сул кулына алганда җилкәсенен бик нык авыртканын тойды. Ыңгырашып куйды һәм яр буена таба хәрәкәт итеп карады. Сазлык, аны үз итепме, малае кебек якын күрепме, җибәрергә теләми. Сәет ике кулы белән аякларын берәм-берәм тартып алып, алгарак чыгарып куйганда, истәлек-ядкарь итеп, туфлиләрен күл үзенә алып калды. Куллары белән аяк киемнәрен эзләргә иелмәкче булган иде, инбашының авыртуына түзә алмыйча, кыйналган эт кебек ирексездән шыңшып, ыңгырашып куйды һәм бар көчен туплап, авыр гәүдәсен яр буена корырак җиргә ташлады.

Яралы инбашын икенче кулы белән кысып, вак куаклыкны, адәм кулыннан ничектер исән калган көз көязе, кызыл иреннәрен салындырып, тулышып утырган миләш агачы яныннан узып, бер агач артына посып, үзләре һәм машиналары торган аланчыкны күз уңына алды.

Анда сасы истән һәм тимер-томыр хәрабәләреннән, сүнеп барган күмер кисәкләреннән башка бернәрсә дә юк иде. Сәет тирә-юньне әйләнеп чыкты, мәҗлестәшләренең мәетләрен күрергә ниятләп, калтырана-калтырана янәдән күл янына килде. Күл мәңгелек һәм шомлы сергә чумган. Яр буенда су бик сай, аста үлән, агач тамырлары, үлгән кеше аска китә алмый. Йөзеп китү мөмкинлеге дә юк. Сәетнең матур иреннәренә зәһәр елмаю инде. Ул барысын да аңлады. Җирән эше бу. Мәетләрне, бензин сибеп, машина белән бергә яндырган, үзе чыгып качкан.

Иңбашының һәм аяк балтырының авыртуы уйланырга бирми. Мәгәр бернәрсә ачык: койрыкны сыртка салып, бу җинаять урыныннан ул тизрәк китәргә тиеш. Аның шаһит яисә үзе бәлагә тарган кеше булып күренәсе, милиция беркетмәләренә керәсе килми. Ул, ярасы, авыр юеш киемнәре мөмкинлек биргәнчә, тиз-тиз атларга тырышып, тар сукмак буйлап, урманга керде. Поезд көпчәкләренең юлны кармалавы ишетелә. Шыкы... шыкы... Тимер юл ерак түгел икән.

Көзгегә карап, үзенне күрәсе иде. Чынында Сәет пычрак, лайлалы суда ятып, тәмам танымаслык хәлгә килгән иде. Чәчләре лайлада, пычрак мүккә катканнар, төсләрен тәгаенләве кыен. Иннәре ишелеп төшкән, куллары

калтырый, аяклары хәлсез, көчкә-көчкә хужаларын йөртәләр. Карсак куаклар арасыннан як-якка каранып килеп чыкканын күргән кеше, җен-пәри йә албасты дигәннәре шул түгелме икән дип курыкмый калмас. Төн, димәк, урманда, кырда узачак. Туктап калырга ярамый, кая таба булса да барырга, барырга. Тик явыз күл белән, шомлы урман гына артта калсын. Әй, сез, төнге, караңгы, куркыныч юллар, кая алып чыгарсыз икән? Сул як инбашыннан, ярасыннан кан саркып тора. Чалбар кесәсеннән юеш кульяулыгын алып, суын сыгып, ярасын каплаган булды. «Юк белән вакытны уздырам. Иң әүвәл юлга чыгарга кирәк»,—дигән уй аңа өстәмә көч биргәндәй булды, эшләпәсен жилләткән, селкегән булып, башына элде. Авырлык белән атлап, яр буендагы сукмакларның берсенә килеп чыкты, аркылы чокырдан дүртаяклап үрмәләп өскә менде. Угры кебек як-ягына каранды. Үрдән шул ук шомлы, үзендәге серләрне беркайчан да сөйләмәячәк өсте кара сулы, яр буйлары ямь-яшел күл, вак-төяк агачлар күренә, тирә-якта гына урман. Сәет «пикник» янынннан шактый читкә киткән икән. Үз-үзеңне саклау теләге (кемгә кирәген бардыр инде синең!) һәм армиядә, милициядә хезмәт итүе, спорт белән шөгыльләнүе аңа су астында үзен саклап калырга мөмкинлек биргәндер. Димәк, үтерүче ашыккан, кабаланган, юкса ул берәүне дә исән калдырырга тиеш түгел иде. Иң яхшы шаһит—фани дөньяны сиңа кирәк чакта ташлап киткән шаһит, диләр түгелме әле. Аны күмгәндә, ихластан кызганып фикерләр әйтәсең, якыннарына, туганнарына ялагайланып теләктәшлек белдергән буласың, бер уч туфрак ташлап, сәдака өләшәсең. Шуның белән вәссәлам. Бар хәбәр-күрсәткечләр җир астында. Бу көтелмәгән зәхмәттән кем исән калды икән? Йөзе чалшайган, күзе акайган Нургали Ваһаповның элеккеге баш инженеры, «уң кулы» Мостафа Гаделевка ике кургаш ярчыгы утыртканын һәм наганын аның ягына борганын Сәет тәгаен хәтерли. Димәк, акыллы башка сыймый торган әкәмәт гарасатны Нургали дус оештырган. Ни өчен? Зиһене зәгыйфьләнгәнме, шөрепләре бушаганмы? Ошбу ахырзаман тамашасында Җирәннең урыны нинди? Әгәр бу операцияне бергәләп әзерләгән булсалар, Ваһаповка ни пычагыма калтыраган куллары белән үзе атып интегергә? Җирән бу шөгыльне яратып вә остарак башкарып чыгар иде. Кызык эзли икән, буш шешә, коры ботак, мәхлук чыпчык беткәнмени? Әгәр безнең белән берргәттән, бик күп җинаятьләренең шаһиты Җирәннән дә котылырга уйлаган булса? Монысы, бердән, буш хыял, Җирән үз эшенең остасы, һәр көнне һөнәрен чарлап тора, икенчедән, берниндин гадәти мантыйкка сыймый торган шәй. Әгәренки, Нургали Ваһапов безнең белән берргәттән, Җирәнне теге дөньяга озатырга ниятләгән булса, димәк, ул үзе дә фани дөньяда яшәп киткән кешеләр аймагында.

Күнелсез уйларының очына чыгарга тырышып, Сакманов янындагы куакка таянып, тәнендә сакланган көче мөмкинлек биргәнчә, киемнәрен салып, сыккандай, җилләгәндәй итте. Шул киемнәре белән, эшләпәдән һәм оекбаштан вагонга килеп керсә, халык аны ничек кабул итәр иде икән? Хәер, хәзер адәм баласын берни белән дә шаккатырып булмый. Артыграк салган, аңа бу өс-баш килешеп тора, диярләр.

Аяк табанын авырттырмаска тырышып, песи кебек кенә юлны кармалап атлап, тар бер аланны чыкканда, Сәет ыңгырашкан тавыш ишеткәндәй булды. Агачлар арасыннан, елан кебек башын гына чыгарып, як-ягына үткен караш ташлады. Игътибар итмәскә дигән карарга килде: яшьләр дәрт, ләззәтләрен эчкә сыйдыра алмыйча, тавышка, авазга күчерә торганнардыр. Ыңгырашу янәдән кайтавыз булып килгәч, Сакманов ирексездән, шул якка күз салды һәм яшел төсле җинел машинаны күреп алды. Күрәсең, бәхетле ыңгырашу авазлары шуннан килә торгандыр. Ярулла улы юлын дәвам иттермәкче иде, тавыш көчәйде, инрәү кебек чыкты, аяк белән тимергә типкәндәй тоелды.

Сәет машинага якынрак килеп тәрәзәдән эчкә күз салырга җөрьәт итте. «Ниссан»ның алгы утыргычында куллары артка каерып бәйләнгән, авызына чүпрәк тутырылган адәмне чамалады. Бернәрсәгә дә гаҗәпләнмәскә, шаккатмаска күнеккән Казан мафиясенең күренекле вәкиле, утларны-суларны кичкән Сакмановны да гаҗәпләндерерлек иде бу манзара. Урман

эчендә ялгыз җинел машина. Утыргычка, Сәетнең тәҗрибәле күзе чамалап алганча, яшь чибәр ханым бәйләп куелган. Нәрсә бу? Ничек аңларга бу хәлне? Машина кемдер якын килүгә эчендәге, янындагы кешеләрне упкынга эләккән йомычкадай үзе белән ияртеп шартларга җайланган булса яисә агач төбенә сыенып утырган киллер чит кеше якынлашуны саклап утырса, үзеңне җәһәннәмгә озатса? Мондый борылыш-уеннар, дөресен әйткәндә, Сәетнең планында каралмаган, башка зат өчен әзерләнгән кургашны гына җыеп йөрисе калмаган.

Сәет акрын гына кире чигенә башлады. Янына кеше якынлашуын сизеп алган хатын сәер ыңгырашу, ялвару ымлыклары чыгара, аягы белән ярсып-ярсып машина идәненә тибә башлады. Шул рәвешле үзенә игътибар, ярдәм сорый иде бугай, бичара.

«Син, иптәш Сакманов, сәвит офицеры, төп һөнәрең буенча милиционер, ялгыз хатынны бу хәлендә ташлап китә алмыйсың, белешергә, ярдәм кулын сузарга тиешсең».

Сакманов аяк очына гына басып атлап, яшел машина янына килеп чүгәләде. Гаҗәп хәл, ишекләре биктә булса да, хатын ягындагы тәрәзә яртылаш ачык.

Сәет ачык тәрәзәдән кулын тыгып, акрын гына ишекне ачты, бер кулы белән утыргыч өстенә таянып, икенчесе белән ханымның авызыннан кара пычрак чүпрәкне тартып алды. Тегесе һава җитмәүдән, авыз мускуллары авыртудан интеккән иде бугай, ашыга-кабалана сулый, төрле ирен хәрәкәтләре ясый башлады. Шуннан соң гына, «рәхмәт» сүзен кысып чыгара алды һәм күзләрен Сәеткә төбәде. Янында басып торган ир белән үзен шул хәлдә ташлап киткән баскынчылар арасында аерма күрмәде. Монысы, киресенчә, тагын да сәер, куркыныч, пычрак күренә, «бомж» дип шундыйларны атыйлардыр инде. Тимер юл вокзаллары тирәсендә ышкынып йөрүче бер йолкыш, исерек баштыр. Сайланып торыр хут юк, өлешенә тигән көмешең, кулларны гына чишсен. Станциягә кемнедер эзләп киткән теге кабихларнын кардәше булмаса. Әгәр шул кеше нәкъ үзе булып чыкса, нихәл итәрсең? Авырткан башка тимер тарак дигәннәре шулдыр инде. Ханым, суда батучы саламга ябышкан кеше кебек:

—Зинһар, кулларымны чишегез!—дип ыңгырашты.

Шактый изаланды Сәет бау белән. Канны аз югалтмаган булса кирәк, кулларынын җегәре киткән. Азаплана торгач, ханымны азат итте. Әнисә урамга чыгып, яшь кәҗә бәтиедәй сикеренде, кулларын язды, шуннан соң гына коткаручысы ягына борылып сөаль бирерлек көч тапты:

—Сез кем буласыз, бирегә ничек килеп чыктыгыз, ни эш бетереп йөрисез?

Коткаручысының «тегеләр» кешесе түгел икәнлегенә инанган иде инде ханым. Сәет, тавышына үпкәчел төсмер чыгарып:

—Рәхмәтләр укып, битемнән әп итеп аласы урынга сорау арты сорау яудырасыз, әйтерсең лә, мин гаепләләр эскәмиясендә утырам,—диде.

Ханымның йөзенә җинелчә кызыллык йөгерде.

—Әлбәттә, сезгә рәхмәтнең иң зурысы. Шулай да каян килеп чыктыгыз сез, кеше йөрми торган урынга.

Ә үзе «мондый шакшы битне үбүдән Ходаем үзе сакласын», дип уйлап куйды.

Сакманов шул авыр яралы хәлендә, күңелсез халәтендә шаяртыр көч тапты. Башкача ярамый. Кем икәненне, нәрсә эшләп йөргәнеңне чыгар да сал, тот капчыгынны...

—Космостан сезгә ярдәм кирәк дигән хәбәр алдым һәм йөгереп, суга бата-чума, аяк киемнәрен сазлыкка бүләк итә-итә килеп тә җиттем.

Шунда гына Әнисә чәчләренә кырау төшсә дә, әле нык, таза абзыйның велюр эшләпәдән һәм аксыл йон оеклардан басып торуына игътибар итте. Фаҗигасе турында онытып, көлеп җибәрде.

—Сез, абый, берәр клоун-мазар түгелме соң?

—Булса соң. Клоуннар кешеләрнең күңелен күтәреп, гел изгелек эшләп йөриләр. Менә мин дә сезне ниндидер сәер пленнан азат иттем.

Фаразымча, сезне яраткан яна бай кылган изгелекләрегез өчен машина бүләк итәргә булган. Сез, кыргыйланып, баш тарткансыз. Ул бәйләп киткән.

«Бу ир анын язмышыннан хәбәрдар түгел, бугай. Теге шайтаннар белән бәйле булса, бауларны чишмәс, болай теленә салынып тормас иде. Инбашын кысып тоткан, чү, аннан кан саркый түгелме»?

—Сез әллә яралымы?

—Космостан сезгә ярдәм итәргә дигән әмерне алгач, бик ашыктым. Имән ботагына туры килдем. Бик тирәнгә керде. Хатын-кызның барысы да шәфкать туташы бит. Бәлки, яраны бәйләп тә куярсыз әле. Кунак ашы—кара-каршы булсын инде.

Бу иргә ышанырга була, анын да хәле шактый катлаулы, бергә генә котыла алабыз дигән фикергә килеп ханым машинасыннан әйберләрен алды, Сәетне дусларча килеп култыклады, «Киттек биредән. Тизрәк ычкынсак яхшырак булыр».

—Ә машина? Ни өчен җәяү китәргә? Бензиныгыз беттеме? Мал җинел эләккәч, яшьләр анын бәясен дә, ягулык белән эшләгәнен дә белмиләр шул,—дип, өлкәннәрчә мыгырданып алды.

Әнисә ир ягына гасабиланып, үртәлеп, һәр дәкыйкасы саф алтыннан кыйммәт вакытны юк-бар турында сөйләнеп әрәм итүе өчен рәнҗеп, күз атты. Хозыр Ильяс кеби әллә каян килеп чыккан сәер коткаручыга үпкәләп тә булмый. Ул берни белми.

—Мин, иптәш, бандитлар кулына эләктем. Заложница. Алар икәү, коралы. Станциягә, йомышлары белән киттеләр. Менә-менә әйләнеп кайтулары бар. Машинанын бензины житәрлек.

—Ник вакыт уздырып торабыз, үзегез әйтмешли. Киттек. Шәһәргә чаклы мине дә, бәлки, алырсыз. Бавыгызны чишкән өчен булыр.

—Җәяү китәргә туры килер шул.

—Ни өчен? Кабынмыймы? Без аны хәзер тәртипкә чакырырбыз,—дип Сәет, онытылып китеп, кулларын уып алган иде, ярасы үзе турында искә төшерде. Ыңгырашып куйды.

—Тизрәк китик без бу тирәдән. Милициягә барып хәбәр итик... Ачкычларны үзләре белән алып киттеләр шул.

Акыллы хатын икән, зәнгәр күзләрен Сәет ягына борып, тукталып-төртелеп калды.

—Хәзер менә дөрес уйлап, дөрес туктадыгыз. Мина милициягә барырга ярамый әлегә. Сезне дә җибәрә алмыйм. Властьларга яхшатланып, бәйләп киткән узаманнар турында гына түгел, минем хакта да бер-ике кәлимә сүз ычкындыруыгыз бар.

Әнисә еларга да, көләргә дә белмичә: «Бер көндә ике тапкыр заложница буламмыни инде мин. Йа Ходам. Ник тудырдын, анам, мине бу фани дөньяга»,—дип, бераз артистланып та алды. Сәетнен фикер сөреше, үз-үзен тотышы, хәтта кискенлеге ана охшаганнан охшый бара. Төз, тыгыз гәүдәсе турында әйтеп торасы да юк.

—Хәзер болай итәбез,—диде Сәет, каршы килергә урын калдырмыйча.— Сез бер әр чүпрәк белән минем яраны кысып бәйлисез. Ә мин машинаны турыдан кабызып карыйм. Ачкычсыз.

Машинанын аптечкасында бинт белән йод калган икән, Әнисә яраны эшкәртеп, тыгыз итеп бәйләде. Сәет әүвәл бер корыган агачны сындырып, күсәк әзерләп, аны машинага сөяп куйды. Уртак фаҗига әле чирек сәгать элек кенә бер-берсенен дөньяда яшәүләрен белмәгән кешеләрне тиз якынайта, бер тәсбих җебенә тезә, бик күбесе шуннан бер-берсенә ифрат игътибарлы, ярдәмчел булып калалар. Сәет тә «син»гә күчүен сизми калды.

—Исеменне оныттым.

—Ничек инде ул белмәгән исемне онытып була,—дип, ханым каршы килеп маташты да:—Әнисә,—дип өстәде.

—Әнисә, юлны, як-якны күзәт. Сразы мина хәбәр бир,—дип, машинаны актара башлады, чыбыкларны тартып чыгарды, кисте, ялгады, кесәсендә сакланган үз ачкычларын тыгып, борып карады. Чит ил машиналары катлаулы шул, гел чыбык та электроника, бер җаен табып булмый. Ширкәт сәрвәре

булып алгач, Сәетнең машиналарда казынырга вакыты булмады. Ихтыяж булганда, әзерен ишек төбенә китереп куялар иде...

Киракмәгәндә караңгылык пәрдәсе җирне капларга ашыга шул. Бандитлар килеп чыкса, күрми калуың бар. Сукыр куяннарны аткан кебек, ике мәет калдырып, иплән кенә машинага утырып китәрләр. Кем көчле, кем белә, техника шуны тыңлый, аның этнеке кебек тәгаен зурлый торган хуҗасы юк.

—Барып чыкмый, Әнисә, синен бандитларына хезмәт итмәсен дисәк, дүрт көпчәген дә тишәбез дә, юлга чыгабыз. Автобус тукталышын табарбыз әле. Туктале, туктале... Бу чыбык бензинга юлны ачты бугай. Машина калкулыкта тора. Утыр әле рульгә. Мин этәм, син икенче скоростька сал...

Сакманов аякларын терәп, исән инә белән машинаны алга әйдәде, тегә, чырт-пырт итте һәм, боларның хәленә кереп, кабынып китте. Әнисәнең яңа танышын, күсәген кочаклатып, шунда калдырып китеп барырга мөмкинлеге бар. Аның монысы да шул ук угрылар, караклар, бандитлар нәселеннән булса кирәк. Тик бусы зыялы, акыллы күренә. Алар арасында иртәгә Президент итеп утыртырлык зирәкләре бар, диләр. Ул азат итмәсә, ни белән бетәр иде ошбу эпопея? Машина шып итеп туктады. Сәет күсәген юлга аркылы куйды да, машинага йөгерде. Чөнки сул яктан аларга таба ниндидер кешеләр йөгерә-атлый килә иде. Сакманов алга кереп утыруга, ату тавышлары ишетелде. Пулялар машинага тимәде.

Бер көн эчендә бер гомерлек ачы тәҗрибә алган Әнисә Асылбаеванын машинасын туктатырлык көч юк иде инде дөньяда.

—Сез нинди көчле,—дип, Әнисә куршесенә мактау сүзе әйтергә тиеш тапты.

—Сөләйман пәйгамбәр заманасыннан ук хатын-кыз ирләрне мактау белән алдап, үз янында тоткан,—дип, Сәет рәхмәтен әйтте. Әнисә кабалана. Шоссега чыгып, эзгә төшкәч, чак кына күпер башы баганасына бәрелмәде. Берәүнең дә нервылары корычтан ясалмаган. Тимер дә чыдамый, шартлап сына торган хәлләр була.

Үз уйларына чумып утырган Сәет Әнисәнең хатасын сизми калды. Бер яктан, иңбашының сызлавына күз аллары караңгыланып китә, икенчедән, аның хәле һәр яктан мөшкел иде. Нургали Ваһаповны хәл итеп, ике мәетне һәм машинаны яндырган Җирән (шулай буласына Сәетнең бер кәррә шиге юк) Сакмановны йә үләләр, йә терeләр арасыннан эзли башлаячак. Табылмаса, анардан бала көткән Фәридәдән үч алачак. Сәет хәзер Казанда күренсә, Җирән табылганчы, Ваһаповнын, Гаделевның якыннары, дусишләре, Сакмановның дошманнары, көндәшләре бар гаепне аңа өячәкләр. Гаяровка янәдән эреләнеп, «сезнең пычракны сөртә-сөртә, үзем керләнеп бетәм инде», дип зарланып алырга мөмкинлек туа. Җирән барысын Сәет өстенә аударырга тырышачак. Акылы муафыйкъ булса, берәр чит шәһәргә, хәтта илгә чыгып китәргә тиеш.

Сәет Сакманов мәсьәлә ачыкланганчы, фаҗига беркадәр онытылганчы, бу вакыйганы башка, тагын да текәрәк үтерешләр, суешлар каплап киткәнче, югалып торырга, аска төшеп ятарга тиеш. Кая? Кемгә? Әхмәдиша карт исән булса, берәр танышында яшерер иде дә, изге җан Сәет энекәшен ташлап китте, үз янына хәләл җефетен дә алды. Малае эчкече, тинтәк булып чыкты. Фәридә янында күренергә, хәтта хәбәр итәргә ярамый. Менәтерә, күпме байлыгы, ничәмә фатиры, кунакханәсе була торып, авыр хәлдә кайтып егылырлык ятагы юк. Уйларын ханымның соравы бүлдерде. Тавышы ягымлы икән шайтанның.

—Сезне кая алып барырга?

—Мин Сәет Сакманов дигән кеше булам,—дип җавап бирде «Игелек» ширкәте сәрвәре әллә сорауны аңламыйча, әллә башын юри юләргә салып.

—Бик әйбәт. Мин адресыгызны сораган идем. Әйтергә теләмәсәгез, теләсә кайсы тукталышта калдыра алам...

Шунда ханым ирнең оектан гына, курткасы, күлмәге канда, житмәсә юеш икәнне шәйләп алды, төпченүдән туктап, хәрәкәтен дәвам иттерде.

—Минем хәлем авыр, Әнисә, мөмкин булса, үз өегезгә алып кайты-

гызчы? Мәшәкать тудырмам. Курыкмагыз. Мин—житди кеше. Акрынлап үзем, бүген минем баштан узган вакыйгалар турында сөйләрмен.

—Минем ун яшьлек улым бар. Ул нәрсә дияр?

—Мине үлемнән коткарган, әсирлектән азат иткән Сәет абыең белән таныш бул, улым, диярсең!

Асылбаева тәвәккәлләде, артык сораулар бирмәде. Чыннан да, ул канга батып, юеш киемнән утырган иргә исән калуы, улын күрүе белән бурычлы, нәрсә анда үзен әллә кемгә куя, кылана. Әнисә аңа мәңге бурычлы. Анык карарга килеп, машинасын подъезд төбенә үк китереп туктатты, моторын эшләтеп калдырып, Сәетне култыклап лифтка алып керде. Кызыксынучылар күз жегәрләрен әрәм итмәсен дип, почмаккарак бастырып, күкрәгә белән амбразура каплаган төсле, Сәетне ышыклап барды, тиз генә фатирын ачып, эчкә уздырды.

—Менә бу шкафта иремнең иске киемнәре булырга тиеш, сайлап алыгыз кирәкләрен.

—Ә үзе кайтып кермәсме? Гафу итегез.

—Борчылмагыз, кайтып кермәс. Ул—тю-тю,—дип, матур итеп сызгырды Әнисә.

—Мин машина куярга киттем.

—Башка ачкычыгыз бармы?

—Онытканмын да. Сүндерә алмыйча интегермен. Нишләргә?

—Ягулыгы беткәч, үзе сүнә ул.

—Ярый, мин йөгердем.

Әнисә ике бүлмәле, Ленинград проекты белән төзелгән фатирда яшәп ята икән. Чисталыгына, лифтның эшләвенә, йортның кирпечтән булуына караганда, кооператив йорт булырга охшый. Бүлмәләре зур булмаса да, бик жайлы урнашкан. Аш-су, йокы бүлмәсе озын коридорның бер ягында, янә бер бүлмә бөтенләй читтә, уң якта. «Анысы, Сәет иптәш, тәртибең яхшы дип табылса, картлыгына скидка ясалса, синә булыр»,—диде үз-үзенә Сакманов. Адәм баласын авыр, иң хәтәр, болганчык вакытларда юмор хисе, авырлыкларны үткәрә белү тәжрибәсе коткара.

Мебельләре кыйммәтле түгел, әмма зәвык белән сайлап алынган, һәркайсы үз урынында. Олы бүлмәдә, кухняда телевизорлар тора. Киемнәр эзләп кеше шкафында актарынырга яхшысынмаса да, күл, үлән, мүк исе килеп торган киемнәрдән, үтеп киткән фажигале көн басымыннан арынасы, авыр йөкне жилкәдән төшереп ташлыйсы килү—табигый халәт. Сәеткә мөнәсәбәтебез нинди булса да, бу омтылышы өчен аны гаепләве кыен иде. Ул кием шкафыннан, аркылыга кызыл сызыклар төшерелгән ак төсле халат тапты. Үлчәп караса, аның өчен махсус тегелгән диярсең. Үзенең сәгатен, ачкычларын, таныклыгын алып телевизор астындагы комод читенә куеп, киемнәрен ваннадагы тазга ташлап, ярасына тидермәскә тырышып, тәнен сабынлап юынды. Шул мизгелдә хужабикә кайтып керде, ваннага шакылдатып, «берәр нәрсә кирәкмиме», дип белеште.

Сәет сөртенеп, яшәреп килеп чыкканда, кухняда кичке аш әзер иде инде. Әнисә, кунакка карап, пырхылдап көлеп жибәрде:

—Минем халатны кигәнсез ич.

—Мина таман, үзегезгә кирәкмиме?

—Юк, юк. Утырыгыз.

—Мин, Әнисә ханым, булса бер-ике рюмка коньяк, һич югында аракы эчәр идем. Бүгенге стресслардан соң, өшеп торам, тешем тешкә тими.

—Табарбыз. Мин үзем дә әле исән-имин калуыма ышанып бетә алмыйм. Бу хәлләр минем белән булдымы соң, дип, үз-үземә сорау бирәм дә чәчләрем үрә тора, тәнем калтырана башлый.

Машинада кайтканда, аннан соң шактый вакыт кызулык белән, исән калу шатлыгыннан, яралары авыртуын һәм бигрәк тә көзге күлдә яту нәтижәсен Сәет сизми иде әле. Бераздан ул туна башлады. Салкын әүвәл аякларына төште. Кеше фани дөнья белән саубуллашканда, әүвәл аяклары суына, ди бит. Сәет үлемнең жанны өшеттергеч, беркадәр төче исен сизгәндәй булды. Ләкин аның әле тиз генә бирешәсе килмәде. «Ике тапкыр төзәп

атудан калган килеш сасы күл салкынына бирешеп торырга», дип ул, үзен үртәп, котыртып, рухын күтәрергә тырышып үрсәләнде. Үзе белгән барча алымнар белән аякларын жылытырга тырышты. Юрганны ике кат бөкләп аякларына япты, башы астындагы мендәрне аска төшерде, аякларын бер-берсенә ышкып, куллары белән жылытып карады. Аякларга жан кермәде. Әйтерсең лә, аяк табаннарына, бармакларга эчке яктан котып бозы тыгып куйганнар, шул суыкны өрдереп тора.

—Аякларым туңа,—дип ыңгырашты Сәет.—Берәр төрле әмәлен табып булмыймы? Газ плитәсе өстенә куясымы әллә үзләрен. Кешенең жаны жылылык белән бергә аяктан чыгып китә дип ишеткәнем барые, хактыр ахырысы.

—Юкны сөйләмәгез. Мондый көфер сүзләрне авызыгыздан жил алсын, жылынырсыз,—дип, Әнисә ирне юатырга тырышты, ә суык аякларны кулларына алырга тарсынды: бөтенләй белмәгән, чит кеше ич.

—Бәлки, врач чакырырга кирәктер.

—Юк. Юк... Борчылмагыз. Ярам тирән түгел, тирене генә эләктереп узган. Салкын тию узар.

—Минем шәфкать туташы таныклыгым бар, малаема да уколларны үзем ясыйм. Сезнең өчен куркам. Берәр төрле заражение булмасын.

—Жаваплылыктан куркасызмы?—диде Сәет, ханымны котыртып.

Тегесе ихластан жавап бирде.

—Дөресен әйткәндә, әйе. Урманны чыкканда, исем-фамилиягезне әйткән идегез. Хәзер исемә төште. Минем дустымның сезнең фамилияне телгә алганы бар иде.

Сәет сүзнең жебен өзмәс өчен генә чыраена кызыксыну, хәтта борчылу төсмере чыгарып, кызыксынгандай булды:

—Мактапмы, сүгепме?

Укыган кеше укыган кеше инде ул. Ханым да сыртка төшә торганнардан түгел икән.

—Бәясен хәтерләмим. Хатын-кыз эше түгел,—диде Әнисә, матур иреннәре белән елмаеп. Елмаю килешә икән үзенә. Бит алмалары чокырланып китә.—Сакманов егетләре фәлән-фәлән литр спирт, киемнәр алып киттеләр. Аның белән эш итүе ышанычлы, дигәне хәтердә.

Киң дип авыз корыткан дөньябыз нинди тар икән.

Шул вакыт фатирны үз ачкычы белән ачып кергән ун яшьлек Илдар бүлмәгә башын тыкты. Әнисе диванда яткан кешене арты белән каплап утыру сәбәпле, малай, баш киемен якындагы урындыкка ташлап, сорауларын яудырды:

—Әнием, кем бар анда? Әти килмәгәндер?Әллә теге абзыймы?

—Юк, улым. Әтиең бит шимбә көнне, күрше бакчага гына килә.

«Теге абзый» турындагы сорауны «онытып», улының фикер юнәлешен башкага юнәлтергә омтылып:

—Кулларыңны сабынлап ю да, ашарга утыр.

Малай да булсын, диванда кем ятуын белми дә калсын, ди. Так не бывает, дияр иде берәү. Әнисе кебек үк аксыл-коңгырт чәчле, озын буйлы, ак тешле Илдар тавыш-тынсыз гына атлап, Әнисәнең жилкәсе аша аркасында яткан иргә күз сала. Яшь, бөркет күз иңбаштагы яраны, кан тапларын күреп ала. Бу манзара әзерлекле жирлеккә төшеп, аның хисси дөньясын уятып жибәрә. Малай залга чыгып, үрле-кырлы сикеренеп кычкыра башлый:

—Урра, бездә шпион. Ура, безгә дә шпион кунакка килгән. Ярасы да бар.

Мондый тәэсири борылышны көтмәгән өлкәннәр аптырашып, бер-берсенә карашып, сүзсез калалар. Бу—икесе өчен дә көтелмәгән, һичнинди программа буенча каралмаган, яңа бер вәзгыять иде.

Хатын, аңына килеп, улы янына чыкты, иңнәреннән алып, Илдарны гәүдәсенә кысты, үзенеке төсле үк чәчләреннән сыйпады:

—Нишләп шулай шаулыйсың, Илдарчик. Нинди шпион булсын, ди. Шпион кем була соң ул?

—Шпион ул дөреслек яклы кеше. Күрше подъезда яшәүче Андрейның

әтисе эшкә киткәч, әнисе янына гел шпион килә. Ул бик добрый. Конфетлар өләшә. Аның пистолеты да бар. Безнең шпион абыйның пистолеты бармы?

Әнисә ни өчендер кызарып, алсуланып алды.

—Бардыр, улым, бардыр. Белмим.

—Шпион абый бездә яшәргә калсын,—диде малай ихластан.

Һич уйламаганда килеп чыккан ошбу хәл-әхвәл ханымны почмакка китереп кысты. Ире белән аралары күптән өзелеп, хәзер ул—тол ялгыз хатыннар, Илдар—анасы тарафыннан гына тәрбияләнүче малайлар рәтендә йөри. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, малай әллә ниткән «шпион» образын уйлап тапкан. Без үскәндә шпион кабәхәт, кыйбласыз, акчага, байлыкка сатылган, каһәрләнгән кеше саналып, кабан дуңгызы рәтендә йөрсә, хәзер әнә ул чистый унай каһарман икән. Әтиләре эштә чакта, әниләренең хәлләрен белергә килә икән. Изгелек беләндер инде, әлбәттә.

Илдар өйгә язмыш фәрманы белән килеп эләккән кеше турында, алар аңлавындагы шпионга юрап, Андрейга, башка дус-ишләренә сөйләп йөри башласа, бетте баш, калды муен тырпаеп.

Улына әлегә үзе белән булган хәлләр турында дөресен сөйләп булмый, ул аны үзенчә аңлап, мактанып, масаеп йөриячәк. Ялганласаң да, ышандырырлык, хәтта үзең инанырлык вакыйга уйлап табарга кирәк. Әтисенең туганы дисәң, шимбә көнне очрашканда, «ник абыең белән элегрәк таныштырмадың», дип бәйләнүе бар.

Чечня сугышында катнашкан, шунда яраланган ерак туганыбыз кебегрәк ялганны ызанга кертеп җибәрсәң, барыбер дус-ише алдында мактанудан тыела алмас. Малай-шалайның күп белергә теләве, кызыксынуы, тыкшынуы олыларга вакыты белән шул чаклы зур мәшәкать тудыра, әнә тишегеннән чыгып качардай буласың.

Әнисә улын аш-су бүлмәсенә алып чыкты, алдына кыздырылган казылык, каймак, ипи куйды.

—Аша, улым. Башка әйбер пешерергә өлгерә алмадым. Бу абыең шпион түгел, әбиең ягыннан безнең туганыбыз.

—Ана кем аткан? Батыр яралы була, диләр. Бу абый батыр була инде алайса. Нинди кызык,—дип малай, урынында сикеренеп, кулларын чәбәкләп алды.

—Шаулама, Илдар. Аңа беркем атмаган. Машинасы авариягә очраган. Сул як тәрәзәсенең тимере кулбашына кергән. Ярасы төзәлгәнче, может, бездә калыр.

Сугыш, атыш, үтереш, качыш белән бәйле хикәяләү көткән Илдарны, табигый ки, мондый гадәти аңлату канәгатьләндерми. Кәефе кырыла: кызык булмый калды бит! Малай иренеп кенә чәнечке белән казылыкка үрелә.

Әнисә, улын калдырып, диван кырына ипле итеп чүгәләп, Сәетнең яраларын тазартып, сөртеп, янәдән тыгыз итеп бәйләде. Батырның икс ярасы да куркырлык тирән түгел икән. Бу шөгылен аның ашыкмыйча, яратып, яра кырындагы урыннарны сыйпый-сыйпый эшкәртүе Ярулла улының игътибарыннан читтә кала алмый.

—Тәнегездә ярасыз урын юк диярлек. Сез Чечнә сугышларында катнашмагансыз ич? Яраларыгызны Илдар күрсә, хөрмәте бермә-бер артыр иде.

—Без катнашкан орыш-фетнәләр белән чагыштырганда, Чечнә—балачага уены, хөкүмәт акчасын бүлешү генә.

Асылбаева киренке халәтеннән арынып җитмәгән иде әле, күз алдында һаман теге үләтләр тора, шул сәбәпле Сәетне аңлап бетермәде. Автомат рәвештә диярлек соравын бирде.

—Нинди ул тагын мин белмәгән, ишетмәгән сугыш?

Сәет фикер агышын янәдән жинелчә шаярту, сүз уйнату юлына кертеп җибәрергә тырышты, хәле шәптән түгел, температурасы бар иде, бугай.

—Илдар әйткән шпионнар сугышы инде.

—Андый гына булса ярый. Әфәндем, безгә дә капкалап алырга вакыт җитмәде микән? Чәйгә чыга аласызмы? Әллә биргә генә алып керимме?

—Ничек инде аш бүлмәсенә генә барып житә алмыйм, ди.Әле синең ике бандитыңны күсәк белән сугып үтерергә җыенган идем.

Әнисә үрсәләнеп, иркәләнеп, иреннәрен турсайтты.

—Минекеләр дип инде. Рәсәй бандитлары барысы минем милек буламыни?

Сәет исән кулына Әнисәнең учын алды, ярылган иреннәренә тидерде. Рәхмәт әйтүе иде. Аш-су бүлмәсендә бая сораган ике рюмка аракыны эчеп куйды. Ханым үзе дә тартынып тормады, аңа да бүген нервыларын тынычландыру өчен ярдәм, өстәмә көч кирәк. Өстәлдә булган нигъмәтләрне капкалап, чәйләп алгач, шәраб пары миләренә менеп житкәч, бер сәбәпсез көлешә башладылар.

—Сез үзегезне күз алдына китереп карагыз: агачлар арсыннан килеп чыгасыз, башыгызда кыйммәтле эшләпә, аягыгызда ертылып беткән чабаксар оегы, өстегездән тамчы тама... Су атасы диярсең...

—Үзеңне бел. Авызында кирза итек сөртергә дә ярамый торган пычрак чүпрәк, син шуны сабый баладай суырып утырасың, кулларың артка каерып бәйләнгән. Теләсәң ни кыйландыр. Ыңгырашуың ошады, килештереп, кенәри, тутый кош, иң оста фәхеш хатыннар тавышы чыгарып, үзенә чакырдың.

Барча ак, дымлы тешләрен күрсәтеп, дөньясын онытып кычкырып көлеп утырган ханымга иң соңгы чагыштыру охшап бетмәде бугай. Сәет тә арттырып җибәргәнен аңлады. Сүз шул коштан да хәтәр, кире кайтмый. Мактанып алырга булды.

—Күсәкнең нинди шәбен юнәткән идем. Берсенең башына, икенчесенең биленә тондырам, пистолетларын алып, үзләрен бәйләп, урманда ташлап калдырырга иде исәп. Курыктылар, килеп житмәделәр.

—Ә ни өчен милициягә хәбәр итмибез,—дигән, Сәет өчен авыр сөаль ханымның теленнән бик җиңел төште.

—Безнең хөкем оешмалары яхшылыкны аңламый. Алардан ераграк торуың хәерле. Иң әүвәл үзебезне үк ябып куеп, бездән үк сорау ала башлаячаклар.

Күренеп тора, хуҗабикә төшеп калганнардан түгел. Сәетне дикъкать белән тыңлаган булып, бөтенләй башка нәрсә турында уйлап утыра.

—Фаразыгыз дөрес, нәкъ шулай булыр иде. Сезнең дә милициядән куркырга башка сәбәбегез бар кебек.

—Без икебез дә бүген криминал дөнья корбаннары түгелме?

—Минем гаебем юк,—диде Әнисә, Сәет белән бер басмада торудан баш тартып.

—Мәсьәләгә тирәнтен караганда, минем дә гаебем юк, мин дә нәкъ сезнең шикелле очраклы яисә явыз ният корбаны. Ләкин бит дөреслек юлы һәрвакыт авыр, берәүнең дә тирәнгә керәсе килми.

—Сезнең белән ни-нәрсә булганы миңа мәгълүм түгел. Кем әйтмешли, кара урман. Минеке ике икең дүрт, яз артыннан җәй килгән кебек ачык,—дип, ханым үҗәтләнүен дәвам итте.

Сәет болай да чамалы жегәрен алган, нигездә буш сүз көрәштерүдән туйса да, аның үз максаты бар иде: берничә көнгә булса да, аякка басканчы, мәсьәлә ачыкланганчы, биредә, Әнисә фатирында качып (фу, нинди килбәтсез сүз) яту. Куркып яисә хатын-кызлыгын итеп, кәжәләнеп баш катырмасын өчен, мәгълүм күләмдә аны да уртак арбага жигәргә, тәртәгә кертергә кирәк. Теләсә нинди чыгымчы атка каеш табып була, диләр.

—Килешәм. Хәзер сез үзегезгә ике бандитның һөҗүм ясавы, машинагызга кереп утыртулары, куркыту, янаулары турында хәбәр иттегез, ди. Анда озын-озын протокол тутыра башлаячаклар. Исем- фамилиягез, эшләгән урыныгыз, адресыгыз, машинагызның маркасы, номеры... Шуннан китә, мондый кыйммәтле чит ил уенчыгын нинди акчага алдыгыз, кая һәм нинди бурыч белән бардыгыз, әлеге бандитларны нинди максат белән яныгызга утырттыгыз, узып китәргә тиеш идегез, ни өчен туктадыгыз? Сезнең иске танышларыгыз түгелме, адресларын белмисезме? Алар хәзер кая, табып китерегез. Ошбу кеше үтерүчеләр сезнең сообщниклар түгелме?

Ханым, тырнаклары алсу төскә буялган куллары белән йөзен каплады.

—Житте. Кошмар. Йа ходам. Инде нишләргә?

—Берни булмагандай яши бирергә! Яраларым рәтләнгәнче, мине ят эт шикелле өйдән куып чыгармаска! Хәзер миңа телефоннан шалтыраткалап алырга рөхсәт итегезче? Кыен мизгелләрдә дуслар кирәк, якынлык шунда сынала.

«Милициядәге таныш-белешне борчырга иртәрәк әле, алар «өлгереп» житәргә тиеш. Фәридәгә исәнлегем турында бирәр ничек хәбәр итәрмен, әлегә телефон аша бәйләнешкә керергә ярамас. Астан кисеп, өстән ямау сәләтенә генә ия Хәлилгә дә ышанып булмый. Сатуын сатмас, әмма миң дә бер сәбәп табып, ярдәм дә итмәс. Хәзер аңа төрле-төрле киемнәр, азык-төлек, бәлки, машинасы да кирәк булыр».

Бер ышанычлы кешесе бар кебек. Ырынбур төрмәсеннән исән-имин чыккач, Әлфия Мисхәттән чын-чынлап фән әһеле ясарга ниятләде. Профессор Рамил Вәлишин, кандидатлык имтиханнарын тапшыруга, Мисхәтне Алманиягә Франктфурт шәһәренә тел өйрәнергә һәм материал жыярга жибәрергә ниятли.

Мисхәт белән чибәрләрнең дә гүзәле булып киткән Әлфиягә Сәет шактый матди ярдәм күрсәтте, егет барасы шәһәрдә үзенең исәп-хисап счетын ачып жибәрде, ашарга сорамый, кара көнгә кирәк булыр дип, шактый акча күчерде. Алардан ярдәм сорарга була, шатланып риза булырлар.

Телефон янында уйланып утырганда, хәзер инде үзе бернича кибет һәм Казан читендәге базар хужасы—Замир исенә төште. Аңардан да ышанычлы кешесе табылмас. Тик ул аның телефонын хәтерләми икән. Адресы күңелдә. Белешмә бүлеге аша номерны язып алды, шалтыратты. Алтынчыда укучы кызы аны танымыйча, «кем сез, нәрсәгә ул» кебегрәк сораулар бирә башлаган иде, Замир трубканы үзе алды.

—Кайнар сәлам, Замир. Хәлләрең?

Элеккеге йөртүчесе аны сулышыннан ук таныды, шатланды, кирәк булса, жанын ярып бирергә әзер булуын яшерүне кирәк тапмады.

—Синең эшләрең күпме? Нәрсә белән мәшгуль?

—Сезне тыңлау белән мәшгуль.

Рәхәтләнеп кычкырып көлде теге: Сәет, видеотелефон алдында сөйләшкәндәй, Замирның кара тут йөзен, авызы тулы алтын тешләрен күрде. Күңеленә рәхәт жылылык йөгерде.

—Кызың мине танымый инде.

—Сирәк күрешәбез, Сәет Яруллович. Яшь гомерләр аккан сулар кебек узып бара,—дип, Замир фәлсәфәгә кереп китәргә әзер иде дә, Сәет аның хисси сөйләмен бүлдерергә булды.

—Замир, гафу ит, ашыгыч эш бар.

—Хәзер килеп житәм. Адрес. Машинам ишек төбендә генә.

—Мин, гадәтемчә, үземнән тормаган бер ямьсез тарихка килеп каптым.

Сәеткә рәхмәтле, иң якын туганнарыннан да артыграк яраткан Замир, бөтен авырлыкны икегә бүлергә риза булып, ихластан курка калды.

—Нәрсә булды, Сәет Яруллович? Төзәтеп булырлык хәлме? Тимерне кызуында сугыйк.

—Әлегә безнең арада гына калсын. Мин бөтенләй чит-ят, очраклы кешеләрдән хәбәр салам. Вообщем, болай булды. Нургали Ваһапов мине, Гаделевне табигатькә, күз белән хушлашуга алып чыкты. Явыз нияте алдан уйланылган булганмы, әллә кинәт зиһене чуалып, шариклары ычкынып киттеме, пистолетын тартып чыгарды да, шатыр-шытыр ата башлады. Минем күз алдымда мескен Мостафа суга егылды. Миңа да атты. Бер пулясы инбашның тиресен ертып узды. Шул арада мин суга, күлгә сикердем. Тешем, тырнагым белән жиргә сеңәргә тырышып, читкәрәк киттем. Сулыш бетеп, аңымны югалткач кына, су мине өскә бәреп чыгарган. Куе камышлык эченә килеп эләккәнмен. Кемдер мине эзләгән, ачудан эшләпәмә өч пуля утырткан. Аннан соң бик көчле шартлау, пожар булды. Машина белән бергә мәетләрне дә кемдер яндырды.

—Ваһапов абый эшеме икән бу?

—Юктыр. Анда тагын бер кеше, Ваһаповның жансакчысы Жирән

кушаматлы, жирән чәчле, ифрат явыз, уткәне, киләчәге билгесез бер адәм бар иде. Шуның эше булырга тиеш. Шик миңа төшәргә мөмкин.

—Сәет Яруллович, что сез, кем уйласын инде сезнең турыда шылай. Тузга язмаганны.

Аннары исенә төшереп, өстәп куйды:

—Мостафа Гаделевнең хатыны күптән тегел шалтыратканые. Ирен эзли. Мин анардан бер кибетемә вак-төяк әйберләр алганыем. Мескенкәем. Урыны оҗмахта булсын.

—Замир, бүген өлгерә алмассың инде, миңа киемнәр алып кил. Бер пар костюм, спорт киеме, эчке киемнәр, иң мөһиме, минем ботинкалар күл астында калды. Азык-төлек. Адресмы? Әнисә ханым!

—Мин монда.—Хуҗабикә ишек тупсасына янагын куеп, рәхәтләнеп тыңлап тора икән. Сәет ачудан кызарынды, бүртенде, адресны мыгырдады да, кызылга ташланган үгез төсле, һөҗүмгә күчте. Ул аны ботарлап атарга, балконнан ташларга әзер иде төсле.

—Сез... сез... рөхсәтсез, минем сөйләшкәнне тыңлап тордыгыз. Бу ничек дип атала... подлость...

Сәет нәгърәләр орды, тузынды, жикеренде, авыруы кузгалды, хәле бетеп, шып итеп, телефон янындагы кызыл кәнәфигә сенде. Ул үзенең көчсезлеген таныргa мәҗбүр булды.

Хуҗабикә, яралы кунакның ярсуына исе китмәгәндәй, бүлмә уртасында басып тора бирде. Чалбарын һәм йон кофтасын салып, өстенә тезен каплар-капламас кына иркен соры күлмәк кигән. Тагын да чибәрләнеп, яшәреп киткән.

—Зинһар, тынычланыгыз. Табиб булсам, сезгә борчылырга ярамый, дияр идем. Махсус тыңлап тормадым. Безнең фанер ишекләрне күрәсез. Сез, гел хуҗа булып яшәп, тавышны кысмыйча, курыкмыйча, кычкырып сөйләшергә өйрәнгәнсез. Теләсәләр, күршеләр рәхәтләнеп тыңларлык иде.

Сәет һаман тынычлана алмый, һавалана, кирәкмәгән хәрәкәтләр ясый.

Кинәт, башка карарга килеп, сөйләвеннән туктап, Әнисә зал ишеген каерып ачты:

—Рәхим итеп, әфәндем, чыгып китә аласыз, чакырып китергән кунагым түгелсез. Шулай да тыңлап бетерегез. Сезнең өчен дә файдалы информация бар дип уйлыйм.

Берни булмагандай, диванга килеп утырды. Аякларын җайлап куйды.

—Очраклы рәвештә күл буендагы фаҗига турында ишетеп, сезнең элеккеге алыпсатар дустыгыз—маньякның корбаны була язганыгызны белдем. Сезнең гаепсез, яхшы кеше икәнегезгә инандым диярлек. Ә инде лексиконыгызга Жирән сүзе килеп кергәч, мин бу якка чыктым һәм бер дә оялмыйча, махсус тыңлап тордым. Миңа калса, егерменче сентябрьдә булган ике вакыйга, ике фаҗига арасында бәйләныш,ниндидер кисешү булырга тиеш.

Сәет, үпкәсен, ачуын онытып, нәфрәт кисәүләрен сүндереп, хатын ягына борылды һәм хикәянең дәвамын көтә башлады.

—Сәяхәтебезнең башында, асфальттан авыл юлына төшкәнче, егетләр тып-тын бардылар, әллә милиция куып җитүдән курыктылар, башка сәбәбе булдымы? Нәрсәдер чәйнәп алдылар, аннан сәер исле, төрекләр әйтмешли, тәмәке—«төтен эчтеләр». Инде төп юлдан читкә чыгып, шактый баргач, телләре ачылды. Бинаһая олы гөнаһ кылган кешеләргә ошаттым мин аларны. Рыжий исемләме, фамилияме кеше белән очрашуга баралар икән. Ниндидер станциядә күрешергә, шуннан инде каядыр, еракка китәргә җыеналар, дип аңладым.

Таныш кушамат аталгач, Сәет сискәнеп китте. Урыныннан торып, йөренеп алганын сизми калды.

—Кем диделәр? Кем белән очрашуга барулары иде? Шул урынны ачыграк күз алдына китереп, төгәлрәк сөйләп бирегезче. Зинһарлап сорыйм, Әнисә ханым.

—Нәрсә, әллә берәр танышыгыз исеме аталдымы?

—Юк, юк. Соңрак әйтермен. Безнең язмышлар тагын бер фаҗигале ноктада кисешә бугай чыннан да. Дөнья нинди тар, ләхет кебек. Сезнең

машинада ишеткән хәлләрне төп-төгәл, түкми-чәчми күз алдыгызга бастыруыгыздан күп нәрсә үзгәрергә, минем язмыш теге яки бу якка хәл ителергә мөмкин.

Асылбаева, исенә төшерә-төшерә, ашыкмыйча гына дәвам итте.

—Мин үземә ышанам,—диде артта утырганы. Ышанычым какшый башлый икән, мин уйламыйча, үз-үземә пуля җибәрәчәкмен. Интуициям мине алдаганы юк. Без бүген исән калабыз. Башка бер транспортка утырып китәрбез. Җирәнне табасы... Ул ниндидер хәлләрдән соң зур акча алып килергә тиеш, дип уйлыйм.

—Бу ханым безне ташлап... теге дөньяга китәме?—дип сорады икенчесе.

Әнисә ханым хәтерли: озын чәчле егетнең наган көпшәсен сыйпап барганына игътибар итте ул, көзгедә күз карашлары очрашып алды. Әлбәттә, анысының да карашы сәер, аңлаешсыз, томанлы пычрак иде. Алда утырганның күзләре салкын, бака тәне кебек юеш, хәтта сасы исле кебек тоелган иде ана. Хәзер ул күршесендә утырганының джинсы чалбарын һәм коңгырт кроссовкаларын гына күрә. Шунысы да бик житкән.

Артта утырганы янәдән сорап куйды:

—Безне Займищедамы, Юдинодамы көтәләр? Бу якның вак-төяк шәһәрләрен һич хәтердә калдыра алмыйм. Барысы урынына да Мәскәү, Нью-Йорк, Токио кебек бер зур шәһәр салып куярга иде шунда.

—Барып житкәч белерсең, миңа ышан,—диде озыны, күз карашы белән Әнисәнең аксыл чыраен иркәләп алып.

Бу юлы аның күзләре елмаючан, акыллы, мәрхәмәт һәм теләк сирпеп торалар. Хамелеон күзләр шул була торгандыр инде ул...

Әнисәнең юл хәлләрен өзек-өтек, ярым-йорты булса да искә төшереп сөйләгәннәре Сәетне зәһәр борчуга салды. Уйланырлык нәрсәләр бар икән. Әгәренки, күл буенда Ваһапов, кинәт бәйдән ычкынып хуҗасына ташланган котырынган эттәй яисә тилебәрән орлыгы ашагандай кыланмаса да, аларны Җирән юкка чыгарырга ниятләгән түгелме? Ул бу шөгылен алдан планлаштырып килгән булырга охшый. Үзен яхшы белүчеләрдән тулаем котылырга җай чыккан. Аның белән бәхәсләшеп утырган ханымны (шул мизгелдә хуҗабикәгә ачуы килеп, «мажара эзләп йөргән җилбәзәк ханымны» диясе килде) әсирлеккә алган бандитлар белән очрашу урыны, якынча вакыты алдан килешенгән булган. Бергәләп җинаять кылган кешеләрдәй, алар шартлы урында очрашып еракка юл тотарга җыенганнар. Күрешү урыны күп алдан билгеләнгән. Мәгәр биредә Җирәннең чын йөзе һәм ахыр максаты гына ачылып житми. Ул ак белән караны, аларның кушылмасы нинди төсләр биргәнне аера торган зат. Асылбаеваны кулга төшергән егетләр (фу, сүзе әрәм) тәвәккәл, әмма акыл шәрифләре, эш-фигыльне мантыйклы алып барулары ягыннан уртакул адәмнәр икәннәре сизелә. Җирәнне эз калдырып йөрүче малай-шалай белән кайсы жепләр, нинди кылган яисә кылынасы җинаятьләр бәйли, шуны беләсе иде.

Сакманов Җирәннең алдап Фәридәне үзенеке итүен, хәзер дә ана жылы мөнәсәбәтен яшермәвен, телефоннан үзе белән китәргә чакыруын, туктаусыз эзәрлекләвеннән хәбәрдар түгел иде. Һәм бүген ул Әнисәнең көрән диванында сызланып һәм иркәләнеп ятканда, төнге Казан каласында аңа кагылышлы нинди вакыйгалар буласын белми иде...

Тормышы кыл өстендә торган вакытлары булгаласа да, Сәет үзенең мондый авыр хәлдә калганын хәтерләми. Атыш, үтереш булганда да «жир асты юлында яктылык сирпелеп тора» иде. Чибәр ханым фатирында озак качып ятып булмас. Адәм баласына күрү өчен ми чокыры—күз, карар кылу өчен аң, ихтыяр бирелгәндер. Кешенең табигате—галимнәр өчен иң олы сер.

Башыннан узганнарны хикәяләү барышында ханым вакыйгалар тәэсиренә бирелеп, аларны янәдән күз алдына китереп булса кирәк, кинәт елап жибәрде. Күрәсең, тыелып килгән-килгән дә, нервыларының ахыр чиккәчә киеренкелегенә түзә алмыйча, риясыз яшьләре тышка бәреп чыккандыр.

Күрше бүлмәдә дәрес әзерләп утырган Илдар йөгереп чыкты.

—Әнием, нәрсә булды? Кем рәнжетә? Бу абый барыбер шпиондыр әле. Миннән генә яшерәсез.

Әнисә улын күкрәгенә кысты. Башыннан сыйпады.

—Улым, тынычлан. Берни булмады. Киттек йокларга. Тыныч йокы, Сәет иптәш!

Илдар йокыга киткәч, Әнисә бүген булган хәлләрне башыннан уздырып, йокыга китә алмыйча интекте. ГАИ, егетләр, Сәет—барысы бергә сагыз төсле миендә укмаштылар, буталдылар. Ни өчендер урыныннан торды. Залга узды, Сәет киң диванда җәелеп ята иде. Онытылып китеп, юрганын читкә ташлаган. Тәрәзәдән төшкән ай нурында ул көмештән коелган һәйкәлне хәтерләтә. Әнисә Сәетнен ирләрчә матурлыгына сокланып карап, аз вакытка гына югалып, үзе дә сындай катып торды, бөтен тәнен биләп алган дулкыннан, җылылыктан югалып калды. Аңа бер үк вакытта рәхәт тә, оят та иде. Соңгы хис җиңде. Ул ярамаган эштә тотылган кешедәй кинәт сискәнеп, имәнеп китте: «Нишләп әле ул ялгыз, бөтенләй диярлек таныш булмаган ир янына килеп керәсе итте. Ялангач кеше күргәне юкмыни? Ә, исенә төште, ул бит яралы, андый чакта ирennәр кибә, су эчәсе килә».

Әнисә, йомшак өй аяк киемнәре белән песи кебек кенә атлап, аш-су бүлмәсенә чыкты, кайнаган салкын суны чәшкәгә агызды да, янәдән олы бүлмәгә узды. Суны өстәл кырыена куеп, Сәеткә якынлашты. Киң мангаенда эре ак тир тамчылары күреп, бүлмәдә чүпрәк эзли башлады. Өстәлдән кечкенә салфетканы алып ифрат саклык белән юеш урыннарга тидереп-тидереп алды. Ул бу шөгылен шундый нәзберек итеп, иркәләп эшләде ки, ир берни сизмәде, һаваны тигез итеп эчкә алып, эшкәртелгәнен кире чыгарып, йоклый бирде. Бераздан ир матур итеп елмаеп куйды. Ханым аны үзенә кабул итте, үзенең дә ирексездән иреннәре җәелеп китеп, энҗедәй тешләре ялтырап алды. Йөрәге тагын да ныграк тибә башлады. Әнисә идәндәге чәчәкле паласка тезләрен чәнчеп, иреннәрен Сәетнен ярасына тидерде. Һәм шунда ук, корт чаккандай сикереп торып, бүлмәдән чыгып китте

Ә Сәет бу вакытта бик матур, татлы төш күреп ята иде. Янәсе, ул әтисе салып калдырган мунча ләүкәсендә җылынып ята. Шул мәлдә ачык тәннек-тән төсле күбәләк очып керә. Чәчәк эзләгәндәй, мунчаны бер урап чыга да, Сәетнең иреннәренә килеп куна һәм елмаюы белән бергә кушылып китә.

Төнлә Сакмановның янәдән температурасы күтәрелә. Көзге, салкын сулы күлдә яту эзсез калмый. Сәет ынгырашып уяна, тавыш биреп, хуҗабикәне чакыра, аспирин сорап ала. «Игелек» сәрвәре шактый көннәр кызышып, вакыты белән аңын югалтып, салкын тию һәм яралар белән кеше өендә көрәшеп ята.

## 5

Иркен кабинетында, читлектәге җанвар кебек, ишекле-түрле йөренеп, полковник Гаяров скрипка кыллары мисле соң чиккәчә тартылган киеренке нервыларын тынычландырырга тырышты. Нишләптер йөрәге кайный, җаны кыйнала, күңеле тыныч түгел. Шул хәтлесе генә җитмәгән, бүлмәсенә керә-керешкә кизүдә утыручы алсу чырайлы лейтенант (ашказаны яхшы эшли) «сөенече» белән шатландырды. Ваһапов, Сакманов, Гаделев дигән бизнесменнар һәм беренчесенең Җирән кушаматлы сакчысы юкка чыкканнар; якыннары, дуслары хезмәттәшләре берни әйтә алмыйлар. Көпә-көндез каядыр чыгып киткәннәр һәм гаип булганнар. Әйтерсең, көтүдән сарыклар югалган. Аларның, әлбәттә, махсус очкычка төялеп, Төркия, Кипр, Египет, Хорватия кебек чикләре ачык берәр илгә кызынып, тозлы суда иркәләнеп кайтырга чыгып китүләре ихтимал. Акчалары бер букча, иртән торып, хезмәткә ашыгасылары, өстә утырганнар каршында җавап тотасылары юк. Мәгәр чит илгә сәфәр тотсалар, ниятләрен кондәшләреннән, ач күзләрдән яшергән хәлдә дә, хәләл җефетләренә, ярдәмчеләренә ым кагарлар иде. Хатыннары хастаханәләргә, милициягә шалтыратып, буза күтәрергә ашыкканнар. Бу вакыйга иң олы хуҗаларга җитми калмас, безне капчыкта яткырып булмас.

Гаяровның көйсез кәефенә бу хәбәр ифрат начар тәэсир итте. Аның бүлмәдән чыгып качасы килде.Алай гына котылырдай кәнәфи түгел шул .

«Хәзер кызыл аппарат шалтырарга тиеш» дип, бөтен барлыгы, жаны-тәне белән шуны теләмичә йөренгәндә, нәкъ шул шайтан, урынында тыпырчынып, бии башлады.

—Сәламнар, иптәш полковник. Хәлләр ничек?

—Исәнмесез, иптәш генерал.

—Миңа кереп чыгыгыз әле. Тәк... Миндә кешеләр бар. Егерме минуттан.

Әйтелгән вакытта полковник Гаяров кызыл агач белән тышланган, өч метр биеклектәге ишек янында яшь солдат кебек үрә катып басып тора иде. Бер-берсенә охшаган, шома битле егетләр ишекне үзләре ачып, өлкән офицерны эчкә кертеп җибәрделәр.

Генерал урыныннан чыкмыйча, мәгәр аякка басып кулын бирде. Гаяровтан яшьрәк булса да, чәче коелган, нык бәдәнле, зур кара күзле иде бүлмә хуҗасы.

—Гафу ит инде, Салих дус, ашыгыч чакыртып алган өчен, Үзең ЧП турында хәбәр бирмисең. Кабул итү бүлмәсенә «ак йорт»тан шалтыратканнар. Информация сорыйлар. Аларга хәбәрне синең кул астында эшләүче майор...

Алдында яткан кәгазьгә күз салды:—Әйе, майор Алексей Тимофеев җиткергән. Сездә тәртип бөтенләй какшаган, чәкесе төшеп калган тәгәрмәчле арба хәленә килгән. Субординация дигән нәрсә бар бит әле дөньяда. Инде миңа шалтыраттылар. «Казан мафиясенең абруйлары юкка чыккан», ди җаваплы абзый. «Мин әйтәм, бик шәп булган, алардан котылырга вакыттыр инде, дим». «Хикмәт башкада, ди. «Аларны милиция үзе җыеп алып, судсызнисез алып чыгып аткан, шуның алдыннан акчаларын талап алганнар», дигән хәбәрне шәһәр буйлап тараталар», ди.

Генерал мондый олы коткыны, гайбәтне берәүдән дә ишетмәде, полковникны өркетеп алу өчен үзе уйлап чыгарды. Болай да хәйләкәр күзләрендә яшеннәр ялт-йолт уйнады, төлке койрыклары күренеп алды. Беркатлы Гаяровка куркыныч булып китте. Бүлмә хуҗасы полковникның югалып, каушап, кечерәеп калуыннан канәгать булып, өстенлеген яшерергә дә теләмичә, һөҗүмне дәвам итте. Җитди тонда башланган сөйләшү бик кырыс булырга ошый. Гомуми җөмләләр белән генә котылып булмастыр.

—Мин сезне, иптәш полковник (бу юлы инде, Салих дус, түгел), ни өчен чакыртып алганны чамалыйсызмы хет?

—Дөресен әйткәндә, сезгә мengәндә белми идем,—диде Гаяров, тәненең һич уйламаган җирләреннән тир бәреп чыгуны, борын очыннан тамчылар тамуны тоеп.—Шактый билгеле кешеләр юкка чыкканнар дисез бит, шунын өчендер диеп уйлыйм. Миңа әле генә әйттеләр. Шул эш белән шөгыльләнмәкче идем.

—Вакытсыз борчыйсыз, әфәндем, дисеңме?

—Мин алай уйламыйм,—диде Салих, кин учы белән борынындагы, битендәге тирләрен сиздермичә генә сөртеп алып.—Кайбер мәгълүматларны тикшерергә вакыт кирәк иде.

—Сез аны бирмәдегез, димәкче буласыңмы?—диде генерал, авыз читенә оялаган мәсхәрәле елмаюны яшереп тормыйча.

Гаяровның эндәшми калуы әлегә иң акыллы «йөреше» булды.

—Республикада барган хәлләр, икътисади баланс өчен көрәш, идән асты байларының котырынуын ничек бәялисез?—дип, генерал атакага күчте.

—Әлбәттә, һәр намуслы һәм порядочный кешене илдә, шәһәребездә барган хәлләр ваемсыз калдыра алмый. Әмма мин, белүегезчә, кечкенә кеше һәм күп нәрсә өчен җавап бирә алмыйм.

—Бик хаклы әйттегез. Һәр кеше үз урынында, үз дәрәҗәсендә дөреслек өчен көрәшергә тиеш,—диде генерал, беркадәр пафоска бирелеп.—Ләкин «һәркемнең үз дөреслеге бар» дигән борынгыдан килгән гыйбарә дә яши, бездән сорамыйча.

Кабинет хуҗасының сүз сөрешен, кайсы якка каеруын, нәрсә әйтергә теләвен аңлап җиткерүе кыен иде. Шуңа күрә полковник Гаяров башын җүләргә салырга булды. Бу гадәти солдафоннан ни көтәсең дип фараз кылсың да, чыгарып җибәрсен, бик эссе бирелә. Әллә яга башлаганнар инде.

—Безнең тәртип саклаучыларның үз фикере була алмый, булырга тиеш тә түгел. Без—хөкүмәт сакчылары, хезмәткәрләр, кушканны үтәүчеләр.

—Халык сакчылары,—дип төзәтте генерал, йөзенә арыган, талчыган кыяфәт чыгарып. Мәче тычкан белән уйнаудан тиз туя, ди. Хужа кеше төп мәсьәләгә күчте.

—Бая мин атаган адәмнәр исән-сау микән, кая олактылар икән? Аларны милиция юкка чыгарды дигән хәбәрне ничек бәялисез? Утсыз төтен чыкмый. Сүз дә юк, һәркайсының халык каршында гөнаһлары зур. Алып чыгып, судсыз-нисез атарлык гаепләре бар, менә болай,—дип, кулын муенына тидереп алды.—Ну, без бит демократик дәүләт төзү юлына чыктык һәм мондый фашистик ялсә коммунистик башбаштаклыкка юл куя алмыйбыз. Дөресме?

Гаяровның килешми хәле юк иде. Элеккеге фирка җитәкчеләренең берсе—хәзерге генерал ифрат хаклы, акыллы сүзләр чәчә иде.

—Фикерегез ифрат тирән, төпле. Ваһапов, Сакмановларның югалуында милициянең бер катнашы, бер гаебе юк дип уйлыйм. Дөрес, әле район милиция бүлекләре, аларның начальниклары бар, еш кына алар үз белдекләре белән эш итәләр, мөгез чыгаралар,—дип, мәсьәләне читкәрәк алып китмәкче иде, «идеология килә, китә, кадрлар кала» дигән ышанычта яшәгән генерал кул ишарәсе белән аны туктатты:

—Без бирелдә милиция структурасын тикшерүгә кереп китмик әле. Аерым алганда, Сакманов, белүемчә, элеккеге милиция хезмәткәре, аны кая дип уйлыйсыз? Исәнме икән? Берәр чираттагы сөяркәсеннән аркасын кашытып ятмыймы? Гәүдәсен ташлаган җаны үзенә урын таба алмыйча, синең тирәдә очып йөрмиме?

Бу юлы Гаяров шабыр тиргә батты: нәрсә әйтергә тели бу сәнәктән көрәк булган, генерал погоннары таккан адәм? Фикерен кистереп әйтми, җепнең очын яшерә. Шулай да бу юлы, мөмкин булган чаралар ярдәмендә, үзен сыртка салдырмаска булды полковник.

—Ни өчен әле сүз Сакманов һәм аның җаны турында гына бара, иптәш генерал? Алар, ишетүемчә, дүртәүме, бишәүме, ягъни бер компания булганнар, әле берсенең дә табылганы юк. Кстати, шул ук көнне Чаллы-Казан юлында күренекле гаишнигыбыз Карам Сәгъдиевне атып үтергәннәр...—Полковник нидер өстәмәкче иде, бүлмә хуҗасы учы белән чебен үтергәндәй өстәлгә сугып, урынбасарын бүлдерде.

—Беләм, беләм. Аны зурлап күмделәр. Урыны оҗмахта булсын. Гаиләсенә ярдәм иттек.

Үлгән кеше берәүгә дә кирәк түгел икән шул. Исемен сүз арасында искә алып, тизрәк оныту ягын карыйлар, бигрәк тә кәнәфи биләүчеләр.

—Ничек уйлыйсыз, менә бу вакыйгалар, югалтулар, үтерешләр арасында нииндидер эчке бәйләнеш, якынлык юкмы икән?—диде генерал, йөз-кыяфәтенә мәртәбәлелек индерергә тырышып.

—Юктыр, дип уйлыйм. Сезнең фикерегездә уйландыра торган нигез-орлык бар.—дип, полковник алып баручының салпы ягына салам кыстырса да, хәйләкәр хуҗа бу арзанлы җимне капмады.

—Монысы юл уңаенда гына. Сакмановны искә төшерүем юкка түгел. Сез аның белән якын дуслар дигән хәбәр килде «саесккан канатында».

—Танышлар. Ул халык белән каберең якын булмасын. Шулай да мин аны чыгырдан чыгып китмәсен дип, контрольдә тотарга тырыштым.

—Соңгы тапкыр кайчан очраштыгыз, кайда күрештегез?

«Бу безнең элемтәләрнең тирәнлегеннән хәбәрдар, бугай. Ниндидер тотынып баскычлары бар, әмма материалы җитеп бетми, әллә үземнән танытасы киләме?..

Чынында мәсьәлә болайрак тора иде. Гаяровның эш телефоны тыңлана. Югалган көнне Сакмановның полковникка шалтыратып, кемнәр белән, кайларга таба барулары турындагы хәбәр тасмага язып алына. Очраклы рәвештә диярлек. Генералның «сезнең телефон тыңлана, миңа язманы китерделәр» дип, «дегетчеләр» дәрәҗәсенә төшәсе килми. Үзе танымасмы дип, кыса. Ут, су аша гына түгел, «бакыр торбалардан чыгып» исән калган полковник башын җүләргә салып утыра.

—Бик хәтерләп бетермим. Эш шундый күп.

—Бу арада телефоннан гәпләшкәнегез булмадымы?—дип, бүлмә хуҗасы яртылаш ачылырга мәҗбүр булды.

Әлбәттә, Гаяров Сакманов белән ул үләсе, югаласы көнне булган сөйләшүне хәтерли. Димәк, язып алганнар. Хәбәр иткәннәр.

—Әйе, булды шул андый хәл. Нәкъ менә шул көнне ул миңа шалтыраткан иде...

—Хуш. Нәрсә турында гәпләштегез, сер булмаса.

Гаяровның күптәннән мондый четерекле хәлдә калганы юк иде. Хәзер ул нинди дә карар кабул итәргә тиеш, ә аның һич кенә ачыласы, үзен сатасы, сатыласы килми. Икенче яктан, пычагымамы аны яшереп торырга? Кыска гына фикер алышуда бернинди дәүләт сере ачылмады, сәясәткә керелмәде, дәрәҗәле түрәләргә бәя бирелмәде. Миенә ярдәм иткәндәй, полковник олы йодрыгы белән маңгаен уып алды.

—Сөйләшү булды. Каядыр ялга чыгабыз, диде кебек. Бик хәтерләмим. Сездән яшерен-батырын түгел, кичә хатынның туган көне иде. Бераз арылган,—дип, аклану нияте белән елмайгандай итте.—Сөйләшүнең эчтәлеген искә төшерергә тырышырмын. Хәбәр итәрмен.

—Ярый, котәм,—диде бүлмә хуҗасы. Торып, кулын бирен хушлашуны кирәк тапмады.—Бер-ике көн эчендә Сакмановны һәм аның әшнәләрен табыгыз!—дип өстәде.

Полковник Гаяров үзен зирәк сәятче санаса да, генералның ни өчен шулай сәүдә икътисады әһеле Сакмановка битараф булмавын аңлый алмады. Үтереш, атыш, кешеләрнең көпә-көндез югалуы—безнең заманда гадәти хәл ич.

Генерал исә Гаяров алдында тулысынча ачылуны кирәк тапмады. Яшь киленнәр кебек тел яшерүнең сере моннан гыйбарәт иде. Генерал алдында бурыч куйдылар: Сәет Сакманов дигән бизнесмен депутатлыкка дәгъвасын алсын, баш катырып йөрмәсен. Ризалыгын, гаризасын кире сорасын. Ул округтан башка кеше, шул район хуҗасы узарга тиеш. Сакманов бай, сүзгә дә, акчага да саран түгел, ирекле күрәштә, юл куйганда, аның узып куюуы да бар. Рәсми эзәрлекли башласын, кире нәтиҗә килеп туачак. Рәсәй сайлаучысы—хөкүмәткә арты белән торган, аның белән бәхәскә, вәсвәсәгә кергән, бигрәк тә житәкче даирәләр, оешмалар тарафыннан рәнжетелгән, кысылган, тыелган кешеләрне яклап тавыш бирә. Рәсми юл белән жиңү кыен булачак. Димәк, сөйләшү, аңлашу, сатып алу, ришвәт кебек тайгак юллар кала.

—Участковый милиционер атом буксиры кебек бара. Аны туктатырга кирәк. Теләсә нәрсә вәгъдә ит, тик гаризасын алсын, депутатлыкка дәгъвасыннан баш тартсын,—диделәр аңа.

Менә шул йөкләмәне үтәү барышында полковникны чакырган иде генерал. Гаяровның Казан мафиясе, аеруча Сакманов белән вась-вась яшәве турында кайбер мәгълүматлар бар. Әмма тотылмаган—карак түгел. Исбатлап кара!

...Бүлмәсенә төшеп, урындыгына утыругa, Гаяров мафия, аерым алганда, Сакманов белән араны кискен рәвештә өзмәгәнe, йомшаклыгы өчен үзен битәрләп алды. Икенче яктан, әлеге халык белән дус яшәмәсә, шәһәрдә, илдә барган вакыйгаларның күбесеннән хәбәрдар булмас, малае да чит ил «тарантасында» түгел, «Ока»да селкенер иде. Менә икенче кызы да, пешеп житкән хөрмә кебек, өзелеп төшәргә генә тора. Кияүгә чыгарга уйласа, йөзгә кызыллык китермәслек туй ясарга, әгәренки, ашыкмаса, аерым фатир юнәтергә кирәк. Кемгә барып егыласың? Әле генә «Сакмановны табарга» дигән хуҗадан айлык хезмәт хакыннан башка сукыр тиен, кәррә ярдәм ала алмыйсың, тагын шул ук Сәет кырына төлкедәй юмалап барырга туры киләчәк.

Кичә хатыны Венера, күзлеген сөртә-сөртә, нәрсә ди:

—Синең бердәнбер ышанычлы кешең, дустың диимме, Сәет Яруллович бар. Аны ташлама...

—Ул пычагыма китсенме, абзанның кесәсендә ул,—дип әтәчләнгән

булды полковник. Әмма хатынының хаклы икәнен эчтән танырга мәҗбүр булды.

Беркемне кабул итми, беркадәр уйланып, утырганнан соң, полковник туры элемтә буенча майор Алексей Тимофеевны чакыртты.

Кылган чәчле, ап-ак чырайлы, төссез күзле майор килеп керүгә, Гаяров аны юри мактарга кереште.

—Синнән илебезгә турылыклы, намуслы, эш сөючән милиция хезмәткәре чыгасына мин бер кайчан да шикләнмәдем. Бүген янә бер кат инандым. Безнең шефка шалтыратып, Ваһаповларның югалуы турында хәбәр биреп дөрес эшләгәнсең!

Майорның, бу бүлмәдә макталуның бәһасен белгәнгә, бик исе китмәде, ә информация мәсьәләсенә ачыклык кертергә булды:

—Миңа иртән генерал үзе шалтыратты, Гаяров килеп житмәгән, миңа шундый хәбәр килде, дөресме? Тикшер, миңа әйт, диде. Сездән, турыдан-туры житәкчемнән узып, нишләп мин авыртмаган башыма бәла эзләп йөрим, ди. Таләп иткәч кенә, хәбәр бирдем.

Полковник, берни аңламыйча, авызын яртылаш ачкан килеш катып калды. Борынгы акыл иясе нәрсә дигән әле: әй, бу замана, әй, бу әхлак.

Тимофеев алдашмый булса кирәк. «Умырзая»дагы вакыйгаларны тикшергәндә артык «тырышканы» өчен аңа шактый «муклашка» эләккән иде. Премиясез калды. Хәзер уйлабрак эш итә, шинель чабуларын җыебрак йөри кебек. Чөнки үз чабуына үзең үк басып, тора алмаслык булып мәтәлеп китүең бар.

—Безнең задание уртак . Сакмановны жир астыннан, су төбеннән булса да эзләп табарга. Көтмәгәндә, уйламаганда кирәкле кишер яфрагы булып китмәсенме «иптәш мафиозник»,—дип, полковник майорга кулын сузды.

Тимофеев һәрвакыт уйлап, сак һәм үзенә файдага эшләргә тырыша. Нервылары таза, какшамаган, үсәсе, шәһәр районына бүлек хуҗасы булып барасы килә. Каядыр күренергә, күзгә чалынырга теләп, вакыты белән артык мөстәкыйль адымнар ясап куйгаласа да, бу очракта Тимофеевның генералга үзе шалтыратып информация бирүенә Гаяров ышанмый. Элемтә, киресенчә, үзәктән килгән булырга тиеш. Ләкин тикшереп дөреслекне табып булмаячак... Икесенә дә ышанмаска гына кала. Бердәнбер дөрес юл шулдыр.

*Дәвамы киләсе санда*



## Шәүкәт Гаделша

### И, СЕБЕР ТАТАРЫМ, НИ ДИИМ?

### Якташым

**Маңгаенда жыерчык—**
**Табан балык чумырлык.**
**Йөзендәге кырыслык—**
**Елан коты очырлык.**
**Күзендәге кысыклык—**
**Ташның суын сыгырлык.**

**Шул якташтан җаныма**
**Җылы бер нур үрелә:**
**Туган якның иң үзәк**
**Тамыры булып күренә.**

### Төмәнне көрткә төрә

**Бураннар йөгереп керә,**
**Төмәнне көрткә төрә.**

**Яр буйлап утрау-утрау**
**Укмашкан... йокымсырау.**

**Турага төшеп карыйм,**
**Бозларын тишеп карыйм.**

---

Шәүкәт ГАДЕЛША *(1949)—шагыйрь; «Ядрә тигән», «Ярык мөгез», «Сөмән кадыйм» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Тирәли этләр өрә,
Дулкыннар йоклый бирә.

Дулкынны коткарырга—
Көч җитми, боз ярырга…

Уйларым үчле, тешле,
Елгыр чуртаннар төсле.

Гарьләнеп, ярга карыйм:
Килүче-мазар бармы?

Бармы, күгәрмәгәнме
Чормада сөмәннәре?

… Бураннар йөгереп керә,
Түмәнне көрткә төрә.

Йоклый себер татары,
Карга чумып, уралып.
… Боз астында, тирәндә
Тончыга… алтын балык!

## Йолдызлы төндә

Карасам йолдызлы күгемә,
Чемердәп, хәл китә тәнемнән:
Әйтерсең, бай ханлык казнасы—
Тәңкәләр, чулпылар чәчелгән.

Шыгырдап куйгалый туңган кар,
Агачтан чыбыклар коела…
Янымa килә алмый, адашып,
Күчемхан йөри күк тоела.

Үз итеп, сөенеп, ник чыкмый
Алдыма, учагым янына?
Батырның саф канын тартырлык
Җегәрлек юктыр шул канымда.

Тынлыкны тыңлыймын: шуңа бит
Чыдамый, шартлады төз чыршы.
И Ай, мә, кадал дип, хәнҗәрдәй
Очланып, сузылмый син торчы!

## Кайсы чорның кошы син?

Куркыбрак, кысылыбрак
Кырда басып торамын:
Аяклары салынган—
Очып килгән торнаның;

Тели сыман моңлы кош
Күз-йөземне тырнарга.
Нинди кара гөнаһым
Җир өстеннән тырпая?

Юк, ашыкмыйм, җыенмыйм
—Мин—гөнаһсыз,—дияргә.
Күл кичкәндә, тамчылар
Таммыймы иреннәргә?!

Теге чорда, изге, дип
Кылганнарым, «ах!»ларым
Булып куйды бу көндә—
Иң кара гөнаһларым…

Юк, карышмыйм, торнакай,
Чукый алсаң, чукырсың.
Шуны гына әйт миңа:
Кошы кайсы чорның—син?

❦

Кычкырып, сызгырып карыйм—
Атны кузгатып булмый.
Ник, дисәм, шулай карыша?—
Ачык авызын... тыңлый!

Дерелди, гүя гәүдәсен
Черки, кигәвен сырган.
Күзләре акаеп тора,
Шартлап чыгарлар сыман.

Мин дә ишетә башладым:
Ах, тыңламыйча булмый!—
Нинди җил, кайсы гасырдан?
Авызга кереп елый?!

Саргылт тешләргә бәрелеп,
Нинди моң йомарлана?!—
Ат белән маңгай терәшеп
Әллә, дим, бер еларга?

Йөрәгем аша үтә күк
Бар дөнья сагаюы.
Суыра мине ат авызы—
Коточкыч тирән кое.

Кешни генә күрмәсен ул—
Куркам хаос туудан.
... Бармак очларыма басып,
Качам—ат баскан кырдан.

## Каен

Кибә инеш, тиздән төбе
Үлән белән капланасы...
Ярындагы ап-ак каен—
Сусыз калган су анасы.

Талпына да, очына да,—
Китә алмый—көтә һаман:
Урлаткан тарагын кире
Аңа китерерләр сыман.

Алтын тарак табылмавын
Җаным һәрчак хуплап торыр.
Китсә каен—су анасы,
Инеш кенәме соң корыр?

❦

Туры килде күпме саз,
Күпме урман үтергә.
Насыйп булмады бүген
Берәр поши күрергә.

Күк йөзе шундый охшаш
Тоз сибелгән тирегә:
Әйтерсең лә, тарттырып,
Элгәннәр киптерергә!

❦

Шаулыйлар карт таллар, шатланып,
Күчемнең кайтыры турында.
Шаулыйлар дулкыннар, «егълашып»—
Ермакның... батуы турында...

Тик урман болганмый—куенында
Кысылган зур дәһшәт йомгагы.
Туйдырды шул дәһшәт каршында
Үкенү, юану, моңаю.

Калды тик, чыгарып аланга,
Акыртып кыйнарга язмышны.
Калды тик рухыма юлдашка
«Уф»лаган ябалак тавышы.

И себер татарым: ни диим?..
Дөньяга, җиргә син ник килдең?—
Бары тик Ермакны, Күчемне...
Тарихта калдырыр өченме?!

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Әсгать Салах

## КАЕННАР ЮЛЫ

ПОВЕСТЬ

*Гашыйклар юлы каен,*
*Каеннар юлы кайгы...*

Әнгам Атнабаев.

### Беренче кисәк

### I

Каенлы Чишмәгә яңа урман каравылчысы куйдылар. Бу зур авылның беркайчан да үз урман каравылчысы булмады. Сугыш чорында, әле сугыштан соңгы елларда да әлеге эштә Әнтәй авылы чуашы Пайморза торды. Яше олы иде—сугышка алмадылар. Ир-атсыз, терәксез калган татар авылында карт чуаш азынды, авыл өстенә ишелеп торган урман була торып та халыкны утынга тилмертте, гел үз урманы сыман кыланды. Сәрхүш урман каравылчысына бер «чөлли»сез якын килмәле дә түгел иде. Утын сорап барган кешегә аның беренче сүзе: «Пер чиртук»,—булды. Сугыш хәсрәте белән генә түгел, ачлык-ялангачлык, авыр колхоз эше белән дә тәмам йончыган, чыгырдан чыккан, очын-очка ялгый алмый интеккән, сугышта ирен югалткан хатынга каян килсен инде ул «чиртук»? Һәлак булган ире өчен ишле балаларга тиешле юк-бар пенсия дә кулга тими, йә заем, йә салым дип тотып калалар.

---

Әсгать САЛАХ *(1935)—язучы, публицист; «Аккан сулар», «Балыкчы малайлар» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Бер салкын кышта үз урманында буранда адашып калды исерек Паймирза, үле гәүдәсен дә яз көне генә таптылар. Ләкин үзен кызганучы булмады, халыкның канын бик нык кайнаткан иде шул. Эзләгәнен тапты, дип, каенлылар җинел сулап куйды.

Яна урман каравылчысы да читтән, Таллы Елга авылыннан, сугыштан исән-имин әйләнеп кайту бәхетенә ирешкән, уңып беткән гимнастеркасын да салырга өлгермәгән яшь керәшен егете иде. Исеме—Микулай. Кайдадыр урманчылыкка да укып кайткан.

Микулай үзеннән бик яшь Сандрасы белән башта авыл очындагы ялгыз Минлезифа карчыкта фатирда өйдәш булып яшәделәр.

—Өемдә чукынмас булсагыз гына кертәм,—дигән теге дөньясы турында кайгырта башлаган әби-карчык.

—Җук, жук, Минзипа әби, без жәшләр бит әле, савитча жәшибез,—дигән Микулай һәм әби кертергә риза булган. Кертми ни... Пичкә ягарга әрәмәдән чыбык-чабык ташый-ташый арып-талып беткән карчык, Микулайдан: «Утынга аптырамабыз» дигән сүзне ишетү белән үк риза иде инде аларны фатирга кертергә. Урманчы, урман каравылчысы ла! Каены бар кайгырмас, тимере бар тилмермәс. Ул да утынга аптыратмас бит инде?..

Микулай белән Сандра өйләнешкәннәр генә, балалары юк иде әле. Яна гына уналтысын тутырган керәшен хатынын күреп, Каенлының яшь ир-егетләре «аһ» итте. Гүзәлләрнең дә гүзәле иде Сандра! Ул коеп куйган кебек буе-сыны, ул алсу-ак кәләч йөзе, ул болыт кебек күпереп торган аксыл-куе чәчләре, шаян очкын сирпеп торган зәңгәр күзләре, кыйгачнечкә кара кашлары, энже кебек тезелеп киткән ап-ак тешләре, зәңгәр бизәкле ситсы күлмәгенең изүенә сыеша алмый яртылаш ташып чыккан йомры-йомры күкрәкләре... Аһ, аның шул матур күкрәкләрен дал-дал селкетеп, авыл ир-атларын чиксез дәртләндереп-ымсындырып, җинел адымнар белән уйнаклап авыл урамыннан үтүләре! Мондый да табигать биргән сылулыкка ия яшь кызны ничек үзенә карата алгандыр кипкән балык кебек ябык, какча гәүдәле, очлы борынлы, тәмәке тарта-тарта саргаеп беткән төксе йөзле, эре тешле урман каравылчысы—анысы халыкка сер булып калды.

Ләкин Микулай да төшеп калганнардан түгел икән—бер ел да узмады, Минлезифа карчык янәшәсендә генә, кыр капка төбендә урын алып, шалкан кебек таза, ап-ак усак бүрәнәләреннән өр-яңа өй салып куйды. Үзенең дә кулыннан килмәгән нәрсә юк икән: бурасын да бурады, кыегын да кыйды, тәрәзәләрен-ишеген дә уйды, аларга янаклар һәм кысаларны да үзе кысты, түшәм белән идәнне дә үзе җәйде. Аның уңган-булган, тырыш урманчы гына түгел, кул эшенә дә бик сәләтле, һәвәс кеше икәнен Каенлы халкы әнә шунда белде.

Минлезифа карчыкның сөйләвенә караганда, ирле-хатынлы керәшеннәр әйбәт кенә, тавыш-тынсыз, анлашып яшиләр иде. Тик бер генә борчулары бар иде аларның—Сандра балага узмый торды. Бер ел, ике ел үтте. Бергә яшәүләренә өч ел тулып килгәндә генә Сандраның көмәне барлыгы беленде. Яна туган малайга керәшеннәр үзләренчә Данка дип исем куштылар, ләкин Каенлы балалары арасында ул Данил булып үсте. Татар авылында Сандра үзе дә күптән Сандра түгел, Сания иде.

## II

Гадәттә авыл—гайбәтче ул, анда сер саклау мөмкин түгел. Барысы да бер-берсенең тормышын бөтен нечкәлекләренә, энәсеннән-җебенә кадәр белеп, күреп тора. Каенлы Чишмәдә исә яна килеп яши башлаган керәшен гаиләсе генә бик озак сер булып кала бирде. Минлезифа әби дә сер саклый торган карчыклардан иде—үзе үлгәнчегә кадәр беркемгә бернәрсә җиткермәде. Үләр алдыннан гына...

Ярый әле Микулай белән Сандра янәшәсендә Минлезифа карчык яшәгән. Ул булмаса, кем саклаган булыр иде ул серне дә, кем ачкан булыр иде аны соңлап булса да?..

## III

Сандра-Санияне күргәннән соң аның матурлыгына сокланып, дөньяларын онытып, аңа гашыйк булып йөргән ир-егетләр арасында Каенлының тимер остасы Сафуан да бар иде. Көмешсу елгасына барып кушылган мул сулы Тирәкле инеше буенда, авыл артындагы аулак, тәбәнәк алачыкта ут көйрәтеп, кыскыч белән бер кулына кып-кызыл булып кызган тимер тоткан, икенче кулында бозау башы чаклы чүкеч уйнаткан, Алып батыр кебек таза, инде вакыты күптән җиткән булса да һаман өйләнмәгән, сазап барган егет иде Сафуан. Төскә-биткә дә Ходай аны өлешеннән мәхрүм итмәгән, телгә-сүзгә дә кеше кесәсенә керүчеләрдән түгел, түше дә, һушы да бар. Осталыгы белән исә үз авылында гына түгел, тирә-якларда дан тоткан, Лесков сулагае кебек борчаны дагалардай тимерче иде ул. Тимер эшеннән тыш, оста калайчы да, агач эшенә дә, мич чыгарырга да—һәрнәрсәгә кулы ятып тора. Әмма дә бер кимчелеге бар иде Сафуанның—сул аягына сизелер-сизелмәс кенә чатанлый иде ул. Балачакта бишектән егылып төшкән дә, аягын имгәткән икән. Шуңа күрә, яше җитсә дә, иптәшләрен сугышка алып киткән вакытта аны алмадылар. Бәхетенә күрә егылып төшкән булган диярсең, бәхетеннән аягын да каймыктырган, чөнки сугышка киткән зур бер төркем иптәшләре арасыннан авылга әйләнеп кайтучылар өч-дүрт кенә кеше иде. Аның каравы, шул афәт елларында Сафуан чын тимерче булып өлгерде. Алай гына да түгел, ярлы колхозның, авыл халкының олы терәге иде ул. Кемгә нинди тимер-томыр кирәк, һәммәсе дә Сафуанга килә. Бу карусыз, киң күңелле, елмаюлы йөзле егет эшләп бирмәгән корал булдымы икән кайсы да булса бер йортта? Юктыр.

Сафуан гүзәл Сандра белән якыннан аларның бураларын күтәргән көнне, өмәдә танышты. Миңлезифа карчыкның тәбәнәк киртә белән әйләндереп алынган хәтфәдәй чирәмле ишегалдына туксан чыгып, туксан керде Сандра, чөнки өмәдәгеләр өчен аш әзерли иде. Аннары шул чирәмгә арба чыбылдыгы җәеп, шуңа тиз-тиз генә аш-су, чәй-мәй, тәм-том ташыды, дистәгә якын ир-атны кыстап-кыстап ашатты, эчертте. Сафуан аның һәр хәрәкәтен күзәтеп, аңа кызыгып карап-карап алды, гәрчә мондый карашын башкаларга сиздерергә теләмәсә дә. Ләкин Сандра сизде, фәкать гүзәл затларга гына хас сизгерлек белән сизде ул тимерченең өмет белән өретелгән карашын.

Төшке аштан соң савыт-саба җыеп, аны юып куйды да, беравык тәрәзә аша гына ирләрнең эшләүләрен карап торды. Әллә ничек кенә шунда аның күзе озын буйлы, таза гәүдәле Сафуанга төште, ябышты. Юан-юан бүрәнәләрнең бер башыннан ике-өч кеше күтәрсә, икенче башыннан Сафуан берүзе генә күтәрә һәм ул аны уйнап кына, җиңел генә күтәрә сыман. Хатын тимерчегә сокланмый кала алмады.

Сафуан исә соң гына өенә кайтып, урынына аугач та Сандраны искә алып ятты. Менә пөхтә иттереп киенгән яшь хатын җәлт-җәлт атлап аш-су ташый... Менә ул башкаларга сиздермичә генә Сафуанга аяз күк кебек зәңгәр күзләрен сирпи. Шул чагында аның алсу-ак йөзендә елмаю чагыла...

Иртән алачыгына барганда да ул кабат Сандра турында уйлады, аны тагын күрәсе килеп китте. Ләкин аңа озак вакыт Сандраны күрү насыйп булмады. Инде ул хатын турында уйлаулар бераз онытылып торган бер көнне, әллә яңа өйгә төрле тимер җиһазлар кирәк булганга, әллә соң башка бер мөһимрәк сәбәп беләнме, Сафуан алачыгына җил уйнатып Сандра үзе килеп керде:

—Арулармысез, Сапуан абый...

Авыл мунчасы кебек бәләкәй, кабер кебек тар, сөремнән каралып, тимер тузанына батып беткән алачыкка саф һава, дөнья ямен, көләч йөз, якты елмаю, әлегә кадәр Каенлының яшь кызларында да булмаган гүзәллекне алып керде Сандра. Сафуан бу хәлдән башта өнсез калды—яшь хатынның сәламен алырга онытып, шактый вакыт авызын ачып, соклануга туялмыйча, аның аяз көндәге күк йөзе сыман зәңгәр күзләреннән, алсуланып пешкән алма кебек түгәрәк йөзеннән, чия кебек карасу-кызгылт иреннәреннән,

изүенә сыя алмыйча тулып ташкан күкрәкләреннән күзен алалмый карап торды. «Чибәр, ай-һай чибәр, каһәр, бер кашык су белән йотып җибәрерсен...» Һәм анын күнел түрендә кабат татлы, ләкин гөнаһлы теләк кымыржый башлады: «Әллә бар нәрсәгә кул селтәп, бер яратып, сөеп, татып калыргамы соң бу гүзәлне?»

Ниһаять, Сафуан телгә килде:

—Әйдә, Сания матурым, түрдән уз! Утыр дияр идем, урын тузанлы. Әллә соң тезләремә генә утыртып торыйммы үзенне?—диде ул, шаяргандай итеп.

—Алай озак торырга бөгөн бакыт жук шул, Сапуан абый.

—Ни йомыш сон, матурым?

—Мина, Сапуан абый, жәмки кирәк иде, шуны жасап бирә алмассын микән?

Сандранын үзен күрмичә дә, тавышыннан гына да сихерләнерсен! Йомшак һәм искиткеч ягымлы иде анын тавышы. Ниндидер моң булып чыкты бу тавыш анын күкрәгеннән. Бирсә дә бирер икән Ходай кешегә һәрьяклап!

—Жәмки дисенме? Ярар, ясармын мин аны, Сания матурым, ясармын...

—Качан жасарсын икән?

—Иртәгә көндез бер арада әйлән, ясап куярмын. Көтеп торам дисән, хәзер үк ясап бирәм...

—Жук шул, әйтәм бит бакыт жук диеп. Иртәгенәк килермен алайса.

—Кил, кил, «эһ» дигәнче ясап бирермен мин аны сина, Сания.

—Жарар, алайса, Сапуан абый, килермен. Ару бул!

Сандра, тәмледән-тәмле ис калдырып, чыгып китте. Ай күрде, кояш алды. Сафуан исә әкияти бер халәттә калды. Йа Хода! Үзе, Сандра үзе килеп керде ич анын янына! Нинди бәхет! Бирим дисә колына... Ничек мөлаем сөйләшә! Нәрсә диде әле? Сафуан: «Әллә тезләремә генә утыртып торыйммы?» дигәч, Сандра: «Алай озак торырга бөгөн бакыт жук»,—диде түгелме сон? Димәк, башка көнне анын озаклап торырга, хәтта тезгә килеп утырырга да уе юк түгел булып чыга...

Сафуан пәри куышы кебек алачыгында гүзәл Сандра белән көн буе, кич буе женләнде. Уйламаган уе, хыялланмаган хыялы калмады.

Икенче көнне иртән-иртүк ясап куйды Сафуан жәмкине. Ясап куйды да, тынычсызланып Сандранын килеп керүен көтә башлады. Тизрәк килсен иде, тик кеше юк чакка гына туры килсен иде. Ату монда юк-бар йомыш белән йөрүче эшем кешеләре бетмәгән.

## IV

Сафуаннын теләгәне-юраганы юш килде—Сандра чыннан да аулак вакытта килеп керде. Кичә анын өстендә гадиерәк кием иде кебек, ә бүген гөлт итеп торган матур бәйрәм күлмәге. Керәшен хатын-кызлары гына оста итеп тегә белгән, борынгы болгар бабаларыбыздан калган милли үрнәкләр белән бизәлгән, салават күперендәге барлык төсләргә буялган өлгеләрдән жыелып тегелгән, Сандранын коеп куйган гәүдәсенә сыланып торган гажәеп килешле күлмәк. Аягында ап-ак йон оеклар һәм ялтыравыклы, очлы тирән башмак, башында өчпочмаклап бәйләнгән күзләре кебек үк зәнгәрсу яулык, күкрәгендә көмеш тәнкәләре ялтырап, чынлап торган түшлек, муенында төрледән-төрле бизәкле муенса, колаклары чын көмештән укалар белән коелган чигәчә белән капланган. Алачыкка жәмки алырга гына түгел, ә Торычын бәйрәменә утырмага килгән хатыннарга охшаган Сандра. Аны шушы тан калырлык матур кием-салымда күреп, Сафуаннын исе-акылы китте. Мондый да күркәмлекне, мондый да зәвыклылыкны анын әлегәчә күргәне юк иде. Ләкин шушы киемдә Сандранын энже кебек тигез ак тешләрен күрсәтеп елмаеп торуы бөтенесеннән дә матуррак, сөйкемлерәк һәм сихерлерәк иде. Шул елмаюлы килеш ул:

—Арулармысез, Сапуан абый. Мин килдем,—диде.

—Сәламәт кенә әле, Саниякәй гүзәл. Ә мин көттем, түземсезләнеп

көтеп тордым синең килгәненне, ипидер менә,—диде тимерче каушый-каушый, ләкин эчендәгене яшерми, чын күңеленнән әйтте.

—Шолай бик сагынып көттеңмени, Сапуан абый?—Сандра наян итеп елмаеп куйды.

—Ә нигә? Сагынып көттем. Әллә нишләттең бит әле син, Сания, Сафуан абыеңны: юксындырасың, сагындырасың...

—И-и, Сапуан абый...—Сандра тирән итеп сулап куйды.—Үзем дә сагындым. Начылый килеп життем...

—Менә, ошармы инде үзенә?—диде Сафуан һәм яшергән җиреннән җәмкине алып бирде. Матур булсын дип, җәмкинең сабын сырлап ясаган иде тимерче. Сандра аны алып кыскалап та, тегеләй дә, болай да итеп карады, аннары Сафуанга күз сирпеп, тагын сөйкемле елмайды:

—Бик матур, җайлы итеп җасагансың, Сапуан абый, рәкмәт! Мына, әниләр күчтәнәч—каклаган каз җибәргәннәр эйе, кул җалы булыр үзенә,—дип, кырыйлары чачаклы-чуклы итеп бизәлгән ак тастымалга төргән әйбер сузды.

—Миңа синнән бернәрсә дә кирәкми, Сания, әйбереңне алмыйм, үпкәләмә,—диде тимерче йомшак, ләкин каттый итеп.

—Ал инде, Сапуан абый, мин бит сиңа жаратып бирәм бу жазулы бистәрне, истәлек итеп,—диде Сандра, үпкәләргә җыенган кыз кебек.

—Нинди бистәр?—Сафуан өчен бу сүз таныш түгел иде.

—Мына бу—бистәр инде,—дип төртеп күрсәтте Сандра кулындагы чачаклы-чуклы тастымалга.

—Язуы да бармыни?

—Бар, жазуы да бар.

Сандра «бистәр»ен сүтеп, Сафуанга күрсәтте. Ак тастымалның бер читендә тамбур белән шундый сүзләр язылган иде: «Сапуан абыйга истәлек». Һәр сүз төрле төстәге чигү җебе белән язылган. Бу инде кадерле бүләк, аны алмый калып булмый. «Истәлек» дип язылуы инде хәлне бөтенләй үзгәртә. Димәк, Сафуан гына Сандра турында уйламый, Сандра да уйлый аның турында...

—Тагын ничек бәкыйлләтим сун сине, Сапуан абый?

Сандраның бу сүзләре тимерчене тәмам котыртып җибәрде. Ул, кыюланып:

—Бер кочаклат, Сания җаным! Бигрәк матур, бигрәк ягымлы, бигрәк татлы инде үзен, гел акылдан яздырасың,—диде.

—И-и, Сапуан абый, кеше килеп керсә, мыскылга калабыз бит...

Ай, Сандраның тел төпкәйләре! «Мин кочаклатырга риза, Сафуан абый, без кочаклашып торган вакытта кеше генә килеп кермәсен»,—дигән сүз бит бу...

Сафуан, ишекне ачып, тышка карады. Аның бәхетенә, алачык тирәсендә яки аңа таба килүче кем дә булса күренми иде.

—Юк, беркем дә юк,—диде ул әллә ничек, тыны кысылып—йөрәге ашкынулы тибә, каны кайнарланып килә иде. Шул кайнарлану белән тузанлы алъяпкычын салып атты да, утлы тәнле Сандраны кочагына алып кысты. Сандра исә калтыранып куйды һәм жылы, йомшак беләкләре белән үзе дә Сафуанның муенына сарылды. Вакыйга гел Сафуан көтмәгәнчә килеп чыкты, ләкин булган эш булды. Шушы яшькә житеп мондый да бәхетле мизгелне татыганы юк иде әле Сафуанның. Сандрасын әйт әле: Болгар ханбикәсе кебек затлы, матур киенеп, тузанга батып беткән тимерчедән кочаклатырга алдан ук уйлап килгән диярсең. Шулай ук җинел-җилбәзәкме, әллә соң алып гәүдәле, ягымлы тимерче артык ошап китеп гыйшкы төштеме аңа?

—Син мине бик азындырма, Сапуан абый, артыгын җараттырма,—диде Сандра тимерченең кочагыннан чыкмыйча гына. Аннары өстәп куйды:

—Үзеңнен дә жараткан кызың бардыр әле, көннәшә башласа...

—Яратканым хәзер куенымда. Ә башканы белмим мин. Элек бер кызга күз төшеп йөри иде, кияүгә чыкты. Беләсең килсә, минем әле синең кебек кочакка алган кызым гомергә булмады.

—Сап жегетмени?
—Саф.
—Мин дә сап кыз бит, Сапуан абый...
—Ничек, саф? Кияүгә чыгып та саф яшәп буламы?
—Була икән шул...

## V

Моннан соң Сандра Сафуан алачыгы бусагасын еш таптады. Җәмки генә түгел, ана әле соскы да, күмер савыты да, мич капкачы да, кычырга белән ухват та, тагын әллә нәрсәләр дә кирәк булып чыкты. Һәм килгән саен Сафуанның кочаклап алуыннан, иркәләүләреннән тәмам исереп кайтып китә торган булды.

Шушы кайнар очрашулар вакытында Сафуан үзенә мәгълүм булмаган сорауларга җавап тапты. Теге юлы Сандра үзенең кияүгә чыгып та саф яшәве турында әйткән иде. Ничек була соң ул?

Микулайның Сандрага өйләнүе болайрак булган икән. Сугыштан соң бик озак госпитальдә дәваланып, тагын күпмедер вакыт урманчылыкка укып кайткач, егет гаиләдә өйләнү турында сүз кузгата. Әнисе Праскый түтәй аның бу теләген күптән белгән кеше сыман:

—Мин сиңа килен карап куйдым, Микулай. Мына дигән, асубый килен,—дип куя.

—Кем сун ул?

—Карга Гөргөри Сандрае. Бер жегет белән дә жөрмәде, чиста кыз. Андыен да асыл керәшен кызы безнен аулда гына төгөл, бөтөн керәшен дөнжәсендә бер генә. Асыл да, пырастуй да...

—Ул бик жәш төгөлме сун?

—Жәше житкән, уналтысы тулган, кияүгә чыгарлык булган,—дип тезеп китә Праскый түтәй.

Микулай анасы сайлаганга риза була. Кызга яучы жибәрәләр. Микулай яучыга Гөргөри дәдәй белән Начтук түтәйгә әйтәсе сүзен дә әйтеп жибәрә:

—Мин казер урман кужасы. Аларның жорты тузып, кәкрәйгән. Сандрайны бирсәләр, аларга жаңа жорт салырбыз,—дигән. Әллә шунамы, кыздан егеткә барырга ризалык тиз килеп житкән. Ярәшкәннәр кызны. Бөтен керәшен йолалары буенча ипи-тоз, бал да май, каклаган каз-үрдәк, башка төр күчтәнәч һәм бүләкләр, кадер-хөрмәт белән Таллы Елга урамнарын тутырып, шаулап-гөрләп, җырлап-биеп туй үткән.

—Яратасынмы соң син аны?—дип төпченде Сафуан.

—Аның кайсы төшөн жаратасын? Үзе жабык, үзенен хале жук.

—Ничек хәле юк?

—Ул бит сугышта кантуж булган, казер мужиклыгын итә алмый,—диде Сандра, керәшен хатыннарына гына хас турылык, хәйләсезлек белән, һич боргалап-сыргалап тормыйча.

—Шуңа балагыз юкмыни?

—Жук шул. Мин ун бала табар ыйем да, ул бит...

Сандра көрсенеп куйды.

—Ә-ә, алаймыни?—дип сузды Сафуан.—Имәндә икән чикләвек. Киләчәктә ничек яшәргә уйлыйсың соң син анын белән?

—Белмим шул ничек жәшәргә, һич уйлый алмыйм...

Тимерче Сафуан тимерне кызуында сугарга өйрәнгән, монда да аптырап калмады, үгезне мөгезеннән эләктерде:

—Син, Сания матурым, артык борчылма. Үзең сылу, бер кашык су белән йотып жибәрерлек сылу. Теләсәң, бер жаен табарбыз. Синең өчен минем жаным фида...

Сандраның да башы карабодай саламы белән япмаган, зирәк, Сафуанның тел төбен тиз аңлады.

—И-и, Сапуан, куркам шул мин. Кеше ишетсә, нишләрбез?

Сафуан Сандраның ана абый димичә генә эндәшүенә игътибар итте. Димәк, үз итә, үз күрә, үз тине итеп саный. Бу хәл аны канатландырып

җибәрде. Керәшен гүзәленең аныкы булачагына өмет көннән-көн зурая, ара якыная бара ич.

—Белдермәскә инде аны, Сания җаным. Авыл урамы буйлап сөйләп йөрмәссең бит инде минем сине якын итүем, яратуым турында.

—Җук та бит. Кырын эш кырык җылдан сун да беленә...

Шулай диюенә карамастан, дәрте ташып торган яшь хатын давыл кебек башланган гыйшык уенын туктатырга исәпләми дә иде. Сафуан аңа таба омтылган һәр мизгелдә Сандра да кабат атылып аның кочагына керде, аның сөю хозурында ләззәтләнде.

—И-и, Сапуан, сине җарата башладым бугай. Ә син мине җаратасыңмы?

Сандра, түгәрәк зәңгәр күзләрен Сафуанга төбәп, наян караш ташлады.

—Мин дә яратам шул, яратмасам шулай йөрер идемме? Яратмасам, сагынып көтәр идемме?

—Мужикларга кыз-кыркыннан бер генә нәрсә кирәк, аларга җаратмасалар да була.

—Алай димә, Сания. Ярату бар ул, аннан башка тормыш ямьле булмас иде. Әнә нинди авыр тормышта яши халык. Минеке дә аларныкыннан җинел түгел. Ә менә сине ярата башлагач, бөтен дөньям онытылды. Хәзер мин сине уйлап яшим. Инде мәшәкатьле дөньям да бераз түгәрәкләнде сыман...

—Безнекеләргә дә авыр,—диде Сандра, уйланып.

—Кемнәр турында әйтәсең?

—Безнең семья—әтиләр, безнең Таллы Җылга авылы калыгы, бөтен керәшеннәр...

—Дөрес әйтәсең, Саниякәй, хәзер барысына да бик авыр: татарынакерәшененә дә, чуашына, мукшысына да, урысына да. Тик бу турыда кычкырып йөрүдән файда юк, алай гына да түгел—төнлә килеп алып китүләре дә мөмкин. Әнә, Галәметдин абзыйны олактырдылар бит. Мыеклы абзый турында мәзәк кенә сөйләгән булган. Эзе дә юк хәзер...

Алар беравык кочаклашкан килеш уйланып, эндәшми басып тордылар. Шулай бер-берсенең йөрәге, кан тамырлары типкәнен, тән җылысын тоеп басып торудан да рәхәте юк икән.

—Минем сиңа бер соравым бар, Сания матурым,—диде Сафуан, нәрсәнедер исенә төшереп.

—Нинди сорау ул?

—Гади генә... Керәшеннәр кемнәр алар, каян килеп чыкканнар, син беләсенме? Ату карап-карап торам... Син дә, Микулаен да—икегез дә яхшы кешеләр. Барлык керәшеннәр дә шулаймы?

Мондый мактау сүзләреннән соң Сандраның күңеле булды ахры—энҗе тешләрен күрсәтеп, елмаеп җибәрде.

—Җакшы булмый ни, җакшы... Тулькы мына керәшеннәр каян килеп чыкканнар? Мин мыны җакшылап белмим шул. Марпа әбинен бер җыруы бар-барын.

—Җыр? Нинди җыр ул?

—Җырлыйммы сун?

—Әлбәттә, әлбәттә... Мин бик телим синең җырлавынны, Саниякәй... Минемчә, син бик әйбәт җырларга тиеш—тавышың йомшак, моңлы. Чиләктән аккан яна сауган җылы сөт кебек агып чыга күкрәгеңнән синең матур тавышың...

—Тулькы башта ишекне ачып кара, Сапуан, кеше-кара килеп кермәсен.

Сафуан ишекне ачып карады—якын-тирәдә кеше күренми иде.

Сандра тамагын кыргалап алды да, әкрен генә сузып җырлый башлады:

> Ургый гына ургый урак урдым—
> Ата-бабаларның кәсебе;
> Керәшеннәр кемнәр, дип сорасаң:
> Болгарлардан килә нәселе.

Сонгы ике юлны, тавышын күтәрә төшеп, кабатлап җырлады Сандра:

Керәшеннәр кемнәр, дип сорасаң:
Болгарлардан килә нәселе.

Сафуан анын жырыннан чын-чынлап әсәрләнде. Әйе, ул ялгышмаган: Сандра бик моңлы жырлый икән бит. Кайчандыр бер елны Каенлы авылының бәләкәй клубында Казан артистлары концерт куйганнар иде. Рәшит Ваһапов, Жәвәһирә Сәлахова, тагын кемнәрдер килгән иде. Алар да әйбәт, бик әйбәт жырлаганнар иде. Ә менә Сандраның жырлавы үзәкне өзгәләп-өзгәләп алды.

—Рәхмәт, Сания жаным, күңелне кузгаттың. «Болгарлардан килә нәселе... » Гажәп, бик гажәп! Син, Сания, тагын жырларсың әле, башка жырларны дим, башка керәшен жырларын...

—Жырлармын, жырлармын, Сапуан жаным. Бүген кайтып китим инде. Бик озак жуандым синен белән, озак жуандым. Жаратам шул, бик жаратам! Сине жаратып, бу дөнҗәдә бөтөнәй жугалмасам жарар иде инде.

Сандра, Сафуаннан һич аерыласы килмичә, артына борылып карый-карый китеп барды.

## VI

Берничә көн Сандраның алачыкта эзе дә булмады. Юк та юк. Килми дә килми. Сафуан сагынып бетте. «Әллә бер-бер кирәкмәгән сүз әйтеп үпкәләттемме, шуңа килмиме»,—дип тә уйлады тимерче.

Ниһаять, беркөнне кичке якта күренде Сандра. Күкрәгенә ике куллап бер кочак төрледән-төрле матур урман, кыр чәчкәләре кыскан. Аларның яртысын аерып, Сафуанга сузды.

—Жаратканга бирәм, бик сагындым үзеңне,—диде Сандра һәм Сафуанның муенына сарылды, аны суырып-суырып үбеп алды.

—Кая югалдың, нигә килми тордың?—диде тимерче сабырсызланып һәм үпкәләгән итеп.

—И-и, жаным, мине Микулай питомникка эшкә куйды, мин казер эшкә жөрим бит.

—Нинди эш ул?

—Орлык чәчәбез, жәш үсентеләрне карыйбыз, аларга инештән ташып су сибәбез. Эш бик күп, арып-талып кайтам. Бөгөн дә арыдым, тик сине күрәсем килде, керми булдыра алмадым.

Сандра питомникта тагын нәрсәләр һәм ничек эшләгәне турында сөйләде. Чыршы, нарат, карагай, каен үсентеләре карап үстерәләр икән алар, аннары аларны төрле жирләргә илтеп утырталар, шулай урман мәйданын арттырырга тырышалар.

—Сапуан, урманда шундый да жәмле. Ташла әле шул алачыгыңны, кил әле минем жанга эштән суң. Бергә-бергә сүләшеп, каеннар белән серләшеп, жырулап утырырбыз бер. Жырак төгөл бит моннан, тауга гына күтәреләсе. «Каеннар жулы»на барырбыз. Синен «Каеннар жулы»н күргәнең бардыр инде. Бигрәк жәмле анда...

Сафуанның чыннан да күптән урманга чыкканы юк. Быел яз каен суына барырга жыенды, тик вакыты житмәде. Әллә соң чыннан да Сандра янына барып чыгаргамы бер? Сандра да анын, әнә, урманга, «Каеннар жулы»на килүен тели.

«Мәхәббәт ул сугыш кебек: көтмәгәндә генә барлыкка килә, ләкин аны туктатуы жинел түгел»,—дигән кайсыдыр бер акыллы баш. Сафуан белән Сандра арасындагы мәхәббәт тә шуңа охшый, туктарга уйламый да...

—Кил инде, Сапуан жаным!

—Ярар, барырмын.

—Иртәгәме?

—Иртәгә...

Икенче көнне Сафуан алачыкта баш күтәрми эшләде. Эшен төгәлләп, алачыгын иртәрәк япты да, әрәмәдән генә турыга тауга таба, «Каеннар юлы»на ашыкты.

Менә «Каеннар юлы»... Кайсы тапкыры аны шулай атаган? Шигырьлемоңлы атама. Сафуанның элек бу турыда уйлаганы да юк иде. Ләкин төз, ап-ак киемле каеннарның рәт-рәт булып тезелеп торуына соклана иде ул: «Ничек алар шулай тигез булып үсәләр, ничек шулай туры килгән?» Сандраның питомникта эшлибез дигән сүзеннән соң аңлады: «Каеннар юлы»н тигез итеп кешеләр утырталар, үзләре генә үсмәгән икән алар.

«Каеннар юлы»... Әйе, каеннарны ике якка аерып юл да үтә аннан, урман юлы. Ләкин аны «Каеннар юлы» дип түгел, ә «Каенлы юл» дип атарлар иде. Хикмәтле атама...

—Начылый эшебезне бетердек, суңга кала җазганмын, син килеп тә житкәнсең икән, Сапуан бәгерем,—дип, тынына каплана язып Сандра да килеп житте. Җылы кочаклашып, ап-ак халатлы, зифа каеннарга сокланып, урман һавасын сулап шактый йөрделәр алар. Аннары бер бәләкәй генә алан кебек җиргә барып утырдылар, татлы итеп үбештеләр, сөештеләр. Кәефе күтәрелгән Сандра сузып җырлап җибәрде. Тик тавышын артык күтәрмичә, кеше ишетерлек булмасын дип, салмак кына җырлады ул:

Җафрагын жарган җәш каеннар
Җәшкәп утырадыр җылгада;
Берләр аерылгач, күрешәлмәбез
Айларында түгел лә, җылда да.

Ак та каеннарны җәмле итә
Җафыракай белән туз гына;
Бу дөнҗәдә чиксез уйлар уйлый
Җегеткәен сүгән кыз гына...

«Җегеткәен сүгән кыз гына»,—дип сузганда, Сандра Сафуанга сыенды, аны ике куллап кочаклап алды. Бу җырны аның Сафуанга атап җырлавы иде. Керәшен «җырулары» алар әнә шулай конкрет берәүгә яки берәүләргә атап җырлана—Сафуан шуны аңлады.

Йомшак тавышы белән Сандраның күкрәгеннән моң ташыды. Сафуан аны ихлас күнел белән, тын калып, бирелеп, уйланып тыңлый бирде. Ә Сандра бер көйдән икенчегә, өченчегә күчеп җырлады да җырлады. Аның күптән шулай ләззәт табып җырлаганы юк иде бугай.

Гөл бакчаларына гөлләр чәчтем,
Гөл бакчалары ла, ай, тулганчы;
Гөл-гөлләргә былбыл, ай, кунганчы,
Аерылмыйык, жаным, ай, үлгәнче...

Сандра кабат Сафуанга елышты, башын аның күкрәгенә салды һәм җырның ахырын кабатлады:

Гөл-гөлләргә былбыл, ай, кунганчы,
Аерылмыйык, жаным, ай, үлгәнче...

Ул тынып калды. Аның җыры белән сихерләнеп, Сафуан да сүзсез калган иде. Каенлыкта өздереп-өздереп сандугач сайрый. Җилдә яшь каен яфраклары җилферди. Ә Сандра, тимерченең күкрәгенә түгәрәк башын салган да, пышык-пышык килеп кайнар яшьләрен түгә. Тимерче аны сүзсез генә, җылы куллары белән яшьле битләреннән, аркасыннан сыйпый-сыйпый сөя-юата. «Аерылмыйык, жаным, ай, үлгәнче»... Сандра җыруының шушы сүзләре аның җанын телгәли.

* * *

Беркөнне Сандра кичке якта ашыгып кына тагын Сафуан янына, алачыкка килеп керде.

—Микулай тагын Акташка, лесничий янына китте. Тагын: «Кунам»,—диде. Киләсенме? Энгер төшкәч тә кил, көтәм, сүләшеп утырырбыз...

Сафуан караңгы төшкәнне ашкынып көтте. Нишләптер, караңгы бик

озак, көттереп төшкән кебек булды ана бу кичне. Күз бәйләнгәч тә, өйдәгеләргә: «Күршеләргә кереп чыгыйм әле»,—дигән булып, бәрәңге бакчалары аша Сандра янына ашыкты. Авыл башындагы яңа йортка тиз барып житте ул. Өй тәрәзәләрендә ут күренми, Сандра аны сүндереп куйган иде ахры. Тирә-якны тикшерә-карый, зур гәүдәсе белән кысыла-кысыла ике киртә арасыннан йортка керде, инде караңгы төшсә дә, ерактан аксыл булып күренеп торган яңа баскычка менеп, әкрен генә ишекне шакыды. Бу минутларда алып кебек таза Сафуан тәүге тапкыр караклык кылырга чыккан кеше шикелле калтырый, йөрәге дөп-дөп тибә, аркасы юеш, үзе исә ялт-йолт як-якка карана иде. Шул мизгелдә кем дә булса берәү «һайт!»—дип кычкырса, торып басса түбәсе түшәмгә тиярдәй Сафуанның нишләгәнен күз алдына китерү авыр түгел иде. Шөкер, алай кычкыручы булмады. Әкрен генә ишек ачылды. Берничә секундтан Сафуан кайнар ялан тәнгә нечкә ситсыдан теккән йокы күлмәге кигән Сандра кочагында иде инде. «Аулак өйгә» чистадан киенеп килгән Сафуан күкрәгенә гүзәл Сандраны алып, шашып-шашып назлый, иркәли башлады, жылы куллары белән аның мулдан-мул тыгыз күкрәкләренә, жылы һәм йомшак аркасына, нечкә биленә, аннан да аскарак жирләренә кагылды. Сандра исә карышмады, Сафуан кайдан тотса, шуна риза булып, ләззәтләнеп, эреп торды.

—Сапуа-ан... Бу синме, жаным?—дип пышылдады Сандра, ниһаять. Сафуан әле күзләре ияләшергә өлгермәгән караңгы өйдә аның түгәрәк матур йөзен дә, зәңгәр күзләрен дә күрми, фәкать кочагына кереп поскан кайнар тәнен генә тоя иде.

—Көтәм, көтәм... Әллә килмисең инде, дип уйлый башлаган ыем,—дип дәвам итте Сандра.

—Менә, килдем бит...

—Бик сагындым...

Икесенең дә йөрәкләре күкрәк читлегеннән чыгып атылырдай булып тибә, тәннәре калтырый, сулышлары кысылган иде.

—Жа-ны-ым...

Тимер сугып мускуллар ныгыткан Сафуан көчле куллары белән кочаклый гына белә, яхшылап, оста итеп, тәм табып үбешергә өйрәнергә әллә вакыты житмәгән, әллә жае туры килмәгән иде. Аңа Сандра үзе булышты, татлы, кайнар иреннәре белән суырып-суырып үбәргә керешге. Сафуанның болай «котырып» суырып үбешкән хатын-кызны тәүге тапкыр күрүе иде. Тора-бара ул үзе дә Сандраның битләреннән, озын керфекле күзләреннән үбә башлады. Аннары аның олы бармаклары Сандраның күпереп торган куе чәчләренә кереп батты. Шул килеш ул аның түгәрәк, матур башын кочаклап күкрәгенә кысты, сыйпады, иркәләде, жилкәләре, күкрәге белән Сандраның жинел ситсы күлмәге аша бөтен тән жылысын тойды, аннары йөзен аның кайнар муенына каплады.

—Шаштырасың мине, Сания бәгърем, шаштырасың... Әллә ничек шунда, яхшы түгел...

Ләкин Сандраның йомшак куллары аның муенына ишелеп сарылган һәм ул аларны жибәрергә уйламый да иде. Кияүгә чыгып та чын-чынлап ир назын татый алмый яшәгән, һаман гыйффәтле булып калган Сандра бөтен нәрсә турында онытып, әхлак киртәләрен сындырып, үз теләгенә ирешү максатын куйган иде. Шуна ишарәләп:

—Сапуан, жаным, мин синеке казер,—диде. Сафуан эндәшмәде, башы белән Сандраның олы-олы күкрәкләренә генә чумды һәм тынып калды. Аннары башын күтәрде дә, яшь хатынның тәрәзә аша әллә кайдан төшкән сүрән яктылыкта шәйләнгән очкынлы күзләренә карады. Сандраның иреннәре түземсезләнеп кабат аның иреннәренә кушылды. Шул килеш ул хатынны кулларына алды һәм йомшак мендәрләр түшәлгән агач караватка илтеп салды. Сандра, бер кулын баш астына куйган килеш, яртылаш һушсыз ята иде. Сафуан кабат аны кайнарланып үбәргә, кочарга, назларга тотынды. Түзмәде, сикереп торды да, үзен-үзе белештермәс хәлдә чишенә башлады. Күлмәген салып атты, чалбарын салганда бер төймәсе өзелеп чыкты һәм ул каядыр агач карават астына тәгәрәде. Бу вакытта Сандраның да сабырлыгы

тәмам төкәнгән иде—кузгалып куйды һәм ситсы күлмәгенең итәкләрен күкрәгенә кадәр күтәрде, ә Сафуан аны бөтенләй салып ташларга булышты. Түзәрлеге калмаган Сафуан Сандраның каршылыксыз тәненә кысылды, ботлары ботка кушылды.

—Сания бәгърем, Саниякәем... Аһ...

Бер мәлне Сандраның тәне дерт итеп китте, ә үзе ыңгырашып куйды...

Күпмедер вакыттан соң алар тындылар. Ләкин Сандра үзенең йомшак беләкләрен тимерченең муенынннан әле бик озак алмый торды, әйтерсең лә шушы кочаклавы белән ул аны мәңгегә үзенә бәйләп куйган иде.

—Ай, карап иттен, Сапуан жаным, бетерден...

—Үзең теләдең бит, Саниякәем, үзең теләдең...

—Теләдем шул, теләдем. Җазыклы булдым инде. Мына казер Микулайга ничек җавап бирергә? Сикерләдең, гел ырымнадын син мине. Җараттырдын, сүдерден үзенне... Казер нишләргә инде? Башым эшләми,—дип берөзлексез сөйләнде Сандра һәм кинәт:—Әй, беткән баш бетсен инде—тагын килерсен, жаным,—дип әйтеп салды.

—Килермен, килермен. Тик хәзер кайтып китим, Сания, мине югалтканнардыр.

—Кем жугалтсын сине, катынын жук ла. Тан алсуланганчы тор инде, жаным, китмә, мин үзем генә куркам бит,—диде Сандра. Ләкин Сафуан калмады, чөнки ул белә—өйдә чыннан да аны югалтулары бар. Өйләнмәгән егеткә ярты төнгә чаклы йөрү ярый әле, ә инде иртә таңда кайту... Юк, анысы һич калыпка сыя торган эш түгел.

Сөю назы белән тәмам тәэсирләнгән, әсәрләнгән Сандра, һаман балаларча беркатлы тәтелдәп, Сафуанны кайнар, сусыл иреннәре белән суырып үбә-үбә, гажизләнеп чыгарып җибәрде...

## VII

Сандра тимерче белән, үзе әйтмешли, чыннан да «сикерләнде». Уналты яшенә чаклы аның туган авылында гыйшкы төшәрлек егет-жилән булмады. Таллы Елганың менә дигән егетләре сугышка китеп, бик сирәге генә яраланып кире кайтты. Карга Гөргөриненең гүзәлләрдән-гүзәл булып өлгергән Сандрасын сөяргә кеше дә юк иде. Дөрес, сугыш бетәр алдыннан гына армиягә алынган күршеләре Дранча Ычтуп малае Җәгүр әле яше дә җитмәгән кызга берничә хат язды, ләкин аларда ярату турында ике сүз дә юк, чөнки үзе дә балалыктан чыгарга өлгермәгән, бары унжиде яшьтә генә иде егет һәм ул мәхәббәт турында кайнар-кайнар хатлар язарга әле өйрәнмәгән, аны белми дә иде. Шулай да бер хатта аның: «Сандрай, үсә тор, минем кайтканны көт!»—дигән сүзләре бар иде. Ләкин соңыннан Җәгүрнең Сандрага хатлары сирәгәйде. Чөнки ул Төлке Аннугы белән еш-еш хат алыша башлаган—бу турыда ана пушты Татук житкерде.

Әнә шулай, уналтысына житеп тә сөю назын татырга туры килмичә, Микулайга кияүгә чыкты Сандра. Ләкин аның күнелендә Микулайны аз гына да ярату хисе тумады. Бәлки бергә тора-тора яратырмын, дип уйлаган иде, юк, анысы да булмады.

Һәм менә, ниһаять, тимерче. Бер аягына чатанлый торган мөселман татары. Үскән чакта анасы Начтук түтәй дә, атасы Гөргөри дәдәй дә, башка керәшеннәр дә нигәдер мөселман татарларын эттән алып эткә салып хурлыйлар иде. Ә менә Каенлы Чишмәдә хурларлык бер генә кеше дә тапмады Сандра. Миңлезифа әбидән башлап, барысы да якты чырайлы, киң күнелле, мәрхәмәтле-шәфкатьле. Ә инде Сафуанга килсә... Аның кебек шәп егет турында Сандрага хыялланырга да туры килмәгән иде. Сандраның бәхетенә алар Микулай белән Каенлыга күчеп килделәр дә, Сандраның бәхетенә Тирәкле инеше буендагы тәбәнәк алачыкта Сафуан дигән гөрнәдир кебек тимерче эшли торган булып чыкты. Менә бит ул язмышлар! Дөрес, бер аягына чатанлый ул тимерче. Ләкин сугыштан соң ике ирнең берсенең йә аягы, йә кулы, йә күзе юк. Алар тирәсендә Сафуанның аксавы—бөтенләй пүчтәк. Аның каравы, ул төскә-биткә дә, гәүдәгә дә, назга да Микулайдан

ике башка өстен. Сафуан сызгырса, ул аның белән жир читенә китәргә дә риза югыйсә, ләкин жир читенә киту турында Сафуанның сүз кузгатканы юк әле. Тәүге ташкын хисләр, тәүге сөю... Инде ике елдан артык ир белән яшәгән хатын дип һич уйламассың Сандра турында. Әнә ничек хозурлы була икән ул чын сөю! Сандра шул ялкында бөтен дөньясын онытты, тулысы белән Сафуан иркенә бирелде.

Шул көннәрдә яшь хатынның уйламаган уе, янмаган-көймәгән сәгате булмады. Бер әрләде үзен, бер аклады, бер яна өенең почмагында Изге сурәт каршына тезләнеп: «Кодаем, кылган жазыкларым өчен кичер мине, жазыклы бәндәңне ярлыка»,—дип тәүбәгә килде. Аннары тагын уйланды.

...Бернича ел элек читтән килгән бер укытучы Сандраларда фатирда яшәгән иде. Начтук түтәй кибеткә барган жиреннән ияртеп кайтты аны. Күпне күргән, күпне белгән бу ялгыз хатын зирәк акыллы, һәрнәрсә белән кызыксынучан Сандраны үзенең сердәше итте. Ләкин язмышы көнләшерлек түгел иде аның. Сугыш алдыннан педтехникум тәмамлаган яшь кызны күрше районның бер авылына укытучы итеп жибәргәннәр. Бернича ел шунда укыткан ул. Сугыш елларында жидееллык мәктәп директоры итеп билгеләгәннәр. Шунда чатнап киткән дә инде аның тыныч тормышы. Район күләмендәге төрле чаралар вакытында еш-еш очрашу-сөйләшүләрдән соң район башкарма комитеты рәисе моңа үзенең мәхәббәтен белдергән. Ир-егетләрнең барысы да сугышта, сайланырга мөмкин түгел. Рәиснең хисләре чындыр дип, кыз бәхетен сынап карарга уйлый. Очрашулар, сөешү-назлашулар кайнар була. Берзаман кызыбыз үзенең борчак белене ашаганлыгы турында сизенә, бу турыда борчылып сөяркәсенә дә житкерә. Ләкин районның иң олы түрәсе чыраен да сытмый: «Анысы синең проблема, мин хатыным өстенә сине алып кайтып китәлмим бит инде»,—ди. Дөрес, әвеш-тәвеш итеп, түрә үзенең бәлагә тарыган сөяркәсен икенче авылга күчерә, шунда тегесе кыз таба. Моннан соң инде ул: «Ирем сугышта һәлак булды»,— дигән уйдырма белән яши башлый. Кызын үз туган авылына, анасы карамагына кайтарып куя.

Укытучының белмәгән нәрсәсе юк, сөйли башласа, теле-телгә йокмый. Тик фәлсәфәсенә генә бик үк төшенә алмады житлегеп килгән Сандра. Шулай да, укытучының бик күп сүзләрен йөрәгенә сеңдереп калды:

—Яшәсәң йөрәк белән яшә, сеңлем. Хатын-кыз өчен мәхәббәт еш кына кайгы да хәсрәт кенә ул, ләкин мәхәббәттән дә татлырагы юк бу дөньяда...

—Ах, Сандра, гүзәл син, бик гүзәл! Бәхетле булсаң иде, мин сиңа шуны телим. Ләкин, сеңлем, шуны да бел: гүзәл хатын өчен шатлыклы чор кыска була. Уналтыда-унжидедә аның янына ялагайланып киләләр, ә бернича елдан инде ташлап та китәләр. Димәк, бу елларның һәр сәгатен бәхетле, күңелле итеп үткәрергә тырышырга кирәк. Аннары соң булыр. Терсәгеңне бик тешләргә теләрсең дә, соң булыр...

Бу сүзләр Сандраның йөрәк түрендә. Алар аның яшәү кагыйдәсе сыман. Шуна да бит инде ул Микулае өстенә Сафуанны үз итте...

## VIII

Каракның бүреге яна. Сафуан белән булган төненнән соң Сандра ут йотып, тын алырга да куркып йөрде. Микулайга күзләрен күтәреп карый алмады, ул барысы турында да сизәдер, беләдер кебек тоелды ана. Ләкин Микулай ул-бу сизенмәде ахры. Әллә эше бик күп идеме—ул ике-өч көнгә бер Акташка, лесничий янына чапты. Инде Акташка киттеме, ул бу кичне кайтмый, куна кала. Ара якын түгел, атка да ял кирәк. Моннан тыш Микулай белән лесничийның борчаклары да яхшы пешә, дуслар, төн ката көмешкә белән сыйланып, күңел ачып чыгалар.

Сандра белән Сафуан өчен исә Микулай Акташтан бөтенләй кайтмаса да ярый. Аларның икесенең дә ташлары кызган көннәр иде, дөньяларын онытып очраша, яратыша-сөешә тордылар.

Шушы хозурлы атналарның берсендә Сандра үзенең балага узуын

сизенде. Бу хәлдән ул бөтенләй пошаманга калды. Микулай белсә, нишләргә? Ничек карар ул моңа? Пыр туздырып аерып җибәрерме, әллә измәсен генә изәрме? Хәер, өч ел бергә яшәп Микулайның әле бер генә дә тузынганы юк, хәтта ачулана да белми. Әнә Сандраның үз атасы атна саен бер тузынып ала, атна саен ил аера, түшәмнән туфрак коя. Дөрес, ул моны салган баштан эшли. Ләкин Микулай да салмый тормый ла. Әнә, беркөн Акташтан ничек кайтып төшкәнен дә хәтерләми, лаякыл исерек иде. Ярый әле Акбәкәл—ышанычлы ат, арбада йоклап яткан исерек хуҗасын тартып, туптуры үз йортларына кайтып керде.

Икенче яклап, Сандра сөенеп туймады: ул бит балага узды, аның баласы булачак! Өч ел бит инде аның якын туганнары, атасы-анасы, бергә үскән ахирәтләре, күршеләре туган авылына кайткан саен күз ачырмыйлар: «Нигә бала тапмыйсың?»—дип авырткан җиренә кагылалар. Бер Микулай гына бу турыда сүз кузгатмый, авызына су капкан, диярсең. Кузгата да алмый. Җиңел түгел аның хәле. Олы авылда сылу бер кызга өйләнә дә, аның күңелен дә күрә алмый яшә. Оят та, хурлык та...

Юк, алай дип әйтү дә дөрес булмас. Микулай гаеплеменни ана? Сугыш, каһәр төшкән сугыш гаепле. Шул сугыш булмаса, япь-яшь Микулай контузия алып, тәмам гарипләнеп кайтмаган булыр иде. Ул бит үзе дә моңа бик нык борчыла, төн йокыларын йоклый алмый уфтанып чыга. Ә үзе эндәшми. Йокысыннан тора—эндәшми, ашап утыра—эндәшми, эшкә чыгып китә—эндәшми, эштән салмыш кайтып керә—эндәшми... Дәшмәкигә әйләнеп бетте инде. Сандра аны кызгана әлбәттә, ләкин аннан ни файда?

Сафуан белән бәйләнеп, Сандра үз тормышын катлауландырды бугай. Ләкин дәрте ташып торган яшь хатын үзенең бала табарга сәләтлеме-түгелме икәнен белергә тиеш иде, шуңа ул тәвәккәл адым ясады.

Иргә чыгып та кыз булып сазамас бит инде. Ул бит хатын-кыз: бала табарга, ана булырга, киләчәк турында кайгыртырга—үзенә алмаш буын тәрбияләп үстерергә тиеш кеше. Әгәр бала табуда ир заты үз вазифасын үти алмый икән, үзенә үпкәләсен. Мондый вакытта хатыны иренә хыянәт итә икән, аның хыянәте изгедән саналырга тиеш. Әйе, изге хыянәт!

Ниндидер бер мизгелдә Сандраның башына ярыйсы гына уй килде. «Әллә соң Микулайның теге көнне лаякыл исерек кайтуын файдаланып, хәйләләп алыргамы? Балага синнән уздым, син исерек булсаң да, эшенне эшләдең, дияргә»... Ләкин беркатлы, саф күңелле, урлашырга-алдашырга өйрәнмәгән Сандраның йөрәге болай эшләүне хуп күрмәде, кабул итмәде. Микулай, начармы-яхшымы, аның ире. Язмыш тарафыннан болай да рәнҗетелгән, кимсетелгән ирен алдауны ул намуссызлык, зур гөнаһ дип санады һәм тыныч хәлдә барысын да ачыктан-ачык сөйләп бирергә, аптыраганнан кылган гөнаһысы өчен гафу үтенергә, иренең ярлыкавын сорарга ниятләде. Ничек булса—шулай булыр. Куып җибәрә икән—китәр, илдә чыпчык үлми. Бер баланы ничек тә үстерер, сугыш вакытында, әнә, бишәр-алтышар баласын ялгыз үстергән хатыннар булды авылда. Бүген дә үстерәләр...

Ләкин Сандра, ничек кенә борчылмасын, Микулайга авыз ачып сүз әйтә алмады. Шулай көннәр, атналар үтте. Сандраның күмәне күзгә күренеп үсә башлады. Аны Микулай да күреп торды. Күреп торды, тик ни дип тә сорашмады, сүз катмады. Ничектер, бик тыныч кабул итте ул бу хәлне: гаҗәпләнмәде дә, шатланмады да, тузынмады да. Әллә инде үзенең чарасызлыгы, көчсезлеге белән килешкән иде, әллә җәнҗалның аның файдасына булмаячагын аңлады, әллә ялгыш үземнең эшемдер бәлки дип уйладымы? Кемнең дә булса башка берәүнең аның түшәген бүлешүе башына да килмәде ахры Микулайның. Югыйсә, Сандра олы җәнҗал көткән иде, шул чакта аңлатып, ачыктан-ачык әйтеп бирермен дип уйлаган иде, тик боларның берсен дә эшләргә туры килмәде ана.

Бер очрашуда Сафуан бик дулкынланган иде. Һәрвакыт елмаеп торган егетнең йөзе җитдиләнгән, уйчанланган. Сөйләшүе дә катгый булды:

—Киләчәктә безнең уртак балабыз булу мине уйландырды. Безгә кушылырга кирәк. Өйләнешик! Син мине яратасың, мин дә синең өчен

жанымны фида кылырга әзер. Ул баланы ятим итмәячәкмен. Кушылыйк! Дөрес, тормышым әйбәт түгел әлегә, ызбам да туксан тәрәүле. Ләкин Ходай ярдәменнән ташламас—үз бәндәләре ич. Һөнәрем бар, дүрт саным төгәл, сәламәт, бу чүлмәк тә буш түгел,—диде Сафуан урта бармагы белән баш сөягенә кагылып.—Авылда калуны хуп күрмәсән, әйдә, чыгып китик! Егетләр әнә шахтага, йә булмаса Урал якларына эшкә китәләр. Без дә югалмабыз...

Сандра уйга калды. Соңгы вакытта анын да күзләре сагышланды, моңсуланды: көтелмәгән хәл уйларын чуалдырды, кайгыга салды аны. Тик Сандра бөгелеп төшмәде. Бөгелә торганнардан булса, Сафуан белән чуалудан тыелган булыр иде. Бу хәлгә анын үз карашы, үз фикере, үз мөнәсәбәте бар.

Уйларыннан арынырга теләгәндәй, Сандра күпереп торган аксыл чәчле түгәрәк башын чайкап алды да, сүз башлады:

—Жук, Сапуан жаным, жук! Мин Микулайга аерылырга чыкмадым. Мин анын закунный катыны. Дөрес, грехым бар анын каршында. Тик мин аны ташларга жыенмыйм». Жук, рәнжетмим! Ул минем ирем. Ә син, Сапуан бәгерем,—минем жаратканым. Без синең менән жаратышып жәшик, ә үләнешү турында бүтән сүз сүләмә, жәме? Бала жәтим булмас: анын жараткан атасы-анасы булыр. Бар алар. Инде грехым фаш булып, Микулай үзе мине эт итеп куып чыгарса... Ул чагында нәстә булса да уйларга булыр. Бергәләшеп уйларбыз, Сапуаным. Ишетәсенме?

—Ишетәм, барсын да ишетәм. Тик бел: алай-болай була калса, мин сине алып китәрмен, үземнеке итәрмен. Ышан миңа!

—Ышанам. Ышанмаган кая!.. Жаратканым—сүгәнемә дә ышанмагач, мина бу дөнжәдә жәшисе дә төгөл.

Алар тагын назлаштылар, иркәләштеләр. Бер-берсенә татлы сыенышып тордылар, уйлаштылар, сөйләштеләр. Аннары икесе дә, тынычлангандай, өйләренә кайтып киттеләр.

Ә Сандранын көмәне үсә торды. Хәзер инде үз авылына кайткач та авырткан сөяленә басучы юк. Гөргөри дәдәй белән Начтук түтәй исә туачак оныкларына—нишләптер алар Сандраларын малай таба дип уйлыйлар иде—исем дә эзли башладылар. Шунысы хак: ике авылнын берсендә дә Сандранын көмәне үз иреннән түгел, ә башка кешедән булуы турында башларына да китермиләр иде.

## IX

Әзер балга ияләшкән шөпшә кебек, Сафуан да бер татыган Сандраны тиз генә ташлый алмады. Төрле мөмкинлекләр, төрле тапкыр яки хәйләле юллар белән алар очраша тордылар, бер-берсенә тартылдылар, иркә сүзләр әйтештеләр, татлы сөештеләр. Микулайнын шалкан кебек ак усак агачыннан салган яна өенең һәр почмагы таныш иде хәзер Сафуанга. Оста куллар чүтлаган бүрәнәләр, кырып ясаган ишек һәм тәрәзә яңаклары, нарат такталарыннан кысып китергән гәрәбә кебек сары түшәм, сайгаклар, өр-яна өйдә исереп китәрлек хуш агач исе, тәрәзә һәм ишек башларында, яңакларында оста куллы керәшен хатыннары суккан һәм чиккән сөлге-бистәрләр, кашагалар, өйне икегә бүлгән төрле төстәге чаршаулар, тәрәзәләрдә ак кәтүк жебеннән бәйләгән нечкә челтәрләр... Сандра да бик уңган, булдыклы, тормыштан ямь табып яши торган хатын икән ләбаса.

Бер нәрсә күңеленә ошамый иде Сафуаннын—ул да булса, алъяпкыч белән каплаган «Тәре почмагы». Әйе, күңеле кабул итми иде анын әлеге хәлне, ләкин янында гүзәл Сандра булганда ул анын турыда онытa яки бу почмакка карамаска тырыша иде. Гыйш-гыйшрәт хозуры Сафуанны да, Сандраны да тәмам йота иде. Вакыт-вакыт аларнын үз язмышлары белән уйнау чигендә тормышларына куркыныч янаган тәвәккәллекләр ясаган көннәре дә булды...

Шулай беркөнне Микулай тагын Акташка, баш урманчы янына китте. Сандра кабат тиз генә алачыкка барып килде. Сафуан күз бәйләнгәч тә сөяркәсе янына йөгерде. Караңгы өйдә назлаша гына башлаганнар иде, капка төбендә арба шыгырдаганы ишетелде.

—И, Кодаем, Микулай бит бу! Куның калмаган ахры,—диде Сандра борчылып һәм ашыгып-кабаланып Сафуанны тизрәк чыгарып җибәрү ягын карады.

Микулай атын тугарып, абзарга кертеп маташкан җайлы бер мизгелдә Сафуан ишектән чыгып шылды да, өй артына яшеренде. Аннары, Микулай өенә кереп киткәч, киртә аша сикереп чыкты һәм сөяркәсенең ире белән күзгә-күз очрашмауга сөенә-сөенә, өенә кайтып китте.

* * *

Бу хәлдән соң Сафуан айнып киткән кебек булды. Караклыкта, бурлыкта эләгә язган кеше хәлендә иде ул. Кырын эш кырык елдан соң да беленә, диде Сандра да. Берсендә котылырсың, икенчесендә дә... Ләкин кайчан да булса барыбер тотылырсың. Тотылгач, соң булыр. Эш җәнҗалга китсә, бөтен авылга таралса, хурлыгын кая куярсың? Җир тишегенә кереп качарсыңмы? Качарсың, җир ярылса... Кинәт кенә ташып киткән дәртен, дөрләп кабынган ялкынын үз вакытында баса алмый ир хатыны кочагына ташланган абруйлы тимер остасы бер мәлне акылына килә башлады. Әйе, Сандраның гүзәллеге, аның карусызлыгы, Сафуанның үзенең исә артык хислелеге аны кинәт гыйшык дәрьясына алып ташлады—бусы бәхәссез. Бүген дә ул татлы кичерешләрдә яши бирә. Каенлы егетләре арасында әле беркемнең дә төшенә кермәгән, фәкать чиксез ымсындырып кына торган гүзәл Сандра-Саниянең игътибарын үзенә җәлеп итте, мәхәббәтен яулады, аның иң хозурлы назына иреште бит ул. Моның белән ничек горурланмыйсың да, моңа ничек сөенмисең? Сандра белән булган ләззәтле көннәрдән соң ул: «Хәзер инде үлсәм дә үкенмим»,—дигән иде. Мондый сүзне кеше бер дә юкка гына әйтми торгандыр.

Ләкин икенче яклап Сафуанның башында борчулы уйлар да тулып ята: бу сөю-сөешүләрнең ахыры ничек бетәр, хәерлегә булырмы? Очы бер булырга тиеш ич моның... Әнә бит, Сандра балабыз була, ди... Балабыз!..

Шундый борчулы уйлар белән корымлы алачыгында ялгыз башы эшләп ятканда, һич тартынусыз бусагада кабат Сандра пәйда булды. Йөзендә шатлыклы елмаю. Нигә елмаймасын, нигә шатланмасын ул? Үз кешесе, яратканы, сөйгәне янына килгән лә! Керү уңаеннан ук килеп Сафуанның муенына сарылды.

—Сагындым, тыным белән тартып алыр идем үзеңне. Гел сагынам,—диде ул, кайнар сулап.

Сандраның кулында тәүге килүеннән соң Сафуан ясап биргән сырлы-мырлы җәмки иде.

—Менә, җәмкием кәкерәйгән иде, шуны гына төзәтеп бир әле, Сапуан җаным,—дип төп-төзек җәмкине сөйгәненә сузды. Сафуан җәмкине алып карады да, Сандраның хәйләсеннән елмаеп, көлеп тезләренә куйды һәм, башын бер якка кырын салып, Сандрасына яратулы-аптырашлы караш ташлады.

—Үзеңне дә, мине дә гөнаһка батырып бетердең инде шушы матур елмаюларың, килешле кыланышларың белән,—диде ул, уйчанланып. Аннары, алай-болай кеше килеп керсә дип, җәмкине утлы күмергә куйды—кыза торсын, суккалап бирер, янәсе...

—Шулай шул, үзем дә бик уйланам, үзем дә бик борчылам. Шуңа килдем дә әле, әйтәсе сүзем бар...

—Сөйләп кара, гүзәлем, нинди сүз, нинди кинәш инде ул? Урманга менеп, ак каен ботагына асылынырга кушмыйсыңдыр бит?—дип шаяртты тимерче.

—Юк, сиңа аны эшләү кирәк түгел. Мин дә эленергә җыенмыйм әле,—диде Сандра бик җитди итеп.—Минем көмәндә синең балаң үсә. Мыңа шатланырга, мының белән гайрәтләнергә кирәк, Сапуан җаратканым. Тик син аны эчтән генә минеке дип җөр, беркемгә дә белгертми генә. Мина Кодай Микулай белән җәшәргә җазган, мин аның закунный катыны. Сина әйтерем шул: син дә катын ал, Сапуан җаным. Син үләнсәң, минем

жанга килеп җөрүдән туктарсын. Мин бөтенләй үк килмә димим. Сине ничек яратуымны беләсен, сине күрми яшәве миңа да җиңел түгел. Тик башка чарабыз юк безнен—үлән син...

Шулчак алачык ишегеннән ике авыл ир-аты килеп керде. Сандраның әйтергә теләгәне ярты сүздә бүленде. Сафуан җәмкине уттан алып сандалга салды да, суккалап-суытып Сандрага сузды. Сандра: «Рәкмәт!»—дигән булып, чыгып китте.

## X

Сандра Сафуанга төпле киңәш бирде. Ай-һай акыллы хатын икән! Мондыйны үз хатының итеп яшәргә дә начар булмас иде дә бит...

Әйе, дөрес әйтә Сандра: өйләнергә кирәк, «катын алырга.» һәм мыштым гына яши башларга. Юк, тынычлап түгел, мыштым гына, чөнки тынычлык булмас ахры, Сандра анын күңелендә мәңге яшәр сыман. Бала да тапса, яши дә яши инде ул аның күңел түрендә...

Сафуанның өйләнергә вакыты күптән житкән. Тик иске, җимерелеп килгән, тугыз тирәүле өйгә ничек килен алып кайтасың? Атасы сугышка киткәнче өй салырга җыенган булган да, өлгерә алмаган. Сафуанның исә өй салырга көче юк. Фәкыйрьлек, хәерчелек, ачлык-ялангачлык белән көн күргәндә яңа өй салу турында уйлыйсы да юк. Менә шуңа да өй житкерү һаман кичегә килә. Шулай ук өйләнү дә. Хәзер нишләргә? Өем иске дип, гомер буе өйләнми дә яши алмыйсың...

Сандраның чираттагы мәртәбә алачыкка Сафуанны күрергә килүендә Сафуан үзенең әлегә өйләнә алмау сәбәбен әйтте.

—Курыкма, жаратканым. Кемнен кулында—шунын авызында. Урманга Микулай кужа. Мин аңа әйтермен, сиңа бер жортлык агач бирер. Бөтен тимер коралларны бер тиенсезгә жасап бирде, ул бик жакшы мужик диярмен,—диде Сандра жиңел сулап, матур елмаеп.—Ә жорт салганчы катын ала тор. Жортынны безнен кебек катынын белән бергә салырсыз...

* * *

Озын-озакка сузмыйча, Сафуан, Сандра кебек үк чибәр һәм татлы булмаса да, эшкә уңган күрше кызы Гөлмәрфугага башкода кертте. Болай авылда житкән кызлар күп иде. Егетләрнең күбесе яу кырында башын салды, кызларга хужа сирәк чыга иде. Кызлар арасында, Сандра кебек үк булмаса да, асыллары да житәрлек. Тик асылларның да төрлесе була. «Дөнья тулы чибәр кызлар, кайдан чыга соң бу явыз хатыннар?»—дип әйтерлек булмасын. Әнә шул явызларга тарымас өчен Гөлмәрфугага башкода кертте дә инде Сафуан. Күз алдында үскән эшчән, күндәм, киң күңелле, телгә керә белми торган кыз ул Гөлмәрфуга. Башка егет-жилән белән йөргәне дә булмады бугай—үзен тыйнак тотты, азмады-тузмады. Һәрхәлдә, Сафуанга шулай тоелды.

Ай-ли, Гөлмәрфуга, бар суга!
Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсын да...

Анысы дөрес. Эшкә талымсыз Гөлмәрфуга суга көненә ике-өч барып кайта. Тик, күрше кызы булса да, барысы турында сөйләшергә генә туры килгәне булмады Сафуан белән Гөлмәрфугага. Сафуанның үзе кебек сазаган, кияүгә чыгып калу турында хыяллану гына түгел, инде төн йокыларын качырып, борчылып арыган кыз Сафуан кебек уңган-булган егеткә чыгу бәхетенә ирешүгә куанып бетә алмады. Кияү егетенең чатан булуы аның гамендә дә юк иде. Күршедә яшәгән Сафуанның ул житешсезлеген кыз күптән күргән, шулай булырга тиеш сыман тоела иде ана.

Коры гына никах ашы белән алар уртак тормыш башлап жибәрделәр. Табында күбрәк ярмалы ярка бәрәңге иде. Шөкер, бакчада жимертеп эшләгән Сафуанның бәрәңгесе уңа, күп иде. Ашка иртә бәрәңге, кич бәрәңге...

Хәзер кызларның мәһәре—
Бер подаука бәрәңге,

—дип жырлый торган еллар иде ул...

Яз житеп, карлар эрегәч, юмарт урман каравылчысы Микулай биргән диләнкедән Сафуан берничә авылдашы белән үгез жиккән арбаларга төяп урман чыгарды да, ашыкмый гына бура бурый башладылар.

Бу игелекле эштә күбрәк Сандра өлеше булуын бер Сафуан гына белә иде. Сафуанны бик яратканга Микулаеннан аңа урман бирдертте бит ул.

## XI

Жәйнең соңгы, ләкин әле кояшлы, жылы аенда уңган балта осталары Сафуанның бурасын бурап бетерделәр дә, өмә жыеп, бураны мүкләп-чутлап өеп тә куйдылар. Нәкъ шул көннәрдә Сандра малай тапты. Тагын берничә айдан Гөлмәрфуга кыз тапты. Озын гомерле, тыныч холыклы булсын дигән теләктән, аңа Даимә дип исем куштылар.

Колхозда күзгә эшләр тәмамлангач, авыр тормышта чиләнгән колхозчыларга сугыштан соң тәүге тапкыр ярыйсы гына икмәк бүлеп бирделәр. Бердәнбер тимер остасы, ару белмәс, ел әйләнәсенә корымлы алачыгыннан чыкмый тимер суккан Сафуанга икмәкне гади колхозчыларга караганда өч тапкырга арттырыбрак китерделәр. Яңа өй салып маташкан кешегә ул бик ярап куйды.

Сафуан белән Гөлмәрфуга көч-хәл белән яңа өй салып кергән елның икенчесендә, атна-ун көн генә авырып, сиксәнен тутырып килгән Минлезифа әби жан бирде. Якты дөнья белән хушлашырга ике-өч көн калгач, ялгыз карчык кемдер аркылы Гөлмәрфуганы чакыртып алды. Миңлезифа әби белән әллә ни аралашмаган, үткәндә-сүткәндә генә хәлен сорашып йөргән Гөлмәрфуга, башта ничектер гажәпсенсә дә, күңелендә нindидер шик белән барып керде үлеп яткан карчык янына. Берничә күрше карчыгы ясин укып утыралар иде. Гөлмәрфуганың килгәнен күргәч, Миңлезифа әби һич үләргә жыенмаган, авырып кына яткан кеше сыман, көч-хәл белән булса да торып утырды һәм:

—Кызыма аерым сүзем бар, корткалар, безне калдырып торыгыз әле,—дип эндәште. Карчыклар чыгып киткәч, ул яңадан ястыгына авып төште.

—Борчыдым инде үзенне, кызым,—диде ул авыр сулап.—Миңа бәхиллегенне биреп кит. Гаепле мин синең каршыңда...

—Нишләп гаепле, Минлезифа әби? Булмаганны... Минем каршымда синең бер гаебең дә юк. Бәхил, мәңге бәхил...

—Алай димә әле, кызым. Гөнаһлы мин, ярлыка зинһар өчен...

Һәм карчык Гөлмәрфугага Сафуанның өйләнгәнче Сандра-Сания белән очрашкалавы, анын үсеп килгән малаен Сафуаннан табуы турындагы кыйссаны житкерде.

—Каян беләсең син боларны, Минлезифа әби?—дип сорады Гөлмәрфуга.

—Беләм, кызым. Сания серләрен үзе сөйләп торды. Ә мин, гөнаһ шомлыгына каршы, хуплап яшәдем анын гыйшык-мыйшык турындагы саташуларын. Тик, кызым, зинһар өчен дип әйтәм, үзең дә сер итеп сакла боларны. Әйтмә беркемгә дә, гакыллы бул. Сафуанның да, балаларың да, Сания үзе дә, малае да белмәсеннәр. Гөнаһымны жуйдым, теге дөньяга тыныч күңел, саф иман белән китим дип әйтергә булдым, балам, кичер мине.

—Тыныч бул, Миңлезифа әби, борчылма. Рәхмәт әйткән сүзеңә, серенне саклармын. Бәхил, бәхил...

—Менә бусына рәхмәт, кызым, мең рәхмәт,—диде әби һәм хәлсез куллары белән озак кына Гөлмәрфуганың кулын тотып торды.

## XII

Шул көннән башлап Гөлмәрфуга эченә бикләнде. Юк, ир хакын хаклап яшәде ул, чөнки ир хакы—тәнре хакы. Үз вакытында ашатты, эчертте, юындырды-киендерде, артыннан карап калып эшкә озатты, «Кайттыңмы?»—дип каршы алды, ләкин ачылып китеп сөйләшүләрдән тыелып яшәде. Сандра белән буталганын башына да китермәгән иде ул. Авыл халкы да белмәгән иде күрәмсең, белсә, гайбәтләрен чәйнәми калмаслар иде. Булса да булыр икән! Менә ышан... Тыныч күлдә пәри була дип, бер дә юкка гына әйтмиләрдер шул!

Торып-торып уйланды ул бу турыда. Бер Сафуан белән Сандраны эченнән генә эт итеп орышты, бер Сафуанын яклап Сандраны гына әрләде, бер Сандраны жәлләп Сафуанны уттан алып суга салып сүкте...

Шулай да Гөлмәрфуга язмышына буйсынырга булды. Яшьлегендә кем ничек шаярмый да, кем кемне яратмый?! Сандра артык чибәр хатын шул, бигрәк тә килеп төшкән мәлне бик күп егет-җиләннең аңа кызыгып селәгәе акты. Ул турыда ачыктан-ачык әйткәннәрен дә ишеткәне булды Гөлмәрфуганың. Ә менә Сафуан белән гыйшык-мыйшык уйнаулары аның өчен һич көтелмәгән яңалык иде. Ләкин, нишләмәк кирәк? Булган—беткән, өстенә мүк үскән. Ахыры хәерле булсын! Сандра дип чапмый бит әле. Үз вакытында алачыгына китә, үз вакытында өйгә кайта...

## XIII

«Тын күлдә пәри була»... Ай-һай дөрес әйтә Гөлмәрфуга. Ләкин, таяк—ике башлы. Гөлмәрфуга үзе дә шул тын күл, үзе дә серле бер дөнья. Һәм аның сере җиде кат җир астына яшерелгән. Авылда бер җор телле, умартачы бөкре Фәтхетдин абзый үзенең бердәнбер кызы Гөлмәрфуганың бу сере турында башына да китерми әле, сизенсә, үз вакытында хатыны Бибисара гына азрак сизенде бугай.

Барысына да шул Бибисараның ике туганнан туганы Шакир малае Минзәки гаепле инде. Шакир үзе, мескен, сугышта югалып калды. Хатыны кыз чактан ук хаста иде, бердәнбер улы Минзәкине калдырып, үлеп китте. Шакир тагын өйләнергә җыенып йөрде-йөргән, тик өлгерә алмады—сугыш башланды. Шып-шыр өйдә ятим малай берүзе калды. Ашарына ашы, киярене киеме, ягарга утыны юк. Иң якын дигән туганы да Бибисара гына иде. Кинәш-табыш итешеп, унбер яшьлек малайны үзләренә сыендырырга булдылар. Бердәнбер кыз янына малай булу Бөкре Фәтхетдин абзый өчен дә начар түгел иде. Үгез җигеп урманнан утын ташу, кырдан салам төяп кайту, бәрәңге бакчасын сөрү, малларны карау, башка йорт эшләрен башкару тулысы белән Минзәки җилкәсенә төште. Ә җәй көннәрендә ул умартачының алыштыргысыз булышчысына әйләнде. Эшен эшләгәч, малайның тамагы тук, өсте бөтен—Фәтхи йортында иске-москы бетмәгән.

Колхозның умарталыгы бик зур түгел иде, булган балына да хуҗалар күп—дәүләткә дә, түрәләргә дә алып китәләр, умартачының үзенә калса шул чәйлек кенә кала иде. Шуна күрә, гомер буе житешсез, ачлы-туклы тормыштан шактый тәҗрибә туплаган Фәтхи абзый бәрәңгене булдыра алганча күп утырта иде: үзләренә дә, малларга да, орлыкка да житәрлек булсын, сатарга да калсын. Кырда нинди буш җир бар, шунда Фәтхи бәрәңгесе үсә иде. Жирне үгез белән сөрәләр, утыртканда да үгез. Ә эшкәртү— Бусы инде Минзәки белән Гөлмәрфуга өлешенә төшә. Тәпкеләргә, өяргә йөри-йөри ике үсмер хәлдән таеп бетәләр иде. Иртән иртүк тәпкеләр, ярты чиләк чи бәрәңге алып китеп баралар да, кичке якта гына кайтып төшәләр. Кырдагы коры-сарыны җыеп, учак дөрләтәләр, шуңа бәрәңге күмеп ашыйлар. Наратлы чишмәсенә төшеп су эчәләр.

Ләкин бу авыр эштә дә үсеп килгән кыз белән малай үзләренә кызык таба беләләр иде. Болай да Минзәкидән бераз олы Гөлмәрфугага, кызларга хас булганча, иртә ис керә башлады. Ерак кырда алардан башка беркем дә юк, өстә, кайдадыр күз күрмәгән җирдә, тургай гына берөзлексез

сайрый. Матур сайрый тургай, күнелләрне тибрәндерә, дәртләндерә, хыялландыра. Бераз эшлиләр дә, ызанга чыгып яшел чирәмгә яталар, ял итәләр, йә чишмә буена төшеп китәләр. Менә шундый ирекле минутларның берсендә Гөлмәрфуга Минзәкигә:

—Әйдә, үбешергә өйрәнәбез,—диде. Минзәки андый эшнең бик үк ярамаганын да белә, чөнки Фәтхи абзый ишетә калса малайның җиде кат тиресен салдыруы мөмкин. Ләкин Гөлмәрфуга монда өлкән кеше, Минзәки аны тыңламый булдыра алмый.

—Ә ничек?—диде ул, кыюсыз гына.

—Менә...

Гөлмәрфуга Минзәки янына килеп тезләнде һәм малайны үбәргә тотынды. Ләкин малай үбешә белми иде. «Менә син минемчә, минемчә ит»,—дип, кыз малайны өйрәтә башлады. Бераздан малай да ярыйсы гына үбешә башлады. Үбешә-үбешә алар чирәмгә авып төштеләр. Ике үсмер үбешүнең татлы нәрсә икәнлегенә, тәнгә рәхәтлек биргәненә, әллә ничек күнелне җилкендергәненә төшенделәр. Бигрәк тә Гөлмәрфуга ләззәтле-дәртле итеп үбешә иде. Аннары ул эндәшми-нитми Минзәкинең кулын алып, калкып, йомрыланып килгән күкрәгенә терәде.

—Син аны тот, сыйпа, миңа аннан бик рәхәт,—диде кыз. Малай кушканны эшләде.

Икенче көнне дә алар бәрәңге жирена килделәр, үзләренә билгеләнгән хәтле тәпкеләделәр, учак ягып бәрәңге пешереп ашадылар, чишмәгә төшеп су эчтеләр, ятып ял иттеләр, кабат үбешергә өйрәнделәр. Ләкин Гөлмәрфуганың бүген үбешеп кенә каласы килмәде, чөнки җитлегүгә таба барган кызның дәрте күәс кебек кабара бара, күңеле алгысый, ярсый башлаган иде.

—Әйдә, ир белән хатын булып уйныйбыз,—диде малайга. Күндәм малай карышмады, кызның һәр теләген үтәргә тиеш иде ул...

Олылар «уены» аларга тәмам ошап китте.

Тагын ике елдан артык уйнадылар алар бу уенны. Тик бу турыда беркем дә белмәде диярлек. Бибисара гына бер кышкы караңгы кичтә соң гына мунчага киткән Минзәки яныннан кызы Гөлмәрфуганың килеп чыкканын күреп алды. Ах, мәлгунь, бер сыйныфта укыган Рәхилә янына барам, дип чыгып киткән иде бит. Ә ул ятим малай белән мунча кәрә, имансыз...

Ләкин Бибисара тавыш-фәлән чыгармады. Котырынкы Фәтхинең мондый очракта нәрсә кыласын белгән хатыны авызына су капты.

Уналты яшендә Минзәкине ФЗОга алып киттеләр. Бибисара: «Котылдым!»—дип калды. Гөлмәрфуга кеше күрмәгәндә Минзәкинең муенына сарылып елады. Минзәки: «Кайткач өйләнешербез, Фәтхи абзый риза булмаса, качып китәрбез»,—дип юатты. Урал якларына китеп барган егеттән сирәк-мирәк хатлар килде. Соңыннан хатлар да тукталды...

Уеннан уймак чыга. Юк, бу очракта Минзәки белән Гөлмәрфуга уеныннан «уймак» чыкмады. Шуңа да Гөлмәрфугага сөенеп шөкерана кылып яшәргә кирәк иде. Һәм ул шөкерана кылып яшәде, бүген дә шөкерана итә. Минзәкиен үзе кебек юантык, яссы битле, имчәкле бәрәңге кебек зур борынлы бер малай ясап калдырган булса, Бөкре Фәтхи йортындагы тавыш яман булган булыр иде.

Гөлмәрфуганың бөтен шөлләгәне—Сафуан иде. Кызлык намусын санга сукмау, кызлык сафлыгын җую әнә шул тимерчегә кияүгә чыкканда исенә бик төште дә бит, тик гыйффәтлелек кызларда ике булмый шул. Мәгәр, Гөлмәрфуганың ул нәрсәсе ике генә түгел, егерме ике булса да кияүгә чыкканчы барысын да җуеп бетергән, саклап калалмаган булыр иде.

Бәхетенә, судан коры чыкты. Бикәчкә кергән кичне Фәтхи абзый ике «Бөгелмә малаен» алып кайтып куйды. Моның өстенә, аның бераз әче балы да бар иде. Мондый олы вакыйганы кияү-балакай белән бик шәпләп билгеләп үтәргә кирәклеген чамалый иде Фәтхи. Бибисарасы да аның бу гамәлен хуплады, чөнки хәтер төбендә хәтәр булу ихтималын кыз анасы сизенә иде. Элегерәк чуаш көмешкәсеннән аз-маз авыз иткәләгән Сафуанның

чын аракыны эчеп караганы булмады. Фәтхинең карлыккан тамак төбе белән:

—Әйдә, кияү, икегез дә пар килгәнсез, бәхетле тормыш насыйп итсен сезгә Ходай,—дип кыстый-кыстый эчерүе, шуның өстенә аракыны әче бал белән бутау тимерчене тәмам кешелектән чыгарды. Ул кайчан һәм ничек мәлҗерәп, оеп киткәнен, ничек чыбылдыкка кәләш янына кергәнен, төнлә кәләш белән эшләре ничек булганын белми дә калды. Гөлмәрфуганың тозагы тозак кына булмады. Бер хатынның хәйләсе кырык ирнең хәйләсеннән дә артык, дип бер дә юкка гына әйтми торганнардыр. Бикәч төнен үзенең «вакытсыз вакытына» туры китергән мут Гөлмәрфуга иртә белән айнып, уянып киткән Сафуанга кызыл таплы җәймәне күрсәтте. Янәсе, кара, син үз эшенне эшләдең, ә мин саф идем...

Бу—кияүгә чыкканчы ук каймагын алдырган кызларның борынгыдан килгән хәйләләренең берсе генә әле. Кызының үсмер чакта ук Минзәки белән шаяруын сизенгән хатын аны алдан ук кисәтеп куйды:

—Төбең тишек булса, әйт, чарасын күрергә кирәк. Үзем өйрәтермен,—диде ул. Гөлмәрфуга анасына аңлатып, сүз куертып тормады:

—Әйтәсенне әйт,—дип сүзен бетерде. Анага барысы да аңлашылды. «Уйладым, уйладым аны: теге тәкәрлек битле мыштым малай башына житкәндер, дип...»

Бибисара чарасын күрде: ул-бу булмагае дип, алдан ук кызын өйрәтеп куйды. Анын бу эштә тәҗрибәсе бар иде. Кыз чагында үзе дә шундый хәлгә тарыган иде. Бибисараның туган ягында шундый гадәт бар: яшьләр аулак өйләргә йөриләр, уйныйлар, җырлыйлар, бииләр. Аннары кызлар белән егетләр кочаклашып ятып йоклыйлар. Егет кочагында, тәнгә-тән, ботка-бот терәлеп йоклаган кызларның күбесе харап була. Бибисара да артык дәрткә бирелеп, үзен-үзе тота алмыйча, чит авылдан кунакка гына килгән бер әрсез алабайның корбаны булды. Югыйсә бик кәттә, чибәр иде ул вакытта Бибисара, Бөкре Фәтхигә генә чыга торган кыз түгел иде.

Әнә шулай төп башына утыртты Гөлмәрфуга зуп-зур авылда дан тоткан тимер остасын. Әлбәттә, анасы белән берлектә утыртты. Шуңа да Сафуанның Сандра белән булган шухыр-мухыр хәлләре өчен баш ватасы килмәде Гөлмәрфуганың. Исәп бергә бер иде. Әле белеп булмый, бәлки ул Гөлмәрфуга файдасына артып та китәр...

## XIV

Сандраның баласы үсә, ныгый торды. Тәпиләп киткән чорда тәтелди дә башлады. Шул бала белән бергә усак бүрәнәсеннән салган керәшен өенә ямь керде. Сандра үзе дә яратты баланы, игътибарының күп өлешен шуңа юнәлдерде. Ни гаҗәп, Микулай да, гадәтенчә, бик үк сиздермәсә дә, малайны ярата, «улым, улым»,—дип кенә эндәшә, анын белән уйный, азмы-күпме булса да йомшак, иркә сүзләр дә ычкындыра иде. Мона Сандра аеруча игътибар итте. Чыннан да, үземнеке дип уйламыйдыр бит ул? Ләкин вакыт-вакыт Микулай Сандрага да, балага да бөтенләй илтифатсыз була. Андый көннәрдә анын йөзе уйчан, кырыс, үзе исә беркемгә дә эндәшми, үз эченә бикләнеп яши.

Таллы Елгага бер кайтканда Гөргөри дәдәй белән Начтук түтәй тагын бер бала табу кирәклеге турында сүз башладылар. Бергә-бергә үсәрләр, малайга да туган, иптәш булыр. «Ике бала бер урынында, берсе җук урынында, дөнҗә хәлен, Кодай сакласын, белеп булмый»,—дигән булды алар. Бу сүзне өч яшен тутырып килгән малай да эләктереп алды: «Мина уйналга теле бәбәй киләк, ул минем энем була»,—диде. Күршеләр дә: «Тагын кайчан бәбәй алып кайтырга жыенасыз, озакламагыз инде, малаегыз үсеп бара»,—диештеләр. Бу сүзләрне Микулай да, Сандра да колак аша уздырып җибәрделәр. Ләкин Сандраның күнеленә кереп калды ул сүзләр, чөнки үзе дә тагын бала табу турында уйлана башлаган иде.

—Нишлибез сун, Микулай?—диде Сандра, икәү генә калгач.

—Нәрсә, «нишлибез?»—диде Микулай төксе генә.

—Бала турында, дим...

Микулай эндәшмәде, Сандрага сынап кына карап торды. Аннары:

—Адресын беләсең,—дип ярып салды. Сандра аптырап китте, ләкин югалып калмады, җинел сулап куйды. Бу инде ачыктан-ачык сөйләшү иде.

—Рөхсәт итәсең? Мин табарга риза,—диде ул күнеле күтәрелеп һәм ябык гәүдәле Микулаен кысып кочаклады.

—Ярар, ярар, бик нитмә...—диде Микулай. Аннары:

—Тулькы онытма, чабуны җыеп җөр, кеше сизәрлек булмасын. Кеше теленә бер керсәң...

—Юк, Микулай, кермәм, сак булырмын. Рәхмәт, җаным...

—И тагын... Тимерчедән башканы белмә! Беренче аңа җарылдың, бусын да тулькы анардан тап, әллә кемнәрдән түгел...

Сандра бер кызарды, бер агарды—дулкынлануының чиге булмады. Кара инде, Микулай барысын да белеп торган икән бит. Белеп торган, тик әйтмәгән, түзгән, эндәшмәгән. Тешен кысып түзгәндер инде, бичара. Менә язмыш нишләтә кешене! Башка чарасы юк шул...

Бу минутларда Сандра Микулайны чиксез кызганды да, шул ук вакытта аңа бик рәхмәтле дә иде. Әйе, ул үзенең бөтен кайгысын, хәсрәтен ут йоткан кебек эченә йоткан һәм тора-бара көчсезлеге, чарасызлыгы белән килешкән. Ә үзе барысы турында да белеп торган. «Тимерче» ди бит. Каян белгән дин син аны? Эчтә җыелып ятканның барысын да бәйнә-бәйнә әллә кайчан сөйләп бирәсе, гафу үтенәсе, шулай кирәк булды бит, дип акланасы калган икән. Ә болай Микулайны тагын да кимсетү, рәнҗетү кебек килеп чыкты. Ләкин шундый хәлдә дә ул күтәрелеп бәрелмәде, тыныч, сабыр булды. Сабырлык сары алтын шул. Ничек кенә булмасын, Микулай әйбәт кеше икән бит. Әнә бит ул ничек: барысын да Сандраның үз иркенә куйды. Тик каян белде икән соң ул беренче баласының атасы тимерче икәнен? Инде барысы да ачылган, сөйләшү дә ачыктан-ачык икән, Сандра бу турыда да Микулайның үзеннән белешергә булды.

—Минзипа карчык сүләп калдырды,—диде Микулай.—Сер итеп әйтәм, катының тимерче белән сүрәлә. Данканың атасы да ул бугай, үзе әйтте, диде. Гонаһымны теге дөнҗәгә алып китәсем килми, әйтеп калдырам, диде.

—Мин аның белән сүрәлмәдем, Микулай, бер-ике генә очраштык. Көмәнемә кадәм төшкәч тә туктадым мин,—дип акланды Сандра.

Микулай моңа ышандымы-юкмы, кабат сүз кузгатмады. Мәгәр Сандра өчен моның хәзер әһәмияте юк иде инде. Алда бит әле тагын бала табасы, ә моның өчен тагын Сафуан янына барасы, муенына сарыласы, кочасы-үбәсе, назлыйсы-назланасы бар. Сафуанда, фәкать Сафуанда гына бөтен өмет, бөтен ышаныч...

## XV

Җәйге матур көннәрнең берсендә Бөкре Фәтхи абзый йортына бик пөхтә киенгән, таза бер егет килеп керде. Фәтхи абзый күрше авылга барырга җыена—аны анда умарта карашырга чакырганнар иде. Килгән кунакка ул бик текәлеп карап торды, ләкин танымады.

—Нәрсә, Фәтхи абый, танымыйсынмы әллә үги малаеңны?—дип гөрелдәде кунак егет калын тавыш белән.

—Йа Хода, Минзәки, синме бу? Менә сиңа мә! Бибисара дим...

Алар кочаклашып күрешкән арада кайдандыр Бибисара апа да килеп чыкты. Кунакны өйгә алып кереп киттеләр, анда да шау-шу килделәр, сөйләштеләр-гөрләштеләр. Минзәки кардәшләренә алып кайткан бүләкләрен, күчтәнәчләрен тапшырды:

—Бусы, Фәтхи абый, сиңа... Бусы, Бибисара апа, сиңа... Бусы Гөлмәрфугага... Ә Гөлмәрфуга нигә күренми?—дип сорап куйды кунак.

—Гөлмәрфугабыз күрше Сафуанга чыкты бит, дүрт ел инде, кыз үстерә, бик матур кыз,—дип тезеп китте Бибисара.—Көненә йөз кереп чыга, әле синең кайтканны белми торгандыр, хәзер кереп житәр. Гөлмәрфуга, Гөлмәрфуга!

Күршедән: «Ишетәм, нәрсә бар?»—дигән аваз килде.

—Минзәки кайтты,—дип кычкырды Бибисара кызына. Шул сүзне ишетү белән Гөлмәрфуга атылып килеп тә керде һәм кин җилкәле, таза гәүдәле егетнең муенына асылынды.

—Күрер күнем бар икән,—дип пышылдады ул кунакның колагына. Әлбәттә, Фәтхи моны туганнарча кочаклашу дип аңлагандыр, әмма Бибисара өчен ул алай түгел иде.

Унбиш яшендә чыгып киткән үсмер танымаслык булып үзгәргән, тазарган, яшенә карата олыгая да төшкән кебек. Нәрсә генә дисәң дә, ун ел вакыт узган. Шул елларда Минзәки Магнитогорск шәһәрендәге бер заводта гади эшчедән мастер дәрәҗәсенә чаклы үскән, шунда фатир да алган. Хәзер исә өйләнергә исәбе. Бәлки, берәр кызны үзе белән алып китәр...

Ак күлмәк, кара костюм кигән таза егеттән күзләрен ала алмыйча карап торды Гөлмәрфуга. Аның өчен бик-бик көтелмәгән, ләкин сагынычлы очрашу иде бу.

Фәтхи абзый, ничек алай итте, шулай, күрше авылга китеп барды. Бибисара апа самавырына су, күмер тутырып, аны таш келәткә чыгарып куйды, чөнки көннәр кызу, коры тора, янгын чыгу куркынычы бар иде. Гөлмәрфуга белән Минзәки өйгә кереп киттеләр. Үсмер чагында ук ләззәтле көннәр бүләк иткән егетнең хәзер каршында басып торуы хыялга да сыймас хәл иде Гөлмәрфуга өчен. Аулак өйдә ул кабат Минзәки кочагына ташланды һәм анардан һич тартынмый, шашып-шашып үбә башлады. Бу турыда Минзәки дә күптән хыялланган, әлеге мизгелне сабырсызланып көткән иде—мөмкинлекне ычкындырмады, үбешү унаенда кайнар кулы белән Гөлмәрфуганың яртылаш ачык изүеннән йомшак, тулы күкрәкләренә кереп китте. Ун ел үтсә дә, бик сагынышканнар, бер-берсен ныклап тансыклаганнар иде алар.

Кичен бәйрәм өстәле әзерләнде. Фәтхи абзый суеп калдырган тавык инде пешеп табынга чыккан. Минзәки күчтәнәчләре дә өстәлдә. Фәтхи абзый да, кунак хакына эшен бүлеп, кайтып җиткән. Минзәки ак шешәнең сургычлы бөкесен ачканда гына «кияү-балакай» Сафуан да килеп керде. Каршында үзеннән таза, озын буйлы тимерчене күргәч, Минзәкинең күңеленә ниндидер шом төшеп, әллә ничек тәне чымырдап куйды. Ләкин Сафуанның елмаюлы йөзен күргәч, тынычланды. Өстәл әзерләшеп йөргән Гөлмәрфуга исә боларга әйләнеп тә карамады, янәсе ул үз эше белән мәшгуль, боларда гаме дә юк.

Ашап-эчеп, бераз сөйләшеп утыргач, Сафуан: «Эшем күп, комбайннарны, чапкычларны уракка әзерлибез, кабат алачыкка барып кайтасым бар»,—дип чыгып китте. Эштән арып кайткан Фәтхи абзый ярты чынаяк аракы эчүдән оеп китте, мендәргә ауды. Бибисара апа: «Минзәки, мунча әзер, бар, кереп чык»,—дип кунакны мунчага озатты. Гөлмәрфуга да, анасына өстәлне җыештырышты да, «Киттем»,—дип, чыгып шылды. Бибисара аны өенә чыгып китте дип уйлагандыр, ләкин кызы ашыгып-кабаланып Минзәки янына мунчага барып керде һәм мизгел эчендә чишенеп тә ташлады. Ун ел буена сагынып беткән, хыялында йөрткән, төшләрендә күреп саташкан, гомеренең иң сизгер, иң дәртле башлангычында ике ел вакытын бизәгән ир-егетнең кайтып төшүе аны тәмам алгысытып, җенләндереп җибәргән иде. Һәм ул саклануны да онытып, сөяркәсе янына ташланды.

Иң элек ул аны ун елдан соң анадан тума хәлендә күрергә теләде. Ундүрт, унбиш яшьләрендә аны анадан тума исәпсез күрде ул, мунчаны да аз кермәделәр бергә, табигать кочагында да Адәм белән Хава кыяфәтендә генә булгаладылар. Ә менә хәзер...

Кайнар пар җибәрелеп, яна каен себеркесе исе белән тулган кызу мунча ләүкәсендә әвен хәтле булып утырган Минзәки теге вакыттагы малай-шалай гына түгел икән. Беләкләренә, күкрәкләренә мускул өстенә мускул өелеп кунган, киң җилкәле, таза бәдәнле. Азгын Мәрфуга иң элек Минзәкинең ирлек горурлыгы белән кызыксынды. Бу инде элеккеге «шырпы» гына түгел, чын-чынлап шәп коралга әйләнгән иде. Шул сыйфатлары һәм тагын әллә кайсы яклары белән егет нәсел үгезенә охшап китте. Гөлмәрфуга

аңа карап, сокланып туялмады: «Менә ичмасам егет тә егет, астыннан җиде көн, җиде төн чыкмассың»...

Кинәт кенә кавышу хозурыннанниләр генә эшләп, нәрсәләр генә кылып, ничек кенә назланышып бетмәделәр алар шул сихри кичне Бөкре Фәтхинең сыер абзары артында, алмагачлар, чияләр ышыгында посып, исерек Мәрдәнша кебек кыйшаеп утырган иске, ярымкараңгы мунчасында. Һәм җае чыккан саен үсмер чакларын сагынып искә алдылар: «Хәтерлисеңме, теге җирдә тегеләй, бу җирдә болай иткән идек...» Бигрәк тә Гөлмәрфуга өчен татлы иде инде ул вакытларны кайтып-кайтып искә алулар...

Өч көн, өч төн кунак булды егет. Һәм шул өч тәүлектә һәр минутны бергә үткәрергә тырышты Гөлмәрфуга белән Минзәки. Өч көндә дә мунча ягылды.

Фәтхи абзаларына кайтып, мондый да абруйлы кунак булудан Минзәки канәгать иде. Бибисара апаның пешкән тавыклары да, коймагы да, өстәлгә чыккан аракылары да—аларын шайтан алсын! Ә менә Гөлмәрфуга белән икәүдән икәү калып үткәргән минутлар... Ах, аларны мәңге онытып булмас, мәңге истә калырлар ахры...

Минзәки, кайткан көннән башлап, Гөлмәрфуганы үзе белән китәргә кыстады.

—Мин бит сине алырга кайттым,—диде ул.—Синнән башка китмим...

—Ә элек нәрсә уйладың соң? Иртәрәк, һичъюгында дүрт ел элек кайтасы иден, мин Сафуанга чыкканчы. Ул чагында уйлап та тормаган булыр идем. Аннары... Без бит синең белән туганнар, ярыймы соң безгә өйләнешергә?

—Нишләп ярамасын? Ярыйбыз бит әле бер-беребезгә. Ун ел элек тә яраштык, хәзер дә... Теләк, дәрт: «Туганмы?»—дип сорамый...

—Юк, Минзәки, анысы аның башка хәл. Азгыннар без синең белән, артык азгыннар. Түшәктә ярашабыз да бит, яши башлагач бала табасы була. Ә ике якын туганнан туган балалар гарип булалар.

—Ну да!.. Безнең заводта үзбәкләр эшли. Алар, әнә, чтобы кәләш аталарына калымны күп түләмәс өчен, даже двоюродныйларны өйләндерәләр.

—Шуңа күрә аларның күбесенең баласы аңгыра, акыш-макыш була да. Минем дә ишеткәнем бар ул турыда.

—Ә бит без только троюродныйлар...

—Юк, Минзәки, болай ярамый, уйларга кирәк.

—Озак уйларга вакыт юк. Мин бит сине городка алып китәм, тирес оясында күпме яшәргә була?

—Юк, хәзер соң инде, безнең монда да тормыш җайланып килә.

—Җайлана ди! Колхозда тормышның беркайчан да яхшырасы юк. Аны гына беләбез инде. Идет беспощадная эксплуатация колхозного крестьянства,—дип урысча тезеп китте егет—Ул элек тә булган, бүген дә продолжается с такой же жестокостью. Без бит тоже сөйләшәбез заводта. Әзме-күпме башы эшләгән кешеләрнең барысы да авылдан чыгып кача, ибо тут концы можно отдать. Скажи менә, былтыр күпме зерно бирделәр трудоденьгә сезнең колхозда?

—Былтыр ярты кило бирделәр, ә элек ике-өч йөз граммнан артмый иде. Быел тагын да күбрәк бирәләр дип ишеттек, әгәр иген унса.

—Ну что это—ярты кило? Синең ничә трудодень бар инде?

—Мин бит фермада эшлим, сыер савам. Ел әйләнәсенә 350 хезмәт көне төшә инде.

—Так, стало быть... Давай посчитаем... Значит, синең ел буена баш күтәрми бил бөгеп эшләгәнеңә 175 килограмм хлеба. Да-а, не густо. Күп булса, өч капчык... Мәсхәрә бит бу! А на заводе мин бер айга ике-өч мәртәбә больше получаю, чем ты за весь год. Давай, поехали! Тут нечего думать...

—Юк, Минзәки, соң дим бит.

—Нишләп соң булсын? Әле син дә, мин дә по-настоящему яши генә башладык...

—Ә бала? Кызым үсә бит минем. Өч яшьтә. Аның анага иң мохтаҗ вакыты.

—Анысын үзенә карыйсың. Хочешь—возьмешь, не хочешь—оставишь. Можно на время калдырып торырга, соңыннан кайтып алырсың. Кайтып алмыйм дисәң, мин сина үзем бер куча бала ясап бирермен, чатың ачылган. Так что озак уйларга вакыт юк. Забираешь самые нужные документы, еще кое-что...

—Әтиләргә-әниләргә әйтми булмый бит инде...

—Ты что, с ума сошла? Может, алачыкка барып Сафуаннан да разрешение сорарсың?

Башта бик нык икеләнсә дә, соңыннан Минзәкигә ияреп качарга ниятләде Гөлмәрфуга.

—Мин Минзәкине юлга хәтле озата чыгам,—дигән булды ул анасына.

—Әни, мин дә балам синең белән,—дип көлмәгеннән тарткалады өч яшьлек тупырчык кебек матур кыз.

—Кызым, анда ерак, арырсың. Мин хәзер кайтып җитәм,—диде ул, кызын юаткан булып. Һәм аны кочып, үбеп алды.

Шушы китүдән Гөлмәрфуганың Каенлыда эзе дә булмады.

## XVI

Микулай белән ачыктан-ачык аңлашкач, сөйләшкәч, Сандра канатланып китте, рухланып, җанында ниндидер җиңеллек тоеп йөри башлады. Элек ул үзен караклыкта йөргән кеше сыман хис итә иде. «Кайчан минем Сафуанны жаратуым турында сизәрләр, кайчан Микулайга болар билгеле булыр да, ул нәрсә әйтер?» Ә хәзер бу авыр тойгылардан ул азат. Микулае ана тулы ирек куйды.

Соңгы вакытта ул Сафуанны сирәк күрә. Өйләнгәннән соң Сафуан үзе дә акылына килде, басылды бугай. Сандраның үзенә дә басылырга вакыт иде. Ләкин менә яңа хәл килеп туды бит әле. Сафуанны күреп сөйләшми булмый инде.

Ләкин бу юлы Сандра бик сак булырга тырышты, чөнки аңа хәзер үзен дә, Сафуанны да унайсыз хәлдә калдырырга ярамый, һич ярамый. Шуна күрә ул Сафуанның алачыгына соң гына, инде кич житкәндә генә, кеше-кара күргәнче кереп чыгарга булды.

Сафуан, бичара, һаман шул сандалы янында, һаман аның кулында олы чүкеч һәм ул тиргә батып эшли дә эшли.

Сандраны күрү белән тимерченең арыган йөзе яктырып китте.

—Син дөньяда бармыни әле, Сания җаным? Һич күренмисең, сагындырыпмы-сагындырасың,—диде ул монсу елмаеп.

—Мин дә бик сагынам да бит...—диде Сандра.—Мына килдем әле. Җомышым бар...

Сандра озын-озакка сузмыйча, сөйлисен сөйләп бирде. Сафуан Микулайның Сандра белән аның арасындагы хәлләрне белеп торуына чиктән тыш гаҗәпләнде. Тагын да гаҗәбе—Микулайның Сандрага тимерчедән икенче бала табарга рөхсәт итүе булды. Билгеле, бу—бөтен кәртне ачып салу дигән сүз түгел, сер сакланырга тиеш. Авыл хатыннары гайбәтне эләктереп кенә алырга тора. Аллам сакласын!

Сафуан сүз арасында Сандрасын күзәтте. Юк, ул элеккечә үк чибәр, сылу—һич үзгәрмәгән. Бала табу ана килеште генә бугай, ул тагын да сылурак кебек тоелды тимерчегә. Бер дә юкка гына әсәрләнмәде инде ул аның белән, мондый гүзәл җанны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың.

Сандра бала турындагы тәкъдимне Сафуан кабул итмәс, өйләнгәннән соң андый адымнан сакланыр, шикләнер, дип уйлаган иде. Ләкин Сандраның аңлатуы дәлилле, нигезле иде—Сафуан каршы килмәде.

Микулайның кабат Акташта куна калган кичендә Сафуан тегe еллардагыча дулкынланып, Сандраның утсыз өенә барып керде. Бу—тимерченең: «Эшем күп, комбайннарны, чапкычларны уракка әзерлибез»,—дип бабасы Фәтхи абзыйның аш өстәлен калдырып чыгып киткән киче иде. Юк, ул ялганламады. Башта чыннан да алачыгына төште, ясыйсы

әйберләрен ясап, эшен бетереп, әзерләп куйды. Шуннан соң гына Сандрасы янына китте. Сандра, һәрвакыттагыча, аны сагынып һәм ашкынып көтә иде. Яратышу, иркәләшү-назлашу гадәттәгедән һич тә ким булмады. Ләкин, мин өйләнгәч төн кыска булды дигәндәй, вакыт тиз үтте. Сафуан өенә соң гына кайтса да, Гөлмәрфуга атасы-анасы йортыннан чыкмаган иде әле. Моңа Сафуан сөенде генә, чөнки анардан: «Нигә озак тордың?»—дип сораучы булмады. Белсә икән ул бу вакытта хатынының ике арадагы читән буенда салынган мунчада Минзәкие белән рәхәтләр гизеп ятканын? Юк, ул аны башына да китермәде. Чишенде дә, ятып йоклады.

## XVII

Гөлмәрфуганың өч яшьлек нарасыен, бөтен авылга абруйлы тимерчесен, картаеп барган анасын һәм бөкре атасын ташлап сөяркәсе белән качуын ишеткән Каенлы Чишмә халкы ах итте. Авылда һичкайчан булган хәл түгел, акылга сыймаслык, кеше ышанмаслык, ят, сәер эш иде бу. Бигрәк тә Сафуан моны авыр кичерде, хурланды, кимсенде, хәтта чигәсендәге чәчләренә чаклы чалланып чыкты. Шулай да үзен кулга алды. Иң элек сабыена үзенен анасын алыштырырдай кеше кирәк иде. Моның өчен анын каршына һич кичекмәстән өйләнү мәсьәләсе килеп басты. Сандра турында да уйлап карады, ләкин анын Микулаен кая куясын?

Нәкъ шуны сизенгәндәй, бер иртәне алачыкка урман каравылчысы үзе килеп керде. Элек аның беркайчан да алачыкка юлы төшкәне булмады. Ә бүген... Кул бирмәде, керәшеннәрчә: «Арулармысез!»—димәде. Керүгә сүз башлады, кеше-фәлән килеп кергәнче әйтәсемне әйтеп бетерим, дип уйлады бугай.

—Синең хальне ишеттем. Но Сандрайга ырасчут тотма! Ул акмак катынның синен белән күзе-башы әйләнгән. Андый ырасчутың булса, плохо будет. Онытма, миндә ыружье бар...

Тимерче курыкмады да, каушамады да, сөяркәсенең ире сөйләгәнне тыныч кына тынлап бетерде. Һәм шулай ук тыныч җавап бирде:

—Мин дә яхшы беләм синең хәлне, Микулай. Ләкин борчылма, мин Сандраңа исәп тотмыйм, синен хәләл өлешеңә керергә уемда да юк. Яшермим: булганы булды, син аны үзең дә беләсең. Инде моннан соң... Тыныч яшәгез! Ә мин үземә табармын...

Урман каравылчысы ничек тиз килеп керде, шулай чыгып та китте. «Ару бул!»—димәде, сөйләштек-аңлаштык димәде.

Шулай да, Сафуан Микулайның бу керер чыгуыннан тынгысызланып калды. Нигә кирәк булды урман каравылчысына мылтык белән янарга? Сафуан аннан курыкмый ич. Яхшылап аңлашу аларның икесе өчен дә кулай иде, югыйсә. Ләкин Микулайны да аңларга кирәк. Ул Сандрасын югалтудан шөлләде булса кирәк. Язмыш тарафыннан кимсетелгән, кыерсытылган мескеннең берләнбер якын кешесе, берләнбер өмете, ышанычы—Сандра. Ул да ычкынса, Микулайның бу дөньяда яшәвенен мәгънәсе дә калмый. Ә Сандра—аныкы, бөтен гөнаһлары—«җазыклары» белән аныкы. Алачыкка килеп дөрес эшләде урманчы, үзенең холкын күрсәтте. Сугышчан характер! Утны-суны кичкән кеше характеры...

Ир—хатынсыз, үрдәк—сусыз тора алмый. Берничә көннән Сафуан кызына яңа әни, үзенә икенче хатын алып кайтты. Бу—Сафуанның үзе белән бер сыйныфта мәктәптә укыган, шулай ук сазап, кияүгә чыгу өмете өзелеп барган Мөршидә иде. Колхоз эшенең кайсына гына тотынмасын, җимертеп эшли торган, беләкләре, йөзе кояшта янып, кызарып беткән унган авыл кызы иде ул. Гәүдәгә дә, төскә-биткә дә Гөлмәрфугадан калышырлык түгел, ә бәлки күркәмрәк тә булгандыр. Йомшак, ихлас күңелле, сабыр холыклы кыз беренче очрашуда ук өч яшьлек Даимәне коча-коча, сөя-сөя елап алды, аңа иркә сүзләр әйтте. Шул очрашуда ук бәләкәй кыз аңа чытырдап ябышты, янындан китмәде, өсте-өстенә «Әни, әни» дип эндәште. Аларның шулай матур чөкердәшүен тынлап торган Сафуанның да күңеле тулып китте, берсенә дә күрсәтмичә генә күзләрен сөртеп-сөртеп

алды. Һәм эченнән генә: «Үз гөнаһларымның җимешен татыйм инде мин, үз гөнаһларымның»,—дип уйлады.

Тагын ике-өч көннән Сандра, алачыкка килеп, үзенен авырга калу сөенечен алды...

Вакыйгалар берсе артыннан икенчесен куа киттеләр. Авылда: «Керәшеннәр китәләр икән»,—дигән хәбәр таралды. Моны алачыкка килгән кешеләр Сафуанга да яңалык итеп сөйләп калдырдылар. Ә аның йөрәккәйләре өзелеп төшә язды.

Чынында исә, Микулайны Акташка лесничий итеп күчергәннәр икән. Тенкәсенә тигән Каенлы Чишмәдән тизрәк китүне кулай күргәндер Микулай, икенчеме-өченчеме көнне үк, бар булган өй җиһазларын ике арбага төяп, Сандрасы белән Данкасын утыртып, китеп тә барды.

Сандраның таң атар-атмас алачык янына килеп, ишек ярыгыннан эчкә ташлаган хатын Сафуан укыганда, алар Акташ юлына чыкканнар иде инде. «Сафуан бәгърем!»—дип башланган иде бу хат. Сафуаннан отып калган «бәгърем» сүзе яшь керәшен хатынына да бик ошый иде, шуңа ул сөяркәсенен ин иркә, иң нечкә хисле сүзен кулланмый булдыра алмады. «Сапуан, бәгърем! Мына айрылышабыз да. Сине уйлап, сине күрәлмәуемә офтанып җөрәккәйләрем өзгәләнә. Бигерәк тә жараттым шул сине, Сапуан жаным! Бүтәнне беркайчан да шолай жаным-тәнем белән жарата алмам, көнелемдә син генә булырсың инде гүмергә. Булдыра алсаң, Акташка килергә тырыш, мин сине сагынып көтәрмен. Онытма, минем корсагымда синең тагын бер сабыең жанланды.

Сапуан, жаным! Син минем жыруларымны жаратадыр иең. Булары соңгы жыруларым булсын.

Сахраларга чыгып жөрсәм дә мин
Жал булмыйдыр жанган жөрәккә;
Әкрен генә тирән уйга чумам,
Башым куеп жалгыз тирәккә.
Сары ла чәчәк ата көнбагыш,
Синсез лә күнелем тулы гел сагыш.

Син беренче булып жафрак жардың
Жырларымда, минем күнелемдә;
Син бердәнбер чәчәк аттың
Гөлләр төсле үрелеп жөрәгемдә.
Сары ла чәчәк ата көнбагыш,
Синсез лә күнелем тулы гел сагыш...

Хуш, ару бул, Сапуан бәгерем! Жаза алмыйм, күзләрем жәшләнә...».

Сафуанның да күзләре яшьләнде, тик аларны беркем дә күрмәде—алачыкта ул үзе генә иде.

## XIX

Көзгә таба Каенлы Чишмәгә генә түгел, ә бәлки бөтен тирә-якка җирле халык өчен тиңе булмаган яңа хәбәр таралды: «Нефть, кара алтын тапканнар!» Озак та үтмәде, Миңлезифа карчыкның тәрәзәләре кабык белән каплаган иске ызбасын бораулау конторасы иттеләр: аралыкны, сәкене сүтеп ташладылар да, өстәлләр, урындыклар, хәтта бер шкаф та кертеп урнаштырдылар. Ләкин, бораулау конторасы өчен бу ызба гына җитмәде. Җитәкчеләр Акташка Микулайны эзләп киттеләр: «Йортынны безгә сат!» Микулайга шул гына кирәк иде. Сүтеп, Акташка күчерергә дип уйлап тора иде йортын, бәхете бар икән, һич уйламаган зур бәягә сатып та калдырды ул аны. Кулыннан килмәгән эш юк, уйламаганда-нитмәгәндә кулга кергән бу акчага берне түгел, ике йорт та җиткерер әле ул Акташта.

Яңа хәлләр Каенлы Чишмәнең дә язмышын төбе-тамыры белән үзгәртте. Мәнге ярлы колхозның җирләрен алып, кырыкмаса-кырык төрле йортлар, биналар, гаражлар, цехлар төзи башладылар. Колхозчыларга да

төшемле, акчалы эш житәрлек булды. Иртәгәсе көне өчен кайгырып, яныпкөеп яшәгән авыл крәстиәннәре өчен яңа тормыш башланды, алар жинел сулап куйдылар.

Озын буйлы, таза гәүдәле Сафуан, Тирәкле инеше буендагы алачыгын ташлап, буровойга китеп барды. Үсмер чактан ук язмышын шушы алачык белән бәйләде бит ул. Шушы алачыкта эшкә өйрәнде, осталык туплады. Шушы алачыкта тәүге тапкыр сөю хисенә бирелде, сөю хозурын татыды: Сандра-Санияне кочып сөйде, аның белән күп мәртәбәләр очрашты, аның аяз күк кебек зәңгәр күзләре, алсу-ак көләч йөзе, пешкән чия кебек карасу-кызыл ираннәре, моңлы тавышы белән сихерләнде.

—Рәхмәт, алачыгым, рәхмәт сиңа, тик гаепләп калма инде, гафу ит,—диде Сафуан ишектән чыккач һәм бер якка кыйшайган, корымга баткан алачыгына баш иде. Бу мизгелдә Алып батыр кебек таза, мәһабәт буйлы ир-егетнең күзләреннән кайнар яшь бөртекләре тәгәрәп төште...

## Икенче кисәк

### I

Дөньяны шаулатты бу нефть, кара алтын дигән галәмәт. Элек тыптын яткан урман-кырларда, текә тау итәкләрендә, елга буйларында хәзер гөрләп буровойлар эшли, алар бораулап киткән коескважиналардан ургып-ургып нефть чыга, ә ул очсыз-кырыйсыз торбалар аша еракларга агып китә.

Юк, шаулатып кына да калмады нефть дөньяны. Күрә торып үзгәртте ул ярлы авыл халкы тормышын. Кичәге колхозчылар ашкынып буровойларга, нефть чыгарырга, төзелешкә киттеләр. Салам түбәле татар авыллары янында матур-матур яңа торак йортлар, оешмалар, цехлар, автобазалар калыкты. Иң мөһиме—кеше дигәнең тырыш хезмәтенә күрә, ниһаять, акчасын да алу бәхетенә иреште. Шулай икән, аның шәхси тормышында да унайга үзгәреш китте.

Ул гына да түгел, тормышның шушы өметле яклары халыкны яктылыкка тартып чыгарган кебек булды. Адәм баласы инде башка кимәлләрдә уйлана, фикер йөртә, гәп, фәлсәфә кора.

Әнә, Микулайны гына карагыз: үзе урманын ташламаса да, житкән улы Данканы нефть институтына укырга жибәрде. Ә бит үз вакытында ул Данканы үзе кебек үк урманчы булыр дип уйлый иде. Әйе, улын югары белемле урманчы итәргә иде аның исәбе. Күрә—дөньялар үзгәреп килә. Урман, урман... Аның белән хәзер исәпләшмиләр дә. Буровойга урын кирәк, нефть үткәргеч сузарга трасса кирәк диләр дә, гасырлар буе тын гына үсеп, күккә ашкан нарат, чыршы, каен, имән, юкә урманнарын дөбер-шатыр актарып, кисеп-таптап, яндырып китәләр. Урманнардагы барлык жәнлекне, кош-кортны пыран-заран китереп, атып-куркытып бетерделәр. Элек кеше аягы да басмаган чәчәкле аланнарны кара мазутка батырдылар. Нефть кенә байлыкмыни? Гомер-гомергә кешене жылыткан да, ашаткан-эчерткән дә, киендергән дә, сөендергән дә урман байлык түгелмени?.. Кара мазут хәзер көмеш кебек сулы урман инешләре белән агып елгаларга төшә. Бер байлыкны алабыз дип, икенче байлыкны харап итә бугай бу комсыз кешеләр...

Әле өченче ел гына ике олы урманны кушу ниятеннән, Коры елга артындагы өч гектар буш мәйданга каен үсентеләре утыртканнар иде. Яздан алып көзгә чаклы тырышып эшләде питомниктагы хатыннар. Жәй корырак килде, үсентеләр һәлак булмасыннар дип күпме су ташыдылар. Шахмат тактасындагы фигуралар кебек тигез итеп, әйбәтләп утыртканнар иде. Үсеп, көчәеп, канат жәеп жибәргәч, шуннан да матуррак каен урманы булмас, урманга килгән һәр кеше сокланып туя алмас, дип хыялланганнар иде. Ә күптән түгел... Йөрәк ярасы белән искә ала аны Микулай да, Сандра да,

питомникта эшләгән башка хатыннар да. Тамыр алган шул яшь үсентеләр мәйданын аркылыга ярып, нефтьүткәргеч төзүче жансызлар киң һәм тирән чокыр-траншея казып чыкканнар...

Гел үз теләгенә каршы җибәрде Микулай Данканы. Җибәрмәс тә иде, дөнья үзгәрә. Бөтенләй үзгәрә. Атасы белән бәләкәйдән үк урман, аның мәнфәгатьләрен кайгыртып үскән, аны чиксез яраткан сары башлы малай үзе дә башта урманчы булу хыялы белән яши иде. Ләкин анасы һәм атасы белән озак уйлашканнан соң ул, әнә, бүгенге тормышка кулайрак белгечлекне сайларга булды.

## II

Институтны тәмамлап кайткан Данилны эшкә Аккүл нефтьчеләр бистәсенә җибәрделәр. Зур калалар кебек шаулап тормаса да, Аккүл күнеленә ошады егетнең. Бер, ике, өч катлы йортлар, нефть идарәсе урнашкан олы бина, культура йорты, кинотеатр, төрледән-төрле башка биналары, торак йортлары белән тигез булып сузылган урамнар. Тротуар-урамнарда, мәйданнарда асфальт. Һәр җирдә яшеллек. Исеменә җисеме дигәндәй, бистәдән түбәнрәк, иске авылның көньягында сузаеп искиткеч зур күл җәйрәп ята. Бистәсе бер хәл, шушы күлне бик яратты Данил. Әллә көнчыгыштан биек таулар ышыгында булгангамы, әллә тирә-юне су өстенә авып, ишелеп төшәрдәй булып үскән карт тирәкләр, ак кәүсәле, куе яфраклы каеннар, төрледән-төрле куаклар һәм тыныч, җилсез көндә дә кыштырдашкан камыш белән уратып алынгангамы, бирегә җил дә үтеп керми һәм шуна да бу күл өсте һәрвакыт тыныч, көзге кебек тигез һәм якты. Су өстенең тигезлеген сирәк-мирәк йөзеп үткән кыр үрдәкләре дә, авыл казлары гына бозып куялар.

Мәһабәт тирәкләр һәм каен аллеясы астында күл буйлап тар гына сукмак сузылып ята. Әлеге тирәк һәм каен ботаклары сукмак өстендә дугаланып килгән мәгарә гөмбәзен хәтерләтә. Рәхәтләнеп бер саф һава сулыйм, җаныма тынычлык табыйм, тәнемә сихәт алыйм дигән бистә кешеләре шушы күл буена чыга, тирәкләр ышыгында сукмакта йөри, уйланамонлана, таныш-белешләрен очрата, сүз-фикер алыша. Бигрәк тә кичке якта, эңгер төшкән чакта күбрәк очрый халык су буенда. Яна бистәнең әлегә паркы да, сквер-бакчасы да юк, халыкның ял урыны әнә шул бердәнбер ыгы-зыгысыз почмак—көндезме, кичме, әллә төнләме булуына карамастан, өсте көзге кебек ялтырап торган ак күл буе иде.

Еш булмаса да, тулай торактагы бүлмәдәше Тимеркәй белән Данил да күл буйларын әйләнеп кайткалыйлар. Эш—эш инде, анысы үзенә бер аерым дөнья. Тимеркәй буровойда, гади бораулаучы. Ә Данилны промыселга мастер итеп алдылар. Эше дә, шартлары да, кешеләр дә яна әле аның өчен. Барысына да төшенәсе, өйрәнәсе, барысының да җаен аласы бар.

Эштән соң егетләрнең дүрт яклары кыйбла—кая барырга теләсәләр, шунда чыгып китәләр. Күбрәк кино карыйлар. Кайсы кичне культура йорты янындагы танцы мәйданына да сугылалар. Ни дисәң дә, яшь чак, гайрәтле чак, кызлар күзли торган чаклары бит аларның. Ә кызлар... һи-и, алар кайда гына юк! Танцы мәйданында да, күл буенда да, урамда да очратырга буладыр җанын теләгәннәрен. Тик Данил өчен биредә андый кызның очраганы булмады әле. Гомумән, кызлар дигәндә Данилның беркайчан да онытылып китәрлекләре белән бәйләнешкә кергәне юк. Институтта бергә укыган кызлардан беренче елда ук гайрәте чикте аның. Ата-ана канаты астыннан чыгып күз унынннан ычкынган, ирекә ташланган, күзе-башы тонган бу чәчбиләрнең кыланмаганы калмады: хәмерне дә чөмерделәр, тәмәкене дә пыскыттылар, итәк асларын да җилләттеләр. Хәтта уйнаштан бала тапканнары да булды. Һәм Данилга югары уку йортында укыган барлык хатын-кыз тотнаксыз, әхлаксыз кебек тоелды.

Ләкин кызлардан, гомумән, хатын-кыздан башка да яшәп булмый. Данил да бер тыйнак, әдәпле-инсафлы кыз турында хыяллана да бит... Насыйбы язган микән соң?..

* * *

...Җылы, йомшак, саф һавалы бер кичтә Данил белән Тимеркәй тагын күл буена төштеләр. Үз җайлары белән, һич ашыкмый, сөйләшә-сөйләшә тар сукмактан үтеп барганда, каршыларына әлегә кадәр алар белмәгән-күрмәгән, аларга һич таныш булмаган, бүгенгә чаклы бистәдә күренмәгән бер кыз килеп чыкты. Ул да ашыкмый, уйланып кына атлап килә. Түгәрәк ачык йөзле, дөнья чибәрләрендә дә сирәк була торган төз, сылу гәүдәле. Аяклары да коеп куйган кебек төз, матур. Конгырт-кара чәчен пөхтә итеп икегә аерып тараган да, калын толымнарын аркасына ташлаган. Өстендә исә гәүдәсенә сыланып торган бик килешле, затлы тукымадан теккән аксыл күлмәк, аягында биек үкчәле ак туфли. Гәүдәсен туры тотып, ышанычлы атлап килә кыз. Уртача буйлы гына булса да, килеш-килбәте белән һәркемне таң калдырырлык бу фәрештә егетләрнең каршына килеп чыккач та, алар бу могҗизадан дөньяларын онытып, телсез-өнсез калдылар.

Кыз алар яныннан һава да селкетми тыныч, күбәләктәй җинел талпынып, төз басып, һичбер тавыш-тынсыз үтеп тә китте. Әйтерсең лә егетләрнең барлыгын да белмәде. Сукмакта аның искиткеч тәмле ислемай исе генә калды.

—Менә сиңа мә-ә,—дип пышылдады Тимеркәй.—Каян килеп чыкты соң әле бу асыл кош? Әлегә кадәр күренми иде түгелме соң? Әл-ләл-лә...

—Юк, күренгәне булмады бугай шул.

—Әйдә, борылыйк, Данил, артыннан барыйк,—диде Тимеркәй, сабырсызланып. Данил талпынып куйды, кыз киткән якка борылып карады. Кыз, шул ук төз адымнар белән, алардан шактый гына ераклашырга өлгергән иде.

—Тукта, Тимеркәй, ашыкма! Болай бөтен эшне бозып ташлавыбыз бар. Сабырлык—сары алтын. Бала-чага уены булмасын. Бу кыз андый-мондый гына түгел.

—Соң, китә бит...

—Китә, дип... Инде бер күргәнбез икән, тагын очратмый калмабыз әле. Монда, бистәдә бит ул.

Шулай диде Данил. Диде диюен, тик үзенең дә эченә ут капканын иптәшенә белгертмәде.

Икенче көнне эштән кайткач, Данил белән Тимеркәй ашханәгә кереп бераз капкаладылар да, аска, күл буена төшеп киттеләр. Икесенең дә башында бер уй: кичәге кызны очрата алмаслармы күл буендагы сукмакта? Төшәрме бирегә? Төшсә, бу юлы да телсез калырга ярамас, ничек тә булса сүз кушу, сөйләшеп алу әмәлен табарга кирәк булыр. Һәм сорашырга: кем син, каян, кайсы төбәктән, кайсы елга аръягыннан килеп чыктың? Озакка килденме, әллә кунакка гынамы? Тормыш бит, андый очракларның да исәбе юк. Тик килгән-килгән бик озакка килсен, кунакка гына булмасын иде...

Эштә көн буе Данилның күз алдыннан китмәгән иде фәрештә кебек ак, матур йөзле, аксыл күлмәкле сылу кыз. Әллә ничә кат аның йөзен, күзләрен бар нечкәлекләре, бар гүзәллекләре белән исенә төшерергә тырышып карады, тик хәтерли генә алмады. Бик тиз үтеп киткән иде шул ул алар яныннан. Чыннан да, нинди төстә иде соң әле аның күзләре: конгыртмы, зәңгәрсумы, әллә башка төстәме? Ләкин нинди генә булмасын, матур һәм... монсу иде алар. Әйе, күзләренә генә түгел, йөзенә дә чыккан иде аның монсулыгы, уйчанлыгы. Нигә шундый икән ул?

Алар тирәк һәм каен ботаклары астында озак йөрделәр. Күлнең теге башына да бардылар, бу башына да килделәр, тагын әйләнделәр. Тик таныш кызны гына очрата алмадылар. Суга чумган кебек юк булды ул.

—Менә, әйттем бит мин сиңа, артыннан барыйк дип. Киткәндер инде. Ничә тиенемә кирәк аңа синең Аккүлең? Бистә, имеш. Олы-олы калаларда, йә булмаса зәңгәр диңгез буенда яшиләр андый матурлар, синең бака күлең буенда түгел,—дип мыгырданып кайтты Тимеркәй юл буе Данилның болай да кисәү булып көйрәгән йөрәген яндырып.

Аннан соңгы көнне дә очрата алмый, сөмсерләрен коеп, бер-берсенә эндәшмичә кайтып керделәр алар тулай торакка. Соң иде инде. Чишенделәр дә, урынга аудылар.

Инде йокыга гына китәм дигәндә, Данилга Тимеркәйнең тоныкы тавышы ишетелде:

—Юк, ул бик акыллы. Матур, ләкин горур. Югарыдан, Асылъяр кебек морзалар нәселеннән. Аксөяк! Минем ишегә карыймы соң ул? Тот капчыгынны, Тимеркәй! Үсәсең бар әле, буровойда эшләп чабатаңны алыштырасың, өстенә бер рәтле кием алып киясең, аннан буровоенны ташлап укыйсың, кеше буласың бар... Әнә, инженерга бара ул. Ишетәсеңме, инженер галиҗәнаплары? Буй-сының үзендә, затың бүтән, сүзгә дә оста, мәкальләр дә, әйтемнәр белән генә сиптерәсең. Ычкындырма син моны, малай! Алай-болай кабат очрый калса, сразы бар янына, оялып торма! Валлаһи! Тимеркәй кушты, ул минем дустым диген. Күктән төшкән, Тәңредән ингән бүләк бит бу, Данил малай...

—Йә инде, юкны сөйләмә, Тимеркәй,—диде Данил, бүлмәдәшенең күнеленә каты кагылмый гына. Әмма серле кызны күрәсе килү теләге тагын да арткан сыман тоелды.

### III

Тимеркәй буровойга кичке вахтага йөри башлады. Ул шулай эшкә—йә иртә таңнан, йә кичке якта, йә төн уртасында чыгып китә. Данилга, бүлмәдә үзе генә калгач, ямансу булып китә.

Бүген ул эштән соң күл буена төшмәскә, үз жанын үзе үртәмәскә, булмастай хыяллар белән җенләнмәскә уйлаган иде: «Ичмасам бер рәхәтләнеп кино карап кайтыйм...»

Барып җитеп билет алганчы кино инде башланган иде. Данил, тамашачылар арасыннан капшанып, бер урынга барып утырды. Тик тынычлана алмады. Үзе кино карый, ә үзенең күңеле күл буенда: ул төшкәндер инде, бер ялгызы йөри торгандыр... Әй, бетмәс лә бу кино, иртәгә дә, аннан соң да була бит әле ул.

Күңелне сизә диләр. Данилныкы да сизенде ул көнне. Кинотеатрдан чыкты да, еш-еш атлап күл ягына китте.

Әмма төшеп җитмәде, каен аллеясында ана каршы ике кеше килеп чыкты. Берсе ул иде—Данил аны шунда ук танып алды, гәрчә бүген аның өстендәге киеме дә гадирәк, аягында да биек үкчәле туфлиләр түгел, ә җинел чүәкләр генә. Икенчесе—какча гәүдәле, озын буйлы, ябык йөзле, таякка таянган, бераз аксый төшеп атлаучы ир кеше иде. Чәчләре сирәк, чигәләренә бәс кунган—яшь түгел инде, олыгаеп килә. Кеме ул аның: атасымы, олы туганымы, әллә?..

Данилның үзеннән-үзе адымнары сагаеп калды. Алар әкрен генә атлап узып барганда, ул кызның күзләренә карады, аларның төсенә игътибар итте. Зәңгәр, карасу-зәңгәр икән аның күзләре, болытлы көндәге Идел суы кебек карасу. Һәм моңсу, кайгылы бу күзләр. Аларда әйтеп тә, сөйләп тә бетергесез яра, әрнү бар сыман.

Данилның шатлыгы эченә сыймады: «Ул китмәгән, ул бирелә. Ә Тимеркәй киткәндер инде, дип пошына...»

Моннан соң да Данил күл буена өч-дүрт төште, кызны теге ир-ат белән дә, ялгызын гына да күрә, очрата торды, ә кыз аны гүя белми дә, белергә дә теләми—күзен дә сирпеп карамады.

Танышу-белешү кинәт кенә, һич уйламаганда, ничарадан бичара кебегрәк килеп чыкты.

Данилның күл буена бер төшүендә каенлы сукмакта кешеләр җыелышкан иде. Шаулашалар, ыгы-зыгы киләләр. «Ниткән хәл бу?»—дип, Данил да аларга якын килде. Караса, җирдә озын буйлы, какча гәүдәле, сирәк чәчле кеше ята. Төсе киткән, күзләре йомык, үзе ыңгыраша да кебек. Данил аны шунда ук таныды, чөнки ул кешене күтәрмәкче булып азапланган кыз да шунда иде. Данил хәлгә тиз төшенде. Кемдер: «Ашыгыч

ярдәм» чакырырга кирәк»,—дип торганда, ул якындагы урамга йөгереп менде һәм ике-өч минуттан юлда торган бер жинел машина белән кул буена төште. Авыруны күтәрешеп машинага салучылар да табылды. Анын башын кызнын тезләренә салдылар. Данил да калмады—автомашина хастаханәгә очты. Анда табиблар иргә беренче ярдәм күрсәткәнче, диагноз куеп, хастаханәгә салганчы шактый вакыт үтте. Данил авыру яныннан китмәде, мәш килде—күтәреште, төшереште. Тулай торагына тәмам карангы төшкәч кенә кайтып керде ул.

Хастаханәдә Данил шуна төшенде: бу авыру ир аларнын даими пациенты икән һәм ул Данил әлегә төшенә алмаган бик катлаулы чиргә тарыган булса кирәк. Ә кыз... Ул бу ирнен хатыны ахыры—шулай сыман тоелды Данилга. Анын йөзендәге монсулык, кайгы билгеләренен сәбәбе дә әнә шул авыру ир, күрәмсен.

Бу хәлдән сон атна-ун көн узгандыр, Данилга кул буена төшеп йөрергә вакыт тимәде. Җәй. Яна скважиналар өлгереп кенә тора. Данил эшләгән промыселда исә шул яна скважиналарны бораулаучылардан кабул итеп, үзләштереп, нефть чыгару мәшәкатьләрен җайга салу көннәре иде. Көнне төнгә бәйләп эшләгән вакытлар. Яшь белгечнен әлегә аз файдаланган энергиясенә мәйдан кин. Берьюлы әллә алты, әллә жиде скважинаны үзләштерделәр—мерниклар тулып кына торды. Аларны даими карап торырга, күз унында тотарга кирәк, чөнки тулып ташуы бар. Ташый калса—эш харап: бөтен тирә-юнь нефтькә, мазутка батачак. Бу инде олы җәнҗал белән бетәчәк, хәтта сине мастерлыктан алып куюлары да бар. Ләкин Данил коры холыклы ата кул астында тәрбияләнде, анын белән ингә-ин торып эшләп үсте. Җаваплылык дигән төшенчәнен дә нинди кыйммәткә ия булганын яхшы белә. Шуна да ул бу киеренке көннәрдә кулыннан эшен ташламады, тырышты, ары чапты, бире чапты. Шушы кайнар көннәрдә үзеннән күпкә олы яшьтәге, ләкин нефть чыгаруда шактый тәҗрибә туплаган оператор абзыйлар белән дә уртак тел тапты. Тыныч холыклы, үзе башлап йөгерә торган яшь инженер аларга да ошап куйды. «Монын белән эшләргә була»,—дигән нәтиҗәне алар әнә шул җаваплы көннәрдә чыгарганнардыр, мөгаен.

Эш-мәшәкате күп булса да, Данил ара-тирә күнелен давылга дучар иткән сылу кызны да искә ала торды. Ә бер кичне эштән кайтканда ул аны тулай торак каршында очратты. Бүген дә ул тәненә ятып, үзенә килешеп торган аксыл күлмәктән, биек үкчәле ак туфлиләрдән. Тик күзләрендә генә монсулык, кайгы билгесе һаман бетмәгән. Берүзе арлы-бирле йөренә. Данилны күрү белән анын йөзе бераз ачыла төште.

—Хәерле кич! Мин бит сезне көтәм,—диде ул. Анын болай килеп чыгасын Данил һич көтмәгән иде. «Сезне көтәм...» Егетнен эченә җылы йөгерде, күнелендә өмет ялкыны кабынды.

—Хәерле кич...

—Зинһар өчен гафу итегез. Сез беркөн безгә шундый да зур кайгыртучанлык күрсәттегез... Ничек дип әйтергә дә белмим инде... Рәхмәтемне әйтергә килдем... Сезне монда яшисез дип әйткәннәр иде. Кичә дә килгән идем. Менә, алыгыз әле шуны,—дип кыз Данилга кульяулыкка төргән бер нәрсә сузды.

—Нәрсә сон ул?—диде Данил, нигәдер шиккә төшеп, әйбергә һич кагылмыйча.

—Булышканыгыз, хезмәтегез өчен... Автомашинага да түли алмый калдык... Ирем түләргә кушты.

Данил бу төргәкчектә акча икәнлеген анлады һәм анын кинәт башыннан төрле уйлар узды, жаны рәнжеп, кәефе китте. Ләкин сабырлыгын җуймады, салкын канлылык белән:

—Сез мине кимсетәм дип уйламыйсызмы?—диде. Каршысында басып торган монсу күзле гүзәл хатыннын кинәт чырае сытылды, ә башы сизелер-сизелмәс кенә бер якка селкенеп куйды.

—И-и, Ходаем... Зинһар өчен, зинһар өчен, гафу итегез! Бу турыда мин үзем дә шулай булмагае дип уйлаган идем. Әллә ничек шунда... Ирем бит...

Аның әрнүдән монсуланып киткән күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты. Данил моны көтмәгән иде, аның үпкәсе шунда ук җилгә очты.

—Җә, җә, тынычланыгыз. Сезгә борчылырга ярамый, үзегезне сакларга кирәк,—диде ул.—Ирегезнең хәле ничек соң әле, тереләме?

Бу вакытта хатын бәләкәй кульяулыгы белән яшьле күзләрен сөртеп маташа иде.

—Терелә дип... Терелә торган түгел инде,—диде ул авыр сулап.—Ята әле. Больницада һаман. Үзем дә менә сезне күрер өчен генә чыккан идем. Яныннан киткән көнем сирәк...

Аның тавышы йомшак, ягымлы һәм... хәсрәтле. Яшь кенә хатын, һәрхәлдә Данилдан олырак түгел, ә кайгы-хәсрәтне батманы белән татырга өлгергән ахры.

—Мин сезнең турыда көн-төн уйлыйм: кемнәр сез, кайдан килеп чыктыгыз?—диде Данил уйланып кына, гади итеп.—Ләкин, күреп торам, бу турыда аңлашырга вакытыгыз юк. Шулай да исемегезне әйтсәгез иде. Мин үзем Данил атлы. Әгәр бер-бер ярдәм кирәк булса, эндәшегез, мин кулымнан килгәнне эшләргә тырышырмын.

—Ай, рәхмәт! Мин—Дилә. Ә ирем Наил исемле. Кызганыч, бирелә безнең беркемебез дә юк. Иремнең туган авылы ерак түгел-түгелен...—ул кулындагы сәгатенә карады.—Соңга калам инде. Очрашмый тормабыз әле. Сезгә бик зур рәхмәт... Сау булыгыз!..

Ул ашыга-ашыга китеп барды.

## IV

Башына төшсә башмакчы буласың. Диләне тәүге тапкыр күргән көннәрдә Данилның күңелендә давыллар уйнады, хисләре ташкын булып ташты, татлы хыялларда гизде. Ләкин соңгы очрашудан соң ул басынкыланып калды: Дилә—ир хатыны лабаса. Ничек бу турыда аның башына килмәде? Яшьрәк шул әле, тәҗрибәсе аз: чибәр кызларга хуҗа тиз табылганын белеп житкерми. Менә моннан соң белә башлар инде. Әйе, чибәрләр, көмеш акча кебек, җирдә ятмыйлар, аларны тиз табып алалар...

Басынкыланса да, Данилның күңеленнән чыкмады гүзәл хатын. Очрашып, танышып киткәннән соң аның тагын күрәсе, сөйләшәсе килде. Дилә белән күрешеп сөйләшү—үзе бер гомер. Юк, гади генә кеше түгел ул! «Югарыдан, Асылъяр кебек морзалар нәселеннән, аксөяк»,—диде бит әле бораулаучы Тимеркәй дә. Каян уйлап тапкан диген син андый чагыштыруны: морзалар нәселеннән...

Эштәме, юлдамы, өйдәме—Данил әнә шулай гел Дилә турында уйлап йөрде. Ир хатыны турында шулай җенләнергә тиеш тә түгел югыйсә. Ләкин бу дөньяда булмаган хәл юк бугай. Күңеле тартылгач, нишләсен соң?

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. Данилның эштә тагын мәшәкате артты, бистәгә кайткан чаклары бөтенләй сирәгәйде. Шулай да, бәхете бар икән, шушы сирәк кайткан кичләрнең берсендә ул Диләне тагын очратты.

Диләнең йөзе һаман уйчан, монсу. Тик үзен бик тыныч тота.

—Бераз больница исен таратыйм, саф һава сулыйм, дип төштем. Әле кибеткә кереп Наилгә фруктылар да аласым бар...

Гел күптәнге танышына сөйләгән кебек сүз башлады Дилә. Һәм дәвам итте:

—Сезгә рәхмәт инде, теге вакытта бик-бик булыштыгыз, игелекле егет икәнсез...

Сүз артыннан сүз китеп, алар күп нәрсә хакында сөйләшергә өлгерделәр.

Дилә үзе авыл кызы икән. Үзенә әле егерме өч кенә яшь, ә ире бишенче дистәсен тутырып килә. Яшь чак—җүләр чак. Урта мәктәпне тәмамлаган елны бәхетен эзләп ул Урал якларындагы әнисенең туганнан туган апаларына китеп бара—йә укырга керергә, йә эшкә урнашырга була исәбе. Әмма институтка керү имтиханнарын бирә алмый. Әллә каян килгән татар кызын институтларына кабул итәргә ашкынып тормый Уралдагы

урыслар, билеттагы сорау өстенә сорау яудырып, үткәрмиләр аны. Эшнең дә ошаганы табылмый. Апаларына җизнәсенең дусты, ул хезмәт иткән полк командиры килеп йөри икән. Шонталы мишәре. Ике татар бергә кич утыралар, шахмат уйныйлар, чәен-мәен эчәләр, серләрен уртаклашалар. Диләгә килеп төшкәннән соң мишәр якташ һәркөн күренә башлый. Ул вакытта әле сәламәтлеге нык. Төз, таза гәүдәле, иннәрендә полковник погоннары. Яшь кызны ул йә киногa, йә концертка чакыра. Тик үзе турында артыгын сөйләми. Диләгә апасыннан аның кайчандыр кемгәдер өйләнгән булуы, ниндидер бер мөһим сәбәп аркасында аерылышулары турында да ишетә. Үгезнең мөгезеннән эләктерергә күнеккән хәрби җитәкче озынга сузмый, кызның кулын сорый.

—Синең укуың да, эшләвең дә кирәк түгел миңа. Мин тапкан мал икебезгә генә түгел, туачак балаларга да житәр. Син бәхетле тормышта яшәячәксең, тик синең миңа тугрылыклы хатын булуың кирәк,—ди ул. Нигәдер, «тугрылыклы хатын» дигән сүзгә аерым басым ясый. Әллә инде авызы пешкән бахырның?

Олы яшьтәге дәрәҗәле хәрбинең дәгъваларына башта хөрмәт йөзеннән генә каршы килгән кыз, буар елан тарафыннан сихерләнгән куян сыман, үзе дә төшенеп житкермәстән, аның ирегенә буйсына. Бу хәлендә аңа апасы да төпле киңәшче була алмый, киресенчә:

—Нәрсәсе ярамаган? Чибәр, таза ир уртасы кеше, кулында малы бар. Балда-майда йөзеп, үз кадереңне үзең белеп кенә яшәрсең,—ди. Бәлки ул артык кашык сеңлесеннән, аның мәшәкатьләреннән тизрәк котылу өчен шулай әйткәндер?

—И-и, апа, яратмыйм бит мин аны. Һәм ярата да алмаячакмын—әти белән бер яшьтәге кеше бит ул,—дип ачыргалана яшь кыз.

—Әллә мин җизнәңне яратып чыктыммы? Өлешеңә тигән көмешең инде. Барысы да яратып кына чыкмый тормышка. Хатын-кызның язмышы шундый: кем туры килә. Ошаганны көтәм дип, бөтенләй утырып калуың бар. Бер яши башлагач, яратып та куярсың әле...

Озак уйлана кыз, озак тулгана, тик башка сайлар юл тапмый—риза була полковникка чыгарга.

Бер, ике, өч ел яшиләр алар бергә. Тыныч, имин, мул тормышта яшиләр. Ләкин болай яшәү генә яшь хатынны канәгатьләндерми, чөнки Диләгә апасы өметләндергән «яратып кую» хисе килми. Рәсәйнең башбаштак армия тәртипләрен сеңдереп, шуның явыз рухы белән көн үткәргән олы яшьтәге офицерның иксез-чиксез хыял белән яшәгән яшь хатынында артык гаме дә булмый. Хезмәтенә иртә чыгып китә, соң кайта, көне-көне белән кайтмый калган вакыты да була: хәрби өйрәнүләр, тревога, тагын әллә нәрсәләр... Ирнең бар таләбе—бала тап! Диләгә каршы түгел, бала табарга риза, берне түгел, икене, өчне дә табар иде ул, ләкин авырга кала алмый. Сәбәбен эзләп табибларга да мөрәҗәгать итеп карый. Алар исә яшь хатынны сәламәт дип табалар. Ике арада ризасызлык туа, болай да тулы аңлашу, җылылык, гармония житенкерәмәгән тормышта тынычлык бетә. Әллә соң ирен дә, Уралын да, туганнарын да ташлап, туган-үскән якларга кайтып китәргә дә, тормышны яңа баштан башларгамы дип тә уйлый Дилә. Тик шушы киеренке көннәрнең берсендә полк саклаган үтә яшерен объектта көтелмәгән хәл—зур авария була. Әлеге фаҗига булып, ике-өч сәгать узгач Диләнең ире атылып өйгә кайтып керә.

—Давай, тиз генә җыен да, поездга чап,—ди.

—Нигә?

—Авария, страшная авария...

—Булса ни? Сине ташлап кая китим мин?

—Юк, Дилә, немедленно җыенып китәргә кирәк. Җизнәңнең гаиләсе дә, башка бик күпләрнең гаиләләре дә китә. Монда ун минутка да калырга ярамый...

—Нишләп? Нәрсә булды соң?—дип һаман аңламый азаплана ваемсыз яшь хатын.

—Авария дим бит, страшная авария...

—Соң, аның нинди зыяны бар мина синең янында калырга?

Эшнең асылын аңламаган яшь хатынның гамьсезлеге ирен чыгырыннан чыгара:

—Син нәрсә, тинтәкме, әллә тинтәк булып кыланасыңмы? Әллә атом радиациясенең нәрсә икәнен белмисеңме? Или жить надоело?—дип кычкыра ире шартлый язып. Шуннан соң гына Дилә хәлнең асылына төшенә.

—Кая китим соң мин хәзер?

—Теләсәң кая кит! Әйтик, туган авылыңа, лишь бы подальше отсюда, лишь бы подальше. И побыстрее!..

—Ә син?

—Мин дә китәр идем, бик китәр идем. Но не могу—служба...

Дилә өч айлап авылда, атасы-анасы йортында яши. Өч ай иреннән хәбәр килми. Дилә аптырап бетә, аның төн йокылары кача, инде нәрсә эшләргә дә белми. Ниһаять, бер көнне ире кайтып төшә. Типсә тимер өзәрдәй ирнең шәүләсе генә калган. Атом-төш кораллары житештерү оешмасындагы аварияне бетерүдә катнашкан хәрбиләр, шул исәптән Диләнең ире дә, күп микъдарда радиация-нурланыш алганнар икән. Хәбәр бирми торган өч ай буена ул госпитальдә яткан, тик сәламәтләнүгә өмет зур түгел. Башка чара юк—полковникны да, башка күп кенә хәрбиләрне дә, инвалидлык группасы биреп, пенсиягә озатканнар.

Туган авылыма якынрак булырмын дип, Башкортстан җирендә, Ык буенда туган отставкадагы полковник Аккүл бистәсенә тукталырга, шунда фатир алып төпләнергә карар кыла. Озаккамы? Анысы инде Аллаһы кулында...

Әнә шулай килеп чыкканнар алар Аккүлгә.

Хәзер ир көннән-көн сулып бара. Электән дә авыр холыклы кеше, хәзер бөтенләй үз эченә бикләнгән, көн буена да сүз катмый, чырае караңгы. Күрәмсең, уйлары җинел түгел. Үзенең каты авыруга тарыганын белә, аңлый һәм үлеп китүдән дә шикләнә. Шунамы, ул еш кына япь-яшь хатынына аптырашлы күзләре белән озак итеп сынап карап тора, тик эндәшми. Ә Дилә күнелсез, боек булса да, зур сабырлык һәм түземлек белән, үз-үзен аямыйча аны карый, анын турында кайгырта, чөнки һәр намуслы хатын өчен ир хакы бар. Ир хакы—Тәңре хакы...

—Тормышның бер яме калмады. Барысы да ишелә, җимерелә, челпәрәмә килә. Белсәгез иде мина ничек авыр булганын,—диде Дилә кайтып китәр алдыннан.

## V

Бораулаучылар нефть чыгаручыларга берьюлы тагын бер төркем скважина тапшырдылар. Аларның барысын да яна оештырылган участокка бирделәр. Участокның житәкчесе итеп яшь инженер Данил Субаев билгеләнгән иде. Ул үзе дә, аның оешып килгән яна коллективы да муеннан эшкә чумды. Көнләп кенә түгел, тәүлекләп китмәделәр нефтьчеләр яна скважиналардан. Бу вакытта эш башында торган яшь белгеч бистәгә кайтып ял итүне бөтенләй онытты. Барысы да жанын-тәнен биреп эшләп йөргәндә, бот күтәреп яткан житәкче турында нәрсә әйтерләр?

Шул киеренке көннәрнең берсендә участокка Данилны эзләп Тимеркәй килеп төште. Буровойда бергә эшли торган бер иптәшенең мотоциклына утырып, Данилны иртәдән бирле эзлиләр, тик таба гына алмыйлар икән.

—Менә кайда югалып ятасың икән, жәһәннәм тишегендә, һич эзенә төшәр хәл юк,—дип битәрләп алды Тимеркәй дусларча.

—Нәрсә булды, әйт тизрәк...

—Хәерле хәбәр түгел, малай. Теге чибәр хатын сина язу җибәргән. Менә, укып кара үзен,—дип ул Данилга кул кисәге кадәр генә кәгазь сузды. Анда: «Данил! Наил вафат. Булышчым юклыгы сезгә мәгълүм. Кая барып бәрелергә дә белмим. Иртәгә үзенең авылына алып китәргә, шунда жирләргә уйлаштык. Тик ярдәмчеләрем аз. Дилә...»

«Иж» мотоциклына алар өчәүләшеп утырып кайттылар. Бистә зур түгел—полковникның фатирын тиз таптылар. Хәрби комиссариаттан вәкилләр дә килгән, тик чирек гасырдан артык гомерен, бар көчен данлыклы Совет

Армиясе сафында илнең сугышчан куәтен ныгытуга, какшамаслыгын тәэмин итүгә кызганмаган өлкән офицерны соңгы юлга хөрмәт белән озатырга мөмкинлекләре юк икән. Мәрхүмнең ярлы авылдан килгән туганнары да, тирән кайгыдан йолкып аткан гөл чәчәгедәй сулып, суырылып төшкән яшь хатыны да тулы аптыраышта. Ишектә Данил күренгәч, Дилә ничектер талпынып куйды һәм елап җибәрде. Шул мизгелдә Данил үзенең мәрхүмне соңгы юлга озату мәшәкатьләре өчен тулы җаваплы кеше икәнлеген аңлады. Тагын ун-унбиш минуттан ул промысел җитәкчесе янында иде. Олыгаеп, чәчләре көмешләнеп килгән промысел җитәкчесе Евгений Иванович дөньяны яхшы таныган, тәҗрибәле кеше иде. Данилның әйткән сүзен ике җөмләдән үк аңлады. Шундый зур дәрәҗәдәге хәрбине соңгы юлга, бөтен йолаларны истә тотып, хөрмәт белән озату өчен кирәк булган бар мөмкинлекләрне эшләде: матди ярдәм дә күрсәтте, оркестр, транспорт турында да кайгыртты, өстенә кызыл йолдыз беркеткән һәйкәл дә әзер булды, такталар да озатылды.

—Җирләүне үзең оештыр, йөзебезгә кызыллык килерлек булмасын,— диде ул Данилга.

Матәм маршы белән озаттылар мәрхүмне соңгы юлга. Җирләгәч тә, карабиннардан шатыр-шатыр атып, гимн уйнадылар.

Данил да нефтьчеләр йөзенә кызыллык китермәде. Авыл халкы мең рәхмәт әйтеп калды аңа.

Зираттан алар Дилә белән иң соңыннан чыктылар. Данил аны бераз озата барды. Шул арада хатын кайгыларын түкте, иренең соңгы көннәрдәге хәлен, сөйләгән сүзләрен искә алды.

—Ах, үләсе килмәде аның... Егерме җиде ел армиядә хезмәт иткәненә уфтанып бетә алмады. Үз башыма җитәр өчен генә сайлаганмын икән хәрби хезмәтне, диде. Без укыган елларда балаларның бар теләге укытучы булу иде бит. Наил дә тарих укытучысы булырга хыялланган, ләкин университетка конкурстан үтмәгән. Үзе кебек ВУЗдан мәхрүм бер иптәшенә ияреп хәрби училищега барып кергән. Анда аларны ун куллап каршы алганнар. Гомере армиядә хезмәт итеп үтсә дә, тарих укытучысы булу хыялы сүнмәгән иде йөрәгендә. «Менә, отставкага чыгам да, мәктәпкә укытучы булып барам. Рәсәй тарихы чын тарих түгел ул, барысы да уйдырма, фәкать урыс дәүләте, урыс халкы интересларын гына истә тотып язылган тарих ул. Урыс дәүләте, урыс халкының баскынчылык идеяләрен аклап, ерткычлыгын, мәрхәмәтсезлеген батырлык, патриотлык төшенчәләре белән буяп һәм бутап биргән ялган, шапырынкы-күперенке, зыянлы тарих. Әнә шул тарих белән ничәмәничә гасырлар буе яшь буыннарның миен агулыйлар хәзер...»

Теләге тормышка ашмады, әйткәне фәрештәнең «Амин» дигән чагына туры килмәгән, күрәмсең...

Саубуллашыр алдыннан Дилә күзләрен Данилга төбәде:

—Рәхмәт сиңа, Данил, бик зур рәхмәт! Кайгымны уртаклашасың, мәшәкатьләремне күтәрешәсең. Уйламаганда-нитмәгәндә миңа терәк булдың. Хәзер минем Аккүлдә синнән дә якын кешем юк...

Данил аның кулларын учына алды. Ни гаҗәп, куллары кайнар иде Диләнең. Аның карасу-зәңгәр, кайгылы күзләреннән тагын яшь сытылды. Аннары түгәрәк, матур, ләкин таҗ кебек авыр башы,ниндидер бер газаплы көчкә буйсынып, егетнең күкрәгенә иелде...

## VI

Юл буе Данил Дилә турында уйланып кайтты. «Хәзер минем Аккүлдә синнән дә якын кешем юк...» Моннан берничә атна элек бу ханым аның хыялына да ашмас кеше кебек иде. Ә хәзер ул аңа синнән дә якын кешем юк, ди. Күл буенда тәүге очрашулар вакытында башын күтәреп күзен дә сирпемәгән гүзәл хатын, бүген бөтен кайгы-хәсрәте, мәшәкатьләре белән аның каршына килеп егылды. Юк, һич уйламаган иде ул шулай булыр дип. Күнеләндә берничә көн давыл уйнады да, кинәт кенә басыла да башлады. Шулай да Дилә кадерле аңа, әнә шул кайгы-хәсрәтләре, мәшәкатьләре белән кадерле. Диләнең бу бистәдә якын кешеләре булмаган кебек, Данилның да якыннары юк. Бүлмәдәше Тимеркәй белән бер-берсенә сыенып яшиләр,

ләкин бу әле якын булу түгел, монын өчен бергәләп бер батман тоз ашарга кирәк.

Ләкин Данил яратамы сон Диләне? Бу сорауга егет әле анык кына жавап та бирә алмый. «Юк!» та түгел, «әйе» дә түгел. Әйтерсен лә шуны ачыклыйсы килде—ул учы белән битен кат-кат ышкып алды. Киләбе чуалды анын—бусы хак. Диләне тәүге очраткан көнне Данил да, Тимеркәй дә анын ир-егет кулы кагылмаган кыз булуын теләгәннәр иде. Юк, булмады. Үз кыйммәтен, үз кадерен белмичә, атасы яшендәге кешегә кияүгә чыккан, алтынын бакырга саткан.

Кызлар күрсәм кызамын,
Ун кулымны сузамын;
Кыз дигәнем хатын булса,
Сулга карап узамын...

Тимеркәй беркөнне сөйләшеп утырганда, әнә, шушы такмакны такмаклап алды. Жор да сон үзе! Сүз сөреше, тел төбе, уе гел егерме яшьлек егетләрнеке түгел, ә гомер иткән аксакалларныкы диярсең.

Тик, ни генә димә, Данилнын күнеле бүген әнә шул хатынга тартыла. Әллә сон артык чибәр булгангамы? Ир-атнын, матур хатын-кыз күрсә, башы-күзе әйләнә анысы. Һәр ялтыраган нәрсәнен алтын булмавын да онытып жибәрә ул кайчакта...

Кайта-кайта егетнен уйлары икенчегә күчте. Әллә ничек, туган авылы, ата-анасы, сенлесе исенә төште анын. Күптән кайтканы юк шул. Бер кайтасы, барысын да күрәсе, урманга кереп чыгасы, һавасын сулыйсы, Якты аланга барып күл буенда балык чиртерәсе килеп китте. Өсте-өстенә өелгән эш, төрле мәшәкать белән ул туган якларына кайтып килүне бөтенләй онытып жибәргән икән бит.

Урманчы малае Данил урманда үсми, кайда үссен?! Кышкы айларда урманда сирәгрәк булса да, жәен ике-өч көнгә бер, ә кайвакыт көн саен булырга туры килә иде ана. Атасынын яраткан сүзе малайнын күнеленә мәнге сенеп калды:

—Урманда кешегә дүрт агач кирәк: нигезгә—имән, бурага—нарат, себеркегә—каен, чабатага—юкә...

Дөрес, Данил монын белән бик үк килешеп тә бетми, анын үз карашы да бар. Атасы бурага нарат диде, ә аларнын өе усак, мунчалары юкә бүрәнәләреннән. Ә утын? Авыл кешесе утынсыз бер көн дә яши алмый: аш пешерәсеме, чәй кайнатасымы, ипи саласымы—утын, утын! Инде чатнама салкын кышкы айлар турында әйтәсе дә юк—өйдә жылы тотар өчен мичкә ягарга атнасына бер олау коры утын кирәк. Малайнын беләкләре бераз ныгый башлау белән атасы аны урманга утын алып кайтырга, аны бушатырга, кисеп турарга, ярырга тарта башлады. Утын, печән, себерке әзерләү, жиләк, гөмбә жыю, юкәдән кабык яру, анасы белән зелпе кайрысы жыю, питомникта яшь агач үсентеләре утырту, аларга чиләк белән ташып су сибү, карап үстерүләр...

Данилнын ин яратканы—күрше малайлары белән Якты аландагы урманчы өе—кордонда берничә көн кунып, күлдән балык тотып яту. Менә кайда ул дөнья рәхәте! Хәзер үстеләр шул, тормыш мәшәкатьләренә чумдылар, ул рәхәт көннәрне сагынып искә алырга гына калды. Әле институтта укыган елларда да Якты аланда балык тотып яткалады. Ә менә хәзер бетте. Аккүлгә киткәннән бирле анын тормышы китекләнә башлаган сыман—урманны ерактан гына күреп йөри. Шулай да, бер кайтасы килә анын авылга, бер утырасы килә Якты алан күле буенда.

Ләкин хыялы тиз генә тормышка ашмады. Эшне жиренә житкерим дип, тагын атна-ун көн узды. Ниһаять, промысел житәкчесе яшь белгечкә өч көн ял бирде.

Күчтәнәчләр алып, юлга жыенып маташканда, тулай торак ишеген кагып Дилә килеп керде. Данилнын авылга кайтып китәргә жыенганын белгәч, башта сөмсерләре коелып, аптырап калган иде, аннары, һушына килеп: «Мине дә калдырма, үлек чыккан фатирда ялгыз башым яшәп акылымнан шашам»,—диде.

Бөтенесе берьюлы хәл ителде. «Әйдә, кайтсын! Әллә иярτеп кайтмаслыкмы? Мондый чибәрне күреп өйдәгеләр «аһ» итәчәкләр әле. Яраткан кызым, диярмен. Хәзер кем иярτеп алып кайтмый йөргән кызын яки сөйгән егетен? Урманга, Якты күл буена да бергә барырбыз. Диләдә кайгысыннан, хәсрәтеннән, авыр уйларыннан бераз арыныр...»

## VII

Акташта кунакларны шатланып та, бераз гына гаҗәпсенеп тә, сагаеп та каршы алдылар. «Әллә эшкә барып урнашмас борын үләнергә дә җыенамы бу Данка?»—дип баш ватты аның анасы. Атасы исә: «Әй, үләнсә-үләнер инде, белемен алды, эшен башлады, катын алса, тормышы түгәрәкләнер, оныклар үстерербез»,—дип үз-үзен юатты. Төсе-бите, буе-сыны белән гел анасына охшаган сеңлесе генә андый уйларны уйларга өйрәнмәгән иде әле, урысча сукалый башлаган ерык авызлы студентка: «Ой, какая замечательная пара, поздравляю!»—дип, абыйсын да, Диләне дә берьюлы килеп кочаклады. Аннары өч хатын-кыз бергәләшеп шау килеп табын әзерләделәр. Микулай өстәлгә каяндыр бер сургыч башлы «малайны» да чыгарып куйды. Инде участок житәкчесе булып киткән улының уңышларын билгеләп үтмәү гөнаһ булыр. Ата белән ул, чәкешеп, берәр җамыяк кабып та куйдылар. Атасының улына сораулары күп иде: нинди эш, авыр түгелме, җитәкчеләр белән мөнәсәбәте ничек, фатир бирерләрме?.. Данил һич авырсынмый, сабыр гына бәйнә-бәйнә җавап бирде. Сандра нефть эшендә җитәкче булып киткән улының үз эше турында төпле итеп сөйләвенә сокланып утырды. Тик соңыннан Данилның: «Без Якты күлгә балыкка, ял итәргә барабыз»,—дигән сүзләре генә аны аптырашта калдырды. Ләкин тормыш юлыннан мөстәкыйль атлаган бу егетнең теләгенә каршы килүче булмады. Нәрсә эшләгәннәрен үзләре белә торганнардыр...

Бераз ризык, тоз-шырпы, кармаклар, төнлә салкынча булыр дип одеяллар алдылар да, урманга менеп киттеләр. Аларга инде ничә ай Данилны сагынып торган Актүш тә иярде.

—Әйдәгез сун, ат белән менгереп төшим үзегезне,—диде Микулай улына, алар чыгып барганда.

—Юк-юк, әти, без үз жаебыз белән, җәяүләп кенә менәрбез,—диде Данил.—Син ял ит...

* * *

Жәй үтеп тә бара—июль ахыры. Зәңгәр күк йөзе, бүз тарткан кебек, аксылланып тора. Тып-тын, тик үлән арасында чикерткәләрнең чер-чер итеп черелдәшүе генә ишетелә.

Ярты чакрым үттеләрме-юкмы, урманга килеп керделәр. Урман сихри тынлыкка чумган. Каен ачысы, ылыс, гөлҗимеш чәчкәләре, абага һәм башка үләннәрнең исенә туенган арба юлы борыла-сырыла сөзәкләп эчкә, һаман эчкә үтә. Кушы төклетуралар чәчкәдән чәчкәгә кунып бал җыялар. Куе чыршы ботаклары аша үтеп кергән кояш нурлары алтын сыман пәрәвезне хәтерләтәләр. Инде көн кичкә авышкан. Кошлар тынган. Җәнлекләр дә өннәрендә ята. Данил белән Дилә генә, тирә-якка карана-карана, һич ашыкмый шул юлдан алга баралар. Ә Актүш алардан да алдарак элдертә. Ул юлның әле бер ягындагы куаклар арасына, әле икенче ягындагысына кереп-кереп китә, иснәнә, аяклары белән җирдә тырнана да, кабат юлга чыга, басып Данил белән Диләнең ана якын килгәнен көтеп тора. Якыная башлагач, тагын үз юлын дәвам итә.

Бу юл Данилга күптән таныш. Дөрес, соңгы ике-өч елда аның биредә йөргәне булмады, чөнки Чалкантау урманында яңа урманчы өе салдылар, ә мондагы урманчы өе ташландыкка әйләнгән сыман булып калды, аңа урманчылар да, аучылар да юлны оныта башладылар. Ә Данил өчен иң кадерлесе—Якты күл, аның керкә балыгы, шул балыкның комсызланып чиртүе, аны су өстендә уйнатып тартып чыгару.

Дилә өчен исә бу урман да, аның юлы да таныш түгел иде әле. Ул

карасу-зәңгәр күзләре белән яшел дөньяны айкый, эчтән генә гаҗәпләнә, соклана. Аның йөзендә кайгы төсмерләре жуелып, кызыксынулы җан тынычлыгы һәм хыялга бирелү билгеләре чалына башлады. Вакыт-вакыт аның йөзе яктырып китә дә, елмаю чалымы абайлана. Данил аңа борылып, туктап күзләренә карап тора, әйтерсең лә: «Күрәсеңме, мин сине нинди матур урманга, нинди хозурлы дөньяга алып чыктым?»—ди сыман.

Диләнең башы тулы уй. Үзенеке кебек үк зәңгәр күзле, дулкын-дулкын сары чәчле, төз һәм таза гәүдәле бу егет аның тормышына һич көтмәгәндә-уйламаганда килеп керде. Данил беренче күргән көннәрдә Диләкүзен дә сирпеп карамады дип уйласа да, Дилә күрми калмады аны. Хатын-кыз ул текәп карамаса да, чит карашны җаны-тәне белән сизә. Бигрәк тә үзе белән кызыксынганнарның карашын тиз сизә ул. Данилга бәлки беркайчан да әйтмәс, ләкин үзеннән яшерә алмый: бу егет ана беренче көннән үк ошаган иде. Карашы ук ниндидер өмет бөркегән сыман тоелды аңа. Иренең көннәре санаулы, ә ана әле яшисе дә яшисе. Ире белән ул-бу була калса, кем аны юатыр да, үзе кем җилкәсенә барып таяныр? Ялгыз башың яшәү ай-һай авыр бу дөньяда. Шуңа да ул бу тубал кебек сары башлы егеткә өметен баглады. Тик акларммы ул аның өметен, алып килерме ана көткән бәхетен? Бүген иртән Аккүлдән аңа ияреп чыгып китү, бәлки, дөрес тә булмагандыр. Бераз тыйнаксызрак, әрсезрәк килеп чыкты. Ахыры гына хәерле булсын! Шулай да бүген Дилә үзен таш дивар артындагы кебек сизә. Гел шулай, гомер буена шулай булса икән...

Урман һавасы исертердәй саф. Дилә, күкрәген киереп-киереп, үпкәләренең иң арткы өлешләренә барып житәрлек итеп сулады шул шифалы һаваны.

Алга таба юл тарая төште һәм Данил аркасындагы биштәрен бераз төзәтеп, алдан китте. Дилә исә арый башлады бугай:

—Барып житәбезме әле?—дип сорады.

—Юк әле. Арыдынмы әллә? Хәзер ял итеп алабыз...

Алар ике-өч ашъяулык чаклы гына бер аланда туктап, жиргә аудылар. Данил биштәреннән одеял алып, аска җәйде. Телисеңме-теләмисеңме, Данил белән Дилә хәзер икесе дә шул одеял кинлегендәге урынга елыштылар.

—Менә ул кайда дөнья рәхәте! Сина ничек, ошыймы?—диде Данил. Дилә озын кара керфекле күзләрен йомып, «Әйе» дигән мәгънәдә башын селкеп куйды һәм Данилның жылы кулларын учына алды. Бу—рәхмәт сиңа, миңа барысы да ошый, синең белән миңа бик рәхәт, син миңа хәзер бик кадерле, тик Ходай гына мине синнән аермасын, дигән ишарә иде. Һәрхәлдә, Данил шулай аңлады. Һәм үзе дә жавапсыз калмады: Диләне кысып кочаклады да, башта монсу күзләреннән, аннары кайнар иреннәреннән суырып үбеп алды. Дилә әз генә дә каршылык күрсәтмәде, әйтерсең лә ул аны күптән көткән иде. Шушы үбешү мизгелендә аларның йөрәкләре шашынып типте, сулышлары ешайды, дөньялары онытылып торды. Ләкин бер-берсенә ике генә дә сүз әйтмәделәр алар. Мәгәр сүз әйтү кирәк тә түгел иде, ике яшь йөрәк бер-берсен болай да бик яхшы аңлады.

Кеше аягы басмаудан инде үлән белән капланып килгән тар юлдан алар тагын ун-унбиш минут бардылар һәм зур булмаган аланга килеп чыктылар. Аланы бер хәл, аның яртысы—аксыл күлмәктән, чуклы-чуклы яшел шәл бөркәнгән кызлар кебек зифа каеннар, баһадирлар кебек ныклы тамырлар өстендә үсеп утырган юан-юан кәүсәле нарат һәм имән агачлары ышыгында көзгедәй җәйрәп яткан урман күле иде. Күлдән өстәрәк авыл мунчасыннан аз гына зуррак, ике бәләкәй тәрәзәле, бер ишекле, түбәсе юкә кабыгы белән ябылган иске генә өй тора. Өй тирәсе киртә белән әйләндереп алынган. Ишек төбеннән алып шул күл буена чаклы кабык сукмак салынган булган, ләкин урыны-урыны белән кабык череп, таркалып беткән. Бу—урман каравылчысы өе, кордон иде.

Ниһаять, алар өйнең ишеген ачып, эчкә керделәр—ишегенең биге юк иде. Кеше аягы сирәгәйгәч, өй бөтенләй ташландык хәлгә килгәндер, дип уйлаган иде Данил, ләкин, бәхеткә, алай булып чыкмады. Аучы-сунарчылар туктала торалар күрәсең—эчтә савыт-саба, пычкы һәм балта, чалгы, кармак таяклары, мичкә ягарга утын, бер кап шырпы, бер савытта шактый гына тоз, тагын башка кирәк-яраклар үз урыннарында, хәтта дивардагы калакта

балык тозагы да эленеп тора. Бер як дивар буенда кечкенә генә өстәл, ә икенче ягында сәке.

Данил жилкәсеннән биштәрен салды. Дилә дә кулындагы әйберләрен өстәлгә илтеп куйды һәм килеп Данилга елышты. Данил аны тагын кочаклап алды. Бер мизгелдән алар кабат үбешү хозурына бирелделәр. Ләкин онытылмадылар. Бергәләшеп өйнең идәнен юып, чистартып алдылар. Данил ишегалдында электән калган ут ягу урынын рәткә китерде: урманнан казыклар кисеп чыкты да, аларны кагып куйды. Имән казыклары беркеткән өстәл, аның ике ягындагы эскәмияләрне дә рәтләде. Кабат урманга кереп, кочак-кочак коры утын ташыды. Бер керүендә череп яткан усак агачы каерылары астыннан биш-алты корт табып, кармакларын караштырып, күлдән балык тотарга төшеп китте.

Данил кая гына бармасын, Актүш анардан калмады, хәтта яр кырыена балыкка төшеп утыргач та ул аның янына, су кырыена килеп ятты. Көзгедәй якты су өсте, кармак таяклары, калкавычлар Актүштә үзенә күрә бер дәрт кузгата булса кирәк. Данил белән аның Көмешсу буена күп тапкырлар шулай балык тотарга төшкәннәре бар. Ә менә урман уртасындагы күлгә соңгы вакытта килгәннәре юк. Урам эте генә булса да, Актүштә аучылык сизгерлеге житәрлек. Шуңа да ул кармак ташланган су өстенә карап, әледән-әле сабырлыгын җуеп чинаштырып ала. «Әйдә, тартып чыгар инде тизрәк, бәлки миңа да өлеш чыгарырсың, ашыйсы да килә башлады»,—дип әйтә сыман.

Якты алан—Данилның иң яратканы. Микулай бирегә хатынын һәм балаларын атлы арбага утыртып жәенә биш-алты мәртәбә алып килә торган иде. Баш урманчы итеп куйгач, аның гаиләсенә вакыты җитми башлады, эше күбәйде. Җиләк вакытында—җиләккә, жылы яңгыр явып үткәч, тегендә дә монда башын калкыткан симез аяклы ак гөмбә жыярга, аннары мунчага каен себеркесе әзерләргә, август ахырында исә чикләвеккә килми калмыйлар иде.

Данил өчен иң хозурлысы—күлдән балык тоту. Бу күлне гел күл генә дип тә булмый. Аның суы—көмеш кебек чиста, үтә күренмәле, чөнки күлдән биш-алты йөз метрда гына өстә, тау итәгендә унлап чишмә агып чыга. Гажәп хәл: тау астында түгел, ә бәлки аның урта бер жиреннән агып чыга ул чишмәләр. Сулары салкын. Шуңа да күлнең дә суы жылы түгел, кызу көннәрдә дә су керәм, коенып чыгам, дия алмыйсың. Әмма балыгы күп. Әллә ничә төрле балык бар анда, ләкин иң затлысы—хан балыгы, ягъни, керкә, форель. Кайбер жирләрдә аны ала балык дип тә атыйлар.

Күл өсте тын. Биек-биек нарат, каен, юкә, усак агачлары аша бирегә жил дә үтеп керә алмый. Шул агачлар ышыгында ап-ак төнбоек чәчәкләре белән бизәлгән күл өсте зур, якты көзгене хәтерләтә. Эре-эре балыкларның әледән-әле шул тынлыкны бозып чупылдап сикерүеннән яр буендагы калын, нык сабаклы әрекмән яфраклары өстендә тынып утырган энә караклары куркып очып китәләр дә, күл өсте тынычлангач, кабат әрекмәнгә килеп куналар.

Җаңга рәхәт һәм тыныч. Данил кармагын суга ташлады. Ташлады да, дулкынланып балык капканын көтә башлады. Каз каурыеннан ясаган калкавычның очлы башы яшькелт су өстендә тырпаеп тора. Ул менә-менә батып китәр сыман. Шул калкавычка карап торулары үзе бер хозурлык. Менә калкавыч кинәт дерт итеп куя, бер якка кыйшая һәм шул көе хәрәкәтләнә башлый. Бу вакытта инде авыз ачып тормаска, балыкны каптырып, тартып чыгарырга кирәк.

Керкә балыгының чиртүе—бер гажәп! Башта ул салган жименне каракларча гына, сиздермәскә тырышып тартып карый. Бу вакытта тәжрибәсе булмаган балыкчы, балык капты дип, кармагын тартып та чыгара, ләкин балык капмый кала. Әгәр беренче тартуда ук ашыкмасаң, керкә икенчесендә жимне комсызланып тартып китә. Бу вакытта ул инде чын-чынлап капкан була. Данил керкәнең бу хәйләсен күптән белә. Атасы белән алар Якты күл буенда да, Көмешсу буенда да балык тотып аз утырмадылар. Иң бәхетле мизгелләр—эләккән балыкны дулкынлана-дулкынлана кармактан ычкындырып, тозакка салу вакытыдыр.

Әнә шундый һәркемгә дә аңлатуы мөмкин булмаган мөкатдәс минутларда Данил биш-алты балык тартып чыгарырга өлгерде. Бу вакытта

Дилә дә, өйдә эшен бетереп, Данил янына чыгып утырган иде. Аннары алар икәүләшеп учак ягып, балык чистартып, өйдән алып килгән бәрәңге һәм ярманы да салып, балык ашы пешереп ашадылар. Ул үзләренә дә, Актүшкә дә житте.

Кояш калын дивар кебек басып торган мәһабәт агачлар артына төшеп югалды. Сиздермичә генә эңгер төште. Әле һаман пыскып янган учакка Данил әледән-әле утын һәм чи үлән ташлаштырды, чөнки чи үлән төтен хасил итә, бу исә ябырылып килгән черки болытыннан сакланыр өчен кирәк иде.

Шул учак янында Данил белән Дилә бер-берсенә сыенып караңгы төшкәнче утырдылар, уй-фикерләре белән уртаклаштылар, назлаштылар.

Инде йоклап ял итәр вакыт та житте. Данил әле караңгы төшкәнче үк алан уртасыннан иң хуш исле үләнне чабып алып кергән иде, сәкегә шуны жәйделәр дә, өй эчен янып торган кисәү белән төтәтеп, черкиләрне качырып, ишекне ябып куйдылар. Шул секундтан алар икесе дә карангыда калдылар. Икәүдән икәү! Житкән, хәтта күптән өлгергән таза егет һәм яшь, ирсез калган гүзәл хатын. Икесенең дә каны кайнап, икесенең дә теләге ташып торган чаклары. Чишенделәр.

—Икебез бергә ятабызмыни?—дип пышылдады Дилә, Данилны үчекләгән сыман.

—Аерым ятам дисәң, әнә, идәнгә жәй урыныңны,—диде Данил да, хәйләкәр елмаеп, ләкин карангыда аның йөзен, әлбәттә инде, Дилә күрмәде.

—Юк, мин анда куркам,—диде ул һәм башкача сүз куертмыйча гына Данилга аркасын куеп килеп ятты. Данил аның өстенә япты, аннары көрәк кебек куллары белән аркасына борып яткырды һәм ана иелде. Өй эчендәге карангылыкка күзләре күнеп килә иде. Бәләкәй тәрәзәләрдән төшкән сүрән яктылыкта Дилә Данилның иреннәрендә назлы елмаю, күзләрендә шаян очкыннар шәйләде. Данил тагын иелә төште һәм шашып, суырып-суырып Диләнең кайнар иреннәреннән үбәргә тотынды.

Июль аеның соңгы төне аларга очсыз-кырыйсыз булып тоелды. Алар бу төндә керфек тә какмадылар, мона вакытлары да булмады: сөештеләр, назлаштылар, иркәләштеләр. Тәмам арып-талып, хәлдән таеп, сызылып таң аткач кына кочаклашып йоклап киттеләр. Инде йокы сөреме белән аңы томаланып барган бер мизгелдә Данилның кичә: «Менә кайда ул дөнья рәхәте!!» дигән сүзләре исенә төште Диләнең. Әйе, дөнья рәхәт иде...

Алар уянып киткәндә көн кичкә авышкан иде инде. Ләкин торып китү уйларына да кермәде: тагын бер-берсенең кочагына ташландылар, тагын ләззәтле һәм татлы сөешү дәртенә бирелделәр...

## VIII

Акташка алар өченче көнне генә кайттылар. Юл буе икесе дә Якты аланда үткәргән хозурлы көннәр, төннәр турында искә алып, рәхәт уйлар уйлап, әледән-әле кочаклашып, үбешеп, назлашып кайттылар. Данил Диләне үзенчә бәяләде. Ул ана бик ошады. Институтта укыган елларында аның түшәген жылыткан кызлардан артык күрде ул аны: кайнар, дәртле, тәжрибәле. Дилә исә парын үзенчә бәяләде: таза, көчле, ару-талуны белми. Данилга аның бигрәк тә: «Иремнән соң син минем икенче кешем»,—дигәне ошады. «Димәк, иренә тугрылыклы булган, мина да, үзенә өйләнә-нитә калсам, тугрылыклы булыр»,—дип уйлады беркатлы егет. Белсә икән ул үзенең чынында ничәнче икәнлеген—сәкедән тибеп кенә төшергән булыр иде. Хәер, төшергән булыр идеме икән? Мирга яраган иргә дә ярый, диләр бит.

Дилә жиденче сыйныфта укыганда ук алдырды каймагын. Ул елларда бер сыйныфта укыган балаларның жыйнаулашып табигать кочагына чыга торган гадәтләре бар иде. Ял көненә туры китереп, палаткалар, азык-төлек, савыт-саба, чиләк-казан алып, бер-ике көнгә урманга, яисә елга, күл буена чыгып китәләр. Ашлар әзерләп, уеннар оештырып, жыр-бию бәйгеләре үткәреп, яна тәэсирләр, көч һәм илһам алып кайталар иде алар. Һәрхәлдә, балаларның ата-аналары шулай уйлый иде. Ләкин аларның күбесе шушы культпоходларның, пионерлагерьларның бик күп кыз башына житкәнен

белеп бетермиләр, яисә соңыннан гына белеп алалар иде. Ләкин инде соң була. Иртә өлгергән үсмерләр мондый форсатны ычкындырмаска тырышалар. Үз яшенә караганда шактый сабакка тартылган Эдик та ычкындырмады форсатны, уйнап-көлеп, биеп туйгач, ул кызлар арасында аерым матур Диләне агачлар арасына алып кереп китте, кочаклады-үпте, әле яна гына калкып килгән күкрәкләренә кагылды, дәртләндерде, шашындырды һәм алар, ниһаять, юан каусәле каен артына авып төштеләр...

Ләкин Диләә артык кайгырмады, чөнки класста чиләк төбе төшкән кыз бер ул гына түгел иде.

Бу вакыйгадан соң кызга тынгылык бетте. Ачык авыз Эдик сертотмас үрдәк булды ахрысы. Диләне үз классы малайлары гына түгел, югары классныкылар да үзләренә музыка тыңларга, елга буена балык тотарга, урманга җиләк яки гөмбә җыярга чакыра башладылар. Ә бер чыгуда Диләне хәтта берьюлы өч егет чиратлашып яратты. Унынчы сыйныфны тәмамлаганчы да, аннан соң да, иргә чыкканчы да аның артыннан йөрүчеләр аз булмады. Данил белән бергә үткәргән хозурлы көннәргә кадәр үзе татыган, якаларын иснәштергән ир-атларның исәбен дә оныткан иде инде Диләә. Данил исә аның киртәдән чыккан хатын булуы турында башына да китермәде.

* * *

Ишекне ачып кергәч тә, Сандра, тавышын күтәреп:

—Сез кая жугалдыгыз?—диде.

—Балык тоттык,—дигән булды Данил.

—Ә балыгыгыз кайда?

—Тотканын ашап бетердек, тотмаганы күлдә калды...

«Тотмаганы күлдә калды...» Ах, мур кырггырлары!..

Бу көннәрдә Сандраның уйламаган уе калмады. Данилга ияреп кайткан, аның белән ялгыз башы урман уртасындагы кордонда куныпп-төнеп калган чәчбиненң нинди кеше булуы турында сорашып кала алмаганга да бик үкенде. Алар кайтып кергәч тә, ул бу хатасын төзәтү ягын карады. Ашын салып, чәен ясап өстәлгә чыгаргач, икесенә дә әкрен-әкрен генә сораулар бирә башлады. Сөйләшергә дә җайлы вакыт—Микулай эшендә иде.

—Данка, улым, моны ничек анларга сун инде? Үләнешергә уйлыйсызмы, әллә болай гына жөрисезме? Бер дә килешә торган эш төгөл бит әле бу.

—Анысын үзебез карарбыз әле. Без бер-беребезне сынашабыз, характерларны өйрәнәбез... Хәзер шулай бит инде, әни. Син безне ачуланма,—диде Данил анасына, аны кочаклап. Йомшак күңелле Сандраның бөтен ачуы, үпкәсе шунда төкәнде дә калды. Шулай да, ул кунак кызына бирәсе сорауларын онытмады.

—Кызым, кайсы жакныкы сун үзен?

—Минем туган авылым моннан ерак түгел, апа. Каенлы Чишмәне белә торгансыздыр?

—Каенлы Чишмә? Жа Кода! Без үзебез дә жәшәдек бит ул авылда. Данкага өч кенә жәш иде без уннан киткәндә.

—Шулаймыни?—дип гажәпләнде Диләә.

—Шолай шул! Кем кызы сун син алайса?

—Кем кызы дип... Хәзер анда безнен беркем дә юк, әтиләр шәһәрдә яшиләр.

—Сун бит, Каенлыда мин белмәгән кеше жук иде теге жылларда. Атан-анан кем?

—Минем әти танылган бораулау мастеры. Тимәшевләр без...

—Тимәшевләр?

Сандра, нилектәндер, Сафуанның исемен генә белә, фамилиясен әллә хәтерләми, әллә бөтенләй белми иде.

—Әйе, Тимәшев Сафуан...

—Са-пу-а-ан?—дип чиксез гажәпләнү белән сузды Сандра. Бу минутта ул ничектер унайсызланып, калтырап куйды, битеннән ут, башыннан кот чыкты.

—Ә нигә? Әйе, Сафуан Тимәшев,—диде кунак кызы салкын канлылык

белән.—Яшьлегендә бик оста тимерче булган минем әти, ә хәзер танылган бораулау мастеры.

—Тимерче Сапуан кызы дисең инде. Син аның ничәнче кызы соң?

—Мин, апа, аның беренче кызы. Тагын сеңлем бар.

—Ә нигә соң алайса син үзеңне Диләдисең? Сапуан кызы булсаң, син бит Даимә булырга тиеш!

Кунак кызы коелып төште. Көтмәгән иде ул мондый фаш итүне. Сандра, чыннан да, бик яхшы белә икән бит. Данил да Диләгә үзенең аптырашлы карашын төбәде. Хәзер инде аңлатырга кирәк иде.

—Әйе, минем чын исемем Даимә. Ләкин мин ул исемне беркайчан да яратмадым, чөнки мәктәптә урыс малайлары мине «Дай!»—«На!», «Дай!—«На!»—дип үчеклиләр иде. Шуңа да мин үземне Дилә дип йөри башладым,—диде кунак кызы, ниһаять, көчен җыеп.

Бер мәлгә барысы да аңлашылды кебек. Ләкин Сандраның сораулары бетмәгән иде әле.

—Алайса, кызым... Данка, безнең икебезне генә калдыр әле, сүзем бетмәде,—диде ул. Данил ишек алдына чыгып китте.

—Алайса, кызым, дөресен әйт: Якты аланда Данка белән ничек булдыгыз?

—Ничек, ничек... Мин, апа, тол хатын. Ирем күптән түгел генә үлде. Инде аңлый torгансыздыр: тол хатынга бернәрсә дә тыелмый бугай...

Сандра сөйләшә-сөйләшә торып өстәлдәге савыт-сабаны җыештыра башлаган иде, бу сүзләрдән соң кабат лып итеп утыргычка килеп утырды һәм тынсыз калды. Киләбе чуалган иде аның.

—Апа, сүзегез беттеме?—диде шулчак чая хатын.

—Җук, кызым, бетмәде әле,—Сандра үзен кулга алды. Ләкин сүзне ничек дәвам итәргә белмәде, аптырап калды. Гомере буе күңелендә саклаган, һичбер кемгә ачарга тиеш булмаган олы серне ачарга мәҗбүр иде ул. Шулай да сүзне башкачарак башлады.

—Кызым, сез Данка белән бөтән очрашырга тиеш түгел...

—Ә нигә? Ул миңа ошый, мин—аңа. Без бер-беребезне яратабыз. Бу беркемгә дә тыелмый. Әгәр эш өйләнешүгә барып житә икән, мин моңа каршы түгел. Инде әйттем: ирем үлде, үзем тол, балам-чагам юк—ялгыз. Аккүлдә ике бүлмәле фатирым, иремнән калган запасым бар. Төсем-битем, буем-сыным бар, дүрт саным төгәл. Улыгызга, кирәк дисә, ун бала табып бирермен. Тагын нәрсә кирәк?

—Анысы шолайдыр да, тик...

—Син кыз түгел, хатын, ә без Данилга кыз алырга уйлыйбыз, дияргә телисезме әллә? Белмим, апа, сезнең заманда ничек булгандыр, ләкин хәзер кызларны көндез чыра яндырып эзләсәгез дә таба алмыйсыз. Юк алар, андый кыйммәтле товарны озак тотмыйлар безнең заманда...

Ах, каһәр! Үзен Сафуан кызы ди, ә үзе ничек чәтердәп тора. Юк, бу бөтенләй Сафуанга охшамаган, гел анасы Гөлмәрфуга галәте монарда. Ул шулай күзен бирсә дә сүзен бирми, гел үзенекен чәтердәп тора торган хатын иде. Шул бит инде Сафуанны төп башына утыртты—баласы белән ташлап, үзенең сөяркәсенә ияреп чыгып качты.

Сандра түзмәде, сүзне икенчеләтеп, аңлатыбрак әйтергә булды. Тик монда да сак булу кирәк иде ана.

—Тукта әле, кызым, тынна әле мине жакшылап. Синең берәр качан бер атадан туган ике баланың үләнешеп жәшәгәнен күргәнең бармы?

—Ничек, ничек?—Сафуан кызының күзләре тоз булды. Сандра сүзен кабатлады.

—Ничек була инде ул алай?

—Мына шолай булды инде, кызым. Зур грехымны ачтырдың син минем. Ун бала табам дисең. Анысы жакшы. Тик үз братың Данкадан сәламәт бала тапмассың—белеп тор! Жа Кода...—дип уфылдады Сандра.

Дилә-Даимә сүзсез калды. Ниһаять, ул төшенде булса кирәк. Ике хатын бер-берсенең хәлен аңлап шактый гына карашып тордылар. Тынлыкны Даимә бозды:

—Шулай да, апа, кайсыбыз кемнең баласы соң без?

Сандра елый-елый яшьлегендәге хәлләрне Даимәгә дә сөйләп бирде.

—Тик зинакар, кызым, Данкага әйтмә мин сүләгәннәрне, җәллә мине,— диде ул.—Сүз бир!

—Аңладым, Сандра апа, борчылмагыз, әйтмәм,—диде Даимә.

Бераздан Данил белән Даимә җыенып Аккүлгә китеп бардылар. Юлда Данил Даимәдән анасы белән нәрсә турында сөйләшүләрен белергә теләгән иде. Даимә: «Ул—хатын-кыз арасында гына була торган сер, сорашма, әйтергә ярамый»,—диде дә, Данил башкача бу турыда сүз кузгатмады.

Аккүлгә кайткач Данил эшенә чумды, Диләә-Даимәсе турында аңа беравык онытып торырга туры килде. Берничә көннән соң ул аны эзләп фатирына сугылды. Ишекне бер яшь хатын ачты:

—Сезгә кем кирәк?

—Дилә кирәк иде,—диде Данил.

—Ә ул юк, китте. Без фатирларны алмаштырдык аның белән.

—Ничек китте, кайсы якка?..

—Мин аны сезгә әйтә алмыйм, чөнки ул әйтмәскә кушты. Ул: мине эзләп бер егет килер. Әйтегез, килмәсен дә, сорамасын да, эзләмәсен дә, очрашуыбыз ялгыш булган, диде.

Данил аңламады. Күпме баш ватса да аңламады ул Дилә-Даимәнең шулай яшертен китеп баруының сәбәбен.

* * *

Күп тә үтмәде, Данилның тормышында тагын бер вакыйга булып алды. Бер кичне эштән кайтып керсә, аларның бүлмәсендә бер яшь кыз җан-фәрманга идән юып йөри. Күрер күзгә уналты-унҗиде яшьләрдәге томрап торган тузынкырак кара чәчле, коңгырт-кара күзле, алсу ачык йөзле бик матур кыз. Өстендә зәңгәр халат. Идән уртасында чиләк белән су. Кыз шул суга чүпрәк салып, манчып-манчып ала да, бөгелеп, бөтен идәнне инләп, дәртле хәрәкәтләр ясап идән юа. Күренеп тора, бик уңган кыз.

Данилны күрү белән кыз бер мизгелгә туктап калды, кызарып, каушап китте һәм шул халәтендә:

—Исәнмесез,—диде.

—Исәнмесез... Әллә син яңа җыештыручымы?

Кыз елмаеп куйды:

—Юк.

—Ә кем соң син, кайсы як җилләре ташлады сине безгә?—дип тезеп китте Данил ниндидер бер күтәренкелек һәм шаянлык белән.—Бәлки танышырбыз? Мин—Данил.

—Ә мин сезнең турыда ишетеп беләм.

—Кемнән?

—Тимеркәй абыемнан.

—Алайса син—Тимеркәйнең сеңлесе.

—Әйе. Исемем—Фәридә.

—Бик матур икән исемең. Фәридә Кудашева кебек җырчы булыргамы исәбең? Абыеңның бер дә сөйләгәне юк иде мондый да чибәр сеңлесе барлыгы турында.

—Ә ул сезнең турыда гел сөйләп тора.

—Нәрсә сөйли инде?

—Әйбәт егет, ди.

Сүз иярә сүз китеп, алар бер-берсе турында бераз мәгълүмат та алдылар. Фәридә быел урта мәктәпне тәмамлаган икән, кая да булса укырга керергә исәбе, тик кая керергә генә белми.

—Сез кайтканчы бүлмәне сафландырыйм, дидем. Кизүдә торучы апа чиләк, чүпрәк, күлмәгенне чылата күрмә, дип халатын бирде. Бүлмәгез бик үк тәртипле түгел, урыннарыгызны җыймагансыз,—дип, Фәридә егетне бераз битәрләп алды һәм иртән җыештырылмый калган ятак урыннарын бик пөхтә итеп җыештырып, рәтләп куйды.

Озакламый Тимеркәй дә буровоеннан кайтып керде. Сеңлесе килүгә бик шат иде ул. Тимеркәй чишенеп, юынып алгач, алар кунак кызын ияртеп өчәүләшеп ашханәгә киттеләр, аннан соң клубка кереп бергә кино карадылар,

кинодан чыккач танцы мәйданына сугылдылар. Танцы мәйданында музыка уйный, яшьләр шау-гөр килеп бииләр. Данил да Фәридәне уенга чакырган иде, ләкин кыз: «Мин танцы итә белмим»,—дип, чыкмады.

Тамашаны карап тору уңаенда Данил Тимеркәйне Фәридәдән читкәрәк алып китте һәм:

—Мондый гүзәл сеңлең барлыгы турында нигә элек бер сүз дә әйтмәдең?—диде, үпкәләгәндәй.

—Сөйләгәнмендер. Тик, күреп торасын, яшь әле ул, укыйсы, белем аласы, һөнәр иясе, кеше буласы бар. Аннан... Әле егет кулын тидергән кыз түгел ул, син үпкәләмә. Синен әнә Диләң бар, барысына да берьюлы борын сузма, дустым.

Данил Тимеркәйгә Диләнең суга чумгандай югалуы турында сөйләмәгән иде әле. Әллә инде гарьлек иде аңа бу турыда сөйләргә, әллә үз җанын бимазалыйсы килмәде. Бу юлы түзә алмады, әйтте:

—Диләә югалды, Тимеркәй дустым. Фатирын алмаштырып, каядыр китеп барган ул, миңа адресын да калдырмаган. Безнең аның белән очрашуыбыз, танышуыбыз ялгыш булган, дип әйтеп калдырган.

—Чынмы бу, әллә шаяртасыңмы?

—Юк, һич кенә дә шаяртмыйм. Үзем дә аптырап калдым: нәрсә булды, ни ярамады ул хатынга? Үзем дә бер ахмак: ничә тиенемә кирәк иде миңа тол хатын? Эх, бу сукыр хисләрне... Әйтерсең лә кызлар беткән бу дөньяда.

—Да-а, парень, жәл.

—Нәрсә, жәл?

—Диләнең китеп баруы, дим. Хатын булса да, шәп хатын иде ул, кайсыбер кызларың бер якта торсын. Сиңа гына түгел, миңа да бик ошаган иде—яшермим. Да-а, жәл...—дип кайтып-кайтып уфтанды Тимеркәй.

—Күрәсең, беребезгә дә насыйп булмаган икән,—диде Данил үзенчә нәтиҗә ясап.

* * *

Фәридә Тимеркәй абыйсы янында өч көн булды. Уңган кыз абыйсы белән Данил эшкә чыгып киткәнче таңнан торып аларга ашарга әзерләде, чәен кайнатты. Алар чыгып киткәч якалары катып беткән күлмәкләрен, майкаларын юып, киптереп, төшкән сәдәфләрен тагып, үтүкләп куйды. Егетләр биреп калдырган акчага кибеттән ризык алып кайтты. Хәтта бистә кырыена чыгып болыннан зур бер бәйләм төрледән-төрле матур һәм хуш исле чәчәкләр дә өзеп керде һәм пыяла банкага су салып аны өстәл өстенә утыртты. Фәридәнең бу кыланышлары егетләрне таң калдырды. Бигрәк тә Фәридәнең уңганлыгына Данил сокланды.

Ниһаять, өчүләшеп алар кызның киләчәген дә хәл иттеләр. Моңа уңай форсат та чыкты. Нәкъ шул атнада Аккүл бистәсендә эшче яшьләр өчен Октябрьский нефть техникумының кечкә филиалы ачылды. Югары белемле яшь белгеч Данил Субаевны шул филиалны оештырышырга, аннары төп фәннәр буенча дәресләр бирергә чакырдылар. Фәридә дә шунда укый башлады. Данил аны үзләренең промыселларына лаборант итеп эшкә урнаштырышты. Кызга тулай торактан урын да бирделәр.

Тимеркәй дә шул ук филиалда укый башлаган иде, тик аны көзен хәрби хезмәткә алып киттеләр. Тимеркәйне поездга Бөгелмә вокзалына чаклы Данил белән Фәридә озата бардылар.

—Кара аны, Данил, Фәридә сеңлемне обижать итмә, саклап кына тор,—диде Тимеркәй.—Син аңа хәзер абый да, укытучы да, башкасы да...

Тимеркәйнең тел төбен аңлавы авыр түгел иде. Кыска гына вакыт эчендә тыгыз аралашу, бер-берсенең хәленә керү, уй-фикерләрне, дөнья мәшәкатьләрен уртаклашып яшәү аларның өчесен дә бик нык якынайтты. Белемле, төпле акыллы Данил белән өлгереп килгән, киләчәккә якты хыяллар белән яшәгән Фәридә исә бер-берсенә егет белән кыз буларак тартылдылар. Сөттән ак, кердән пакъ күңелле Фәридәдә шул айларда тәүге сөю хисе бөреләнде. Данил да бер мәртәбә янып-көйгән, хәзер инде тәмам акылга утырган, тормыштан сабак алган, сабырланган, «Миңа хәзер Диләә дә, Миләә

дә кирәкми, Ходай мине Фәридәдән аермасын, ул минем өчен гомерлек яр булсын»,—дип яшь башлаган иде.

Көзге көннәрнең берсендә яшь белгечкә фатир бирделәр. Данилның шатлыгы эченә сыймады. Һәм бу шатлыкны анын кем беләндер уртаклашасы килде. Кем белән? Кызганыч, Тимеркәй дусты армиядә. Ә, юк! Фәридә, Фәридәкәй бар ич...

Ул Фәриденең тулай торагына чапты.

Данилның Фәридәне эзләп бу тулай торакка тәүге килүе түгел иде. Фәридә юып, үтүкләп куйган күлмәк-майкаларын алырга еш килә ул. Кыз яңа гына эштән кайткан иде. Бүген чәршәмбе—укырга барасы юк, чөнки кичке укуга эшче яшьләр атнасына дүрт кенә көн йөриләр. Ашыгып-кабаланып килеп кергән Данилны күреп Фәридә аптырап китте, аның башыннан бер-бер көтелмәгән хәл килеп чыктымы әллә, дигән уй сызылып үтте.

—Киен әле, Фәридә, барасы җир бар,—диде Данил.

—Кая?

—Баргач үзең күрерсең.

—Куркыныч түгелме соң ул җир?

—Юк, юк, куркыныч түгел. Гаҗәп җир!

Абыйсына ышанган кебек ышанып йөргән Данилга ияреп чыгып китте кыз.

Шулай да:

—Кая барабыз соң инде?—дип сабырсызланды.

—Шүрәлеләр янына,—дип шаяртты Данил.

Яңа төзелеш барган квартал ерак түгел иде. Әле хуҗалар күченергә дә өлгермәгән, шуңа утлары да кабызылмаган ярымкараңгы ике катлы кирпеч йортның икенче катына күтәрелделәр. Данил кесәсеннән ачкыч тартып чыгарды да, капшанып ишекне ачты һәм утларны кабызып җибәрде. Буяу исе аңкып торган ике бүлмәле өр-яңа якты фатир иде бу. Патша сарае диярсең...

—Менә шул!—диде Данил Фәридәгә тантана итеп.

—Әллә синеке? Әллә сиңа бирделәр?—диде Фәридә шатлыклы елмаеп.

—Икебезгә бирделәр, Фәридә җаным, и-ке-без-гә!

Кыз бераз аптырап, уңайсызланып китте, бер кызарды, бер агарды. Дөрес, хәзер Данил гел аның күнелендә, ләкин болай ук тиз булыр дип уйламаган иде чишелешне. Данил исә тыныч иде, ул сүзен дәвам итте:

—Без хәзер икебез бербөтен. Мин беләм: син мине яратасың. Мин дә сине бик яратам. Әйдә, язмышларны бергә кушыйк, син миңа, мин сиңа гомерлек яр, терәк булып яшик. Миңа синнән башка кеше кирәкми.

Кыз башын күтәреп коңгырт-кара күзләрен Данилның зәңгәр күзләренә төбәде. «Барысын да дөрес сөйлисенме соң син, алдашмыйсыңмы, ышанырга буламы сиңа? Мин бит әле бик яшь, тормыш итәргә тәҗрибәм дә юк, укыйсым да, һөнәр-белгечлеккә дә тиенәсем килгән иде»,—дип уйланды ул.

Нәкъ шул уйларын белгән кебек, Данил, Фәриденә җилкәләреннән алып, янына тартып китерде.

—Икеләнмә! Укуыңны дәвам итәрсең, мин сиңа булышырмын. Һәрвакыт, һәрбер эштә булышырмын мин сиңа, кирәк дисәң, ант итәм. Ышанасыңмы?

Фәридә башта дикъкать белән аның күзләренә карап торды. Аннары: «Ышанам»,—дигән мәгънәдә башын селекте. Данил аны кысып кочаклады. Ике яшьнең кайнар иреннәре бергә кушылды.

## IX

Бер мең дә утыз җиденче буровойны Акташ авылы янына китереп утырттылар. Геологик карта буенча скважина авыл уртасында булырга тиеш иде. Шул ноктага авыл кырыеннан торып бораулап төшәргә булдылар. Бораулау бригадасы җитәкчесе, девон катламына кыеклап юл салу эшендә азау ярган, танылган оста Сафуан Тимәшев иде. Шул көннән башлап авыл халкының тыныч йокысы күккә очты. Буровой көндезен дә, төнен дә гөлдер-гөлдер, дөбер-шатыр килеп эшли, ә әрсез борау каты тау токымын кимерә, җимерә башлады.

Беренче метрларны үтеп, «кондуктор» дигән юан торбаны төшереп, цемент белән катыргач һәм эшне башлау мәшәкатьләрен тәмамлагач, бораулау остасы, һәрвакыттагыча, жинел сулап куйды. Хәзер инде даими бораулыйсы, жиргә тишек ясыйсы гына кала. Эш бетте, көлтә жыясы гына калды, дигән кебек инде бу, чөнки кыек скважинаны бораулау үзе бер мәшәкать: әледән-әле кирәкле азимутны билгеләргә кирәк. Моның белән, әлбәттә инде, оста үзе мәшгуль.

Бу эшләргә Сафуан инде күптән күнеккән. Ике дистәдән артык ел эчендә гади эшчедән, бөтен баскычларны үтеп, тәжрибәле бораулау остасы булып житешкән, шулар өстенә шактый вакыт курсларда белем алган Тимәшев эштә суда йөзгән балык кебек. Шуңа күрә эштә аның артык кайгысы да булмый.

Бүген Сафуанның бердәнбер борчуы—Сандра. Буровоен Акташ янына куйган көннән башлап ул яшьлек мәхәббәте—Сандра-Саниясе турында уйлый. Белә—ул шушы авылда. Тик йортлары кайсы тирәдә икән соң? Әллә ничек шунда бер очрашасы, күрешәсе, сөйләшәсе килеп китте аның гүзәл Сандра белән. Юк инде, аны эзләп йортына барып керергә жөрьәт итмәячәк Сафуан. Урамдамы, әллә кибет тирәсендәме очратса гына...

Шундый өмет белән берничә мәртәбә кибет тирәсен әйләнде ул. Юк, Сандра күренмәде. Бәлки танып та бетерми торгандыр? Егерме елдан артык вакыт узды бит инде аларның китүенә. Ә, юк! Моннан жиде-сигез ел элек шәһәр базарында очратты ул аны, ләкин сөйләшә генә алмадылар. Сафуан үзенең Мөршидәсе, Сандра исә Микулае белән иде. Бер-берсенә күз генә сирпештеләр. Сандра яшьлегендәге кебек үк чибәр, тик бераз юаная төшкән иде.

Беркөнне Сафуан кибет тирәсендә йөргән бер малайдан баш урманчы Микулай йортының кайсы тирәдә икәнлеген белеште.

—Әнә, абый, буровой бар бит?—диде теге малай бармагы белән төртеп.—Микулай абзыйлар нәкъ шул буровойга каршы, авыл кырыенда яшиләр...

Сафуанның исе-акылы китте. Була бит дөньяда гыйбрәтле хәлләр! Инде бер атна Сандра йорты каршында, аннан йөз-йөз илле адымда гына жир бораулый Сафуан бригадасы, ә ул аны әллә кайдан эзли. Юк, ул аларны әнә шул буровоеннан гына торып күргәләде дә әле. Яньчелеп беткән ак «Запорожец»ы белән хужасы кайтып-китеп йөри ул йортның, бер юан хатын, ана үрдәк кебек ике якка чайкалып, бер чыга, бер керә. Йорт каршында аларның еш кына әтәч-тавыклары, каз-үрдәкләре үлән ашап йөри. Вакыт-вакыт алар шул драндулетка икәүләшеп утырып китәләр. Микулай белән Сандра икән бит алар. Ә балалары кайда? Зур үскәннәрдер шул, читтә укыйлардыр...

Бер хәерле иртәдә, ак «Запорожец» чыгып киткәч, Сафуан шушы йортка барып керде. Һәм:

—Хужалар, мөмкинме?—дип эндәште. Челтәрләп-нәкышләп ясаган кәрнизле тәрәзәдән эчтә бер хатын күренде. Бераздан ул, болдырны ачып, ишек алдына чыкты.

—Кем кирәк сезгә?

—Гафу итегез, тавыкларыгызның күплеген күреп кергән идем мин. Бер-ике дистә йомырка сатмассыз микән? Без менә бу буровойда эшлибез,—диде Сафуан.

—Жомырка гына бар инде анысы,—диде Сандра һәм Сафуанга текәлеп карап тора башлады. Ниһаять, аның йөзе ачылып китте.

—Сапуан, бу син төгәлме суң? Мынатырак, жавыз... Жомырка сораган була тагын...

—Таныдыңмы?

—Танымый ни...

—Өйдә үзең генәме?

—Үзем генә булсам ни?.. Керик, әйдә. Курыкма, сине тотып ашамаслар. Безнең кайда жәшәгәнне күреп чыгарсың...

—Да-а-а,—дип сузды Сафуан.—Син дә, Сания, үзгәргәнсең. Минем хәтердә гел икенче Сания яши. Шулай да танымаслык түгел. Матурлыгыңны саклагансың әле, гәүдәгә генә бераз юанаеп киткәнсең.

—Син дә теге вакыттагы жегет-жилән төгел инде. Буең зифа иде, казер, аня, бөкрәя башлагансын. Буровой бөкрәйтәдер инде, авыр эш. Жөзең дә сырланган...

—Барысы да бар инде, Сания жаным, барысы да бар. Шулай да хәтердән һич чыкмыйсың. Кил әле, элеккечә бер кысып кочаклыйм әле үзенне шуның өчен,—диде Сафуан һәм юан, ләкин нилектәндер жинел гәүдәле Сандраны кочагына тартып алды. Сандра һич карышып тормады, яшьлегендәге тимерче кочагына рәхәтләнеп кереп посты. Ә үзе:

—Жук, жук, Сапуан! Жанымны да, тәнемне дә кожгытма,—дип ризасызлык белдергән булды.—Болай да гүмерем буе синен азапларын менән жәшим, синен турыда уйлыйм, сине сагынам, гүмерем буе синнән тапкан балаларны жаратып үстердем. Жаным болай да күп таланган. Гүмер жулымда син очрамаган булсаң болай таланмас иде...

Сандра, йомшарып китеп, яшьләренә тыгылды. Ләкин, Сафуанның кочагыннан чыгарга омтылып та карамады. Ә Сафуан теге еллардагы кебек үк кайнар тәнле яшьлек сөяркәсенең аркасыннан сөйде, битенә агып төшкән яшьләрен сөртте. Тик бер сүз дә эндәшмәде.

Бераздан Сандра сүзен дәвам итте:

—Шунда алам димәден бит. Алам дигән булсан, Микулайдан китәдер идем дә, сине генә жаратып жәшидер ийем. Жавыз! Беләм, керәшен катыны дип алмадын син мине...

—Син нәрсә, Сания! Мин Микулайның законлы хатыны, аны ташламыйм, аны рәнжетмим, диден ич. Анысы, икенче яклап, син дә хаклы. Бар ул безнең мөселман татарларында керәшеннәрне өнәп бетермәү. Керәшеннәр үзләре дә мөселман татарын өнәмиләр, югыйсә кайчандыр үзләре дә ислам динен тоткан булсалар да. Бер ата, бер ана балалары гасырлар үтү белән бер-берсен күрәлми торган кавемгә әйләнгән. Шушы дошманлык аны милләт, халык буларак бөлгенлеккә төшергән. Безнең татардан да таркаурак милләт юктыр, бер-берсен ашарга гына торалар. Кодрәтемнән килсә, мин жир йөзендәге барлык татар халкын бергә жыяр идем дә: «Сез онытмагыз үзегезнең бөек халык икәнлегегезне, дус, тату, бер-берегезгә сыенып, ярдәмләшеп яшәгез, бер-берегезне рәнжетмәгез. Тәнегездә менәрчә еллар иксез-чиксез далаларны тетрәткән төрки бабалар каны акканын онытмагыз. Ә мин сина, Сания жаным, беркайчан да кимсетеп карамадым. Сине үлеп яраттым мин! Бүген дә шул яратуым, шул хис белән юанып яшим.

—Үзем дә бик жаратканыйем шул, Сапуан бәгърем, үзем дә бик жараттым. Казер мына шушынын гөнаһлары, грехлары менән, гөнаһ шонныгы булып жәшибез!

—Нинди гөнаһ, Сания жаным?

—Икебез дә, Сапуан бәгърем, икебез дә. Әнә, Данка синен Даимәне алып кайтканыйе. Ике көн Якты аланда, кордонда кунып-төнеп жаттылар. Ир белән катын кебек. «Без бер-беребезне жаратабыз»,—диләр. Курлык бит бу!..

—Тукта әле, Сания. Каян килеп чыкты соң Даимә? Ул бит тормышта, отставкадагы полковник анын ире, кайдадыр Уралда.

—Үлгән бит инде ул палкауник. Әллә шоны да белмисен?

—Йа Хода! Каян белик без аны? Ул кыргый кыз безгә инде менә ничәнче ел үпкә белән яши. Шул карт полковникка чыгуына ачуланган идек. Шуннан бирле ул безнең барлыкны да белергә теләми. Бер киребеткән нәрсә булды. Кайда очрашканнар-танышканнар соң алар Данил белән?

—Аккүл бистәсендә. Данка бит нефть институтын бетерде. Шонда аны эшкә жибәрделәр. Даимә дә ире менән шунда жәшәгән. Иренен үлгәненә әле ун гына көн. Шул арада, әнә, чыдые да беткән, өстерәлә дә башлаган. Данканы әйтер иен... Чытырлый жабышкан.

—Менә сина мә, Сафуан! Иске авыздан яна сүз. Ишетмәсәң ишет, киле тишек!—дип, үз-үзен битәрләп ташлады Сафуан.—Хәзер кайда инде алар?

—Күптән түгел китеп бардылар.

—Сон син анлаттынмы аларга берәр нәрсә?

—Анлаттым! Курлык булса да сүләп бирдем барысын да. Әйттем: сез икегез бер атадан, аналарыгыз аерым булса да, дидем. Инде казер корсагын да күтәрсә... Курлыгыннан кая барырбыз? И-и, Кодаем, грехларымны жарлыкасана!...

Сафуан белән Сандраның очрашуы күнелле генә башланган иде. Ташкын кебек бәреп аударырдай яналык икесенә дә үтергеч тәэсир ясады, зиһеннәрен бутады, кәефләрен төшерде. Шулай да Сандра Сафуанга бер иләк йомырка тоттырып чыгарырга онытмады. Тегесе: «Мин бит сылтау ясап кына сораган идем, берниндн дә йомырка кирәкми, йомыркадан үтте монда»,—дип маташкан иде, Сандра тәмам үпкәләде:

—Әллә минем сина, жаратканыма, жомырка бирерлегем жукмы?—дип, этә-төртә биреп чыгарды. Аннары буровойга таба китеп барган Сафуан артыннан моңаеп карап калды. Сафуанның кабат пәйда булуы аның күнелен кузгатты, сагышларын көчәйтте, хисләрен яңартты. Ярты гомер бит инде аларның очрашып бер-берсенә сүз дә ката алганнары юк иде. Бар икән Ходай: Сандра төшендә ак ат күргән иде. Әрәмә ягыннан бик матур, бик пөхтә ак ат килеп чыкты да, кешни-кешни аларның киртәләре янына килде һәм шул киртәгә башын салып тәрәзәләренә карап торды. Сафуан белән очрашуга, күрешеп сөйләшүгә булган икән бу матур төш. Иллә дә ягымлы, иллә дә күнелгә житкереп, рәхәт сөйли белә аның Сафуаны. Сүз саен: «Сания, жаным»,—дип кенә тора. Сагынырсың да шул!..

Буровоена житкәч, Сафуан артына борылып карады. Сандра һаман да капка төбендә алъяпкычына кулларын төреп баскан килеш, аның ягыннан күзен алалмый тора. Сафуанның чиктән тыш күңеле булып куйды: сөйгәне басып карап калды ла!.. Кулын изәргә теләгән иде, буровойда вахта торган эшчеләрнең күреп әлләниләр уйлаулары бар дип, кулын күтәрергә кыймады, сагышлы карашын Сандра ягына тагын бер кат ташлады да, будкасына кереп югалды. Сандра бу минутта: «Нигә инде, тагын кер, дип әйтмәдем шунда»,—дип үзен битәрләп алды. Аннары әкрен генә жырлап жибәрде.

Француз жаулык киштәдә,
Бөгелә дүрткә, бишкә дә шул;
Синең белән бергә булу
Кермәс инде төшкә дә шул...

Шулай үз жыры белән үзе моңланып, төрле уйлар уйлап, сагышланып Сандра әле тагын күпмедер басып торды. Күзләре һаман буровой ягында иде. Сафуан чыкмасмы, тагын күренмәсме, дип басып торды ул. Тик Сафуан... Ул бу вакытта Сандрасын будка тәрәзәсеннән күзәтә иде. Тәрәзәгә бик үк якын килмичә, будка уртасында басып торган килеш күзәтте ул аны. Капка төбендә кулларын һаман алъяпкычына төреп баскан килеш тора да тора аның Сандрасы. Бигрәк куанычлы була икән якын кешеннән шулай синең тарафтан күзләрен алалмыйча карап торуы! Якын, бик якын, үз икән бит алар бер-берсенә. Аерылышуларына никадәр вакыт үткән, ләкин барыбер якын! Якын булмыйни?! Икесенең үсеп житкән, уртак балалары—йөрәк парәләре әнә дөнья инләп киләләр. Берсе ВУЗ тәмамлаган, икенчесе дә укый. Бер-берсен чын күнелдән яратып, кайнар сөеп, икесенең дә ризалыгы, теләге белән дөньяга аваз салган балалар. Шуна да Сафуан торып-торып Сандрасы турында уйлый. Әйе, Сандра-Сания аның тормышының иң татлы, иң серле, иң кадерле, мәңге онытылмас мизгеле. Сафуанның беркайчан да, беркемгә дә Сандра-Саниягә булган кебек ташкын хисе булмады. Шуна күрә дә ул аны оныта алмый, бөтен уйлары-хыяллары әнә шул яшьлек мәхәббәте, аяз күк кебек зәңгәр күзле, алсу-ак йөзле, якты елмаюлы Сандрасы турында. Бүген исә Сандра аны тагын гажәпкә калдырды: ул да Сафуанны уйлап яши икән бит. «Болай да гүмерем буе синен азапларын менән жәшим, синен турыда уйлыйм, сине сагынам, гүмерем буе синнән тапкан балаларны жаратып үстердем...» Яратмаса, шулай дияр идеме ул?..

Ах, язмыш! Бар күңелен биреп яратышкан-сөешкән, ләкин кавыша алмый калган, гомер буе йөрәге тулы сагыш, эче тулы моң белән яшәгән кешеләр бер Сафуан белән Сандра гынамыни бу дөньяда!?.

Агыйделкәйләргә безләр төшәрбез,
Колачларны җәеп йөзәрбез;
Кычкырыр да кәккүк, сайрар былбыл—
Шул чагында ничек түзәрбез?

Сары ла чәчәк ата көнбагыш,
Сөйгәннәрне уйлау куаныч.
Җанкашларны сагыну куаныч...

Моннан соң да Сафуан тагын, тагын күрер әле Сандраның капка төбенә чыгып басканын һәм монсу күзләрен төбәп, үзенең дә, Сафуанның да йөрәген яндырып, аның шаулы буровоена карап торганын...

## X

Бу вакыйгадан соң да шактый күп җилләр исте, кар-яңгырлар яуды, сулар акты. Көмешсу елгасында да сулар бер шаулап, бер тын калып, гүя уйланып, аның матурлыгына сокланып туялмаган кешеләрне монсуландырып-сагышландырып акты.

...Талгын, җылы җилле көзге көн. Әйе, көзен дә була шундый рәхәт, җылы, коры көннәр. Соңгы яңгырлардан соң һава аязып китте дә, кояш нурлары, көньяктан искән әрсез җил белән җир өсте кипшенергә дә өлгерде. Шулай да Даимә юлга чыгар алдыннан кыска куныччлы итекләрен киде. Аның елга буена чыгасы, тауга менәсе, урманда йөрисе бар иде.

Аның яшьлек әрәмәсе танымаслык булып үзгәргән. Әле егерме биш-утыз ел элек кенә Көмешсу буенда шаулап үсеп утырган биек-биек тал-тирәкләрнең хәзер эзе дә юк. Ах, гомерләр! Куе таллык, баланлык, гөлҗимеш куаклары белән капланган, сыер хәтле сыер кереп югалырдай үлән шаулап үскән, киек казлар, башка күп төрле кош-корт авазы белән ямьле булып хәтердә сакланган әрәмәне бөтенләй бозганнар, үзгәрткәннәр, елга буена әллә ниткән корылмалар төзеп бетергәннәр, саф сулы, моңлы Көмешсуны буып, болганчык бер сусаклагыч иткәннәр.

Даимә туктап, сагышлы карашын тагын сусаклагыч өстенә ташлады. Алар үскәндә чыр-чу килеп су керә торган тирәкле яр да су астында калган. Ай, карт та иде соң ул тирәкләр! Мәһабәт биекләр, тирән тамырлылар, көчлеләр. Тармаклары да бөтен Көмешсу өстен, аның яр буйларын каплап тора, хәтта көчле яуган яңгыр вакытында да алар астында ышык була иде.

Әле шул тирәкләргә бәйле бер фаҗига да хәтерендә Даимәнең. Сөйгән гармунчы егетеннән алданган, авырга калган Маһинур исемле бик матур бер яшь кыз әнә шул карт тирәкнең берсенә асылынып үлгән иде. Гарьлеге көчле булган күрәмсен, бичараның. Ә хәзерге кызлар...

Даимә Көмешсу елгасы аркылы салган зур таш күперне чыкты да, тигез асфальт юл кырыеннан Аю төбәге тавына чаклы җинел генә үтте. Күңелендә сагыш булса да, адымнары ышанычлы иде аның.

Аю төбәге тавы текәрәк. Текә булса да, балачакта күрше кызлары һәм малайлары белән йөгерә-йөгерә, ярыша-ярыша менәләр иде алар. Ә хәзер йөгерү түгел, атлап менүләре дә җинел түгел икән. Даимә тау битендә астан тырпаеп торган үткен ташларга, йә булмаса көчле тамырлы үләннәргә тотынып-таянып, ике атлап бер ял итеп, тирә-юньне күзәтә-күзәтә, мышный-мышный үҗәтлек белән тауга менүен дәвам итте.

Әлеге тау башына менеп төшү—аның күптәнге хыялы иде. Түмән якларында, Уренгойда яшәгәндә үк бу турыда еш уйлый иде ул: «Кайтып житә алсам, бер түгел, йөз мәртәбә менеп төшәр идем яшьлек тавыма. Ялгыз каеным гына исән булсын иде. Исәнме син, ялгыз каеным, җан дустым?!».

Балачак, яшьлек еллары бигрәк сагындыра икән шул. Чит җирләрдә яшәсәң, сагынуларың тагын да көчлерәк була икән! Шуңа да бит инде, Түмән сазлыкларын ташлап, туган-үскән якларына ашкынып-талпынып, эче тулы сагыш, мон-зар белән кайтып егылды ул.

Фатирны ана бердәнбер туганы Акчәчәк тә эзләште. Белдерүләр буенча бармаган, карамаган йорт калмады. Акчәчәк күзлегеннән чыгып фикер

йөрткәндә, ярыйсы гына, чиста урамнарда һәрьяклап унайлыгы булган фатирлар таптылар, карадылар алар. Арада Даимәгә ошаганнары да булды, тик ул алырга ашыкмады. Күнеле тулысы белән кабул итмәде ул фатирларны. Апасының артыгы белән сайлануыннан күнеле кайтып, Акчәчәк тә эзләшергә чыкмый башлады.

Ниһаять, бер көнне Даимә кош тоткан кебек кайтып керде. Шәһәр читендәге биш катлы йортның өченче катында иде ул фатир. Акчәчәк килеп карады да:

—Нәрсәсе белән ошады инде сина бу җәһәннәм тишегендәге иске куыш? Ни автобус, ни троллейбус йөри торган жир түгел. Якын-тирәдә рәтле кибет кенә дә юк. Тапкансың... Ичмасам тәрәзәләре көньякка, кояшка караса иде,—дип тезеп китте.

Даимә сенлесен бүлдермәде, моңсу күзләрен аңа төбәп, сөйләп бетергәнен көтте. Аннары торып сүзсез-нисез генә аның кулыннан барып алды һәм олы тәрәзә янына китерде.

—Әнә, кара әле, сеңлем!..

Тәрәзә каршында, әйтерсен лә кул сузымында гына, искиткеч матур күренеш иде. Тоташтан диярлек урман белән капланган, аскы ягы гына киртләч-киртләч кәжә сукмагы белән сызгаланган Аю төбәге, Кызлар тавы, иң биек тау башында мәһабәт ретрансляция манарасы, сулдарак сабантуй мәйданы...

Ике кыз туган, һич эндәшми, шактый вакыт шул манзараны күзәттеләр, уйландылар. Аннары Даимә телгә килде:

—Мин канаты каерылган, бичара ялгыз хатын, һич югында шул урманга карап, көч алып, аз-маз булса да рухланып яшәрмен. Минем балачагым, яшьлегем таулары алар...

—Минеке дә инде,—диде Акчәчәк.

—Шулай—синеке дә. Ләкин синең тормышың минеке кебек сикәлтәле булмады. Шөкерана кылып яшә: үскәндә тәртипле булдың, ирең әйбәт, балаларың—йөрәк парәләрең, күз тимәсен, янында. Шуна күрә бәлки мине аңлап та бетермисеңдер...

Акчәчәк акылсыз хатын түгел иде, апасының йөрәк ярасына кагылуын тиз аңлады.

—Гафу ит, апа, гафу ит! Мина үпкәләмә, чыннан да аңлап бетермәгәнмен. Игелеген күр фатирыңның! Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең ботак тишеге, дип бер дә юкка гына әйтмиләрдер. Минем дә күңел күзем күреп житкермәгән икән—бигрәк матур күренеш ачыла тәрәзәңнән. Бәхет алып килгән булсын фатирың...

Даиманең «Рәхмәт!» дип әйтерлек көче калмаган, яшенә тыгылган иде—башын гына селкеп куйды...

Фатирга күчеп, тынычлап яши башлаганнан бирле ул тәрәзәләреннән китми хәзер. Олы бүлмәгә керәме, ашныкынамы яки йокы бүлмәсенәме—аның күзләре гел урман, таулар ягында. Гел сихерләре бар диярсең шул тауларның.

—Менә, өемне тегеннән-моннан төзәтеп, агартып-юып, аз-маз жиһазландырып та жибәрсәм, бер менеп төшәрмен инде. Һич вакыт житми бу дөньяда. Югыйсә, әллә кайчан менеп төшәсе иде...—дип сөйләнә иде Даимә эш арасында.

Инде хыялына ирешә бугай. Көч-хәл белән үрмәләп менә-менә, ул, ниһаять, тауның иң текә жирен үтеп, беренче түбәсенә аяк басты һәм хәл алырга утырды. Бу түбәдә алар балачакта да шулай утырып ял итә торганнар иде. Ял итә-итә өстән торып көзге кебек ялтырап, бормалы-сырмалы аккан Көмешсу елгасын, яр кырыенда утырган балыкчыларны, әрәмәдә утлап йөргән атларны, сыер, сарык, кәжә көтүен, көтү артыннан озын чыбыркыларын шартлата-шартлата йөргән көтүчеләрне, алар тирәсендә һау-һау өреп чабышкан йөнтәс маэмайларны күзәтә торганнар иде. Хәзер, әнә, аста бернинди ат та, сыер да, бозау да, сарык-кәжә дә, хәтта әрәмәнең үзе дә юк, асфальт юлдан жансыз машиналар гына каядыр ашыгып чабыша...

Беренче тау түбәсеннән ул тагын да өскә таба атлады һәм тагын тигезлеккә килеп чыкты. Монда инде имәнлек башлана. Элек куе урман

булып утыра иде бу иманлек, хәзер, әнә, ул да сирәгәйгән. Кайдадыр шунда Даимәнең яраткан каены булырга тиеш, әгәр исән торса, комсыз бәндәләр кисеп алып китмәгән булсалар. Ул эчкәрәк атлады, тик яраткан каены күренмәде. Юкмыни? Даимәнең йөрәге дөпелдәп тибә башлады—дулкынлана иде ул. Текә тауны менгәндә дә болай дөпелдәмәгән иде аның йөрәге. Юкмыни соң инде аның сердәш каены, шулай ук башына життеләр микәнни?

Шундый шомлы уйлар белән ул тагын берничә адым алга атлады һәм... Йа, тәнре! Даимә алдында кинәт ачылып киткән бәләкәй алан уртасында Ул—аның мәһабәт ак каены—соңгы сары яфракларын жилдә жилфердәтеп басып тора иде. Ничә еллар аның сердәш дустын күргәне юк! Ул да, әнә, танып булмаслык булып үзгәргән, күккә ашкан, ныгып, юанаеп киткән, чын-чынлап куәтле агачка әверелгән. Хәтта тирә-юнендә үсеп утырган иманнәрне дә күптән буйга узып киткән һәм аларга өстән генә карап тора сыман. Иман урманына ничек килеп эләккәндер ул каен—бусы билгесез.

Даимә, күптәнге танышын кочаклап алган кебек, ак кәүсәле каенга барып сыенды.

—Исән-саумы, каеным? Бу мин—синең мәнге гөнаһлы Даимә сердәшең. Дөнья читендә кангырып, кагылып-сугылып, михнәт чигеп, бер чеметем ләззәткә алданып йөрдем-йөрдем дә, тагын туган төбәгемә, сиңа әйләнеп кайттым. Кичер мине, шулай озак йөргәнем өчен! Кичер мине, барысы өчен дә... Сине бик сагындым, гел искә төшереп тордым үзеңне. Бик күрәсем килде. Сөйлисе серләрем дә күбәйгән иде...

Даимә каен төбенә шуып төште дә, ана аркасы белән утырды. Ә күзләреннән тыелгысыз кайнар яшь түгелде.

...Бар, бар иде аның кайгысыз, яшьнәп торган чаклары. Авылда бер данлыклы, сылу кыз иде бит ул. Йөзе алсу, күзләре карасу-зәңгәр, бөжра-бөжра кара чәчләре маңгаена, ә ике калын толымы тез астына чаклы төшеп тора һәм егет-жиләннең күнелен алгысыта иде. Гәүдәсе коеп куйган кебек, аяклары төз. Мәктәптә иң яхшы укучыларның берсе иде...

Тик кыз артык иртә яшьлек һавасына, яшьлек дәртенә бирелде һәм шуның белән бөтен киләчәген бозып ташлады. Югыйсә, аның да бар күңелен салып сөйгән егете булырга тиеш иде. Тиеш түгел, бар иде ул. Кем иренми, шул аның кулыннан тотып алып киткән вакытларда ул еш кына сыйныфташы Фәриткә күзен теки иде. Кара туткыллы, олы күзле, буйчан һәм шаян сүзле шул Фәрит аңа барысыннан да күбрәк ошый иде. Ачык күңелле, жылы, ягымлы итеп сөйләшә, кешегә ачу саклый белми, барысына да дустанә мөнәсәбәттә, шаркылдап, рәхәт итеп көлә. Фәритнең шулай көлүеннән дә әсәрләнә иде Даимә. Тик Фәритнең күңеле... Даимәнең күршесе, ахирәте Рәхиләне яратты шул ул. Рәхилә үзе дә моңа лаек иде. Тыйнак, тотнаксызлыкны сөйми, егетләргә күз сирпеп тә карамый. Аның үзенең дә яратканы бер Фәрит кенә булды, башкалардан кулын тоттырмады. Шуның белән дуслыклары, мәхәббәтләре нык булды да аларның. Урта мәктәпне тәмамлагач та бергә медицина институтына киттеләр, бергә диплом алып, бер хастаханәгә эшкә кайттылар, өйләнештеләр, балалар үстерделәр, үзләре дә табиб булараk та, житәкче булараk та үстеләр. Фәрит инде әнә, озак еллар баш табиб булып эшли икән. Абруйлы, мактаулы исемнәргә лаек булган баш табиб.

Ә Даимәнең гомере заяга узды. Югары уку йортында да укый алмады ул, яраткан эше, шөгыле дә булмады, шактый ир-атның якасын иснәштереп, берничә тапкыр иргә чыгып яшәвенә карамастан, бала табу, бала тәрбияләп үстерү бәхетенә дә ирешә алмады. Юк, сыйныфташлары, ахирәтләре, күршеләре, таныш-белешләре көнләшерлек тормыш насыйп булмады аңа. Адәм баласының гомер кояшы аска тәгәри башлагач, иң үкенечлесе дә шул була икән...

Соңгы вакытта Даимә үзенең ачы үткәне, көйсез тормышы турында еш уйлана: «Нидән болай килеп чыкты, нигә тормышымның рәте булмады, нигә бәхет читләтеп үтте?» Югыйсә, житди кыз иде бит ул, ихахай да михахай итеп кенә үсмәде, максаты да, омтылышы да юк түгел иде. Хәзер ул тормышының асты-өскә килүенең төп сәбәбен янында үз анасы булмаудан,

ана күрмәүдән дип саный. Үги ана—үги ана инде ул, гәрчә Мөршидә аны һич тә тибәрмәде, какмады-сукмады. Үз карынынннан чыккан Акчәчәкне ул ничек теләсә шулай бөкте, ә өч яшендә анасы ташлап калдырган Даимәне кызганды, холыксызланган вакытында да ана тавышын күтәрмәде, гел җаена гына барырга тырышты. Дөрес, Даимәгә дә, Акчәчәккә дә әйтәсен әйтә килде ул: «Кызларым, егет-җилән тирәсендә сак булыгыз, аларның төче телләренә ышанмагыз, итәгегезне җыеп йөрегез, йөзебезгә кызыллык китермәгез!..» Ләкин Даимәгә ул барыбер йомшак булды. Ире Сафуанның дәгъвасы, ризасызлыгы булмасын, син аны рәнҗетәсең дигән сүзенә сәбәп тумасын дип йомшак булды ул. Бәлки аның шулай итүе ялгыш булгандыр? Даимәсенә дә, Акчәчәгенә дә тигез карыйсы, икесенә дә тигез тәрбия бирәсе булгандыр? Әнә бит, соныннан үги ананың кайгыртучанлыгын санга сукмавы беленде Даимәнең. Көйсез, назлыбикә, үз дигәненчә генә эш итәргә яратучан, башбаштак, үз-үзен генә яратучы—эгоист кыз булып үсте. Хәзер ул бу турыда яхшы аңлый да бит, тик терсәкне тешләп булмый, соң.

Үскән чакта күрше хатыннары Даимәгә: «Син әниеңә—Гөлмәрфугага охшагансың»,—дияләр иде. Ул вакытларда Даимә анасының төсен-битен төштә күргән кебек кенә хәтерләп калган иде. Күршедә генә яшәгән Фәтхетдин бабасы белән Бибисара әбисендә сакланган фоторәсемнәргә еш карый иде Даимә һәм үзенең анасына охшаганлыгын да таный иде. Ләкин аннан ни файда? Җиткән кыз булып үскәнчегә кадәр ул аны бер генә тапкыр да күрмәде ич. Анасының өч яшендә ташлап калдырган сабыен кайтып күрәсе, аның белән аралашасы килмәде, күрәсең. Әллә ул аны кирәк дип тә тапмадымы? «Әни!» Бу сүзне ул үз анасына түгел, үги анасына әйтеп үсте һәм еллар үткән саен үзен кадерләп үстергән үги анасы белән арасы суына, ераклаша барды, ә Даимәнең күңеле, нилектәндер, тик төшендә генә күргәндәй хәтерендә калган үз анасына тартылды. Беркөнне кайтып төшәр дә: «Кызым, мин кайттым, сине сагынып, сине күрергә кайттым мин!»—дияр, кысып-кысып кочаклар, үбәр, назлар сыман иде. Тик ул кайтмады да, күренмәде дә, назламады да.

Бөкре Фәтхи йортына кереп йөрүдән тыймадылар Даимәне. Фәтхи карт үзе дә, Бибисарасы да оныкларына аерым игътибар күрсәттеләр. Картлык көннәренә бөтен өметләрен баглаган кызлары азгын сиернең үгез артыннан чыгып чапканы кебек качып киткәч, аларның бар юанычлары булып Даимә калды.

—Кияү, синең каршыңда безнең мыскал да гаебебез юк. Зинһар өчен, бердәнбер юанычыбыз булган Даимәбезне яратудан безне мәхрүм итмә,—диде Фәтхи Сафуанга. Киң күңелле, йомшак бәгырьле тимер остасы артык сүз катмады, ризалыгын белдереп башын гына какты. Шуннан бирле бала ике йортта үсте, дисәң дә ялгыш булмас. Ләкин бабасы белән әбисе дә, йөрәк җылысы бирәбез дип, Даимәне артык иркәләделәр дә, узындырдылар гына, кирәкле тәрбия бирә алмадылар. Ә Сафуанның кызына игътибар итәргә вакыты җитмәде: буровое, җаваплы эше белән мәшгуль булды. Акчасын җитәрлек алды, гаиләсен туендырып-киендереп торды, әмма үсеп килгән олы кызын күз уныннан ычкындырды. Хәтта Даимәсенең азынып-тузынып, һәр ым ясаган ир-егеткә ияреп китүе турында да ул соңлап кына ишетте һәм эчтән генә Гөлмәрфуга белән үзен битәрләп алды: атасы белән анасына охшамыйча бала кемгә охшасын соң? Үзебез гаепле...

Анасын күрәсе килеп, шул турыда хыялланып яшәгән кызның үсә-үсә анасына үпкәсе генә арта башлады: «Ана түгел, җансыз, каты бәгырьле бер нәмәстә икән. Тәнендә җаны булса, кызын күрергә бер кайтыр иде...»

Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән кеше кайчан да булса бер очраша. Даимә дә анасы белән бер очрашты. Аның урта мәктәпне тәмамлап апаларына, Уралга барган елы иде ул. Институтка керергә теләп имтиханнар биреп йөргән мәшәкатьле көннәре. Шунда апаларына кырык яшьләр чамасындагы саргылт йөзле, арык гәүдәле, гади генә киемнән бер хатын килеп керде. Апасы аны ачык чырай белән каршы алды, түргә утыртты. Ә теге хатынның күзләре гел Даимәдә. Шунда кыз бу көтелмәгән кунакның анасы булу ихтималын сизенде. Сизенде дә, унайсызланып китте. Юк, үзе өчен түгел, әлеге хатын өчен унайсызланды. Өстендә унып беткән иске

соры плащ, бөгәрләнгән яшькелт күлмәк, аягында үкчәләре ямьшәеп торган туфлиләр. Җыерчыклы саргылт йөзеннән нур качкан. Карашы—салкын.

Апасы чәй куеп, өстәл әзерләде. Ләкин Даиманең бу нурсыз йөзле, өметсез карашлы хатын белән аралашасы килмәде—икенче бүлмәгә кереп, китаплар караштыра башлады. Шунда апасы кереп:

—Әйдә инде, эреләнеп утырма, анаң килгән бит,—диде. Даимә аптырап китте, ләкин коелып төшмәде.

—Анам?

Ул кабат олы бүлмәгә чыкты. Бу вакытта теге хатын да торып баскан, күзләре бераз очкынланган иде.

—Кызым... Наныем... Бәгырь кисәгем...

Ул кулларын сузып, Даимәгә таба килә башлады. Ләкин мондый төче телгә күнекмәгән, бу сүзләр артында ярылып яткан ясалмалылыкны таный белгән Даимә баскан җиреннән кузгалмады, кулларын күтәреп: «Якын килмә!» дигән ишарә ясады да, гаҗәпсенгән йөзен бер якка борды. Аннары:

—Туктагыз әле, апа, сез ялгыша торгансыздыр,—диде.

—Юк, ялгышмыйм, син минем Даимә кызым...

—Әйе, мин—Даимә. Ләкин миңа ана булырга тиешле кеше мине өч яшь тә тулмаган килеш, сөяркәсенә ияреп, ташлап качкан. Шул миһербансыз бәндә сез мени инде?

—И, кызым, алай ук каты бәгырьле булма инде...

—Ә соң сез каты бәгырьле булмадыгызмыни балагызны ташлап качканда?

—Анысы тәкъдир инде, кызым...

—«Кызым» димәгез миңа. Сезнең миңа «кызым» дип әйтергә хакыгыз юк. Тәкъдир, имеш... Бик җиңел юл тапкансыз акланырга. Мин хәзер үземне белә башлаганнан бирле кемгә чын күңелдән, өзелеп, йөрәкне эретә торган «Әни» сүзен әйтергә белми сыкрап йөрим, ә сез миңа каты бәгырьле булмаска кушасыз. Йә, әйтегез: кем катырды соң минем йомшак бәгыремне шушы елларда?!

Өйдә тынлык урнашты. Чит хатынның чырае сытылды, йөзе ямьшәйде, аннары ул хәлсезләнеп урынына утырды һәм йөзен кулындагы яулыгы белән каплады. Вөҗдан газабы кичерү галәмәте идеме бу, юкмы—Даимә төшенеп җитмәде.

Сүзгә апасы кушылды:

—Ярар, Даимә, тынычлан, кызма алай ук, җәзалама ана...

Ул: «Ананны»,—дип әйтергә теләгән иде, ләкин бу сүз Даимәне чыгырыннан чыгарыр дип:

—Җәзалама кешене,—дип төзәтте.—Ул үз җәзасын җитәрлек алган инде...

Бар очрашу-күрешү, бар сөйләшү-аңлашу әнә шул булды. Аның бөтен нечкәлекләре хәзер Даимәнең исендә дә калмагандыр. Ә менә апасының соңыннан сөйләгәне хәтердә.

—Минзәки белән биш-алты ел гына бергә яшәгәннәр, ни сәбәптәндер, теге бәрәнге борын куып чыгарган ананны. Аннары ул тагын берәү белән яшәп караган, тик анда да озак төпләнә алмаган. Хәзер, әнә, эшли торган эше, яшәргә урыны, ашарга ризыгы юк мескеннең... Син дә инде... Начармы-яхшымы, күкрәк сөтен имезеп үстергән бит ул сине. Дөрес, син дә хаклы, ялгышкан инде, ялгышкан. Зәкинең тасма теленә ышанып ялгышкан. Бәрәңге борын!.. Кая да булса эшкә урнаштырышмый булмас инде ананны...

Даимә анасы белән эре-тере сөйләшүенә соңыннан бераз үкенеп тә алды. Ул гына да түгел, Даимәдә ана карата кызгану хисе дә уянды, хәтта тагын бер очрашасы, яхшылап аңлашасы да килгән иде. Тик шушы хәлдән соң ул, әнә, полковникка тормышка чыгып, авариядән соң апалары белән элемтәне югалтып, Аккүлгә кайтып, аннан да Түмән якларына чыгып китеп, тагын бер иргә кияүгә чыгып, аның белән дә аерылышып, озак еллар ялгыз яшәп, ниһаять туган якларына кайтып егылды. Тик анасының, апаларының язмышын бүгенгәчә белми яши ул. Һәм шуны белми яшәү дә Даиманең күңелендә җуелмас бер төер булып тора. Анасы белән уртак тел табып, чөкердәшеп бер сөйләшә алмадылар алар—шунысы аяныч...

Даиманең уйларын кинәт шартлап сынган бер ботак бүлде. Ул сискәнеп торып басты һәм кабат карт каенның юан кәүсәсенә сыенды:

—Кичер мине, каеным, кичер...

Карт каен, тын калып, анын зарын тынлады.

Кин күнелле, юмарт, бөдрә карт каен аны бәлки кичергәндер дә. Тик әле каеннардан да, таулардан да, болытлардан да өстәрәк Кодрәтле көч бар диләр бит. Даимә ул турыда әллә оныткан, әллә аны танымый, әллә бөтенләй белми иде—ялвару авазын Ана салмады. Эче тулы моң-зар, кайгы-хәсрәт белән тирән уйга батып, ул сердәш каены төбендә утыра бирде. Хәтта әллә нидән көн караңгыланып киткәнен дә сизми, абайламый калды. Көчле жил исеп, урман шаулый башлады. Карт каен да, айнып киткәндәй, искән жилдә канат-кулларын жәеп, чайкалып-чайкалып алды. Өстән шыбырдап эре-эре яңгыр тамчылары төште. Шунда гына Даимә кинәт уйларыннан арынып китте һәм, хәтәр буласын сизгәндәй, башын күтәреп өскә карады. Өстә, анын сердәш каены һәм имән башларына кагыла-сугыла, могжизалы кара болыт әйләнә-тулгана, куера һәм кайный иде. Ул шулкадәр кара, шулкадәр дәһшәтле һәм куркыныч иде—Даимәнен йөрәге жу-у итеп китте. Шул куркуыннан каушап, нәрсә эшләргә дә белми аптырап калды. Югыйсә урманнан чыгып, тау астына төшәргә, хәтәр жирдән тизрәк һәм ераккарак китәргә, ашыгырга кирәк иде ана. Ә ул гипнозланган кеше сыман һаман бер урында таптана. «Язмыштан узмыш юк...» Нишләптер, кинәт, гомере буе әледән-әле кабатлаган шушы сүзләр килде Даимәнен башына соңгы минутта. Шулай ук анын язмышы да кыл өстенә куелган мыни инде? Ах, бәрәкәтле, матур, мәгънәле тормыш итеп булмады. Әгәр Ходай гомер бирсә, бәлки бу хатаны азмы-күпме төзәтергә дә мөмкин булыр иде. Гомерне генә бирсен...

Шул мизгелдә кайнап торган кара болытны икегә-өчкә телгәләп, бөтен жиһанны мәхшәр утына чолгап яшен яшнәде. Дәһшәтле чытырдау һәм көчле шартлаудан жир калтырап, тетрәнеп куйды, тау селкенеп торды. Карт каен, дөбер-шатыр килеп, икегә аерылып төште.

Даимәнен бу мәхшәрдән колаклары тонды, коты очты, өне югалды. Күпмедер вакытка ул баскан урынынннан кузгала алмый катып калды. Шаулап һәм ишеп яңгыр яварга тотынды. Шунда гына ул бераз һушына килде һәм тәмам хәлсезләнгән аякларын көчкә өстерәп, калтырана-калтырана урынынан кузгалды. Тик ерак китә алмады. Чиләкләп койган яңгыр астында тайгакланган тау битеннән ике адым да ясарга өлгермәде, тотырыгын югалтып аска тәгәрәде, бәргәләнде, сугылды. Күпме тәгәрәгәндер, аны үзе дә чамалый алмады. Бер вакытны аркасы белән бик каты нәрсәгә килеп төртелгәч кенә кабат һушына килде. Тау итәгеннән өстәрәк үсеп утырган ялгыз имән кәүсәсенә килеп терәлгән икән. Имән ана тагын да аска тәгәрәргә ирек бирмәгән.

Яңгыр һаман коя да коя. Даимәнен инде бер генә коры жире дә калмады, анын өсте лычма юеш, балчыклы иде. Ләкин торып та китә алмый.

—Йа Хода, бу дөньяда кылган гөнаһларым өчен мине шулай газаплыйсындыр инде,—диде хатын һәм көчкә кузгалып имәнгә аркасын терәп утырды. Авыртмаган, сызламаган жире юк, башы түнгән, күкрәге кыса, сулыш алалмый, ләкин шулай да ул әле үлмәгән, тере. Суга батып баручы саламга тотынган кебек, ул да һаман кыймылдый, һаман бу мәхшәрдән котылмакчы була. Ах, үләсе килми шул, яшисе килә, яшисе... Гөнаһлары чиксез булса да, яшисе килә, чөнки дөнья матур, бик матур. Тик анын кадерен генә белергә кирәк. Ә Даимә анын кадерен белмәде. Бүген исән калса, иншалла, дөньянын, тормышнын, бар жиһаннын кадерен белеп яшәр иде инде ул. Кадерен белеп, игелек кылып, матур итеп. Тик исән генә каласы иде. Исән каласы иде...

*Әлмәт, 2002 ел, гыйнвар.*

# Şiğriət
# Шигърият



## Рим Идиятуллин

### Дүртенче кыш

**1**

**Дүртенче кыш килде. Дүрте-енче-е кы-ыш!**
**Палаткадан корган кышлакка...**
**Әйтерсең лә менә сөймәс үги улын**
**Явыз ата салкын почмакка**
**Бастырган да дүрт ел буе тота;**
**Белми-күрми, бәлкем оныткан...**
**Чечен Али, татар Апуш кебек,**
**Яланаяк, әллә оекчан,**
**Бозлы карга басып катып тора,**
**Йә, кемнән ул шәфкать көтмәктә?!**
**Ә тауларда кыя бөркет оча,**
**Вәхши угы җитмәс биектә...**

**Әйтегезче, кемнең кодрәтеннән**
**Яратылган соң бу һава-җир?—**
**Ходай дисәң, нигә бәндәләре**
**Үз илендә үксез—мөһаҗир?!**
**Тумыштан ук как җир аңа—ястык,**
**Йолдызлардан сырган күк—юрган;**
**Бу кышы да үтәр, еллар үтәр,**
**Үсмер Али китәр кай юлдан?—**
**Йөзем үстерерме, йорт төзерме,**

---

Рим ИДИЯТУЛЛИН *(1940) —шагыйрь; «Хәерле иртә», «Хәерле көн» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Уфада яши.*

Әллә безнең уллар-оныкларга
Тар үткелдә мылтык төзәрме ул—
Көпшәсенә утлы үч тулган?..

2

Илдә сугыш ачкан ул кемсәләр
Үзенәме, кемгә үч итә?—
Өйдә сабыйлары, ә ул мәнсез,
Ихатада бүре үрчетә...

3

Кавказ сыртын кансыраткан сугыш
Кайтавазы кайда?! «Без—тылда»,
Дип яшиме шагыйрь?—Җир-Күк күзе,—
Кыбырдатмый энә, аһ, кыл да;
Кичерерме аны иртәгәсе?!

Ул мәдхия яза җылыда...

♣

Борын заман шагыйрьләрнең хакы
Шактый кыйммәт торган мәгәр:
Мәдхиясе хаким мәртәбәсен
Тәңрегә тиң итсә әгәр,—
Алтын-мәрҗән тутырганнар
Авызына сыйган кадәр...

Шактый очсызланды шагыйрь халкы
(Заман башка, такса башка):
«Күрмәдек без акыл Сиңа чаклы,
Һәйкәлләргә сының шиксез хаклы!»
Дип дан җырлар,—
бер-бер хаким-патша
Авызына ипи сонып,
Күкрәгенә калай такса...

♣

Кибетләрдә сатыла ялтыр портретлар:
«Нихәл!» диеп күз кысалар президентлар
(Берәү түгел, икәү. Хаклары бер),—
Һай туклар!..
... Нигә искә төшә әле балачаклар,
Нигә төшкә керде әле кичәгенәк
Ындыр арты, учак, ябык үлән,
Ач атлар?!
Ә без туклар!—
Авызларда шарт-шорт килә—көлдә
Кыздырылган симез борчаклар...

## Нигә, ник?

Алкын гына агым сулардан да
Нигә язмыш ачы көлә?—
Дәрьяларны барып кочалмыйча
Сазлыкларга батып үлә.

Йолдызлар бит, зат-милләткә бүлми,
Барчабызга назлы бага,—
Ник мең милләт, үзенеке итеп,
Үз телендә исем тага?

Сайрар кошлар кайгы күрми мәллә?—
Шат сайравы һич өзелми;
Кадерләрен, әйе, һәркем белә,
Каберләрен беркем белми.

Кем аңлатыр безгә, энисенең
Күкрәк сөтен имеп үскән
Бала... үскән... аннан, ниләр уйлап,
Әнисенең җанын кискән?..

... Нигә эчем поша
бакчадагы
Тир түгүче дус кырмыска
Сәламем дә алмый узса?..
Башым тубал, чыгарыйм соң
Бу кыйссадан нинди хисса?..

## Memento mori*

*Неапольдәге дустым Зиләгә*

Сөйгән ярлар чиккән кулъяулык ич
Туган җирнең шадра ак кары;
Шадраларын үбеп гел кабатла:
Memento mori! Memento mori!

Гомер язы—кыңгыравын кояр
Умырзаямыни нибары?!
Зәңгәр битен үбеп гел кабатла:
Memento mori! Memento mori!

Әнкәйләрнең назлы карашыдай
Күзгә сеңеп кала җәй нуры;
Син аларның каберләрен ура:
Memento mori! Memento moti!

Бу күзләрнең йөзләренә кемнәр
Сагыш йөгерткән соң?—сап-сары;
Соңгы дуслар белән җылы күреш:
Memento mori! Memento mori!

... Уян, чал Везувий! Син уянсаң,
Күңелләрдә күкрәү өзелми;
Инде безгә хушлашсак та ярый:
Memento mori! Memento mori!

---

Memento mori *(латинча)*—үлем турында онытма.



# Сәйдә Зыялы

ТЫЛСЫМ

## Кайсы кыен?

Кайсы икән иң кыены?
Утлар-сулар кичкәндәме,
Күзгә үлем баккандамы?
Үз илкәең үз баласын
Рәнҗеткәндә, каккандамы?

Сорауларым кыска да бит,
Әмма, озын—җавап табу.
Иң кыены шул дип уйлыйм:
Кеше булып кала алу.

*

Бәхетле дим шул кешене:
Вакытында тапса үзен.
Яшьлегендә
олпатларча
Әйтә алса ул үз сүзен.

Бәхетле дим шул кешене:
Гомере буе яна алса.
Олыгайган көнендә дә
Күңеле яшь булып калса.

## Сагышлы көй

И, моңланды ялгыз гармун,
Еракларда туган яктан.
Күз алдыма килеп басты
Яланаяк йөргән чаклар.

Балачакның бәхетенә
Тиңләшерлек бер көн юктыр.
Читтә ишеткән бу көйдән
Сагышлырак бер көй юктыр.

Сәйдә ЗЫЯЛЫ—*шагыйрә, прозаик; «Айның тулган чагы», «Кайнар сукмаклар», «Песи мәхәббәте» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Болыт киткән...

*Агыла да, болыт агыла...*
Хәсән Туфан

**Безгә тигән кырыс язмыш сыман,
Агыла да, болыт агыла.
Балачакның болын-тугайлары
Аның агышында чагыла.**

**Агыла ул шулай... Агыла да
Туктап кала... тынып, тын кала...
Сурәтендә—яланаяклы кыз
Басма өстенә басып су ала.**

**Басмада кыз. Көянтәсе—иңдә.
Үрелә-үрелә тутырып су ала.
Гаҗәпләнеп ак болытка багам:
Мин үзем лә икән бу бала.**

**Мин үзем лә икән ак болытта,
Бөдрә чәчем җилдә тузынган...
Тар басмага басып яшьлек калган,
Болыт киткән,
Гомер узылган...**

*

**Син дәрья бит.
Ә мин бары бер җил.
Кичеп киләм карын, яңгырын.
Дулкыннарга кереп уралам да,
Синең тавыш булып яңгырыйм.**

**Киләм сиңа урман-кырлар аша,
Тукталганчы соңгы сулышым.
Мин—омтылыш.
Син тирәнлек һәрчак:
Син—мәгънәсе минем тормышның.**

## Соңгы учак

**Яшьлек калды.
Калды еракларда.
Газабы да бетте ул чакның.
Олыгаю инде януыдыр
Күптән күмерләнгән учакның.**

**Яшьлек, яшьлек!
Нигә икән шулай
Уйсыз, гамьсез шаулап актың соң?
Эңгер күләгәсе томалады
Көле төшкән күмер яктысын.**

**Учны куеп учак өсләренә
Тотып торам соңгы җылыны.
... Яктыга дип очкан бер күбәләк
Ут өстенә килеп егылды.**

## Төн уртасы

Иртәме соң, кич җиткәнме?—
Никтер аңламыйм.
Бертуктаусыз сине көтәм,
Һич тә алдамыйм.

Белми киттең сөюемнең
Иң-иң олысын.
Кулларыңны иңемә куй,
Тойыйм җылысын.

Шул җылыга гомер бакый
Җаным тартылды.
... Төн уртасы икән лә бу!
Йолдыз атылды.

## Тылсым

Челтер-челтер йөгерәдер суың.
Чулпы чыңы, чишмә, агышың.
Бар сафлыгың, бар муллыгың белән
Кайсы диңгезләргә барышың?

Юлың озын. Бардыр киртәләр дә...
Торасыңдыр, бәлки, бөялеп?
Уйлыйм әле бүген синең хакта,
Өянкеләреңә сөялеп.

Аңлашыла синең челтерәвең
Җир шарында барлык кешегә.
Кипкән чишмәләрне күрәм дә мин,
Җаным туңа, җаным күшегә.

Кешеләре җансыз бу заманда
Бер сабырлык ничек чыдасын?
Барып җитәр өчен диңгезләргә
Таш-кыялар кисеп чыгасың.

Шигырьләр дә төрмәләрдән чыга...
Тоткынлыкта алар ни кылсын?
Чишмә!
Син дә сихри көчкә ия,
Шигырь кебек син дә бер тылсым!

## Тик бәхеткә

Төрле төстә кырның чәчәкләре.
Исе китеп баккан игенче.
Җиргә нинди язмыш язылганын
Сиземләгән
Шагыйрь беренче.

Төрле төстә кырның чәчәкләре...
Такыялар гына үрәсе.
Әйтелмәгәнмени шигърияттә
Кешелекнең ниләр күрәсе?

Төрле төстә кырның чәчәкләре...
Тик уятсын иркә таң атып.
Шигърияттнең бөек тылсым көче
Кочагында тотсын яратып.

Төрле төстә кырның чәчәкләре...
Өзсен Шагыйрь белеп йоласын.
Алсуланып аткан таңнарны ул
Тик бәхеткә генә юрасын.

**Фирүзә Җамалетдинова**

# АЛМА

хикәя

—Сонга калабыз, тор!—дип пышылдады бер кояш нуры.

Сискәнүдән юрганы ятакның икенче ягына шуып төште. Ашыга-ашыга күлмәк-ыштанын киде. Чалбарының бер балагына Сары чишмә сазы ябышкан икән, ул урындык аягына бәрелде. Һәм... аңа рәхәт булып китте.

Шәһәрдә түгел, әбисендә кунакта икән бит. Мәктәпкә дә барасы юк. Ашыктырмыйлар аны. Юкса, туган көненнән башлап кояш нурын күрергә вакыт тими: башта балалар бакчасына, аннан мәктәпкә.

—Чип-чип-чип... чип-чип-чип...

—Кыт-кыт-кыт... кыт-кыт-кыт...

Әнә, әбекәе дә йортта бугай. Тавыкларга җим таратадыр.

Малай көзге каршына килеп чәчен тарады, әнисе калдырган чемоданнан ап-ак носкиларын эзләп тапты һәм ком белән ышкып юылган гәрәбәдәй сары юеш болдырга чыгып утырды. Яргаланырга торган тәпиләренә ак оекбашын киеп куйды да чалбар балагын кагып алды. Чишмә сазы, тузанга әверелеп, оекбашлары өстенә коелды. Тагын шәһәр исенә төште. Әзрәк кәефе кырылудан авызын турсайтты.

—Исәнме, песием!

Малай сәер тавыш килгән якка, күрше йортның биек болдырына күз салды. Анда ике йодрыгы белән күзләрен уып, авызын уймактай түгәрәкләндереп, татлы иснәп торучы бер кызны күрде. Чәчләре тузган, үзе яланаяк, үзе эчке күлмәктән. Кыз кояшка, ак болытларга үрелгәндәй итте, чирәмгә йөгереп төште дә яңгыратып кычкырып җибәрде:

—Исәнмесез, чебиләр?!

—Чеп-чеп-чеп, чеп-чеп-чеп,—дип җавап тотты чебиләр, болдыр тирәсенә җыелып.

Кызның ирен читенә кояш нурлары кунды, йөзе җәйге чиләдәй яктырды. Бер кулы белән болдыр таянгычына тотынган көе ул янә аваз салды:

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА—*яшь язучы; «Яшен күзләре» һәм «Уйлы җил» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

—Исәнме, әтәч?!

—Кик-ри-күк!—диде әтәч аны тавышыннан танып һәм затлы койрыгын чөеп, тавыклар төркеменә кушылды. Кыз бармаклары белән күзләренә төшкән чуалчык чәчләрен рәтләмәкче булды. Татлы итеп киерелде һәм янә:

—Исәнмесез, тавыклар?!—дип кычкырып җибәрде.

—Кыт-кыт-кыт, кыт-кыт-кыт,—дип ябырылып килделәр тегеләре. Чебиләр куркышып читкә сибелде. Бар табигать бу мәлдә кыз күзләренә төбәлгән иде.

Малай кинәт ак оекбашларын салып атты һәм яланаяк өйгә элдерде. Әбисенен суыткычында ике зур алма барлыгы исенә төште. Кичә бакчадан үзе өзеп кергән иде. Җәлт кенә икесен ике кулына тотып болдырга чыкты.

—Исәнме, кояш!..

Кыз инде иң өстә, бусага төбендәге баскычта тора иде. Малайга ул үзе дә биектә-биектә, кояш тирәсендәге ак болытлар янында булып күренде.

—Әй, кыз!—дип эндәште ул кыюсыз гына.

Кыз игътибар итмәде, ишетмәде дә бугай.

—Әй, кыз!—диде, янә алсу алмаларны ике уч төбендә әйләндереп.

—Әйдә, кил, икәү уйныйбыз.

—Алма!—диде кыз шыпырт кына.—Алма!

Һәм баскычлардан йөгереп төшеп ямь-яшел чирәмле сукмактан ялантәпиле малай кулындагы алмаларга таба атлап китте.

Ә урамда аларны яланаяклы, пычрак чалбарлы малайлар уратып алды. Күз ачып йомганчы алсу алманың берсе әрсез алабайлар кулына күчте. Кайсыдыр кесәсеннән җәпле пәке чыгарды. Бүлешүләр башланды. Кыз күзләрен тутырып малай кулындагы икенче алмага карап тора иде. Малайның да монысын икегә, бары тик икесенә генә бүләсе килде—әйе, яртысын үзенә, яртысын аңа. Булмады. Пәке сорап тору файдасыз, хәзер кисәкләп талап бетерәчәкләр. Шул мәлдә аның башына бер уй килде һәм ул шуны тиз-тиз әйтеп калырга ашыкты.

—Әй, кыз, мә,—диде ул,—йөгер өенә! Урталай кис тә, яртысын миңа алып чык...

Кызның җил дә тарый алмаслык тузган чәчләре, йомшак тәпиләре малайның күз алмасында уйнап калды.

Шул көнне сабыр гына сулап яткан юл тузанын ду кубарып җиңел машинада әтисе белән әнисе кайтып төште. Өйгә банан, әфлисун, лимонише шәһәр исе тулды. Бераздан, малайның сары сазга баткан чалбарын юып, йорттагы кер бавына чыгарып элделәр. Күп тә үтми ак оекбашын, тузаны сөртелгән туфлиләрен, сыры беленерлек итеп үтүкләнгән чалбарын кидертеп, җиңел машинаның арткы урындыгына чыгарып утырттылар.

...Ә тиздән әбисе дә бөтенләйгә шәһәргә күчте.

* * *

—Мә яртысын,—дип эндәште кояш нуры.

«Йокларга дип тә ятмаган иде ласа. Саташа мәллә соң?»

—Мә яртысын,—диде хатыны ана алсу алма сузып.—Киләсе елга тагын бер шушындый алмагач утыртырга кирәк булыр. Үзе сусыл, үзе баллы...

Ирнен күз алдыннан чуалган чәчле, ялан тәпиле кара күзле кыз йөгереп узды.

—Алтыратма әле,—диде ул хатынына төксе генә.

—Миңа кирәк мәллә бакчаң? Үзен җенләнгәнгә генә... Синен өчен генә мин... Бала-чагам булса, бер хәл... Әнә балконда монысы да череп ята...

Хатын авызын бүселдерде, ике ярты алманы тотып бүлмәдән чыгып китте.

—Әйе, кирәк булыр. Утыртырбыз язга,—дип сөйләнде ир үз-үзенә. Күзләренә янә ябырылып кояш нуры тулды. Физзарядка ясап алды.

Өрфия пәрдәләрне тартып бер почмакка шуыштырды һәм кемнәндер курыккандай куырылып:

—Исәнме, кояш!—дип пышылдады.

Тагын уе алмагачка күчте. Ә авылда бәлки әбисенең бакчасы исәндер әле. Алмалары һаман шулай эредер. Күз явын алырлык матур алсудыр. Алып киләсе иде дә орлыктан шул алманы үстерәсе иде. Башта тәрәзә төбендә. Аннан бакчага күчерер иде...

Ул уйларыннан бүленеп урамга карады. Выжт-выжт узган тимер машиналар, салкын юллар күңелен өшеткәндәй булды. Кинәт күңелсез булып китте...

* * *

—Алма кайда?—дип пышылдады кояш нуры.

—Алма?—дип сорады ул, йокы аралаш.

—Әйе, алманы кая куйдың, әни?

—Ә-ә-ә,—хатын айнып китте. Улы икән.—Кызларга ташып бетердең тәмам. Бер капчык иде ласа...

—Бу юлы күп кирәкми, икәү житә,—диде улы.

—Балконга чыккач та уңга кара, шкаф өстендә, катыргы әржәдә...

Улы күтәреп кергән ике алсу алмада балачак хатирәсенең яктысы балкый иде.

—Берсе малайларга. Ә берсен... әйтмим...

Ана елмайды. Димәк улының алма белән сыйларлык сөйкемлесе бар. «Кешеләрне Ходай яртышар алма сыман бүлгәләп җиргә тараткан ди имеш. Һәркем үз яртысын үзе эзләп тапса гына бәхетле була»,—дия иде әбисе... Ана бербөтен алманы берүзенә алды. Авызыннан сулар килсә дә кисәргә җөрьәт итмәде. Алма череп бетте. Күрше малай кайтмады. Үсте. Зур кыз булды. Шәһәргә күчте. Тәвәккәлләп ир бала тудырды. Аңа насыйп алманың икенче яртысы бар иде инде. Гомер бакый җаны авылда, гәүдәсе шәһәрдә яшәде. Фатиры булмаса да, җәйгелек өчен бакча сатып алды.

—Улым, икегә бүлегез. Икәү бүлеп ашагыз,—дип калды ул ишектән кош тоткандай чыгып барган бәгырь җимешенә.—Бәхет—бергәлектә...

Һәм торып тәрәзәгә карады. Урамда салкын көз иде. Юеш, караңгы юллар, янгыр тамчылары сыенган тәрәзәләр...

* * *

Берсен-берсе танымыйча, гомер бакый бер подъездда дөнья көтүче ике зат бу мәлдә бер үк алсу алма турында уйлады..



## Әнәс Исхаков

### И гомер агышлары

Тауларга менеп, тауларча
Офыкларны күзәттек.
Яңгыр явар болытларны
Сезенең якка озаттык...
Аяк-кулларны сыдыртып,
Омтылдык биеклеккә.
Изге максатлар этәрде
Табынган бөеклеккә.
Җитте таудан төшәр вакыт.
И гомер агышлары...
Узган юлда сызылып калды
Күңелнең ак эшләре.
Таудан төшү җиңел түгел,
«Ах, авыр...» дип әйтмичә...
Өлкәнлекне узасы бар
Күңелне имгәтмичә.

### Игенченең йөрәге

Басуда туа, картая,
Гомере шулай уза.
Бу җиһанда ул берүзе
Бураэналарга хуҗа.
Сабый сымак ул гөнаһсыз,

---

Әнәс ИСХАКОВ *(1945) —шагыйрь; «Нигә уйчан бу дөнья», «Чишмәләр иле син, Туган як» исемле китаплар авторы. Азнакайда яши.*

Эше тора хикмәттән,
Патшалар да кече кала
Ул пешергән икмәктән.
Туганын көтеп алгандай
Каршылый ел фасылын.
Күңелендә кояш аның
Тәшкил итә асылын.
Күктә янган кояшка да
Иярер кебек кеше.
Ике кояшның җимеше—
Гәрәбәдәй бу көшел.
Басуда туа, картая.
Юк, картаймый, яшь кала.
Игенченең йөрәге ул—
Әйтерсең лә яшь бала.

## Ничек йоклап калсын бу җаның...

Тымызык Ыкның уйчан болынында
Йокымсырап калган күл буе.
Томан күтәрелә, әйтерсең лә,
Яңа сауган сөтнең күбеге.
Әллә шашкан—Иске Тымытыкның
Әтәчләре ярсый ярышып.
Әзерләнә чеглә уртасында
Серкә очырырга арышы...
Чатыр тауны урап кояш чыга
Буйый-буйый күкне ал төскә.
Бер ваемсыз изри сабый бала
Ак мендәрдә күреп ак төшләр.
Көтү чыга басу капкасыннан,
Чыбыркысы шартлый хуҗаның.
Ярты авыл уяу инде таңда,
Ничек йоклап калсын бу җаның...
Моңсу җилләр назлар эш кешесен...
Җәй уртасы—гомер уртасы.
Авыл яши икән—без яшибез,
Авыл бит ул—җирнең тоткасы.

## Юкә урманнары

Урталары җиткәч җәйләрнең
Шау чәчәккә юкә күмелә.
Ду китереп килеп керде бит
Юкә урманнары күңелгә.
Хискә сеңгән урман һавасы
Әйләндерер хәтта хур башын.
Карурманда йөрим исереп,
Сандугачлар белән җырлашып.
Кайдан алыр идем җанга көч
Күңелләрем җырга тулмаса?
Мин шул кадәр моңлы булмас идем,
Юкә урманнары булмаса.

## Дүртьюллыклар

Гел мактыйбыз
Җирнең хуҗасын.
Ә ул эчә
Күбрәк нужасын.

Саубуллашты минем белән
Мәхәббәтең, дуслыгың,
Җан очты йөрәк түреннән,
Калды күңел бушлыгы.

Серен чишеп абага да
Елга бер чәчәк ата.
Йөрәгемне аңламыйча
Гомер буе баш ватам.

Ялгыш булса кайбер
Хәрәкәт,
Көтеп тора сине
һәлакәт.

## Туган көн

Чәчәкләр белән күмүләр...
Бәхет килми һәркемгә.
Бу бүләкләр... миңа түгел,—
Дәрәҗәгә—хакимгә.

Айдар Хәлим

# КЫРЫМДА КҮРГӘННӘРЕМ

## Мостафа Җәмилевтә кунакта

БАКЧАСАРАЙ шәһәре.

Мин кырымтатар халкының мәшһүр улы—кырымтатар халкының Милли Мәҗлесе рәисе Мостафа-бәй Җәмилевтә кунакта. Без аның яңа бистәдә төзелгән ике катлы йортында сөйләшеп утырабыз. Безнең очрашмаганга алты ел. Мостафа-бәй бер дә үзгәрмәгән. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Төрмәләрдә, айлар, хәтта елга сузылган сәяси ачлыклар кичереп, «какланган» бу легендар шәхес төрки милләтләрнең гражданлык көченең, потенциясенең расламасы, паспорты.

Мин килгәндә Кырым республикасының Премьер-министр урынбасары Әдип Гафаров та Мостафа-бәйдә иде. Әйе, кырымтатар халкы соңгы елларда үзенең угылларын шундый урыннарга үстерде. Алар барысы да милли хәрәкәт чапаныннан чыкты. Без Әдип белән таныш түгел идек. Мостафа-бәй безне таныштыра: «Болар безнең булачак кырымтатар хөкүмәтенең беренче әгъзалары...» Ул бүгенге хөкүмәттә милләтара мөнәсәбәтләр, репатриантлар, депортацияләнгән халыклар, социаль мәсьәләләр сферасы белән җитәкчелек итә икән. Өрек җимеше кебек кояшта янган, каракучкыл йөзле, кыска буйлы, физик яктан нык бәдәнле бу егет белән без туганнарча күрешәбез. Әдип бик тыныч, тыйнак кеше, ул безнең сөйләшүдә бөтенләй катнашмый диярлек. Мостафа-бәй ниндидер исемне, вакыйганы, мәгълүматны исенә төшерә алмыйча туктап калганда гына ул шундук ярдәмгә килә...

Бүлмәдә эссе. Бер-берсе белән ярыша-ярыша эшләп утырган ике вентилятор һаваны җиләсләп өлгерә алмый. Мостафа-бәй, төрекләр сыман, кәһвә (кофе) бик ярата һәм еш эчә. Кәһвәне Премьер-министр урынбасары үзе ясый. Мин кәһвә яратмасам да, «Хөкүмәт әгъзасы үзе ясагач, эчми булмый инде...»,—дигән булып, ара-тирә уртлап куйган булам...

Минем Мостафа-бәй белән берничә тапкыр очрашканым, әңгәмәләшеп утырганым бар иде. Ике тапкыр Казанда да күрешкән идек. Архивымнан аның беренче тапкыр Казанга килгәнендә төшереп алынган сурәт килеп чыкты. Мәрхүм көрәштәшем Марат Мөлековның якты чырае да булган бу сәхифә минем күңелемдә сагынычлы-моңсу уйлар уятты...

Мостафа-бәй миңа без күрешмичә торган чорда үзе турында чыккан ике китап бүләк итә: «Российская Федерация против Мустафы Джемилева. (Омский процесс)» (Киев, 1998) һәм «Шестой процесс Мустафы Джемилева» (Симферополь, 2001). Бу китапларның никадәр кызыклы булуын чамалап, мин

---

Ахыры. Башы 5 санда.

шунда ук, Мостафаның үзенә сиздерми генә, аларны татарчага тәрҗемә иттереп, бастырып чыгарып булмас микән дип хыяллана башлыйм. Китаплар икесе дә «Крымскотатарское национальное движение» дигән сериядә чыкканнар. Соңгысын Төркиянең Әхмәт Ясәви исемендәге фонды һәм, бая әйткәнемчә, Донецкиның «Шахтер» клубы президенты, чыгышы белән Казан татары миллионер Ринат Әхмәдов чыгарган. Мостафа Җәмилев безнең якташыбызга бу һәдиясе өчен бик тә, бик тә рәхмәтле. Укучы хәтерләсә, бу кеше күптән түгел Казанда булып, Президент Минтимер Шәймиев белән очрашты.




*Академик Мансур Хәсәнов, Кырымтатар Милли Мәҗлесе рәисе Мостафа Җәмилев һәм Татар Иҗтимагый үзәге рәисе Марат Мөлеков ТИҮ корылтаенда. Казан, 1992 ел.*

Бу китапларны күргәннән соң мин кырымтатар туганнарыбыздан ак көнләшү белән көнләшеп тә куйдым. Бераз алда әйтелгәнне кабатлап әйтәм: нишләп без, казан татар милли хәрәкәте, миллият өчен көрәш тарихын шундый китапларда мәңгеләштереп калдырмыйбыз? Шул ук Марат Мөлековлар турында китаплар язмыйбыз? Кемнәрнеңдер миннән дә шулай дип соравы мөмкин. Беренче карашка, дөрестер бу, егетләр. Әмма, әмма... Бер мин генә ничек өлгерим? Бу юнәлештә мин эшләгәннең йөздән берен эшләсен иде безнең кайберәүләребез?! Бу мактанудан әйтеләме? Юк, бу гарьләнүдән әйтелә. Нинди бөек кешебезне хәтергә алма, аның турында китап язылмаган. Кая безнең үзебезнең «ЖЗЛ»ыбыз. Аны бит Габдулла Тукай турындагы китабы белән төнкыйтьнең сирәк кабилиятенә, принципиальлегенә ия булган Ибраһим агабыз Нуруллин башлаган иде. Аны кем дәвам итте? Үзенең Җәлил турындагы хезмәтләре белән Рафаэль Мостафин. Безгә билгеле булмаган нидидер сәбәпләр аркасында әшен азагына кадәр алып барып җиткермәсә дә. Киләчәк буыннарның Җәлилнең Сталин һәм Гитлер диктатураларына карата булган мөнәсәбәтен бик тә беләсе киләчәк. Ул кем корбаны булды да, кемнең курчагы булды? Ул, изелгән милләт вәкиле буларак, ике сандалның да корбанымы, әллә мәсьәлә бирәдә башкачарак торамы? «Интернациональ-демократ» Рафаэль Мостафин моны инде әллә кайчан ачарга тиеш иде. Тагын кем язды бөек шәхесләр турында китап? Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасы, Ибраһим Нуруллинның «Тукай» романы, Җәмит Рәхимовның «Батырша» романы, Рашат Низаминың Фәрит Яруллин турындагы «Ут һәм җыр» романы... Такташ турындагы тетрәткеч китапны Фәүзия сеңлебез Бәйрәмова язган икән. Тагын кем? Башка мондыйлар бер дә искә төшми. Без бит мең бөегебез турында мең китап язып үзебезне күтәргән булыр идек! Исемнәрен исемә төшкәнчә, очраклы гына алам: кая безнең Гаяз Исхакый, Һади Такташ, Фатыйх Кәрими, Мулланур Вахитов, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәш, Фатыйх Кәрим, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин, Альфред Халиков, Әбрар Кәримуллин кебек титаннарның фәнни биографиясе?! Кая атаклы Кол Гали, Кол Шәриф, Батырша, Акай-батыр кебек каһарман көрәшчеләрнең, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдин кебек галимнәребезнең, Кәримовлар кебек нәширләребезнең, Хөсәенов, Юнысов, Агафуров кебек байларыбызның, Петр Гаврилов, Гази Заһитов, Мәгубә Сыртланова кебек солдат-каһарманнарга кадәр булган улларыбызның һәм кызларыбызның, кыскасы, милләт тарихына кергән меңләгән шагыйрь, язучы, философ, галим, көрәшчеләребезнең гыйльми биографияләре?! Кем язарга тиеш аларны безгә—нинди Розенкранцлар?! Нигә шулкадәр «Тукай премиясенә капланып», «үзенә-үзе күзе төшкән Нарцисс»лар, үшәннәр без?! Әгәр безнең язучылар атаклы кешеләребез,

бөек замандашларыбыз, мәшһүр татарларыбыз турында, әйтик, талантлы язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез, драматургларыбыз Рахмай Хисмәтулла, Рәшит Бәшәр, Зиннур Мансуров, Ризван Хәмид, Марсель Гали, Гәрәй Рәхим, Газинур Морат, Зөлфәт, Зөлфәт Хәким, Лерон Хәмидулла, Нәбирә Гыйматдинова, Мөдәррис Әгъләм, Наис Гамбәр, Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла һәм башкалар берәр кечкенә генә китап (брошюра!) язган булсалар да, без никадәр баеган булыр идек!...

Әлбәттә, мондый китапларны башта язарга кирәк. Аннан аларны чыгару өчен Ринат Әхмәдовларың кирәк. Әнә бит, эзләгәч, кырымтатар туганнарыбыз тапкан. Казантатар туганнары арасыннан тапканнар. Мондый китаплар чыгару өчен, әлбәттә, мондый тарихларың, материалларың булу зарур. Кешеләр, шәхесләр кабатланмаган кебек, тарихлар да кабатланмый. Әмма бездә, Казан татарында, без күтәрерлек тарих һәм кешеләр юк дип әйтеп булмас иде. Бездәге тарихмы?! Бездәге тарих!..Тарих бит ул күтәрә белү, тарихны тарих ясый белүгә бик нык бәйләнгән. Сез Батырша белән Салават Юлаевны гына искә төшерегез. һәм чагыштырып карагыз. Батырша кебек бөек шәхеснең тарихтагы роле Салаватныкы гынамы?! Әмма бүген Салаватның исем-абруе нинди биеклектә дә, Батыршаныкы нинди хәләттә? Салаватны кем белә дә, Батыршаны кем белә? Салаватны, башкорт буларак, башкорт һәм аның курае гына Салават итте. Молодчина аларга. Нигә татар да курайны күтәрми? Курай—беренче чиратта татар уен коралы бит ул!.. Милләте ягыннан татар булган Батыршаны бөек батыр, философ, мәгърифәтче итеп татар да, башкорт та күтәрмәде һәм аны бүген аерым тарихчылар даирәсе генә белә. Менә бит ул ничек. Без, Казан татарлары, үзебезнең патриотизмга хезмәт итмибез. Без—батыр. Әмма без урыс империясе өчен сугышларда гына батыр. Урысның үзеннән дә батыррак. Үзебез өчен дигәндә юк без. Чүп без. Уфа радиосын, телевидениесен борып ачу белән башкортның җәйге челләдә дә төлке бүрек кигән баласы тиргә төшеп «Яшәһен Салават!» дип кычкыра. Аның турында җырлар җырлый башлый. Сикереп-сикереп бии башлый. Безнең Казан радио-телевидениесеннән синең шундый нәрсәне күрүең-ишетүең мөмкинме? Казан ул җырласа да гел «куркак куяннар» турында җырлый. Биесә дә, батырлык биюе түгел, бер мәгънәсез «Корт чакты»ны бии башлый. Кайвакыт, аптыраган чакларда, «Соң безнең, татарның, болай Салаватка табынган сыман табыныырлык, горурланырлык бер кешесе дә булмаган мәллә?»—дип үзеңнән-үзең сорап куясың. Нишләп без, татарлар, шундый бер, «бердәнбер» булса да табыныр батыр «тудырмаганбыз», яки башкорт кебек, «уйлап тапмаганбыз»? Тарих өчен «кичә генә туган» шагыйрь Габдулла Тукай белән моннан ике гасыр ярым элек туган «Салават-Батыр»—болар бит икесе ике төшенчә. Икесе ике категория. Милләттә сугышчан рух, батырлык тойгысы тәрбияләүдә шагыйрьләргә караганда Батыр Салават «кулайрак» түгелме? Без, Казан татарлары, бу хакта уйлап та караганыбыз юк. Без, Казан татарлары, тарихыбызга битарафбыз. Барны күрмибез. Юкны эзлибез. Күбрәк үзара тарткалашабыз. Көнләшеп, аяк чалабыз. Кызганычка каршы. Сез былтыр бер төркем сәяси алыпсатарларның Татар халкы Милли Мәҗлесен ничек итеп таратуларын гына исегезгә төшерегез. Безнең Милли Мәҗлес ничек бетерелде дә, аларның Милли Мәҗлесе ничек үстерелде? Әлбәттә, тарткалаш кырымтатар милли хәрәкәтендә дә бар. Анда да бер-беренә аяк чалучы, милләт байлыгына кул сузучылар бар. Ләкин алар бер-берсен былчыракка батырмыйлар, шөкер. Хәтта дәүләтчелекнең безнеке шикелле «автоном формасы» да булмаган кырымтатар җәмгыяте лидерларын «ашатмый», аларны ничек кенә булса да үстерергә тырыша. Әгәр алар безнең шикелле вак тарткалаш юлыннан киткән булсалар, Милли Мәҗлес милләтнең легитим дәүләтчелек формасын алмас, чит ил президентлары аның белән исәпләшмәс, аның оешмалары барлык Кырымны биләп өлгермәс һәм хәрәкәт үзенең арасыннан Мостафа Җәмилев, Рифат Чубаров, Надир Бекиров, Әйшә Сейтморатова, Ильми Үмәров, Лилия Буджурова, Әдип Гафаров, Ремзи Ильясов һәм башка шундый шәхесләрне үстермәгән һәм сакламаган булыр иде. Исемнәре аталмаганнар гафу итсеннәр, мин үзем белгәннәрне генә атыйм...

Минем Мостафа-бәй белән алдан сөйләшеп куелган әңгәмәм башлана. Бу безнең үз гомеребездә икенче әңгәмәбез. Беренчесе моннан алты ел

элек булган һәм «Убить империю!» дигән китабымда басылып чыккан иде.

Шулай итеп, беренче сорау:

*—Бисмилләһир-рәхманир-рахим. Мостафа бәй, мин казантатар җәмгатьчелегенә Сезнең ярдәм белән кырымтатар җәмгыятенең бүгенге социаль сурәтен ачып салу бурычын куйдым. Әйтегез әле, соңгы биш-алты елда, кырымтатар халкында күзгә күренерлек нинди уңай күренешләр булды?*

Мостафа авыр тын ала. Бераздан ул тыныч, ерактан килгән, чак-чак кына ишетелгән «хәлсез» аһәң белән сөйли башлый:

—Беренчедән, мин гыйззәте нәфес казантатар халкына үзләренең кырымтатар кардәшләре белән якыннан кызыксынганы өчен рәхмәтемне белдерәм һәм язылачак материалыгызда безнең исемнән барча туганнарга кайнар сәламнәр җиткерүегезне үтенәм. Моннан унбиш көн элек кенә Казанда кырымтатар сәнгате бәйрәме булып узды. Аның уңышлы үтүе белән без канәгатьбез һәм, форсаттан файдаланып, Татарстан җитәкчелегенә, Президент М. Шәймиевкә рәхмәтләр иңдерәбез. Үз чиратыбызда без киләсе елда, Ходай кушса, Кырымда Татарстан әдәбияты һәм сәнгате декадасын үткәрербез дигән ышаныч саклыйбыз. Әлбәттә, бу безнең реаль бәйләнешләрнең башлануы гына әле...

Үзебезнең хәлләргә килсәк... Күрәсең, тормышның кануны шулайдыр инде—эшләнгән саен эшләр аз тоела, күзгә күренми... Чөнки, кая карама, хәл ителәсе мәсьәләләр. Бер караганда, алар шактый. Иң мөһиме, без, сөргеннән үзебез өчен Урта Азия һәм башка яклардан яңа табигый халәткә, шул ук үзбәк һәм башка яклардагы иҗтимагый-сәяси халәттән яңа иҗтимагый-сәяси халәткә кайтып төшкән халык, Украинаның, гамәлдә урыс республикасы булган Кырым республикасы шартларына берегә, кулайлаша, социология теле белән әйтсәк, интеграцияләнә алдык. Бу бик тирән мәгънәгә ия булган гамәли-фәлсәфи процесс. Сөргеннән кайту ул бит гади «кайту» гына түгел. Ярый, кайттың, ди. Илең бармы? Юк. Җирең бармы? Юк. Йортың бармы? Юк. Эшең бармы? Юк. Синә почта буенча каяндыр ун тәңкә акча җибәргәннәр. Син аны ала аласыңмы? Пропискаң бармы? Юк. Паспортың бармы? Юк. Социаль яклаучың бармы? Юк... Бүгенге кырымтатар җәмгыяте кайтуның нәкъ менә шул «кайтканнан соң җирле, йортлы, пропискалы, эшле булу» мәҗбүриятләре аркасында иза чигә. Әйе, безнең соңгы ун елдагы иң зур социаль җиңүебез бар—без өч йөз меңгә якын кардәшебезне туган Ватаныбызга кайтара алдык. Әмма бу әле аларны җирле, пропискалы, йортлы, эшле, ягъни тулы хокуклы гражданин иттек дигән сүз түгел...

Башта төзелеш өчен җир алып булмады, хәзер башланган төзелешне дәвам итеп булмый—акча юк. (*Мостафа-бәй өстәлдә яткан кәгазьләрне караштыра.*) Украина Эчке Эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча бүген Кырымда 265 мең кайткан татар исәпләнә. Алар барысы 70 мең гаиләгә берекkән. Кырымда барлыгы 2 миллион кеше яшәгәнлеген исәпкә алсак, бу барлык халыкның 12,6 процентын тәшкил итә. Аларны җирләштерү, исәпкә алу, ягъни пропискага кертү иң кискен мәсьәләләрнең берсе иде. Украина Президенты Леонид Кучма тырышлыгы белән Үзбәкстан белән Украина арасындагы килешүдән соң без бу мәсьәләдә шактый уңышларга ирештек. 265 мең кешенең 258 меңе бүген җирләштерелеп, паспорт режимына кертелгән.

Үзләрен чын Кырым татары, туган Ватаны улы—патриоты итеп тойган кардәшләребез кайтып бетте дип әйтергә мөмкин. Кайтмаганнар арасында—күбрәк матди хәлләре бик начар, йә булмаса артык яхшы булып, гаиләләре белән үзбәк җиренә нык береккән, кузгалырга хәленнән килмәгән кешеләр. Украин гражданлыгы кабул итеп тә, кайда яхшы, шунда яшәп азапланган ун меңгә якын кардәшебез бар. Үзбәкстан белән Кырым арасында «сәяхәт иткән», әмма әлегә Үзбәкстан белән араны да өзмәгән, Украина гражданлыгына да күчмәгән кардәшләребезне дә исәпкә алып, бүген Кырымда өч йөз меңнән дә ким булмаган милләттәшләребез яши дип әйтергә мөмкин. 22 мең гаилә төзелеп бетмәгән йортларда гомер кичерә. 25 мең, ягъни 8 мең гаилә өйдәш формасында хосусый

фатирларда, гомуми торакларда яши. 110 мең татарның бөтенләй торыр урыны юк. Дәүләт әле дә булса, күп кенә очракларда, хәтта туганнарында торырга урыны булган милләттәшләребезне дә теркәми... Андыйларның саны гомумтатар халкының 4 процентын тәшкил итә. Паспортта вакытлыча теркәлүең дә булмагач, эш эзләп маташырга мөмкинме? Нәтиҗәдә, милләтнең эшкә яраклы өлешенең яртысыннан күбесе—142 меңе—эшсез. Менә шуннан чыгып безнең хәлләрне чамалый аласыз инде.

Әмма «Шайтан гына өметсез», дигәндәй, без дә өмет белән яшибез һәм соңгы биш елда, кырымтатар гавамы әле һаман үзенең дәүләти мөстәкыйльлегенә дә, Кырымның җирле, төп халкы итеп танылуына да ирешмәгән шартларда, мондый уңышларга ирешүебезгә шөкрана да итеп куябыз. Без Украина Президенты Леонид Кучма, Украина хөкүмәтендә кураторыбыз булган Премьер-министр урынбасары Владимир Семиноженко, Кырым республикасының яңа парламент рәисе Борис Дейч, Кырым республикасы Премьер-министры Сергей Куницын, Милләтләр Эшләре буенча Дәүләт Комитеты рәисе Григорий Середа кебек күркәм инсаннар белән бик тә килешеп эшлибез. Соңгы елларда Кырым татарларына акча бүлүнең артуы нәтиҗәсендә, безнең өчен дәүләт алып барган төзелеш эшләре—3, йортларга, бакчаларга су үткәрү—7, электрлаштыру 3,5 тапкырга артты. Сез сораган «уңышлар»ның кайберләре менә шулардыр. Башка уңышларыбыз да бар. Шуларның беренчесе, минем фикеремчә, Украина Президенты каршында кырымтатар милләте вәкилләре Шурасы булдырылды. Президент кимендә елына бер тапкыр безнең Шура әгъзалары белән очраша һәм без әйткән фикерләр, таләпләрне исәпкә алып, Украина хөкүмәте алдына гомумдәүләти бурычларны куя. Үзбәкстаннан кайткан кардәшләребезгә Украина гражданлыгы алуның гадиләштерелүе, Украина Президенты каршындагы Дәүләт белән идарә итү Академиясенә кырымтатар милләте вәкилләре өчен гарантияле урыннар булдыру, Кырым республикасы Мәгариф министрлыгы каршында кырымтатар мәгарифе идарәсен төзү, милләтебезнең югары белем бирү өлкәсендәге башлангычы булган Кырым индустриаль-педагогия институтында яңа бүлекләр ачылу, Исмәгыйль Гаспралының тууына 150, кырымтатар театрына 100 ел тулу уңаенан Акмәчет кырымтатар музыкаль-драма театрына, ниһаять, «Академия театры» исеме бирелү... Шуннан... *(Ул Гафаровка ымлый.)* Өстә әле, Әдип, өстә...

Әдип Гафаров:

*—Безнең халкыбыз утыз процент тәшкил иткән Карасу-Базар районына газ үткәрә башлау, кайбер районнарда, җирле советларның карары белән кырымтатар халкына җир пайлары бүленә башлау, безнең милләтнең закон чыгару һәм хөкүмәт органнарында үз вәкилләрен булдыра башлау...*

Мостафа-бәй Җәмилев:

—Әйе, әйе, дөрес әйтәсез. Кая карама, *башлау*!.. Дәүләтнең закон чыгару һәм законнарның үтәлешен тәэмин итү даирәләрендә үз вәкилләребезне булдыра башлау—бу принципиаль мәгънәгә ия мәсьәлә. Быелның язы-җәендә Украинаның Югары Радасына һәм Кырым парламентына булып үткән сайлауларда без барлыгы 9 депутатыбызны үткәрә алдык. Әлегә бу ситуация тудырган уңыш кына дип исәпләнсә дә, зур сәяси мәгънәгә ия уңыш. Барлык халыкның 13 процентын тәшкил иткән Кырым татарлары депутатларның биштән бере чамасын алып торырга һәм безгә бу санны закон үзе гарантияләргә тиеш. Без моның белән тулаем булмаса да канәгатьбез. Милли хәрәкәтебезнең ике актив җитәкчесе Ильми Үмәров, мәсәлән, Кырым парламентының рәис урынбасары булып сайланды, ә менә безнең белән бергә гәпләшеп утырган кардәшебез Әдип Гафаров... *(Ул Гафаровка баш кагып ала)* хөкүмәт Премьер-министры урынбасары итеп билгеләнде. Минем Украина Верховный Радасына депутат булып үтүемне дә шул уңышлар исәбенә кертергә кирәктер. Республиканың элеккеге парламент рәисе, коммунистларның һәм урысларның иң карагруһларын җитәкләгән Леонид Грач блогы җимерелгеч җиңелүгә дучар булды. Әй, алар безгә нинди генә пычрак ишмәделәр! Урыс шовинистларының үзәк органы булган «Крымская правда» газетасы менә нәрсәләр язды... *(Мостафа-бәй алдындагы газетадан нәрсәдер эзли һәм көлә-көлә укый.)*

*«...Нынешней весной нагло, чисто силовым путем был устранен с политической арены председатель Верховного Совета Крыма Леонид Грач...».* Әйтерсең, урыс шовинисты Леонид Грач сайлауларда үзенең инсаннарга каршы булган сәясәте нәтиҗәсендә түгел, ә, имеш, аларның оятсыз рәвештә раслауларынча, 2002 елда безнең халык тарафыннан «силовым методом» бәреп төшерелгән. Әйтерсең, безнең халкыбыз 1944 елда «силовым методом» куылып алып кителмәгән!.. Нишлисең, сәясәт шундый нәрсә инде, «грачи прилетают и улетают...» Шул ук газетаның мөхәррире карагруһ Михаил Бахарев менә нәрсә яза: *«... Представители Русского блока не получили ничего, тогда как нелегитимные действия нелегализованного в правовом поле меджлиса привели к нелогичному результату—получению постов в руководящих органах. Получается, что законы для русских, белорусов и других народов одни, а для татар, а вернее, для меджлиса,—совершенно другие...»* Менә бит ничек. Һаман да Кырым татары начар. Урамда ятса, исеме татар булганы өчен начар. Өй төзеп керсә, татар булуына «карамастан» төзеп кергәне өчен бигрәк тә начар. Барыбер начар. Сайлаулардан соң икенче көнне «Крымская правда» газетасының беренче бите тулысы белән «Русская идея требует консолидации»,—дип чыкты. Анда нинди генә нәрсәләр юк!.. Халык, ничек кенә булмасын, матбугатка ышана. Ул шулай тәрбияләнгән. «Гәзиткә язганнар»,—ди ул.» Безгә алар белән матбугат сугышы алып баруы мөмкин түгел. Үзегез күз алдыгызга китерегез: дәүләт ярдәменнән мәхрүм татар газетасы 800-2000 тираж, урыс телендәге кырымтатар газетасы нибары 9000 тираж белән чыкса, Грачларның шовинистик «Крымская правда», «Крымское время»лары дәүләт исәбенә 100 мең тираж белән басыла...

Безнең исәпләүләр буенча, элеккеге СССР территориясеннән безгә тагын да кайтырга тиешле милләттәшләребезнең гомуми саны 200-250 мең чамасы. Уңайлы шартлар тудырылган хәлдә бу халыкның 95 проценты кайтуы ихтимал.

*—Мостафа-бәй, безнең барлык бу тырышлыкларыбыз милләтнең киләчәге хакына эшләнелә. Ә менә милләтнең киләчәге аның зыялы, укымышлы һәм үз телендә зыялы булуына бәйле. Сөргеннән кайткан, чит-ят якларда үз телендә белем алудан мәхрүм булган кырымтатар милләтен махсусан программа нигезендә, милләтнең һәр баласы өчен мәҗбүри рәвештә туган телендә укыту юлында нинди омтылышлар белән яшисез? Гомумән алганда, андый омтылыш бармы? Без, төркиләр, яшерен-батырын түгел, ата-бабаларыбыз төзеп биргән бөек мәгариф системабызны беренче булып әләф-тәләф итеп бетердек. Бу юнәлештә кырымтатар милләте Рәсәйнең башка төрки милләтләренә үрнәк була алмас идеме?*

—Сез бик тә авырткан җиргә кагылдыгыз. Юк, әлегә без үрнәк була алмыйбыз. Без бу үрнәкне Казаннан көтәбез. Сездә моның өчен барлык шартлар да бар. Габдулла кардәшемез Тукай нәрсә дигән әле? «Сезгә важибдыр миңа ярдәм кыйлу?»—дигәнме?

Кырымга кайткач туган балалар инде мәктәпкә килде, килүләрен дәвам итәләр. Алар милләт өчен гражданнар булса да, дәүләт өчен әлегә граждан түгелләр. Менә бит нинди ясалма каршылык. Гражданин—син бу җирнең тулы хокуклы хуҗасы. Паспортлы. Җирле. Йортлы. Эшле. Туган телеңдә укулы. Пенсияле. Гражданнар булгач, аның хокуклары социаль якланырга тиеш, шулай бит? Әлегә безнең бу юнәлешләрдә эшлисе эшләр чиксез.

Без яшермибез, милләтне үз телендә укытуга күчерү безнең глобаль бурычыбыз. Ул безнең рухи камиллеккә омтылуыбызның мәгънәсе һәм гарантиясе. Әйтергә кирәк, Леонид Кучма җитәкләгән Украина җәмгыяте һәр милләткә, шул исәптән кырымтатар милләтенә үз телендә уку өчен яхшы перспективалар ача. Ләкин бу бурыч—без ничек кенә теләсәк тә, бүген һәм якын киләчәктә тулаем тормышка ашырыла алмый торган бурычыбыз. Моның сәбәпләре дүрт: Кырымтатар Милли Мәҗлесенең милли мәгариф сәясәте югары хакимият тарафыннан әле дә булса расланмаган. Чөнки татар милләте Кырымның төп, җирле милләте буларак конституцион статус алмаган. Бу—бер. Кырымтатар милли мәгарифе белән шөгыльләнгән махсус дәүләт структурасы әлегә кадәр булмады, ул әле оешып кына килә. Бу—ике. Милли Мәгарифкә булган финанс чыгымнары аерым маддә буенча бармый, ул сөргеннән кайткан милләтнең тормышын җайга салу программасы

буенча алып барыла һәм аңа киткән акча гомумтөзелешкә бирелгән акчаның 2-3 процентын гына алып торды. Быелдан гына аның микъдары 10 процентка җитәргә тиеш дигән директива бирелгән. Димәк, акчасыз милләтнең балаларын туган телендә укытып булмый. Болары—объектив сәбәпләр. Әһәмияте ягыннан болардан да ким булмаган, болардан да «дошманрак» булган дүртенче, субъектив сәбәп бар: ул милләтнең шактый өлешенең ата-аналык педагогикасы, милли педагогикадан читләшкән булуы, сөргендә сукбай фәлсәфәсен үзләштереп, үз балаларын бары тик «чит телдә укытып кына кеше итәргә мөмкин», дигән ялган доктринага ышанган булуында. Аңа әле «татар теле» түгел, ягъни баш өстенә куыш кирәк. Реаль тормышта ул шулай да. Баласын бары тик «урыс телендә генә инженер итә алуга» ышанган ата-ана, эстетик категория булган гүзәллекне меркантиль категория булган файдадан аера алмаган ата-ана, еш кына милли мәгарифкә каршы чыгып, үз-үзенә аяк чала. Ул яхшы, чын, гадел, милли, дини, тәртипле, эчкечелекнең, наркоманиянең нәрсә икәнлеген дә белмәгән кырымтатар баласын бары тик туган тел һәм ислам нигезендә генә тәрбияләү мөмкин икәнлеген өлегә күз алдына китерә алмый. Хәлләремез турында менә шундый-шундый тасвират.

—Мондый күренеш Казан татары өчен дә табигый. Хәтта һәр колониаль милләт өчен.

—Әйе, аның төбендә индоевропеизм дигән нәрсә ята. Әйе, индусларны бары тик инглизләр генә, татарларны бары тик урыслар гына кеше итте, әлифба алып килде, тел бирде, мәдәният алып килде, имеш... Бу фәлсәфә дистә еллар буе, буыннан-буынга сеңдерелә килә икән, ул инде хәлиткеч факторга—милләт өчен тормозга әйләнә. Инсан күңеленә беренче чиратта сәкинә вә тәфәккер (күңел тынычлыгы, тынлык) кирәктер. Бу халәт тормышның, үзең белән риза булудан килә. Кырымтатар милли мәгарифенә килгәндә, без өлегә үз хәлләремез белән бер дә канәгать түгелбез. Үткән гасырның туксанынчы елларында, сөргеннән кайтуның беренче шаукымлы елларында булып алган җанлану шактый сүреләә төште. Өч сәбәптән. Беренчедән, Рәсәйдә барган демократик чигенү, милитар борылыш украин җитәкчелеге һәм җәмгыятенә дә тәэсир итми калмый. Икенчесе—даирәләрдә урлашу көчәйгәнгә күрә, олигархлар ятимнәрне талау көнено килеп җитте һәм бу гади халыкта болай да көчле булган финанс кытлыгын тагын да көчәйтте. Өченчедән—яңа гына сөргеннән кайткан милләттә, яңа шартларда телне төрле сфераларда куллану өчен социаль ихтыяҗ юк. Шулай да безне бер нәрсә куандыра: үзе күптән түгел генә милли изүдән котылган украин җәмгыяте «вак» милләтләрнең тел ихтыяҗын өлегә ихтирам итә. Алда да шулай булсын иде. Инде, иншалла, урындагы шовинизм, башка җирләрдәге кебек, Украинада да котырып китеп, безгә, татарларга зыяны тия күрмәсен иде дип Ходай Тәгаләгә зарый кылабыз...

*Мостафа-бәй беразга туктап кала, кәгазьләрдә эзләнә башлый.*

Сүзне Әдип Гафаров эләктереп ала:

—Шулай да балаларыбызны туган телдә укытуга күчерүдә шактый позитив үзгәрешләр бар. 1988 елда ук ата-аналар теләге белән Кырым республикасы мәктәпләрендә татар теле өйрәнелергә тиешле телләр исемлегенә кертелде. 1990 елда беренче дүрт кырымтатар сыйныфы ачылды. 1993 елда беренче кырымтатар милли урта мәктәбе эшли башлады. Укытучылар белән тәэмин итү өчен Акмәчет университетында кырымтатар филологиясе, Кырым индустриаль-педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты факультеты ачылды. Анда белем алучы студентларның 50 проценты Кырым татарлары. «Кырымучпедгиз» нәшриятендә әсбаплар чыгарыла башлады. Кырым республикасының Министрлар Советы 1997 елның августында украин һәм кырымтатар телендә укыта торган мәктәпләр, тәрбияви учреждениеләр челтәре булдыру турында 260 санлы карар кабул иткән иде. Бу карарны ата-аналар зур илһамлану белән каршыласа да, без яңа мәктәпләр ачу өлкәсендә әлле ни алга китә алмадык. Шартларыбыз җитмәү сәбәпле, кайбер туган телдә укытырга тиешле мәктәпләребез дә «Ике телдә укыта торган мәктәп» итеп үзгәртелде...

*Мостафа-бәй дәвам итә:*

—Менә-менә, таптым!.. Бирелә кызыклы гына мәгълүматлар очраштыра.

Кырымтатар укытучыларының «Мәгариф» ассоциациясе мәгълүматлары буенча... бүген Кырымда мәктәп яшендәге 40000 татар баласы бар. Туган телебездә 7 мәктәп эшли. Анда 2500гә якын бала белем ала. Татар һәм урыс телләрендә 13 мәктәп бар. Анда 3000 бала укый. Кыскасы, кырымтатар балаларының 6 проценты туган телендә, 7,7 проценты ике телдә укый. Әгәр без бу халәтне Бөек Ватан сугышына кадәр булган хәл белән чагыштырсак, күренеш болайрак килеп чыга: ул заманда мәктәп яшендәге балалар саны шул чама—36 мең була. Кырымда татар телендә 371 мәктәп, алар арасында 280 башлангыч, 68 тулы булмаган урта, 21 урта мәктәп эшли. Болардан тыш, ике һәм тагын да күбрәк телдә укыткан 53 мәктәп була. Гомумиләштереп әйткәндә, татар баласы белемне гарантияле рәвештә үз телендә алган һәм шуңа күрә әдәпле дә, белемле дә, физик яктан таза да, иманлы да булган.

Кырымтатар халкы борын-борынгыдан укымышлы халык. Хәтта илле еллык сөрген чорында да без мәгърифәт җепләребезне өзми саклый алдык. Рәсәйнең кайбер милләтләре «үз теләкләре» белән милләтләреннән баш тартып, урыс булып язылганда (мукшылар), без сөргендә дә егерме мең тираж белән газета, ун мең тираж белән журнал чыгарып килдек. Украинаның миграция хезмәте мәгълүматлары раславынча, бүген Кырым татарларында һәр 1000 кешегә 300 югары белемле туры килә. Бу—без белемебез ягыннан украиннардан кала икенче урында (аларда—360) торабыз дигән сүз. Моңа кадәр кырымтатар милләтенең украин гражданлыгына күчерелми торуы, пропискасы булмавы безнең яшьләребезнең ВУЗларга керү мөмкинлеген бик чикләде. Хәзер бу чикләр алынды, мәсьәлә акчага барып терәлде. Килеп туган ситуациядән чыгу өчен Кырым хөкүмәте депортацияләнгән милләт балаларын түләүсез укыту буенча карар кабул иткән иде. 1996 елда 95 гаризаның 74е, 1998 елда 127 гариза канәгатьләндерелде, әмма акча вакытында түләнмәгәч, хөкүмәтнең уку йортлары алдындагы бурычлары күбәйде, нәтиҗәдә, бу ысулда белем алучыларның саны кискен кимеде.

Болардан тыш, безнең 500гә якын егет-кызларыбыз Төркиядә белем ала. Әмма аларның сирәкләре генә илгә кире әйләнеп кайта. Кайтканнары да белгечлекләре буенча эшкә урнаша алмыйча җәфа чигә, йә карбыз сатарга, йә эшсезләр армиясендә тырай тибәргә мәҗбүр була. Балаларыбызны Төркиядә укыту һич кенә дә мәртәбә түгел. Болай да сөргендә гомерен уздырган милләтнең балалары да биш ел буе ата-ана җылысыннан читтә гомер кичерергә мәҗбүр. Яшь күңелнең бит әле еш кына бозыклык, мәзәммәт юлыннан да китеп баруы ихтимал, шулай бит?

Киләчәктә безнең милләт күпме зыялылар белән байыячак? Бүген Кырымның 7 югары уку йортында һәм 2 техникумында 3076 студент, шул исәптән, 2110 кеше түләүсез укып, 966 студент исә коммерция нигезендә, үзләре түләп укый. Бу Кырымдагы барлык студентларның 18,1 процентын тәшкил итә... (Укучым, гафу ит, Мостафа-бәй шулкадәр аныклык белән бу саннарны китергәндә мин сискәнеп куйдым: «дәүләтсез» Кырым татары бу саннарны белгәндә, «дәүләтле» Казан татары үзенең ничә баласы кайда белем алганын белә микән?!)

Соравыгызга шактый озынга сузылган җавабыбыз шушы, Айдар-бәй.

*—Рәхмәт, Мостафа-бәй. Кырымда мин шактый кардәшләрем белән очрашып, сөйләштем. Сөргеннән кайтканнан соң, иске булган «яңа» Ватанда тормыш корган халыкта, беренче чиратта яшьләрдә, «җиргә тамырлану», ягъни яшәргә өйрәнү, интеграция синдромы барлыкка килә. Ул бик нечкә нәрсә. Еш кына психологик шаукым алу, җан җәрәхәтләү кебек күренешләр белән бәйле. Казан татары ата-анасы өчен дә хас күренеш ул. Әмма без инде ул фазаны үткәнбез, бу юнәлештәге югалтуларыбыз бихисап булса да, аңа татарча мыштым гына «күз йомганбыз». Кырымтатар ата-аналарында нинди дер шом сизелә, алар балаларында яңа Кырым, урыс Кырымы шартларында урыслашу, көнбатышчылык шаукымында сукбайлашу, әчкечелеккә бирелү, милли әдәпне оныту, әхлаксезлек, катнаш никахларга җиңел карау күренешләрен күреп, бик борчылалар. Сез, кырымтатар халкының Милли Мәҗлесе рәисе, бу тенденцияләрдә табигый закончалык күрәсезме, әллә болар вакытлы, очраклы күренешме? Милләттә әүвәл кайтырга омтылып, соңыннан ник кайтканга үкенү тойгысы яралмыймы?*

—Иншалла, милләттә андый үкенү юк һәм булмас та дип фараз

итик. Шулай да, сез безнең җәмгыятьнең яңа бер чирен бик нечкә тотып алгансыз. Әйе, ул чир сезләрдә күптән бар, ләкин сез аның белән килешкәнсез. Без аның белән килешергә җыенмыйбыз, әмма вакытлыча булса да исәпләшмичә дә булдыра алмыйбыз. Эш беләсезме нәрсәдә? Сезнең Урта Азиядән кире Рәсәйгә, Рәсәйнең урта полосасы өлкәләренә кайткан урысларның үз фаҗигасына игътибар иткәнегез булды микән? Алар, мөселман әхлагы даирәсендә, әчкечелек белән имгәнмәгән төрки-мөселман арасында яшәп, аек акыл, хезмәт сөеп тәрбияләнгән халык. Алар Рәсәй шартларына, андагы әчкечелеккә, тәртипсезлеккә өйрәнә алмый җәфалана һәм кайберләре хәтта үзләренә кул сала башлый. Бездә, Аллага шөкер, бу симметрик мисал түгел, мин моны проблеманың нинди дә микъдарда охшаш булуын аңлату өчен генә китерәм.

Без моңа кадәр, төрки татар, мөселман өммәте, татар белән бер гаиләдән, бер өммәттән булган төрки вә мөселман үзбәк даирәсендә яшәдек. Безнең кануннар төрки, мөселман кануннарында тәрбияләнгән иде. Әйтик, Үзбәкстанда исерек килеш урамга чыгуны, кеше алдында хатын-кыз, ир-ат белән белән кочаклашып, үбешеп торуны, сүгенүне, төкеренүне, транспортта өлкәннәргә урын бирмәүне күз алдына да китерә алмаган татар баласы, монда, Кырымда, урыс арасында «иркенгә чыккан» яшүсмер, мондый тыюлар аша бик җиңел атлап чыга ала. Телевидение оятсыз котыра. Радиода да оят юк. Ятса, йорты-урыны, эшләсә эше, сөйсә, дистәләгән-маржа «красоткалары» белән уратып алынган. Яшьләр арасында катнаш никахлар арта, хәтта гаилә һәм башка социаль сәбәпләр буенча безнең милләттә беркайчан да булмаган үз-үзеңә кул салу кебек күренешләр күренә башлады. Бераз алда әйтелгән иҗтимагый тотанаксызлык халәте «иркенлеккә чыккан», әмма тормыш тәҗрибәсе булмаган яшь егетләребезне, яшь кызларыбызны шайтанчылык магнетизмы белән коралландыра. Милләт баласы бу шартларда судагы тоз кебек тиз генә эреп югала ала. Без аларны мондый сәкыймлектән (бозыклыктан) сакларга тиешбез. Вә ләкин моңа каршы күсәк күтәреп кенә көрәшеп буламы? Юк. Моңа каршы без бары тик милли гаилә тәрбиясе, милли мәктәп тәрбиясе, ислам тәгълиматы аша гына көрәшә алабыз. Һәм шулай итәбез дә. Дөрес, кырымтатар җәмгыятендә бу мәсләктә яңа куркыныч тенденцияләр хасил булды. Бу безне бик тә борчый. Бездә бу хакта, ярымшаяртып һәм гомумиләштереп: Кырымда, татарга каршы өч нәрсә—урыс маты, урыс маржасы һәм урыс Генасы, ягъни ГАИ хезмәте һөҗүм итә, диләр... Безгә шулардан сакланырга кирәк. Калганы Ходай Тәгаләдән һәм үзебезнең тырышлыктан тора...

*—Тирән әчтәлекле җавапларыгыз өчен рәхмәт сезгә, Мостафа-бәй. Инде килеп, соңгы сорау. Казанга барырга җыенмыйсызмы?*

—Безгә җыену озак түгел. Әмма миңа, кырымтатар халкының Милли Мәҗлесе рәисенә, мондый рөхсәтне милләтем бары тик рәсми чакыру алгач кына бирә. Чакыру алган хәлдә, казантатар туганнарыбыз белән очрашу безнең өчен һәрвакытта да чук гүзәл вакыйга...

## «Кырымда начар яшәү—оят...»

*«КЫРЫМДА начар яшәү—оят. Мин нәрсә эшләргә, кем белән ничек эшләргә икәнлеген беләм...»*

Бу шигарь кырымтатар милли хәрәкәте лидерларыннан берсе, Кырымның 59 нчы сайлау округыннан Кырым парламентына депутат булып үткән, парламентның рәисе урынбасары булып сайланган Ильми Рөстәм улы Үмеровның программасыннан.

Ильми-бәй минем күптәнге танышым. Хәтта дустым дип әйтергә мөмкин. Без аның белән моннан нәкъ биш ел элек Төркиянең Измир каласында үткән Төрки халыклар Ассамблеясының IV Корылтаенда танышып дуслашырга өлгергән идек. Без аны ул чакта Ассамблеяның рәисе итеп сайлаган идек.

Ильми искиткеч тә мөлаем инсан. Ул матур инсан. Аның белән сөйләшүе дә, эшләве дә җиңел. Әгәр Мостафа Җәмилев кырымтатар

сәясәтенең архитекторы булса, Ильми Үмәров аның иркен чалымнар, ярымшаян гыйбарәләр белән эш иткән шагыйре. Әгәр шулай чагыштырырга яраса—Сергей Есенины. Үзбәкстанның берничә колачлы чинар агачларында ботактан-ботакка сикереп, уйнап үскән бу «малай» бүген инде яңа Кырым демократик дәүләтен төзүчеләрнең берсе.

Минә без аның белән Кырым парламенты бинасының өченче катындагы 103 нче кабинетында сөйләшеп утырабыз. Ягъни, мин казантатар матбугаты өчен аңардан интервью алам. Ильми моңа рәхәтләнеп риза булды. Бу офис—аның рәсми офисы. Ильми Кырым парламенты җитәкчелегенең өченче баскычында тора.

Шулай итеп, беренче сорау:

*—Ильми-бәй, сез сөргеннән кайтканнан соң, кырымтатар милләтеннән беренче булып урындагы парламентка депутат булып кына түгел, парламентның җитәкчел структурасына сайланган инсан. Әйтегез әле, милләте ягыннан татар булган инсаннар ничегрәк итеп җирле хакимияткә күтәрелә һәм милләтнең үзе турында кайгыртырга тиешле җитәкчелеге ничек үстерелә? Кырымның төркиләрне җене сөймәгән карагруһчыл җитәкчелеге шартларында бу бит бик тә авыр бурыч...*

—Без үзебезнең бу юнәлештәге бурычыбызны нәкъ әнә шул «авыр» икәнлеген аңлаудан үти башладык. Кырымтатар милләтен әле булса Кырымның төп, җирле милләте итеп, Милли Мәҗлесне әле һаман да милләтнең бердәнбер вә легитим җитәкчел органы итеп танымаган шартларда безнең милләт вәкилләренең төзелештә бригадир итеп билгеләнүе дә гадәттән тыш вакыйга иде. 1994 елдан соң Кырым Югары Советында бары тик бер Рифат Чубаров кына рәис урынбасары, ә мин Анатолий Франчук хөкүмәтендә вице-премьер булып эшләп алган идек. Безнең белән халык арасында вакуум булды, чөнки, ни өчен дигәндә, татарлардан түбәнге һәм урта звено җитәкчелегендә кадрлар үстерелмәде. 1997 елда хакимияткә Грач «очып килгәч», без һәм безнең белән бергә берничә министр урынбасары, унбер районда рәис урынбасары булып эшләгән татарлар «отставкага ычкындык». Шуннан бирле без хакимияттән читтә булдык. Бу инде безнең хакимияткә икенче тапкыр килүебез.

Әйе, хәзер заманнар үзгәрә һәм, Ходайга шөкер, безнең файдага үзгәрә. Әлбәттә, безнекеләрдән әлегә «сам»нар түгел, «зам»нар гына күтәрелә. Нишлисең, без, изелгән милләт балалары, шунысына да куанабыз. Бүгенге көндә Кырым хакимиятендә татарлардан парламентта—1 (мин булам), хөкүмәттә—3, министр урынбасарлары булып—7, шәһәр һәм район хакимнәре рәисләре урынбасарлары булып—16, район советлары рәисләре урынбасарлары булып 3 татарымыз эшли. Бездә барлыгы 16 район һәм 7 шәһәр исәпләнә. Һәр министрлыкта урынбасар булып бер татар утыра дип әйтергә мөмкин. Әмма көч структуралары—милиция, куркынычсызлык хезмәте һәм армиягә безнең татар кадрларын урнаштыру бик авыр нәрсә. Берәүләр тели—алмыйлар, икенчеләр тест, «сиземләү детекторы» аша үтми, өченчеләр үзләре теләми... Байтак татарлар хуҗалык органнарында җитәкче урыннарда эшли. Әмма болар гына аз әле. Бик аз. Закон чыгару һәм законнарны үтәүне тәэмин итү органнарында эшләүче Кырым татарларының вәкиллек күләме милләтнең саныннан чыгып караганда өч мәртәбә кимрәк.

Ничек кенә булмасын, куанычларыбыз бар. Кайчандыр, моннан унбиш ел элек, Акмәчет базарында сату иткән татар кешесен күрү мөмкин түгел иде. Бүген исә Акмәчетнең Үзәк базары һәм башка базарларда сәүдә Кырым татарлары кулына күчеп бара. Кара диңгез буендагы ял базаларында, курортларда, ял йортларында, юл буйларындагы сәүдә нокталарында аш-су, сөт-катык, яшелчә белән, гомумән алганда, татарлар сәүдә итә. Бу безнең акча-икътисад мөнәсәбәтләребез аз-азлап булса да ныгый, дигән сүз. Кырым татарына бүген ышаныч кредиты кирәк. Ссуда кирәк. Вак бизнес, бәләкәй сәүдә аякка бассын өчен, кешеләр эш белән тәэмин ителсен өчен процентлы ссудалар кирәк. Әмма, кызганычка каршы, болар әлегә барысы да матур теләк булып кына кала килә. Чөнки алар милләтнең яңа шартларда гражданин буларак ныгуына бәйле.

Гомумән алганда, гражданлык, җир, эш, органнарда вәкиллек белән

тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителмәү кырымтатар җәмгыяте алдында Гамлет куйган сорауны куя: «Булыргамы безгә, әллә булмаскамы?» Чынлап та, Яшәргә йортың, йорт төзергә җирең, эш йөртү, эшкә урнашу өчен гражданлыгың, паспортың, кулыңның, күкрәгеңнең көчен куярга урының булмаган очракта адәм баласы нишләргә тиеш? Аның бит үз язмышына ачынып, ник туганына үкенеп, үз көчен бөтенләй көтмәгән юнәлешкә юнәлтүе мөмкин. Аның актив социаль элементтан актив антисоциаль элементка әйләнүе мөмкин. Без җитәкчел структураларда кырымтатар халкының вәкиллеген миллəт санына пропорциональ итә алсак, безгә бу мәсьәләләрне хәл итү җиңелрәк булыр иде бәлки.

*—Ильми-бәй, сөргеннән кайткан халыкның, ул сәяси яктан акланган булса да, урындагы халык белән чагыштырганда социаль статусы икенче. Аңа, ул үзе кайчандыр бу җирнең төп милләте булган булса да, шикләнеп, кыеклатып карыйлар. Бу шартларда кырымтатар милләте лидерларына сәяси көрәш алып барганда, әйтер идем, көтелмәгән, «экстравагант» адымнарга да барырга туры киләдер. Сез кайбер шундый көтелмәгән адымнар, Кырым шартларындагы сайлау үзенчәлекләре турында сөйләсәгез иде.*

—Бик дөрес әйтәсез. Бүгенге Кырым шартларында татар милли хәрәкәте алып барган сәяси көрәш—закон белән халык дипломатиясе арасында яткан, гел яңарып, көтелмәгән формалар белән баеп торган һәм мәңге тере булган иҗат. Ул ниндидер шагыйрәнә фантазия белән әртелгән. Әйе, мин казантатар туганнарыбызга безнең сайлаулардагы эш үзенчәлекләребез, сайлау нәтиҗәләре турында сөйләү кызыклы булыр дип уйлыйм. Үзегез күз алдына китерегез. Моңа кадәр Украинаның бер генә сәяси хәрәкәте, фиркасе дә сайлауларда безнең Милли Мәҗлес белән бердәм хәрәкәт итүгә бармый иде. Алар безне тар милләтчелектә гаепләп, «исәпкә алмаска» тырышалар иде. Бу сайлауларда исә күренеш бөтенләй башкача булды. Милли Мәҗлес барлык Украина масштабында *күзгә күренерлек сәяси көчкә әверелде*. Без Виктор Ющенко җитәкләгән «Наша Украина» блогына кердек. Югары Радага сайлауларда безнең блок беренче, коммунистлар икенче, Президент блогы өченче урынны яулады. Кырымда Ющенко өчен бары тик татарлар гына тавыш бирде. Кырым парламентына сайлауларда коммунистлар беренче, соцдемократлар икенче, Ющенко блогы өченче урынны алды. Без йөз округның 7сендә җиңеп чыктык, нәтиҗәдә, җиде урынны яулап, Грач блогыннан үткән депутат Безазиевне дә санап, сигез татарны парламентка үткәрә алдык.

Коммунистлар парламентка рәис итеп элеккеге рәис—бөекдержавачы Грачны, без исә үзебезнең блоктан Борис Давыдович Дейчны күрсәттек. Милләте белән Румыниядә туып-үскән яһүд. Судак шәһәрендә яши, санаторий директоры. Белгечлеге ягыннан экономист. 64 яшьтә. Кырымда христиан-славян дәүләте төзү белән янган Грачның абруе халыкта бик тә түбәнәйгән иде. Без Грачның татарны җирсез итү сәясәтенә каршы берничә көчле акция ясадык. Бу акцияләр, теге, сез сөйләвебезне үтенгән «көтелмәгән адымнар» исәбеннән буладыр инде... *(Ильми-бәй көлә.)* Алар шуңа күрә дә Украинада гына түгел, бөтен дөнья матбугатында яңгыраш тапты. Грачны бары тик тупас көч, басым аша гына хакимияттә тоткан «Урыс блогы» парламентка рәис сайлау чорында үзенең аюларча чалышбасарлыгын, сыгылмалы эшли белмәвен күрсәтеп җиңелде. Нәтиҗәдә, Грач рәис таныклыгын тапшырып, залдан чыгып ук китәргә мәҗбүр булды. Борис Дейч күпчелекне алды. Безнең Грачка карата үз исәп-хисабыбыз бар иде. Моннан ике елга якын элек Украина президенты каршында кырымтатар милләте вәкилләренең шурасы төзелде. Моңа ачуы килгән Грач үзенең «Аксакаллар шурасы»н булдырды. Сез беләсез, милләтнең балалары арасында төрлесе була. Грачның картаеп, акыл ягыннан инде җиңеләя, үз мәнфәгатьләрен милләт мәнфәгатьләреннән өстен куя башлаган 24 кырымтатар сәяси сукбаен табып оештырган «аксакаллар шурасы»н милләт шунда ук «акшакаллар шурасы» дип атады. Һәркайсына кабинет, хезмәт хакы, шәхси машина бүленгән бу «акшакаллар советы»на Милли Мәҗлес сәяси бойкот белдерде. Хөкүмәт үткәргән утырышларның берсендә мин залга кырымтатар флагын чыгарып элмичә, кырымтатар милли гимнын уйнамыйча утырышны башламаска,

аксакаллар шурасы белән хезмәттәшлектән баш тартырга тәкъдим керттем. Бу Кырым телевидениесе буенча туры эфирдан барды. Аксакаллар шурасы озакламый яшәүдән туктады. Бу вакыйгалардан соң мине «Гражданин намусын түбәнсетү»дә гаепләп хөкемгә тапшырдылар. Грач хөкем процессы белән астан үзе җитәкчелек итте. Хөкемгә тапшыручылар миңа 50000 гривна (урыс акчасында—300000) штраф салуны таләп иттеләр. Хөкем «нибары» 15 мең гривна белән чикләнде. Хәзерге көндә мин үземнең Бакчасарай район хакимияте рәисе урынбасары вазифасының айлык хезмәт хакы суммасыннан 20 процент күләмендә «штраф» түләп барам. Ягъни, үземне изүчеләрне баетам. Әйдә, алсыннар, алар барыбер баемый бит.

1999 елның маенда без кырымтатар халкының сөргенгә куылуына 55 ел тулу уңаенан Кырымның барлык районнарыннан Акмәчеткә «Кайгылы Марш» оештырдык. Акмәчетнең Үзәк мәйданына 45 мең татар җыелды. Без анда чатырлардан шәһәрчек булдырдык. Куркуга төшкән Кырым республикасы җитәкчелеге шәһәрнең украин театрында «Хәтер кичәсе» үткәрергә мәҗбүр булды. Җыелышка Грач та килде. Президиумга менеп утырды. Ул чыгыш ясарга тиеш иде.

Мин залдан белдерү белән чыгыш ясадым:

—Кырымтатар халкына бу кадәр рәнҗешләр китергән, безне гражданлыктан, туган телебездән, туган җиребездән мәхрүм итү өчен барлык түбәнлекләрне эшләгән Грач залдан чыгып китәргә тиеш! Без аңардан бу җыелышта чыгыш ясау хокугын тартып алабыз!..

Зал котырып кул чапты. Грач сөйләргә дип авызын ачуы була—зал кул чаба, авызын ачарга гына итә—зал тагын кул чаба, аяклары белән дөберди башлый...

Аны сәхнәдән тәрткәләп төшерделәр. Грач телен тешләп, залдан чыгып китәргә мәҗбүр булды. Грачның сәяси карьерасы барлык Украина масштабында шуның белән юкка да чыкты. Бездә аннан соң «Грачи улетели» диген тәгъбир генә тарихта калды.

Кырымтатар халкы лидеры закон белән оппозицион әхлакъ иҗаты арасында яши. Әгәр шулай булмаган хәлдә, без бернәрсәгә дә ирешә алмыйбыз һәм алмаячакбыз да.

*—Ильми-бәй, һөнәрегез буенча сез кем?*

—Табиб-гинеколог.

*—Бу бик кызык бит! Сез бүген дәүләт кадәр дәүләтне тудырасыз!*

—Мин бүген дәүләт тудыруга караганда балалар тудыруны, ягъни, табиб буларак, тормышка балалар кабул итүне кулайрак күргән булыр идем. Социаль шартлары җиткән очракта бүген һәр Кырым татары гаиләсендә ике генә өстәмә бала тудыру белән без милләтебезнең санын бермә-бер арттырган һәм Кырым атавында сан ягыннан милләтара паритетка, тора-бара сан өстенлегенә ирешкән булыр идек.

*—Булыр, Алла боерса, андый көннәр дә килер. Әлегә бит үзенең тарихи Ватанына кайткан Кырым татары үз җирендә тернәкләнеп китү өчен җир даулый. Җир булса, җыр да, иген дә, халыктан туым да—артым да булыр. Кырымда килеп туган җир мөнәсәбәтләрен аңлатсагыз иде.*

—Без әлегә начар яшибез. Кырымда начар яшәү—оят. Яхшы яшәү үз җирең булу белән бәйләнгән... Җир... Туган җир... (Ильми-бәй бераз уйланып тора. Аның күзләре дымлана.) Безнең халык «Җирле булу—Илле булу»,—ди. Милләтебез сөргеннән кайткач, Кырымның шовинистик җитәкчелеге, әйткәнемчә, Россия коткысы белән аңа җир бирмичә, илсез итү әлмәге белән буа башлады. Әгәр хакимиятнең кемнәндер котыласы килә икән, ул аны яратуы турында җырлар җырлый, әмма басып торырга, утырып торырга, димәк, яшәп торырга җир бирми—шуның белән вәссәлам. Әмма милләткә балалар үстерергә, балалар үстерү өчен әүвәлдә бәрәңге үстерергә кирәк иде. Моның өчен Кешегә имана җире, ягъни җир бүлемтеге кирәк иде. Ләкин хакимият татарга бу «участокны» бирми, чөнки анда татар йорт төзи һәм бакчасын булдыра. Бу шартларда татар «нишлисең инде, язмышыбыз шулдыр» дип җебеп утырырга тиеш идеме? Юк, без борынгы һуннбабаларымыз калдырган васыять нигезендә җирне үзебезнеке итеп тойдык.

Менә сезгә мисал. Бүген Кырымда татар гаиләсе кулы белән төзелгән 50 мең йорт бар. Шуларның 45 меңе үткән гасырның сиксәненче-туксанынчы елларында «самозахват» юлы, ягъни тартып алынган җирләрдә төзелгән йортлар... Без үзебез 1987 елда шушы юл белән Бакчасарай янында 500 җир бүлемтеге тартып ала алдык. Хәзер бу бистәдә 4000 йорт бар. Аны шәһәр дип атарга мөмкин. Акмәчет янында шушындый ук юл белән төзелә башлаган Фонтан бистәсендә бүген 3000ләп йорт бар...

Аһ, ул заманнар!.. Ничегрәк эшләнә идеме? Хәзер инде сөйләргә ярый. Мин Бакчасарай райбашкармасы рәисе Таряникка керәм. Ул яхшы адәм. Һәм тизләнеп диярлек 500 участок сорыйм. Аның күзләре шар була.

—Моның өчен бернинди нигез юк,—ди бу.—Кайтучылар өчен мондый закон да, квота да юк. Җир алу өчен Кырымда ун ел яшәргә кирәк...

—Әгәр без җирләрне ничектер рөхсәтсез ала башласак?—дим мин.—Сез моны күрми торсагыз?

—КГБ, Прокуратура, башка органнар кая карар дип уйлыйсыз?—ди бу миңа ышанмыйча.—Алар бит иртәгә үк застучат!..

—Ә сез әйтми торырсыз! Бер-ике атна көтәрсез!..

Ул күзләрен йомып килешкән кебек булды.

—Ничә кеше сез?

—Илле ике гаилә!—дигән булам мин аны-моны уйламыйча.—Күбрәк тә булуы мөмкин әле!

—Бар! Син мине күрмәдең, мин сине күрмәдем!..

Бер төн эчендә мин илле ике кешене таптым. Әмма таңга кадәр уйлап ятканнан соң, иртәгесен «җиргә казык кагарга» нибары 26 кеше генә килде. Алар иң батырлары иде. Без ике көн эчендә уникегә дүрт метр мәйдан биләячәк йортларның нигезен бетон белән ныгытып та куйдык. Биләмәләргә төзелеш материаллары китереп бушаттык. Төзелеш башланып китте. Безнең белән янәшәдә йөзгә якын йорт күтәрелә башлады.

Ике түгел, өч атнадан гына билгеле була бу хәбәр органнарга. Бу хакта украин халкының намуслы улы Таряник та хәбәр итми тора. Шулай итеп, татарларга нигезне ныгытырга мөмкинлек бирә. Кырым обкомының беренче секретаре Багров Таряниктан самострой төзелешләрен җимереп чыгу өчен бульдозерлар җибәрергә куша. Партия менә таралам, менә таралам дип торган заманнар иде. Тракторлар, бульдозерлар да килде безне җимерергә. Әмма без аларның юлына яттык. Безне керосин сибеп яндырырга маташтылар. Барып чыкмады. Безне кулга да алып карадылар. Ләкин без бирешмәдек. Кырымтатар милләтендәге батырлык һәм сабырлык барлык төрки милләтләргә җитәрлек ул. Безгә каршы тагын да бульдозерлар җибәрүен таләп иткән Багровка Таряник:

—Җибәргәннәре чак-чак исән-сау кайтты,—ди икән.—Боларын инде үзегез алып барыгыз!..

Яшь төзелешкә бер рота ОМОН солдатлары алып килделәр. Йорт-нигезләрне кулдан җимерү һәм безне кулларны богаулап алып китү өчен алар Таряниктан санкция таләп иттеләр. Әмма бирмәде рөхсәтне Александр Иванович. Погром булмый калды. Без аңа мәңге рәхмәтлебез. Ул бүген Кырым хөкүмәтендә курортлар һәм туризм буенча министр булып эшли. Севастьяновка, Холмовка, Тополи һәм башка авыллар янында бүген зур шәһәр булып күтәрелгән татар авыллары менә шундый юл белән төзелде...

Безнең җирсез булуыбыз тарихы аңлашыладыр. Ул бик тә гади. Сөргеннән кайткан халык буларак, без җирсез идек бит инде. Реабилитация нигезендә безгә тартып алынган җиребез дә, йортларыбыз да, мөлкәтебез дә кире кайтарып бирелмәде, гәрчә, кайбер кардәшләребезнең йорт-ихаталары сакланган булса да. Украинаның Җир Кодексы буенча җир пайлары бары тик колхозчыларга һәм колхозчы булган пенсионерларга гына бүленә. Җир пае белән хәтта авылда яшәгән интеллигенция вәкилләре, хезмәткәрләр дә тәэмин ителми. Халкыбыз сөргеннән кайтып төшкәч, Украина хөкүмәте Җир Кодексы турындагы законга тиешле үзгәрешләр керткән булса, татарлар җирне бәлки җиңел генә ала алган булыр иде. Әмма андый үзгәреш кертелмәде. Татарлар колхозларга әгъза итеп тә кабул ителмәде. Һәм бу чарасызлык Кырымга аның төп милләте булган татарларны кертмәү, аларны моннан кире куу, сукбайга әйләндереп, хезмәтче-батрак ясау чарасы итеп кулланылды. Без бу хакта

Президент Кучмага дистәләгән хатлар җибәрдек, пикетлар, демонстрацияләр, сәяси ачлыклар, петицияләр оештырдык. Боларның берсе дә тәэсир итмәде. «Һәр район мәсьәләне үзенең эчке резервларыннан чыгып хәл итсен». Җаваплары шул булды. Без вариантлар эзләдек. Һәм таптык. Һәр авыл советы территориясендәге колхозларны, уставлары нигезендә, КСПлар, ягъни авыл хуҗалыгы предприятиеләре итеп үзгәртергә дә, мөлкәтнең формасын да үзгәртеп, җирнең 15-20 процентын «резерв»та калдырырга. Төрле хәлләр булуын күз уңында тотып без шундый шигарь ташладык: «Җирләргә национализация үткәрергә һәм яңа пайлар булдырырга!» Бу исә резервтагы җирләрне авыл интеллигенциясе һәм Кырым татарларына бүлеп бирергә юл ача иде. Хакимият вәкилләре моңа каршы чыгып, татарларга җир биргән очракта бары тик хуҗалыкта кулланылмый яткан чокыр-чакыр, тау-таш «резервларын» гына бирергә диген шигарь ташлады. Җирләре күп һәм чагыштырмача яхшы булган районнар өчен бу күрсәтмәдән файдаланып булса да, әйтик, Бакчасарай кебек соргылт-көлсу, начар туфраклы, әмма татарлар күп тупланган үзәк районда булу өчен хәтта мондый җирләр дә аз иде. Әйтик, андагы 16 авыл советының өчтән берендә бу ярыйсы, өчтән берендә өлешләтә хәл ителде, өчтән берендә бөтенләй хәл ителми калды. Бүтән резерв юк: тарихи тыюлык, лесхоз, авыл советы җирләре! Бу хәл борынгы сөнәк сугышларын искә төшерә иде...

Менә шушы җир пайларын яңадан карау турындагы таләбебез хәл ителмәү аркасында бүгенге көнгә татар халкының 80 проценты әле дә булса җир белән тәэмин ителмәгән. Кайбер авыл советлары җитәкчеләре Президент Кучманың күрсәтмәсен бозып, татарларга җирне иң начар тау-таш кырлачларыннан гына бүләләр. Кырым республикасында уртача җир пае 5,1 гектар булса да, татарларга дигәндә ул нишләптер 2 гектардан да артмаска тиеш булып чыга. Авыл җирендә яшәүче татарлардан җир пае алучылар саны халыкның 18 процентын тәшкил итсә, урыс, украин, белоруслардан бу күрсәткеч 50 процентка якын. Җитмәсә, бу җирләрнең күбесе аларда файдаланылмыйча ята, яисә начар файдаланыла. Татарлар җиргә, илгә, хезмәткә—җиләк-җимеш үстерергә сусаган, әмма бирмиләр!..

Без кырымтатар халкының җирне башка халык вәкилләре белән бертигез алуын таләп итәбез. Без өстенлек сорамыйбыз.

*—Шулай да, кырымтатар Милли Мәҗлесе лидерларының Украина җитәкчелеге белән мөнәсәбәтләре нинди? Украинаның тышкы сәясәте белән сез килешеп бетәсезме?*

—Гомумән алганда, безнең үзара мөнәсәбәтләр әйбәт. Украина Президенты Леонид Кучма каршында кырымтатар милли хәрәкәте вәкилләренең Шурасы оештырылу безнең тәрәккыяттә бик зур роль уйный. Милли Мәҗлес лидерлары Мостафа Җәмилев, аның беренче урынбасары Рифат Чубаровлар теләгән вакытта Президентның үзе белән очрашып сөйләшә алалар. Президент үзе, йә булмаса аның вәкиле елына бер тапкыр Шура әгъзалары белән очрашып, эшләнгән эшләрне барлыйлар, бәя бирәләр, яңа бурычлар куялар. Тышкы мөнәсәбәтләргә килгәндә, минем карашка, Украинаның Көнбатыш һәм Россия белән мөнәсәбәтләрендә эзлеклелек юк. Бу аның чагыштырмача яшь дәүләт булуыннан, сәясәттә салкын акылга, дипломатиягә караганда хискә өстенлек бирү, лидерларның әлегә җитәрлек дәрәҗәдә тәҗрибәле булмавыннан, украин милли характерының үзенчәлекләреннән дә килә. Мәсәлән, НАТОга керү юлында Украина Көнбатыш белән Россия арасында уңга-сулга ташлана. Украина Конституциясе буенча дәүләт территориясендә чит ил базаларына урын калдырылмаган, әмма шул ук Украина Кара диңгездә урыс хәрби базаларын тота. Кырымда Россиянең йогынтысы бик көчле. Миллләтара мөнәсәбәтләрдә килеп чыккан барча тотрыксызлык, Кырым татарларына карата алып барылган кысым, сепарация барысы да тыгыз агым булып Лужков Мәскәвеннән (әлбәттә, урысларның хәрби базасы Севастополь аша) Кырымга килә. Мәскәү хәтта Кырым республикасының региональ сәясәте белән дә җитәкчелек итә. Берничә генә мисал. 1987 елда Фирганәдә булып үткән вакыйгалардан соң татарлар йортларын бушка ташлап кайтырга мәҗбүр булды. Бер үк вакытта Кырымда йортларга хаклар бермә-бер күтәрелде. Татарларны кайчандыр сөргенгә куган, аларның йорт-җирләрен яңа колонистларга бушка биргән Россия бүген яңадан кыен хәлдә калган татарларга ярдәмгә килергә

тиеш иде. Әмма ул Кырымда татарга каршы шау-шу күтәреп, кайткан халыкның чатыр-шәһәрчекләрен яндыру, татарларны яман чирләр, шул исәптән себер язвасы, ящур алып кайтучылар дип, аларга каршы коткы тарату, поездларга утыртып, кире озатуларны оештырып җибәрде. Ул бүген дә Кырым җитәкчелеген татарларга каршы котыртырга тырыша. Әйтик, Татарстан Россиянең Кара диңгездәге хәрби базаларын мазут һәм нефть продуктлары белән тәэмин итеп тора. Шул ук вакытта суыкларда өшегән тугандаш кырымтатар халкы Татарстаннан грамм да мазут алалмый. Бер үк вакытта Россия үзенең 19 регионын Кырым республикасы белән килешү төзергә рөхсәт итеп, шул ук Кырымга... Татарстан һәм Башкортстан белән килешү төзергә рөхсәт итми.

Ике арада куанычлы мисаллар да бар. Әле берничә генә көн элек Татарстанда кырымтатар сәнгате көннәре булып үтте. 2003 елның җәендә, Алла боерса, Кырымда Татарстан сәнгате һәм әдәбияты көннәре үтәчәк...

## Беренче татар «Күмәк хуҗалыгы»

МИН БЕРЕНЧЕ татар «күмәк хуҗалыгы» һәм аның рәисе белән таныштым.

Дөресрәге, күптәнге танышым Назыйм Ибраһимов белән дип әйтүем. Ул, Хаҗи-Булат авылы милли мәҗлесе рәисе, IV бөтенкырымтатар корылтаеның депутаты, без күрешмичә торган вакыт эчендә күмәк хуҗалык оештырып, аның рәистәшләренең берсе булып өлгергән икән.

һәм менә ничек булды безнең бу очрашу.

Кичке сәгатьләр иде. Мин диңгездә коенып кайтканнан соң ял базасындагы кечкенә куышыбыз алдында эскәмиядә утыра идем. Алдымда каяндыр өермә кебек бер каракучкыл кеше калкып чыга:

—Айдар ага! Әссәламегаләйкүм! Сез биредә сәхрәдә ятасыз, ә без бу хакта бихәбәр!..

Ул минем монда ял итеп ятканны безнең база ярында пәһләвә белән сәүдә итеп утырган Роза ханымнан ишеткән икән. Монысы да мәзәк кенә килеп чыккан. Сөйләсәң—сүз, тортсәң—күз, диләр, бугай, бу очракта. Назыйм, Бакчасарайдан килеп, кырык дәрәҗәдәге Кырым кояшында, пәһләвәләрен сатарга кирәклеген дә онытып, минем «Убить империю!» не укып утырган Роза ханымны күреп, аптырашта кала:

—Син бу китапны каян таптың?—дип сорый Назыйм.

—Нигә тапмаска?—дип сораугa сорау белән җавап бирә Роза.—Аның авторы биредә ял итә, ләбаса!..

—Кит аннан!

—Бер дә китмим! Менә монда... тугызынчы вагонда яши ул!..

Менә шуннан соң өермә сыман өерелеп килеп кереп таба да инде мине борынгы дустым Назыйм. Аның хәбәр итүенчә, Хаҗи-Булат авылында берничә кешедә минем «Убить империю!» китабы бар, алар кулдан-кулга йөретелеп укыла, имеш. Иң аптыратканы шул булды: монда, Хаҗи-Булатта, Казан татарларыннан атаклы бертуган Хәеровлар гаиләләре яши икән, алар да минем белән бик тә очрашырга телиләр, имеш. Роза ханымга килгәндә, якты сагышлы кеше ул. Хаҗи-Булаттан алтмыш чакрым юл үтеп, бу искиткеч мөлаем, сирәк зирәклеккә ия ханым, берьялгызы, минем Акмәчетнең Гаспралы исемендәге китапханәсендә булган очрашуыма килде. Без аның белән танышып киттек. Бик авыр язмышлы булып чыкты ул. Хәер, безнең татарда «җиңел» язмышлы кеше буламы соң инде ул?! Хезмәт инвалиды икән. Мин кешенең тырышлыгына һәм сабырлыгына таң калдым. Пәһләвә сатып булса да, үзеннән тыш, матди авырлык кичергән тагын да ике гаиләнә асрарга тырышып ята ул. Кияүләре йорт бетереп азаплана. Әлегә яшәп торырга юньле почмаклары да юк. Пәһләвәләре сатылса-сатылмаса көне буе кояш ялкыны астында утыра мескен хатын. «Мин барыбер үземне бәхетле тоям. Туган кояш бит ул,—ди Роза.—Кырым кояшы.» Аның ике кызы бар икән. Севиле һәм Сусанна. Монда, Кырымда, Сусанна исеме еш очрый. Мин кызыксындым. Гарәпчәдән ирис чәчәгенә аңлата, имеш. Дөрестерме, белмим. Сүзлектән карап тапмадым инде. Өлкән кызының кияве Кырымга кайткач, түбәдән егылып

төшеп, гариплөнә. Дүрт кызлары бар—Асике, Хәдиджә, Әнифе, Мавиле. Икенче кызының кияве шофер булып эшли. Амет һәм Шефкет исемле биш һәм алты яшьлек угыллары бар.

Киң күңелле бу ханым без базар башыннан күренү белән бездән күзен алмый утыра да, без килеп җитүгә минем төпчегем Кадриянең итәгенә пәһлевәләр тутыра башлый. Минем күземә яшь бәрә—кичә генә сөргеннән кайткан татар мөһаҗиресе Казаннардан килгән дүрт яшьлек татар мосафиресен тәм-том белән сыйлый, иркәли бит, җәмәгать!..

Икенче көнне Назыйм минем янга якын дусты Сеитислам Кишвеевны алып килде. Ул да урындагы мәҗлес һәм беренче татар «кумхуҗ»ы әгъзасы икән. Хаҗи-Булат авылының кайчандыр җеннәр дә ояламас тау башын татарлар кайтканнан һәм шунда «самозахват» ысулы белән гөлбакча сыман авыл «иҗат иткән»нән соң гына яңа авылга «Татарстан» дип исем биргән, үзләре шунда яшәгән бу егетләрдән Сеитислам бер генә ягы белән аерыла: ул—иҗат кешесе. Ул—Акъяр (Севастополь) телевидениесе буенча татар телендә атнасына бер сәгать күләмендә «Акъяр далгасы» («Севастопольская волна») дигән тапшыру алып бара.

Алар мине машиналарында шушы беренче кырымтатар «колхозы» җирләренә алып китте.

Шактый искергән, шыгыр-шыгыр килеп ыңгырашкан, салоны эчендә тегендә, йә монда электр үткәргечләре асылынып торган «Москвич» (Кырым, гомумән, иске «Москвичлар» дөньясы), кызган тимер белән аңкыган һава, безне сикерткән юлсыз юллар, һәр тарафтан озатып барып, бер караганда бик тә тантаналы, шөрәфле, икенче караганда сөйкемле тыйнак, өченче караганда бары тик яшеренеп кенә ярлы күренгән кабатланмас Кырым табигате—болар барысы да кайчандыр минем милли җанымны айкап сагындырасы манзаралар иде. Егетләрнең кәефләре яхшы. Алар мине—Казаннан килгән кардәшләрен, олуг бер горурлык белән, үзләре яулап алган җирдә үстергән беренче уңышны—солы уңышын күрсәтергә алып баралар. Күрелгән хәлме бу?! Илле ел сөргенлектән соң Ватанына кайткан милләтнең беренче мәртәбә үзенә хосусый милек итеп яңадан яулап алган законлы җирендә татар авыл хуҗалыгы кооперативы?! Егетләрнең җаннары җырлый, җөядән ычкынган ук булып стратосферага кадәр күтәрелә, аннан яңадан төшә, яңадан күтәрелә—һәм мин бу җаннарның җырын тетрәнеп тыңлый идем...

—Башкалар алдында безнең бер өстенлек бар,—дип сөйли Назыйм.—Без ташны да гөлбакча итә алабыз. Без, үзебезгә җир бирелмәгәч, Угловое авылы каршындагы тау түбәсен биләдек тә йөз кырык йорт салдык, йөз кырык бакча ясадык. Ләкин безгә, Кырымда яшәгән башка авыл гражданнары шикелле пайлы—җирле буласыбыз килсә дә, җир бирмәделәр. Бүген безнең сиксән сигез татар хуҗалыгының 88 гектар җире бар... —Назыйм туктап кала. Ул авыр тын ала. Аның тамагындагы үкенечле шатлык төене безнең тамакларга да төен булып тыгыла. Якындагы кырлачтан һавага бөркет күтәрелә. Назыйм дәвам итә.—Ә бит безнең бер генә чеметем дә җиребез юк иде. Биредә, диңгез чиге булып, погранзастава сызыгы үткәнгә күрә, җир өчен көрәш аеруча кискен булды. Бу чик безне тәвәккәл булырга өйрәтте. Башта безне, кайткан татарларны, җир пае бирмичә генә колхоз тегермәнә аша үткәрергә булдылар. Ягъни мәсәлән, син—колхозчы, әмма сиңа җир пае бирмиләр, син монда батрак, хезмәтче. «Дармавай труддин» исәбенә яшәргә тиешсең. Мине, мәсәлән, югары белемем белән йөзем плантациясендә рәт араларын сөрә торган сукага «сукачы малай» итеп утырттылар...

Угловоеда барлыгы ике мең гаилә яши, шуларның нибары йөз кырыгы гына татарлар. Алары да тау башындагы ташларга кысрыкланган. Йортлар төзи башладык. Гражданлык булмагач, алынган төзелеш материалына документлар да табып булмый, паспорт сорыйлар. Колхозчы булып эшләсәң дә, акчасы иң өчсыз ракушка да (*диңгез ком-кабырчыгыннан ясалган кирпечләр—А.Х.*) сатып алырга җитми. Эшең булса, торырга йортың булмагач, түрәләр безнең халыкны уңга караган өчен дә, сулга караган өчен дә эштән куарга торалар...

—Урыс кешесе эшкә чыкмыйча эчеп ятса да сүз әйтмиләр—аларның өе, хуҗалыгы, тирән тамырлы туган-тумачасы, хөкүмәте-дәүләте бар, шуларга якланып ята,—дип өстәде Сеитислам.—Безнекеләрнең хәл икенче!.. Күбебез колхоздан чыгарга мәҗбүр булды. Без сиксән сигез хуҗалык авыл советына

Президент Кучма күрсәтмәсе буенча бүленгән резервтан җир бүлеп бирүләрен үтенеп алты тапкыр гариза яздык. Авыл советы исә, безгә җирне бирмәс өчен, резерв биләмәләрен колхозга беркетте...

Егетләр ярсый-ярсый, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә сөйли иде.

Тире-якта биек булмаган калкулыклар, кисәк-кисәк кенә күренгән басулар, тәбәнәк кенә урман-куаклыкларны хәтерләткән йөзем плантацияләре... Күктә, биектә—ялгыз бөркет. Туган һавасында ул да парын эзли, бугай.

—Без җирләрнең кире авыл советына—ягъни Кырым татарларына һәм җирсез калган инвалидларга, авыл интеллигенциясенә кайтарылуын таләп иттек. Болай да булмагач, без, 400 татар, митинг оештырдык һәм авыл советы бинасын камадык. Алар мәсьәләне уңай хәл итәргә сүз бирде,—дип дәвам итте сүзен Назыйм.—Әмма бу юлы да булмады. Яз җитеп килә иде. 26 мартның иртәсендә без, 400 татар, башкарма комитеты сессиясе барган чакта авыл советы бинасын басып алдык. Анда егерме депутат, алар арасында өч татар да бар, совет башлыгы, колхоз рәисе үзләре бар иде. Карар бер иде: резервтагы җирләрне татарларга һәм дә җирсез зыялыларга бирми торып, беркемне кертмәскә, беркемне чыгармаска, ашатмаска, эчертмәскә, хәтта «патшалар җәяү йөри торган җиргә» дә җибәрмәскә! Чолганышта калган бу җитәкчел состав мәсьәләне алты мәртәбә тавышка куеп, алты тапкыр кире тавыш бирде.

—Милиция, махсус органнар җитәкчеләре җыелды. Хәтта алар да безне яклауларын белдерделәр!..

Моныса Сеитислам иде.

—Район советы рәисе коммунист Кретов та килде. Дмитрий Сергеевич үзе дә авыл советы җитәкчелегенә татарларга җир бүлеп бирергә киңәш итте. Ниһаять, Кырым республикасының Куркынычсызлык советы идарәсе начальнигы кичке 20 сәгать кырык минутта халык алдына чыгып, мәсьәләнең тыныч юл белән уңай хәл ителүен хәбәр итте.

Безнең шатлыкның чиге юк иде...

Аларның йөрәк тибешләре ишетелә, ә бу йөрәкләр гүя минем уч төбемдә тибә иде.

—Сиксән сигез татар хуҗалыгына, берәр гектар исәбеннән, резерв җирләрдән иганә бүлемтекләре бүлеп бирелде. 24 апрельдә карар канунлаштырылды. Әмма аның сертификатын—шаһәдәтнамәсен кулга төшерәсе бар иде әле. Инде моңа хәзер бу җирләр кергән «Черноморец» колхозының шовинистик җитәкчелеге каршы иде.

Егетләр тынып калды.

—Менә шулай... Кайда җир өчен актив көрәш бара, шунда җир дә була,—дип өстәде Сеитислам.—Әмма без Кырымдагы һәр милләт вәкиленә җирнең тигез бүленүен таләп итәбез. Дөнья тарихы шуны раслый, әгәр яңа Жанна д Арк, яңа Пугачевларны тудырасың килсә, адәм баласын җирдән мәхрүм ит. Дискриминациягә урын калмаска тиеш...

—Без, ун активист, «Фермер—LTD» кумәк авыл хуҗалыгы предприятиесе булдырдык. Үзебезчә, «кумхуҗ», колхоз инде, колхоз... Без үзебезгә сертификатлар буенча хосусый җир милке итеп «Черноморец» колхозыннан әле менә без барган «Олы Кул» басуын бирүләрен таләп иттек...

«Олы Кул» дигән атаманы ишетү белән миңа эсселе-суыклы булып китте. Гүя мин туган ягыма кайтып килдем. Бәлки мин дөрес ишетмәгәнмендер?! Минем туган ягымда да яланнарны шулай «кулларга» бүлеп йөртәләр бит. Мин яшь чагымда авылымның «Токан Кулы», «Кыска Кул», «Озын Кул»ларында күпме печәннәр чапмадым да, урманнарында күпме бүрәнәләр аудармадым!..

«Кул... кул...» дип кабатладым мин авыз эчемнән. Димәк, үзәнлектәге бүлкәләрен «кул» дип атау башка, ә бәлки барлык төрки халыкларда да бардыр?! Әсәрләнеп, үз кайгы-шатлыкларын сөйләгән егетләрдән мин бу хакта сорашырга уңайсызландым.

—Мәйданы нәкъ йөз гектар чамасы булган бу басу менә ничә ел инде күз күгәртеп буш ята иде... «Черноморец» колхозы җитәкчелеге, республика парламенты рәисе Грач, район җитәкчелеге, урындагы коммунистлар (аларның бередә штабы)—безгә сертификатлар бирүгә каршы чыктылар. Без яңа митинглар белән яндык. Ниһаять, без, Кырым татарлары, Кырым республикасында беренче булып 88 гектар мәйданы булган «чын Кырым»

басуына хуҗа булдык—республика башыннан Грач иерархиясе җимерелеп төшкәч, яңа җитәкчелеккә Борис Дейч килгәч, парламент рәисенең урынбасары Ильми-бәй Үмеров «Җирнең безгә мәңгелеккә хосусый милек итеп тапшырылуы» турындагы сертификатларны үзе килеп тапшырды.

Бу көн безнең өчен чынлап та Кырым татарларының дәүләтле булу бәйрәме кебек хәтердә калды. Ышанасызмы, без беренче булып җиребезне хосусыйлаштырдык!..

Назыймның тавышы калтыранып куйды.

—Әнә, безнең җирләр! Әнә, «Олы Кул»!..

Күз алдыбызда, ике яктан да иңкүлеккә төшеп күтәрелгән, гүя офыкның бер очыннан икенче очына асылган гигант бишектән уч төбендәгедәй күренеп һәм көрәз сыман сары алтынланып иген басуы ята.

Машинадан төштек.

Безне талкынган иген һәм салам тузаныннан гына тарала торган сихри ис биләп алды.

—Безнең җир!.. Безнең җир!..—Назыйм белән Сеитислам кулларын Илаһка сузган кебек хәрәкәт ясап, минем кулларымны кыса башладылар.—Безнең җир!.. Безнең җир!..



*«Олы Кул»ның чын хуҗалары белән*

Бу чынлап та *аларның гына җире* иде. Мин киләчәктә барлык Кырым җирен менә шулай аларныкы итеп күз алдына китердем. Әгәр барлык Кырым алар кулына күчкән хәлдә Кырымда яшәү бер генә милләт вәкиле өчен дә оят булмаячак. Чөнки төрки-мөселман кырымтатар милләте вак, тар, әйтик, бүгенгә башкортка хас милләтчелекнең нәрсә икәнен дә белми. Шовинист булу өчен бераз гына булса да надан һәм караңгы булырга кирәк. Шовинист була алу өчен кырымтатар милләте артык күпне күргән, артык зыялы, артык якты, артык белемле, артык зур тарихлы шул ул. Кырым үзенең тарихи хуҗасы булган татар кулына күчкән хәлдә, аның барлык милләтләр өчен дә бәхет бишегенә әвереләчәгендә шик юк...

Алар сабыйларча шат, мин дә сабыйларча шат, әмма моңсу да идем. Җир өчен утка кергән шушы асыл егетләр артында Рәсәйнең соңгы елларда әрем басып киткән һәм буш яткан миллион гектар басулары, утсыз-сусыз, җәен эшсез кашынган, кышын суыктан өшегән патриотик губерналары, Рәсәйнең генә түгел, хәтта Татарстан авылларындагы тәрәзәләре кадакланган, имана җирләре буш яткан меңәрләгән хуҗалыклар, исерек ирләр вә хатыннар, ятим һәм ата-анасы булып та ятим үскән сукбай сабыйлар күз алдыма килде. «Юк, бу хәлләр имансызлыгыбыз өчен Ходай Тәгаләдән килгән газап,—дип уйладым мин.—Ә менә боларның балалары андый булмаячак, Аллаһ боерса!..»

Басу буйлап биш-алты комбайн йөри. Шунда ук иген ташучы машиналар көтеп тора.

—«Черноморец» колхозы рәисе кайчандыр безнең белән конфронтациядә иде,—дип аңлатма бирә Назыйм.—Хәзер, менә элек буш яткан безнең бу басуда шактый гына уңыш көтелгәч, ул берничә көнгә үз комбайннарын арендага бирде. Безнең кырык тонна солыны аренда хакына суырсалар да, нишлисең, башка чарабыз юк...—Назыйм беразга хафага кала да, аннан үз күңелен үзе күтәреп куя.—Баегач, комбайннарны Америкадан кайтартырбыз әле!.. Без аларны компьютерларга басып кына эшләтербез әле! Без Кырымның бәрәкәтле туфрагында үстерелгән иген һәм яшелчә вә җиләк-җимеш белән дөнья базарын яуларбыз әле!..

## Кара диңгездәге «Татарстан»да

ХАҖИ-БУЛАТ авылы каршындагы тау өстендә, чарлакта, сөргеннән кайткан татарларның үз авылларын төзүләре һәм авылга «Татарстан» дип исем бирүләре турында бераз алдарак әйткән идем шикелле. Без «Олы Кул» басуында булганнан соң Назыйм һәм Сеитислам белән өчәүләп татар авылы белән танышып чыктык.

Бу сәяхәт җанны тетрәтә торган булып хәтердә калды.

Моңа чыдау өчен ныклы йөрәк кирәк.

Беренче хис—ул татар өчен горурлык. Илле ел сөргендә булганнан соң, мөлкәтне башта туган Ватанда, аннан Үзбәкстанда калдырып кайтканнан соң, акчасыз һәм малсыз, бары тик кул, аяк, акыл тырышлыгы белән тау кырлачында, таш өстендә мондый гөлбакчаны булдыру өчен бары тик татар, бары тик Кырым татары гына булырга кирәктер. Кырымның Кара диңгезе ярындагы иң тәмле йөземнәрне, чия-өрекләрне, кавын-карбызларны бары тик монда үстерәләрдер кебек тоелды миңа. Иң матур, иң күркәм рауза чәчәкләре биредә чәчәк атадыр кебек тоелды. Нибары ун ел эчендә?! Ничек мөмкин? Мин моны булдыра алыр идемме? Сез аны булдыра алыр идегезме? Минем шушы соравыма бер урыс кардәшебез, һич тә аптырамыйча, «Так, они же крымские татары...» дип кенә җавап бирде. Әйтерсең, илле ел аның йортын, җирен биләгән һәм дистә еллар буе каралмаган, инде җимерелеп беткән бу йортны әле булса биләп яткан «олы туганыбыз» яңа төзелеш башлар өчен кырымлы кардәшебезгә бер капчык акча биреп куйган диярсең.

Фәрит Маминның йорт-ихатасы белән танышу миндә нәкъ шундый тойгылар калдырды. Фәрит әти-энисенең авыр язмышын улы Данияр белән бергә күтәрә алган ир-егет. Аның әтисе, Бөгелмә тирәсендәге Иске Мастак авылы татары, хәрби врач (кызганычка каршы, исемен язып алмаганмын), авыр заманнарда кырымтатар кызы Хуртхаҗанга өйләнеп, Кырым татарлары язмышын үз өстенә ала, шактый яшь килеш, 1976 елда ук үлеп китә. Аның турында сөйләгәндә Хуртхаҗан апаның керфек очлары яшьләнеп куйды. Аларны куып алып киткәндә кызга 19 яшь була. Кияүгә чыгып, туган җирендә балалар гына үстерәсе дә бит... Юк. Бер ай баралар алар сөргенлек көткән Коканд өлкәсенә. Саратовта ризык һәм су бирмичә өч көн яткыруларын мәңге онытмас ул. Саратов дигәндә бүген дә тетрәнеп китә. Ярты халык юлда кырылып бетә. Калган халыкның яртысы яңа җир бизгәгеннән, су һәм туфрак бизгәгеннән һәлак була.

Бүген менә Хуртхаҗан апа, ике улы, килене һәм оныгы Данияр белән менә диган йортта яшәп ята. Ихаталары, әйткәнемчә, гөлбакча. Бер улы Фуркәт диңгез ярында кечкенә кафе тота. Фәрит автобуста эшли.

Хуртхаҗан апа безнең Татарстаннан икәнлекне белгәч коелып төште. Кунакка чакырды. Иртәгә китәсебезне ишеткәч, бөтенләй тынсыз калды:

—И-и, туганнарым! Шулай ярый ди мени инде? Нигә иртәрәк килмәдегез? Нигә үзебездә генә яшәмәдегез? Шунда, яр буенда, әллә кемнәрдән калган салкын караватларда йоклый ди мени кеше?! Язучы була торып!.. Монда туганнарыгыз була торып!—Ул, әниемә хас милләт-анасы, мине битәрли-битәрли, каядыр кереп китә һәм бер кәрзин помидор, берничә савыт варенье күтәреп чыга.—Менә, алыгыз. Юлга булса да алыгыз. И-и, Ходаем, бигрәк уңайсыз хәлдә калдым бит! Икенче килгәндәме... икенче килгәндә әгәренки үзебезгә төшмәсәгез, бик тә рәнҗеячәкмен!—дип һаман да юкка өзгәләнә-өзгәләнә күчтәнәчләрен тутыра башлый.—Икенче килгәндәме...

Кояш. Иркенлек. Бакчада тәгәрәп яткан кавыннар. Бу җирдә—туган җирдә—беренче уңыш. Яшь йөзем сабаклары яңа йортның тәрәзәләренә үрли. Сабаклар буйлап йортка кояш үзе тәгәрәп керә. Менә мин гаиләне ишек алларында «чәкетеп» тә алам. Әтисе, картинәсе җитәгендә кояшта күзе чагылган Данияр чатный-чатный объективка карый. Ул—татар баласы. Кырымның, кырымтатар милләтенең киләчәге...

...Кырымнан китәр алдыннан мин Хаҗи-Булат (Угловое) авылында Назыймнар таныштырган сирәк бер гаилә—безнең як татарлары Хәеровлар гаиләсендә булдым.

Ленин урамындагы 118 нче йорт. Бу яклар өчен хас булганча, урам

яктан лапас, лапасын ябма итеп йөзем сабаклары билэп алган йорт-ихата. Йортлар биредә, гадәттә, саманнан, йә булмаса диңгез кабырчыгыннан сугылган кирпечтән салына. Хөеровларныкы—саманнан. Ихата биләгән җир—ун-уникe сутыйдан артмас кебек. Гадәти яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы.

Кояшта янып-пешеп, йөзем лапасы астындагы күләгәдә бераз җилләнеп алырбыз дип ихатага аяк басу белән туганнарыбызның кайнар кочагына килеп кергәндәй булдык. Безнең килгәнне алдан белгән бертуган Хөеровлар династиясе, җыелышып көтеп торганнар икән. Җитмәсә, мунча да ягылган. Егерме көн буе диңгез тузында тузланган, душта коенудан башканы күрмәгән тәннәребез үзебезнең чын татар мунчасы ләүкәсендә чабына-чабына мунча кергәндә, татарның кайда да тормышын матур итеп кора белүе өчен горурландык. Мунчадан соң тамак ялгап алгач, мин хуҗаларга үзем белән алып килгән китапларны бүләк иттем. Алар, заманында татарча яхшы гына белем алган кешеләр, татар телендәге китапларга мөкиббән киттеләр. Ике телдә басылган «Биктырыш»ны шундук оныклар «үзләштерде».

Хөеровлар—тәвәккәлләр нәселе.

Алар үткән тормыш юлы шуны раслый.

Ульян өлкәсенең Иске Кулаткы районының Иске Зеленый (ул яктагы исемнәр шундый сәеррәк инде, беләсез) авылында колхозда «таякка» эшләп иза чиккән, бер тиен акчасын да, игенен дә ала алмый ачлык хәленә барып җиткән өч бертуган—Шамил, Шәфкать, Камил Хөеровлар 1966 елның маенда хатыннары, балалары белән бер вагонга утырып, күзләре кая карый шул якка таба чыгып китәләр. Бернинди дә көткән-чакырган кешеләре, трактор йөртүдән башка белем-профессияләре булмаган, урысча юньле-рәтле сөйләшә дә белмәгән туганнар 19 май көнне шушы Угловое авылына килеп егыла. Җитмәсә, алар белән Шамил белән Харирәнең өч баласы да—җиде яшьлек Дамир, биш яшьлек Дамирә, өч яшьлек Ринат, Шәфкать белән Рәфыйканың яшь ярымлык Венерасы да бар. Җәмгысы тугыз җан иясе. Әйтүе генә җиңел. Өстәвенә, ике кече туганның хатыннары көмәнле.

Күз алдыгызга китерегез: моңа кадәр туган авылыннан бульдозер белән сөйрәп тә кузгата алмаган татарны, атап әйткәндә, Хөеровларны, бу кадәр нәсел белән бу кадәр ерак, көтелмәгән сәфәргә алып чыгу өчен никадәр рәнҗетергә кирәк булгандыр!

Алар, ниһаять, нәкъ өч тәүлектән 20 май көнне килеп тә егылалар, ике көннән соң кайсы кайда эшкә дә чыгалар. Хатыннар дигәннән. Бер авылдан булган өч бертуган шул ук авылдан бер нәселдән булган туган-тумача кызларга өйләнәләр. Шамилгә Харирә туташ Җәннәтхан (исеме ни тора!) кызы, Шәфкатькә Рәфыйка туташ Муса кызы, Камилга Әкълимә туташ (гафу итә күрегез, атасының исемен теркәмәгәнмен) кияүгә чыга.

Килеп төшкәч, беренче ике көндә алар үзләренең бер якташларында яшәп азаплана. Авылларыннан бурычка акча билэп чыгып киткән, монда да, аларга ышаныч күрсәтеп, акча биреп торган кешеләргә бурычка батып, бер иске «ызба» сатып алалар. Беренче Кырым кышын шунда кышлыйлар. Аннан сугыш вакытында ашханә булып хезмәт иткән җир идәнле складны сатып алалар да, яшәргә яраклаштырып, тормышны бергә шунда алып баралар. Склад бинасын мөһаҗирләргә сатып бирүдә колхоз рәисе—тумышы белән Башкортстаннан булган чуваш кешесе Николай Никитич Данилов зур ярдәм итә. Туганнар Даниловны җылы хисләр, олуғъ сагыну белән искә алалар.

Озакламый Хөеровларга беренче югалту да килә.

Баланы туфрак кая тартыплар китергән булган икән: чит-ят җирләрдә суык тидергән өч яшь тә дүрт айлык Ринат дөнья куя. Татар зираты юк. Урыс зиратына җирләтмиләр. Ата-ана рөхсәт сорап Вилино авыл советына бара. Сабыйны христиан зираты эченә христиан каберләренән җиде метрда җирләргә рөхсәт алып кайталар һәм шунда җирлиләр дә. Татар җирендә татарны җирләргә җир юк. «Законлы» бит. Шулай бит? Өч яшьлек Ринат энекәшем Хөеров Угловое авылында урыс каберлегенә җирләнгән беренче татар-мөселман буладыр. Урыны оҗмахтадыр сабыйның.

Тора-бара туганнар һәркайсы үзенә йорт салып керә. Без булган йорт Хөеровларның иң өлкәне Шамилнеке икән. Бу урын ул чакта әле буш яткан була. Шамил белән Шәфкать колхозда тракторчы, энекәшләре Камил суыту корылмасында машинист булып эшли. Башта килендәшләрнең юньле-рәтле

урысча белмәүләре теңкәләренә тия. Аннан алар урысча урысларның «үзләрен сатып җибәрерлек» итеп сөйләшә башлый. Килендәшләр өчесе дә гомерләренең күп өлешен йөзем үстерүгә бирәләр, вакыт-вакыт шәраб заводында, соңрак кондитер цехында да эшләп алалар. Кайда гына эшләмәсеннәр, яраталар аларны. Эшчән, туры сүзле һәм тәвәккәл гамәлле булганнары өчен яраталар. Бу уңайдан Харирә кардәшебез бер бигүк «матур булмаган» истәлек белән дә уртаклашып алды.

Бермәлне, йөзем плантациясендә эшләгәндә, әле генә чирдән котылган Әкълимә сеңлесе белән йөзем яланы буйлап килгәндә бер «сакаллы сабый» Әкълимәне көчләп кочаклый һәм халык алдында «Идем со мной, татарка!» дип мәсхәрә итә башлый. Харирә озак уйлап тормый,—якларга кирәк!—кулындагы кискече (секаторы) белән аның бармагын кисә дә җибәрә. Бармактан кан ага башлый. Яландагы халыкның күпчелеге «татарларны салкын корал белән һөҗүмгә күчүдә» гаепли башлый. Харирәнең «законсыз адымын тикшерүгә багышлап, »Халык хөкеме» үткәреләә. Хөкем аны аклый. Әмма тагын да шул колхоз рәисе чуаш Даниловның акыллы чыгышыннан соң. «Син бу татар кызы белән «кети-мети» уйнарга булган идеңме?—дип пешекли ул «кияү егетен».— Әлбәттә, без сине аңлыйбыз. Теләгең зур булган синең. Әмма аларны да аңларга кирәк. Теләгән җиргә керү өчен, үзең белесең, башта санитар эшкәртү үткәреләр бит. Харирә, сеңлесен яклап, сиңа бигүк уңышлы булмаган санитар эшкәртү үткәргән. Ярар, гафу ит син аны. Син дә башка чакта уйлабырак ясарсың мондый адымнарны. Борынгы заманда мондый хатыннар куркак ирләре урынына һөҗүмгә барганнар! Алларына тезләнмәсәң дә, рәхмәт әйт!..»

Бу хәлләр турында ишеткәннән соң минем, татар язучысының күкрәгендә скрипкалар хоры башлана.

Скрипка кыллары өзелергә җитеп чыңлый!

Сез бу моңны ишетәсезме, укучым?!

Хәзер, еллар аша, колхоз парторгы Михаил Пьянов, бухгалтер Мария Слышкинаны сагынып исә ала алар. Аларның һәркайсына үзенчә рәхмәтле Хәеровлар. Гомер үткән саен күңел нечкәрә. Инде кайберләре якты җир йөзеннән китеп тә барган яхшы кешеләр, нинди милләттән, нинди диннән булуларына карамастан, искә төшеп йөдәтәләр...

Татар милләтенең башка милләтләр белән үрелеп яши алу мөмкинлеге. Нинди зур, ачылмаган тема. Кайчан языла икән бу бөек хезмәт? Җанда сыкраган скрипкалар турында олугъ хезмәт!..

Абзыйлар һәм апалар хәзер инде барысы да хаклы ялда. Бер-берсенә барышып-килешеп яшиләр. Минә, ичмасам, чын бертуганнар алар!..

Әлбәттә, тормыш булгач, авыр чаклар, җирле халыкка рәнҗегән чаклары да булган. Мәсәлән, Кырым татарлары туган якларына кайта башлагач, авылда Хәеровларны «Алдан килеп, Кырым татарлары өчен җир биләгән оккупантлар» итеп гаепләү таралып ала. Чынлап та, кырымтатар туганнарына яшермичә, турыдан-туры теләктәшлек күрсәтә алар. Ә нишләргә тиеш иде алар үз өммәтләренә якты чырай күрсәтми? Аларның бит әле Ходай Тәгалә алдында да җавап бирәселәре бар! Моның өчен барлык татар милләте алдында йөзләре ак. Тора-бара яман сүзләр барысы да тына, үз урынына утыра.

Балалары төрлесе төрле якларга таралышкан инде. Шамил белән Харирәнең Дамиры—Самарада, Дамирәләре туган авыллары Иске Зеленыйда клуб мөдире, Даниярләре Казанда аптека мөдире урынбасары булып эшли. Шәфкать белән Рәфыйканың Венералары Ташкентта ире белән бергә криминаль милициядә рентгенолог булып эшли. Илдарлары Киевта, тракторчы. Камил белән Әкълимәнең Рамилләре биредә, Хаҗи-Булатта шәраб заводында эшли, Раильләре шулай ук үзләре белән яши, тракторчы икән...

Минә шундый бер кызыклы гаилә язмышы белән таныштым мин Кара диңгез ярында утырган Хаҗи-Булат авылында.

Хәеровлар исән. Алар хәерле нәсел. Без хәерле милләт. Шулай була күрсен иде.

Минем «Кырымда күргәннәрем» дигән язмаларым шуның белән тәмам. Түземлек күрсәтеп, укыган укучыма рәхмәтлемен.

*Чаллы-Казан-Мәскәү-Акмәчет-Хаҗи-Булат.*
*Кырым, июль 2002 ел.*

**Дания Заһидуллина,**
*Казан дәүләт университеты профессоры*

# МИЛЛИ РЕАЛИЗМ ЮЛЫННАН

Гасырлар алышынган чорда татар әдәбиятында «Мөслим ягы шагыйрьләре» дигән дәрәҗәле исем янына тагын яңасы—«Мөслим ягы прозаиклары» дигәне дә өстәлде. Нуриәсма, Гөлҗиһан кебек классик образлар иҗат итеп, Фоат Садриев белән Факил Сафин әдәбият чикләрен киңәйтеп җибәргән булсалар, Флүс Латыйфи берәүгә дә кабатламаучы лирик-психологик, фәлсәфи төсмерле проза әсәрләре белән әдәбиятта үз мәйданын, үз укучысын тапты, үз сүзен әйтте һәм, шулай итеп, ул чикләрнең әле соңгы үр түгел икәнлеген раслады. Хис-кичерешләргә байлыгы, аларның үзгәреп-көчәеп килү хасиятен укучыга тәэсир чарасы итеп куллану, шигъриятләге кебек төгәл-калку образ-сурәтләр, мәгънә тирәнлеген тәэмин итүче символлар һәм ачкыч-сүзләр белән эшләү һәм Казан арты сөйләше өчен инде архаик саналучы бик күп сүзләрне әдәбиятка кайтару кебек сыйфатлар Ф. Латыйфи стиленең асыл нигезен хасил итә. Татар вакытлы матбугатында киң карашлы талантлы публицист, яңа проблемалар күтәреп чыгарга, хәл-халәтнең үзгә бер бәяләнеш ноктасын табарга сәләтле журналист булып танылган Флүс әдәбиятта да әзерлекле укучыга йөз тота, бервакытта да әсәрләрен очсызлы мәзәк яки натуралистик бизәк белән чүпләми, ягъни акыллы-зыялы, нечкә зәвыклы прозаик дигән исемне лаеклы йөртә.

Флүс Фатих улы Латыйпов Татарстанның Мөслим авылында туган. Болын-тугайлыклар буйлап йөгерүче Ык елгасы, калын урманнар, кызгылт-күгелҗем төскә төренгән Метрәй таулары итәгендәге авылның матурлыгы әйләнә-тирәгә игътибарлы күз белән карарга өйрәткәнме, киң күңелле кешеләр һәм аларны—табигать балаларын—кысаларга куып кертергә ашыккан кырыс кануннар каршылыгы иҗатның беренче орлыгын тәшкил итүче «ни өчен?», «нигә?» кебек сораулар тудырганмы, ерак бабаларның иҗат куәсе нәкъ шушы бөҗрада уянганмы—талантлы кешенең иҗатка килү юлын, сәбәбен төгәл генә ачыклап, әйтеп бирү кыен.

«Мин шомыртлар шау чәчәктә чакта, Мөслим ак күбеккә баткандай яктырып утырган көннәрдә—1943 елның 3 июнендә дөньяга килгәнмен,—дип яза Флүс Латыйфи «Сабантуй» газетасында басылып чыккан автобиографик язмасында.—Әти-әниләрем икесе дә укымышлы нәселдән. Әтием Фатих Әхмәтлатыйф улы (Латыйфи дигән тәхәллүсем шуннан килә) әле Октябрь инкыйлабына кадәр үк мәдрәсәләрдә гыйлем эстәп, чоры өчен шактый югары белем алган кеше. Әнием Дөррия Актаныш якларыннан, җиде буын бабалары указлы мулла булган Әбүгалисина хәзрәт гаиләсеннән». Бу мәкаләне әзерләп

йөргән көннәрдә мин Татарстан Диния нәзарәте чыгара торган «Иман нуры» журналының 2001 елгы март санында Актаныш районы Мерәс авылы тарихына багышлы язмада кызыклы мәгълүматка тап булдым: «Мулла мәсьәләсен Уфа мөфтие тиз хәл итә. Мошты авылыннан ике бертуганны—беренче имам итеп Фәхерлегаян, икенче имам итеп Әбүгалисина хәзрәтләрне юллый. Әбүгалисинаның оныгы—язучы Флүс Латыйфи», диелә анда. «Имәндә икән чикләвек» дигәндәй, менә кайдан башланган икән ул юл башы. Казан педагогика университетының татар филологиясе факультеты деканы, милли кадрлар әзерләүдә армый-талмый эшләүче күренекле профессор Клара ханым Зиннәтуллина, Санкт-Петербургта шәһәрне төзекләндерү белән шөгыльләнүче R«R» агентлыгының генераль директоры, техник фәннәр докторы Фәнил Гаянов та 1937 елда Сталин репрессияләре корбаны булган шушы Фәхерлегаян белән Әбүгалисина хәзрәтләр токымыннан. Ялгышмасам, бу нәселдән әле байтак кына тагын башка фән һәм сәнгать эшлеклеләре дә чыккан.

Күрәсен, әдәбиятка тартылу кечкенәдән үзен сиздерә килгән. Автобиографик язмада тагын мондый юллар бар: «Балачакта төп шөгылем—китап кибетенә янсә гәжит-журнал киоскысына барып, рәсемле китаплар арасында озаклап актарыну иде. Анда эшләүче абый-апалар сүз әйтми, алар миңа дөньяда иң бәхетле кешеләр булып тоела. Ул чакта балалар өчен уч төбе хәтле генә китапчыклар бик күп чыга, сирәк-мирәк эләгә торган вак акча, нигездә, әнә шул китапларга китеп бара иде. Хәтта өйдә фанер тартмага киштәләр ясап, китаплар тутырып, өстенә «китапханә» дип язып куйганымны да бүгенгедәй хәтерлим әле. Дүртенче сыйныфтан башлап үзем үк шигырьләр, әкиятләр язып, аларны китап итеп тегеп, рәсемнәр белән бизәп шул китапханәгә куя торган идем».

Мөслимдәге урта мәктәпне тәмамлагач, Флүс Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. Ләкин ил өстендә болытлар куерган, тарихка Кариб кризисы исеме белән кереп калган вакытта меннәрчә башка студентлар шикелле үк ул да икенче курстан армиягә алына. Эзләнүчән, тырыш егет армиядә чакта ук немец теле белән «женләнеп» китә, чит телләр институтына имтиханнар тапшыра. Ләкин язмыш киләчәктә татар әдәбиятына зур романнар бирәсе улының башка юл сайлавына үзенчә «каршы төшә»: Казанга кайткан егетне профессор Хатип Госман белән очраштыра һәм Флүсебез аның хәер-фатихасы белән документларын Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына, татар теле һәм әдәбияты бүлегенә тапшыра, имтиханнарсыз гына икенче курска кабул ителә. Милли тарих, татар фольклоры, дөнья әдәбияты белән чын-чынлап кызыксынуның башы шушыннан—университеттан килә булыр.

Укыган вакытта ук журналистлык һөнәрен үз иткән егет (1967—68 елларда «Татарстан кооператорлары» гәзитендә әдәби хезмәткәр) унжиде ел Татарстан радиосында эшли: репортер, мөхәррир була, яшьләр өчен тапшырулар редакциясен житәкли. Бу хезмәт Татарстанны аркылыга-буйга инләргә, СССРның байтак республикаларыннан, Германия, Венгрия, Чехословакия кебек илләрдән тапшырулар әзерләргә, йөзләгән кешеләр, аларның язмышлары белән күзгә-күз очрашырга, тормыш тәжрибәсе тупларга мөмкинлек бирә. Сонрак, язу өстәле янында утыру ихтыяжга әйләнгәч, Ф. Латыйфи «Социалистик Татарстан» гәзитенә күчә (1985 ел), бер елдан «Казан утлары»на эшкә килә. 1991 елны латин хәрефләре белән «Dənja» исемле халыкара татар гәзите нәшер ителә башлагач, шунда баш мөхәррир урынбасары вазифасына алына. Тагын бер елдан—«Татарстан хәбәрләре» гәзитендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1993 елдан—«Татарстан» журналында баш мөхәррир урынбасары. Ләкин 1997 елны ул янадан «Казан утлары»на әйләнеп кайта, бүген дә шунда баш мөхәррир урынбасары булып эшләвен дәвам итә. Күрәсен, һәм журналист, һәм язучы буларак, үз урынын шушы журналда таба.

Флүс Латыйфиның беренче китабы «Кырагай» исеме белән 1988 елда дөнья күрә. Ул авторның акыл-тәжрибә җыеп, холык утыртып, каләм чарлап әдәбиятка килүен сөйләп тора. Китапка кергән әсәрләр (сигез хикәя һәм бер лирик повесть) тормышны әхлак кануннары ноктасыннан бәяли, кешенең үзе өчен бик мөһим сынау алдында калу мизгелен тергезә. Китапка исем биргән «Кырагай» хикәясенен төп герое Зәбидә дә шундый сынау алдында тора.

Матур, яшь кызның күңелендә мәхәббәт хисе бөреләнеп килә торган студентканың аркасындагы бөкредән котыласы килү гаҗәпме? Ләкин бу котылу гомерлеккә әни булу хокукыннан мәхрүм итсә? Хикәя ахырына инде укучы рухи дөньясы бай һәм гүзәл итеп сурәтләнгән кызның икенче юлны сайлаячагына шикләнми. Яки «Әманәт» повестеның герое, сугышлар кичкән, гомер иткән Галләм карт шулай ук сайлау алдында. Соңга калып булса да, ул да сугышчан дусты Галимҗан каршындагы бурычын үти, улы һәм оныкларына аның каберен күрсәтеп, онытмаска кушып калдыра. Сынаулардан рухи чистарып, тагын да күркәмләнеп чыккан геройларны сурәтләү объекты итеп сайларга ярата язучы.

Китапта татар авылын, татар кешеләрен милли характер буларак ачкан, бераз елмаеп тасвирлаган хикәяләр дә бар. «Себер хикәясе»н авторның уңышы дип атасак, ялгыш булмас. Себер ягында фольклор җыеп йөрүче студентлар исеменнән сөйләнгән хикәядә яшьләр шулай ук сынау уза. Көне буе йөреп, бер генә җыр яки әкият тә язып ала алмаган егет белән кыз үз ялгышларын аңлый: картларның өстәлгә куйган сыеннан авыз итеп, үзең дә һөнәреңне күрсәтсәң генә, уртак тел табып, теләгәнеңә ирешеп була икән лә. Хикәядә ачылып киткән татар карт-карчыкларының холык-фигыле, бай рухи дөньясы, күңел киңлеге сокландыра, милли характер сурәтләнеше игътибарны җәлеп итә. Нәкъ шушы сыйфатлар—халык тарихында инде онытыла төшкән, тоемлап һәм күңел күзе белән генә «күреп» була торган ваклыкларны урынлы куллана белү—әдәбиятка сизгер күңелле прозаик килүен белгертә дә инде.

«Рустик» хикәясе милләт фаҗигасен, балалары-оныклары шәһәргә китеп, ялгыз яшәүче картлар сагышын, бабаларсыз үскән малайлар үкенечен ачуы белән кызыклы. Хикәя Ф. Латыйфиның характерлар тудыру остасы булуын, берничә штрих, эш-гамәл һәм үз-үзен тотыш аша кешенең эчке дөньясын, «легендасын» ачу сәләтенә ия икәнлеген раслый.

Китап басылып чыгып озак та үтми, язучы каләмен зуррак жанрда «тикшереп карый»:«Ак-карага тимәскә» дип исемләнгән повестен укучы хөкеменә тапшыра. Әсәр заман һәм шәхес каршылыгына нигезләнгән, заман-системаның төп сыйфатын: дөреслекне, ягъни акны-кара, ялганны—караны ак дип күрсәтүгә, алдауга корылган булуын ача. Көрәшче-герой, хакыйкатьне бар нәрсәдән өстен санаган, ләкин ак-кара буталышын аерым кешеләрнең намуссызлыгына бәйле аңлата торган яшь кеше образы тудыра. Сюжет җебе аның аңындагы төп үзгәрешне—«ак-карага тимәү» кагыйдәсенең системадагы төп канун икәнлеген аңлауга килү юлын колачлый. Әйе, татар әдәбиятында җәмгыятьнең төрле катламнарына үтеп кергән ялган хакында әсәрләр булды. Ләкин аларның геройлары—яшен яшәгән, картлык көннәрендә хакыйкатьне ачкан кешеләр иде. Ф. Латыйфи повесте әле генә ВУЗ тәмамлаган яшь кеше—Рәис Хаков мисалында заман шушы системага тугрылыклы итеп тәрбияләгән, шуңа намуслы хезмәт итәргә әзер яшьләрнең чынбарлык белән очрашу ситуациясен тергезә. Шушы сынауны үткән кешеләрнең йә сынуын, йә ялгыз көрәшчегә әверелүен, яки яраклашырга күнегүен язучы геройның тирә-юнендәге кешеләр мисалында күрсәтә. Нәтиҗәдә, «җәмгыять кешеләрне ялган белән сыный, ул рухи гарип кешеләрдән тора» дигән фикер-идея әйтелә. Реализм кысаларында язылган әсәр Ф. Латыйфиның киләчәк иҗатында калкып чыгачак бер үзенчәлекне: халык иҗатын табигый рәвештә куллану сыйфатын калкытып куя.

Сиксәненче еллар ахырында, татар әдәбиятын үзгәртү мөмкинлекләре эзләү башланган бер вакытта, Флүс Латыйфи да иҗат эшендә үз сукмагын билгели, алга таба әсәрләрен башка татар язучылары иҗатыннан аерып торырлык та, укучыга үз һәм яңа булып тоелырлык та агым—милли реализм агымын сайлый. Бу сукмактан китеп язылган беренче зур әсәре—«Хыянәт» романы (1991 ел). Нәкъ менә шушы роман Латыйфины прозаик буларак таныта, ана исем алып килә. Тарихи романнар белән мавыгу дулкыны җәелгән чакта дөньяга чыкса да, әсәр башка авторларның тарихи романнарыннан да сайлаган сукмагы белән аерылып тора, шул сукмакка туры килерлек өслүбе белән башкаларны кабатламый.

Әсәрнең иҗади агымын нинди сыйфатлардан чыгып билгелибез соң? Алар икәү: беренчесе—әсәрнең темасы һәм проблемалары, уйланма катламы, һәм икенчесе—анда чагылган тормыш-яшәү моделе. Ф. Латыйфи әдәби

әсәрдә милли каршылыкка корылган сюжет җебе сузып, милли чынбарлыкны аерып тергезү юлын тапты, шуның ярдәмендә милли фәлсәфә тәкъдим итү һәм милләткә бәя бирү мөмкинлеген күрсәтте. Менә, бәлки, авторның публицистика өлкәсендә милли мәсьәләләр күтәрүе, татар укучысы белән журналистика мәйданында сөйләшү башлавы да тәэсир ясагандыр. 1988—89 елларда Латыйфиның «Вөҗданыңнан сора» һәм «Канатлар очканда ныгый» исемле ике җыентыгы—публицистик язмалар, очерклар тупланган китаплары дөнья күрә. Аларда автор үз укучысын уяныргa, милли хәл-халәтенә күз салырга чакыра, «денебезне, иманыбызны, телебезне һәм хәтеребезне, хәтта милләтебезне югалта язганбыз» дип ачына. «Хыянәт» авторын да охшаш мәсьәләләр борчыганы аермачык.

«Хыянәт»—роман жанры таләпләренә тулысынча җавап бирә торган, жанр хасиятләре калку күренеп торган әсәр. Анда ике төп сюжет сызыгы бар. Беренче, гадәттә иҗтимагый дип билгеләнә торган сюжет сызыгы милли—ул татарлар белән руслар арасындагы каршылыкка нигезләнгән һәм шушы каршылыкның үсүе, 1552 елны Казанны яулап алуга китергән хәлиткеч сугыш белән төгәлләнә. Беренче бүлектә үк, «ашлык җыя, корал туплый урыс» дип Сәетнең хәвефләнүендә төенләнгән сюжет җебе авторның бу хәлләрдә русларны гаепләү ягына басканын, позициясен ачык белдереп сызыла. Әсәр эчендәге шушы хактагы бәхәсләр (тарихка мөрәҗәгать итеп, ике милләт арасындагы каршылыкта татарларның ун һөҗүмгә бер җавап бирүләре хакында сөйләү, Сәет китергән башка дәлилләр) укучыны да язучы хакыйкатенә ышандыра. Татар-рус каршылыгы да руслар күзаллавында барлыкка килгән, уйлап табылган кебек тәкъдим ителә («Утка—су, көнгә—төн, җиргә—күк... Урыс дигәч—татар бар, татар барда хәтәр бар» сүзләрен язучы Василийдан әйттерә, романдагы бер генә татар кешесе дә Иван патша һөҗүменә каләр русны үзенә каршы көч итеп карамый).

Икенче—шәхси сюжет сызыгын төп герой Сәетнең үз эчендәге каршылык дип билгеләргә кирәк. Тамырларында татар каны акса да, моны үзе белмәгән Сәетнең, гашыйк булу сәбәпле, мөселманлык кабул итүе, ләкин Казанга куркыныч янаган көннәрдә, бик күп газаплы икеләнүләр аша, үзенең асылы кем икәненә төшенергә теләп бәргәләнүе, ахырда, татар дип хис итеп, соңгы сугышка катнашуы кебек үскән икенче төп сюжет сызыгы да милли төсмерле, кешенең үз-үзен эзләвен шушы яссылыкта хәл итә. Димәк, язучы ике төп сюжет сызыгын да милли каршылыкка буйсындыра, бу ана ике төрле милли тормыш моделе төзергә, аларның бер-берсенә охшамаганлыгын ассызыкларга ярдәм итә. Дөрес, тарихи романга алынган хронотип һәрвакыт милли урын-вакыт сайланышын сорый. Монда да вакыйгалар Казан шәһәре һәм аның тирәсендә бара, якынча 1533—1552 елларны үз эченә ала. Ләкин сурәтләнгән дөньяның ике чиккә аерылуына, урын-вакыттан бигрәк, һәр каршылыкның милли мәсьәлә булып әверелүе сәбәпче. 13 бүлеккә бүлеп уйланган романда 13 ярдәмче сюжет сызыгы бар. Аларның алтысы XVI гасырның 30, җидесе 50 елларына карый. Шуларның күбесе, төгәлрәге—унысы шулай ук милли каршылыкка мөнәсәбәтле.

Әсәрдә ике милли яшәү моделе тергезелә, дидек. Милли тормыш картинасы өч элементның: табигать, милли характер һәм фикерләү рәвеше, ягъни милли логиканың берлегеннән оеша (Г. Д. Гачев). Ф. Латыйфи да әсәренең буеннан-буена шушы элементларга укучының игътибарын юнәлтеп, татар тормышының бөтенлекле сурәтен барлыкка китерә.

Укучысын ялыктырмыйча гына, автор-хикәяләүче үз геройлары күргән табигать манзарасын, Казан тирәсендәге калын урманнарны, зәп-зәңгәр чиста сулы, тәңгә сихәт бирә торган елгаларны, көмеш чишмәләрне тасвирлап бара. Ләкин төп игътибар шәһәр сурәтенә бирелә, ул халыкның культура дәрәҗәсен күрсәтүче көзгегә әверелә. Менә Санька беренче тапкыр күргән шәһәр манзарасы: «Әнә, томан өстеннән, бер-берсен уздырырга теләгәндәй, шәмдәй төз, ярымайлы, нечкә, биек манаралар күккә үрелде, аларның алтынланган очларында кояш нуры җемелдәде. Алар сансыз, исәпсез иде. Әйтерсең лә алар акрын гына үсәләр һәм күктәге ап-ак каурый болытларга тоташырга ашыккандай томан эчендә йөзәләр иде (...) Якынайган саен тылсымлы сурәт зурая, матурлана бара. Әнә инде төрле төсләргә буялган

йорт түбәләре, ялык-йолык килүче ярымтүгәрәк гөмбәзләр пәйда булды. Каезланган юан имән бүрәнәләрдән тезелгән диварлар калкып чыкты, калын тимер капкалар күренде». Тирә-юнь сурәте матур, бай-зиннәтле итеп тасвирлана. Шуның аша язучы Казан ханлыгының югары мәдәниятле, житеш, мул тормышта яшәвен ассызыклый. Кеше кулы белән бар ителгән чишмәләр, жир асты юллары хакында сөйләгәндә автор кешенең дә табигатьне үзенә жайлап камилләштерүен искәртә сыман. Әсәрдәге табигать картинасы бу гармонияне тагын да көчәйтә:«Томан таралуга тагын икенче күренеш ачылды. Офыкта, күз күреме ераклыктагы урманнар өстендә салават күпере пәйда булды. Ул бер очы белән урманнарга таянса, икенче очы белән артта калган Идел өстенә барып тоташты. Әйтерсең лә бинаһая олы капка аларның килүен генә көтеп торган да менә хәзер тылсымлы дөньяга юл ача, керер урын күрсәтә иде». Казанлыларның йортларын, көнкүрешен, Мәмәт би жәйләвен сурәтләгән урыннар да әсәрнең башында ук сайланган өслүбтә бирелә. Иркенлек, муллык, табигатьнең беренчел сафлыгын-матурлыгын саклаганлыгы беренче планда тора. Күп кенә сурәтләрнең Санька-Сәет күзлегеннән, ул күргән-бәяләгәнчә бирелүе рус шәһәрләренең, көнкүрешенең мондагыга охшамаган булуын искәртә һәм аны Казан ханлыгының тышкы сурәтенә капма-каршы модель кебек аңлауга юл ача.

Милли характер тудыру, күрәсең, язучының үз алдына куйган максатларыннан берсе булган. Мәмәт би һәм Шәһит, Гөлйөзем, Галиәкбар ага, Нургали һәм балыкчы карт, Әжем һәм Кол Шәриф—һәрберсе шушы максатка ирешүгә хезмәт итә, үзенчәлекле сыйфатлары белән бергә, уртак хасиятләргә ия. Төп сыйфатларны язучы текстта да аерып билгеләп бара. Геройларның тышкы кыяфәтендә, эш-гамәлләрендә беренчел куелган сыйфат—сабырлык. Сәет уйларында кабатланганча, «бу йортта, бу кешеләр арасында сабырлыктан да югары бәяләнүче нәрсә юк» яки «йөзеннән бөркелгән сабырлыкны, улының басынкылыгын, тырышлыгын күреп, күңеленә тагын рәхәт булып китә». Савелий Кузьмич авызыннан әйтелгән сүзләр дә шуны ук раслый: «Алар кабаланганны сөйми». Ә инде әсәрдәге Василий, Савелий Кузьмич, Иван кебек геройларның эш-гамәлләре, бик тиз кызып китүчәнлеге рус характерындагы төп хасият кебек кабул ителә.

Милли характерны формалаштыру казанлылар өчен тискәре саналган сыйфатларны барлау аркылы дәвам итә: «Күңелеңдә хөсетлек, калебеңдә комсызлык, саранлык юкмы, кулың кәкре түгелме, телең йозактамы, күзеңне нәфес пәрдәсе капламаганмы, йөрәгеңне май басмаганмы, эчке хасиятләрең тышкысына туры киләме?» Шунда ук уңай сыйфатлар да ачыклана: «Аягың житез, зиһенең йөгерек, кулың нык, сүзең акыллы, йортың таза, авызың биктә булсын!» Тискәре сыйфатларны башка милләт вәкилләрендә төп үзенчәлекләрдән итеп кую (Иванда—хөсетлек, караклык, Василийда—комсызлык, Иван патшада—нәфес һ.б.) милли характерларны да капма-каршы китерә.

Вакыйгалар агышында геройларын батыр һәм тәвәккәл, чыдам һәм түзем итеп сурәтләгән автор бу сыйфатны да төп герое Сәет авызыннан әйттерә: «кызларның түземлегенә, чыдамлыгына хәйран калды Санька». Тагын бер сыйфат, аерым бер күренешләрдә ныгытылып барган үзенчәлек—горурлык: «Алар горур иде. Карашларын яшермичә, үч һәм нәфрәт кайнаган күзләрен дошманнарына туп-туры төбәп тордылар (...) Татар әсирләренең үлемнә өстен күрүе, горур батырлыгы аларны таң калдырды».

Аерым бер урыннарда казанлылар холык-фигыле автор-хикәяләүче авызыннан да бәяләнеп бара. «И киң күңелле укучым, шуны белеп тор: без тасвирлап яткан бу заманнарда Казан дәүләтендә адәм баласы хөсетлекне белми иде, күзгә карап астан пычак белән кисү юк иде. Хәйлә, мәкер вә астыртынлык бик сирәк затларның гына коралы булып, алар иң бозык, фасикъ адәмнәр исәпләнер, кылганнарының язык икәнлеген күпләр белеп торыр, вә һәм дә алардан котылу чарасын күрер иде...»

Милли логика, фикерләү үзенчәлеге дә шактый тулы һәм җентекле билгеләнгән. Бу яктан, хикәяләүче-автор һәм аерым геройларның фикере кебек китерелгән бәяләмәләр шулай ук әсәр тукымасына бик табигый ялганып бара. «Казанлыларның кунак сыйларга, назланып, ялындырып кына сыйлатырга яратуы мәгърипттә дә, мәшрикъта да билгеле анысы», «казанлылар

тар күңелле түгел». Бу халыкның башкаларга хөрмәт белән каравы игътибарга алына: «Казанлылар чит-ятларның гореф-гадәтенә тыкшынмый». Аерым бер бүлекләрдә милли фикерләү, дөньяга караш хакында сөйләү этнографик материал белән үрелеп китә, милли характерны да ачуда катнаша. «Теге яки бу халыкның борынгылыгын, зәвыгының камиллек дәрәҗәсен белергә теләсәң, аның хатын-кызларына, аларның да кием-салымына, үз-үзен тотышына игътибар ит, дигән акыл иясләре. Бу җәһәттән Казан кызлары бик күп кавемнәргә, тирә-яктагы эреле-ваклы ыруларга үрнәк булырлык иде. Кул эшенә, төрле-төрле һөнәрләргә ия булу белән бергә, аларга тыйнаклык, басынкылык, һичкем алдында каушап калырга ирек бирмәслек дәрәҗәдә горурлык, чамасын белеп кенә уенчаклык хас иде. Кием-салымнары да шул хасиятләренә туры килеп, бик күп мосафирларны сокландырырдай чибәр иде». Язучы тормыш-көнитешне тасвирлау аша югары мәдәнияткә ия, иркенлек-хөрлек һәм матурлыкка табынучы, киң күңелле һәм башка халыкларга тиң итеп караган милли бердәмлек сурәте тудыра.

Кол Шәриф образы милли менталитетның тагын бер ягын—гыйлемгә мөнәсәбәтне ача. Бер үк вакытта ул язучыга Казан ханлыгы чорындагы космогоник күзаллауларны тергезергә мөмкинлек биргән. «Яшәеш һәм һәлакәтнең галәм әйләнеше фасылларына бәйлелеге» фәлсәфәсе Казан ханлыгының жимерелү сәбәбен ачыклау кебек яңгырый. Ләкин язучы вакыйгаларны язмыш кысаларында аңлату белән чикләнми. «Гөнаһны да, җәзаны да кеше үзе уйлап чыгарган (...) Ә нәрсә көткәнен мин әйтә алмыйм, киләчәгегезне сез үзегез корасыз. Бүгенгегез, үткәнегез белән аңа нигез саласыз. Котылу юлын да үзегез табарга тиеш». Кол Шәрифкә житкерелгән бу хакыйкать язучының тарихи вакыйгаларга бәйле әйтелгән фәлсәфәсе дә булып тора.

Романда Сәет һәм Гөлйөзем мәхәббәте соклангыч, бар нәрсәдән өстен көч буларак яратуны югары күтәрә. Мәхәббәт фәлсәфәсе балыкчы карт авызыннан әйттерелә: «Дөньяда адәм балалары бер-берсе өчен яратыла. Ялгыз кеше—ярты кеше. Бербөтен булу өчен әнә шул үзенә билгеләнеп дөньяга килгән затны таба, аның өчен көрәшә белергә дә кирәк». Мәхәббәтнең бу милли тирәлектә хөрмәт ителүен язучы Сәет һәм Гөлйөзем хисләренә Шәһитнең, Галиәкбарның, Кол Шәрифнең һәм башка геройларның мөнәсәбәтен күрсәтү аркылы тагын бер кат ассызыклый.

Шулай итеп, табигать һәм тирәлек, холык-фигыль һәм дөньяга караш үзенчәлекләре аркылы Ф. Латыйфи милли тормыш картинасын, татар тормышының тулы сурәтен тудыруга ирешә. Авторның идеалы кебек аңлашыла торган бу модельгә капма-каршы икенче бер дөнья—рус тормышы булу искәртелеп барыла. Ләкин язучы осталыгы вакыйгалар тезмәсендә ике милли модельне кушып-үреп жибәрергә дә мөмкинлек бирә. Савелий Кузьмич образына тупланган күп кенә сыйфатлар татар кешесендә беренче планда тора. Акыллы, гадел, комсызланмаучы, башка милләт-дин вәкилләренә хәерхаһлы сәүдәгәр Булгаков бер генә милләтне дә стереотип кысаларга кертеп бәяләргә ярамауны искәртә сыман.

Бу яктан, Сәет образы бик отышлы уйланылган. Тамырларында ике милләт каны аккан Сәет-Александр язмышы символик мәгънәгә ия. Автор бу геройга салынган мәгънәви тирәнлекне «хыянәт» сүзен уйнату аша тагын да арттыра. Шушы ачкыч-сүз әсәрнең буеннан-буена кабатланып бара, вакыйгалар катламында гел калкып чыгып тора. Беренче бүлектә, Сәетнең Нургали белән очрашу мәжлесендә үк хыянәтнең иң олы жинаять, кичерә алмаслык эш булуы искәртелә. «Инде безгә хыянәт кылсаң, серебезне ятларга чишсәң, аны үз мәнфәгатең өчен генә файдалансаң, башың чапкылыкта бетәр», ди базарбашы. Икенче төп сюжет сызыгы, Сәетнең үз эчендә барган көрәш тә шушы сүз белән бәйле. Нәрсә ул хыянәт? Моннан унжиде ел элек якыннарын алдап, сөю хакына башка дингә күчү, башка кеше булып яши башлаумы? Яки үзенә ышаныч күрсәткән җәмгыятьтән, яраткан хатының һәм балаларыннан яшереп, кан-кардәшләрең русларның мәкерле эшенә катнашумы? Ил өчен сугыш барганда, бер якка да кушылмыйча, хыянәттән сакланып калып буламы? Сәет язмышы бу сорауларга җавап бирә. Ләкин «хыянәт» сүзе белән уйнау төп герой тарихында тәгәлләнми. Ачкыч-сүз дә романда әледән-әле кабатланып тора. Иван-сәүдәгәр дәүләт серен әйтүне хыянәт саный

(«Хыянәткә кереп, җанымны пычратасым килми»), Василий өчен энесенең кайчандыр Казанда калуы—хыянәт («Ышанмады ул синең үлгәнеңә... Хыянәтеңә ышанмады...»), Сәет исә моны хыянәткә санамый, бу сүзгә кемнәргәдер зыян китерә торган эшләрне генә кертеп карый («Ул үзен хыянәт иткән дип санамый, әмма бик үк туры юлда булмаганлыгын да белә. Дөрес, мал белән, акча белән, кемнеңдер мөлкәте белән эш иткәндә гадел куллы, туры сүзле булды, хәрамга бармады»), аның өчен Василийның тәкъдиме—хыянәт, чөнки ул аның гаиләсенә, якыннарына яный. Әсәрдә ике төрле аңлау мөмкин булмаган хыянәт тә очрый: Камай морзаның Казанны ташлап чыгуы, сатылуы хәтта русларда нәфрәт уята. Ләкин хыянәткә ике хакыйкать сыйган булырга да мөмкин икән ләбаса! Василийның Җәгъфәр үлеменә сәбәпче булган ук белән җибәргән хаты, аннары сугышка күтәрелеп, энесен кадап үтерүе, яки Сәетнең хатыны, улы, дуслары белән бергәләп көрәшкә кушылуы һәм абыйсын чәнчүе шикелле. Әлеге сүзне уйнатып, язучы рус—татар каршылыгының да бөтенләй башка яссылыкта аңлануына китерә. Каршылык, сугыш—хыянәт түгел, ике милләтне сугыштыру—хыянәт, ди автор. Идеясенең дөреслеген төп герое Сәет авызыннан тагын бер кат ассызыклый: «Ярдәмләшеп яшәгән мөселман белән христианның дошманлашуы гөнаһ! Моны Алла кушмый.»

Әсәрдә «сер» сүзе дә әһәмиятле урын били. Язучы вак кына тормыш-көнкүреш детальләреннән алып яшәеш кануннарына кадәр—барысын да укучы кызыксынырлык сер итеп бирә, үзе дә шушы сүзгә еш мөрәҗәгать итә. Чаң тавышларының (хәбәр итү), Казан сәүдәгәрләренең (тамга), шәһәрнең үзенең (җир асты юлы) һәм тормыштагы вакыйгаларның да (дисбе) сере бар. Һәр герой, бигрәк тә Сәет, Прасковья, Иван, Мәмәт, Галиәкбар язмышы сер саклый. Мәхәббәт һәм сагыну, югалту сере җырга әйләнә. Болар барысы да әсәрне уку өчен кызыклы һәм тәэсирле итә.

Ачкыч-сүзләргә мөрәҗәгать итү, җеп очын яшерү алымнары авторның осталыгы хакында сөйли. Моннан тыш, язучының әзерлекле укучы аңларлык, мәгънә мөмкинлекләрен киңәйтерлек мәгълүматларны текстка урнаштыру сыйфатын да әйтеп китү урынлы булыр. Мәсәлән, шундыйларның берсе—Сәет улының исеменә салынган символик мәгънә. Җәгъфәр—Г.Исхакый әдәбиятка кертеп җибәргән («Ике йөз елдан соң инкыйраз»), аннан соң XX йөз башында күп кенә татар прозаиклары иҗатында файдаланылып, Г.Гобәйдуллин тарафыннан символ дип билгеләнгән исем. «Елаучы Җәгъфәр»—татарлык, татарларның үз азатлыгы һәм киләчәге өчен көрәшүчесе символы ул. Шушы контекстта Ф. Латыйфи герое да үзенчәлекле кабул ителә башлый. Аның холык-фигыле һәм фаҗигале тәгәлләнгән язмышы милләт киләчәгенә барып тоташа.

Милли реализм агымында иҗат итү Ф. Латыйфига, татар тарихындагы аерым бер сәхифәләрне тергезү белән чикләнмичә, милләтнең бөтенлекле сурәтен тудырырга ярдәм итә. «Без—татарлар нинди?» соравына әдәби әсәрдә җавап биргәннән соң, автор публицистик-фәнни җавап варианты да бирә: күләмле «Алтын тамырларыбыз» дигән мәкалә эшли. Анда мондый юллар бар: «Тарих белә: татарлар һәм аларның бабалары гаярь сугышчылар гына түгел, ә бәлки үз чоры өчен Көнчыгыш Европада иң югары культурага, һөнәрчелек-кәсепчелеккә, бай мәдәнияткә ия кешеләр. Тарих белә: урыс дворяннарының, аксөякләренең, сәргаскәрләренең, шагыйрьләре һәм галимнәренең байтагының тамырында татар каны ага(...)» Шуның белән Ф. Латыйфи тарихи роман жанрына мөрәҗәгать итү сәбәбен дә ача. Бу жанр тарих белгәнне белдерергә, тарих күргәнне күрсәтергә, бүгенгегә тарих күзлегеннән бәя бирергә ярдәм итә!

Романда мифологик ышанулар һәм халык авыз иҗаты җәүһәрләренең бик табигый рәвештә әсәргә кереп урнашуы, үзенчәлекле, бүгенге укучы тарафыннан борынгы кебек кабул ителә торган тел тудырылу хакында тәнкыйть инде язды, унай бәяләде. Болар—авторның фольклор белән чынлап, җитди шөгыльләнүе, күп уку-эзләнүе нәтиҗәсе дә. Бер генә мисал: 1993 елны Ф. Латыйфи румын татарлары теленнән тәрҗемә итеп, кереш сүз белән «Чура Батыр» дастанын бастырып чыгара, төрки халыклар мирасын барлау һәм таныту эшенә үзеннән өлеш кертә.

«Хыянәт»не язганда сайлаган иҗат сукмагына тугрылыклы калып, автор «Ишелеп төшкән бәхет» (1999 ел) дигән яна роман яза һәм милли тормыш картинасын тарихи материалда гына түгел, бәлки безгә таныш чынбарлык

мисалында да күрсәтү мөмкинлегенраслый. Реалистик юнәлештә иҗат ителгән әсәр татар тарихында «ак тап» булып, күпләрнең күңелләрен эчтән генә сызарга-әрнергә мәҗбүр итүче сәхифәләрне якты көнгә чыгара. Һаман кычкырып әйтелмәве сәбәпле дә, татар язмышында бик зур роль уйнаганлыгы өчен дә тәэсирле һәм уйландырырлык шундый проблемаларның үзәктәгесе—совет хөкүмәтенең татарларга каршы алып барган геноцид сәясәте. Радиоактив матдәләр белән эшләүче хәрби объектларга татарларның күпләп җибәрелүе хакында сөйләү солдаттан кайткан егетләрнең серле үлемнәре яки эчүгә сабышулары сәбәбен ача, бу сәясәтнең милләт тамырына балта чабу—аның таза-сәламәт генофондын юк итү булуын күрсәтә. Шуның белән бергә, әлеге сәясәтнең руслаштыру тегерменәнә су коюын да (Асиянең руска кияүгә чыгуы мисалында) искәртеп үтә.

Романның геройлары, армиягә барырга тиеш тә булмаган Сирин, авылдашы Рифгать, Ильяс Комаровлар—шушы тәмуг оясында канатлары сындырылган, язмышлары җимерелгән шәхесләр. Аларның фаҗигале тормышы кешене чүпкә дә санамаган хакимият һәм шәхес каршылыгында һәм милли яссылыкта бәяләнә.

Хакимиятнең татар милләтенә каршы алып барган сәясәтен 1945 елда ерак Чәнчүн шәһәрендәге татар гаиләләренә китерелгән кайгы-хәсрәт, Г. Исхакый шәхесеннән дошман ясау мисалында күрсәтү, илдән читтә яшәүче татарлар хәтерендә саклanучы җәрәхәтләрне барлау, татарлар кулы белән милләттәшләренә каршы эшләтелгән явызлыклар да ачып сала. Шушы фаҗига очраштырган Хафиз һәм Оркыя, Әмиржан Акчуриннар бәйләнеше алдагы буында Сирин һәм Галия, Илдарлар язмышына килеп кагыла. Хафиз гомерлек үкенеч булырлык эшкә тарыган—Әмиржан хатын ертып ташлаган кичтә рус солдатының Тукай портретына кул күтәрүе һәм егетләр арасында чыккан сөйләшүнең автор тарафыннан шәрехләнүе солдатларга ил иминлеге белән бәйләп аңлатылган эш-гамәлләрнең милли нигезен, татарларга каршы алып барылган сәясәтнең асылын билгели.

Гомумән, әсәрдә көтелмәгән янәшәлекләр, очраклылык кебек тә, закончалык итеп тә аңлашыла алырлык вакыйга-күренешләр күп. Хафиз һәм Әмиржан линиясе, беренчесенең улы Сириннең Әмиржан балалары Илдар һәм Галия белән очрашуы, Сириннең яраткан кызы Асиянең Галия белән туганнар булып чыгуы да, Хафиз һәм Әмиржанның язмышына кергән Гыймаевларның киләсе буынга да явызлык китерүе дә шундыйлардан. Мондый кисешү-ялгаулар әсәрне мавыктыргыч һәм кызыклы итә, эчке мәгънә төсмерләре белән балкыта.

Миллилек әсәрнең төп сюжет сызыгында ук күзгә ташлана. Акыллы, булдыклы, намуслы татар егете—булачак фән кешесе, математик Сирин Сабиров көтмәгәндә хакимият-хөкүмәт белән каршылыкка керә. Дамир Гыймаев белән кыз өчен башланган юк кына тартыш Сириннең армиягә алынуы, кеше гомере өчен гаять тә куркыныч урынга җибәрелүе, анда сәламәтлеген югалтуы, мәхәббәтеннән баш тартуы булып үсә. Армиядән кайтып, тормышын җайга сала башлаган егет янадан Дамир Гыймаевлар алып барган күзәтүгә эләгә, аны чит һәм куркыныч кеше итеп күрсәтү уены башлана. Бу тартыш Сириннең үз илендә кирәксез, кадерсез, хокуксыз кеше булуын аңлавы белән тәгәлләнә. Татар егете үз җирендә тибәрелгән ялгыз кеше булып кала. Шул язмышка капма-каршы итеп тасвирланган Илдар тормышы, аның карьера ясау—«йомырка кабыгын ватып чыгу» тарихы исә ерак Америкада хәлләрнең бөтенләй башкача икәнлеген искәртеп тора. Америка белән чагыштыру, соңгы еллар матбугатында алып барылган сәясәт нәтиҗәсендә, бераз сискәндерсә дә, акыл шунда ук каршы төшә: илнең үз егет-кызларын чүпкә дә санамавына мисал эзләп ерак барасы юк бит! Бер үк вакытта Сирин һәм Илдар язмышларының янәшәлеге фәлсәфи аңланылу мөмкинлегенә ия. «Хыянәт» авторы, әйтерсең лә, мөстәкыйльлеген югалткан татарларның чит халык кул астында яшәвен, татарларга каршы алып барылган рәсми һәм яшерен сәясәтне генә күрсәтеп калмый, бәлки бу мөнәсәбәтләрнең башка юлдан китү мөмкинлеген искәртә, Америкадагы татарлар мисалында шуның идеаль моделен тергезә.

Хакимиятнең гыймаевлар кулына бирелүе, Гыймаев—Хафиз, Дамир—Сирин, Дамир—Асия каршылыкларында кабатланып, власть башында

утыручыларның үз мәнфәгатьләрен алга сөрүен, шәхси сыйфатларның милләтләр язмышына тәэсир итәр көчкә әверелүен үткен проблемага әйләндерә. Гыймаевларның татар милләтеннән бирелүе кат-кат искә төшерелә торган милли сыйфатка янә бер кат ишарә итә.

Романнын милли хасияте образлар белән танышканда да тоела. Сирин—теләсә нинди шартларда, заманда милли каһарман була алырлык егет. Автор аны заман герое итеп сурәтләгән (ул Ф. Латыйфиның «Ак-карага тимәскә» повестенда ук табылган иде). Әйтерсен, шушы герое аша язучы заман героеның хакыйкатьне бар нәрсәдән дә өстен куючы, яраклаша-җайлаша белмәүче, үз асылына-табигатенә тугрылыклы кеше булырга тиешлеген белдерә. Бер үк вакытта роман мондый геройның бу чорда үз урынын таба алмавын, үз көчен милләт файдасына эшләтү мөмкинлегеннән мәхрүм булуын да искәртә. Аның югалуы яки чит илгә китүе, бәхет-мәхәббәтеннән, киләчәгеннән, шушы җир өчен көрәшүдән баш тартуы, бер яктан, күңелдә канәгатьсезлек уятса, икенче яктан, үз хәл-халәтебез өчен ачынуны арттыра гына.

Милли-матур хасиятле Асия, Хәдичә апа образлары да җиренә җиткереп, яратып иҗат ителгән. Әсәрнең теле бай, нәфис. Психологик анализ алымнары уңышлы. Алар студент Сириннең рухи дөньясы, кичерешләре хакында сөйләгәндә, нәкъ менә татар авылыннан килгән егетнең холык-фигылен, дөньяга карашын күрсәтүгә хезмәт итә.

Әсәрдә «бәхет» сүзе, «ишелеп төшкән бәхет» ачкыч ролен үти. Ишелеп төшкән—язмышларны сындырырлык хәсрәт мәгънәсендә дә, кара бәхет кебек тә аңлашыла. «Чыннан да, болар миңа бәхет телиме, әллә, киресенчә, минем бәхетемне ишеп төшерергә маташалармы? Кеше үз бәхетен үзе корырга тиеш түгелмени?»—Сириннең бу сүзләре, һәр кешенең үз бәхетен үзе төзү мөмкинлеге кебек, иҗтимагый яңгыраш ала, системага тәнкыйть булып яңгырый. Аерым кешеләрнең башкалар бәхетен җимерүе әхлакый яктан бәяләнә. Бу гыйбарә 1945 елны, 1970—90 елларда татарларга каршы алып барылган сәясәтнең тамырлары буйлап китеп, 1917 ел инкыйлабына, «Хыянәт» романын хәтергә төшереп, 1552 елны дәүләтчелекне югалтуга—шуларның татар өстенә «ишелеп төшүенә» ишарә бирә: милли мәсьәләгә әверелә. Бер милләтнең икенчесенә аяк чалуы, каршы төшүе хакындагы нәтиҗәгә китерә. Бер үк вакытта төшенчә фәлсәфи аңланылышка ия. Бәхет һәм бәхетсезлек—сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә (Сириннең Асияне яратуы армиягә алынуга сәбәп булган кебек), алар арасындагы чик шартлы билгеләнеп, автор укучысын төрле катламнарда билгеләнгән бәхетсезлектән котылуга үз өлешен кертергә чакыра. Кайбер урыннарда чын дуслык, ярату, үзара хөрмәт, туганлык хисләренең кеше өчен чын бәхет булуы да шушы гыйбарә белән янәшә кабул ителә.

Әсәрдә бәхәсләшер, уйландырыр урыннар күп. Сирин язмышының ахыры, аның үз мәхәббәтеннән баш тартуы кебек моментлар яңадан романның төрле урыннарына әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә. Әсәр шуның белән дә кызыклы, шуның белән дә тәэсирле. Бу романда да автор укучысын кызыксындырып, «бөтереп» алып кереп китәрлек—Америка товарларының күргәзмәсе оештырылу вакыйгасын тапкан. Бер-берсенә охшамаган, һәрберсе үз язмышы белән яшәүче, һәрберсе бөтенлекле характер дәрәҗәсендә иҗат ителгән геройлар, тегеләйме-болаймы, милләткә мөнәсәбәт сынавына юлыга. Шуны узганда үзгәрә, еш кына асылын югалта.

Әсәрдә хикәяләүче-автор образы калку сурәтләнеп, аның милләтпәрвәр, милләт кайгысы белән яшәүче, киләчәк хакында уйланучы сыйфатлары беренче планга чыгарыла. Романны тәмамлаучы «Автордан» өлеше, әйтерсен, татар әдәбиятында өр-яңа ике проблема: 1917 елдан соң чит илгә киткән татарларны юк итү һәм совет чорында татарларга каршы алып барылган геноцид сәясәтләрен күтәреп чыккан язучының үз укучысын бу хәлләрнең чынлыгына гына түгел, бәлки зур афәт булуына ышандырырга омтылуы, чынлык эффекты бирү булып аңлашыла. Бу өлештә әдәбиятка кагылышлы, милләт язучысы уйлана һәм борчыла, тормыштагы һәр нәрсәне акыл үлчәвенә салып карый торган укучы тәрбияләүгә омтылырга тиеш дигән фикер дә ярылып ята.

Хәзерге татар романнарына күзәтү ясаганда, Ф. Латыйфи алардагы күләмлелек-колачлылыкның еш кына бүгенге заман укучысы өчен тискәре

сыйфатка әверелеп китүен күрсәткән иде. Бу яктан, язучы роман материалын җыйнак бирү юлын-алымын үз иҗатында күрсәтә. «Хыянәт»тә бүлек исемнәре, эпиграфлар, кыска-җыйнак формада, вакыйга-хәлләрне автор теләгән дулкында кабул итәргә әзерли, күпсүзлелектән котылу чарасына әйләнә, бүлекне укый башлаганчы ук хис-кичереш кырын көйли, укучыда билгеле бер халәт хасил итә. «Ишелеп төшкән бәхет»тә дә язучы тәҗрибәләрен дәвам итә. Әсәр текстына кертеп җибәрелгән хатлар зур вакыйга-хәлләрне тирәнрәк аңларга мөмкинлек тудыра, геройларның аларга мөнәсәбәтен билгели. Моннан тыш, язучы ике төрле сурәтләү алымын үреп бара: укучы өчен кызык булырлык күренешләрне җентекләп-детальләп бирә, аларны геройларның хис-кичереш, уй-фикер агышын сурәтләү белән кушып җибәрә. Ә инде иҗтимагый-сәяси, тарихи-фактик мәгълүмат әйтеп үтелә, шәрехләнми, шуның белән укучыга да үз бәясен бирергә, үз фикерен булдырырга урын кала.

«Милли тормыш картинасы» бу романда, барыннан да элек, төп герой Сирин һәм аның янәшәсендәге Илдар, Ильяс, Асия кебек яшьләрнең холык-фигыле аша барлыкка китерелә. Бер үк вакытта милли логика, дөньяга карашның үткәндә калган, инде югалып баручы кыйммәт итеп тасвирлануы сизелә: бу, бигрәк тә, доктор Янисның сугыш чорындагы Балтамак авылын бәяләвендә, Хәдичә апага һәм Оркыя ханымга хас сыйфатларның өлкән буын вәкилләрендә яки чит илләргә китүчеләрдә генә саклануын искәртүдә ачык чагыла. Милли көнкүреш-көнитешкә алмашка башка халык традицияләре килү, татар гаиләсе, авылы, җәмгыятенең үз йөзен югалтуы шулай ук үткен мәсьәлә төсен ала.

Автор осталыгын күрсәтүче тагын бер үзенчәлек аерып бәяләнергә лаек, ул—язучының типиклаштыру максатында ниндидер деталь-сызыкны, аталып кына үтүче геройларны файдалануы. Мәсәлән, Сирин гомерендәге кечкенә генә аралыкны—аның сырахәнә юлын таптавын тасвирлау өлеше система сындырган акыллы кешеләр язмышын типиклаштырса, Сириннең әти-әниләре язган хаттагы Рифгать үлеме аны армиядәге ялган һәм күз буяу гомерләрен өзгән күпләрнең берсе итеп кабул итәргә юл күрсәтә. Эпилогтагы «Күзәтүче» донесениесе Рәсәй дип аталучы иксез-чиксез илне төрмә итеп бәяләргә мөмкинлек бирә, ә инде?. Акчурин хатына Чита өлкәсе прокурорының җавабы хәбәрдарлык җилләренең генә бу төрмә диварларын аудара алмавына дәлил булып яңгырый.

Әсәрдә фәлсәфи катлам көчле һәм ул автор фикере-идеясе белән тоташып китә. Төрле вакытка мөрәҗәгать итү, сугыш чоры һәм бүгенге көн геройларын бер җепкә ялгау нәкъ менә шушы катламны тирәнәйтә дә. Һәр кеше—киләчәктәгеләр алдында җаваплы, үткән буыннар, аталар хатасы-ялгышы бүгенгеләргә бәхетсезлек булып «ишелеп төшә», бүгенгеләр ялгышы киләчәктә кайтаваз булып яңгыраячак, дигән язучы укучысын язмышына үзе хуҗа булырга, эш-гамәлләр кылганда балалар-оныклар бәхетен күз уңында тотарга чакыра.

Әдәбиятта милли характер, милли тормыш моделе хакында уйлану Ф. Латыйфиның хикәяләренә дә тәэсир ясады. Бу жанрда да автор әхлакый—гомумкешелек проблемаларыннан милли-фәлсәфи яссылыкка күчә бара. Бер генә әсәргә, авторның олы уңышы, табышы дип бәяләнергә хаклы «Көмеш беләзек»кә тукталыйк. Кечкенә генә хикәя—татар карчыгының соңгы көннәрен сурәтләүче моңсу әсәр чын мәгънәсендә үткен проблемалар күтәрә: традицияләрнең, милли кыйммәтләрнең югалуы хакында уйланырга мәҗбүр итә. Нәсел мирасы булган көмеш беләзеген Җиһан карчык үзе үлгәндә балаларына калдыра калдыруын, ләкин аларның беләзек хикмәтен аңламаячагын, оныкның беләзектән медальон ясатачагын белгән укучы күнелендә язучы милләтнең киләчәгенә карата борчу уята.

Җиһан карчык—татар әдәбиятындагы Акъәбиләр дәвамчысы. Менә әсәрнең беренче күренеше, Җиһан карчыкның үзенә иптәшкә калдырган чуар тавыгы белән «сөйләшүе»:

«Менә коштабагын күтәреп ишегалдына чыгар, бер кукәй салып бөтен дөньяны яңгыратучы тавыгын шелтәли-шелтәли аның ашаганын күзәтер.

—Кыт-кыт-кыт,—дияр тегесе.

—Әйе шул, авырып торам әле. Бүген соңлабрак чыгылды инде,—дияр

Җиһан. Тавыкның үз көне—көн, үз теле—тел: «Кыт-кыт-кытак»,—диеп кабатлар.

—Шулай шул, инде мина да вакыт житкәндер, ахрысы,—дияр Җиһан. Әйтсә дә үкенеп әйтми ул аны.»

Шушы күренештә үк күз алдына йомшак күңелле, тирә-яктагы кош-корт, үлән-агачлар белән сөйләшеп йөрүче, үзе дә табигатьнең бер баласы кебек яшәп яткан өлкән буынның бер вәкиле килеп баса. Сугыш афәтләрен, җан өшеткеч авырлыкларны күргән карчыкның күңеле катмаган, тупасланмаган. Мондый әбиләр дә—инде югалып баручы милли хәзинәбез ләбаса, дип куясың.

Хикәя мифологик катлам: беләзекнең өч хикмәт күрсәтүе белән баетылган. Җиһан өстәлендә кәрәзле бал, мәтрүшкәле чәй табыны пәйда булу, аннары аның югалуы карчыкның саташуы кебек аңлашылырга мөмкин булса да, язучы аның чынлыгына ышандырырга омтыла. Бу катлам серле-хикмәтле булуы белән кызыксындыра, бер үк вакытта беләзекнең асыл кыйммәтен арттыруга хезмәт итә. Җиһанның беләзек хикмәтен элегрәк файдаланмавына үкенүен кабатлап, язучы фәлсәфи нәтиҗәгә алып килә: «кеше никадәр генә дөрес яшәргә тырышмасын, гомер ахырында барыбер үткәненнән үкенерлек сәхифәләр таба». Әсәрнең башында Җиһан уйларында әйтелгән: «Кеше гомере кыска да, озын да була ала. Ничек яшисең бит?» дигән сүзләр карчыкның үз гомерен искә төшерүе янәшәсендә әлеге фәлсәфәне дәвам итә. «Башкаларга файда итеп яшәлгән гомер озын була», ди сыман. Бу фәлсәфә йөзек эченә язылган сүзләр белән дә керешә: «теләсә нинди таш гәүһәр булмаган кебек, яшәлгән еллар саны гомер озынлыгын билгеләми». Нәтиҗәдә, укучыны үз гомере, яшәү мәгънәсе хакында уйлануга этәрә.

Хикәядә Җиһан карчык үлгәннән соң казанга салынган чуар тавык һәм эрстеләчәге—медальон коелачагы мәгълүм көмеш беләзек, беркемгә дә кирәксез икәнлеге аермачык сандык бер-берсен көчәйтеп киләләр, беләзеккә салынган символик мәгънә башка детальләр белән тирәнәйтелә. Геройларның исемнәренә яшерелгән сер дә өлкән, урта һәм яшь буын геройларны аллегорик-символик планда кабул итүгә юл калдыра. Җиһандагы сабырлык һәм табигыйлек, башкаларга кирәкле булып һәм борчу китермичә яшәү фәлсәфәсе—автор өчен идеал булса, урта буындагы һәм яшьләрдәге матди-практик дөньяга карашның беренче урында торуы сискәндерә. «Ядкарьсез кеше ярлы була, сукбай булып яши, сукбай булып үлә» дип, Җиһан карчык уенда әйттерелгән сүзләр милләткә мөнәсәбәтле гомумиләштерелә.

Сайлаган сукмагында калган хәлдә, 1990 еллар уртасында Ф. Латыйфи татар әдәбияты аз игътибар иткән өлкәгә аяк басты һәм фантастиканы милли фәлсәфә белән үреп, татар укучысы өчен үз тоелырлык, тәрҗемә яки рус-аурупа авторлары фикеренә ияреп түгел, оригиналь иҗат ителгән әсәрләр бирде. «Танир Сулф» тәхәллүсе астында дөнья күргән, Ринат Якушев белән бергәләп уйланган повестьлар татар фантастик китабын мондый юнәлештәге дөнья әдәбияты үрнәкләре белән ярышыр баскычка күтәрде.

Беренче карашка повестьлар, фантастик булудан бигрәк, ирреалистик әсәр итеп уйланганнар кебек тәэсир кала. Беренчесе—«Тамга» теләсә кайсы татар кешесенең аң төпкелендә пәйда булып ала торган хыялны: 1552 еллар тирәсенә әйләнеп кайтып, Казан ханлыгы фаҗигасен булдырмый калу мөмкин түгелме икән дигән гайре табигый фикерне тормышка ашырып язылган. Повестьтагы вакыт та икәү: төп герой Маратның, фантастик машина—супертранспьютер тәэсирендә, ерак буыннар хәтере уяна, ул Казан ханлыгы чорындагы кодрәтле Морат бәккә әйләнеп, тарихны үзгәртергә омтылып карый. Ләкин бу теләк авторларның фәлсәфи нәтиҗәсен генә ныгыта: узганга тәэсир итү мөмкин түгел! Бәлки, бүгенгене үзгәртү кешенең кулыннан киләдер?! Татарларның мөстәкыйльлеккә омтылышы көчәйгән, милли үзаң хәрәкәткә килгән бер вакытта язылган әсәр шушы идеясе белән дә сокландыра.

Гадәттә, фантастик әсәрләр коры тел, корыч логиканы ярата төшә, шуңа да аларда мавыктыру өчен сурәтлелек түгел, бәлки акыл уены файдаланыла. «Тамга» исә лирик-җылы дулкында, үзәк геройлар Марат/Морат бәк, Лотфи, Әхмәт Сихәтович/Сихәт бәй, Залинә образларын характер дәрәҗәсендә ачып, үткән һәм бүгенгене үз теле, үз детальләре һәм заман сулышы бөркелеп торырлык итеп язылган. Әсәрдәге һәр вакыйга-күренеш, һәр деталь күпмәгънәлелеккә ия. Мәсәлән, Залинә исеме белән бәйле маҗара укучыны кызыксындырып

кына калмый, сюжет үсешен аңлатып та килә, бер үк вакытта Марат/Морат бәк характерын ачуга ярдәм итә. Яки барымтадан кайтучы Касыйм белән Морат бәк очрашуы, бер яктан, сюжет сызыгындагы әһәмиятле буын булса, икенче яктан Морат яки Касыйм, Сихәт бәй кебекләрне әхлакый бәяләргә, Яхшылык һәм Явызлык, Мәрхәмәт һәм Хөсетлек, Киң күңеллелек һәм Эчкерлелек кебек гомумкешелек кыйммәтләрен аңлатырга юл ачса, тарихи яктан Казан ханлыгының җимерелү, тирә-яктан ярдәм ала алмау сәбәбен билгеләп куя, фәлсәфи яссылыкта исә мал, байлык беренче планга чыкканда, кешенең кадере-кыйммәте югалу турындагы нәтиҗәгә алып килә. Шулай итеп, фантастик уйланма-тышкы кабык, эчтәлек катламы булып кала, ә инде асылда «Тамга» кеше, яшәеш, үткән һәм бүгенге хакында уйланып язылган милли-фәлсәфи әсәр дип бәяләнергә лаек.

Повестьның исеме милли-символик яңгырашка ия: тамга—хәтер, тамга—тарихны һәм киләчәкне белергә ярдәм итүче билге, тамга—буыннан-буынга тапшырыла килүче холык-фигыль, тамга—ялгышу яки уңышның милләт язмышына әверелүе, тамга—һәр кешенең киләчәккә җибәрә торган хәбәре дә. «Тамга» авторларның киләчәк буынны кисәтүе, милләтнең иртәгесен кайгыртып хәвефләнүе кебек тә аңлашыла, чөнки әсәр җебенең төенләнү ноктасы—танып булмаслык язулар «тылсымлы инану сүзләрен» сөйләргә, кабатларга чакыра. Милләт язмышы хакында үзең инанганны тәкърарлау, шуны укучыга җиткерү—язучы, иҗатчы кешенең иң төп бурычы, әлбәттә.

Икенче повесть—«Игезәкләр», әйтерсең, беренчесен дәвам итә. Кайчандыр супертрансnúmьютер хикмәте белән үткәнгә сәяхәт иткән Маратның «игезәге» пәйда булу, аның Марат та, Морат бәй хәтерен саклаучы да икәнлеге сер томанына төрелгән. Авторлар бу хәлнең саташу-аң югалту нәтиҗәсе булуын да кире какмый, ләкин «игезәкне» Лотфиның да күрүе хакындагы соңгы вакыйга гайре табигый хәлне чынбарлык кебек аңларга юл ача. Фантастик катлам милләтнең бүгенгесенә бәя бирү вазифасын башкара. «Игезәк», Морат бәй исеменнән, мондыйрак сүзләр әйтә:«Сез хөрлегегезне җуйгансыз(...). Сез кем икәнлегегезне оныткансыз, горурлыгыгыз югалган(...). Кайда безнең хөрлек, иркенлек?! Дин беткән, дин беткән Казанда... Иман беткән! Ул гынамы? Тел беткән, кайчангы дошманыбыз телендә дөрес итеп сөйләшә, аңлаша алуны дәрәҗә саный башлагансыз». Шунда ук бүгенге укучыга юнәлгән сүзләр килә: «Бүген беркем дә сезне дин тотмаска, татар иманын сатмаска мәҗбүр итми. Иманлы, динле, денле булу авыр, ай-һай, авыр эш! Яулап алган халыктан сезгә җинүчеләрдә тамыр җибәрә торган рухи ялкаулык ингән. Шуннан котылмыйча торып, Казан горурлыгын, татар иманын янартмыйча торып сез бу йокылы-уяулы сәрхуш тормыштан, имансызлык баткагыннан чыга алмассыздыр, шөт». Бу сүзләр әсәрнең идеясен, язылу максатын бик ачык күрсәтеп тора. Моратның кырым татарларына ярдәмгә китеп баруы да рухи ялкаулыктан котылуның бер юлы булып аңлашыла. Янәшәдә үк фантастик уйланманың вазифасы искәртелә: «Хәтер көчен, хәтере көчле халыкны беләк көче белән җиңеп булмый». Хәтер көче хакындагы хыялый уйланма, шулай итеп, милләтнең хәтер көчен уятырга һәм кузгатырга теләп әдәби формага төрелгән, әдәби әсәргә әйләндерелгән булып чыга.

Повестьларның өченчесе—«Соңгы кисәтү» башкарак дулкында язылган. Әсәрдә сүз милләткә генә түгел, гомумән, кешелек дөньясына яный торган куркыныч, афәт хакында бара. Гомумиләштерү ясап, бу афәтне Явызлык дип атарга мөмкин. Авторлар төшенчәне конкретлаштырмый, әсәр эчендә дә берничә аңланылу варианты саклана. Марат исеменнән әйттерелгән: «Яманлыкның башы кешедәдер» дигән сүзләр аны әхлакый категориягә әйләндерә. Ришат көндәлегендәге һәм ана аваздаш Лотфи фикерләре сәясәткә ишарә ясый: «Киләчәктә татарның рухи байлыгын, гыйльми хәзинәсен тудырасы кешеләр бер-бер артлы юкка чыга. Юри сайлап алалармыни?!» Ә инде Ришат үлеме, Лотфи юлыккан бәлаләр, соңгы шартлау Явызлыкны, гомумән, яшәеш нигезендә ята торган, Яхшылыкка каршы торучы көч итеп карарга кирәклекне искәртә. Шунысы кызык: Яхшылык һәм Явызлыкның фәлсәфи категорияләр итеп аңланышы, алар арасындагы чикнең бик шартлы билгеләнүе фантастик уйланма катламында да, детальләрдә дә кабатлана. Җомабай карт үзенә ярдәмгә ашыккан Маратны башта Женния дип кабул итә. Марат билгеләгәнчә, бер үк таш «мәгълүм бер ешлыктагы нурланыш тәэсирендә кеше күңеленә курку, шом салса, икенче бер ешлыкта

инде хөрлек, рәхәт талгынлык хисе уятуы да ихтимал».

Фантастик уйланма, төрле ешлыкта тарала торган тавыш дулкыннарының кешегә тәэсире үзгәрү теориясе кешелекне борчыган кайбер табышмакларга (мәсәлән, Бермуд өчпочмагы) җавап варианты бирә. Әсәр кешелекнең юкка чыгу куркынычын әйтеп кисәтә. Марат ясаган аппарат белән бергә лабораториянең шартлатылуы ярдәмне фән-техника прогрессыннан көтәргә түгел, бәлки кешене үзгәртергә кирәк дигән идеягә китерә. Текстта әлгәрге цивилизацияләрнең юкка чыгу сәбәбе «ваемсызлык һәм әхлаксызлыкта» дигән сүзләр бар. Димәк, хәзерге кешелек җәмгыяте дә шушы ук сәбәп аркасында юкка чыгарга мөмкин. Милләткә янаган куркынычның башы табигатьтән ераклашуда («табигатькә тоташкан кендегегезне югалта барасыз, димме...»), ә инде кеше һәм җәмгыятьнең озын гомерле булу сере үзара ярдәмләшүдә («Бер-береңә ярдәм итмичә яшәп булмый. Менә шул озак яшәтә торгандыр да инде адәм баласын...») дип күрсәтелә.

Әсәрнең сюжет-композиция биреләше дә катлауланган: Марат һәм Лотфи сызыклары аерым-аерым үстерелеп, соңгы ноктада гына килеп тоташалар. Явызлык китереп чыгарган курку, шомлану-шикләнү хисләренә, кан түгелү, авырту-газап һәм үлемгә капма-каршы автор күзаллаган идеал тормыш тергезелә. Ул Миннурый белән Ришат мәхәббәте һәм үзара мөнәсәбәте, бер-берсе өчен корбан булырга әзер Марат һәм Лотфи дуслыгы, Җомабай карт мисалында башкаларга хөрмәт һәм ярдәмчеллек, Марат белән Джон Кеннет арасындагы хезмәттәшлектән җыела. Алдагы әсәрләрдә кеше һәм милләт язмышы бер тәңгә тәйнәлгән булса, бу повестька Америка галимен һәм планетаның төрле урыннарында ак яки кара энергия туплану хакындагы теорияне кертү милләт һәм кешелек тарихын тоташтырырга ярдәм итә. Нәтиҗәдә, әсәрдәге фәлсәфә дә киңәя: кешенең эш-гамәлләре, уй-омтылышлары милләт язмышына тәэсир итсә, милләтләр язмышы—кешелек тарихы ул. Милләтнең юкка чыгуы кешелекне дә юк итәргә мөмкин, дигән кисәтү китерелә.

Гомумән, кеше һәм җәмгыять хакындагы фикерләрне фәлсәфи яссылыкка күчерә бару—Ф. Латыйфиның иҗат юлы, тоткан мәсләге ул. Иң соңгы әсәрләреннән берсе—«Бәйсез этләрне атарга» (1999 ел) дигән фәлсәфи-символик повесть төрле әзерлектәге укучыга атап уйланган берничә әдәби катламны берләштергән үзенчәлекле, татар әдәбияты өчен яңа күренеш дисәк, ялгыш булмас.

Эчтәлек катламын аңлауга эпиграф юл күрсәтә: автор әсәрен «сугыш елларында туган, балалык, үсмерлек еллары үтә дәһшәтле һәм авыр чорларга туры килсә дә сынмаган, хыялларына тугрылык саклый белгән» замандашларына багышлый. Повесть икенче класста укучы авыл малае Харис исеменнән сөйләнелә һәм аның хыялы белән башланып китә: гыйлем алып, матур һәм белемле кешеләр булып туган якларына әйләнеп кайту ул! Монысы—киләчәк эше. Харисның тагын бер хыялы бар: тачка ясау. Нәкъ менә шушысы сюжет җебен сузарга ярдәм итә дә инде. Тачкасына тәгәрмәч алган Харисны караклыкта гаепләү һәм аклау булып вакыйгалар тәгәлләнә һәм укучы күз алдына сугыштан соңгы авыл тормышын, аның кайгы-борчуларын, авыр көнкүрешен, самими балалык омтылышларын китереп бастыра. Бу катлам Харисның саф күңелен, уй-фикер, хис-кичерешләрен, кешеләргә, тормышка, әхлакый кыйммәтләргә мөнәсәбәте матурлыгын күрсәтеп сокландыра. Харис—татар әдәбиятындагы балалар образлары галереясын баета торган, үзенчәлекле һәм җылы, җанлы булып чыккан.

Шушы эчтәлеккә «яшереп» кенә, укучыны игътибарлы укырга чакырган кебек, җәмгыятькә бәя урын алган. Ул нинди элементлардан җыела соң? Алар шактый, бөтенесе бергә, мозаика кебек, совет хөкүмәте дип аталган системага хөкем карары булып җыела. Шуларны күздән кичерик. Җәмгыять икегә аерылган: халык ачлы-туклы яши, житәкчеләр бөтенләй башка төрле тормышта яши. Эш башында наданнар, эшлексезләр утыруы кирәк, чөнки акыллылар ялганга каршы көрәш ачарга мөмкин. Хөкүмәт халыкка ярдәм итү түгел, аны талау сәясәте алып бара. Халык куркытылган, хәтта үз хәленнән зарланырга, дәреслекне кычкырып әйтергә дә кыймый. Үткәнне сүгү һәм пычрату, бүгенгене мактау чәчәк ата, тарихны оныттыру сәясәткә әверелгән. Милли аңны буу, руслаштыру колач җәя. Нәселсезләр, милләтсезләр, динсезләр, телсезләр, денсез-намуссызлар заманы бу! Кечкенә Харис шаһит булган күренешләрдә, аның

әтисе белән әнисе сөйләшкәндә, мәктәп хакында сүз барганда җәмгыятькә менә шундый нәтиҗәләр чыгарыла һәм алар автор бәясен дә тәшкил итә.

Эчтәлек катламында Харисның тормышка ашкан хыялы—эт үстерергә теләп, көчек тәрбияләве хакында сүз алып барыла. Әсәрнең ахырында милиционер этне атып китә. «Бәйсез этләрне атарга!» дигән гыйбарә шушы урында янгырый, ләкин ул фәлсәфи-символик катлам барлыкка китерә. Харис, авыл малайлары—бәйсез, хәр булып дөньяга килгәннәр, ләкин җәмгыятьтәге кануннар шул бәйсезлек белән көрәшә, хәр фикерлеләрне юк итә, ди язучы. Идея малайның хыялларын сөйләү белән үстерелә: бәйсез кешедә генә зур хыяллар, олы максатлар булырга мөмкин, колларның хыял-максатлары—канатсыз! Язучы бу әсәрендә кеше, буыннар һәм милләт фаҗигасен система һәм ул тәрбияләгән коллык психологиясе белән аңлата.

Әсәрдәге һәр образ, һәр деталь шартлы-символик гомумиләштерү баскычына күтәрелә. Харис белән Лилия—үсеп килүче буын вәкилләре, Харисның əти-әнисе—кол кабыгына куып кертелгән буыннныкылар, мәктәп һәм укытучылар—шушы системаның тәрбия коралы булса, милиционер образы үзенә ярдәм иткәннәргә—начарлык белән җавап кайтару, көчсезләр белән көрәшү кебек моментларга игътибар юнәлтә. Харисның Тигр атлы эте, тачка ясаганда кулын яралавы, яки тарих китабындагы татар-монголларга каршы көрәшнең шәрехләнүе, татар әдәбияты укытучысының дөнья әдәбияты җәүһәрләре турында сөйләү белән мавыгуы кебек детальләр дә эчке, икенче мәгънәгә ия. Алар Ф. Латыйфиның «Хыянәт», «Ишелеп төшкән бәхет» кебек әсәрләре белән дә ассоциациягә керә, янадан-яна нәтиҗәләргә китерә.

«Ф. Латыйфи прозасы нинди ул?»—дигән сорау куеп карасак, моңа бер сүз белән генә җавап бирү дә мөмкин түгелдер. Әсәрдән-әсәргә авторның сайлаган тормыш материалы үзгәреп тора: ул укучысын әле ерак тарих төпкелләренә алып төшә («Хыянәт»), әле тылсымлы-мифологик серләр ача («Көмеш беләзек), әле бүгенге җәмгыять-яшәешкә үзенчәлекле-усал бәя белән сискәндерә («Ишелеп төшкән бәхет»), әле фәлсәфи-символик гомумиләштерүләр ясаучы эссема жанрын татар әдәбиятында «сынап» карый («Бәйсез этләрне атарга!), хыял һәм киләчәк белән үткән тарихны тоташтырып, бүгенге хакында сөйли башлый (фантастик повестьлар). Ләкин әсәрләр өчен уртак яклар, хасиятләр дә бар. Милләт язмышы хакында борчылучы, укучысында милли горурлык уятырга омтылучы автор, милли реализм агымына туры китерелгән әдәби эшләнеш: милли каршылыкның барлыкка килү-үсү-чишелүе кебек уйланылган сюжет, милли характер һәм милли тормыш картинасын тудыру, татар әдәбияты традицияләрен дәвам итүче өслүб, «нәкъ безненчә» җырлап торучы тел... Тарихка һәм киләчәккә күз ташлау язучыга бүгенге көн проблемаларын күтәрергә, бүгенге укучы белән сөйләшергә, хәзерге яшәешкә бәя бирергә ярдәм итә. Димәк, прозаик буларак Ф. Латыйфи—милли бүгенгенең җырчысы, хәзергебезнең елъязмачысы. Шуңадыр, ул публицистика өлкәсендә эшләвен дә дәвам итә (1998 елны аның «Уяну» китабы басылып чыкты).

«Уянып киләбез... Уяныйк та җиң сызганып эшкә тотыныйк. Безнең өчен беркем дә хыялларыбызны тормышка ашыру юлында эшләп йөрмәс. Барысы да үзебезгә бәйле. Үзебез эшлик!» диюче автор үзе—әдәбият һәм публицистика, журналистика өлкәсендә кыйммәтен бернинди үлчәүләргә дә салып булмаслык эш күрсәткән кеше. Ә инде «Татар булу белән горурлану хисе безгә кайчан кайтыр икән?! Ләкин, никадәр кызганыч булмасын, бу сорауга унай җавап табар көннәр шактый ерак сыман тоела миңа» дигән сүзләр Латыйфиның милләт язмышы өчен борчылып, милли дулкында иҗат ителгән әсәрләре әле күп булачагын, үз укучысын янадан-яна табышлар белән сөендерәчәген дә сөйләп тора сыман.

*Февраль, 2003 ел.*

**Редакциядән:** *Бу айда хезмәттәшебез, журналның баш мөхәррир урынбасары, күренекле язучы Флүс Латыйфига 60 яшь тула. Каләмдәшебезне ихлас күңелдән юбилее белән тәбрик итәбез, иҗат уңышлары, саулык-сәламәтлек телибез.*

Гэп
Фэн

# «ТӨСЛЕ ТОЕМЛАУ»—МОГҖИЗАМЫ, ӘЛЛӘ ГАДӘТИ БЕР «КҮЗ БУУМЫ»?

Өлкәнрәк буын укучылар хәтерли булыр, үз вакытында минем, моннан шактый еллар элек, «Казан утлары» журналында төсле музыканың төрле мәсьәләләренә караган мәкаләләр белән чыгыш ясаганым бар иде инде. Хәзер исә, шактый мавыктыргыч һәм четерекле бу өлкәнең турыдан-туры сүз сәнгатенә, аның да образлы сүз сәнгатенә килеп тоташкан кайбер гамәлләренә (өстән-өстән генә булса да!) тукталып үтмәкче булам.

Соңгы дәвердә дөньяның төрле почмакларында «төсле тоемлау»ны, ягъни «синестезия» күренешен (тагын да төгәенләбрәк әйтсәк, «тоемлауны тоемлау» үзенчәлеген), хәтта шулай дип әйтергә мөмкин—ниндидер бер ашкынып мавыгу дәрәҗәсендә—өйрәнү башланды. Әле анда, әле монда дигәндәй, шушы мәсьәләгә караган Халыкара конференцияләр уздырыла, күпсанлы диссертацияләр яклана, халыкара Интернет челтәрендә берсеннән-берсе кызыграк тематик битләр ачыла; алай гына түгел, соңгы вакытта синестезиянең Халыкара һәм Америка Кушма Штатларында җәмгыятьләре барлыкка килде.

...Туган Казаныбызда без үтә дә кызыклы бу мәсьәлә белән, психология, эстетика һәм әдәбият теориясе кысаларында, менә кырык елга якын инде «кайный-кайный» шөгыльләнәбез. «Төсле музыка» мәсьәләләренә багышлап Казанда үткәрелгән һәр ун Бөтенсоюз конференциясендә «Төсле тоемлау» бүлекчәсе аерым урын алды. Без—энтузиастлар—Мәскәү дәүләт университеты белән берлектә Мәскәү шәһәрендә шушы тематикага багышланган махсус конференция дә үткәрүгә ирештек. Форсаттан файдаланып тагын шунысын да хәтергә төшерик, 60-70 еллар аралыгында без «Советлар Союзында яшәп иҗат итүче» 25 мең иҗаткярдан анкетага җаваплар алуны да оештырган идек. Хәзер Россиянең музыка әһелләреннән «сорау алу» белән мәш килеп йөрибез. Күп еллар дәвамында балаларның музыканы ничек күрүләрен, ягъни музыканы ничек сурәткә төшерүләрен өйрәндек һәм бу эшне бүген дә дәвам иттерәбез. Шушы чорда синестезиягә багышланган күп төрле мәкаләләр, китаплар, шул исәптән энциклопедик эчтәлекле хезмәтләр дә дөнья күрде. Уртак тырышлыгыбыз күз алдында, ялган тыйнаклыкка төренмичә әйтә алабыз—шушы могҗизаи күренешне өйрәнү буенча Казан галимнәре, хәтта әйтергә мөмкин, Казан мәктәбе соңгылар рәтендә түгел, шул җөмләдән чит ил галимнәре арасында да. Әмма монда да шул, әлеге дә баягы, телләр арасындагы киртәгә киләбез дә төртеләбез—кем әйтмешли, «кордон артына» ни урысча, ни татарча басылган китаплар барып ирешә алмыйлар. Кыскасы, офтанырга гына кала. Хәер, журнал укучылар белән безнең арада андый аңлашылмаучанлык хөкем сөрми, ләбаса. Шәт, шулай икән, нәрсә соң ул синестезия, ягъни татарча итеп әйтсәк, «төсле тоемлау» дигәннәре?

Әмма аңлашуыбыз җиңел генә булмастыр кебек. Шулай да...

«Флейты звук зарево-голубой» (К. Бальмонт), яки: «В глазах красно от бузинной пузырчатой трели» (М. Цветаева) кебек төсләр өермәсенә килеп юлыккач, яки композитор Скрябинның C-dur тональностенең кызыл төстә булуы турындагы искәртүләренә, рәссам Кандинскийның, Бальмонт кебек үк, музыкаль инструмент тембрларын төсләргә «мануы» кебек күренешләргә тап булгач, белгечләр гадәти булмаган, хиссияти тәэссоратлар аралыгындагы метафоралар белән эш итүләрен баштарак бөтенләй абайламаганнар да. Бу

күренешне—синестезияне алар чынбарлыктагы реаль «тоемлауны тою» дип кенә аңлатырга тырышканнар: төгәлрәк итеп әйтсәк, тавыш белән төсләр хәрәкәтен тәңгәлләштереп («имештер, аларның икесе дә дулкыннар таралышыннан килеп туган күренешләр»); анатомияне эшкә җигеп («бәлкем, нерв җепселләре буталышкан булгандыр»), атавизм күренеше түгел микән дип хисаплап («беренчел тәэссоратлардан сакланып калган сенсорлык сикретизмының кабатлануы» дип), файдалы булса да, барыбер авыру дип исәпләп («тавышны күрү, ә төшләрне ишетү табигый күренеш була алырмы?), психоделика бәласе дип («әйтик, наркотиклар кулланганда, галлюцинацияләр башлану сәбәпле, тавышлар чынлап та күренергә мөмкиннәр, ләбаса»), психиканың могҗизага охшаш, мистик халәте («бу серләр дөньясыннан хәбәрдар даһиларга гына хас сыйфатлар ич») дип аңлатырга тырышканнар. Тик ни генә булмасын, синестезия һәм аның бер өлешен тәшкил иткән «төсле ишетү», «төсле тоемлау» уңай яктан да, тискәре яктан да гадәти булмаган күренеш, аномалия буларак бәяләнеп киленде. Шунлыктан энциклопедик, хәтта академик басмаларда да мондыйрак имеш-мимешләр хөкем сөрде: «Синестезия—ул сенсорлык (тою, тоемлау) системасында барлыкка килгән үзгәрешләр; синестезия белән Рембо, Бодлер, Бальмонт, Блок, Скрябин, Римский-Корсаков, Кандинский кебек олуглар җәфа чиккәннәр; XX гасырда синестезия җирлегендә—аерым алганда, абстракт музыканың төсле чагылышы оеткысында яңа—төсле музыка сәнгате тудырырга омтылу киң тамыр җәйде». Мондый хорафат—сафсаталар тарату совет чоры фәне өчен дә, хәзерге Рәсәй фәне өчен дә, бүгенге чит илләр фәне өчен дә хас бер күренеш иде; баксаң, арба һаман да үз урынында тора. Аерым энтузиастларны исәпләмәгәндә, әлбәттә.

Ә инде чынбарлыкның күзенә туры карап икърар итәргә теләсәк, синестезия—бернинди «тоемлауны тою»да түгел, дөресрәге, алай гына түгел, ә бәлки (тагын да төгәлрәк булырга тырышып карасак)—«тоемлауны күзаллау». Үзенең психологик табигате белән ул «бары тик» еш кына очракларда күп катламлы, системалы тоемлауларны берләштергән ассоциацияләр—тәэссоратлар җыелмасы; метафорик фикерләүнең асылын нәкъ шулар хасил итә ләбаса (ул да бит, мәгълүм булганча, чынбарлыкны кабул итүдәге ассоциацияләргә таяна). Төптәнрәк уйлап баксаң, «төсле тоемлау»—үзе үк, барлык табигате белән чәчрәннәп торган метафора икән ләбаса. Болай фикер йөртә калсак, Бальмонт флейтаның сихри моңнарында, асылда, бернинди төсләр дә күрмәгән булып чыга түгелме соң?..

Шул рәвешле, метафоралар, ассоциацияләр, чагыштырулар, читләтеп әйтүләр дөньясына килеп чыгабыз... Әгәр «кызый—җикән камыш» метафорасында сурәт күзгә күренеп торган бер күренешне күзгә күренеп торган икенче күренешкә охшату нәтиҗәсендә килеп туса, ә шул ук сылу кызыкайны Рөстәм Яхинның «Ноктюрн»ы яки курай моңнары белән чагыштырабыз икән, бу инде икенчерәк яссылыктагы—синестетик үзенчәлекле чагыштыру булыр иде. Метафора, фәндә кануни хакыйкать булып расланганча, генетик—килеп чыгышы ягыннан «охшашлык ассоциацияләренә нигезләнгән; синестезиягә килгәндә исә, мондый «охшашлык» бөтенләй дә тәңгәл куеп булмаслык хискичерешләр (мәсәлән, күрү һәм ишетү аша туган тәэссоратлар) нигезендә оеша, шуңа күрә дә ул, тыштан караганда, кичерешләрнең парадоксаль оеткысы буларак кабул ителә. Әйтергә кирәк, «охшашлык» бирелә яки эчтәлек буенча (Бальмонттан китерелгән мисал үрнәгендә), яки форма (структура) буенча (Цветаевадан алынган өлге төсмерләрендә) барлыкка килергә мөмкин. Хис-кичерешләр арасындагы мондый күчеш—синестетик чагыштыру—теләсә нинди охшашлык буенча тәңгәлләштерү кебек үк, аңлашылса кирәк, фикерләүнең үзенчәлекле нәтиҗәсе. Тик фикерләү бу очракта сенсорлык—сиземләү кысаларыннан читкә чыкмыйча хәрәкәт итә; ягъни ул сүзсез—вербаль булмаган—хиссеми, сурәтле фикерләү төренә карый. Алай гына да түгел, әйтик, гадәти күреп торудан туган яки музыкаль фикерләүдән аермалы буларак, ул сүзсез—вербаль булмаган—фикерләүдән югарырак баскычта тора, чөнки ул чынбарлыкны төрледән-төрле полимодаль бөтенлекле кабул итү системасы югарылыгында башкарыла. Ә инде мондый синестетик фикерләү аңның тирән вә яшерен чоңгылларында туа дип фараз кылсак һәм тышка аның нәтиҗәсе генә саркып чыгуын тәкърарласак (әйтик сүзләрдә—«флейты

звук зарево-голубой»), болар барысы да аңа серлелек төсмерен ести—укымышлы мохит-даирә арасында аңа карата ышанмаучан хорафатлар яшәп килүе шуның белән аңлатыла да инде.

Бу тема белән кызыксынучылар була калса, тәгәлрәк мәгълүматларны мин фәкыйрегезнең «Содружество чувств и синтез искусств» *(М.: Знание, 1982)* һәм «Человек—искусство—техника: проблема синестезии в искусстве» *(Казань, изд-во КГУ, 1987)* дигән китапларыннан алырга мөмкин. Тагын да яңарак мәгълүматлар белән танышырга теләүчеләр Интернеттагы «http: // prometheus. kai. ru» дип аталган безнең махсус чыгарылыш битенә мөрәҗәгать итә алалар. Хәзер без әзләнүләребезне туган телебезгә һәм татар әдәбиятына мөнәсәбәтле рәвештә дәвам итәбез. Бу программа Татарстан Республикасының Фәннәр Академиясе канаты астында алып барыла. Татар шигъриятендә синестезия күренеше дигән тема—яшь галимә Гүзәл Сафинаның иҗат мәйданы. Түбәндә исә, аның бүгенге татар шагыйрьләре иҗатында кайбер метафора үзенчәлекләренә багышланган кечкенә күләмле мәкаләсен тәкъдим итәбез.

Булат ГАЛИЕВ,
*профессор, философия фәннәре докторы.*

## ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ СИНЕСТЕЗИЯ КҮРЕНЕШЕНӘ КАЙБЕР МИСАЛЛАР

Мәшһүр каләм остасы Лев Николаевич Толстой сәнгатьнең асыл нисбәтенә карата бик тә гыйбрәтле мондый сүзләр әйтеп калдырган: «Сәнгатьнең төп максаты—әгәр ул бар икән һәм аның максаты бар икән, шуннан гыйбарәт—гади сүзләр белән генә әйтеп бирә алмый торган серләрне ачу. Чөнки сәнгать үзе дә шуннан башлана. Сәнгать—ул сәнгаткярнең үз күңеле катламнарына юнәлдерелгән микроскобы һәм шуның аша бөтен кешеләргә уртак булган серләрне тасвирлый.»

Шигърият, уйлап карасаң, сәнгатьнең үтә дә серле төрләреннән саналырга хаклы түгелме икән? Әлбәттә, шулайдыр, чөнки нәкъ менә сүзләрнең тылсым көченә таянган очракта гына шигъриятта нинди дә булса уңышка ирешергә, кем әйтмешли, яңалык ачарга мөмкин, ләбаса. Һәм бу озын вә катлаулы сәфәрдә шагыйрьләр Галибанә сүзнең нинди генә тылсымлы кодрәтенә таянмыйлар да, нинди генә хәйләкәр тозаклар кормыйлар?! Метафора исә, бу сәфәрдә аларга иң ышанычлы юлдашчыларның берсе булып тора.

Сүз дә юк, метафора көтелмәгән вә кабатланмас образлар тудыру ягыннан телнең иң үтемле чараларыннан саналырга хаклы. Нәкъ менә метафорик күзаллаулар аша шагыйрь теге яки бу күренешләрнең һәм вакыйгаларның асыл мәгънәләрен ачып бирә, аларга төсмерләр өсти. Алай гына да түгел, метафоралар—алар чынбарлыкның каршылыклы бербөтенлеген ачып бирердәй, бер ноктага кысылган моделе.

Сүзләргә кысан булса да хис-кичерешләргә иреклек—бу шигъриятнең асыл сыйфаты. Шушы нәүбәттән, метафоралар шигъри арсеналда бик тә отышлы корал булып хезмәт итә алалар.

Халык күңеленең биниһая кинлекләрен үз эченә сыйдырган татар теленә килсәк, ул метафорик гыйбарәләргә бихисап бай. Алар, нигездә, «катып калган» метафоралар; озак еллар куллану нәтиҗәсендә аларның күчмә мәгънәләре

шулкадәрле кристаллашкан, стандартлашкан, без аларны баштарак метафора буларак та кабул итмибез: «китап бите», «тау түбәсе», «өстәл аягы», «көймә койрыгы», «сәгать суга», «сәгать йөри», «җылы сүз», «якты бәхет», «каты сүз», «салкын авыз», «татлы өмет», «якты теләк»—саный китсәң, туган телебез тоташ метафоралардан тора дип уйларсың.

Шигъри әсәрләрнең арсеналында мондый саллы коралларның куәтлерәк тә, катлаулырак та формалары өстенлек итә, әлбәттә: «мәхәббәт уты», «дуслык бакчасы», «каеннарның ак көлмәге», «сүз тәме», «юл читләре—яшел келәм», «күк тәхете», «уктай кара кашлар», «күзләреңнең йолдызлардай януы», әйтик, әнә шундыйлардан.

Алда санап үтелгән гомуми сөйләм теленә караган һәм шигъри метафоралар арасында чынбарлыкны тоемлау—кичерешләр аралыгында туганнары да очрый, алар фәндә синестезияләр дип аталалар. Синестетик фикерләүнең кабатланмас асылы шуннан гыйбарәт, ул арадашчы ассоциацияләр җирлегендә, кешенең ике төр тоемлау берлеге оеткысында барлыкка килә. Әйтергә кирәк, синестетик метафоралар барлык вакытларда да һәм бөтен шагыйрьләр иҗатында да очрамыйлар. Шунлыктан булса микән, алар бик аз өйрәнелгәннәр. Андый метафораларга, мәсәлән, түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: «җылы сүз», «каты сүз», «салкын сүз», «төссез сүз», «көмеш тавыш», «яшел тавыш», «җинел көй», һ. б. һ. б.

Тел һәм әдәбият өлкәсендә синестезияләрдән тыш синестемияләр дә киң кулланыла. Бу очракта кеше табигатенә хас булган биш төр тоемлаудан—күреп белүдән, ишетеп белүдән, ис сизеп белүдән, тоеп белүдән һәм тәм сизүдән гайре һәр төрле кичерешләр, абстракт хиссемиятләр дә «эшкә җигелә». Һәм аларны һич тә үзара бутарга ярамый.

Синестемияләргә, мәсәлән, түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: «җылы караш», «якты бәхет», «якты теләк», «нурлы киләчәк», «кара уйлар», «зәңгәр хыял», «якты хыял» һ. б.

Татар шигъриятендә синестезияләр һәм синестемияләр күпләп һәм уңышлы кулланыла. Бу кечкенә күзәтүебездә аларның барлык төрләренә дә тукталу, төпле анализ ясау мөмкин булмас, әлбәттә, шулай да беренче нәтиҗәләрне ясау зыян итмәстер, мөгаен. Әйтик, Нәҗибә Сафинаның «Сиңа да, миңа да» дигән шигырендә шушы юнәлештә кызыклы гына күзәтү ясала:

*Күңел канатларын сыгып төшкән*
***Әче алма булып уй калды.***

Синестезияләрнең кодрәте шуннан гыйбарәт, алар көтелмәгән ассоциацияләр тудырырга сәләтлеләр. Чыннан да, алда китерелгән мисалда «уй»ны «әче алма» белән бәйләп сурәтләү бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәләргә китерә.

Булган булсын дигәндәй, шушы ук шагыйрәнең иҗатыннан тагын бер мисал китереп үтик, нәтиҗәне укучылар үзләре ясарлар:

***Ярый, җырың ертык түгел.***
(«Синең җаның»)

Шагыйрь Ләбиб Лерон иҗатында да синестезик табышлар шактый мулдан «сибелгән».

*Уйнап кына*
***бер җомарлам***
***җыр** ыргыттым*
*тыгыз мәйдан уртасына.*
(«Йомарлам»)

Бу өзектә Л. Лерон, безгә калса, үз укучысына гайре табигый образлар системасын тәкъдим итә. Бер карасаң, шагыйрь уйнап кына, бер йомарлам кар ыргыткан кебек (сөйгәненә, әлбәттә!), ләкин ул образлар аша, ягъни метафора аша халык күңеленә җыр ыргыта икән ич—һәм бу очракта ул кулланган образ-предметлар колак белән генә түгел, җан-рух белән дә, икенче югарырак мәгънәгә күтәрелеп кабул ителәләр: **«тыгыз мәйдан уртасына ыргытылган җыр булып»**. Сүз дә юк, ахыр чиктә шагыйрь үзенә генә хас фикерләү рәвешенә ия булганда гына шундый халәт күзәтелә.

Тагын бер мисал:

> ***Сусыл сулыш ала бөкшәйгән җил.***
> («Төсле саз»)

Яки:

> *Карашына кан сарыла,—*
> ***Төсләр туңган, оешкан.***
> («Кышка кералмый торам»)

Шушы ук шигырьдә мондый юллар да бар:

> *Кыш ишеге шып-шыр ачык—*
> *Атлый түргә пар туннар.*
> ***Туңган көлү авазлары***
> *Иярә алар артыннан.*

Шулай итеп, бер мисалда шагыйрь «туңган төсләр» турында сүз алып барса, икенче очракта «туңган көлү авазлары»на мөрәҗәгать итә. Соңгы мисалда шагыйрь беренче карашка яраштырырга мөмкин булмаган кебек тоелган сүз-төшенчәләрне бергә куша һәм бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәгә ирешә: баксаң, кыш көнендә барлык сулый, үсә торган әйбер, тереклек ияләре генә түгел, «авазлары да туңарга» мөмкин икән ләбаса.

Аңлашылса кирәк, шагыйрь бу нәүбәттән үзенең иҗатында билгеле бер осталыкка ирешә алган. Л. Н. Толстой сүзләре белән әйтсәк, «гади сүзләр белән генә әйтеп биреп булмый торган серләрне ачкан».

Танылган шагыйрь Әхсән Баянов та синестезияләр белән «уйлый белә». Аның күп кенә шигырьләрендә берьюлы берничә шундый мисалны табарга мөмкин:

> ***Кәкре-бөкре һәм кара сәбәпләр,—***
> *Күзгә-күз очрашты кыз белән.*
>
> *Актык **мәрмәр сүзне** әйтербез тик*
> *Башыбызны кисеп карагач!*

Яки:

> ***Учакларның якты кычкыруын***
> *Күрәм ишетеп еллар үтәли.*
>
> *Ә җавапсыз **тынлык** шундый **суык**—*
> *Йолдызларын тота очкылык.*
>
> *Син яралган **сары җил***
> *Тын ярларга ашыга.*

Күренекле шагыйрь Равил Фәйзуллинның синестемияләр палитрасы үзенең байлыгы белән аерылып тора. Менә бер генә мисал: синестемияләр бирелә «серияләп» кабатлана:

> *Туган илдә **сагыш***
> *Күзге яфрак кебек*
> ***Сары төстә** генә.*
> *Ә монда сагышның*
> ***Зәңгәре, аклары, аллары.***

Шул рәвешле синестетик шигырьләр чынбарлыкны төс-хисләр һәм кичерешләр гаммасында, башкалар күрә алмаган «төстә» күрергә ярдәм итәләр. Мона борынгы грек философы Аристотель дә игътибар иткән булган, һәм ул болай дигән: «Иң мөһиме—метафораларга талымлы булу, тик моны гына башкалардан күчереп алып булмый; бу—талант билгесе.»

Сүзебезне шушы урында тәгәлләп торып, татар шагыйрьләренә болай дип мөрәҗәгать итәсебез килә: әгәр сез үзегезнең иҗатыгызда синестетик метафоралар бар дип исәплисез икән, андый мисалларны түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз: **420111, Казан шәһәре, К. Маркс урамы, 10, КГТУ, «Прометей» Фәнни тикшеренү институты.**

**Гүзәл САФИНА.**

*P. S.* Җавап бирү өчен сорауларга кайбер ачыклыклар кертергә кирәк таптык.

**1.** Кеше исемнәрен, хәреф-авазларны, саннарны, хисләрне, музыкаль тембрларны һәм башка төрле тавышларны төсләрдә күз алдына китергәнегез бармы? Әгәр бар икән, мөмкин булса, үзегез ясаган күзәтүләрдән мисаллар китерсәгез иде.

**2.** Музыканы график һәм пластик формаларда күз алдына китергәнегез бармы? *(А. Куприннан алынган цитатаны карагыз).*

Мөмкин булса, төгәл мисаллар ярдәмендә үзегезнең шундый күрүишетүгә караган синестезияләрегезне күрсәтсәгез иде *(мисалларны әсәрләрегездән китерсәгез, яхшы булыр иде).*

**3.** Сезнең бу сиземнәрегез үзеннән-үзе туамы, әллә сез аларны үзегез махсус ясыйсызмы? Моны патология дип яисә «аерым шәхеснең искиткеч бер сәләте» дип саныйсызмы?

**4.** Башка шагыйрь (яисә язучы) әсәрендә синестезиягә караган мисалларны очратканыгыз бармы? Табылган мисалларны китерә алсагыз, рәхмәтле булыр идек.

**5.** Башыгызга бүтән синестезияләр килеп торамы? Мәсәлән: авазлытиеп сизүле (звуко-осязательные), төсле-ис сизүле (цвето-обонятельные), тәмтөсле (вкусо-цветовые) һ. б. Үз иҗатыгыздан мисаллар китерүгезне үтенәбез.

Катнашуыгыз өчен алдан ук зур рәхмәт белдерәбез.

Тикшерүнең нәтиҗәләре экспериментка йомгак ясаудан соң билгеле булачак. Бу нәтиҗәләр, бәлки, аерым хезмәт булып та чыгар.

Адресыгыз белән бергә телефоныгыз, фамилиягез, һөнәрегез (прозаикмы, шагыйрьме, тәнкыйтьчеме), яшегез һәм туган телегезне күрсәтүегезне дә үтенәбез.

Şəngət
Сәнгать

# ҖАН АҺӘҢЕ

Табигатьнең гаҗәеп зур дөньясын җаны аша үткәреп, ана үз аһәңен өстәп, әлеге дөньяның һәммә төсләрен, зиннәтләрен күрә-күрсәтә алучылар бар. Болар— сүз, төс һәм көй рәссамнары. Татарның танылган рәссамы Эрот Зарипов та— шулар сафында.



Бактың исә, Эрот Зариповның иҗаты белән мин дүрт яшемнән бирле таныша-аралаша башлаганмын икән.

Хәрефләрне хәрефкә култыклаштырып, тырыша-тырмаша мавыгып, ашыгып-кабаланып тылсымлы сүзләр иләнә кереп барган мәлем иде. Шундый көннәрнең берендә әнием миңа бер китап алып кайтты. Кечерәк альбом форматындагы бу китапчыкның тышына: «Илдар Юзеев. Пони малае нәни җирәнкәй. Эрот Зарипов рәсемнәре»—дип язылган иде. Дөньяның төрле-төрле тарафларыннан җыйналган җәнлек-җанвар, кош-кортның зоопарктагы тормышы сурәтләнгән иде анда. Искитмәле матур, ачык төсләр тантанасындагы бу гаҗәеп сурәтләр мине шундук җәлеп итеп, үз дөньясына алып кереп китте. Бу китаптагы сүзләр дә бары тик аңлатма сыйфатында гына иде. Кемнен-кемнен, ә менә Илдар Юзеевның каләменнән тамган сүзләрнең дә биредә фәкать аңлатма сыйфатында гына булуы үзе үк инде байтак нәрсә хакында сөйли торгандыр. Әйе, автор белән рәссамның, эчтәлек белән сурәтнең бербөтен рәвештә күңел түренә кереп урнашуы булган икән бу!

Сүземне бала чагым хатирәсеннән башлавым юкка гына түгел. Мин ул китап белән танышканда Эрот Зарипов Татарстан китап нәшриятында эшләгән икән. Нәшриятның техник редакциясендә җитәкче, бизәлеш мөхәррире һәм китап бизәлеше редакциясенең баш рәссамы да булган. Шул дәвердә дөнья күргән берничә йөз китапның бизәлеше-күрке өчен җавап биргән ул. Шәхсән үзе генә дә ике йөздән артык китапка рәсем ясаган, бүтәннәргә исә киңәш-табышы белән ярдәм иткән. Мәгълүм ки, рәсем сәнгатенең башка тармакларыннан аермалы буларак, китап графикасының үз хасиятләре, үзенчәлекләре бар. Еш кына кырыс төгәллек таләп ителә. Купшы төсләрне, чуарлыкны чамасын белмичә уйнатсаң, һич тә көтелмәгән кире тәэсир уятуың да ихтимал. Тоем кирәк, эчке тоем! Хәтта китап тышлыгындагы һәрбер хәреф, һәрбер сызык, үз урынын табып, эчтәлеккә тәңгәл килергә тиеш. Рәссамның нәшриятта эшләгән еллары хакында Фаил Шәфигуллин ул чакта болай дип яза: «Львовта И. В. Федоров исемендәге полиграфия институтында укыганда иптәшләре Эротның шаян рәсемкарикатурасын ясаганнар. Ул биек итеп китаплар өйгән дә, үзе иң өскә менеп баскан. Карикатура Эротның күп укуына ишарә. Эрот бүген дә күп укый. Чит ил һәм рус графикларының иҗат методларын, стильләрен өйрәнә. В. Фаворский, Н. Пискарев, А. Гончаров кебек рәссамнар турындагы хезмәтләргә еш мөрәҗәгать итә, татар китап сәнгатен камилләштерүгә күп көч куя». Эрот Зарипов тарафыннан ул елларда эшләнгән Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры турындагы альбом, Җәүдәт Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» исемле җырлар җыентыгы, дөрестән дә, рәссамның тәҗрибәсенә һәм җитди хезмәтенә саллы дәлил булып тора. Фаил Шәфигуллин: «Күп

укый»—дип язган 1976 елда Эрот Зарипов әле Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих фәннәре институтының сәнгать өлкәсендә белгечләр әзерләүче аспирантурасында да белем алган икән. Хәер, болары хакында бераз сонрак тасвирланыр. «Сүз башы—шүрәле»—дигәндәй, Тукайга мөрәҗәгать итик әле. Ул да заманында үзенен «Шүрәле» поэмасының рәсемле китап булып балаларга барып ирешүе хакында хыялланган бит. «Ихтимал, үз арабыздан маһир рәссамнар чыгып, шүрәленен кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кылынган урманнарны—һәммәсен тәрсим кылып чыгарлар»—дип тә язып калдырган. Шөкер, бөек шагыйребезнен бу хыялы тормышка ашты. Татарның да балалар өчен эшләүче маһир рәссамнары пәйда булды. Эрот Зарипов—шулар сафында. Танылган сәнгать белгече Марина Ильина анын хакында: «Рәссамның татар язучыларының балалар өчен язылган китапларына ясаган иллюстрацияләре тапкырлык, нәфислек һәм мәзәклек белән аерылып торалар»—дип әйтүе шуны раслый түгелме сон?!

Эрот аганын үз иҗатын балалар дөньясыннан башлавы һич тә очраклы хәл түгел. Кайчандыр мин аннан: «Балачакта ин истә калган тәүге хатирәгез нидән гыйбарәт?»—дип сораган идем. «Рәсем ясау»—дип җавап бирде ул. «Аннан соңгы хатирәләрегез?—«Аннан соңгылары да рәсем ясау». Рәссам боларны һич кенә дә кыланып әйтмәде. Ихлас иде анын бу җаваплары. Альбомнар, төсле карандашлар түгел, хәтта ак кәгазь бите белән каләм карасы да дөнья бәһасе торган кытлык заманга—авыр сугыш елларына туры килгән бит анын балачагы. Нәкъ менә шул сабый чагында матурлыкны күрергә һәм күнеленә сендерергә өйрәнгән икән, анын бу татлы хатирәләренә бер дә гаҗәпләнәсе түгел.



*«Әтием портреты»*

Эрот Якуб улы Зарипов 1938 елнын 20 июлендә Башкортстанның Янавыл районында урнашкан Ямады авылында туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан сон, Пермь шәһәрендәге сәнгать студиясендә укый, аннары исә совет армиясендә хезмәт итә. 1965 елда ул Львов каласында И. В. Федоров исемендәге Украина полиграфия институтын тәмамлый һәм Казанга кайта. Без, гадәттә, тәрҗемәи хәлләрне менә шушылай, берничә рәсми-коры җөмләгә сыйдырып бирергә тырышабыз. Югыйсә, шушы коры җөмләләр артында никадәр кызыклы да, гыйбрәтле дә язмыш ята лабаса!

Эрот ага кечкенәдән тиктормас-шук, тынгысыз бала булып үсә. «Мәктәптә укыганда утырып дәрес әзерләгәнемне хәтерләмим, әмма дә бөтен фәннән дә «5»легә генә укыдым»—ди ул үзе. Беренче рәсеме исә туган авылының су буйлары, шунда үскән тирәкләр булган. Аннары инде болын чәчәкләрен, басуда күкрәп үскән иген, кичке шәфәкъ, озын-озак сәфәргә кузгалган торналар теземен сурәтләгән. Нәкъ менә туган якның шушы газиз-сихри күренешләре анда рәссам булу теләген уяткандыр да инде. Сигезенче сыйныфта укыганда ул ныклы карарга килә: рәссам булырга! Мәктәпне тәмамлагач, әтисеннән ун сум акча алып, Пермьгә укырга китә. Биредә ул рәсем сәнгате нигезләрен генә түгел, рус телен дә ныгытып өйрәнә. Хәер, тел белү-өйрәнү җәһәтеннән, Эрот агага чын мәгънәсендә сокланырга була: сонрак, Львовтагы полиграфия институтын тәмамлаганда, ул дипломны алман телендә яклый! Киләчәге бик тә өметле күренгән егетне Львовта, яисә Киевта калырга кыстыйлар, Мәскәүгә дә чакыралар. Һай, милләтнен никадәрле балалары, шул чакыруларга алданып, башы-аягы белән читләргә хезмәт итү упкынына чумып, харап булган, булды, була?—Мен вә меннәр...

Әмма Эрот Якуб улы кырт кисә: «Юк, мин Казанга кайтам!»—ди ул. Әле

гомерендә бер мәртәбә дә үз күзе белән барып күрмәгән Казан каласына «кайтам», ди. Язмышындагы иң мөһим бу адымын рәссам бүген болай аңлата: «Мөгаен, бу карарга интуитив рәвештә, эчке сиземләү тойгысы китергәндер. Читтә килмешәк булырга теләмәүдәндер, күрәсең, кайчан да булса үз милләтемә кирәгем чыгасына ышану булгандыр».

Шулайдыр, Эрот ага, мөлдерәмә тулы җан аһәнең шулай кушкандыр. Җиде ятка бил бөгүчеләр көтүенә иярмәвең белән мең бәхетле син! Кадере китеп барган милләтнең җелегең инде болай да байтак суырдылар лабаса.

* * *

Житмешенче еллар уртасында Эрот Зарипов Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының аспирантурасында укый һәм шушы институтта берничә ел дәвамында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. Шул елларның вакытлы матбугатына күз салсаң, еш кына Эрот Зарипов мәкаләләренә тап буласың. Замандаш рәссамнарның иҗат портретлары, күргәзмәләре хакында язмалар, татар рәсем сәнгате тарихына кагылышлы мәкаләләр—татарчасы да, русчасы да бертигез кимәлдә, тыгыз мәгънәдә тасвирланганнар. Каләмдәшләре хакында татарча түгел, русча язучы рәссамнарыбыз да, кызганыч ки, бармак белән генә санарлык шул. Күренекле рәссамыбыз Әхсән Фәтхетдиновның фәлсәфи уйлануларын укып карагыз!—Татар язмышын бәгыре аша үткәреп яза бит. Туган тамырларын онытмыйча, үз милләтенең мәдәният-сәнгать эшелләре, әдипләре белән аралашып яшәгәнгә күрә дә, бу ике рәссам чын мәгънәсендә «татар» рәссамнары дип әйтерлек дәрәҗәгә күтәрелгәннәр дә инде.




Рәссамның тарихи портрет жанрына керeп китүе дә шушы елларга туры килә. Бу хакта Эрот ага үзе миңа ниләр сөйли: «ТӘТИ дә фәнни хезмәткәр булып эшләгәндә, XVIII йөзнең күренекле татар мәгърифәтчесе Габделнасыйр Курсавиның сурәтен ясарга уйладым. Әмма аның рәсемнәре сакланмаган. Нишләргә? Тарихчы галим Әнвәр Хәйри белән Курсави турында язылган бөтен язмаларны өйрәнеп чыктык, архивларда утырдык. Шулай итеп, сүздән сурәт туды. Эскизны ТӘТИнең гыйльми советына тәкъдим иттек. Курсави портретын расладылар: рәсем тарихи дөреслеккә туры килә иде». Әнә шулай итеп, XIX гасыр ахыры һәм XV йөз башында яшәгән татар мәгърифәтчеләренең портретлар сериясе иҗат ителә башлый. Рәссамга иске фотосурәтләр, тарихи китаплар, сүз тасвирламалары ярдәмгә килә. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Гали Чокрый портретлары туа. Ул чакта Татарстанның Милли китапханәсен җитәкләгән Разил Вәлиев рәссамга күренекле татар мәгърифәтчеләренең тулы сериясен эшләргә тәкъдим итә. Һәр шәхеснең үзенә күрә тарихи урынын да, образын да гаҗәеп төгәл тасвирлау, гаять зур җаваплылык та таләп итеп бирелә. «Бу портретларны мин бик тә бирелеп, мавыгып, бөтен дөньямны онытып эшләдем,—ди Эрот ага үзе.—Татарның шушы боек шәхесләре белән әңгәмәләшеп, алар өчен горурлык тоеп эшләдем. Шул горурлык хисе илһам өстәде дә инде миңа». Эрот Зариповның бу ике йөздән артык портретны берләштергән «Татар мәгърифәтчеләре» сериясе хәзер инде мәктәпләр өчен дә әйтеп бетергесез зур хәзинәгә әверелде, рәссамның үзен исә милләтнең игелекле улы итеп танытты.

Соңгы дистә ел дәвамында рәссам, әзлекле рәвештә, «Багышлаулар» сериясен иҗат итү белән шөгыльләнә. Әйе, әзлекле рәвештә! Узган гасырларның күренекле татар шәхесләрен сурәтләгәндә үк, миңемчә, Эрот ага болай дип уйлый башлагандыр шикелле: «Бездә кешенең кадерен үлгәч кенә беләләр. Юк, болай ярамый! Замандашларның күз карашларын хәзердән үк теркәп куярга кирәк!»

Казандагы атаклы Шамил йортында—хәзерге Габдулла Тукай музеенда куелган

ул «Багышлау»лар башкаланың зыялы җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну уятты. Нур чәчеп елмаючы Гариф Ахунов, бераз моңсу Илдар Юзеев, горур Равил Фәйзуллин... Портретта сурәтләнүченең холкын ин төгәл итеп аның күзләре сөйли. Шәхеснең эчке энергиясен, милли горурлыгын, хәтта ки уй-фикерләрен дә күзләр аша биреп була. Бу җан аһәңе фотография сурәтендә чагылмаска да мөмкин. Әмма аны Эрот Зарипов бик белеп, вакытында тотып ала һәм, маһир зәркәнчедәй, кирәк җиренә оста гына беркетеп тә куя. Үзе белән аралашып гомер кичергән замандашларының холык-фигыльләрен вә хәл-әхвәлен, кем-кем, ә менә бу рәссам тирәннән тоемлый. Кешене яхшырак белү өчен аның туган якларын күрергә, ул туып-үскән нигездә булырга, ул атлаган тәүге сукмаклардан йөрергә, аның дуслары-туганнары белән очрашырга кирәк. Тукайны аңлауны Арчадан башлау фарыз. Эрот Зарипов нәкъ менә шушы хакыйкатьне аңлап иҗат итә. Шәүкәт Галиевны—Апас, Гариф Ахуновны—Арча, Равил Фәйзуллинны исә Балык Бистәсе төбәге аша ачып бирә ул. Мөгаллимнәрне, рәссамнарны, әдипләрне, артистларны, хакимият башлыкларын, югары хөкүмәт даирәләрен бергә җыйган мондый күргәзмәләр, шөт иншалла, әле алга таба да булыр. Инде янә шунысы бик тә сөенечле: «Багышлаулар» шәхеснең туган ягындагы музейларга бүләк ителә. Димәк, күренекле якташлары үз үрнәкләре белән әле никадәр баланың, үсмернең үсеш шытымнарына шифа бөркиячәк.


*Яшь буын «Багышлаулар» белән таныша*

Эрот Зариповның пейзаж жанрындагы хезмәтләре хакында сөйләүне махсус азакка калдырдым. Гәрчә «Багышлаулар»да күзгә чалынгалап киткәләсә дә, рәссамның бу тармакка кагылышлы әсәрләре әле үзе бер аерым өйрәнүне сорыйлар. Заманында рәссам «Авыл» иҗат төркемен оештыручыларның берсе булды. Авыл темасын, әлбәттә инде, табигатьтән башка күз алдына да китерү мөмкин түгел. Үзе иҗат итү белән бергә, ул әле республикабыз районнарында байтак кына күргәзмәләр оештырып, үзешчән рәссамнарга да ихлас күңелдән ярдәм итеп йөргән кеше. Әйе, һәр рәссамның гомере буе тугры кала торган үз темасы була. Эрот Зарипов өчен бу—авыл темасы, табигать күренешләре. Аның күргәзмәләренә килгән сәнгать сөючеләр тәкъдимнәр дәфтәренә язып калдырган искиткеч, соклангыч сүзләр байтак. Ижау, Курган, Гомель, Киев, Ташкент һәм дә башка калалардан, чит илләрдән килгән тамашачылар язган аларны. Менә, мәсәлән, рәссамның бер генә рәсеменә ике бертөрле караш. «Коеп яуган яңгыр»... Үзем дә сизмәстән, бу рәсемгә бармакларым белән кагылам,—дип яза бер туташ—Тәрәзә пыяласы ачылып китәр дә, түнлә яуган яңгыр тавышы ишетелер сыман». Ә бер ханым исә урысчалатып болай дигән: «Ливень великолепно! Я промокла!» Кыска—шәп, озын сөйләп торуның һич тә кирәге юк. Мәгълүм ки, пейзаж жанры моннан мең еллар элгәре дә булган. Анда ачыласы ачышлар да инде югыйсә ачылып беткән кебек. Хәер, һәр рәссамның—үз ачышы, үз казанышы. Рәсем сәнгатенең кайсы гына тармагында иҗат итсә дә, Эрот Зарипов үзенең бу ачышларына җан аһәңен дә өсти.

**Марат ЗАКИР**





# 42—ШУРА (КИҢӘШ) СҮРӘСЕ

**Шура сүрәсе 53 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. 23-26 нчы аятьләре генә Мәдинәдә иңгән. Шура—киңәш яки бер оешмага тупланган берлек мәгънәсендә.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Ха. Мим. **(2)** Гайн. Син. Каф.

**3.** Сиңа вә синнән әүвәлгеләргә дә Аллаһ шулай вәхий боерды. Аллаһ—җиңелмәс кодрәт вә хикмәт иясе. **(4)** Күкләрдә һәм Җирдә ни булса—барысы да Аңа буйсынган. Ул *(даны, гамәлләре, әхлагы белән)* бөек вә *(могҗизалары белән)* олугтыр. **(5)** *(Аның олуглыгыннан)* иң югары каттагы күкләр шартлавы ихтимал. Фәрештәләр дә Раббыларын мактап тәсбих әйтер. Һәм җирдәгеләр өчен ярлыкау сорарлар. Шуны яхшы белеп торыгыз ки, Аллаһ—ярлыкаучы һәм рәхмәте киң миһербан иясе.

**6.** Аллаһтан башка *(ялган илаһлар)*га табынганнарны Аллаһ өзлексез күзәтеп тора. Син *(Мөхәммәд)* аларга каравылчы түгел.

**7.** Шәһәрләрнең анасы Мәккәдә вә аның якын-тирәсендә яшәүчеләрне кисәтү, аларның барысын да һичшиксез бергә тупланачак *(Кыямәт)* Көн белән куркыту өчен, сиңа гарәпчә Коръән иңдердек. Инсаннарның бер өлеше—җәннәттә, башкалары дөрләп янган утлы җәһәннәмдә булачак.

**8.** Аллаһ үзе теләсә, аларның барысын да бер өммәт *(бер диндә)* иткән булыр иде. Ләкин Аллаһ теләгән кешесен генә рәхмәте белән кавыштырыр. Залимнәрнең һәрбер дусты вә ярдәмчесе булмас. **(9)** Әллә соң алар Аллаһтан башка *(потлар)* ны химаяче итеп алдыларммы? Ләкин химаяче дус берәү генә—Аллаһ. Ул үлеләрне терелтер, Ул барысына да кодрәтле.

**10.** Сезнең низаглашуыгызның нәтиҗәсе Аллаһ хөкемендә. Менә шул Аллаһ минем Раббымдыр. Мин Аңа юнәлдем, Аңа сыендым. **(11)** Ул—күкләрне, Җирне юктан бар итүче. Ул сезне дә, хайваннарны да пар-пар итеп яралтты. Шулай итеп, ул сезнең үрчүегезгә юл ачты. Аның тиңдәше *(Аңа охшаш)* юк. Ул бөтен нәрсәне ишетеп, белеп тора.

**12.** Күкләрнең вә Җирнең *(хәзинә вә сер)* ачкычлары Аның карамагында. Теләгәненә ризыкны мул бирер, теләмәгәненең ризыгын кисәр. Ул һәр нәрсәне белеп тора.

**13.** —Динне *(саф килеш)* саклагыз, аеры-чөере килеп бетмәгез,—дип Нухка васыять иттек. Сиңа вәхий иткәнебезне Ибраһимга да вәхий иттек. Мусага да, Гайсәгә дә васыять иткәнебезне Аллаһ сезгә дә дин итте. Бу дин Аллаһка уртак уйлап чыгарганнарга бик авырга туры килде. Аллаһ үзе теләгән кешене пәйгамбәр итәр вә үзенә юнәлгәннәрне тугры юлга бастырыр.

**14.** Аларга белем *(мәгълүмат)* килгәч, фикер каршылыклары һәм хөсетлек аркасында, аерым фиркаларга бүленеп беттеләр. Әгәр дә мәгълүм бер вакыткача *(аларның җәзасын кичектереп торам, дип Аллаһ)* әйтмәсә иде, *(һәлак итеп)* аларны хөкем иткән булыр иде. Алардан соң Китапка *(Тәүратка, Инҗилгә)* варис булганнар *(яһүдләр, христианнар)* аның хакында *(Мөхәммәднең пәйгамбәрлеге, Коръәннең Аллаһтан иңүенә)* бик нык шикләнәләр.

**15.** Шуна күрә, син берләшергә өндә вә сиңа боерылганча *(Исламга)* тугры бул. Аларның нәфесләренә иярмә һәм әйт:

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

—Мин Аллаһ иңдергән Китапка инандым вә арагызда гаделлек белән эш йөртергә вазифаландым. Аллаһ—безнең Раббыбыз, сезнең дә Раббыгыз. Безнең гамәлләребез—безгә, сезнең гамәлләрегез—сезгә. Үзара бәхәсләшергә сәбәп юк. Аллаһ бөтенебезне дә бер урынга туплар, кайтарылыш та Аның хозурына булачак,—диген.

**16.** Аллаһ*(ның дине)* турында, үгетләрне *(иңдерелгән аятьләрне, Аллаһның берлеген, Ахирәтнең булачагы турындагы кисәтүне)* кабул иткәннән соң да *(диннең хакмы, юкмы икәнлеге турында)* тарткалашулар Аллаһ каршысында буш нәрсә булып калыр. Андыйлар өчен җәза, тагын да хәтәррәк газаплар хәзерләнгән.

**17.** Китапны һәм *(хаклык)* бизмәнен Аллаһ иңдерде. Белмәссең, бәлки, Кыямәт сәгате якында гынадыр! **(18)** Аңа инанмаганнар, *(Кыямәтнең)* тиз килүен тели. Инанганнар исә аның *(Кыямәт көнендә җавап бирүдән)* куркалар вә аның чыннан да киләсен беләләр. Яхшы белеп торыгыз, Кыямәт көнен инкарь итеп тартышканнар чыгалмаслык булып адашыр.

**19.** Аллаһ бәндәләренә миһербанлыдыр. Теләгәнен ризыкландыра. Ул—кодрәт иясе, һәрвакыт җиңүче.

**20.** Ахирәт*(тә уңыш җыярга өметләнгәннәрнең)* нигъмәтләрен теләгән *(Аллаһка ихлас гыйбадәт кылган)* кешенең өлешен арттырырбыз. Дөнья малы теләгәнгә дә муллык бирербез. Ләкин аңа Ахирәттә өлеш булмас.

**21.** Әллә соң аларның Аллаһ рөхсәтеннән башка бер дин алып килгән илаһлары бармы икән? Әгәр дә кичектерү сүзе булмаса иде, аларның язмышы шундук хәл ителгән булыр иде. Һичшиксез, залимнәргә җан өтүче газап биреләчәк.

**22.** Кылган яманлыклары үз башларына төшкәч, залимнәрнең куркудан ничек калтыранганнарын күрерсең. Иман китереп, игелек кылганнар җәннәт бакчасында булыр. Раббы янында алар теләгән бөтен нәрсә булачак. Бөек бәхет менә шул булыр.

**23.** Аллаһның иман китереп, игелек кылган бәндәләренә вәгъдә иткән нигъмәте шушы булыр.

Әйт син *(ий, Мөхәммәд)*:

—Мин бу эшләрем өчен сездән кардәшлек мәхәббәтеннән башка һичбер түләү таләп итмимен. Игелек кылган кеше артыгы белән саваплы булыр,—диген. Шик юктыр ки, Аллаһ—ярлыкаучы, шөкер иткәннәргә савап бирүчедер.

**24.** Әллә соң алар:

*—(Мөхәммәд)* Аллаһ турында ялган сөйли,—диделәрме? Аллаһ ихтыяр итсә, синең күңелеңне дә йозаклап куя ала. Һәм Аллаһ яманлыкны юк итәр. Хакыйкатьне уртага салыр. Шик юктыр ки, кеше күңелендә ни бар, Аллаһ шуны белеп тора.

**25.** Бәндәләренең тәүбәсен кабул итүче, *(тугры юлга басканнарның элекке)* хаталарын ярлыкаучы вә кылмышларын белеп торучы—Аллаһ.

**26.** Иман китереп, игелек кылганнарның тәүбәсен кабул итәр, мул нигъмәт бирер. Кяферләрне хәтәр газапка тартыр.

**27.** Әгәр дә Аллаһ һәркемгә муллык бирсә, Җир йөзендә бозыклык артыр иде. Шуңа күрә, Ул ризыкны теләгәне кадәр генә иңдерә. Аллаһ бәндәләренең кылмышларыннан хәбәрдар, аларны күреп тора.

**28.** Өметләре өзелгән чакларда *(ачлык елларда)* Аллаһ янгыр яудыра, рәхмәтен һәр тарафка тарата. Ул—мактауга лаек чын химаяче.

**29.** Күкләрне, Җирне яралтуы да, Күктәге, Җирдәге бөтен җан иясен барлыкка китерү дә Аның *(барлыгына, кодрәтенә)* дәлил*(е)* булып тора. Аллаһ үзе теләгән вакытта *(Кыямәттә)* боларның барысын да бер урынга тупларга да кодрәтле.

**30.** Башыгызга төшкән һәр бәла үзегез казанганга бәрабәр. Шуңа да карамастан, *(тәүбәгә килгәннәрнең)* күбесен *(Аллаһ)* ярлыкаячак.

**31.** Сез Аллаһны бичара хәлдә калдыра алмассыз. Аллаһтан башка бер химаячегез вә бер ярдәмчегез дә юк.

**32.** Тау кебек көймәләрнең дәрьяларда йөзеп йөрүе дә Аллаһның *(барлыгына, кодрәтенә)* дәлил.

**33.** Ихтыяр итсә, Аллаһ җилне исүеннән туктатып торыр да, диңгез өстендәге көймәләр хәрәкәттән туктап калыр иде. Әлбәттә, монда нык түземсабыр кешеләргә вә чиксез шөкер итүчеләргә гыйбрәтләр бар.

**34.** Кылган гөнаһлары өчен аларны *(диңгезгә батырып)* һәлак итәр. Ләкин байтакларын *(ың тәүбәсен кабул кылып)* гафу итәр.

**35.** Шулай булгач, аятьләребез хакында гауга куптарганнар качып котылыр урын таба алмасларын белеп торсыннар.

**36.** Сезгә бирелгән *(байлык, ләззәт, дәрәҗә)* бары тик шушы дөнья өчен *(вакытлыча гына)*. Аллаһ хозурындагылар исә тагын да яхшы, тагын да дәвамлы. Бу бүләкләр иман китергәннәр һәм Раббыга сыенганнар өчен генә.

**37.** Алар *(мөселманнар)* иң зур гөнаһлардан берсе—оятсызлыктан ерак йөри. Ачулары чыккан чагында да, кызмаслар, кешене гафу итәрләр.

**38.** Янә алар Раббының чакыруына ияреп намаз укыйлар. Аларның эшләре үзара киңәш-табыш илә бара. Үзләренә иңдерелгән ризыктан алар *(Аллаһ юлындагыларга вә мохтаҗларга)* хәер бирә. **(39)** Аларның берәрсенә хаксызлык кылынса, бергәләп ярдәмләшәләр.

**40.** Яманлык өчен җәза шул кылынган яманлык кадәр булырга тиеш. Кем гафу итсә, тынычлык сакласа, *(бозылышканнарны татуландырса)* аңа бүләк Аллаһ тарафыннан булыр. Дөресе шул, Аллаһ залимнәрне сөйми. **(41)** Рәнҗетелгән кеше соныннан хакын кайтарса, аңа җәза булмас.

**42.** Яманлык кылганнарга вә Җир йөзендә хаксызга кеше рәнҗеткәннәргә җәза бар. Аларга—әче газап. **(43)** Кем дә кем *(үч алмыйча)* сабыр итсә һәм *(рәнҗетүчене)* кичерсә, һичшиксез, бу кеше мәртәбәле, нык рухлы икәнен исбатлар.

**44.** Аллаһ кемне дә булса адаштырса, ул кешенең һичбер ихлас дусты булмас. Җәзаны күргәннән соң залимнәрнең:

—Кире *(Дөньяга)* кайтыр юл бармы?—дип үкенгәннәрен күрерсең.

**45.** Син *(Мөхәммәд)* күреп торырсың. Утка ташлана торган урынны күргәч, алар чарасызлыктан башларын түбән иеп, күз кырыйлары белән генә утка багарлар. Иманлылар:

—Менә, асылда газапка дучар ителгән кешеләр шушылар булыр. Кыямәт көнне үзләрен дә, гаиләләрен дә бәлагә батырган кешеләр шул булыр,—диячәкләр. Аң булыгыз! Залимнәр өзлексез газап эчендә булачак.

**46.** Аллаһтан башка аларга ярдәм итәрдәй һичкем булмас. Аллаһ юлдан яздырган кеше *(кылмыш гөнаһларыннан кире әйләнеп)* чыгардай *(җәннәткә керердәй)* юл табалмас.

**47.** Аллаһ тарафыннан кичектерелми-кучерелми торган *(Кыямәт)* Көн килеп җиткәнче, тизрәк Аллаһ юлына басыгыз. Анда сезнең качып котылыр урыныгыз булмас, гөнаһларыгыздан да баш тарта алмассыз.

**48.** *(Ий, Мөхәммәд)* әгәр алар йөз чөерсә, *(син хафаланма)* беләсең ич, сине аларга каравылчы итеп куймадык *(Аллаһны инкарь итеп, гөнаһ кылсалар, алар өчен син җавап бирмисең)*. Синең җилкәнә төшкән вазифаң фәкать *(аятьләребезне)* аларга ишеттерү генә. Тарафыбыздан рәхмәтебез җимешләрен татыттыргач, ул кеше сөенә. Әмма үзе кылган җүнсезлекләренә күрә, башына бәла килсә, шөкер итүне оныта.

**49.** Күкләр һәм Җир—Аллаһның милке. Үз теләгәнен бар итәр. Теләсә—кыз балалар бирә, теләсә—ир угланнар бүләк итә. **(50)** Яки, теләгән кешесенә Аллаһ кыз балалар да, ир балалар да бирер. Теләмәгәнен кысыр итәр. Ул бөтенесен белеп тора, һәрнәрсәгә Аның кодрәте җитә.

**51.** Аллаһ кеше белән бары тик вәхий ярдәмендә яки пәрдә аша сөйләшер. Яки, илче күндереп, аның аша ихтыярын белдерер. Ул—бөектер, хакимдер.

**52.** Менә, шулай итеп, сиңа да әмеребез илә Коръәнне вәхий иттек. Син китапның ни икәнен дә, иманның ни икәнен дә белми идең. Әмма Без бәндәләребезне шушы Китап ярдәмендә туры юлга өндәр өчен нур иттек. Шөбһәсезләр ки, син туры юлны күрсәтүче.

**53.** Ул—Күкләрнең вә Җирнең хуҗасы Аллаһның юлыдыр. Аң булыгыз! Бөтен эшләр ахырда Аллаһ хозурына барып тоташачак.

Хәтер

# Розалина Нуруллина

## ТОМАННАРГА ЕЛЛАР КҮМЕЛДЕ...

* * *

*Намуслыны, әйтегезче, кайсы заман*
*Колач җәеп көткән?*
М. Әгъләмов

Ибраһим Нуруллин турында алтмышынчы елларда җәмәгатьчелектә билгеле бер фикер урнашып житкән иде. Рәсми кешеләр аны үз итмәсәләр дә, әдәбият сөючеләрдә, язучыларның шәхси шөһрәт өчен жан сатмый торган өлешендә үткен каләме, эш өчен кайгыртып язуы, туры әйтеп хакыйкать өчен көрәшүе аңа карата хөрмәт уяткан иде. Мәсәлән, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Нурихан Фәттах аңа ачу сакламадылар, хөрмәт белән карадылар, Нәби Дәүли фатир мәсьәләсен зурга җибәрмәде, дуслыгына хыянәт итмәде.

Ибраһим Нуруллин каршы килгән, тәнкыйтьләгән күренешләр, исемнәр арасында аның шәхсән кабул итә алмаганнары да бардыр, бәндә хатадан хали түгел. Әмма аңа карата өстә, адәмнәрнең язмышларын хәл итә торган даирәләрдә, мөнәсәбәт тудыра торганнары нәфис әдәбиятта тәрәккыятьне алга сөрәләр. Әгәр аның фикерләре иҗтимагый әһәмиятле булмасалар, шәхси файдаларын күзәтүче кешеләр партия өлкә комитетын корал итә алмаслар иде.

Ибраһим үзенә таш яудыручыларның берсенә дә шәхсән әшәкелек эшләмәде, ул гомумән, итәк астыннан ут йөртә торган кеше түгел иде. Киресенчә, гаделлек хакына ул үзен хурлаучыларны да яклый белде. Мисалы—Гали Халит. Гали абый жае чыккан саен Ибраһимга төртеп-тибеп китә иде. Ә менә Ибраһим Гали абыйның алтмыш яшьлегенә, иҗатына югары бәя биреп, матур мәкалә чыгарды.

Яхшы әсәрләр укыганда Ибраһим шатлана гына иде. Шуңа күрә аның бер үк язучылар турында (мәсәлән, Мирсәй Әмир, Атилла Расих, Гариф Ахунов һ. б.) һәм тәнкыйди, һәм мактаулы мәкалә-рецензияләре бар. Ул әсәрне авторына карап түгел, сыйфатына карап бәяләде.

Хәзер язучылар, тәнкыйть юк, дип зарланалар. Хәтта Гариф Ахунов та зарлана иде. Зарланмый хәлләре юк, төлке яшәмәгән Австралияне куян басып киткән кебек, тәнкыйтьсез калган татар әдәбиятын чиле-пешле хикәяләр, шигырь дип атала торган такмаклар басып китте. Барысы да бөек, барысы да даһи!

Равил Фәйзуллин телевидениедән ясаган бер чыгышында: Тәнкыйть язучы өчен түгел, укучы өчен языла ,—диде. Бу фикерне Ибраһим кат-кат кабатлады. Менә аның язганы: «Әдәби тәнкыйть дигәндә без *бүгенге әдәби процесска* багышланган һәм *киң катлау укучылар массасына адреслап язылган* рецензия һәм мәкаләләрне күздә тотабыз» (ассызык Ибраһимныкы—Р. Н.).

---

Ахыры. Башы 5 санда.

Әмма һәр язучы әсәренә карата әйтелгән тәнкыйди фикерне бик авыр кичерә, хәтта күбесе кичерә алмый. Әсәренә карата әйтелгән фикернең дөреслеген танып, шуннан нәтиҗә ясыйсы урында, ул фикер иясенә ташлана, аны гаепли. Ибраһимнын тәнкыйть фикерен ишеткәннәр, хәтта ишетмәгәннәре дә, аларның иҗатларын мактап чыкмаган өчен (берсе Ибраһимга турыдан-туры әйткән: «Мактап та язмадың»,—дигән), аны гаепли иделәр.

Минем карашымча, Ибраһимнын әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтенең әһәмияте аерым әсәрләргә ясалган анализ һәм бәяләмәләрдә генә түгел. Ә әдәбиятның торышына гомуми караш ташлап, нәфис әдәбиятның үсешенә киртә булган, искергән яисә яңа бөреләнеп килә торган унай сыйфатларын нәзари (теоретик) нигездә дәлилләп, язучылар җәмәгатьчелеге алдына куя белүендә дә. Ул, укучыларга әдәби әсәрләр дәрьясыннан үзләренә кирәклене сайлап алуда булышуы белән бергә, язучыларның үзләрен дә уйландырды. Шундый мәкаләләре бүген дә әһәмиятләрен югалтмаганнар, яшь иҗатчыларга дөреслек булып хезмәт итә алалар. Бүген журналистикада һәм нәфис әдәбиятта купшы чәчәк аткан күп сүзлелекне, үзенә-үзе сокланып язу гадәтенең зарарын аңлатуда Ибраһимнын «Кыскалык турында» кебек мәкаләләре игътибарга лаеклы түгелмени? Ибраһим Нуруллинның шундый мәкаләләре өч җыентыгына тупланган: «Образлар дөньясында» (1964), «Реализм турында» (1974), «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» (1984). Чыккан елларыннан аңлашыла—болар аның 40, 50, 60 яшьлеге уңаеннан басылганнар. Илле яшьлегенә нәшрият И. Нуруллинның «Аның йолдызы» исемле зур җыентыгын да чыгарды. Монда аның хикәяләре, пьесалары тупланган.

Габдулла Тукайның иҗатына һәм шәхесенә Ибраһим 1946 елдан башлап үзенә бер житдилек белән игътибар бирә. Ана Мөхәммәт Галинең Тукай иҗатына багышланган мәкаләсе бик ошый. «Яратып укыдым, шагыйрьнең кешелек сыйфатларына сокландым», дип язып куйган (27 апр. 1946). Ибраһим Тукайны үзе яшәгән тирәлектән өскә күтәрелә алган кеше итеп, аның бөеклегенә һәм даһилыгына сокланып, язмышы һәм яшәеш шартлары сәбәпле туган сыйфатларын һәм гамәлләрен аңлап, тирән бер сөю белән яратты. Ул аның өчен шагыйрь генә түгел, йөрәгенә якын бер шәхес иде. Ул аны тормыш ваклыкларына бирелмәгән мәгърур, кыю һәм олы җанлы кеше итеп күрә иде.

И. Нуруллин иҗатында Тукай турында сүз чыккач, алгарак, сиксәненче елларга, күчү булса да, әйтеп бетерим инде. Мәскәүдә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә Тукай турында китап чыгару фикере туа. Аны кем кузгаткандыр, мин белмим. Галимнәр тәкъдиме белән партия өлкә комитетыдыр, мөгаен, ул чакта һәртөрле гамәл шул оешма аша үтә иде. Китапны язуны кемгә тапшыру мәсьәләсе шунда каралды һәм Ибраһим Нуруллин моның өчен иң кулай кеше дип табылды. Мәскәүдән Ибраһимның Тукай турында моңарчы язылган әйберләрен соратып алдылар. Аннары үзен чакырдылар, кульязманы тапшыру вакытын билгеләделәр. Мәскәүне канәгатьләндергәне—Ибраһимнын һәм художестволы әсәрләре (Тукай турында хикәяләре, пьессасы), һәм гыйльми хезмәтләре булу. Чөнки бу серия документаль төгәллек һәм гыйльми дөреслекне нәфис әдәбият чаралары белән тасвирлауны таләп итә. Чачаклы-чуклы купшы тел белән котыла алмыйсың.

Китап 1978 елда чыкты. Язучыларның Ибраһимга хәерхаһ булганнары, әдәбият сөючеләр аны чын күңелдән шатланып каршыладылар. Ниһаять, безнең Тукайны русларга, алар аркылы бөтен дөньяга таныту иде бит бу! Мөхәммәт Мәһдиев: «Ибраһим абый, сез бүтән бернәрсә эшләмәсәгез дә, бу китабыгыз белән әдәбият тарихына керәсез»,—дип чылтыратты. Менә тагын берничә фикер: «Китап бик төпле. Достоверно (башкортча сүзен таба алмыйм). Тасвирлауларга мавыгып, «купшылык» артыннан куып, дөреслек көчен киметмәгәнсең. Шул ук вакытта бик җиңел укыла». *(Мостай Кәрим).*

«Сезнең бу мәшһүр китапханәдә чыккан матур китабыгыз Тукай мөхлисләренең күңелен шат итеп кенә калмый, бәлки, мәгълүм мәгънәдә зур сәяси-мәдәни вакыйга да булыр дип уйлыйм» *(Әсхәт Мохтар).*

Михаил Львов, Якуп Чанышев һ. б., һ. б. рәхмәт һәм котлау хатлары яздылар. Нәкый Исәнбәт Ибраһимны үз даирәсенә керергә лаеклы саный башлады.

1979 елда «Габдулла Тукай» китабы Казанда татарча чыкты. Икенче елны ике китабын,—Мәскәүдә чыккан русча һәм Казанда чыккан татарча вариантларын—Тукай бүләгенә тәкъдим иттеләр һәм ул үтте. Гаҗәп хәл булды бу!

Тагын алтмышынчы еллар азагына әйләнеп кайтыйк әле. «Шагыйрьне өйрәнү

юлында» мәкаләсе Ибраһимга карата гаять каршылыклы мөнәсәбәт тудырган шартларда, 1967 елда Ибраһим докторлык диссертациясен тәмамлады.

Хатип Госман бер каршылыксыз диссертацияне яклауга тәкъдим итү ягында булды. Кафедра әгъзалары да шул фикердә. Чөнки XX йөз башы татар әдәбияты буенча дәреслек урынында йөри торган егерме табаклык китабы инде чыккан, күп кенә мәкаләләре диссертация темасына карыйлар. Ибраһимның ул китабы тирән нигезләнеп һәм икеләнү калдырмый торган итеп язылган.

Кафедра диссертацияне яклауга тәкъдим итте. Ә тарихчы Рәфыйк Нәфигов Ибраһимга каршы чыгарга җыенып тора. Аларның Тукайга карашлары бертөсле түгел. Рәфыйк Тукайны большевик ук булмаса да, аларга бик якын тора дип исәпли, аның бу карашлары «Тукай и его окружение» исемле китабында бәян ителгән. Ибраһим исә, юк, Тукай большевик булмаган һәм була да алмаган, дигән фикердә. Ул бу фикерләрен төгәл итеп Нәфигов китабына язган «Ближе к истине...» исемле бәяләмәсендә аңлата *(«Сов. Тат.», 1986, 16 ноябрь)*. Ибраһим дәлил итеп дөреслеге тәмам тәгаенләнгән фактларны гына ала, Рәфыйк икенче-өченче буын аша тоташканнарга да таянырга мөмкин дип саный. Ә бу очракта инде ул бөтенләй филология мәсьәләләренә кереп, Ибраһим диссертациясенең төп концепциясен юкка чыгармакчы.

Икебезнең дә күңелебез борчулы.

Менә яклау көне килеп җитте. Гыйльми совет бертавыштан И. Нуруллин фән докторы дигән исемгә лаек дип карар чыгарды.

Бу юлы инде банкетны зурлап үткәрдек—Идел өстендәге «Парус» ресторанында. Тормыш дәрәҗәсе ягыннан бу елларда инде шактый ярыйсы тәэмин ителгән булсак та, бу әле бай идек дигән сүз түгел. Мин—«Ялкын»дагы хезмәт хакымнан шактый ким стипендияле аспирантурада. Ибраһим бер елга фәнни хезмәткәрлеккә күчеп, шулай ук сизелерлек ким ала башлады. Ә кызларыбыз үсеп җитте, кием-салым башкачарак кирәк.

Ибраһим докторлык диссертациясен кырык дүрт яшендә яклады. Ул яшь доктор һәм профессор булды. Хәзер утыз дүрттә дә доктор булалар. Ә ул чакта илледән узгач, алтмышлар тирәсендә генә ул исемнәрне алалар иде. Ибраһим доктор, профессор булгач, кыланыш-торышларын, кешеләргә мөнәсәбәтен үзгәртмәде, ул бер дә үзен зур итеп күрсәтә белмәде.

* * *

*Гыйлемлек нурани җәүһәр.*

Г. Кандалый

Докторлык яклагач, безнең тормышта беркадәр тынычлык чоры урнашты. 1973 елга кадәр, Ибраһимга илле яшь тулганчы. Бу елларда ул мәкаләләрне аз язган. Язганнары да үткен, кискен мәсьәләләр түгел.

Бу елларда ул ныклап торып Тукай һәм Әмирхан тормышларын өйрәнүне дәвам итте. Тукайның замандашларын, аларның балаларын эзләп Казан урамнарын таптады. Шагыйрь булган җирләргә сәфәр кылды. Акчуриннарның Гурьевкадагы сукно фабрикаларын карап кайтты. Анда аңа бер егет беренче тапкыр «отец» дип эндәшкән. Шуңа бик моңсуланып: «Картаям микәнни инде?»—дип сөйләнгән иде. Әстерхан, Уфа шәһәрләрендә Тукай эзләреннән йөреп, шагыйрьнең ул чактагы кичерешләрен аңларга азык эзләде. Ленинградта 1956 елда ук Тукай эзләрен барлаган иде инде. Архивларда күп эшләде. Аның исәбе Тукай турында роман язу иде. Планын «Атаклы кешеләр тормышы» сериясенә китап язу кирәклеге үзгәртте.

1971 елда нәшрият аның докторлык диссертациясенең китап вариантын «Путь к зрелости» исемендә чыгарды. Аңарчы, 1970 елда, «Вопросы литературы» журналында басылган «С ходуль—на свои ноги (к вопросу о реализме в тюркоязычных литературах)» исемле мәкаләсен үзбәк, казакъ, әзәрбәйҗан галимнәре төрки әдәбиятлары тарихы гыйлемендә вакыйга дип кабул иттеләр.

Үзбәкстанга барган чакларында Ибраһимны бик зурладылар. Ташкентта ул берничә тапкыр булды. Ике тапкыр мине дә алып барды. Берсе нәкъ «Вопросы литературы» журналында мәкаләсе чыккан тирәгә туры килде. Анда Лола Максумова татар-үзбәк әдәби бәйләнешләрен өйрәнеп, кандидатлык якларга тиеш иде. Ибраһимны, татар әдәбияты белгече буларак, гыйльми Совет әгъзасы ясадылар. Нил Юзеев оппонент сыйфатында барды.

Аннары берничә елдан соң, үзбәк галиме Бегали Касыймовның докторлык диссертациясенә Ибраһимны оппонент итеп чакырдылар. Анда без өч көн коммунизмда яшәдек. Безгә бернәрсә өчен дә түләттермәделәр. Без бик унайсызландык. Андыйга күнекмәгән. Бегали безне тынычландырды: «Муаллим, сез түләсәгез, минем эшем унмаячак. Үз акчам түгел, мина андый байлык каян килсен. (Туган районы хакимияте, ага-энеләре барлык чыгымнарны үз өсләренә алганнар.) Килгәне бере кесәгә пуль сала»,—ди Бегали. (Пуль—үзбәкчә акча дигән сүз.) Район җәмәгатьчелеге үз районнары кешеләренең доктор, профессор булуы белән горурланалар.

Бу юлы да Ибраһимны бик зурладылар. Яклауда чыгыш ясаган һәркем диярлек, Бегалиның диссертациясе белән бергә, Ибраһимны да олы галим дип зур хөрмәт белән сөйләделәр. Кеше үзенең дәрәҗәсен читкә киткәч белә, дип уйлап утырдым.

Казакъстанда да шулай булды. Анда да мин Ибраһим белән ике тапкыр бардым. Берсе—конференциягә, икенчесе Тәлгат Галиуллинның докторлык яклавына Ибраһим оппонент булганда. Ләзиз Каюмов, Турсынбәк Кәкишев кебек зур галимнәре Ибраһимны олылап, аңа хөрмәт белән карадылар.

1973 елда беренче һәм соңгы тапкыр Ибраһимның юбилей бәйрәмен Татар ашлары йортында 90 кеше чакырып үткәрдек. Зал ике тапкыр аякка басып кул чапты. Берсе—Нәкый Исәнбәтләр кергәндә, икечесе—улын күтәргән кызыбыз Гүзәл ишектә күренгәч.

* * *

*Эт кебек һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.*

Г. Тукай

Иҗтимагый-сәяси яшәеш нисбәтеннән авыр, катлаулы, фәнни-иҗади юнәлештә саллы казанышлар чоры булган 70-80 еллар. Шулар арасында иң газаплылары—1975—1978 еллар арасы.

Ибраһимның кешеләргә мөкиббән китә торган гадәте барлыгын язган идем. Альберт Яхинны да ул сәләтле, хаклык өчен көрәшүче намуслы кеше дип санап аерата яратты, туганы кебек якын күрде. Кайдадыр, Тымытык районындамы, эшләп яткан җиреннән аспирантурага чакыртуга иреште. Аспирантураны диссертация якламыйча тәмамлагач, өстендә торып диярлек, диссертация язарга мәҗбүр итте. Аны кафедрадан үткәрүдә күз-колак булып торды.

Кафедра мөдирен алыштыру фикере тугач, Ибраһим Альбертны тәкъдим итте. Яхин исә кафедрага килүгә беренче эше итеп Ибраһимга һөҗүм башлады: аспиранты Р. Якуповны укуыннан куды, И. Нуруллин фәнни эш планын үтәми, лекцияләрен начар укый дип тикшерүгә куйды. 1977 елның 24 гыйнварында барган Совет утырышының протоколын мин Ибраһимның көндәлегенә язып барганмын. Тикшерүчеләр фикеренчә, Ибраһимның бер житешсезлеге—лекцияләрен үз китабы буенча укый. Әнвәр Ахунжанов сорау бирә: «Башка дәреслекләр булмагач, кайдан укысын?» Кызык һәм гыйбрәтле сорау бит!

Бөек Ватан сугышы инвалиды булган ирләргә пенсиягә 55 яшьтән китәргә хокук биргән указ чыккан иде. Ибраһим болай да, яхшы гына эшләп торса да, 55е житүгә пенсиягә чыгып, ярты ставкага калырга жыена иде. Ә хәзер, эшләр жанжалга киткәч, пенсиягә чыкты да, татар әдәбияты кафедрасыннан бөтенләй китеп, рус һәм көнчыгыш әдәбиятлары кафедрасына күчте, профессор-консультант буларак 1989—1990 уку елы беткәнче шунда эшләде. Хөрмәт итәләр иде үзен.

Заманында Ибраһимның сәламәтлеге өчен кайгыртып, булган хәлләрне аның белән бергә кичереп, мин мәсьәләнең икенче ягына әһәмият биреп житкермәгәнмен. Хәзер, ерактанрак карап исем китә. Минем ирем нинди куәтле рухлы кеше булган икән. Нинди авыр вәзгыятьтә дә ул эчүчелеккә сабышмады, иҗади каләмен кулыннан төшермәде. «Детская литература» басмаханәсе кушуы буенча Тукай турында «Напевы мятежного саза» исемле китап язды. Фатих Әмирхан иҗатын һәм аның даирәсен өйрәнүгә башы белән чумды.

1978—1979 уку елында рус әдәбияты кафедрасына күчкәч, Ибраһим әдәби иҗат белән иркенләбрәк шөгыльләнә башлады. Аның иң яраткан көннәре шимбә, якшәмбе иде. Ул көннәрдә жыелыш-фәлән булмый, эш белән телефоннан чылтыратмыйлар, рәхәтләнеп өстәл янында утыра, бүлмәсендәге караватка ятып укый, уйлана.

1980 елда Ибраһим Фатих Әмирхан турындагы китапка кереште. Аңарчы Фатих Әмирхан иҗаты турында 50 елларда ук кандидатлык диссертациясе темасы алган Рәшат Гайнановка әйтте: «Бер ел эчендә якламыйсың икән, үзем Ф. Әмирхан турында яза башлыйм». Ә Рәшат, төрле кешеләр турында мәгълүмат җыю белән мавыгып китеп, диссертациясен тәки өлгертмәде.

Тукайның тормышын өйрәнгәндә үк Ибраһим классик әдип турында күп нәрсә белгән иде. Ике бөек шәхеснең 1907—1913 еллардагы яшәешләре бер-берсенә нык бәйләнгән, аралашкан кешеләре, уй-фикерләре уртак. Әдипнең Тукайдан соңгы гомерен белүчеләр белән, туганнары белән очрашып истәлекләр, фоторәсемнәр җыйды (Әмирханның сөйгән кызы Шәмсенисаның рәсемен тапкач, шатланганын белсәгез!), архивларда утырды, Ялтага барып, ул дәваланган шифаханәне күреп, әдипкә хезмәт күрсәткән шәфкать туташларының берсенең эзенә төште. Минем карашымча, Ибраһимның Ф. Әмирхан турындагы китабы «Тукай»га караганда да баерак һәм тирәнрәк. Тик ул 1988 елда, халык Н. Дудинцевның «Белые одежды» кебек, моңарчы ябылып яткан әсәрләрне ябрылып укыган чакта дөнья күрде. Шуңадыр, күләгәдәрәк калды. Хәер, матбугатта уңай бәяләмәләр басылды.

Ниһаять, Ибраһимның алтмыш яшьлеге җитте. Аны билгеләү җәһәтеннән берәр нәрсә эшләргәме-юкмы дигән сорау килеп басты. Ул Әмирхан Еники абыйдан киңәш сораган һәм менә нинди җавап алган:

«...Син—әдәбиятчы-тәнкыйтьче, ә бездә бу адәмнәргә кадер-хөрмәт бик кечкенә. Мин әле бер генә әдәбиятчының да зур итеп үткәрелгән юбилеен күргәнем юк. Хатип Госманның 70 еллыгын бер дәрес бүлмәсендә, гади генә чәй табыны янында 15-20 кеше җыелып үткәрдек. Союздан килүче дә, котлаучы да булмады шикелле... Ә бит ул да җитди галим, доктор, профессор... Мин моның белән синеке дә шулай гына үтәргә тиеш дип әйтергә һич тә җыенмыйм, Алла сакласын (хотя, юбилейларга мин үзем бик скептически карыйм). Әмма синекен дә шулай чикләргә, кечерәйтергә тырышалар икән, моңа исең китмәсен. Синең әдәбиятта тоткан урының зур, нык, гомерлек—һәртөрле юбилейлардан да өстен тора! Бөтенләй отказаться итсәң дә, берни югалтмаячаксың».

Ибраһим Әмирхан абыйның киңәшен тотты. Бернинди рәсми билгеләүләр, бүләкләр булмады. Үзебез туганнар, дуслар белән Яшьләр үзәгендә бәйрәм иттек.

* * *

*...Шулай әрни, көя-көя,*
*Торам татар арасында,*
*Үзем дә шул татарның бер*
*Баласымын баласын да...*

С. Рәмиев

Бу елларда дуслар-фикердәшләр даирәсе беркадәр үзгәрде. Мәрьям һәм Җәмил Гыйльмановлар аша да, гомернең икенче ягына авышып җитдирәк яши башлаганга күрә дә, яна дуслар өстәлде. Ибраһимның 70 елларда дуслашып киткән кешеләреннән тарихчы галим Әгъдәс Борһановны әйтергә кирәк. Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов белән Ибраһим Әгъдәс өчен бик борчулы көннәрдә танышып, дуслашып китте.Әгъдәсне Җәмил Ибраһимның докторлык яклавына алып килгән иде.

Әгъдәснең Займищедагы бакчасы безгә янәшәдә генә иде. Анда очрашулар араны нык якынайтты. Шунда ук аның үзбәк аспиранты пылау пешерә. Җәмил, Әгъдәс, Павел Васильевич, Ибраһим шахмат уйныйлар. Кем отыла, шул урынын башкага бирә. Шахматның иң зур мәгъшугы Павел Васильевич иде. Займищеда, Әгъдәсләрнең өендә очраша-очраша, Асия Фәридовна белән Павел Васильевичлар да безнең табындаш, фикердәш булып киттеләр. Павел Васильевич Абрамов—зур галим, финанс-экономика институтының директоры (ул заманда институт җитәкчеләрен директор диләр иде) булган кеше. Ул үзен бик гади тота, гаять сөйкемле, үткен сүзле иде. Асия Фәридовнаны без инде күптән беләбез, ул—«Азат хатын» журналының редакторы иде.

Мин берәр кая китсәм, бакчадамы, өйдәме Ибраһим «мальчишник» ясый. Шул егетләр түгендә очраша-очраша Әгъдәс Әмирхан Еники белән дуслашып китте. Ул безнең дөнья эченә бөтенләй керде дияргә була. Без аны Нәкый агалар, Әмирхан

абыйлар, Бакый Урманчелар, Павел Васильевичлар кебек мөхтәрәм кунаклар янына да, бәйрәмнәрдә һәм туган көннәрдә була торган гадәти табыннарга да чакыра башладык. Бакчасына авыррак әйбер алып барасы булса, Ибраһимның машинасы әзер. Алар Горький урамындагы Гази ага Кашшафлар белән бер өйдә торалар иде. Гази аганың кухня тәрәзәсе ишек алдына чыга. Ул шул тәрәзәдән Ибраһимның Әгъдәсләргә килеп-китеп йөргән күзәтә икән. Бер көнне миңа бик үпкәләп әйтте: «Шунда безне дә алып китсәгез ни була?» Мәнсезлек күрсәткәнбез, Гази ага безнең игътибарга мохтаж дип исебезгә дә кермәгән.

Соңыннан Әгъдәс Борһанов бер академикның (хәтерем ялгышмаса, Константинов фамилияле бугай) кызына өйләнеп, Мәскәүгә күчте. Әмма үзенең кызы Казанда булгач, еш кайта, кайткан саен өйгә, Мәскәүгә барсак, кунакханәгә Әгъдәсләрне чакырмый калмыйбыз, үзләрендә дә булабыз, хатыны Алисә бик ачык чырайлы, яхшы күңелле кеше.

Һәм менә 1985 ел житте. Үзгәртеп кору чоры башланды. Горбачевны башта бик яраттык: кәгазьгә карамыйча да сөйли ала, үз аягы белән йөри, журналистларның сорауларына үзе жавап бирә. Аннары эчүчелеккә каршы көрәш китте. Сүз боткасы башланды. Ельцин килде. Әгъдәс демократларны, Ельцинны, ваучеризацияне берсүзсез яклый, күләгәдәге, талап жыелган, байлыкларны яктыга чыгарга ирек бирергә кирәк дип саный, Чубайсның приватизациясен дөрес дип хисаплый. Хәзерге хәлләрнең төп гаеплесе Ленин, ди. Ә Ибраһим аның белән килешми: юк, Лениннан түгел, Сталиннан башланды, ди. Ленин безгә республика бирде, шуның өчен генә булса да, аны хөрмәтләргә кирәк. Соңгы килүләренең берсендә Ленинны бик каты сүгә башлагач, мин ана: «Безнең өйдә Ленин турында начар сөйләмиләр (в нашем доме о Ленине плохо не говорят)»,—дидем. Сәяси бәхәсләр рус телендә бара, Әгъдәс татар телен яхшы белми. Ибраһим вафатына чаклы Лениннан һәм коммунизм идеяләреннән ваз кичмәде, надан һәм комсыз житәкчеләр идеяләргә хыянәт итеп, илне упкынга төшерделәр дип санады.

Әмирхан Еники белән Ибраһим 50 еллар азагыннан ук, бөек әдипнең әсәрләренә югары бәя биреп язылган мәкаләләре чыккач ук, аралаша башладылар. Башта алар гаиләдән тыш, үзләре генә очрашалар иде. Тора-бара Әмирхан абый да безгә килә торган булып китте. Ибраһимның көндәлекләрендә бик күп очрашуларның тәфсиләте бар. Ул Әмирхан Еникине халык күңелендә мәхәббәт яулаган язучы итеп хөрмәтле, үзара мөнәсәбәтләрендә гаять намуслы, керсез күңелле кеше булганга яратты. Ә Әмирхан абый үзе Ибраһимның елын үткәргән вакытта аңа мөнәсәбәтен болай аңлатты: «30 ел буена бер дә үпкәләшмичә дәвам иткән дуслык. Гәрчә без икебез ике түтәл жимеше, идеологик карашларыбыз төрле. Шулай булса да, ул үзенекен такмый, минекен какмый, дигәндәй, бер-беребезгә дустанә калдык, ул үзенең миңа мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Бөтен эчке серләрне уртага салып сөйләшеп була иде, сүзне чыгарыр, серне таратыр дигән шик күңелдә һич булмады, бик ышанычлы ихлас сердәш иде. Гаилә серләрен дә, дөнья хәлләрен дә рәхәтләнеп сөйләшеп була иде. Ул заманнарда сер саклаучыны табуы бик кыен иде».

1991 елда, Ибраһимга фажига буласына 4-5 ай калганда, Переделкинода без тагын Гыйлемдар Рамазановлар белән бергә ял иттек. Анда Мостай Кәрим, Муса Гали, Мидхәт Гайнуллиннар да бар иде. Алар белән аралашу да Ибраһимга рух өстәде, күңел азыгы булды. Ул—Ибраһимның иң илһамланып, иң жәелеп эшләгән чаклары, Гаяз Исхакый өчен көрәшеп йөргән заманнары. Гаяз Исхакый исемен илгә кайтару өчен Ибраһим алып барган көрәш халык күзендә, аеруча яшьрәкләрдә, аңа ихтирамны бермә-бер арттырды. Наз күрми ятимлектә үсеп, кинәт үз анасы куенына килеп кергән бала кебек, ул үзенә карата хөрмәттән ләззәтләнде, күңеле язылып, иркенләп яши башлады. Шул ук вакытта идеологик бәхәсләрне дә туктатмады.

Ибраһим коммунизмнан, Лениннан баш тартмады. Ул—Ленинның әһәмиятле хезмәтләренең барысын да укыган, кешедән ишетеп түгел, үзе аңлап белгән кеше. Ләкин ул догматик булмады. Әмирхан Еники: «Әдәбиятчылар һәм тәнкыйтьчеләр арасыннан миңа бердәнбер якын торучы дияр идем мин аны... Башкалары белән болай якыная алмадым, чөнки алар барысы да идеология сагында торучылар иде, ә мин алардан никтер сагая идем. Ибраһим миндә шул сагаю хисен бервакытта да уятмады. Хәлбуки, кайбер житди мәсьәләләрдә безнең бик нык аерылган чакларыбыз да булды... Шулай да нәрсә якынайтты соң безне? Ул бервакытта да рәсми идеология колы булып, коры догматикка әйләнмәде. Беренче мәкаләләрендә үк ул язучының тормышка кыю керүен, реаль каршылыкларны курыкмыйча ачарга хаклы булуын

яклап чыкты... Ибраһим әдәби әсәрнең беренче нәүбәттә сәнгатьчә булуын, нәфислеген, эстетик әһәмиятен күрә, бәяли белде. Чын язучы өчен иң кирәге шулар бит инде» («Тат. хәб.», 1993, апр.).,—дип язып чыкты.

«Салават күпере» журналының баш мөхәррире шагыйрь Зиннур Хөснияр 1997 елның гыйнварында телевизордан ясаган чыгышында: «Коммунистларның мораль кодексының кайсы таләбе начар, явыз ниятне алга сөрә?» дип сорау куйган иде. Чын коммунистлар әнә шул кодекста күрсәтелгән әхлаклылык, намуслылык, туган илне сөю һәм туган халкына эчкерсез хезмәт итү кебек принциплар белән яшәделәр. Ибраһим шундыйларның берсе иде. Ватан сугышы фронтларында, «Коммунистлар, алга!» дип, дошман өстенә ташланган командир кебек, ул да иң куркыныч, әмма иң кирәкле сүзне вакытында әйтә белде. Аның көрәш мәйданы—әдәбият. Анда ул партиялелек принцибын яклады, аны реалистик әдәбиятта тормышны хезмәтчел халык файдасын күзәтеп, аның ноктаи нәзарыннан торып гәүдәләндерү дип аңлады.

* * *

Ибраһим 1990 елның июленнән эштән бөтенләй китте. Пенсиягә чыкты. Декан Флорид Әгъзамов: «Ник китәсез, эшләгез әле»,—дисә дә, китте. Пенсиябез житәрлек, балалар әйбәт кенә тормышларын жайлап жибәрделәр, хәзер аларга ярдәм итмәскә дә мөмкин. Рәхәтләнеп яшәп калабыз, янәсе. 1991 елның июнендә Ибраһимга инсульт булды. Ул жомга көн иде, безгә кунаклар килергә тиеш иде. Иртүк торып, мин камыр куйдым, ашап-эчкәч, Ибраһим савыт-сабаларны юды да: «Тагын эшең булса әйтерсең»,—дип, бүлмәсенә китте. Бераздан ниндидер тавыш ишетеп борылып карасам, иңдәндә, бүлмә ишеге янында, кулы күренеп тора. Йөгереп барсам, Ибраһим идәндә торырга маташып ята, сүзен әйтә алмый, ниндидер авазлар гына чыгара. Йөрәгем жу итеп китте. Паралич! Тирә-күршеләрдән яшьрәк ирләр юкмы күтәреп салырга дип, эзләдем, берәү дә юк. Көч-хәл белән, бер кулын муеныма ябыштырып, протезлы аягын исәне янына шудырып китереп бастырдым, урынга илтеп салдым. Тотындым «ашыгыч ярдәм» машинасына, хастаханәгә чылтыратырга. Ашыгыч ярдәм тиз килде, уколлар ясадылар да китеп бардылар, янәсе, урынын кузгатырга ярамый. Ибраһим, сугыш инвалиды буларак, өлкә комитеты хастаханәсенә беркетелгән иде инде. Чылтыратам, невропатолог юлламасыннан башка кабул итмибез, диләр. Ә аны жибәрә алмыйлар, чөнки ул берәү генә, икенчесе ялда икән...

Төрле урыннарга, таныш-белешләргә чылтыратам, бар да ялда. Сәгать уникеләрдә берлек рәисе Ринат Мөхәммәдиев эшкә килде, аның ярдәме белән хастаханәгә салу мәсьәләсе хәл ителде: анда кичке сәгать дүртләрдә генә килеп життек. Төн буе аңсыз диярлек ятты. Су эчәсе килә, тамагыннан су үтми, сүзен әйтә алмый. Иртән мине алыштырырга кызыбыз Гүзәл килде. Табиб аңа әйткән: «Әзер булып торыгыз: мондый авыруларның йөздән икесе-өчесе исән калса кала»,—дигән. Ай ярым реанимациядә ятканнан соң, Ибраһим тагын бер ай гомерен гомуми палатада үткәрде. Бер генә сәгатькә дә ялгыз калдырмадык.

Реанимациядә ятканда ук эшли дә башлады ул. Горький музеен бетерү турында матбугатта сүзләр кузгалган чак иде, шул музейны яклап «Советская Татария» газетасына мәкалә язды.

Аның сул кулы һәм протезлы аягы зәгыйфьләнде. Таягына таянып иде дә, ике-өч адым саен туктап торыр иде. Мин моның төп сәбәбен аңламаганмын.

—Ник торасың инде, атла,—дим.

—Тукта, планлаштырасы бар бит әле,—ди.

Бер генә тапкыр да: «Хәл жыеп торам бит»,—димәде. Мин моның шулай икәнен бераздан гына төшендем.

Элек тә Ибраһим берничә тапкыр аңын югалтып, каты авырып алган иде. Берсендә, ГИДУВта реанимациядә ятканда, тәмәкесен ташлады (ә нинди тәмләп, бирелеп тарта иде бит). Шуннан соң бер тапкыр да авызына алмады. Бик кирәксә, өрек суыра иде. Бу юлы да ихтыярының куәтле икәне расланды. Аз гына хәле яхшыру белән ул элекке гадәтенчә яши башлады: иртән торып эш өстәле янына барып утыра. Нәрсә булса да яза. 1991-95 елларда аның 70 ләп язмасы басылып чыккан. Алар арасында замандашларының портретлары, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай кебек олпат әдипләрнең ижатына караган корреспонденцияләр, төрле тәкъдимнәр бәян ителгән, хәтта проблемалар куйган язмалар, үзе яраткан әсәрләргә

карата тәфсилле бәяләмәләр бар. Аның әдәбият дөньясында элек булган уңай традицияләрнең югала башлавына бик эче поша иде. Шуларның берсе—яшь сәләтләрне эзләү, тәрбияләү. Әдәбият тарихын бозмыйча өйрәнү, совет чоры әдәбиятын юкка чыгарырга тырышуның зарары, истәлекләрнең әһәмияте һ. б., һ.б. хакында язды. Ул инде ниндидер ярдәмлекләрдән файдалана алмый. Башында булган байлыктан гына фикерләр, дәлилләр чүпли иде. Фикерләве зәгыйфьләнмәде. Рафаил Төхфәтуллин, Фәнис Яруллин иҗатлары хакында язылган бәяләмәләре авторның кин мәгълүматлы, нечкә, сизгер зәвыклы, сәнгатьне аңлый һәм ярата торган каләм иясе икәнен күрсәтеп торалар.

Гомеренен соңгы дүрт елында Ибраһим тормыш мәгънәсен матбугатта катнашуда күрде. Үзенең фикерләре, карашлары, тәэсирләре белән уртаклашып торудан көч алды. Газетларны көтеп ала, укып бара, язганы матбугатта озаграк чыкмый торса, борчыла, чыдырата башлый. Өйдә генә ятарга мәҗбүр булганга, телефон аның өчен зур юаныч булды. Алар Фәнис Яруллин һәм Рифгать Исмәгыйлев белән көнаралаш чылтыратышалар, Әмирхан абый белән элемтәсе өзелмәде, туган-тумачалар машина белән кунакка алып китәләр. Әлбәттә инде, аның белән телефоннан сөйләшү җиңел түгел иде. Аның сөйләшүе акрынайды, озын-озак сүз эзләп тора. Шулай да аның белән сөйләшәләр, түзәләр, үзләре чылтыраталар. Гомернең соңгы елларында Ибраһим Салих ага Баттал белән аеруча якынлашып китте. Салих абый үзе дә килгәли иде. Ул Тукай әсәрләрен өйрәнде, бәлки нәрсә дә булса язгандыр да, «Тукайның менә бу шигъри юллары кайсы әсәреннән, Тукай аны кайсы елда язган?» ише сораулар белән еш мөрәҗәгать итә иде.

Җәмилнең тудык энесе күптәнге фикердәш һәм дус Мәсгут Гайнетдинов килгәли. Йөрергә чыккан җиреннән Сафа Сабиров кереп чыга. Менә бервакыт Уфадан Фәния белән Гыйлемдар Рамазановлар килеп төштеләр. Алар белән бездә, Әмирхан абыйларда, Рифгатьләрдә очрашулар гомер онытылмаслык матур хатирәләр булып күңелдә саклана.

Ибраһим табигатьне ярата, табигать кочагында һәрчак хозурлык таба иде. Бакчада баскыч төбенә, йә өй янына чыгарып куелган кәнәфигә утырып агачларны, чәчәкләрне күзәтә. Мин, төшенкелеккә бирелеп: «Тормышның яме калмады, китсәк тә ярый инде бу дөньядан?»,—дисәм: «Әй, әнисе, менә шушы яшел яфракларның лепелдәвен карап утыру да рәхәт, шуның өчен генә дә дөньяда яшәрлек»,—ди иде.

Үлем үкенечсез булмый, диләр. Минем күңелемдә дә бер үкенеч саклана. Җәй көннәре без аның белән кайтмыйча диярлек бакчада яши башладык. Анда тирә-күршедә бик мөлаем яхшы кешеләр. Алар Ибраһим янына килеп сөйләшеп утыралар. Күршедәге бакчасында булганда Кыям Минлебаев кергәли, Рифгать атна саен диярлек килеп хәлен белеп китә.

Шулай да Ибраһимнын Казанга кайтасы килә, дусларны, балаларны сагына. Атна арасында Гүзәл белән Миләүшә ризыклар китергәннәр иде, әйтеп җибәрде:

—Якшәмбе көнне Солтан килсен, шашлык ясасын, барыгыз да җыелыгыз.

Мин әйтәм:

—Алай ук катгый куйма мәсьәләне, эшләре булуы мөмкин.

—Юк, килсеннәр,—ди.

Килделәр, бакча өебезнең ачык верандасында гаиләбез җыелып, матур итеп сөйләшеп-гәпләшеп утырдык. Һәм бу безнең актык утыруыбыз булды. Үкенечем исә мондый. Икенче атнаның атна киче көнендә Ибраһим Казанга кайту турында сөйли башлады. Мин әйтәм:

—Менә шимбә көнне балалар килә, алар белән кайтырбыз, бер генә көнгә түз, көн саен машина куып булмый бит инде,—дим.

Җомга көнне аның кәефе яхшы түгел иде инде:

—Гәүдәмнең сызламаган җире юк, протезым шулкадәр авырайды, аягымны кочкә атлыйм,—ди.

—Протезың авыраймады, аягыңның хәле юктыр,—дим.

Без көн саен Татарстан телевидениесенең яңалыклар тапшыруын карыйбыз да, мин Ибраһимны бәдрәфкә алып барып киләм. Ә бу көнне мин нәрсә беләндер мавыккан арада үзе генә барып килгән:

—Мин эшемне бетердем,—диде. Кереп ятты.

Гадәт буенча, кичке сәгать уннарда аның өстенә ябарга кердем. Чигәсеннән үбеп: «Тыныч йокы, әтисе»,—дидем. «Сиңа да тыныч йокы, ул сиңа бигрәк тә кирәк»,—диде. Аның миңа әйткән соңгы сүзе шул булды.

Иртән сәгать алтынчы яртыда ишегеп ачып карасам, хырылдап йоклап ята. Нишләп бүген озак йоклый икән дип кенә уйладым, аны-моны сизмәдем. Сигезенче яртыда да тормагач, кереп: «әтисе»,—дип мангаеннан сыпырсам, күзен ачмый, аңында түгел. Күршеләр Казанга балаларга чылтыратты. Васильеводан ашыгыч ярдәм чакырдылар. Сәгать уникеләрдә Солтан профессор Фроловны алып килде. Мин әйтәм: «Баш мие шешми микән?»—дим. Профессор: «Әйе,—ди,—үпкәсе дә шешенә»,—ди. Казанга алып кайтырга кирәк, Васильеводан ашыгыч ярдәм машинасы бирмиләр, Солтан Казаннан кичкырын гына алып килде. Хастаханәгә алып кайтып җиттек үзе. Тик шунда ун-унбиш минуттан аның йөрәге тибүдән туктады. 1995 елның 1-нче июль көне киче, сәгать сигезенче егерме минут иде. 44 елдан артык сердәш, фикердәш булып яшәгән җан дустым, ирем дөньядан китте. Хәлемне чәчмә сүз белән анлату кыен. Фәния Чанышеваның шигыре минем кичерешләрем турында язылган кебек.

Йомылды шәфкатьле күзләрен,
Колакта ягымлы сүзләрен;
Үткәндә—хаталар, ялгышлар...
Калды тик тау хәтле сагышлар.
Төннәр ул болай да төн инде,
Көннәрем карага төренде,
Син яткан ләхеткә минем дә
Иң якты елларым күмелде.

Җеназасы университетның мәрмәр залында үтте. 4 июль—җәй уртасы булуга карамастан, кеше шактый җыелган иде. Кайгынамәгә Минтимер Шәймиевтән башлап барлык зур җитәкчеләр кул куйган иде, җеназага хакимияттән мәдәният министры урынбасары килде. Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев университеттан гына озатып җибәрде, зиратка Ибраһимны хөрмәт иткән шактый кеше барган иде. Араларында иң хөрмәтлесе—Әмирхан абый Еники.

Әгәр дә татар милләте яшәсә, килер яңа буыннар. Үткәндә яшәгәннәрнең хезмәтләренә, кылган гамәлләренә фәнни күзлектән карап, вак-төяк алыш-биреш, ыгы-зыгылар белән буялмаган ноктадан торып бәя бирерләр. Мин ышанам, Ибраһим Нуруллин исеме хөрмәт белән искә алыныр. Чөнки ул фәндә дә, әдәбиятта да корсак кайгысын беркайчан да намустан өскә куймады.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Kitap kūzәtu
Китап күзәтү

# МУЛЛА АБЗЫЙ КИТАП ЯЗА

Кемгә ничектер, әмма соңгы араларда минем үземә традицион алым белән язылган реалистик проза әсәрләре торган саен якынрак, кадерлерәк, тансыграк була бара... Мөгаен, бу хис, мондый тойгы бер миңа гына хас түгелдер. Җәмгыятьтә кискен һәм зур үзгәрешләр күбәйгән саен, күңел үзе өчен ышанычлырак нигез булган тотрыклылыкны ныграк юксына, тели бара. Үткән егерменче гасырның башыннан алып бүгенгәчә дәвам иткән социаль һәм сәяси тәҗрибәләр, революцияләр кешене инде тәмам туйдырды кебек.




Ә бүген безнең күңелләр теләгән ул тотрыклылык кайда микән соң?

Минемчә, безне тудырып үстергән табигатьтә, туган җиребездә ул! Әнә шул бердәнбер ышанычлы нигезнең, бәрәкәтле туфракның бетмәс җегәре, мәңге яшәүчән көче хәзерге шәһәрләр һәм алар тудырган тормыш белән чагыштырып караганда бигрәк тә ачык күренә.

Рәсәй дигән илдә килеп чыккан зур үзгәрешләрнең җанга якыннары бик аз булу да; бу илдә һәм дөньяда «көчәк сәясәте»нең беренче урынга чыгуы да; җәмгыятьтә гаделсезлек, ачлык, ялангачлык көчәю дә—болар барысы да безгә якын үткәнебездәге гуманистик идеалларны искә төшерә.

Күңел тансыклаган әнә шундый кешелекле идеалларны, әнә шундый яшәешне табарга теләп без бүген әдәбиятка һәм анда да күбрәк өлкән буын каләм ияләре иҗатына мөрәҗәгать итәбез.

Ә ни өчен нәкъ менә алар иҗатына?

Чөнки өлкән буын иҗатчыларның күбесе кечкенәдән үк авыл тормышының, авыл табигатенең гармониясен үзенең җанына, күңеленә, рухына сеңдереп үскән... Менә мондый шәхеснең эчке дөньясы, аның үзенең кем икәнлеге, нинди икәнлеге ул язган әсәрне укыган чагында шундук сизелә бит аның. Аннары тагын шунысы да бар: өлкән буын каләм ияләре озак яшәү дәверендә үз күзләре белән бик күп гыйбрәтле һәм тетрәндергеч вакыйгалар күргәннәр, шулар белән нык тәэсирләнгәннәр—аларның хәтерендә онытылмаслык һәм үзенчәлекле бик күп язмышлар яши... Мондый иҗатчы инде язарга утырса, кайсыбер яшьләр сыман, сиңа үзенең телевизордан күргән киносын яисә укыган китабын гына сөйләми! Ул инде сиңа олы чынбарлык хәлләрен бәян итә!

Алтмыш-җитмеш яшьлек әнә шундый прозаикларыбызның һәр язган әсәрен диярлек кызыксынып һәм сокланып укып барам: Фоат Садриевныкын, Радик Фәизовныкын, Зәки Зәйнуллинныкын...

Соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында берничә проза җыентыгы чыгарган Габдулла ага Галиевне дә, һичшиксез, әнә шулар янәшәсенә язарга тиешбездер. Аның үткән ел дөнья күргән «Хәзрәт малайлары» дигән китабы моңа саллы гына дәлил булып тора.

Китапка уртача күләмдәге өч повесть һәм тугыз хикәя кергән. Повестьларның исемнәре мондый: «Сандугач», «Үкенү», «Терсәк якын да бит...» Ә шулай да сүзебезне китапка исем биргән хикәядән—«Хәзрәт малайлары»ннан башлап китик әле. Бу хикәягә һәм тулаем китапка ни өчен шундый сәеррәк исем кушылган икән соң? Әллә инде бу замана агымына бер иярү генәме?

Хәер, замана агымына иярү генә түгел икәнлеген Габдулла ага Галиевнең үзенең Әгерҗе төбәгендә инде менә

Габдулла ГАЛИЕВ. «Хәзрәт малайлары». Татарстан китап нәшрияты. 2002 ел.

күп еллар буе фельдшер булып эшләве һәм хәзер Кырынды авылында мулла вазыйфасын башкаруы ук әйтеп тора. Боларның һәр икесе дә кеше турында, аның физик һәм рухи сәламәтлеге хакында иң нык кайгырту таләп итә торган изге Вазыйфа бит. Димәк, биредә инде модага иярү хакында сүз була алмый. Бу—кешенең бөтен тормышы, тулы язмышы дигән сүз.

Ә инде бу китаптагы «Хәзрәт малайлары» дигән хикәяне укыгач без моңа тагын бер мәртәбә ышанабыз.

Сугыш алды еллары. Миншәех хәзрәт белән Мәрьям остабикә икесе дә вафат булган да, аларның ундүрт һәм унбер яшьлек малайлары авылда үзләре генә яшәп, көн күреп яталар. «Хәзрәтнең каралты-курасы буп-буш, сыер мөгрәгән, сарык бәәлдәгән, тавык кытаклаган тавыш юк. Абзарларның каерылып ачылып калган ишекләреннән җилләр генә сызгырып тора. Терлекләрнең барысын да сәвит алып колхозга тапшырган. Әмма шушы йортта яшәп ятучы ике ятимне авыл халкы онытмый. Аталарының исән чакта игелекле хезмәте күп булды диеп, мич ашын, хәер-сәдакасын китерештереп тора. Әмма ул ярдәм белән генә җан асравы җиңел түгел шул аларга».

Юк, бу ятим балалар үзләре дә кул кушырып утырмыйлар анысы. Олырагы бер торбага зурайткыч пыяла көйләп, түсле рәсемнәрдән кино күрсәтә башлый... Аннары скрипкада уйнарга өйрәнеп авыл балаларына концерт куя... Боларның барысы да бер-ике телем ипи, бәрәңге бәрабәренә... Тамак ялына!

Әмма көннәрдән бер көнне ятимнәрнең хәле тәмам авыраеп китә, алар бөтенләй ач кала. Шунда күрше малае Хәкимҗан керә дә болай ди:

—Кичә Минһаҗ абзый бер капчык он тартып кайтты... Келәтләренә кертеп куйганын үз күзләрем белән күрдем... Онның берәр потын чәпәргә кирәк!

Бу тәкъдимне хәзрәт малае баштарак аңламый, тәшенми тора... Аннары аны умачлы аш бераз кызыктырып та ала... Ул инде менә ничә көн энесе белән бергә ач тора бит!

Ләкин шулай да хәзрәт малаеның Хәкимҗанга биргән җавабы менә мондый була:

—Ходай кушканы булыр... Телем ачылган көннән алып атам белән анам мине Аллаһыдан, кеше хакына кагылудан куркырга өйрәттеләр... юк, угрылык кыла алмыйм мин! Ул эштән соң ничек Аллаһы каршына барырмын? Авылым халкы күзенә ни йөзем белән күренермен? Атам-Анам рухы алдында ни дип җавап бирермен? Юк, Хәкимҗан, юк—йөз кат юк! Мин ул эшкә бара алмыйм!

Хикәя героеның менә шушы—көчле рух балкыган сүзләрен— укыган кеше инде шуннан соң китапка ни өчен мондый исем куелуга аптырап тормый. Әйе, бу сүзләр безнең чор кешеләре өчен дөрес яшәү юнәлеше күрсәтердәй якты маяк шикелле.

—Атам-Анам рухы... Авыл халкы... Аллаһы каршына...

Бу сүзләрдә безнең җәмгыятебез рухи нигез итеп алырга тиешле асыл мәгънә дә чагыла—якты рухлы һәм ныклы иман да. Ә инде бүген без бу юлның капма-каршысын сайлыйбыз һәм шул юлдан китәбез икән—ул чагында әйләнә-тирәдәге, җәмгыятьтәге хәзерге каршылыклар тагын да тирәнәя барачак, кеше кешегә бүре булып күренә башлаячак дигән сүз—без бүре законы буенча яши башлаячакбыз дигән сүз! Бу юл—Рәсәй инде ничә мәртәбә кичергән сыйнфый бәрелешләр, революцияләр юлы дигән сүз!

Ләкин шунысы бар: әлеге сыйнфый бәрелешләргә алып килми торган, менә бу хикәядә хәзрәт малае әйткән бердәнбер гадел юлны сайларга бүген безнең җәмгыятьнең көче житәрме, гаделлек һәм татулык хакына үз нәфесләрен, үз амбицияләрен тыя алучылар күпме бүген?

«Хәзрәт малайлары» дигән кечкенә генә күләмле бер хикәя әнә шуларның һәммәсе турында да уйлата, фикер кузгата.

Әнә шундый актуаль һәм житди эчтәлек салынган әлеге хикәядә әдәбисәнгати яктан караганда әлләни зур яңалык бар дип тә әйтеп булмый. Хәтта аның исеме астына «булган хәл» дигән сүзне язып куярга да мөмкиндер сыман. Ләкин, шулай да, бу—примитивлыкка алып килгән гадилек түгел. Бу—чын тормышның үзендәге кебек—бөеклекнең гадилектә чагылышы. Олуғ әдип һәм фикер иясе Лев Толстой бер дә юкка гына: «Килер шундый заман—әдипләр бары тик булган хәлләрне генә яза башларлар»,—дигән алтын сүзләрне әйтмәгәндер. Чынбарлыкның теләсә кайсы бөек язучыга караганда да көчлерәк, бөегрәк иҗатчы булып торуын тану дигән сүз бу!

Габдулла ага Галиев тә үз әсәрләрен язганда иң элек үзе күргән яисә ишеткән реаль вакыйгаларга таяна, чынбарлыкның Лев Толстой әйткән бөек иҗади көченә ышанып, шуна ияреп бара.

«Хәзрәт малайлары» дигән бу китапта өч повесть бар дидек. Алар

укучыга нинди эчтәлек сөйли һәм алар әдәби әсәр буларак нинди сыйфатларга ия соң?

Китапка кергән өч повестька да хас булган иң беренче билге—алар бик тә мавыктыргыч һәм тыгыз сюжетка ия. Вакыйгалар кызыклы кинодагы сыман синең күз алдыннан бер-бер артлы агыла тора һәм син алардан аерыла алмыйсың. «Сандугач» повестында безнең күз алдыннан немецларга әсир төшкән Абдулла абзыйның аянычлы язмышы үтә. Концлагерьдан ул ничә генә мәртәбә качмый, немец овчаркалары аны талап үтерә яза... Соңгы качуыннан соң аны тоталар да, үз-үзенә кабер казытып, шунда ук атарга да җыеналар.

«...ышанасыңмы, энекәш, миңа әнә шул тетрәндергеч минутта кинәт илһам килде. Башымны югары күтәрдем дә, бар көчемә сандугач булып сайрый башладым. Яшел аландагы тынлыкны ярып сайраган сандугач тавышы фашистларны бер мәлгә өнсез калдырды. Немец офицерының атарга команда бирергә күтәрелгән кулы һавада асылынып калды... Ә мин бөтен осталыгымны җигеп, өздерә-өздерә сайрадым да сайрадым. Бу минем газиз туган илем белән, сөйгәнем Гөлчирә белән хушлашуым иде. Бу минем якты кояшым белән, җиһан белән хушлашуым иде.»

Әнә шундый талантлы Абдулланы үлемнән коткара—немец офицеры бу «сандугачка» яшәү бүләк итә... Ә качуын барыбер кача ул әсирлектән. Сандугач читлектә яши аламыни соң?!

«Үкенеч» повесты исә шул ук сугыш чорында авылда ачлы-туклы яшәп ятучы яшүсмер балалар турында. Әле житмәсә ягарга утыннары да юк... Ике яшүсмернең күз ачкысыз буранда еракта урманга барып, көч-хәл белән исән кайтулары биредә тетрәндергеч кичерешләр аша тасвир ителә. Ә шулай да иң үзәккә үткәне—ачлык... ачлык... Ул явыз халыкны көн дә, төн дә газаплый, тилмертә. Әсәрнең бу битләрен укыганда күздән яшьләр килә.

Көннәрдән берсендә авылга сөенечле хәбәр кайта: күрше авылдагы сепаратордан бераз эремчек һәм әйрән бирергә тиешләр, ике ат белән шуны барып алырга кирәк!

Көтелмәгән әлеге «күчтәнәчне» алырга Зиннәт дигән абзый белән яшүсмер Рафик китә. Әмма кайткан чагында боларга ике кеше очрый, аркаларындагы биштәрдә спиртлары да бар... һәм шул чагында Рафикның юлдашы Зиннәт спиртка кызыгып, авылның ачларына дигән эремчекне бүлеп бирә... Рафик та ныклап каршы тора алмый, чөнки башта аның үзенә спиртны авыз иттерә. Ә теге явызлар... Ә авылда исә ачлыктан берәм-берәм кешеләр кырыла.

Рафикның яратып йөргән кызы да ачлыкка тилмереп, күзләрен мәңгелеккә йома... Малай йөрәгендә шулай итеп мәңгелек яра кала: ул үзен бик нык гаепле саный!

«Терсәк якын да бит...» дип исемләнгән өченче повесть та житди проблемага багышланган: анда Мансур белән Аннаның яшь чагындагы мәхәббәте һәм олыгайгач ике милләт вәкилләре арасында килеп туа торган четерекле хәлләр ышандырырлык, дулкынландырырлык итеп тасвирлана. Егерменче гасыр башындагы милли идеологыбыз Гаяз Исхакыйның шушына охшаш сюжетка корылган «Ул әле өйләнмәгән иде» дигән хикәясе бар, биредә исә без проблеманың бүгенге яшәеше белән очрашабыз: ике милләтле гаиләдә балаларга нинди исем кушу, аларны чукындыру-чукындырмау, картаеп үлгәч нинди зыяратка күмелү...

Күреп үткәнебезчә, Габдулла ага Галиев үз әсәрләрендә замана куйган сорауларның иң-иң житдиләренә мөрәҗәгать итә һәм аларга тормыш ягыннан да, сәнгатьчәлек таләпләреннән чыгып караганда да ышандырырлык җаваплар бирә. Аның фикер сөрешенә без дә ышанып барабыз.

Баштагы ике повесть унаеннан бәлки кайсыберәүләр: «һаман шул сугыш хәлләре, ачлык, ятимлек күренешләре...»—дип йөз чөерергә дә теләр. Бездә шундый артык «эстетлар»—дөнья агышына исе китмичә, бары тик кәгазьдәге хәрефне һәм җөмләне генә күрүчеләр бар бит әле. Бу унайдан андыйларга болай диясе килә:

—Ә сез илдә чын сугыш барганын онытдыгызмыни? Инде ничә ел сугыш бара бит... Ә ятимнәргә килсәк: бүгенге көндә Россиядә рәсми рәвештә билгеләнгән 3 миллион ятим бала бар икән! Ачлык белән ялангачлыкны, җинаятьчелекне инде әйткән дә юк! Болары белән адым саен очрашып торабыз.

Моннан чыгып шуны әйтәсе килә: димәк Габдулла ага Галиевнең без югарыда телгә алган әсәрләре алар нәкъ менә бүгенге мәсьәләләр, бүгенге кешеләр хакында! Аларны бары тик аңлый белергә, күңел күзен ачыбрак карый алырга кирәк.

Инде янадан хикәяләргә әйләнеп кайтсак, бу китапта алар тугыз кисәк: тугызында да, әлбәттә, авыл тормышы—кош-корт, мал-туар белән бәйле яшәеш. Ләкин, шулай да, атлар аерым урын алып тора. Биредә хәтта «Атлар да

елыйлар икән» дигән хикәя дә бар. Сугыш чоры малайлары Гали белән Рәсим илле чакрымдагы нефтебазадан авылга керәчин алып кайтырга тиешләр. Хәлсез, ябык, ач атлар белән. Җитмәсә өстән яңгыр коя—салкын, җилле яңгыр. «Ат кузгалды-кузгалуын, әмма аның атлавында һич тә рәт-чират юк, аяклары йомшак тирән кардан чаңгы тагып барган кебек сөйрәләләр иде». Бераздан Галинең аты тәмам туктап кала—аның алга барыр хәле дә юк инде. Һәм аптыраган-йөдәгән малайлар, инде бүтән ни эшләргә дә белмичә, үзләре тәртә арасына кереп басалар, көч-хәл белән кузгалып та китәләр... Ә арбада дәүдәү мичкәләр... Юл—пычрак.

Ике тәүлек буе яңгыр астында йөргән ач-ялангач әнә шул малайларны колхоз рәисе мондый сүзләр белән каршы ала:

—Нәкәнис кайттыгызмыни?! Нигә тагын берне кунмадыгыз?!

Язучы Габдулла ага Галиев тасвирлаган менә шушы күренеш озакка күз алдында кала. Ач-ялангач балалар һәм чыбыркылы явыз түрә... Андый адәм әлеге ач, хәлсез балалар хәтерендә Гитлерга караганда да әшәкерәк булып кала торгандыр инде ул! Хәер, дөнья бүлү өчен сугыш башлаган Гитлер белән Сталин үзләре дә әнә шундый адәмнәр токымыннан бит инде алар!

Ә менә язучының «Хыялый мәхәббәт» дип аталган хикәясе гади җир кешеләренең күңел байлыгы, кешелек хисләренең тирәнлеге, садәлеге, көче турында сөйли. Буе кечерәк булганга күрә сугышка алынмаган Хәмәт дигән егет урманнан кузгалаклар, юалар алып чыгып Рәсимәгә биргәч, кыз болай ди:

«—Минем өчен ниләр генә эшләмисең инде, син! Рәхмәт, Хәмәткәем! Ярый әле син бар бу дөньяда!

Бу сүзләрдән Хәмәт абыйның күзләрендә мөлаемлык тагын да арта төште, дулкынланудан бит очлары кызарды, кинәт бөтен гәүдәсе белән кызга таба тартылып куйды.»

Җылы сүзнең, кешелекле мөнәсәбәтнең тылсымлы көчен язучы әнә ни рәвешле җиткерә! Озак еллар буе авыл фельдшеры булып эшләү һәм мулла вазыйфаларын башкару дәверендә Габдулла абыйга мондый очраклар белән бик күп очрашырга туры килгәндер шул! Үзенә ярдәм сорап килгән йөзләгән, меңләгән кешегә шәфкатьле мөнәсәбәтен, җылы сүзен һәм якты йөзен кызганмаган ул. Ә менә хәзер Габдулла ага кешеләр күңелен дәвалауны әдәби әсәрләре аша дәвам итә.

Табиб һәм мулла абзыйның әдәби осталыгы ни дәрәҗәдә соң?

«...атлар әкрен генә сөйрәлә, агач очлары арасыннан кичке алсу уклар белән бизәлгән күкнең сыек зәңгәрлеге күренеп китә. Тагын кич килеп җиттемени соң әле, дигән төсле юл буендагы агачлар безне боегып кына озатып кала...»

Сугыш чоры тормышының авырлыгы, төшенке, боек көннәр, ачлык, хәлсезлек—Габдулла Галиев язган берничә юлда болар барысы да төсмерләнә, сизелә, күренә.

Менә икенче бер хикәядән өзек:

«Күккә күтәрелеп караган саен малайларның йөрәкләре кысылып куя, болай да борчылудан алҗыган күңелләренә бу болытлар ташкынының азагы юктыр, алардан җир өстенә ингән сыек караңгылык мәңгелектер, инде бервакытта да зәңгәр күк йөзе ачылмас, җирдәге тереклекне куандырып кояш та балкымас, кошлар да сайрамас кебек тоела. Кая карама—баш түбәсендә дә, аяк астында да—су. Табигатькә кушылып күз яшьләрен агыза-агыза, үксеп-үксеп елыйсы килә».


Китаптагы шушының ише җөмләләрдә әсәр геройларының эчке кичерешләре дә тирәннән һәм дулкынландыргыч итеп ачыла, шул вакытта укучы күңеленә көчле тәэсир дә ясала һәм аларда без авторның үзенең кем икәнлеген, нинди шәхес икәнлеген дә бик ачык тоемлыйбыз. Әйе, авыр чорның бөтен кыенлыгын үз җилкәсенә салган, ачлы-туклы гомер итүче сугыш чоры яшүсмерләре һәм агай-апалары авторга бик тә, бик тә якын һәм кадерле—чөнки алар арасында ул авыр елларда яшүсмер Габдулла үзе дә булган бит. Биредә сурәтләнгән вакыйгаларның бик күбесе аның үз башыннан кичкән гыйбрәтле хәлләр бит!

Галәттә дөньяны күп күргән, аның ачысын-төчесен мулдан татыган каләм ияләренең язганнары ныклы сюжетка, эзлекле вакыйгалар чылбырына корылган була. Габдулла ага Галиевнең бу китабындагы хикәя һәм повестьлар да әнә шундыйлар. Алар шуның белән нык оталар да. Ә гомумиләштереп карасак, бүген—үзенең янәшәсендә көне-төне телевидение эшләп ятканда—безнең әдәбият, бигрәк тә аның проза жанры, әсәрләрдә ныклы һәм мавыктыргыч сюжет җебе булуны төп һәм иң кирәкле таләпләрнең берсе итеп куярга тиештер, минемчә. Әнә шуннан башка безнең әсәрләр бүгенге укучының «азгын» күңелен биләп тора алмаячактыр.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

# НУРЗИЛӘ НОВЕЛЛАЛАРЫ...

Татарча да, урысча да новелла дип йөртелә торган кызыклы һәм хикмәтле жанрның инде гомере бетеп, тарих битләренә кереп югалгандыр дип уйлаган идем. Дөрес, тарихка кергән әйбер бөтенләй үк югалып бетми анысы. Заманында О. Генри, Антон Чехов, Шәриф Камал кебек мәшһүр әдипләр тирән мәгънәле, нык сюжетлы, күңелне кузгатырдай яңалык сирпеп торучы, һәм кинәт кенә, көтелмәгәнчә тәмамланучан мондый әсәрләрне байтак бүләк иткәннәр.




Исеме соңгы вакытта гына укучыларга күренә башлаган Нурзилә дигән авторның «Кашлы балдак» дип аталган яңа китабын укып чыккач, үземә күрә бер кечкенә ачыш ясагандай булдым: «Кара әле, бу новелла дигән жанр бүген дә әдәбиятыбызда яшәп ята лабаса... Автор хыялында туган гыйбрәтле һәм кызыклы хәлләр нәкъ шушы жанр кануннарына туры китереп сөйләп бирелгәннәр бит!».

«Кашлы балдак» китапчыгына урнаштырылган жиде хикәянең һәркайсында, чыннан да, новелла дигән жанрның характерлы үз билгеләре бар: ул хикәяләрнең кеп-кечкенә мәйданнарында яшәешкә, кешеләргә карата авторның үзенчә мөнәсәбәте ачыла, көтелмәгән сюжет борылышлары, яңаны һәм үзенчәлекен чын күңелдән сурәтләп һәм әйтеп бирергә омтылу теләге аларны мавыктыргыч һәм мәгънәле итә. Яшь авторның әлегә тапталмаган юл-сукмаклар эзләве дә бүгенге әдәби көнкүрешебездәге игътибарга лаеклы бер яңалык булып тоелды миңа.

Жыентыкка кертелгән хикәя-новеллалардагы вакыйгалар барысы да бүгенге чынбарлыктан, бүгенге тормыштан. Ә тормыш дигәнебез гел ал да гөл генә түгел шул. Әйләнә-тирәбездә уйландырырлык, борчылдырырлык, хәтта утыртып елатырлык хәлләр дә тулып ята. Авыр фажигаләргә юлыгучылар да, юк жирдә үзләренә тормыштан өстәмә мәшәкать-кыенлыклар уйлап табучылар да очрап тора. Менә шундыйларның берсе—гел малай гына көтеп яшәгән, киләчәген бары тик туачак улына гына бәйләп хыялланган, кызы тугач, ана әйләнеп тә карамаган ата кеше («Иң кадерлем»). Ул инде бик күптәннән әлеге гаиләсен ташлап киткән. Ә кызы Нурия инде үсеп житеп, дөньяның агын карасыннан аерырга, танырга өйрәнеп килә. Тик ул беркайчан да «Әти» дигән газиз сүзне кычкырып түгел, пышылдап та әйтә алмаган. Әмма кадерле булырга тиешле затка карата жылы тойгылары бүген дә сүнеп бетмәгән әле аның: менә-менә бер көн туар да, гафу итешү, гафу үтенү яшьләре тәгәрәр, дип көтә ул.

Дөрестән дә, язмыш дигәнебез ата белән баланың юлларын кисештерми калмый. Әти кешебез, яңа лимузинына утырып, юлдагы үсмер кызын күрмәмешкә салынып, яныннан үтеп киткәли... Әмма көннәрдән бер көнне ул, һич тә көтмәгәндә, кызны очраткач, тукталып кына калмый, ә үзенең иң кадерле әйберләренең берсен—жиңел машинасын—баласына рәсмиләштереп, бүләк итеп, тапшырып китә! Нәрсә бу? Рәхимсез бәндәләрнең каткан күңелләренә дә шәфкать орлыклары салып, үзгәртәме әллә Ходай боларны? Юк икән шул! Хикмәт менә нәрсәдә булып чыга: абзыйның кинәттән күзләре начарлана башлаган да, ана моны рәнжү төшүдән,

НУРЗИЛӘ. Кашлы балдак. Хикәяләр. Казан. «Мәгариф», 2002 ел.

дип, «әгәр иң кадерле нәрсәңне нәзер итеп бирмәсәң, бөтенләй сукыраячаксың» дип аңлатканнар, тегенең шул рәвешчә үзенә янаган афәттән котылу чарасын эзләп маташуы икән бу...

Хикәя, әнә шулай, көтелмәгәнчә—новелла таләбе кушканча—тәмамлана:

«Ялан тәпиләре белән кулдәвектә басып калган кыз, күзлеген утыргычка салып атып, күзләрен куллары белән каплады. «Йә, Аллам,—дип пышылдады ул,—хәзер миңа нишләргә соң?» Иң кадерле кешесе аны икенче тапкыр юл читендә калдырып киткән иде».

Исеме китапның тышлыгына күчкән «Кашлы балдак» хикәясенең нигезендә тагын да олырак фаҗига ята. Хикәядә сурәтләнгән Чәчкә белән Ралиф—тик бер-берсе өчен генә яратылганнар. Чәчкәнең хисләре аеруча тирән. Әмма ни үкенеч: аның өзелеп сөйгән, «Туган якларга бөтенләйгә кайтам, башкача сине калдырып китмим, мәңге бергә булырбыз» дигән Ралифенең—уңган нефтьченең—Төмән якларындагы чираттагы вахтасыннан үле гәүдәсе генә әйләнеп кайта.

Хикәя дәвамында шушы хәсрәтнең авырлыгын йөрәге аша кичерүче Чәчкәнең эчке халәте күрсәтелә. Сүз уңаенда Нурзиләнең башка хикәяләрендә дә саф, эчкерсез, нәзакәтле хатын-кыз күңелен ачарга тырышып язылган урыннарның—безнең карашыбызча, шактый уңышлы талпынышларның—еш очравын искәртеп үтик. Кайчагында автор үзе дә геройларның хисләренә бирелеп, шагыйрәгә әверелеп китә сыман:

«Тып-тып-тып... Яңаклар буйлап тәгәрәгән әллә яшь, әллә яңгыр тамчылары шунда, инде белеп тә булмый... Сулыш та ала алмый кебек иде бит, шөкер, кузгала әнә, дип куанды жил, сары яфраклы каен, толымнарын чайкалдырып һәм кайдандыр табып, кызга бер яшел яфрак сузды. Битенә «чәп» итеп яфрак кунгач кына, Чәчкә калтыранып куйды, гүя моңарчы жилне тоймаган да иде ул».

Ралифнең ялгыз калган әнисе дә, сөйгәне Чәчкә дә зур кайгыны күтәрә алмыйлар—бичара ананың акылына зәгыйфьлек килеп, «сары йорт»ка эләгә, ә Чәчкәнең аяк-куллары йөрмәс була, дәваланыр өчен акчасы калмагач, ул сөйгәне истәлеге итеп саклаган балдакларны да сатарга уйлый—тик тукталып кала.

Менә шушы—аяныч нәтиҗәләре өзми-түкми сөйләп бирелгән фаҗигане дә Нурзилә чын энҗегә—матур новеллага әйләндерә алган. Ралиф кулларының жылысын саклаган балдаклар Чәчкә кулында кала, югалган сөйгәненең жиде ел буена төшендә генә булса да күрергә хыялланып, ул, ниһаять, шушы кечкенә теләгенә ирешә:

«Кинәт кыз яңгыр аша үзен чакырып кул изәгән Ралифен күрде. Бер кочак ап-ак розалар күтәргән сөеклесе елмая, тик никтер дәшми. Китмә, көт мине, мин хәзер!» дип кычкырырга теләсә дә, Чәчкәнең тавышы чыкмады...»

Хикәянең ахырында ярдәмчесез, терәксез калган Чәчкә янында автор кодрәте белән җанландырылган Жил сурәте генә торып кала. Бу образның фантазия жимеше генә икәнлеген анык белсәм дә, кызның шушы халәте сурәтләнгән мәлдә ул миңа һич тә ясалма булып тоелмады:

«Ник һаман уянмый соң, нигә шулкадәр авыр сулый, тәне ут яна бит, дип борчылды үзе, кыз аша үтәли исеп. Бары кич авышкач кына килеп кергән күршесе Чәчкәне авыр хәлдә табачагын да, үпкәсе шешеп, реанимациядә берничә көн яткач, тәмам хәлсезләнгән тәнен калдырып, жанының Ралифе янына китәчәген дә, пар балдакларны йомарлап күкрәгенә кыскан сул учын күмгәндә дә ачтыра алмаячакларын белми иде әле көзге жил».

Әнә шул рәвешчә, табигатьнең без аңларлык яки без белеп үк житкермәслек яклары да Нурзилә әсәрләрендәге геройларның язмышларына орына. Мондый хәлләр күңелләре китекләргә, язмыш тарафыннан биртелгән-рәнжетелгәннәргә ачыграк аңлашыла. Тормыш-көнкүрештә дә сөйкемле, рухи яктан бай, нечкә күңелле гүзәл затларның бәхетсезлекләре күзгә тизрәк ташланучан икәнлеге һәркайсыбызга яхшы мәгълүм бит.

«Биюче» исемле хикәядәге нәни героиня беренче күренүендә үк сокландыра:

«Аллы-гөлле утлар жемелдәшеп, дәртле шәрык көе яңгырый башлауга, сәхнәдә нәни биюче пәйда булды. Гүяки, залны яктыртып, ут шарчыгы тәгәрәп китте: бөтерчектәй әйләнгән кызчыкның болыт сыман кабарынкы алтынсу-сары чәчләре көзгедә чагылган кояш нурлары шикелле сибелделәр... «Алтынчәч! Сөякләре дә юктыр ахры бу балакайның»,—диештеләр биючене танып алган халык һәм көй тактына туры китереп, гөр килеп алкышлый да башлады».

Әсәрдәге вакыйгалардан аңлашылганча, бу бала ике яшендә ятим калып,

искиткеч ягымлы, шәфкатьле кешеләр— Зөһрә һәм Заһир янына сыенган, шулар-да тәрбияләнгән. Ә үз әнисе Ленаны елга буенда коры яшен сугып үтергән икән... Бала ялгыз йөрми дигәндәй, биюгә һәвәсләнгән кызчыкка да кинәт-тән чир зәхмәте тиеп, аяктан ега, һәм инде әнисе булып тоелган Зөһрә ханым-ны да хәсрәткә сала.

Инде хәле өметсезләнә барган бала янына ашыгыч ярдәм чакырталар. Сәер-рәк көн була бу. Алтынчәчнең әнисе Лена һәлакәткә юлыккан чактагы кебек коры җил-давыл чыга. Бөтен кварталда утлар сүнеп, телефоннар да эшләми башлый. «Ашыгыч ярдәм» дигәнебез дә килергә ашыкмый... Ниһаять, бусаганы атлап, өйгә ак башлыклы, ак халатлы хатын килеп керә. Ул арада өйдәгеләр аның бала имезеп утырганын күрәләр. Озакламый хатын «бала савыгыр, башкача авырмас» дип, Зөһрә белән Заһирны куандырып, иплән кенә саубуллашып, чыгып та китә.

«...Күзләрне чагылдырып, гөлт итеп ут кабынгач, Зөһрә аңына килгән-дәй булды, күзе иренә төште. Заһир: «Лена... Лена иде бит ул»—дип пышыл-дады. Инде икәүләп телсез калдылар.

Бераз аңга килүгә, тиз-тиз кунак бүлмәсенә йөгерделәр. Кызлары тыныч кына көлемсерәп, диванда йоклап ята. Баланың йөзе алсу, сулышы тигез, ә өлгергән чия шикелле иреннендә ахактай сөт тамчысы җемелдн иде».

Әлеге җыентыкка сүз башын язган тәҗрибәле әдип Фәнис Яруллин Нурзилә хикәяләрендәге мондый күренешләрне бик дөрес бәяли:

«Бер уйлаганда бу—мистика кебек. Ләкин әдәбият нәкъ менә адәм ышан-мастай хәлләрне ышандырырлык итеп укучыга сурәтләп бирүе белән чынбар-лыктан аерылып тора да инде. Өлкәнрәк әдипләр «социалистик реализм»га ябы-шып яткан арада, икенче төрле формалар, стильләр эзләүче һәм шушындый мисти-каларның әдәбият өчен шактый отышлы икәнлеген раслаучы яшь иҗатчылар барлыкка килгән икән».

Чынбарлыкта адәм баласы өстенә ишелеп-ишелеп ябырылган фаҗигаләр шаукымы Нурзилә җыентыгындагы хикәя-новеллаларга да тәэсир итмичә калмаган. «Күзләреңдә синең җәй төсе» әсәрендә юл фаҗигасе Азаматның сөекле хатыны Алсуның гомерен өзә. Коточкыч һәлакәттә сабыйлары Ләйлә ничектер исән кала. Бераздан үзенә яңа әни дә табыла тагын. Очраклы танышу Азамат белән Рәзиләне бәхетле итә. Әлегә аны-моны белештермәгән баланың киләчәге дә караңгы булмаска ошый:

«Күпме шулай сүзсез карашып торган булырлар иде, көтелмәгән бер мизгел барысын да хәл итте: кызчык нәни көмеш кыңгырау сыман чылтерәп көлеп җибәрде һәм «Әнием!» дип кулларын сузып, Рәзиләгә таба йөгерде».

Кайбер хикәяләрдә әнә шулай югалтулар ачысы киләчәккә карата якты өмет хыяллары белән дә юыла. Әйе, кеше алдагы гомереннән матурлыгын, шатлыгын тоя алса гына бәхетле була. Яшь прозаикның фаҗигале хикәяләрендә әнә шуна өмет чаткылары да бар. Китап укучыларга бүген монысы да бик кирәк.

Без карап үткәннәре—Нурзиләнең беренче китабына кергән хикәяләрнең иң уңышлылары. Күргәнебезчә, аларда авторның тормышка үзенчә каравы, әдәбиятта йөз тоткан принциплары шактый ачык күренә. «Әни димим», «Һаваларда оча ике аккош», «Мина ул кирәк» исемле башка хикәяләреннән дә укучы үзенә гыйбрәт алырдай, күңеленә хуш килердәй күренешләр, яңәшәлекләр табар. Шулай да боларында шактый ук мәгълүм хакыйкатьләрне кабатлаган, фикерне образларга тиешенчә төреп җиткермәгән урыннар да күренгәләп ала.

Кем әйтмешли, болар берсе дә төзәтә алмаслык гаеп тә, хата да түгел. Бүген татар шигъриятенә генә түгел, прозасына да яңа сулыш өрүче гүзәл затларның—ханым-туташларның килүе күңелне куандыра. Шуларның берсе—Нурзилә сайлаган юл аеруча өметле тоела. Ана уңышлар телик!

**Рифат СВЕРИГИН**

# НУР АГАНЫҢ НУРЛЫ ЭШЛӘРЕ

НУР ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНГА—75 ЯШЬ

Әдәбият фәненә беренче адымнарын Нур ага 1949 елда ясый. Казан дәүләт педагогия институтын бары тик «яхшы» билгеләренә генә тәмамлаган яшь егет үзенең белемен тагын да үстерү нияте белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасына укырга керә. Булачак диссертациясенә «Кави Нәҗминең прозасы» дигән гыйльми теманы билгелиләр. Ул тиз арада үзен тырыш, карусыз һәм эшенә бик җитди карый торган аспирант буларак таныта. Дөрестән дә, максатчан эшчәнлек үзенең нәтиҗәсен озак көттерми: билгеләнгән вакытта диссертация тәмамлана һәм уңышлы яклана. 1953 елның февралендә Нур агага «филология фәннәре кандидаты» дигән гыйльми дәрәҗә бирелә.



К. Нәҗминең тормыш юлын һәм иҗади эшчәнлеген өйрәнүне галим алга таба да үзенең мөкатдәс бурычларыннан берсе итеп билгели. Ул 1956 елда «Кави Нәҗми: Тәнкыйть-биографик очерк» дип аталган китап бастырып чыгара. Әлеге хезмәт бер елдан соң рус телендә дә нәшер ителә. Язучының әдәби мирасын барлау-туплау юнәлешендә нәтиҗәле эзләнүләр алып барып, аның хатыны язучы һәм тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова белән берлектә 1958—1960 елларда алар әдипнең дүрт томлык «Әсәрләр» тупланмасын нәшер итәләр.

Әлеге юнәлештә эшне дәвам иттереп, Нур ага язучының әдәби-публицистик мәкаләләрен туплап, 1976 елда «Әдәбият дөньясында» дип аталган китап бастырып чыгара. 1981—1984 елларда Кави Нәҗминең улы Тансык Нәҗметдинов белән бергә төзелгән «Әсәрләр»нең дүрт томлык җыелмасы кабат дөнья күрә.

Ә 1958 елда, совет чорында беренче буларак, Нур ага дүрт йөз илле терминны үз эченә алган «Әдәбият белеме» сүзлеге төзеп чыгара.

Институт хезмәткәрләре 1960 елда «Татар совет әдәбияты тарихы. Очерклар» дип исемләнгән күмәк хезмәт әзерләп нәшер итәләр. Андагы «Бөек Ватан сугышы елларында татар совет әдәбияты» (кереш), «Проза» (Бөек Ватан сугышы еллары), «Сугыштан соңгы татар әдәбияты» (кереш), «Проза» (сугыштан соңгы еллар), «Кави Нәҗми» дигән бүлекләр Нур ага тарафыннан язылган.

Әлеге коллектив, татар әдәбияты белән киң даирә укучыларны таныштыру максатыннан, 1965 елда Мәскәүдәге «Фән» нәшриятында «История татарской советской литературы» дип аталган китап бастырып чыгара. Бу басмада Нур ага 1941—1945, 1945—1960 еллардагы чәчмә әсәрләргә багышланган язмалары белән катнаша.

Узган гасырның 70 елларында СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты илдәге төрле халыкларның әдәбияты турында «История советской многонациональной литературы» исемле алты томлыкны укучыларга ирештерде. Аның икенче һәм дүртенче томнарын-

дагы (1971, 1974) «Татарская литература», «Проза татарская» бүлекләренең авторы Нур ага булды.

1984—2001 еллар аралыгында Институт тарафыннан беренче тапкыр әзерләнгән «Татар әдәбияты тарихы»ның күптомлы академик басмасы тулысынча нәшер ителде. Зур көч таләп иткән әлеге коллектив хезмәтнең барлыкка килүендә Нур аганың да ихтирамга лаеклы өлеше бар. Галим алты томның да Баш редколлегия әгъзасы булды. Дүртенче томдагы (1989) гражданнар сугышы чоры, егерменче-утызынчы еллардагы әдәби хәрәкәт, татар әдәбияты белеме һәм тәнкыйтенең беренче буын вәкилләре Габдрахман Сәгъди, Галимҗан Нигъмәти турындагы бүлекләр аның тарафыннан язылды. Ә менә Бөек Ватан сугышы чоры һәм аннан соңгы еллар (1941—1960) әдәбиятына багышланган бишенче том исә тулысынча Нур ага җаваплылыгында башкарылды. Китапның кереш мәкаләсе һәм, 1941—1960 еллардагы әдәби хәрәкәт, проза, әдәбият белеме һәм тәнкыйть турындагы әтрафлы очерклар, Кави Нәҗминең иҗади портреты, йомгак, әдәби вакыйгалар хроникасы һәм исемнәр күрсәткече барысы да Нур ага каләме белән язылган.

Нур ага—таләпчән мөхәррир дә. Бу хакта сүз алып барып, редколлегиядә ул катнашкан байтак хезмәтләр турында язарга мөмкин. Әмма игътибарны аларның кайберләренә юнәлтү белән генә чикләнәбез: «Татар теле һәм әдәбияты» (1968), «Герой, стиль, осталык. Татар совет әдәбиятының кайбер мәсьәләләре» (1972), «Әдәбият баскычлары. Татар совет әдәбияты елъязмасы» (1917—1973), (1976), рус телендәге «Взаимодействие культур народов Поволжья и Приуралья» (1977), Г. Ибраһимовның тууына 90 ел тулу уңае белән үткәрелгән фәнни конференция материаллары «Писатель, революционер, ученый» (1980), «Урта гасыр әдәбияты тарихыннан» (1981).

Нур ага танылган әдәбиятчы гына түгел, ә үткен каләмле тәнкыйтьче дә. Әлеге өлкәгә ул аспирантурада укыган елларында ук килә һәм Гази Кашшаф, Гали Халит, Хәсән Хәйри һ. б. өлкән буын тәнкыйтьчеләр сафын тулыландыручыларның берсе була. Ибраһим Нуруллин «Каләмдәшем турында» дигән язмасында шул вакытларны менә ничек искә ала: «Бәхәсләшәбез, кычкырышып та алабыз. Тик шунысы бар: алга карап яшәгәнгәме, әдәбият мәнфәгатен бар нәрсәдән өстен куйгангамы, бер-беребезне өнәмәү, күпсенү, үчләшү кебек нәрсәләр юк иде» *(«Казан утлары».—1978.—№ 6.)*.

Татар әдәбияты гыйлеменең концептуаль проблемалары турында Нур ага бик күп мәкаләләр бастырды. Ә 1988 елда аның әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган «Әдәбият һәм тормыш» дигән китабы да дөнья күрде.

Нур ага—«Казан утлары» журналы белән дә тыгыз элемтәдә торып, актив хезмәттәшлек иткән галимнәрнең берсе. Журналның 900 нче саны дөнья күрү уңаеннан язган мәкаләсен дә ул «Казан утлары»ның беренче саныннан хәзерге вакытка кадәр үткән данлы юлы, аеруча аның сугыш чорында кичергән авырлыклары, әмма ул вакытта да чыгудан туктамавы һәм башка кызыклы күренешләр турында әтрафлы язып чыкты.

Нур ага—бик тә оптимист кеше. Хәзер дә институтка килгән вакытларында: «Ягез егетләр, сезне бераз ял иттереп алыйм әле!»—дип, үткәндәге үзе яхшы белгән кызыклы һәм гыйбрәтле хәл-вакыйгаларны зур тәгәллегендә, хәтта кайвакыт елы белән генә түгел, көне белән дә искә төшереп сөйләп, күңелләрне күтәреп җибәрә... Ә аның безгә—яшьләргә—сөйләрдәй хатирәләре күп... Чөнки институтта ярты гасыр эшләү дәверендә галимебез нинди генә шәхесләрне күрмәгән дә, кем белән генә аралашмаган!

Татар әдәбияты гыйлемендә үзенең лаеклы урынын алган мөхтәрәм юбилярыбызны мөбарәк бәйрәме белән ихластан тәбрикләп, аңа ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете, иҗади уңышлар телибез!

**Рәмил ИСЛАМОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

*Xatirə*

## Mirqasim Ğosmanov

### Qartlar həm... qızlar

«Qartlar süzendə xikmət bar» dilər. Bu xəkemnen dəreslege kətelməgən misallar belən də raslana ikən. Şunı raslıy torğan keçkenə genə, məgər ğibrətle istələklərem də bar minem.

«Ayaqlar da kürenməgəç...»

1996 yılnıņ kəzendə İrannan qaytqan ğına kənnərem ide. Taceddin Bolğarinıņ «Ət-Tiryaq əl-kəbir» isemle əsərennən küçermələr alıp qaytqan səfərdən soņ, Ğ. Kamal teatrınıņ direktorı Şamil Zakirov şıltırattı: «Monda ber kiņəşmə bula, kilsəgez ide. Əmirxan ağa Yenikigə maşina cibərəbez. Uramğa çığıp torsağız, sezne də ala kiler ide». Maşinağa kerep utırğaç, xəl-əxwəl soraşqaç, Əmirxan ağa sorap quydı:

—Əle genə İrannan qaytqansıņ dip işettem. Yə, nərsələr kürdeņ anda?

Min qaylarda buluıbız, nilər eşləwebez xaqında səyli başladım. Ul ğədətençə «şulay ikən» dip, tıņlap qına utırdı. Teatrğa citkəç, üzək işekkə taba basqıçtan menər aldınnan, Əmirxan ağa tuqtap, tağın ber soraw birde:

—Anda xatın-qızlar yaņadan pərəncə yapqan dilər, dəresme şul?

—Əye,—didem.—Pərəncə belən yərüçelər küp, ğəmumən xatın-qızlarnıņ baş-küzen də, ayaq-qulın da yaxşı uq qaplaw kiņ taralğan anda. Kübrək qara cilən yabınıp yərilər. Barı zur borınnarı belən ayaqlarınıņ başmaqlı təpilere genə kürenə. Qara qarğalar kebek...

—Şul xətle ükme?—dide ğəcəplənüdən basqıçnıņ urta təşendə tuqtap qalğan Əmirxan ağa.

—Əye,—didem,—cilən itəkləre cirgə qədər ük təşkən bulır...

Ul küzləremə turı qaradı, annarı küņelsez genə qulın seltəp:

—Xatın-qıznıņ ayaqları da kürenməgəç, ul İranda küņelle tügel ikən...—dip, əkren genə basqıçtan menep kitte.

Yəşe 85 tən uzıp kitkən olı keşeneņ süzlərə altmışqa citkən Xəsən Tufannıņ «Tənəkə» isemle məşhür şiğerendəge qayçandır üzemne nıq uylandırğan ber serle, xikmətle yulların iskə təşerergə, alarnıņ tirən məğnələre xaqında tağın da qat-qat uylanırğa məcbür itte:

Min tügel,
Suqmaqlar kətələr
Şiğerneņ canlısı kilgənne...
Yalanğaç ayaqqa—tatarça
Çigelgən başmaqlar kigənne...

## «Abındıra şul...»

1961 yılnıŋ sentəbr ayı ide. Student çağım. Kitapxanədən çığıp, Lenin baqçası arqılı tramvay tuqtalışına taba kittem. Lobaçevskiy baqçası yanında Nəqi ağa İsənbət oçradı. Qulında sarğıltraq təstəge zur ğına kün portfel'. İsənləşep, qaya barasımnı belgəç (fatirım xəzerge «Aqçarlaq» tirəsendəge ber yortta ide), ul:

—Əydə, kən bik matur bügen, teləsəŋ, parkka qədər cəyəw barıyq,— dide.

Bik teləp kileştem, əlbəttə. Berniçə mərtəbə bezgə, studentlarnıŋ ğilmi tügərəge utırışlarına kilgən, şunda tanışqan, tatar məqəlləre cıyılmasınıŋ berençe tomı belən huşlarıbıznı alğan, uzğan yılnı ğına altmış yəşlek yubileyen universitetta da uzdırğan oluğ ədipkə iərep baruıŋ üze genə ni tora!

Barabız şulay əkren genə səyləşep. Nəqi ağanı studentlarnıŋ ictimaği aŋlılıq dərəcəse, fən belən şəğellənü-şəğellənməwləre qızıqsındıra ide. Üzeneŋ yeget çağındağı yəşlərneŋ ictimaği aktivlığın da iskə təşerde. Min qayçandır təzi başlağan həm küptən tügel anıŋ üzenə birgən qulyazma cıyıntıq kisəgendəge qayber məqəllərneŋ ikençe tomğa alınuın da əytte. Gor'kiy uramında radiokomitet turısınnan uzıp, uŋ yaqtağı baqçağa citərək, minem küz qarşı yaqtan kilüçe bik çibər ber xatın-qızğa təşte. Təs qiəfəteneŋ iskitərlek güzəllegenə soqlanıp, şul qədər aŋar təbəlep qarağan bulğanmın, ayağım nərsəgəder tərtelep, abınıp, yığılıp ta kitə yazğanmın. Çibər xanım uzıp kitkəç, Nəqi ağanıŋ soŋğı süzləren işetmi qaluımnı əytkən idem.

—Hım...—dide ul mıyıq astınnan ğına yılmayıp.—Ber uylap aldım digen, ə... Çibər xatın-qız şulay ul, abındıra əylənməgən yegetlərne, çuqraq ta itə...

Əç-dürt adım barğaç, uyçan ğına əstəp quydı:

—Xəyer, əyləngənnəren də...

Nəqi ağanıŋ əllə niçek sağış belənrək əytelgən bu süzlərendə üzeneŋ şul yıllarda yazılğan ber şiğereneŋ yəşeren moŋı da yaŋğırap kitkən sıman buldı:

Əy, yəşlegem, yəşlegem,  
Yəşlegem—güzəllegem,  
Aqılım birep alır idem,  
Ber genə cülərlegen!

Qaytarıp bulmıy ikən şul andıy yəşlekkə genə xas mizgellərne...

## «Tabiğətneŋ sənğət əsəre...»

Citmeşençe yıllarnıŋ axırı ide buğay, təgəl xəterləmim xəzer. Şulay da bezneŋ tarix-filologiə fakultetınıŋ ximik korpusta «əydəşlektə» yəşəp-eşləp yatqan çorı ide əle.

May ayınıŋ ğəcəp yaqıtı, matur, xatın-qızlarnıŋ isə, Taqtaş əytmeşli, «çişenə başlıy» torğan cılı, nurlı kənnərenəŋ berse ide. Üzək poçtağa barırğa dip, Lenin uramına borılğan cirdə, Baqi ağa Urmançığa oçradım. Qulında tayaq, əstendə makentoş pəltəme, əllə plaşmı, hərxəldə, cılıraq ozın kiem ide. Anıŋ belən oçraşqalap, əŋgəmələşep yərgən, aradan əle «qara məçe» uzmağan çaq. Ul Kreml' yağına bara ikən. Səyləşə-səyləşə biş ayaqta, dəresrəge dürt ayaq həm ber tayaqta yənəşə atladıq. Poçmaqtan altmış-citmeş adım da kitep əlgermədek, qarşığa kilüçe ber yəşüsmer qız balağa küzebez təşte. Unbiş-unaltı yəşlərdə bulır. İğtibarnı anıŋ surət kebek tabiği çibərlege—qoyıp quyğanday nəfis buy-sını, neçkə bile, cəyge fasılğa xas matur itep tegelgən yəşlərçə ciŋel kiem-salımı cəlep itte. Küperep iŋnərenə qədər təşkən, yəzeneŋ aqlığına nur əstəgəndəy bulıp

torğan çem-qara çəçləren külməgenen, tuflilarının təsenə turı kiterep qızıl bant ta bizəgən.

Yəşlegen, saf güzəllegen şul rəweşçə kiem-salımı da zinnətləp, kürkəmlətep cibərgən qız bala waq-waq atlap, yanıbızdan uzıp kitügə, ikebez də, ber komanda alğan təsle, artqa borıldıq. Min—yartılaş qına, Baqi ağa isə, qartlarğa xas rəweştə, bəten gəwdəse, ayaqları, tayağı belən də bergə borılıp, ber uçın manğayına quyıp qarap qaldı.

—Ya Alla,—dide ul pışıldap qına,—birsə də birə ikən ber keşegə!..

Bu qiəfəttən, bu soqlanudan min ireksez yılmayıp cibərdem. Tayağına qarap alğaç, awızım cülərlərçə ük yırıldı buğay. Minem bu qiəfətem ana oşamadı:

—Nik ırjaydın?!—dide ul şeltəle ton belən.—Sin üzençə qaradın, ə min tabiğətnen sənğət əsərenə soqlandım!..—Annarı tağın qabatlap quydı:— Bulsa da bula ikən, ya Alla!..

Monarçı da, Baqi ağanın əyendə oçraşqan çaqta, ul yış qına üzenen in yaratqan şağire Dərdməndne yattan uqıy ide. Cəmlədən:

Tənkəyen—aq, tüşkəyləren kin yaratqan,
Bitkəyenen in oçında min yaratqan;
Saqlar əçen zifa buyın yaman küzdən,
Çəçkəylərən ayaq belən tin yaratqan!..

Şul yıllarda məşhür robağıydağı bu güzəllekne ul üzenen ber rəsemendə də gəwdələndergən ide...

* * *

Bu iskə təşkən (bəlki onıtılmıy torğan) bələkəy genə waqiğalardan son küp kenə yıllar uzğaç, üzem də olığayıp, qartlar «kətüenə» kertelep, dənyağa başqaçaraq küz belən qarıy başlağaç, qayçandır qızıqlı, kəlkele bulıp toyılğan əlege süzlərnen, xəkemnərnen məğnələren beraz anlıy başlağan təsle buldım. Qızıqlı ğına tügel, ğəcəyep xikmətkə də iə bulğan ikən ul ğibrətle süzlər.

*2003 yıl.*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*“Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы” шигаренең рәсми девиз булып яңгыраган чорлары. Рәсемдә: сулдан уңга—латыш Вилис Лацис, татар Кави Нәҗми, кыргыз Аалы Токомбаев, рус Александр Фадеев. Үткән гасырның 50 еллары.*



*1975 елның 8 нче маенда Печищи авылында (Югары Ослан районы) белорус халык шагыйре Янка Купала истәлегенә музей-йорт ачыла. Әнә шул музейны ачу тантанасында безнең язучылар да актив катнаша. Рәсемдә Гариф Ахунов, Фаил Шәфигуллин, Ренат Харис, Зөлфәт, Әхсән Баянов, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Вакыйф Нуруллин, Җәүдәт Дәрзаманов һ. б. күрергә мөмкин.*



*Язучылар Мәхмүт Хәсәнов, Габдрахман Минский Татарстан Язучыларының VI съездында. 1965 ел.*



*1982 елда СССР Верховный Советы Указы белән "Казан утлары" журналы "Почет билгесе" ордены белән бүләкләнә. Орденны редакция коллективына Татарстан Министрлар Советы Председателе урынбасары Мансур Хәсәнов тапшыра. Бу рәсем әнә шул көннең истәлеге. Сулдан уңга—Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ, Рәшит Әхмәтҗанов, Фәүзия Бәйрәмова, Әмирхан Еники, Ринат Мөхәммәдиев, Фарваз Миңнуллин, Сәмига Сәүбанова, Мансур Вәлиев, Мансур Хәсәнов, Роза Сөләйманова, Зәки Нури (журналның ул вакыттагы баш редакторы), Роберт Миңнуллин, Солтан Шәмси, Гөлшат Салихҗанова, Рәзифә Вафина.*

*Юмор-сатира*

# Ләбиб Лерон

## Аулак почмак

*Ни өчендер мин гомерем буе*
*Аулак почмакларны яраттым...*

Гәрәй Рәхим

Аулак почмакларны гел яраттым—
Балачактан бирле, мөгаен:
Төрле шуклык өчен почмакларга
Еш бастырды әти малаен!

Борыннардан төтен чыгарырга
Мин шул почмакларда өйрәндем.
Үзем белән үзем көн дә уйнап,
Кәрт сугуның бирдем кирәген!

Аулак почмакларда башта аз-маз,
Аннан күпләп тамак чылаттым...
Караңгыда ялгыш кармаланып,
Күпме кызны шактый елаттым.

Аулак почмакларда сөйгән ярлар
Кайсы малай, кайсы кыз тапты...
Берсе хәтта негр малай тапкач,
Үз-үземә үзем шаккаттым!

Аулак почмакларны яратуым
Арта гына барды отыры...
Шунда яшәп, шунда ашап-эчеп,
Шигырь-фәлән яздым котырып.

Әле менә китабымны укып,
Утырганда аулак почмакта,
Бер хөрәсән малай килеп чыгып,
Төртеп егып китте... пычракка.

## Лимит

*Мал-данга да исем китми*
*хәтта—яшь тәнгә...*

Равил Фәйзуллин

Язасын яздым шикелле,
Сыздым—сызасын...
Алтмыш яшькә—кырык китап!—
Каләм чыдасын.

Аласын алдым шикелле,
Күрдем—күрәсен...
Укып ятар чагым хәзер
Коръән сүрәсен.

Әйе, диндар карт булып бер
Сәҗдә китәр чак.
Кылган гөнаһларны уйлап,
Тәүбә итәр чак.

Ләкин юк шул... Килми һаман
Диндар картлыгым—
Шагыйрьлегем комачаулый,
Шайтан алгыры!

«Шигырь язмыйм»,—дигән идем,
Яздым бүген дә...
Язгач—яңа уйлар килә
Азгын күңелгә.

Кызыктыра яңа даннар,
Бүләк-санагы...
Ничек түзмәк—алган чакта
Җыен салага!

Картаерга иртә әле
Миндәй шагыйрьгә...
Тагын давай—мал-дан... яшь тән...
Миндәй шәп иргә!

Чү! Чабудан кем ул тарта—
Көнләшә миннән?
Орчык кадәр улым Газиз
Эндәшә икән...

—Шалишь, әти!—диеп әйтте
Улым—өметем.
—Чират миндә, синең инде
Бетте лимитың...

## Сандугачлар, күгәрченнәр һәм шагыйрь

*..Минем күңелгә һаман да*
*Сандугачлар оялый.*

Роберт Миннуллин

Минем шагыйрь икәнемне
Сандугачлар беләләр:
—Синең күңел иркен!—диеп
Очалар да киләләр.

Киләләр дә оялыйлар,
Чут-чут итеп сайрыйлар...
—Безнең хакта яз син!—диеп
Миннән шигырь даулыйлар.

Язсаң, һич тә ошатмыйлар:
—Пүчтәк булган бу!—диләр.—
Эштер-өштер язганыңның
Яртысы гел су!—диләр.

—Фәлән шагыйрьдән дә начар
Язгансың син,—диярләр.
Премия ала-ала,
Азгансың син!—диярләр.

Урынсыз тәнкыйть итүгә
Ничек инде түзәсең?!—
Боларны куып җибәреп,
Алып кайттым күгәрчен!

Тора-бара күңелемдә
Күгәрченнәр арттылар:
Күңелдәге өй кыегын,
Күрәсең, ошаттылар!

Күгәрчен—сандугач түгел...
Алар мактый беләләр:
—Синнән дә шәп шагыйрь юк!—дип
Гөлдер-гөлдер киләләр.

Андый чакта мин үземне
Бөек итеп тоямын...
...Алар мактый, ә мин көн дә
Тизәкләрен җыямын.

## Пәрәвез

*Пәрәвезләр җебе буйлап*
*мин сине эзләп киләм...*

Акъегет.

Син—үрмәкүч,
мин—үрмәкүч,
бөҗәкләр икебез дә:
Пәрәвезләр җебе буйлап
сәяхәт итик без дә!

Син барасың,
мин дә барам—
икәүләшеп барабыз...
Чыдам җептән үргән идем,
шәпме минем пәрәвез?!

Минем кайда үргәнемә
игътибар ит син тагы:
шигырь китабы булыр бу—
Акъегетнең китабы!

Күрәсеңме бер чебенне:
ята кәңкәйгән килеш...
Шигырь сөюче чебен бу—
Мәнле булырга тиеш!

Сизәсеңме, монда рәхәт—
Беркем сине борчымый:
Бүтән мондый шәп урын юк,
Җанкисәгем, бел шуны!

## *Берлекнең яңа әгъзалары*

### Равил Фәхретдинов



*Равил Габдрахман улы Фәхретдинов 1937 елның 14 мартында Татарстанның Балтач районы Кариле авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Әмма бөтен балачак, үсмер һәм яшь егет еллары әти-әнисенең, әби-бабаларының төп, нигез йорты булган Балтач авылында—район үзәгендә үтә, шунда урта мәктәпне тәмамлый. 1958-1963 елларда Равил Казан дәүләт педагогия институтында укый, биш ел буена группа старостасы, башта факультет (тарих-филология), аннан соң институтның татар хорын оештыручы, аның җитәкчесе була; II курста—Тукай, III-V курсларда—Ленин стипендиаты. Һәр елның җәендә Татарстан археологик экспедициясенең отряд җитәкчесе буларак, республиканың күп төбәкләрен йөреп чыга, йөзләрчә яңа истәлекләр табып өйрәнә, шулар хакында студентларның фәнни түгәрәгендә, Бөтенсоюз археологик конференцияләрендә еш кына докладлар белән чыгышлар ясый.*

*Педагогия институтының татар теле, әдәбияты һәм тарих бүлеген кызыл диплом белән тәмамлагач, Равил Фәхретдинов 1963 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы—Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына археология буенча аспирантурага укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлап, шул институтта төрле елларда (1966-1996) кече, өлкән һәм төп гыйльми хезмәткәр булып эшли; Мәскәү дәүләт университетында археология буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклый.*

*Равил Фәхретдинов—Татарстан, Идел буе, гомумән, Урта Евразия җирлегенең, бөтен татар халкының урта гасырлар археологиясе һәм тарихы буенча танылган белгеч, ул—270 тән артык басма хезмәт авторы, шул исәптән 30 китап: фәнни монографияләр, фәнни-популяр китаплар, мәктәпләр, гимназия һәм лицейлар өчен «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» исемле дәреслек, уку әсбаплары, күрсәтмә әсбаплар (Атлас), фотоальбом һ. б. Равил әфәнде Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының, шулай ук Алтын Урда төньяк улусы археологик истәлекләренең тулы җыелмасын һәм картасын төзеп, басып чыгарды һәм бу ифрат кыйммәтле, бай академик басма фәндә беренче тапкыр эшләде. Бу Җыелма (Свод) ике меңгә якын истәлекне үз эченә алса, аның яртысын диярлек автор үзе дистә ярым ел эчендә Татарстанның, күрше өлкә-республикаларның җирләрен җәяү йөреп эзләде, тапты, фәнни өйрәнде. «Свод»ка кергән истәлекләр аннан соң төзелеп «Татарстан АССРның археологик картасы» өчен төп нигез булды. Бүгенге көндә ул институтның планына кертелгән бөтентатар халкының VI-XX йөзләргә караган тарихи-мәдәни мирасының академик Корпусын төзү белән мәшгуль.*

*Равил Фәхретдинов халкыбыз тарихын җентекләп тикшереп фәнни басмаларда дөньяга чыгаручы күренекле галим генә түгел, ул әле 1920—30 елларда Газиз Гобәйдуллиннар, Гали Рәхимнәр башлап җибәргән, әмма Сталин репрессияләреннән соң тукталып торган, милләтебез өчен бик тә кирәкле фәнни-популяр китаплар язуны, фәнни публицистиканы яңадан аякка бастырды, гамәлгә кертте. Археология-тарих, җыр һәм гамәли сәнгать турында матур әдәби тел белән язылган «Җырчы» (Илһам Шакиров турында, 1973 ел), «Ташлар моңы» (беренче тапкыр 1978 елда чыга, соңрак тулыландырылган басмалары татар һәм рус телләрендә берничә кат басыла), «Мондадыр безнең бабайлар» (1992), «Кичке азан» (1997) китаплары әнә шуны раслый.*

*Бүгенге көндә Равил Фәхретдинов Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты баш гыйльми хезмәткәре, тарих фәннәре*

*докторы, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге лауреаты. ТРның атказанган фән эшлеклесе, «Татар археологиясе» журналының баш мөхәррире.*

*2003 елның 30 апрелендә, кабул итү Коллегиясе карары нигезендә, Идарә әгъзалары бер тавыштан Фәхретдинов Равил Габдрахман улын Татарстан Язучылар берлегенә кабул иттеләр.*

## Рәзинә Мөхиярова (Мөхияр)



*Мөхиярова Рәзинә Хайбрахман кызы 1956 елның 26 маенда Башкортстан Республикасының Чакмагыш районы Аблай авылында туа. Аблай урта мәктәбен тәмамлаганнан соң 1974–1979 елларда Башкорт дәүләт университетының филология факультетында укый. 1979–1982 елларда Башкортстанның Дүртөйле районы Чишмә сигезьеллык мәктәбендә, 1982–1992 елларда Чаллы шәһәре мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта.*

*1992 елдан Чаллы дәүләт педагогика институтында эшли.*

*1994–1998 елларда читтән торып, Казан дәүләт университетында аспирантурада укый. 1999 елда профессор Ф. С. Сафиуллина җитәкчелегендә «XX гасырның 80–90 елларында татар әдәби теле лексикасы үсеше» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.*

*Башка милләт балаларын татар теленә өйрәтү өчен төзелгән программа һәм дәреслекләр язуда катнаша, 2 нче һәм 8 нче сыйныф өчен төзелгән дәреслекләрнең автордашы.*

*«XX гасырның 80–90 елларында татар әдәби теле лексикасы» дигән монография, берничә программа, 4 методик кулланма, 50 ләп фәнни-методик мәкалә авторы. Доцент.*

*Соңгы елларда татар шигыре поэтикасын өйрәнә.*

*Рәзинә Мөхиярованың өч шигырь җыентыгы дөнья күрде: «Сиңа булсын җырым» (Чаллы, 1997), «Шәмдәлләрдә утлар» (Чаллы, 2001), «Учларымда утлы күмер» (Казан: «Мәгариф», 2002).*

*Шигырьләре шулай ук Татарстан һәм Башкортстан матбугатында даими басылып тора.*

*Рәзинә Мөхиярованы Татарстан Язучылар берлегенә Чаллы оешмасы тәкъдим итте (рекомендация бирүчеләр: Факил Әмәк, Әхсән Баянов, Рәшит Бәшәр).*

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең быелның 30 апрелендә узган җыелышында Мөхиярова Рәзинә Хайбрахман кызы Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.*



# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## «ТАТМЕДИА» АГЕНТЛЫГЫ ТӨЗЕЛДЕ

Президент Минтимер Шәймиев гаммәви коммуникация чаралары буенча Татарстан Республикасының «Татмедиа» агентлыгын төзү турындагы Указга кул куйды.

Әлеге агентлык Татарстанда мәгълүматның гражданнар өчен ачык булу принцибын гамәлгә ашыру, аларның мәгълүматка хокукларын яклау, дәүләт хакимияте органнары һәм җәмгыять арасында нәтиҗәле үзара хезмәттәшлек урнаштыру, милекнең төренә бәйсез рәвештә гаммәви мәгълүмат чараларын, нәшрият һәм полиграфия эшчәнлеген тагын да үстерү, шулай ук гаммәви мәгълүмат чаралары үстерү өлешендә мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә 2003–2007 елларга Татарстан дәүләт сәясәте нигезләрен гамәлгә ашыру максатында оештырыла. Указда «Татмедиа»ның төп бурычлары күрсәтелгән, Татарстан Министрлар Кабинетына әлеге агентлыкны төзү буенча бурычлар билгеләнгән.

Шушы уңайдан Татарстан Министрлар Кабинетында үткәрелгән матбугат конференциясендә вице-премьер Зилә Вәлиева әлеге агентлыкның дәүләти, иҗтимагый һәм социаль функцияләрне үтәячәген әйтте. Шуна күрә ул туры мәгънәсендәге дәүләт идарә органы булмаячак. Ана республика медиа-базар инфраструктурасын камилләштерү бурычы йөкләнә. Ә бу исә медиа-базарның барлык субъектлары белән бергә эшләү дигән сүз. Бу уңайдан З. Вәлиева моңа кадәр булган эш формасының искерә төшүе турында әйтеп узды. Яңа төзелгән агентлык медиа-базарда катнашучыларның барысына да дәүләт заказын үтәү хокукына ия булу мөмкинлеге бирәчәк. Моннан тыш, дәүләт элеккечә үк мәгариф, мәдәни функцияләрне үтәүгә юл тоткан гаммәви мәгълүмат чараларына ярдәм итәчәк. Яңа агентлык нәкъ менә шушы яктан медиа-базарның барлык субъектлары өчен дә кызыктыргыч булып әверелергә мөмкин. Кыскасы, «Татмедиа» дәүләткә үзенең мәгълүмати сәясәтен нәтиҗәләрәк үткәрүгә ярдәм итүче эш коралы булачак.

* * *

Татарстан Республикасы Президентының 2003 ел 12 майдагы Указы нигезендә «Татмедиа» массакүләм коммуникация чаралары буенча Татарстан Республикасы агентлыгы генераль директоры итеп Моратов Марат Яшәр улы билгеләнде.

Моратов Марат Яшәр улы 1965 елның 6 июлендә Киров өлкәсенең Кирово-Чепецк шәһәрендә туган. Журналистлык белгечлеге буенча Казан дәүләт университетын тәмамлаган.

Армия хезмәтеннән соң 1986 елдан 1991 елга кадәр Казан шәһәрендә «Союзнефтепромхим» фәнни-житештерү берләшмәсендә оператор булып эшли. 1991-1992 елларда «Казанский телеграф» газетасында мөхәррир урынбасары вазифасын башкара. 1992-1993 елларда «Фатум» чикләнгән җаваплылыктагы ширкәте директоры, 1994 елдан 1998 елга кадәр «Сигма Плюс» ТД ябык акционерлык җәмгыяте директоры урынбасары. 1998 елдан Түбән Кама шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары булып эшли.

14 майда Татарстанның массакүләм мәгълүмат чаралары житәкчеләрен һәм Россия газеталарының үз хәбәрчеләрен «Татмедиа» массакүләм коммуникация агентлыгы генераль директоры итеп билгеләнгән Марат Моратов белән таныштыру булды. Яңа житәкче белән ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева таныштырды.

## ЯЗДАН АЕРЫП БУЛМЫЙ ТУКАЙНЫ

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган шигърият бәйрәме, һәр елдагыча, республика күләмендә зурлап үткәрелде. Шушы уңайдан мәктәпләрдә, мәдәният сарайларында, театрларда да күп төрле чаралар оештырылды.

26 апрель көнне иртән бер төркем татар әдипләре Яңа Бистә зиратында Габдулла Тукай, шулай ук Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев һ. б. күренекле каләм әһелләренең каберләрен зиярәт кылдылар. Аннары башкалабызның 1 Май мәйданындагы Муса Җәлил һәм җәлилчеләр, опера һәм балет театры бинасы янындагы Габдулла Тукай, Александр Пушкин һәйкәлләренә, үзәк мәдәният һәм ял паркында Һади Такташ, Галиәсгар Камал, Фәхри Әсгать, Шәһит Әхмәдиев һ. б. ларның каберләренә чәчәк салынды.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда оештырылган төп тантананы

Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачты, һәм 2003 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында Татарстан Президенты Указын игълан итте. Аннары яңа лауреатлар: музыкант Рөстәм Абязов һәм язучы Мөсәгыйт Хәбибуллиннар чыгыш ясады.

Шигъри митингны Галимҗан Гыйльман алып барды. Анда шагыйрьләрдән Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗан, Рәдиф Гаташ, Харрас Әюп, Лена Шагыйрьҗан, Илдус Гыйләҗев, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Роза Кожевникова, Флера Тарханова, Рифә Рахман, Лилия Газизова, Җәүдәт Сөләйман, Мөхәммәт Мирза, Рәшит Ягъфәров, Луиза Янсуар, Рәмис Аймәт һ. б. чыгыш ясады.

Шигърият бәйрәмендә Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе Разил Вәлиев катнашты.

* * *

Соңгы елларда Г. Тукайның туган төбәге Балтач районында да киң билгеләп үтелә башлады. 25 апрель көнне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин җитәкчелегендә бер төркем әдипләр бөек шагыйребезнең әнисе Бибимәмдүдә абыстайның җәсәде яткан Сасна Пүчинкәсенә сәфәр тотты. Ана барышлый кунаклар Балтач районы үзәгендә үткәрелгән Шигърият бәйрәмендә катнаштылар. Балтачлылар алдында Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәдиф Гаташ, Мәдинә Маликова, Харрас Әюп, Тукай җәмгыяте рәисе Хатыйп Миннегулов, Җәүдәт Дәрзаман, Галимҗан Гыйльман, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Нәҗибә Сафина, Җәүдәт Сөләйман, Луиза Янсуар һ. б. чыгыш ясады. Аннары каләм әһелләре район мәдәният сараенда мәктәп үзешчәннәре тарафыннан әзерләнгән концертны карадылар, Сасна Пүчинкәсендә шагыйрь әнисенең каберен зиярәт кылганнан соң, Чепья туган як музее белән таныштылар. Балтач үзәгендә үткәрелгән бәйрәмдә район хакимияте башлыгы Марат Зарипов катнашты.

* * *

Күп еллардан килә торган күркәм гадәт буенча, Шигърият бәйрәме эстафетасын 28 апрельдә Габдулла Тукайның туган төбәге Арча районы кабул итте. Иң әүвәл Арча вокзалында Габдулла Тукай бюстын (скульптор Нәүфәл Адылов эше) ачу тантанасы булды. Аннары вокзал мәйданында Шигърият бәйрәме үткәрелде. Шуннан соң кунаклар Кушлавыч авылында шагыйрьнең әтисе Мөхәммәтгарифнең каберен зиярәт кылдылар. Тукаевларның музей-йортында мәктәп укучылары белән очраштылар. Тукай-Кырлайдагы тантана исә бәйрәмнең таҗы булгандыр. Бәйрәм чаралары Арча педагогия колледжында әдәби-музыкаль кичә белән тәгәлләнде. Арчалылар белән очрашуларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Тукай бүләгенең быелгы лауреатлары: музыкант Рөстәм Абязов, язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин, шулай ук әдипләр Туфан Миннуллин, Мәдинә Маликова, Радик Фәизов, Зиннур Мансуров, Флера Тарханова, Мөхәммәт Мирза, Наилә Ахунова, Рәдиф Сагъди, Тукай җәмгыяте рәисе Хатыйп Миннегулов, Луиза Закирҗанова (Чиләбе) һ. б. лар катнашты. Кунакларны Арча районы хакимияте башлыгы Алмас Нәзиров озатып йөрде.

## ЭЛЕМТӘЧЕЛӘР БӘЙРӘМЕ

Татарстан Элемтә министрлыгы 8 майда үзенең 10 еллыгын билгеләп узды. «Казан» милли мәдәният үзәгенә тиз үсүче шушы өлкәнең барлык тармак вәкилләре җыелды. Моннан 10 ел элек Татарстан Россиядә телефонлаштыру буенча иң артта калган төбәкләрнең берсе булса, бүген ул Россиянең алдынгы төбәкләреннән санала. Аның 1 миллион 340 мең телефоны, Интернеттан 100 мең файдаланучысы бар. Халыкка хезмәт күрсәтү елдан-ел камилләшә бара: яңа элемтә челтәрләре булдырыла, эшчеләрнең профессиональ осталыклары арта, эш шартлары яхшыра... Бүгенге көндә автомат шәһәрара һәм халыкара телефон элемтәсе хезмәтләреннән республиканың иң ерактагы почмакларында да файдалана алалар, «Татарстан—Яңа гасыр» телеканалының барлыкка килүе, һичшиксез, казаныш булып тора. Ул тапшыруларны спутник элемтәсе аша алып бара.

Татарстан Элемтә министры Ринат Җәләлев тантананы ачканда бу уңышларга 25 мең кешелек дус коллектив тырышлыгы аркасында ирешелүен күрсәтеп узды. Аның котлау сүзендә район һәм шәһәр хакимиятләренә, партнер министрлыкларга, моннан ике ел элек Элемтә министрлыгы өлкәсенә кергән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә байтак җылы сүзләр әйтелде.

Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әгъзам Гобәйдуллин республика башлыгы Минтимер Шәймиев котлавын һәм шушы тармакның иң яхшы хезмәткәрләренә Татарстанның дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Юбилярларны ТР вице-премьеры Зилә Вәлиева һәм Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Мәһдиев котлады.

## ТАТАР ТАРИХЫ

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында «Татар тарихы» академик басмасының 1 томын тәкъдир итү кичәсе булды. Анда ТР Президенты М. Шәймиев, ТФАнең Тарих институты директоры Р. Хакимов, ТФА президенты М. Хәсәнов, татар тарихын өйрәнүдә тырышлык куйган галимнәр, китапның авторлар коллективы, журналистлар катнашты. Президент М. Шәймиев, яңа китап турындагы фикерләре белән уртаклашып, болай диде: «Безгә матур тарих түгел, ә чын тарих кирәк иде. Ниһаять, шушы хакыйкать дөньяга килде. Бу хезмәтне республикада яшәүче һәр кеше укырга,

белергә тиеш. Мин моны зур эшнең яхшы башлангычы дип бәялим».

Бу зур хезмәтнең «Дала Евразиясе халыкларының борынгы тарихы» дип аталган беренче китабы Россия Фәннәр академиясе профессоры С. Г. Кляшторный редакциясендә чыккан. Кичәдә мөхтәрәм профессор татар халкы тарихын өйрәнү һәм язуга тирән әзерлек белән һәм бик теләп алынуын әйтте.

7 томнан торачак бу академик басманы әзерләүдә Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Махачкала, Ижау фәнни-тикшеренү үзәкләре һәм тарихчы-тюркологлары да катнашачак. Китапны Тарих институты һәм «Рухият» фонды бергәләп әзерләгән. Спонсоры—«Девон-Кредит» банкы. Тиражы 10 мең данә.

## ИЛҺАМЛЫ ҖЫР ТАНТАНАСЫ

28 апрельдә татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге халыкара конкурсына йомгак ясалды. Йомгаклау бәйгесе С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында узды. Илһам Шакиров исемендәге халыкара җыр бәйгесенең йомгаклау концертында Татарстан Республикасыннан гына түгел, элекке СССРның, Россиянең дә бик күп төбәкләреннән яшь җырчылар катнашты. Алар арасында Башкортстаннан, Мари Иле, Чуашстан республикаларыннан, Ригадан, Оренбург, Сарытау өлкәләреннән, Баку, Омск, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдән килгән җырчылар да бар иде.

Җиңүчеләр арасында I премиягә Владимир Васильев һәм Элина Митина (Рига); II премиягә Илүс Гыйльманшин (Нефтекамск) һәм Сиринә Вахитова (Казан); III премиягә Марсель Вәгыйзов (Казан) һәм Алим Каюмовлар лаек булды. Конкурста катнашкан 12 кешегә лауреат исеме бирелде. Илһам Шакиров исемендәге бу мәртәбәле конкурста төп бүләкка—Гран-прига Башкортстан егете Илдар Хәкимов лаек булды. Ана бүләкне Президент Минтимер Шәймиев һәм Илһам Шакиров тапшырды.

Конкурста вокаль ансамбльләр дә катнашты. Татарстанның фольклор музыкасы дәүләт ансамбле I премиягә лаек дип табылды. Җиңүчеләргә дипломнар, акчалата премияләр тапшырылды.

Йомгаклау концерты бу зур конкурсның хуҗасы Илһам Шакировның «Туган тел» җырын башкаруы белән тәмамланды.

## «МӘГАРИФ» ЖУРНАЛЫ БӘЙРӘМЕ

28 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Мәгариф» журналы бәйрәме булып узды. Ул татар телендә дөнья күрә башлаган иң беренче фәнни-педагогик журналның 90 еллыгына багышланган иде. Анда Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары З. Вәлиева Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең «Мәгариф» журналы укучыларына, хезмәткәрләренә һәм авторларына котлавын тапшырды, редакция коллективын, аның авторларын һәм күпсанлы укучыларын бу олуг юбилей белән тәбрикләде. Шулай ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов, Татарстан Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комиссиясе рәисе Р. Вәлиев, Мәгариф министры Ф. Харисов, Элемтә министры Р. Җәләлев һ. б. үзләренең котлау сүзләрен һәм бүләкләрен ирештерделәр.

Журнал редакциясенә котлаулар Мәдәният, Эчке эшләр министрлыкларыннан, төрле районнардан, Мәскәүдән, республикабыздан читтәге кайбер өлкәләрдән дә шактый күп килгән. Журналның баш редакторы Ф. Шәрифуллин үзенең кыскача чыгышында Татарстан Республикасы житәкчеләренә, журналның күпсанлы укучыларына зур рәхмәт белдерде.

## ТАТАР ПЕН-КЛУБЫ—«КАЗАН УТЛАРЫ»НДА

17 апрельдә «Казан утлары» журналы редакциясендә Татар ПЕН-үзәгенең күчмә утырышы үткәрелде. Клуб әгъзалары журналның быел дөнья күргән саннары хакында фикер алыштылар. Басылып чыккан әсәрләргә күзәтүне язучы Рафаэль Мостафин ясады. Утырышта шулай ук бүгенге татар әдәбиятының үсеш юллары турында этрафлы сөйләшү булды. Бу темага Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миннуллин, «Казан утлары» журналының баш редакторы Равил Фәйзуллин, академик Миркасыйм Госманов, «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев, шагыйрьләр Гәрәй Рәхим, Нур Әхмәдиев һәм башка иптәшләр чыгыш ясады.

Иҗатында бүгенге сәяси вәзгыятьне, тарихи үткәнебезне ачык яктырткан, иҗтимагый хәрәкәттә актив катнашкан язучыларны бүләкләү өчен Татар ПЕН-клубы «Сүз иреге—ирекле сүз» дигән махсус диплом булдырган иде. Беренче номерлы дипломны язучы Зәки Зәйнуллинга бирергә карар чыгарылды.

Утырышта катнашучылар шулай ук «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарган «Татар акылы» китабы белән таныштылар.

«Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары, язучы Флүс Латыйфи бертавыштан ПЕН-клубка кабул ителде.

## ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Апрель аенда Әлмәт төбәгендә яшәүче язучыларның гомуми җыелышы булып узды. Анда оештыру эшләре каралды. Язучыларның Әлмәт бүлеге җитәкчесе Разим Вәлиуллин эшеннән азат ителде. Ул урынга язучы һәм шагыйрь, «Татнефть» АҖ карамагындагы «Хәзинә» газетасының баш мөхәррире Нур Әхмәдиев тәгаенләнде. Утырышта Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, аның урынбасары, язучы Галимҗан Гыйльманов катнашты. 30 апрельдә үткән идарә утырышында Нур Әхмәдиев Әлмәт язучыларының җитәкчесе итеп расланды. Ул 90 елларда бу җаваплы постта эшләп киткән иде инде.

## СҮЗНЕ ОЛЫЛАУЧЫ ЯШЬЛӘР

«Казан» милли мәдәният үзәгендә нәфис сүз осталарының IV республика бәйгесен йомгаклау кичәсе узды. Әлеге бәйге февраль-март айларында районнарда дәвам итте, анда меңнән артык һәвәскәр катнашты. Ниһаять, Шигырь бәйрәменә якынлашып килгәндә сүз тәмен, туган тел тәмен бик сизгер тоючы иң талантлы 60 нәфис сүз остасы Казанга җыелды. Башта алар Тукай музеенда көч сынашты, аннары җиңүчеләр "Казан" милли мәдәният үзәгендә чыгыш ясап, аларга кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

Үзешчәннәрнең осталыгын Татарстанның атказанган артисты Флера Хәмитова җитәкчелегендәге жюри бәяләде. Балалар арасында иң оста шигырь укучы дип Түбән Камадан Айрат Ибраһимов табылды. Үзе иҗат иткән әсәрне укучылар арасында исә Актаныш кызы Лилия Гыйбадуллинага тиңнәр булмады. Иң яхшы шигырь укучы дип Балтачтан Ленар Алмаев, прозаны иң яхшы укучы дип Чистайдан Кадрия Абдуллина игълан ителде.

## ХӘТЕР ҺӘМ КАДЕР КИЧӘСЕ

Башкортстанның халык шагыйре, милләттәшебез Әнгам Атнабаевның тууына 75 ел тулды. Шушы уңайдан Уфада һәм аның туган ягында байтак кына мәдәни чаралар үтте. Шуларның иң зурысы халык шагыйренең туган көнендә Башкортстан дәүләт опера һәм балет театрында булды. «Хәтер һәм кадер кичәсе» дип аталган бу матур бәйрәмгә шагыйрьнең туган ягы Тәтешле районыннан зур гына вәкиллек тә килгән иде. Район хакимияте башлыгы Ф. Гайнаншин мәшһүр якташлары хакында җылы сүзләрен җиткерде һәм халык шагыйренең истәлеген мәңгеләштерү буенча районда башкарыласы эшләр турында сөйләде.

Кичәдә Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Бикбаев чыгыш ясады. Ул Ә. Атнабаевның башкорт һәм татар әдәбиятларына калдырган зур әдәби мирасы хакында сөйләде. Хәтер кичәсе җыр-моң, спектакльләрдән өзекләр белән үрелеп барды. Мәгълүм булганча, Ә. Атнабаев оста драматург та иде. Аның пьесаларын күп кенә театрлар сәхнәләштерде һәм ул спектакльләр озак еллар зур уңыш белән барды. Кичәдә артистлар тарафыннан Атнабаевның шигырьләре дә укылды.

## ЯРСУ САБЫРЛЫКЛАР ИЯСЕ

7 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фәнис Яруллинның 65 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы кичә булды.

«Ярсу сабырлыкта уза гомер...» дип аталган әлеге кичәне Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Фоат Галимуллин ачып җибәрде.

Юбилярны котлап Президент Минтимер Шәймиев юллаган тәбрикләүне вице-премьер Зилә Вәлиева укып ирештерде.

Әдибебезне шулай ук Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Роберт Миннуллин, Баулы районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Нурислам Хәбипов, Әлмәт районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Ришат Әбүбәкеров, Ютазы районы хакимияте башлыгы Сирин Галиев һ. б. котлады.

Кичәдә артистлар башкаруында Ф. Яруллинның шигырьләре, аның шигырьләренә язылган җырлар яңгырады.

## РАУЛЬ МИРХӘЙДӘРОВ КИЧӘСЕ

Язучыларның Тукай исемендәге клубында Мәскәүдә яшәүче күренекле язучы Рауль Мирхәйдәровның Татарстан китап нәшриятында «Иртәләгән сагыш» исемле китабы чыгу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Кичә «Казан утлары» журналы инициативасы һәм Язучылар берлеге ярдәме белән оештырылды. Мәгълүм булганча, язучының татар телендәге (тәрҗемәчесе—Марс Шабаев) әсәрләре иң әүвәл «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Кичәдә Р. Мирхәйдәров иҗаты турында язучыларыбыз Флүс Латыйфи, Харрас Әюп, Тәлгат Галиуллин, Марс Шабаев, Лена Шагыйрьҗан, Нәҗибә Сафина һ. б. чыгыш ясады, сәнгать осталары автор әсәрләреннән өзекләр укыдылар, халык җырларын башкардылар.

Рауль Мирхәйдәров Казанда үткән иҗат кичәсенең истәлеге итеп «Казан утлары» журналы редакциясенә һәм Татарстан Язучылар берлегенә Тукайның зур форматта яхшы сыйфатлы итеп эшләнгән (рәссамы—Ш. Закиров) портретларын бүләк итте.

Кичәне Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин алып барды.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Алтын Урда.

*Уфа рәссамнары Илдар Гаянов һәм Рафил Кадыйров эше*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** әдәбият галиме Рифат Сверигин.

# ЯҢА КИТАПЛАР

ЛАТЫЙФИ Флүс. **Бәйсез этләрне атарга:** Роман-нәсер / **Bəysez etlərne atarğa**: Roman-nəser.—Казан: Мәгариф, 2002.—239 б. Тиражы—3000 данә.




Бу китап күренекле язучы, каләмдәшебез Флүс Латыйфига 60 яшь тулу уңаеннан басылып чыкты. Китапның башына «Сугыш елларында туган, әле бүген дә дөньяның төп йөген җигелеп тартучы замандашларыма багышлыйм» диелгән эпиграф куелуы да очраклы түгел. Бу әсәрдә ниләр бәян ителә соң?

Унике яшьлек малай авызыннан сөйләнгән бу вакыйгалар, балалар мәңге хәл итеп булмаслык санаган бу проблемалар беренче карашка көлкеле һәм мәзәк булып тоелырга да мөмкин. Ләкин алар артында үсмернең җәмгыятьтәге гаделлек һәм гаделсезлекнең сәбәпләрен аңларга, өлкәннәр арасындагы четерекле мөнәсәбәтләрнең асылына төшенергә, үзен шәхес буларак расларга омтылу ята. Гомумән, кеше һәм җәмгыять хакындагы фикерләрне фәлсәфи яссылыкка күчерә бару—Ф. Латыйфиның иҗат юлы, тоткан мәсләге ул. Бу әсәрне дә фәлсәфи-символик югарылыкка күтәрелгән, төрле әзерлектәге укучыга юнәлтелгән һәм берничә әдәби катламны берләштергән, үзенчәлекле, татар әдәбияты өчен яна күренеш дисәк, ялгыш булмас. Бәйсез кешедә генә зур хыяллар, олы максатлар булырга мөмкин, колларның хыял-максатлары канатсыз! Язучы бу әсәрендә кеше, буыннар һәм милләт фаҗигасен система һәм ул тәрбияләгән коллык психологиясе белән аңлата.

Китап эчтәлеге белән генә түгел, форма-шәкли яктан да игътибарга лаек: текст ике имлада—латин һәм кириллица графикасында басылган. Ахырында авторның тормыш һәм иҗат юлы турында этрафлы белешмә-мәкалә, басылып чыккан әсәрләренең библиографиясе бирелгән.

Басманың мөхәррире—**Н. Нотфуллина**, рәссамы—**Н. Хаҗиәхмәтов**.

Китап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру Комитеты ярдәмендә нәшер ителде.

Индекс 73210



Рифат Сверигин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)